НАБЕРЕЖНОЧЕЛНИНСКИЙ ГОСУДАРСТВЕННЫЙ ПЕДАГОГИЧЕСКИЙ УНИВЕРСИТЕТ
НГПУ

# Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын

# Жизнь люби, люби отчизну, всё, чем жив родной народ

Укытучылар һәм укучыларның эзләнү-тикшеренү, проект һәм иҗади эшләре Бөтенрәсәй форумы материаллары.

Материалы всероссийского форума

«КАЗАН (ИДЕЛ БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ» ФЕДЕРАЛЬ ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ ЮГАРЫ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕНЕҢ
ПСИХОЛОГИЯ ҺӘМ МӘГАРИФ ИНСТИТУТЫ
«ЯР ЧАЛЛЫ ДӘҮЛӘТ ПЕДАГОГИКА УНИВЕРСИТЕТЫ»
ФЕДЕРАЛЬ БЮДЖЕТ ЮГАРЫ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ МӘГАРИФ ИДАРӘСЕ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ МУСА ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ «1 НЧЕ ГИМНАЗИЯ» МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ

# Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын
# Бөтенрәсәй форумы материаллары

Түбән Кама
2025

**УДК 37.01**
С97

«Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү учреждениесенең психология һәм мәгариф институты, «Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты» федераль бюджет югары белем бирү учреждениесенең психолого-педагогик һәм махсус дефектологик белем бирү кафедрасы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының башкарма комитеты мәгариф идарәсе, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге «1 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе карарлары белән басыла.

Төзүчеләр:
1. Мөхәмәтшин Азат Габделхакович, педагогика фәннәре докторы, профессор, федераль бюджет югары белем бирү учреждениесенең «Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты» беренче проректоры;
2. Хәзрәтова Фирүзә Вакильевна, педагогика фәннәре кандидаты, федераль бюджет югары белем бирү учреждениесенең «Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты» психолого-педагогик һәм махсус дефектологик белем бирү кафедрасы мөдире;
3. Хөснетдинова Резидә Рөстәмовна, психология фәннәре кандидаты, федераль бюджет югары белем бирү учреждениесенең «Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты» психолого-педагогик һәм махсус дефектологик белем бирү кафедрасы доценты;
4. Шәрәфетдинова Зимфира Габдрахмановна, филология фәннәре кандидаты, федераль бюджет югары белем бирү учреждениесенең «Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты» башлангыч һәм мәктәпкәчә белем бирү теориясе һәм методикасы кафедрасы доценты;
5. Галимов Алмаз Мирзанурович, педагогика фәннәре докторы, профессор, федераль дәүләт автоном югары белем бирү учреждениесенең «Казан (Идел буе) федераль университеты» психология һәм мәгариф институтының мәгариф эшчәнлеге буенча директор урынбасары;
6. Шәймәрданов Шамил Фатович, педагогика фәннәре кандидаты, доцент, федераль дәүләт автоном югары белем бирү учреждениесенең «Казан (Идел буе) федераль университеты» психология һәм мәгариф институтының мәгариф эшчәнлеге буенча директор урынбасары;
7. Хәбибуллин Илнур Илдарович, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге «1 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең директоры;
8. Хәйруллина Гөлназ Рәшитовна, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге «1 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы;

9. Хәйруллина Гөлнара Илсуровна, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге «1 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең информатика укытучысы;
10. Сөнгатуллина Ләйлә Мөхәммәтовна, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге «1 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы;
11. Әпсәгыйтова Адилә Ильясовна, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге «1 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең математика укытучысы.

**С97 Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын.** = Жизнь люби, люби отчизну, всё, чем жив родной народ : (Укытучылар һәм укучыларның эзләнү-тикшеренү, проект һәм иҗади эшләре Бөтенрәсәй форумы материаллары. – Материалы всероссийского форума). - Түбән Кама : 2025. – 409 б.

Җыентыкта “Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын” Бөтенрәсәй форумында катнашучы укытучы һәм укучыларның доклад тезислары урын алды.
Җыентык материаллары гомуми белем бирүнең инновацион эшчәнлектәге төп аспектларын үз эченә ала: мәгарифкә яңалык өстәү, яңа педагогик технологияләр һәм методикалар кертү, укучыларның интеллектуаль-иҗади эшчәнлеген оештыру, инновацион педагогик проектларны һәм программаларны тормышка ашыру, мәктәп имиджын булдыру һәм уңай тәрбия мохите тудыру өстендә эшләү. Искәрмә: язмаларда автор орфографиясе һәм пунктуациясе сакланды.

Автор редакциясендә басыла

**УДК 37.01**

**Беренче бүлек. Укытучылар чыгышы.**

Аменова Эльмира Зөфәр кызы, Куприянова Диләрә Илнар кызы. Укыту-тәрбия эшендә мәктәп музееның роле 7
Ахметова Миләүшә Индус кызы, Яруллина Ләйсән Минсагыйть кызы. Укучыларда гражданлык һәм патриотик хисләр тәрбияләү 8
Бадреева Зөлфия Мирза кызы, Гайнетдинова Зәлфирә Рәшит кызы. Мәгариф учреждениеләрендә милли һәм мәдәни проектларны тормышка ашыру 11
Бахтегараева Айгөл Әлфис кызы. Балалар бакчаларында «Әти-әниләр клуб»лары аша киләсе буынга карата милли гореф-гадәтләргә карата мәхәббәт уяту-ватанпәрвәрлек хисләрен тәрбияләүнең бер өлеше 14
Вагыйзов Фәрит Яхъя улы, Харисова Чулпан Сәгыйть кызы. Милли традицияләр саклауда топонимиканың роле 16
Валиева Алия Ринат кызы, Валетова Елена Владимир кызы. Балалар бакчасында кече яшьтәге икенче төркемдә татар халык авыз иҗаты әсәрләре аша балаларның сөйләм телен үстерү 20
Валеева Ләйсән Мидхәт кызы. Укучыларда ватанпәрвәрлек хисләре тәрбияләү – һәрберебезнең бурычы (эш тәҗрибәсеннән) 42
Валиева Гөлназ Рәсим кызы, Фазылҗанова Лилия Рифкать кызы. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда гражданлык һәм патриотик хисләр тәрбияләүдә эш алымнары 45
Валеева Суфия Васил кызы. Шагыйрь Кадыйр Сибгатуллин иҗатында шәфкатьлелек мәсьәләләре 47
Гайнетдинова Зәлфирә Рәшид кызы, Шәрифуллина Алсу Илнур кызы. Әдәби әсәрләр аша яшь буынга патриотик тәрбия бирү 52
Галиева Энҗе Илһам кызы, Юнысова Гөлназ Рамир кызы. Уйный-уйный укыйбыз (телнең лексикасын һәм грамматикасын уеннар аркылы, проблемалы укытуга нигезләнеп, укучыларга җиткерү) 55
Галимова Гөлфинә Салихҗан кызы, Гыйздәтуллина Эльмира Мирзаһит кызы, 1 сыйныф укучыларында игътибарлылык тәрбияләү 58
Галәмова Гөлия Илгиз кызы. Үсеп килүче буынга патриотик белем бирүдә милли гореф-гадәтләрне саклауның роле 60
Гәрәева Айгөл Миншакир кызы, Шарафеева Рамия Әнәс кызы. Милли гореф - гадәтләрне саклау - укучыларга патриотик тәрбия бирү нигезе 62
Гарипова Лилия Рәүф кызы, Гарипов Рәсим Фаиз улы. Рисаләи Газизә - милләт сандыгы 65
Гәрәева Маһинур Абрам кызы. Туган тел дәресләрендә сәләтле бала шәхесе формалаштыру өчен шартлар 70
Гарифуллина Ләйсән Әнәс кызы. Этнографик компонентны дәрестән тыш эшчәнлек аша тормышка ашыру 73
Гыйзәтуллина Гөлнара Хамис кызы, Нуртдинова Гөлсинә Әсхәт кызы. Дәрестә һәм дәрестән тыш чараларда укучыларда патриотик хисләр тәрбияләүнең кайбер юнәлешләре 75
Гыймранова Илсөяр Гарәфетдин кызы. Сәләтле укучылар белән эшләү алымнары 78
Җәләлиева Ләйсән Равил кызы, Минҗанова Гөлсем Абделгазиз кызы. Үсеп килүче буынны тәрбияләүдә милли традицияләрне саклауның роле 81
Куряева Людмила Петр кызы. Мәктәптә патриотизм тәрбияләүдә милли традицияләрнең роле 83
Мәүлетова Ранилә Хәмәтгали кызы. XXI гасыр баласын тәрбияләүдә мәктәпкәчә белем бирү оешмасының роле 85
Минегалиева Ләйсән Ризат кызы. Дәрестән тыш эшчәнлектә функциональ грамоталылыкны үстерү 87
Мифтахова Эльмира Флүр кызы. Матурлык (Критик фикерләү технологиясе) 88
Мулламөхәмәтова Рәсимә Риф кызы. Кеше химия мохитендә 91

Насртдинова Гүзәлия Сәлимҗан кызы. Халык традицияләрен киләчәк буынга җиткерү 94
Низамеева Ландыш Фәрит кызы. ИКТны РАС белән авыручы балалар мәгарифендә куллану 96
Набиуллина Резеда Хәйдәр кызы, Садыкова Лидия Хәмдегали кызы. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә, дәрестән тыш эшчәнлектә патриотик тәрбия бирү 99
Сәгыйтдинова Рәсимә Наил кызы. Инглиз теле дәресләрендә милли гореф-гадәтләр һәм йолалар аша патриотик тәрбия бирү 101
Садыкова Сиринә Илсур кызы. Татар әдәбияты дәресләрендә укучыларда патриотизм тәрбияләү (Гариф Гобәй әсәрләрен өйрәнү мисалында) 104
Сахабиева Люция Заһит кызы. Үсеп килүче буынга патриотик белем бирүдә милли гореф-гадәтләрне саклауның роле 107
Сөнгатуллина Ләйлә Мөхәмәт кызы, Хәйруллина Гөлназ Рәшит кызы. Ф.Яруллинның "Кояштагы тап" әсәрендә намус төшенчәсе 117
Фалахиева Ильмира Ризатдин кызы, Миннегалиева Гөлназ Сәләхетдин кызы. Проект эшчәнлегенең өстенлеге 129
Фатхуллина Гүзәл Фәһим кызы, Халикова Нурсинә Далиф кызы. Укучының гражданлык үзенчәлеген формалаштыруда патриотик тәрбиянең роле 132
Хайруллина Гөлнара Илсур кызы, Апсагитова Әдилә Ильяс кызы. Дәрестә информацион технологияләрне куллану 134
Хәйрутдинова Фәридә Илнар кызы. Татарстан Бөек Ватан сугышы елларында 135
Хәйруллина Лилия Аркадий кызы. Функциональ грамоталылыкның компоненты буларак уку грамоталылыгы (эш тәҗрибәсеннән) 138
Хакимова Рәмзия Риф кызы. Туган тел дәресләрендә функциональ грамоталылык 143
Һадиева Сиринә Әсхәт кызы, Ильина Зоя Евдоким кызы. Сәхнәләштерү эшчәнлеге аша балаларның сөйләм телен үстерү 149
Хазиева Лилия Җәүдәт кызы, Хуҗина Эльза Айрат кызы. Яшь буынга патриотизм тәрбияләүдә милли традицияләрнең роле 151
Шайдуллина Миләүшә Рафаил кызы. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны патриотик тәрбияләүгә заманча якын килү 153
Якупова Венера Бәдертдин кызы. Патриотик тәрбия бирүдә милли традицияләрнең роле 154
**Икенче бүлек. Укучылар эшләре.**
**Төбәк тарихы, ономастика һәм топонимика** 158
Аскаров Адель. Әдип Маликовның “Яшьлек утравым” повестеның поэтик ономастикасы 158
Афанасьева Лиана. Хуҗиәхмәт Мәхмүтов – милләтем горурлыгы 168
Зиннәтуллина Рузилә. Туган авылым – чишмәләр иле 177
Ислямова Зарина. Авылымның данлы битләре (Болгар авылы тарихы) 183
Мансурова Алсу. Башкортстан Республикасы Бүздәк районы Каран җирлеге авылларының антропонимикасы 197
Сөнгатуллина Нәргизә. Татар халык әкиятләрендә мифопоэтик онимнар 206
Шәймәрданова Диләрә. Нинди кош син, Каз? 220
**Татар халкының Бөек шагыйре, журналист, хәрби корреспондент Муса Җәлилнең бай мирасы** 227
Муфтахов Ильяс. Түбән Кама шәһәрендә М. Җәлил һәйкәле тарихы 227
Харисов Азат. Дөньяны бары тик Тынычлык яшәтә, яшәртә! 234
Шәфыйкова Динә. Хыялланырга да курыккан вакыйга: Муса Җәлил премиясе лауреаты – скрипкачы Динә Закирова 239

**Тарих битләрен барлаганда. Халкымның гореф-гадәтләре** 247
Байгузина Айзилә һәм Инзилә. Курай моңы – халкым бизәге 247
Галеева Зарина. Минем гаиләм шәҗәрәсе 251
Гарипов Раяз, Ибраһимов Әмир. Чәй – шифалы эчемлек 254
Кадыйров Ихсан. Әлмәт мураллярында татар халкының тарихы һәм гореф-гадәтләре 259
Кәримова Аделина. Серле “40” саны 265
Мингараев Рияз. Туган ягы кирәк кешегә... 271
Шакирова Язиля. Гаилә – буыннарның өзелмәс чылбыры 282
Шәяхмәтов Камил. Коръән – могҗиза 288
**Фән дөньясында** 297
Абдуллина Алия. Сәмигулла Хәйретдинов – фән күгендәге йолдыз 297
Садыкова Рамилә. Дизайнда математиканы куллану 301
Хабибуллин Бәхтияр. Тәрбияче Шәвәли 305
Хайруллин Булат. ШӘКЛИ ФӘҺЕМ, ягъни ясалма интеллект татар телен саклау һәм үстерү өчен нишләргә кирәк дип саный? 312
Харисов Әмир. Кеше тормышында ырым, юраулар. Аларга ышаныргамы, юкмы? 315
**Авторлык эше: проза. Авторлык эше: поэзия** 321
Әлмөхәммәтов Әмирхан. Бабам сугышта катнашкан 321
Багаува Азалия. Тиен кызы Назлыкай турында әкият 321
Бадрутдинова Азалия. Һәр районның, һәр шәһәрнең була үз батырлары 322
Гараева Азалина. Җирдә сугыш булмасын... 324
Гыйззәтуллина Алисә. Балачагым. Биюче булам. Әбием догалары. Туган көн. 325
Нуриева Ләйлә. Килмәде. Төнге урам. Тәүге хисләр. Татар икәнеңне онытма! 327
Фәтхетдинова Нәзилә. Муса Җәлил – безгә маяк. Авылкаем. Гаиләм – җылы учагым. Шаян песи. 335
Шайдуллина Ильвина. Мәңге үлмәс, Муса, синең җыр! 337
Шайдуллина Чулпан. Тыныч яшәргә язсын! 339
Шакирянова Әмирә. Әнием минем 341
**Без онытмаска тиеш! Сугыш һәм тыл геройлары турында эзләнү-тикшерену эшләре** 342
Ахметвәлиева Зәринә. Бер солдат тарихы 342
Белодурова София. Туганнарымның хәрби юлы 347
Галиев Искәндәр. Г.Әпсәләмов хикәяләрендә батыр сугышчы образын тудыру алымнары, табигать образлары һәм тасвирлары 353
Гатиятуллин Сәид. Һәр заманның үз геройлары 361
Гыйлемханова Инзилә. Советлар Союзы герое Зәки Шаймарданов – нәселем горурлыгы 365
Гильфанова Равилә. Кеше бәхете 371
Фазлиева Ралина. Сугыш чоры баласы — гади укытучы 380
Һадиев Инзил. Мәңгелек хәтер 388
Хуҗиәхмәтова Ильвина. Батырлар исеме мәңгелек 393

## Беренче бүлек. Укытучылар чыгышы.

*Аменова Эльмира Зөфәр кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «22 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*Куприянова Диләрә Илнар кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге «1 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең инглиз теле укытучысы*

### Укыту-тәрбия эшендә мәктәп музееның роле

«Музей – кешелек, халык, милләт хәтере генә түгел, ә музейга килүчеләргә педагогик йогынты ясау чарасы да»

(В.Старцев «Музей педагогикасы турында»)

Бүгенге көндә мәктәп алдында гаять зур бурычлар тора. Конкуренциягә сәләтле, заман таләпләренә туры китереп, патриотик рухлы һәм физик яктан камил шәхес тәрбияләү – төп бурычларның берсе.

Патриотик тәрбия - ул балаларны Ватанның лаеклы уллары, кызлары итеп тәрбияләү. Укучыларда туган илгә мәхәббәт, халкыбызның истәлекләрен хөрмәт итү, бүгенгесенә ихтирам һәм горурлык хисләре, милли үзаң тәрбияләүдә, укучыларга патриотик тәрбия бирүдә мәктәп музейларының роле бик зур. Музейлар туган якның тарихын өйрәнү, якташларыбызның якты истәлекләрен саклап калу, аны буыннан-буынга җиткерү һәм укыту-тәрбия эшендә зур ярдәмлек булып торалар. Мәктәп һәм музей киләсе буында патриотик хисләр тәрбияләүдә бербөтен тәрбия үзәге булып тора.

Мәктәп музеен  укыту-тәрбия учагы дип әйтә алабыз, чөнки барлык җыелган материал укучыларның һәм укытучыларның үз куллары белән эшләнгән, тәртипкә китерелгән һәм алар дәресләрдә бик кадерле, кызыклы күрсәтмәлелелек ролен үтиләр. Мәктәптәге тарих, әдәбият, тел  дәресләренең күпчелеге музейда үтә. Үз халкыңның үткәнен бүгенгесен чагыштырып өйрәнү өчен мәктәп музее иң кулай урын. Һәр укытучы дәресләренең, сыйныфтан тыш чараларының эчтәлеген баету өчен, үз халкының миллилеген саклаган һәрбер нәрсәдән файдаланырга тырыша. Чөнки мәктәп музееның бай материалын уку-укыту процессында һәрдаим кулланырга мөмкин. Каядыр барасы һәм чыгымнар турында уйлыйсы юк, дәресләреңә кирәкле әзер материал кул астында. Музей

эшчәнлеге укучылар үзидарәсенең эшчәнлегенә әверелә, укучыларны эзләнү-тикшеренү эшчәнлегенә тарта. Һәрбер укучы да музейга үзеннән өлеш кертә. Кайсы укучы – үзенең сугышта катнашкан яки сугыш вакытында тылда хезмәт иткән туганының фотосын, сугыш кырларыннан исән-сау кайткан бабайларының хатирәләрен язып килә.

Алар бу өлкәдә танып-белү даирәсен киңәйтә, үзен компетентлы шәхес итеп тәрбияли. Менә шуңа күрә без әдәбият дәресләренең кайберләрен, бигрәк тә Бөек Ватан сугышына багышланган әсәрләрне үткәндә, мәктәп музейларында үткәрүне күпкә уңышлырак та, файдалырак та дип саныйбыз. Музейның бай материалын укытучылар дәресләрдә һәм дәрестән тыш чараларда, балалар белән фәнни-тикшеренү конференцияләр һәм конкурсларга әзерләнгәндә куллана.

Мәктәп музее җыелган кыйммәтле әйберләр җыю урыны гына түгел, ә фәнни-педагогик эшчәнлек алып бару урыны да. Җыелган материалны эшкәртү вакытында дәресләргә дидактик ярдәмлек тә эшләнә.

Мәктәп музее – ул мәктәпнең дәвамы. Музейда үткәрелә торган һәр чара зур тәрбияви һәм танып-белү үзенчәлегенә ия. Чөнки милли традицияләргә нигезләнгәндә генә мәктәп үзенең тәрбияви һәм белем бирү бурычларын тулысынча үти ала.

*Ахметова Миляуша Индус кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 15 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*Яруллина Лейсан Минсагит кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 15 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең беренче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Укучыларда гражданлык һәм патриотик хисләр тәрбияләү

Туган тел – туган җир, Туган ил төшенчәләренең төп мәгънәсен бала аңына җиткерүче иң мөһим чара. Балаларга патриотик тәрбия бирү туган телдән һәм тәрбия чараларыннан башка мөмкин түгел. Баланың аңы үсү, белеме арту, чынбарлыкны танып-белүе һәм чын кеше булып тәрбияләнүе аның туган телен – ана телен белүенә бәйле.

Патриотик тәрбия бирү төшенчәсе киң мәгънәне аңлата, ягъни ул бала күңелендә Туган илнең табигатенә, туган йортына, туган авылына яки шәһәренә, халкының тарихына, аның мәдәниятенә мәхәббәт уятудан гыйбәрәт.

Әхлакый-патриотик тәрбиянең кирәкле шарты булып әти-әниләр белән үзара тыгыз элемтә тора. Үз гаиләсенең тарихына кагылу балада көчле эмоцияләр барлыкка китерә. “Сезнең гаиләдә һәм сезнең кул астында булачак гражданин үсә… Илдә нәрсә генә булса да, сезнең күңелегез һәм сезнең фикерегез аша ул балаларга барып ирешергә тиеш”, – дип яза күренекле рус педагогы А.С.Макаренко.

Укучыларга патриотик тәрбия бирү мәктәптә һәрвакыт игътибар үзәгендә тора.Ул иң элек укучыларда туган илгә һәм туган җиргә карата мәхәббәт тәрбияләүне, патриотизмны күздә тота.

Патриотизм нәрсә ул? Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә: “Патриотизм - ул үз иленне, халкыңны өзелеп ярату һәм үз Ватаның өчен армый – талмый көрәшергә әзер тору. Патриотизм-гасырлар буе тәрбияләнеп килгән тирән хис”- дигән мәгънәдә. Бүгенге көндә безнең алда торган мөһим бурычларның берсе – тормышка әзер булган, үз Ватанына чын күңелдән бирелгән Кеше,Гражданин һәм Патриот тәрбияләү.Ә кем соң ул патриот? Патриот – үзенең туган җирен, халкын, Ватанын сөюче, шулар өчен һәртөрле корбаннарга да әзер булган кеше.

Җәмгыятьнең мораль кризис кичерүе, әхлак нормаларының таркала баруы, игелек, мәрхәмәтлелек сыйфатларының кими баруы яшьләргә тискәре йогынты ясый. . Хәзерге балаларга совет чоры әсәрләрен, бигрәк тә патриотик рухта язылганнарыннарын аңлау кыенлашты. Ләкин җәмгыять ничек кенә үзгәрмәсен, кеше яхшы белән начарны, ак белән караны, бөеклек белән түбәнлекне аерырга, үз иленең гражданины, патриоты булып үсәргә тиеш. Чөнки бәхетле тормышны үз илебездә үзебезгә төзергә туры киләчәк.

Яшьләрне патриотик рухта тәрбияләүдә төп рольне укытучы үти. Укытучы – ул буыннарны тоташтыручы, белем биреп кенә калмыйча, укучыларга өлкән буыннарның рухи байлыгын җиткерүче дә, шәхес тәрбияләүче дә. Ә шәхес - җәмгыятебезнең җимеше. Җимешне өлгертер өчен күпме вакыт һәм көч кирәк: җирен йомшартып орлык чәчәргә, кибәргә бирмичә суын сибеп торырга. Заманча технологияләр никадәр генә алга китмәсен, күпме генә аларны мактамасыннар, барыбер укучыга рухи тәрбияне укытучы бирә.

Укучыларда гражданлык һәм патриотик хисләр тәрбияләү юнәлешләре:
а)республикабыз,туган ягыбыз тарихы, мәдәнияте турында мәгълумат бирү;
б)төбәктә яшәүче язучылар, сәнгать кешеләре белән очрашулар үткәрү;
в)халкыбызның гореф-гадәтләре,традицияләре белән тулырак таныштыру;
г)хезмәт һәм сугыш ветераннары белән очрашулар үткәрү.

Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк, диләр. Безнең бай тарихыбыз, мәдәниятебез, мәгарифебез, батыр, эшчән халкыбыз бар. Шәһәребезнең тарихы – халкыбыз тарихының аерылгысыз бер мөһим өлеше ул. Аларны өйрәнү, үзең яшәгән төбәк белән горурлану хисләре тәрбияләү – һәрберебезнең бурычы.

Без үзебезнең дәресләребездә һәм дәрестән тыш чараларыбызда патриотик тәрбия бирүгә зур игътибар бирергә тырышабыз. Туган ил тарихының һәрнәрсәгә, һәркемгә, шул исәптән үзләре яшәгән гаиләгә дә, кагылышлы булуын тирән аңлату, төшендерү кирәк. Шул максаттан укучыларга әби-бабайларының Бөек Ватан сугышы чорындагы тормышы белән кызыксындыру өчен сочинение язып килергә, нәсел шәҗәрәләрен төзеп килергә кушабыз.

Башлангыч сыйныфларда әлеге максатка ирешү өчен, яңа материал аңлатканда, диалоглар уздырганда, укучыларның белемнәрен тикшергәндә, Туган як турында җөмләләр, текстлар файдаланабыз . Өйдә эшләп килер өчен “Минем шәһәрем” темасына инша язу уңышлы бер алым дип саныйбыз. Рухи кыйммәтләребез үз төсен югалта, онытыла барган бу чорда туган якны өйрәнү шул максатка ирешү юлы булып тора һәм мөстәкыйль, ирекле, намуслы, үз Ватанының лаеклы улы яки кызы булырлык шәхес тәрбияләргә ярдәм итә. Шул максаттан чыгып,без укучыларда милли тарихыбызга, туган телебез һәм әдәбиятыбызга, мәдәниятебезгә мәхәббәт тойгысы, үз халкың белән горурлану хисләре, аның тарихын, уңай гореф – гадәтләрен, традицияләрен өйрәнү белән кызыксындыру шикелле сыйфатлар булдыруны күз алдында тотабыз. Һәр дәрес, класстан тыш чаралар патриотик тәрбия бирү мәктәбе булырга тиеш

Безнең мәктәбебездә күп еллардан бирле Юнармия төркеме эшләп килә. Без кайбер класстан тыш чараларны, тәрбия сәгатьләрен төрле шәһәр музейларында үткәрү гадәтен алдык. Ветераннар белән очрашу чараларын шулай ук үткәрергә тырышабыз. Балалар ветераннардан сугыш турында күп мәгълүмат алалар, алар белән әңгәмә коралар. Ил өчен барган аяусыз көрәш барганда да, Ватаныбызга булган чын ярату, Ватан өчен көрәшнең изге, хак булуына ышанудан көч алып җиңүгә ирешкән ветераннар яшь буында патриотизм, гражданлык хисләре уяталар.

Шулай итеп, бүгенге авыр, катлаулы чорда әдәпле һәм итагатьле патриот шәхес тәрбиялим дисәң, эшне, балага кечкенәдән үк туган ягы, халкы тарихын өйрәтүдән башларга кирәктер.

*Бадреева Зөлфия Мирза кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 16 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле инглиз теле укытучысы,*
*Гайнетдинова Зәлфирә Рашит кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 16 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең беренче категорияле директорның уку эшләре буенча урынбасары*

**Мәгариф учреждениеләрендә милли һәм мәдәни проектларны тормышка ашыру. Сәләт мохите - АКЫЛ, РУХ һәм ТЕЛ берлеге!**

27-30 июнь көннәрендә Сәләтле балалар беренче сменага - ҺӨНӘРЛӘР БИЛӘР ФОРУМГА (Ремесла/Junior skills) җыелган иде! Мохит үзе тәрбияли диләр. Биләрдә безнең 16нчы мәктәп базасында урнашкан «Сәләт-Җиһан» клубының (https://vk.com/seletzhihan16) активистлары да катнашты.

Биләр Форум - гаҗәеп мохитле уникаль урын! Республикабызның төрле почмакларыннан килгән катнашучыларның танышу һәм дуслашу урыны. Бу масштаблы сменада Сәләт берләшмәсе Клуб лидерлары һәм безнең «Сәләт -Җиһан» активистлары да бар иде. Ул ел да «Изге чишмә» мемориаль комплексында, ягъни «Хуҗалар тавы»нда оештырыла. Биредә балалар салкынга бирешмичә, ата-бабаларыбызның тирән рухы булган җирдән үзләренә энергия җыя, изге чишмә суларыннан көч ала, Хуҗалар тавына менеп, канатлана! Сәләт Биләр Форум-беренче чиратта аралашу, яңа танышулар, дуслар һәм 24 сәгать саф һава.

Бу форум сәләтлеләрнең киләчәктә үз-үзләрен үстерүләре өчен яңа һөнәрләр өйрәнүенә багышланган иде. Анда төрле уен һәм мотивацияләүче дәресләр, остаханәләр узды, сәлкешләребез төрле белем өлкәләрен үзләштерде. Нейротехнологияләр; «Робоняша» робототехникасы Роботлар ясау һәм аларны JavaScript телендә программалаштыру; молекуляр биология; планерлар җыю; рәсем сәнгате, каллиграфия, химия; камил IT продукт, шәм, кәгазь, барельеф ясау; эксперименталь фән, фешн-иллюстрациядә татар дизайны һәм бердвотчинг - төп темалары булды.

Безнең мәктәптән 21 бала (1-8 нче сыйныфлар) катнашты. Алар арасында: фән олимпиадалары, конференцияләр һәм иҗади фестивальләрнең җиңүчеләре һәм призерлары, югары уку нәтиҗәләре буенча сайлап алынган балалар. Әлеге сменада укучыларыбыз үзләрен төрле өлкәләрдә сынап карый алдылар.

Сәләтлеләребез төрле хан исемнәре белән аталган аланнарга бүленгәннәр иде. Мәсәлән, Кодрак Хан, Күлтәгин, Модэ, Алмас Хан, Илкам Хан, Атилла һ.б. Һәрбер аланның үзенә генә хас сөрәне (речевка) бар иде. Сәлкешләребез аны яттан өйрәнеп, һәрбер чара башлану алдыннан кабатлап, кем көчлерәк һәм кем матуррак бер-берсен сәламли, ярышкан сыман иделәр.

Сменаның һәр көне уку-укыту программасы, уеннар, спорт ярышлары һәм кичке чаралар белән үрелеп барды. Смена вакытында укучылар волейбол, шахмат, бура һәм бочче чемпионатларында, интеллектуаль турнирларда (ЧГК), джем-сессияләрдә, тотрыклы үсеш максатлары буенча уеннарда һәм башка күп кенә активлыкларда катнаша алдылар. «Бер, ике, өч, дүрт - Биләр супергуд!» интерактив кичәсе һәм Һәр сәлкеш зарыгып көтеп алынган чараларның берсе - дискәтүк беркемне дә битараф калдырмады. Сәлкешләр рәхәтләнеп биеде! Гомумән, сәләтлеләребезнең көн дә күңелләренә хуш килгән дәресләргә йөрделәр.

Сәләттәге радио ул аерым тема. Көн дәвамында Форум территориясенә махсус радио хәбәрләр ирештерелде, җыр-моңнар белән сөендерде. Балалар 7:30 - 20:00 Selet FM радиосын тыңладылар! Сәлкешләребездә «Хәерле иртә», «Хәерле көн», Сәләт гимны, «Ашарга, барабыз ашарга...», «Мин-Сәләт һәм бу җәен...», «Мин инде әзер, ә син әзерме...», «Ач күзләреңне - очарга вакыт җитте...», «Тыныч йокы...», Азнакай, Саба, Рухият, Раушан һ.б. аланнарның танылып, таралып киткән җырлар күңелләрендә мәңге истә калыр. Монда телисеңме теләмисеңме татар телен тыңлап кына да өйрәнә аласың.

Татар теле дигәндә, Сәләтнең бер низамәте (принцип) болай яңгырый: «СӘЛӘТ - мохитендә - Инглиз теле - ИПИ, рус теле - СУ, ТАТАР теле – ҺАВА». Иписез без 1-2 атна тора алабыз, сусыз 1-2 көн, ә һавасыз 1-2 минут. Татар теле безгә ҺАВА кебек кирәк. Сменаларда катнашу өчен татар телен камил белү мәҗбүри, булмаса да, бу форумнарда татар телле мохит тудырыла, тәрбия бирелә, мәдәни чаралар программалары туган телебездә үткәрелә.

Сменага килгән укучылар тулысынча татар мохитенә эләкте дияргә була: элмә такталардагы язулар, әйдаманнар белән аралашу, чаралар, радиодан яңгыраган җырлар - барысы да татар телендә. Уку-укыту чараларының да күп өлеше татар телендә узды. Сменаның соңгы көненә таба, берничә вакыт үтү белән, укучыларыбыз татар телендә сөйләшә, мәдәниятне аңлый башлады, күренекле шәхесләр белән танышты. Ә «Сәлкеш (сәләтле кеше). - әйдаман (әйдәп баручы) - башҗитәк» чылбыры ул – нинди дә булса

кыйммәтләрне башкаларга тапшыру гына түгел. Бу – бик мөһим кадрлар мәктәбе. Бу кадрлар – татар мәдәниятен үстерүчеләр, телне һәм тарихны белүчеләр. Белем бирү программасы 2 телдә алып барылды: рус һәм татар телләрендә. Ял итү өлеше татар телендә генә. Ә иң күңелле, кызу кичке чаралар Медиа Биләр Форумда

Традицион рәвештә форумда Эко-юнәлеш буенча активлык узды. Сменада табигатьне саклау һәм экологик шартларны яхшырту мәсьәләләренә багышланган мастер-класслар һәм практик дәресләр сериясе гамәлгә ашырылды.

Укытучылар өчен (безнең 16 нчы мәктәбеннән алар 3 иде) әйдәп баручы белгечләрдән махсус «Остаз» проекты булдырылды. Проект кысаларында әхлакый кыйммәтләр, мәктәпләр белән идарә итү һәм баланың шәхесен үстерү темаларына багышланган сессияләр һәм остаханәләр узды.

«Остаз»га өстәп, «16 нчы мәктәп» делегациясе «Сәләт» проектлары җитәкчесе Җәүдәт Сөләйманов белән очрашты. Түгәрәк өстәл кысаларында катнашучылар ике оешманың эшчәнлеге турында фикер алышты. Сменаның һәр көне уку-укыту программасы, уеннар, спорт ярышлары һәм кичке чаралар белән үрелеп барды. Смена вакытында остазларыбыз волейбол, шахмат чемпионатларында, интеллектуаль турнирларда, джем-сессияләрдә, тотрыклы үсеш максатлары буенча уеннарда һәм башка күп кенә активлыкларда катнаша алдылар.

Форумда «Җанлы Сәләт» турыдан-туры эфирлар студиясе эшләде. «Җанлы Сәләт» ярдәмендә һәр теләгән кеше, өеннән чыкмый гына да, форумның онытылмаслык мохитенә кушыла, Биләр җирендә барган вакыйгаларны, ата-аналарыбыз балаларын күзәтә ала. Трансляцияләр форумның ВКонтакте һәм YouTube официаль аккаунтларында алып барылды.

Смена мәктәп укучыларынахәзерге заман һәм киләчәк һөнәрләрен үзләштерү өчен яңа мөмкинлекләр тудыруга юнәлтелде. Смена программасы укучыларга кече яшьтән үк һөнәри юнәлеш бирүгә нигезләнде, уку-укыту чаралары гамәли-юнәлеш бирү форматында оештырылды. Ул укучының шәхес буларак үсешенә этәргеч бирә торган, практикага юнәлгән, уен, ярыш, вакыйга форматындагы дәресләрне үз эченә алды.

Форум Татарстан Республикасы Хөкүмәте, ТР Яшьләр эшләре министрлыгы һәм ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы ярдәме белән уздырыла.

*Бахтегараева Айгуль Альфис кызы,*
*Казан шәһәре Совет районының «Катнаш төрдәге билингваль тәрбия һәм белем бирүче 178 нче балалар бакчасы» муниципаль автономияле мәктәпкәчә белем учреждениесенең югары категорияле өлкән тәрбиячесе*

**Балалар бакчаларында «Әти-әниләр клуб»лары аша киләсе буынга карата милли гореф-гадәтләргә карата мәхәббәт уяту-ватанпәрвәрлек хисләрен тәрбияләүнең бер өлеше.**

«Бер канатым була туган телем,
Бер канатым була туган җирем».

Туган җир һәм туган тел. Һәр кешегә якын, кадерле һәм бер генә. «Кайда барсам, кайда торсам, нишләсәмдә, хәтеремдә мәңге калыр туган җирем»- дип язып калдырга бөек шагыйребез Габдулла Тукай.

Әйе, бөтен донья буйлап сибелгән татарларыбызның кыйблалары бер, ул- Татарстан. Рәсәйдә генә түгел, бөтен җир шарында уникаль дип саналган газиз Республикабыз. Ләкин, киләчәк буыныбыз үзебез туган төбәктә татар телендә сөйләшә, аның гореф-гадәтләренә тугры каламы ? Яисә чит төбәктә яшәүче татарлар берләшеп моңа күбрәк көч куямы? Бу сорау мине инде күптән борчый.

6 ел балалар бакчасында тәрбияче булып эшләп, хәзер бер ел өлкән тәрбияче булып эшләп, татар гаиләләренең дә үз балалары белән татар телендә түгел, рус телендә аралашу очраклары көннән көн күбәя генә баруына шаһит мин. Кечкенәдән үк туган телем, туган ягым дип йөргән Айгөлнең күңеленә тимәскә мөмкин түгел иде бу хәлләр. Елга бер туган тел көненә багышлаган чараларның гына әһәмияте булмавы да көн кебек ачык иде миңа. Балалар бакчасында 414 бала тәрбияләнә, бу ким дигәндә 800 әти-әни, әле әби-бабайларны чутламаганда. Ата-аналар җыелышында без сорау үткәрдек:

1. Татар телен саклап калу өчен үз гаиләмдә эш алып бара алам дип әйтә аласызмы?
2. Бу мәсьәләдә балалар бакчаының ярдәме кирәк ме ?
3. Милли темаларга багышлган чараларга йөрер идегез ме?
4. Нинди юнәлеш сезгә кызыклы булыр иде?

Беренче сорауга бары тик 30% ата-ана гына «әйе» дип җавап калдырган иде. Икенче сорауга 72% «әйе» диде, өченче сорауга «вакыт булганда» диючеләр күпкә күберәк иде. Дүртенче сорауга килгәндә, әниләребез өчен күберәк «иҗади кич»ләр кызыгырак булса, этиләребез, әлбәттә, спорт дип җавап кайтарды. Җавапларга анализ ясап, без бакчабызда милли тәрбия буенча «әти-әниләр клуб»ы ясарга булдык. Кич белән эштән соң балаларыбызны иң кадерле кешеләре белән бергә бакчабызда җыеп, милли тәрбия бирү өстендә эшли башладык. Бу проект эшен ике юнәлештә алып барырга булдык:

1. Татар халкының гореф-гадәтләрен саклап калу буенча;

2. Купмилләтле Республикабызның төрле милләт вәкилләре йөргән балалар бакчасы буларак Идел буенда яшәүче халыкларны өйрәнү.

Һәр кешегә үз милләте якын, үз туган теле матурырак яңгырый, үз гореф-гадәтләре купкә кыйммәтерәк. Татарстаныбызда яшәүче төп халыкларны: татар, рус, башкорт, удмурт, чуаш, мордва, марый һәм бакчабызда милләт вәкилләре буенча өченче урында торагн таджик халкын алдык. Сигез милләтне сигез айга бүлдек. Бер ай эчендә, тәрбиячеләребез балалар белән бер милләт вәкилен өйрәнде- йолаларын, җыр-бию, ашсу белән таныштылар. Әти-әниләр бик теләп мастер-класслар үткәрде. Проектның тәмамлау өлеше булып бакчабызда «Халыклар дуслыгы» бәйрәме узды. Безнең бу чара хакында хәтта Яр Чаллы шәһәренең «Көмеш кыңгырау» гәҗите язып чыкты.

Ә татар халкының милли гореф-гадәтләре өйрәнүгә килгәндә, без әти-әниләребез белән айга бер тапкыр кичке уенга җыелдык:

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Сентябрь | Татар милли бизәкләре кулланып чигү чигү |
| 2 | Октябрь | Әтиләр өчен «Татарча футбол» турниры |
| 3 | Ноябрь | «Аулак өй» |
| 4 | Декабрь | «Каз өмәсе» |
| 5 | Январь | Гипстан милли орнамент белән тәлинкә ясау |
| 6 | Февраль | Муса Җәлил иҗатына багышланган түгәгрәк өстәл |
| 7 | Март | «Җырлыйк әле» татар халык җырлары өйрәнү |
| 8 | Апрель | Татар халык ашсулар мастер-класс |
| 9 | Май | Йомгаклау концерты |
| 10 | Июнь | «Сабантуй» |

Июль аенда без эшебезгә нәтиҗә ясап, эти-әниләр белән янәдән сорау үткәрдек.

Телебезне, милләтебезне, гореф-гадәтләребезне саклап калуда «Әти-әниләр клуб»ы булдыру үзенең әһәмиятен күрсәтте. Бакчабызда тәрбияләнүче балаларның татар теленә карата кызыксыну арту безне сөендерде. Нәтиҗәләргә шатланып, канатланып, без, әлбәттә, бу эшне бу елны да дәвам иттек.

Һәр сабый үз милләте, теле белән горурланып, аның гореф-гадәтләрен саклап калсын иде дигән өмет белән яшибез. Чөнки без- бик бәхетле халык! Безнең бүгенге көндә күпне күреп, күп сынаулар аша үткән,сөйләшергә яраткан татар телебез, тыңларга моңлы бырларыбыз, тотарга динебез бар.

*Вагыйзов Фарит Яхъя улы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 11 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең беренче категорияле туган тел һәм әдәбияты укытучысы,*
*Харисова Чулпан Сәгыйть кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 11 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең, беренче категорияле география укытучысы*

## «Милли традицияләр саклауда топонимиканың роле»

Патриотизм тәрбияләүдә туган як тарихын өйрәнү бик мөһим. Туган якка мәхәббәт беренче чиратта үзеңнең шәһәр һәм авыл исемнәрен, туган төбәк атамаларының тарихын өйрәнүдән башлана. Язучы Константин Паустовский әйткәнчә: «Исемнәр халыкның характеры, аның тарихы, һәвәслеге һәм көнкүреш үзенчәлекләре турында сөйли». Географик атамаларның килеп чыгышын ачыклау, аларның формасы, мәгънәви озату белән шөгыльләнүче фән «топонимика» дигән грек сүзе белән күрсәтелә, аның нигезендә **топо -** «урын» һәм **оним** - «исем» сүзләре ята. Милли традицияләрне торгызу төбәкне өйрәнүдән башка мөмкин түгел, ә аның юнәлешләренең берсе - топонимика.

Борын заманнарда Актаныш районы урнашкан җирләрдә кара урманнар булган. Аю, Бурсык, Кабан, Куян, Җылан, Әтәч һ.б. авыл исемнәренең атамалары моны раслый. **Актаныш** атамасының килеп чыгышы турында берничә фараз бар. Бер версия буенча Актаныш төрки-татар шәхси исеменә (антропонимга) барып тоташа һәм ике тополексемадан тора: кушымта. ак - » ак " + асыл. таныш - » таныш", ягъни ак (бәхетле) таныш (кеше). Икенче версия буенча, Актаныш ойконимы ике компоненттан ясалган: акты фигыле - «агып чыккан» + инеш гидронимы - «елга». Актаныш атамасы, безнең карашка, фин-угро-самодий чыгышлы, ике топонимнан тора: акта + ныш. Актның беренче компонентын фин-угор гидронимы: манс белән бәйләү мантыйкка ярашлы. “ахт” - күлдән (картлыктан) агып чыккан инеш", хант. огата - "течь”,«огсем - » ручеек, ключ, родник", Хант. ох (ы) т, охггт - «волок», вепс. "карчык", “Ий – елга” – эвенклар телендә, коми-пермяцкийда “нютша “- дымлы, чи, кипмәгән урын.

**Такталачык** топонимы барлыкка килүе турында түбәндәге риваять сакланган. Башта күчмә башкортлар кечкенә елга янындагы зур аланлы урманга килеп урнашалар. Алар урман кисү белән шөгыльләнгәннәр һәм башта үзләре өчен кечерәк кенә корылма:

алачык яки шалашлар төзегәннәр. Алар такталардан - берничә өлешкә ярылган бүрәнәләрдән була. Бу урынны "Такта +алачык" дип атый башлыйлар.

**Богады авылына** XVII гасырда нигез салына. Бу хакта җирле риваятьтә түбәндәгечә хикәяләнә: «Богады авылы Башкортстандагы Каңгы Богады дигән авылдан килеп чыккан. Бу авылда ике бертуган ир бала яши. Бервакыт боларның әниләре кайдандыр бик кыйммәтле әйбер табып алып кайта. Әниләре кечесен ярата төшә, шуңа күрә әйберне дә кече улына бирә. Мөмешмөхәммәт исемле олы улы үпкәләп, «КаңгыБогады»сыннан чыгып китә. Ул агач кисеп сал ясый да, Караидел буйлап Агыйделгә төшә. Аннан Бурсык авылына килеп туктый. Шәбез елгасы буйлап җәяүләп китә. Такталачык авылын да үтә.Елгадан йомычка агып килүен күрә дә, монда кеше яшидер, дигән уй белән, су буйлап Гәрәй авылына күтәрелә һәм шунда яши башлый. Вакытлар узгач, бу егет Гәрәй байның кызына өйләнә. Гәрәй бай хәзерге Яңа Богады, Иске Богады урнашкан җирләрне биләгән була һәм ул аларны киявенә бүләк итә. Мөмешмөхәммәт хәзерге Иске Богады җиренә гаиләсе белән килеп урнаша һәм үз авылының «Каңгы» исемен төшереп калдырып, аны Богады дип кенә атый».

Актаныш районында гидронимнарның бик күбесе **Агыйдел** елгасына кушылучы елгалар белән бәйләнгән. Бер версия буенча Агыйдел (Белая) елгасы көньяктан, кояштан аккан атаманы алган, шуңа күрә "якты", "ак". Икенче версия буенча анда эретелгән известь күп булу сәбәпле ак төстәге су дип атыйлар.

**Шәбез -** Агыйдел елгасының сулъяк кушылдыгы. Озынлыгы 35 километр. Агыйдел елгасына Такталачык авылыннан 3 км көньяк-көнчыгышта килеп кушыла."Шәбез" гидронимы "чишмә башлангычы" сүзтезмәсе белән бәйләнгән. "**Ыштанчык елгасы**" гидронимының килеп чыгышы халык риваятенә нигезләнгән. Авылдашлар сөйләве буенча, бик күптән инде, су буенда коенганда, җирле крестьян чалбарын югалткан һәм яр буенда озак кына "ыштан, чык!" дип кычкырып йөргән.

**"Күпер колагы"** гидроним да Шәбез елгасы белән бәйле. Исеме «күпернең колагы» дип тәрҗемә ителә. Элек аулак урында урнашкан, печәнлек вакытында гына кулланылган зур булмаган агач күпер су басу зонасына эләккән һәм хәзер су астына яшерелгән.

**Шәбез тамагы** гидронимы конкрет географик урынны - Шәбез елгасы тамагын аңлата. Ягъни Агыйдел белән кушылу урыны.

**Иске Идел** дип Агыйделнең зур утрау белән аерылып торучы елга култыгы атала.

**Шарлама** - Шәбез елгасы тугаендагы ермак, «шарлама» төркичә «шарлама», ул «шарпад, агым» дигәнне аңлата.

Актаныш районында көнчыгыш ягында гидронимнар икенче зур елга – **Сөн** белән бәйле. Академик Гомәр Саттаров "Сөн" (Шон, шун) атамасын бик борынгы дип саный һәм

моннан меңнәрчә ел элек безнең төбәктә яшәгән гун кабиләләре белән бәйли. (Татарстанда шулай ук Мамадыш районында “Сөн” топонимнары күп таралган). Манси халыклары “Сөн” дип күп балыклы, үрдәкле елгаларны атыйлар икән.

**Биҗады елгасы** – Сөннең сул кушылдыгы. Елга башы Югары Богады авылыннан 2,5 км көньяк-көнбатыштарак, тамагы Аеш авылыннан 2 км көнчыгыштарак. Гидроним антропонимик чыгышка –Актаныш ягында эле Баҗанай, Базит исемнәре киң таралган булган.

**Күҗәкә суы** Иске Байсар авылы янында Сөнгә коя. Удмупрт телендә “Күҗ” чокыр, чоңгыл, тирән урын дигәнне аңлата икән.

**Җылкыя суы** – шулай ук Байсар янында Сөнгә кушыла. Галимнәр фараз кылганча, “чылкыи” сүзе фин-угор телләренә нигезләнгән, удмуртча “чиста”, “пөхтә” мәгънәдә кулланыла. Шунды ук сүз Калмия һәм Сәкия елгаларының исемнәре килеп чыгуга бәйләнешле дип санала.

Зур елгалар янында Актаныш төбәгендә авылының тирә-ягында күлләр бик күп, бу төр топоминимнары галимнәр **лимноним** дип атыйлар..

**Кәрге күле**. Бу күл Агыйдел елгасыннан 500 метр ераклыкта, Бурсык авылыннан ерак түгел сазлыклы урында урнашкан. Төрки теленнән «карга» сүзе 1.карга (кош); 2. Урман, күл, топь; фин –угор телләреннән “сазлык”, “сазлык арасындагы калкулык” дип тәрҗемә ителә.

**Киндер күле** күптәнге заманда киндер тукыма (татар телендә киндер) әзерләгәндә, чималны сулыкларда чылатып эшкәрткәннәр. Картларның сөйләүләре буенча, бу күл бик тирән, урыны-урыны белән 7-8 дилбегә (15-20 метрга) җиткән. **Бәкелде күле** күленең исеме “бакылдый” фигыль сүздән килеп чыккан. Борынгы заманнардан бирле бу күлдә бик күп кыргый үрдәкләр яшәгән. **Чәйлекүл** исеменең килеп чыгуыда бик гади. Тирә-юньдә камышлар күп булганлыктан, мондагы сулыкның төсе һәрчак коңгырт төстә. Шунысы кызыклы, күл тирәсендә җирле халык чәйгә өстәргә яраткан хуш исле үләннәр(зәңгәр һәм сары мәтрүшкәләр) бик күп үсә. **Мүкле күл**: бу күлдә элек агач буралар төзегәндә кулланыла торган мүк табалар.

Авыл җирлегендә җир кишәрлекләренең исемнәрен - сөрүлекләрне, кырларны һәм башка җирләрне билгеләү өчен ***агроонимнар*** бар.

**Чәбе болыны** . Исеме татар телендәге «чабу» фигыленнән килеп чыккан, бу – печән чабу дигән сүз. Түбән Кама районында да шуңа ошаш топоним бар. Әмма галимнәр “Чабья” сүзенең удмурт телендәге «чабей» - бодай сүзенә катнашы бар дип фаразлыйлар, шулай ук бу сүз удмуртларның нәсел шәҗәрәсенә барып тоташа.

**Әҗмәт болыны** - Әҗмәт болыны, күрше авыл исеме белән. Уразай болыны шул җирләрнең элеккеге хуҗасы исеме белән аталган. **Чатлыкай болыны** - «чат» сүзе татарча икегә аерылучы юл чаты дигәнне аңлата. **Уразай таллыгы** - авылга нигез салучыларның берсенең исеме буенча.

**Оронимнар** – бу атамалар тау темасы белән бәйле: **Кашлак** тавы - зур булмаган калкулык, җиләк урыннар; **Бурсык** тавы – бурсыклар күп яшәгән урын , анда элек аучылык җирләре булган. **Нүрек** тавы - алтмышынчы елларда Актаныш юлында барлыкка килгән зур булмаган калкулык. Ул елларда СССРда Нурек ГЭС ы төзелде, бәлки, җирле атама бу вакыйга хөрмәтенә барлыкка килгәндер (Россиянең барлык шәһәрләрендә дә, шул исәптән Түбән Камада да, ерак торак районнарны "БАМ", “Тында” дип атый башлаганнар).

**Кушай чокыры**. Борын-борын заманнарда Табанлы Күл авылы янында ике бик тирән чокыр булган. Алар кызыл балчыкка бик бай булганнар. Авыл халкы аннан савыт-саба ясау өчен балчыкалган. Бу чокырларны «Куш» дип атаганнар. Бераздан чокырлар тагын да тирәнәйгән һәм авыл халкы чокырларны күмәргә булган. Вакытлар үтүгә берсен күмә алганнар, ә икенчесе хәзер дә бар. Еллар үткән саен Куш чокыры Кушай исеменә алышынган

**Гайшә күпере.** Бу урын узган гасырның егерменче елларында булган Такталачук авылы тарихында булган фаҗигале вакыйгаларның берсе белән бәйле. 1920 елда Совет хакимиятенә каршы сәнәк күтәреп күтәрелгән крестьяннар бу җирдә авыл активистларын, шул исәптән авыл мөгаллимнәрен дә үтергәннәр.

Сазлыклы урыннарны билгеләүче атамалар **гелонимнар** термины белән билгеләнә**.**

**Әбугали баткаклыгы**. Бу топоним шулай ук тарихи вакыйгага нигезләнгән. 1910 нчы елны авылда земство больницасы төзелә башлагач, Агыйдел буенча баржалар белән кызыл кирпеч алып киләләр. Ярга бушатылган кирпечләрне ат арбаларына төяп ташыйлар. Ул елны ташу көчле була, Әбугали исемле бер кеше аты белән адашып сазлыклы урында батып үлә.**Каенсаз(ы**) – Каенлык авылында урнашкан. Сазлыкның исемен авыл исеме белән тиңлиләр. Атама «каен»һәм «саз» сүзләре кушылыпясалган. Татар телендә «саз» төшенчәсе саз сүзе белән белдерелә (чагыштырыгыз: казак, каракалпак, нугай – саз, башкорт – һаҙ,алтай, хакас, себер татарлары –сас «саз»). **Тарлау җире** – Сәфәр белән Иске Богады арасында калучы сазлык җир. Сазлык тар гына өчпочмаклы җирне тәшкил итә.Тарлау сүзенең килеп чыгышында «тар», «кысан» мәгънәсендә аңларга кирәктер. Г.Ф. Саттаров хезмәтендә исә “тарлау” сүзе көтүлекне белдерүче җирле географик терминнар исемлегенә кертелгән.

**Йомгак**

Без бу эштә топонимнарның никадәр киң тикшерелүен, аларны өйрәнү һәм системага салу алымнарының төрлелеген, шулай ук Актаныш районы авыллары топонимиясен төрле яктан анализларга тырышып карадык. Башкарылган эшкә нәтиҗә ясап, куелган бурычлар үтәлде дип әйтергә мөмкин: 1. Билгеләп үтелгәнчә, авыл һәм аның тирә-ягындагы атамалар очраклы рәвештә генә сайлап алынмаган, алар бу урыннарның географик һәм башка үзенчәлекләрен аңлаталар. 2. Топонимик атамалар авылыбызның

барлык халкы өчен бик зур әһәмияткә ия, чөнки аларда якын һәм бөек кешеләр турында, күңелгә якын җирләр, кече Ватаныбызның бөеклеге турында истәлекләр яшәвен дәвам итә. Авыллардагы топонимнарга һәм микротопонимнарга лингвистик анализ ясаганда, тарихи документларны, шулай ук кайбер географик объектларны өйрәнгәч, исемдә халыкның якты һәм үзенчәлекле тарихы чагылган дигән нәтиҗәгә килдек. Киләчәктә туган якның микротопонимнарын өйрәнү эшен эвам итәргә планлаштырабыз, чөнки барлык мәсьәләләрне дә хәл итеп булмады, күп кенә исемнәрне аңлату үз чишелешен көтәләр. Алга таба «Актаныш төбәгенең топонимик сүзлеген» төзүне дәвам итәргә, шулай ук топонимнар һәм микротопонимнар мәгълүматлары буенча табигать объектларының фотоальбомын төзергә уйлыйбыз.Авылның топонимик характеристикасын төзү кече Ватан тарихы буенча белешмәләр өстәргә, кыйммәтле материалны язып алырга һәм сакларга мөмкинлек бирде. Бу эшне дәвам итеп, топонимнар сүзлеге төзергә уйлыйбыз. Безнең тикшеренү эшендә җыелган материалларны тарих, география һәм туган якны өйрәнү дәресләрендә кулланылырга мөмкин.

**Кулланылган әдәбият исемлеге**

1.Татарстан Республикасының административ-территориаль бүленеше (белешмәлек) / Татарстан Республикасы Премьер-министры Р.Н. Миңнеханов редакциясендә. - Казан: Инновацион технологияләр үзәге, 2005.

2.Әсфәндияров, А. З. Минзәлә башкортлары. – Уфа : Китап, 2009. – С. 410-421

3.Гарипова, Ф. Г. Татарстан гидронимиясе буенча тикшеренүләр. – Москва : Фән, 4.

4.Суперан, А. В. Нәрсә ул топонимика? – Москва : Наука, 1985. - 182 б.

Шулай ук **Интернеттан электрон чыганаклар** белән файдаландык.

*Валиева Алия Ринат кызы,*

*Валетова Елена Владимир кызы,*

*Казан шәһәре Совет районының «233 нче балалар бакчасы» муниципаль автонимияле мәктәпкәчә белем учреждениесенең югары категорияле тәрбиячеләре*

**Балалар бакчасында кече яшьтәге икенче төркемдә татар халык авыз иҗаты әсәрләре аша балаларның сөйләм телен үстерү буенча**

Әлеге программа кече яшьтәге балаларның халык авыз иҗаты чараларын кулланып сөйләм телләрен үстерүгү юнәлдерелгән. Балаларны үз халкының гореф-гадәтләренә, үз төбәгенең мәдәниятенә җәлеп итү заманча җәмгыять тормыш өчен мөһим булган проблемаларнын берсе санала. Балалар бакчаларында сөйләм теле үстерүне формалаштыру, камилләштерү балаларга үз туган теленең матурлыгын, кодрәтен аңларга, аны яратырга,

халкыбызның рухи һәм иҗади байлыгын, чын тарихы белән кече яшьтән үк тирән кызыксыну уятырга ярдәм итә. Балалар бакчасында үткәрелә торган барлык бәйрәм яки чаралар бәйләнешле сөйләм үстерү бурычларын читләп үтә алмый. Бәйләнешле сөйләм үстерү балалар бакчасында туган телне тирәнтен үзләштерүнең гомуми методы, телгә өйрәтүнең төп принцибы.

Халык авыз иҗаты әсәрләренең тәрбияви әһәмияте аеруча зур. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны халык авыз иҗаты әсәрләре белән тел үстерү чаралары вакытында да, уйнаганда да, теләсә нинди буш вакытта да таныштырырга була. Җанлы һәм тапкыр сүзле мәкаль-әйтемнәр, санамыш, такмак, табышмак, экиятләр һ.б.ш. балаларда тел матурлыгын тоемлау тәрбиялиләр, танып белү эшчәнлеген, сөйләм телен үстерәләр.

Матур әдәбият, халык иҗаты, күрсәтмәлелек, предметлар белән уен хәрәкәтләре, кошларның, җәнлекләрнең образларын имитацияләү - болар барысы да нәниләрне туган телгә өйрәтүдә, аларның сөйләмен үстерүдә зур әһәмияткә ия.

Безнең туган телебез татар теле – изге дә, көчле дә. Аның көче - тәрбияви әһәмиятендә. Бакчада бала туган телебездә халкыбызның бишек җырларын, халык экиятләрен, такмактакмазаларын, җыр моңнарын ишетеп үсә, аңлап үсә икән, димәк ул изгелек, игелек дигән төшенчәләрне аңлап үзләштерә.

Программа түбәндәге **юнәлешләрдән** чыгып оештырыла:

-балаларга әдәби һәм мәдәни байлыгыбыз турында күзаллау булдыру;

-туган телдә сөйләшергә теләк уяту, аны хөрмәт итү;

-нәфис сүз,ягъни әдәби әсәрләр аша чынбарлыкны өйрәтү;

- образлы уенчыклар,нәфис сәнгать образлары аша чынбарлыкны тану.

**Теманың актуальлеге:**

Бугенге көндә балаларның сөйләм теле бик түбән дәрәҗәдә. Бик күпләрнең теле озак һәм авыр ачыла. Моның сәбәбе бала белән аралашу җитмәүдә. Ата-ананың бала белән сөйләшергә, төрле уеннар уйнарга вакыты да, теләге дә юк. Бала күбрәк компьютерда утыра, телевизор карый. Шул сәбәпле тел озак һәм авыр ачыла. Бүгенге көндә бу тема бик актуаль. Хәзерге чорда компьютерның үтеп кергән, техниканың алга киткән вакытында туган тел, татар теле югала башлый. Сөйләмгә чит ил сүзләре үтеп керә, ә компьтер теле әдәби матурлыктан мәхрүм. Татар халык авыз иҗаты аша бала туган телне өйрәнеп кенә калмый, ә аның матурлыгына төшенә, гореф – гадәтләре турында беренчел күзаллаулар барлыкка килә.

**Максат:**Кечкенәләр төркеменә йөрүче татар балаларын халык авыз иҗаты әсәрләребелән таныштыру.

**Бурычлар:**

-татар халык авыз иҗаты әсәрләрен, аларның төрләрен өйрәнү.

-балаларның сөйләм телен үстерүдә һәм тәрбияләү системасында татар халык авыз иҗатының әһәмиятен ачыклау;

-татар халык иҗатының балаларның күңел байлыгын, фикерләү һәм сөйләм телен үстерүдә нәтиҗәлелегенә инану;

-балаларның сөйләм телен үстерүдә халык авыз иҗатының роле, төрләре;

-ата-аналарга татар телен өйрәнүнең мөһимлеген аңларга ярдәм итү;

-татар халык авыз иҗатына җәлеп итү, кызыксындыру.

**Программаны формалаштыруның принциплары.**

Россиянең төп бердәм мәктәпкәчә белем бирү программасының ФДББСка яраклашуы түбәндәгеләрдән күренә:

- балачакның узенчәлеге;

- кешелекнең гомуми усешендә мәктәпкәчә чорның уникаль булуы;

- өлкәннәр һәм балаларның гуманлы аралашуы;

- баланың шәхесен хөрмәт итү;

- балаларның спецификасын искә алып, белем бирү процессын уен, танып белү, эзләнү, иҗади активлык формасында тормышка ашыру.

Программаны тормышка ашырунын төп принцибы – яшь узенчәлегенә туры килү. Мәктәпкәчә чорда ул уен, тәҗрибәләр ясау, әңгәмә кору, проблемалы ситуацияләрне чишүһ.б. Әлеге эш төрләре мәҗбүри эшчәнлекне тәлап итми, ә бәлки программа балалар һәм педагогларның бердәм эшчәнлеге, шулай ук балаларның мөстәкыйль эшчәнлекләре аша тормышка ашырыла.

Интегральләштеру принцибы – предметлы белем бирү программасын төзүгә альтернатив. Һәр белем бирүөлкәсендәге бурычлар башка өлкәләрне тормышка ашырганда да утәлә ала. Тәкъдим ителгән белем бирүөлкәләре шартлы, ул материалны системалы оештыру өчен бирелгән.

Проблемалы белем бирү принцибы – билгеле бер авырлыкларны жиңү өчен бурычларны үтәү, сорауларга җавап эзләү. Бала өчен проблеманың практик мәгънәсе булу бик мөһим. Проблеманы чишеп, бала дөньяның күптөрле, үзгәрүчән булуын белэ.

Ситуатив принцибы – белем бирү процессында балаларның кызыксынучанлыгын исэпкә алуга юнәлгән.

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

-сүзнең фонематик һәм лексик якларын кабул итү буенча беренчел күнекмәләр формалаштырылачак;

- балалар сөйләм телен белә, үз фикерләрен, хис-тойгыларын һәм теләкләрен белдерү, аралашу ситуациясендә сөйләм гыйбарәсен төзү өчен куллана алалар;

-балалар сүзлеге ел ахырына яңа сүзләрбелән баетыла;

-халык авыз иҗаты, сәнгать әдәбияты белән кызыксыну формалаша, сөйләм иҗатында, нәтиҗәле эшчәнлектә таныш халык авыз иҗаты әсәрләрен файдалана белүләрен күрсәтәләр;

-балалар кызыксынучанлык күрсәтәләр, өлкәннәргә һәм яшьтәшләренә сораулар бирәләр, төрле жанрдагы татар халык авыз иҗаты әсәрләре турында башлангыч белемгә ия.

**Эш формалары:** танышу, ятлау, ныгыту; уен дәресләре (тематик, сюжетлы, сюжетлы-тематик, комплекслы).

**Балалар эшчәнлеген оештыру алымнары:** уен (уеннар-драматизация, уеннар-инсценировкалар, дидактик уеннар, өстәл-басма уеннар), күрсәтмә, сүзлек (коллектив уку, җырлар, әкиятләр тыңлау), гамәли.

**Балаларның яше:** 2-3 яшь.

**Программаны тормышка ашыру вакыты:** 1 уку елы.

**Эшнеңкыскача эчтәлеге.**

Туган тел – рухи байлыгыбыз сандыгына ачкыч ул. Ана телендә тәрбияләнгән бала гына, үз халкының әхлак кануннарын кабул итеп, милләтенә, аның теленә һәм гореф-гадәтләренә чын мәгънәсендә ихтирамлы була ала.

Милли тәрбия бирү, халык тарихын өйрәнү, аның мәдәни байлыгы турында күзаллау булдыру, туган теленә, халкына карата соклану, горурлану хисе тәрбияләү, балаларда ул яшәгән республика, шәһәр тарихы турында мәгълүмат бирүдән башлана. Һәр яктан үсеш алган киләчәк буын кешесе үссен дисәк, барлык тәрбия өлкәләрен дә кулланып, тәрбиягә нигез балалар бакчасындагы нәниләргә юнәлдерелергә тиеш.

Баланың телен ачуда, сөйләмен формалаштыруда бармак уеннары аерым бер урын тота. Әле сөйләм теле ачылмаган бала белән бармак уеннары уйнаганда, сүзләрен өлкәннәр үзләре әйтә бара. Бармак-кул моторикасы үсеше тел ачылуга, сөйләм үсешенә уңай тәэсир ясый. Шуларны искә алып, без халык авыз иҗатыннан алынган бармак уеннарын кечкенәләр төркеме балалары шөгыльләрендә кулланабыз. Мәсәлән, «Бу бармак бабай…», «Бармак, бармак, кайда булдың?» һ.б.. Бармак уеннарын кечкенәләр белән өйрәнү дәресләрне җанландыра, дәресләргә кызыксыну уята, балаларның теле ачылуга ярдәм итә.

Балаларны тәрбияләүдә әкият, сынамыш, санамыш, җырлы-биюле, хәрәкәтле уеннарны куллану, татар халкының милли йолалары, гореф-гадәтләре, бәйрәмнәре, бәйрәмнәрнең тарихы белән таныштыру зур урын алып тора.Ел әйләнәсе шөгыльләрдә һәм шөгыльдән тыш вакытларда балалар белән эшчәнлек татар халык уеннары, табышмаклар, бишек җырлары, җырлы - биюләр белән үрелеп барса бик отышлы.

Телнең нечкәлекләрен, тирәнлеген өйрәнүдә табышмакларның әһәмияте искиткеч зур. Сөйләм телен үстерү шөгыльләрендә табышмаклардан файдалану аеруча уңышлы. Балаларга әзер табышмаклар гына биреп калмыйча, алар белән берлектә яңа табышмаклар да уйлап чыгару да бик яхшы. Бу эш алымы баланың сөйләм телен дә, уйлау сәләтен дә камилләштерә.

Халык авыз иҗаты әсәрләреннән балаларга иң якын һәм алар ярата торганы –әкиятләр. Халык әкиятләре – сөйләм телен үстерүдә бай материал булып исәпләнә. Барлык әкиятләрдә дә җиңеп чыгучы геройларның тапкырлык, зирәклек, акыллылык, уйлап табучанлык сыйфатлары мактала. Әкиятләрне сөйләм телен үстерү барышында төрлечә куллану дөрес: башта аудиоязмаларда тыңлау, булганнарын интерактив тактада карау, сәхнәләштерү. Курчак театрын сәхнәләштерү өчен ширма, курчаклар, өстәл курчак театры өчен курчаклар, маскалар, бармак курчаклар булдыру бик уңышлы. Балалар курчак театрын карарга гына түгел, үзләре дә уйнап күрсәтергә яраталар. Бу әлбәттә аларның сөйләм телен үстерүдә зур булышлык итә.

Кечкенәләр төркеме балалары белән шулай ук юаткычлар эндәшләр, мавыктыргычлар, бишек җырлары кебек халык авыз иҗаты әсәрләре дә кулланыла. «Учтеки, учтеки», «Карга әйтә кар, кар…». Эчтәлеге белән алар балаларның төрле хәрәкәтләр ясавын: кул чабу, баш селкетү, аяк басу, яулык болгау, баштан сыйпау һ.б. күздә тоталар, кечкенә балаларның хәрәкәт итү ихтыяҗына туры килгән бу әсәрләр рифмалашкан авазларны сиземләү, телнең байлыгын һәм матурлыгын тану да тәрбияли.

Балалар курчаклар белән уйнарга: киендерергә, күтәреп йөрергә, коляскада йоклатырга, юындырырга, ашатырга яраталар. Алар белән бергәләп курчакларны төреп, җырлар җырлап йоклату, үчтеки иттеру уңышлы.

Балалар белән урамда уйнаганда, төркемдә уен моментларында такмаклар, әйтенүләр, үртәвечләр, эндәшләр куллану да бик отышлы. Балалар аларны бик теләп кабатлыйлар. Бу балаларның фикерләү сәләтен үстерүгә, дөньяны күзаллавына, сөйләм телен үстерүгә зур булышлык итә.

**Тематик план.**

| **Эш төрләре** | **Шөгыльләр саны** |
|---|---|
| Такмаклар уку | 2 |
| Эндәшләр уку | 3 |
| Бишек җырларын өйрәнү | 2 |
| Әкиятләр уку | 4 |
| Бармак уенын уйнау | 2 |
| Татар халык уенын уйнау | 3 |
| **Барлыгы:** | **16** |

**Балалар белән халык авыз иҗаты әсәрләрен өйрәнү буенча кече яшьтәге икенчетөркемдә еллык эш планы.**

| № | Тема | Максатлар | Эш төрләре | Җиһазлар |
|---|---|---|---|---|
| Октябрь | | | | |
| 1. | «Курсәт әле, үскәнем» татар халык уенын уйнау. | Халык авыз иҗатына, йорт хайваннарына карата кызыксыну тәрбияләү;йорт хайваннарының исемнәрен ныгыту; мөгри, кычкыра, мияулый, өрә фигыльләре хисабына балаларның сүзлек запасын арттыру. | Мияудан хат алу, авылга сәяхәткә китү. Хайваннар тавышы яздырылган аудиоязма тыңлау.«Тавышны таны» уены.Балалар белән бергәләп «Курсәт әле, ускәнем» уенын уйнау. | Уенчык эт, песи, сыер, кәҗә, хайваннар тавышы яздырылган аудиоязма. |
| 2. | «Үчтеки, үчтеки» такмагын уку. | Халык авыз иҗаты әсәрләре белән кызыксыну уяту, шигъри әсәрнең эчтәлеген аңларга өйрәтү. | Кыз һәм малай курчагы белән таныштыру. Такмакны хәрәкәтләр ясап уку. Курчакларны машинада йөртү. | Ширма, кыз курчак һәм малай курчак. |
| Ноябрь | | | | |
| 3. | Йорт хайваннарын чакыру эндәшен уку. | Эндәшнең эчтәлеген аңлату, текстның эчтәлегеннән чыгып, аваз ияртемнәрен, ымлыкларны дөрес әйтүләренә, тәрбияче сорауларына дөрес җавап бирүләренә ирешү. | «Автобус» уенын уйнау. Йорт хайваннары турында әңгәмә кору. | Кәҗә, сарык, тавык, песи, ат, эт рәсемнәре яки уенчыклар, «Автобус» уенына кирәкле әйберләр. |
| 4. | «Әлли – бәлли итәр бу…» бишек жырын жырлау. | Шигырьнең эчтәлеген аңлап кабул итүләренә ирешү, авазларны дөрес әйтергә | Курчакны йокларга яткыру турында әңгәмә кору. Ике тапкыр бишек жырының сүзләрен | Коляскага салынган курчак,һәр балага бирәр |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | күнектерү; курчакка карата кайгыртучанлык тәрбияләү. | тыңлау. Курчакны көйләп, тирбәтеп йоклату. | курчак, бала елаган тавыш язылган аудиоязма. |
| Декабрь | | | | |
| 5. | «Каргаәйтә кар, кар…» эндәшен уку. | Шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү, балаларның кошлар турында белемнәрен арттыру һәм ныгыту. | Бәйрәмнәрдә кунаклар каршы алу турында әңгәмә кору. «Каргаәйтә…» эндәшен тыңлау. «Каргалар оча» хәрәкәтле уенын уйнау. Эндәшне тагын бер тапкыр кабатлау. | Мичкә куелган бәлеш һәм карга рәсеме, карга тавышы аудиоязмасы. |
| 6. | «Кәккүк – чыпчык» уенын уйнау. | Балаларны авазларны дөрес итеп әйтергәөйрәтү, сүзлекне активлаштыру. | «Кәккүк һәм чыпчык» уены уйнаучы эти һәм малай сюжетлы рәсеме буенча әңгәмә кору. Уенның тәртибен өйрәтү, уйнаганда әйтелә торган сузләрне тыңлату. | Кәккүк һәм чыпчык рәсемнәре, кәккүк һәм чыпчык тавышлары аудиоязмасы. |
| Январь | | | | |
| 7. | «Кем нәрсә ярата?» татар халык әкиятен уку. | Балаларны татар халык авыз иҗаты әсәрләре белән таныштыруны дәвам итү, әкиятне тыңлау теләге тудыру. | Әкияне тыңлау. Эчтәлеген аңлауларын тикшерү. «Кем нәрсә ярата» уенын уйнау.Әкият буенча мультфильм карау. | Әкият эчтәлегенә туры килгән рәсемнәр; песи, эт, этәч, кәҗә уенчыклары. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 8. | «Кем нәрсә ярата?» татар халык әкиятен кабатлау. | Әкиятне тәрбияче белән бергә сөйләргә өйрәтү; аерым фразаларны кабатлатып, балаларның сүз байлыгын активлаштыру. | Әкиятне кабатлап уку. Эчтәлеге буенча әңгәмә кору. «Кем нәрсә ярата» уенын уйнау. | Песи, эт, әтәч, кәҗә уенчыклары. |
| Февраль | | | | |
| 9. | «Җиләк җыям, как коям…» татар халык уенын уйнау. | Балаларны татар халык уеннары, аларның үзенчәлекләре, кагыйдәләре белән якыннан таныштыру. | Балаларны уенның эчтәлеге, тәртибе белән таныштыру, уенны уйнау. | Аю яки бүре маскасы. |
| 10. | «Песи нечкә бил» бишек җырын җырлау. | Шигъри әсәрне аңлап кабул итуләренә ирешү, бишек җыры текстына туры китереп, хәрәкәтләр башкарырга өйрәтү. | Елаган курчакны тынычландыру, Әңгәмә.<br>Бергәләп җырлау. | Уенчык песи, коляскага салынган курчак, елаган бала тавышы аудиоязмасы. |
| Март | | | | |
| 11. | «Төлке белән каз» татар халык әкиятен уку. | Балаларны яңа әсәр белән таныштыру; әкиятне аңлап тыңларга өйрәтү. | Әкиятнең эчтәлеге белән таныштыру. Иллюстрацияләр карау. Эчтәлек буенча әңгәмә кору.Әкият буенча мультфильм карау. | Төлке һәм каз уенчыклары, әкият эчтәлегенә туры килә торган рәсемнәр. |
| 12. | «Төлке белән каз» татар халык әкиятен сәхнәләштерү. | Әкият белән таныштыруны дәвам итү;балаларны сәхнәләштерү эшчәнлегенәҗәлеп итү, уен барышында | Әкиятнең эчтәлеген искә төшерү, эчтәлек буенча сораулар бирү. Балаларга битлекләрне киертеп әкиятне сөйләү. | Төлке һәм каз битлекләре. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | фразаларны дөрес әйтү осталыгына ирешү. | Теләгән балалардан әкиятне уйнатып карау. | |
| Апрель | | | | |
| 13. | «Кояш чык, чык…» эндәшен уку. | Балаларга эндәшнең эчтәлеген аңларга, сюжетны истә калдырырга ярдәм итү. | Сюжетлы рәсем буенча әңгәмә кору. Эндәшне 3 тапкыр тәрбияче укый. Аннары балалар белән бергә уку. Актив катнашкан балаларны мактау. | Кояш, казанда пешә торган ботка, кашык рәсемнәре. |
| 14. | «Бу бармак – бабай…» бармак уенын уйнау. | Яңа сүзләр белән таныштыру: әби-дәү әни, бабай-дәү әти; балаларның бармак хәрәкәтләрен үстерү,кул чуклары мускулларын ныгыту, мөстәкыйль рәвештә бармак уеннары уйнау теләге тәрбияләү. | Гаиләәгъзалары исемнәрен искә тошерү. Кунакка килгән курчак белән таныштыру, аның гаиләсе белән танышу. Бармак уенын уйнау. | Курчак, гаиләәгъзалары төшкән рәсемнәр, сюжетлы рәсемнәр. |
| Май | | | | |
| 15. | «Тор, тор, тургай» такмагын уку. | Такмакнын эчтәлеге белән таныштыру, аваз иялтемнәре хисабына балаларның сүз байлыгын арттыру. | Такмакны уку. Тургай һәм чыпчык рәсемнәрен карап такмакның эчтәлеге буенча әңгәмә кору. «Кош канатларын кага…» хәрәкәтле уенын уйнау. | Тургай һәм чыпчык рәсемнәре, тургай һәм чыпчык тавышлары аудиоязмасы. |
| 16. | «Бармак, бармак, кайда булдың?» бармак уенын уйнау. | Балаларның бармак уеннары, кул чуклары күнегүләре аша сәламәтлекләрен ныгыту, психологик | Гаиләәгъзалары исемнәрен искәтөшерү. Бармак уенын уйнау. | Гаиләәгъзалары төшкән рәсемнәр. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | уңай халәттудыру; өйрәнгән материалны туплап балалар күңеленә салып кую. Бармак уеннарына карата уңай караш, үз – үзеңә ышаныч тәрбияләү һәм үз мөмкинлекләрен бәяли белергә өйрәтү. | | |

**КУШЫМТА**

**«Курсәт әле, үскәнем» оештырылган белем бирү эшчәнлегенең технологик картасы.**

| | |
|---|---|
| **Тема:** | **«Курсәт әле, үскәнем» татар халык уенын уйнау.** |
| **Балаларның яшь төркеме:** | Кече яшьтәге икенче төркем |
| **Төп белем бирү өлкәсе:** | Сөйләм телен үстерү |
| **Белем бирү өлкәләрен интегральләштерү:** | Сөйләм үстерү үсеше<br>Физик үсеше |
| **Үткәрү формасы:** | Төркемләп |
| **Җиһазлар:** | Уенчык эт, песи, сыер, кәҗә, хайваннар тавышы яздырылган аудиоязма. |
| **Алдан эшләнгән эшләр:** | Йорт хайваннары рәсемнәрен карау, әңгәмәләр үткәрү, сораулар ярдәмендә нәрсә белән тукланулары, ничек кычкыруларын ачыклау. |
| **Максат:** | Йорт хайваннарына карата сак караш тәрбияләү. |
| **Белем бирү программасы бурычлары:** | **Белем бирү бурычлары:**<br>Халык авыз иҗаты белән таныштыруны дәвам итү, катлаулы булмаган фразаларны куллануда күнектерү, йорт хайваннарының исемнәрен ныгыту; мөгри, кычкыра, мияулый, өрә фигыльләре хисабына балаларның сүзлек запасын арттыру; [м], [у] авазларын дөрес әйтергә өйрәтү.<br>**Үстерү бурычлары:** |

| | |
|---|---|
| | Хәтерне, кабул итү сәләтен, авазларны әйтү күнекмәләрен үстерү.<br>**Тәрбия бурычлары:**<br>Халык авыз иҗатына, йорт хайваннарына карата кызыксыну тәрбияләү. |
| **Эшчәнлекнең структурасы:** | **I.Оештыру**<br>-Мияудан хат алу.<br>- Келәмгэ утырып авылга очу.<br>**II. Төп өлеш**<br>-Йорт хайваннарының тавышын тыңлау.<br>-Хайваннар белән танышу.<br>-Сойләм телен активлаштыру.<br>-Хәрәкәтле уен: «Күрсәт әле, үскәнем».<br>-Уен «Йорт хайваннарының тавышын таны».<br>**III. Йомгаклау өлеше.** |
| **Эшчәнлек барышы:** | **I.Оештыру**<br>*Төркем бүлмәсендә ярым түгәрәк ясап утырышалар.*<br>**Тәрбияче:** Хәерле көн, балалар. Кәефләрегез ничек?<br>Миңа мияудан хат килде. Хәзер мин аны укып күрсәтәм. Ул безне авылга чакырган. Ә мин сезгә оча торган келәмгә утырып барырга тәкъдим итәм.<br>*(Балалар келәмгә утыралар һәм күзләрен йомалар*)<br>**Тәрбияче:** Бер, ике, өч, келәм авылга оч! *(Күзләрне ачалар).*<br>**II. Төп өлеш**<br>**Тәрбияче:** Балалар,ишетәсезменииндидер тавышлар килә? Безавылга килеп тә җиттек. *(Аудиоязмада хайван тавышлары ишетелә).*<br>**Тәрбияче**: Карагыз әле монда. *(Тәрбияче өстәлгә йорт хайваннары: уенчык сыер, кәҗә, песи, этне куя).*<br>**Тәрбияче**: Балалар, бу нәрсә?<br>**Балалар:** Сыер. *(Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар)*<br>**Тәрбияче:** Балалар, сыер печән ашый. Сөт бирә. «Му-му!»дип мөгри.<br>**Тәрбияче:**Бу нәрсә?<br>**Балалар:** Кәҗә.<br>**Тәрбияче:** Кәҗә дә сөт бирә. Ләкин ул мөгри белми. Ул: «Мееe - мееe!» – дип кычкыра. Кәҗә ничек кычкыра? |

**Балалар:**«Мееe - мееe!» *(Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар).*

**Тәрбияче:** Менә песидә килде.Карагыз әле, ул нинди матур! Ул сөт эчә. Балалар, песи сөтне теле белән ялап эчә. *(Тәрбияче күрсәтә.)*Песи мияуларга ярата: «Мияу - мияу!». Песи ничек мияулый?

**Балалар:** Мияу - мияу!

**Тәрбияче:** Менә эт тә килеп җитте. Эт сөяк кимерә. Эт нишли?

**Балалар:** Сөяк кимерә. *(Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар).*

**Тәрбияче:** Ул: «Һау-һау-һау!»дип өрә. Эт ничек өрә?

**Балалар:** Һау-һау-һау! *(Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар).*

***Сөйләм телен активлаштыру.***

**Тәрбияче:** Кәрим, кил әле. Сыерны тап әле. Ул ничек мөгри?

**Тәрбияче:** Сәлим, кәҗәне күрсәт әле. Ул ничек кычкыра?

**Тәрбияче:** Булат,этне күрсәт әле. Ул ничек өрә?

**Тәрбияче:** Ралинә, песине күрсәт әле. Песи ничек мияулый?

**Тәрбияче:** Балалар әйдәгез әле без йорт хайваннарына уен уйнап күрсәтик.

***Хәрәкәтле уен: «Күрсәт әле, үскәнем»***

-Күрсәт әле, үскәнем, ничек сыер мөгри?
-Му-му-му,- диеп,
Безнен сыер мөгри.
-Күрсәт әле, үскәнем, ничек кәҗә кычкыра?
-Мә-мә-мә,- диеп,
Безнең кәҗә кычкыра.
-Күрсәт әле, үскәнем, ничекпеси мияулый?
-Мияу-мияу-мияу,- диеп,
Безнең песи мияулый.
-Күрсәт әле, үскәнем, ничек этләр өрәләр?
-Һау-һау, ау-ау, -диеп,
Безнең этләр өрәләр.

**Тәрбияче:** Булдырдыгыз! Балалар, карагыз әле, ишетәсезме тавышны, тыңлыйк та җавап бирик.

***Уен «Йорт хайваннарының тавышын тану»***

*Фонограммада йорт хайваннары тавышы ишетелә. Балалар һәр йорт хайванының тавышын танып әйтәләр.*

| | |
|---|---|
| | **III. Йомгаклау өлеше.**<br>**Тәрбияче:**Булдырдыгыз, молодцы. Балалар, безнең бакчага кайтырга вакыт җитте. Килегез әле, келәмгә утырыгыз, күзләрегезне йомыгыз.<br>Бер, ике, өч, келәм бакчага оч.<br>**Тәрбияче:** Балалар, сезгә сәяхәт ошадымы? Нәрсәләр кызыклы булды һәмхәтерегездә калды? *Балаларның җаваплары.* |

**«Кем нәрсә ярата?» татар халык әкиятен уку» оештырылган белем бирү эшчәнлегенең технологик картасы.**

| **Тема:** | **«Кем нәрсә ярата?» татар халык әкиятен уку.** |
|---|---|
| **Балаларның яшь төркеме:** | Кече яшьтәге икенче төркем |
| **Төп белем бирү өлкәсе:** | Сөйләм телен үстерү |
| **Белем бирү өлкәләрен интегральләштерү:** | Сөйләм үстерү үсеше<br>Физик үсеше |
| **Үткәрү формасы:** | Төркемләп |
| **Җиһазлар:** | Песи, эт, әтәч, кәҗә уенчыклары, хайваннарның ашамлыклары. |
| **Алдан эшләнгән эшләр:** | Йорт хайваннары рәсемнәрен карау, әңгәмәләр үткәрү, сораулар ярдәмендә нәрсә беләп тукланулары ачыклау; табышмаклар чишү. |
| **Максат:** | Йорт хайваннарына карата сак караш тәрбияләү. |
| **Белем бирү программасы бурычлары:** | **Белем бирү бурычлары:**<br>Әкиятнең эчтәлеген аңлап кабул итүләренә ирешү; сорауларга җавап бирү омтылышы уяту.<br>**Үстерү бурычлары:**<br>Балаларның игътибарын үстерү.<br>**Тәрбия бурычлары:**<br>Халык авыз иҗатына, хайваннарга, кошларга карата шәфкатьлелек тәрбияләү. |

| | |
|---|---|
| **Эшчәнлекнең структурасы:** | **I.Оештыру**<br>- Табышмаклар чишү.<br>**II. Төп өлеш**<br>-«Кем нәрсә ярата?» әкиятен тыңлау.<br>-Сөйләм телен активлаштыру.<br>-Уен «Кем нәрсә ярата».<br>**III. Йомгаклау өлеше.** |
| **Эшчәнлек барышы:** | **I.Оештыру**<br>*Төркем бүлмәсендә ярым түгәрәк ясап утырышалар.*<br>**Тәрбияче:** Хәерле көн, балалар. Кәефләрегез ничек? Буген без сезнең белән әкият укырбыз. Әкиятнең нәрсә турында икәнен табышмакларны чишкәч белербез.<br>**Тәрбияче:**Иртүк тора<br>«Киккрикүк »,- дип кычкыра.<br>**Балалар:**Әтәч .<br>2. **Тәрбияче:**Ул бик файдалы, сакаллы хайван<br>Сөт, ит, йон бирә.<br>**Балалар:**Кәҗә.<br>**Тәрбияче:**Ул матур, йомшак, акыллы хайван.<br>Сөт ярата, тычкан тота.<br>**Балалар:** Песи.<br>**Тәрбияче:**Ул акыллы, кешенең дусты, йортның сакчысы.<br>Ит, сөяк ярата**.**<br>**Балалар:** Эт.<br>**Тәрбияче:**Булдырдыгыз. Димәк, буген без песи, эт, әтәч һәм кәҗә турында әкият тыңларбыз. Җайлашып утырыгыз, «Кем нәрсә ярата?» әкиятен тыңлыйбыз.<br>**II. Төп өлеш**<br>*Хайваннарның уенчык фигураларын кулланып балаларны әкиятнең эчтәлеге белән таныштыру.*<br>***Кем нәрсә ярата?***<br>*(Татар халык әкияте)*<br>Бер йортта Песи белән Эт, Әтәч һәм Кәҗә яшәгәннәр. Кич белән алар ишек төбенә җыелалар да үзләренең эшләре турында сөйләшәләр |

| | |
|---|---|
| | икән. Сөйләшәләр дә бәхәсләшеп тә китәләр икән. «Кем нәрсә ярата? Нинди азык тәмлерәк?» дип бәхәсләшәләр икән.<br>— Иң тәмле сый,— сөт,— ди Песи.— Сөттән соң бер Тычкан да тотып кабып җибәрсәң, бигрәк тә шәп була инде! Тик Тычканны тотуы кыен.<br>— Сөт нәрсә? Ул бит сыек, тамак туйдырмый. Ә менә ярма бөртекләрен, солы орлыгын тук-тук итеп чүпләсәң — менә шунда тамак тук-тук-тук була! — ди Әтәч.<br>— Юк-юк! — дип сүзгә кушыла Акбай.— Бөртек чүпләп кенә туеп бул-бул-булмый. Менә сөяк кимерсәң, чынлап та әйбәт була, шунда ук тук буласың. Нинди азык тәмле, нинди азык файдалы икәнен миннән дә әйбәт белгән хайван юк.<br>— Нәрсә-ә-ә сөйлисең син,— дип каршы килә Кәҗә.— Менә кәбестә-ә-ә булса икән. Иң тәмле азык — кәбестә-ә-ә! — Ди ул.<br>Алар бәхәсләшәләр икән әле — һаман килешә алганнары юк, ди.<br>***Сөйләм телен активлаштыру.***<br>**Тәрбияче:** Балалар,әкияттә сүз нинди хайваннар турында бара?<br>**Балалар:** Песи, эт, әтәч, кәҗә.<br>**Тәрбияче**: Хайваннар нәрсә турында бәхәсләшкәннәр?<br>**Балалар:** Кем нәрсә яратуы турында.<br>**Тәрбияче:** Балалар, кайсы хайван нәрсә ярата соң? Мин сезгә «Кем нәрсә ярата» уенын уйнарга тәкъдим итәм.<br>***Уен «Кем нәрсә ярата»***<br>*Балалар уенчыкларны кулланып хайваннарны сыйлыйлар.*<br>**III. Йомгаклау өлеше.**<br>**Тәрбияче:**Булдырдыгыз, балалар.Сезгә әкият ошадымы?<br>**Тәрбияче:**Хайваннар бәхәсләшеп дөрес эшлиләр микән?<br>*Балаларның җаваплары.* |

**«Йорт хайваннарын чакыру эндәшен уку» оештырылган белем бирү эшчәнлегенең технологик картасы.**

| | |
|---|---|
| **Тема:** | **Йорт хайваннарын чакыру эндәшен уку.** |
| **Балаларның яшь төркеме:** | Кече яшьтәге икенче төркем |

| | |
|---|---|
| **Төп белем бирү өлкәсе:** | Сөйләм телен үстерү |
| **Белем бирү өлкәләрен интегральләштерү:** | Сөйләм үстерү үсеше<br>Физик үсеше |
| **Үткәрү формасы:** | Төркемләп |
| **Җиһазлар:** | Кәҗә, сарык, тавык, песи, ат, эт рәсемнәре яки уенчыклар, «Автобус» уенына кирәкле предметлар. |
| **Алдан эшләнгән эшләр:** | Йорт хайваннары рәсемнәрен карау, әңгәмәләр үткәрү, сораулар ярдәмендә нәрсә белән тукланулары, ничек кычкыруларын ачыклау;<br>«Автобус» сюжетлы – ролле уенын уйнау. |
| **Максат:** | Йорт хайваннарына карата сак караш тәрбияләү. |
| **Белем бирү программасы бурычлары:** | **Белем бирү бурычлары:**<br>Эндәшнең эчтәлеген аңлату, текстның эчтәлегеннән чыгып, аваз ияртемнәрен, ымлыкларны дөрес әйтүләренә, тәрбияче сорауларына дөрес җавап бирүләренә ирешү.<br>**Үстерү бурычлары:** Балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү.<br>**Тәрбия бурычлары:** Халык авыз иҗатына, хайваннарга карата ярату хисе тәрбияләү. |
| **Эшчәнлекнең структурасы:** | **I.Оештыру**<br>-«Автобус» сюжетлы – ролле уенын уйнау, авылга кайту.<br>**II. Төп өлеш**<br>-Сөйләм телен активлаштыру.<br>-Хайваннар турында әңгәмә кору.<br>-Йорт хайваннарын чакыру эндәшен уку.<br>-Сөйләм телен активлаштыру.<br>**III. Йомгаклау өлеше.**<br>- «Автобус» сюжетлы – ролле уенын уйнау, кире бакчага кайту. |
| **Эшчәнлек барышы:** | **I.Оештыру**<br>**Тәрбияче:** Балалар, без бүген сезнең белән авылга, әби белән бабай янына кунакка кайтабыз. Менә бу - безнең автобус.*(Урындыклардан төзелгән «автобус» күрсәтелә).* Балалар, урындыкларга утырыгыз. *(Музыка куела, автобус кузгала)* |

| | |
|---|---|
| | **Тәрбияче:** Менә без килеп тә җиттек.<br>**II. Төп өлеш**<br>*Келәмгә уенчык йорт хайваннары куела: кәҗә, ат, эт.*<br>***Сөйләм телен активлаштыру.***<br>**Тәрбияче:** Балалар, карагыз әле, әби белән бабайның ишегалдында нинди хайваннар бар?<br>**Балалар:**Кәҗә, сарык, тавык, песи, эт, ат.<br>**Тәрбияче**: Кәҗә ничек кычкыра?<br>**Балалар:** Ми-ки-ки.<br>**Тәрбияче:** Ул нәрсә ашарга ярата?<br>**Балалар:** Кәбестә.<br>**Тәрбияче:** Ә сарык ничек кычкыра?<br>**Балалар:** Бә-бә-бә.<br>**Тәрбияче:** Песи нәрсә ярата?<br>**Балалар:** Сөт.<br>**Тәрбияче:** Бу нәрсә?<br>**Балалар:** Эт.<br>**Тәрбияче:** У ничек өрэ?<br>**Балалар:** Һау-һау-һау.<br>**Тәрбияче:** Ә бу нәрсә?<br>**Балалар:** Ат.<br>**Тәрбияче:** Атнын нәрсәләре бар?<br>**Балалар:** Башы, гәүдәсе, койрыгы, аяклары.<br>**Тәрбияче:** Балалар, хәзер мин сезгә әлеге хайваннарны ничек чакыру турында эндәш укыйм, сез игътибар белән тыңлагыз.<br>***Хайваннарны чакыру.***<br>-Чакырабыз кәҗәне*:*<br>- Кәҗ-кәҗ-кәҗ!<br>Кәҗ-кәҗ-кәҗ!<br>-Чакырабыз сарыкны:<br>-Бәр-бәр-бәр-бәр!<br>Бәр-бәр-бәр-бәр!<br>- Чакырабыз чебиләрне (тавыкларны):<br>-Чеп-чеп-чеп-чеп!<br>Чеп-чеп-чеп-чеп! |

| | |
|---|---|
| | - Чакырабыз песине:<br>-Пес-пес-пес-пес!<br>Пес-пес-пес-пес!<br>-Чакырабыз маэмайны:<br>-Маһ-маһ-маһ!<br>Маһ-маһ-маһ!<br>-Чакырабыз аткайны:<br>-Бах-бах-бах!<br>Бах-бах-бах!<br>**Тәрбияче:** Балалар, без кәҗәне ничек чакырабыз?<br>**Балалар:**Кәҗ-кәҗ-кәҗ!<br>**Тәрбияче:** Сарыкны ничек чакырабыз?<br>**Балалар:**Бәр-бәр-бәр-бәр!<br>**Тәрбияче:** Тавыкны ничек чакырабыз?<br>**Балалар:**Чеп-чеп-чеп-чеп!<br>**Тәрбияче:** Песине ничек чакырабыз?<br>**Балалар:**Пес-пес-пес-пес!<br>**Тәрбияче:** Этне ничек чакырабыз?<br>**Балалар:**Маһ-маһ-маһ!<br>**Тәрбияче:** Атны ничек чакырабыз?<br>**Балалар:**Бах-бах-бах!<br>**III. Йомгаклау өлеше.**<br>**Тәрбияче:**Булдырдыгыз, балалар.Хәзергә хайваннар бик арыдылар. Алар ял итсеннәр. Без дә сезнең белән «автобус»ка утырып бакчабызга кайтырбыз.<br>*Балалар урындыкларга утыралар, музыка кабына, бакчага кайталар.* |

**Уку өчен текстлар.**

***Такмаклар.***

***«Үчтеки, үчтеки»***

Үчтеки, үчтеки,
Үсмәгәнгә кечтеки.
Үсә – үсә зур булыр,
Бигрәк матур кыз булыр. (кызларга)

Бигрәк батыр егет булыр. (малайларга)

***«Тор-тор, тургай!»***

Тор-тор, тургай!

Таң, таң ата бугай.

Син дә кил, чыпчык!

Чырык, чырык, чырык.

***Эндәшләр.***

***Хайваннарны чакыру.***

-Чакырабыз кәҗәне*:*

- Кәҗ-кәҗ-кәҗ!

Кәҗ-кәҗ-кәҗ!

-Чакырабыз сарыкны:

-Бәр-бәр-бәр-бәр!

Бәр-бәр-бәр-бәр!

- Чакырабыз чебиләрне (тавыкларны):

-Чеп-чеп-чеп-чеп!

Чеп-чеп-чеп-чеп!

- Чакырабыз песине:

-Пес-пес-пес-пес!

Пес-пес-пес-пес!

-Чакырабыз маэмайны:

-Маһ-маһ-маһ!

Маһ-маһ-маһ!

-Чакырабыз аткайны:

-Бах-бах-бах!

Бах-бах-бах!

***Карга***

Карга әйтә: «Кар, кар,

Мичтә бәлеш бар, бар,

Мичтән бәлеш алыр идем,

Өйдә кунак бар, бар».

Карга әйтә: «Кар, кар,

Җирдә чеби бар, бар.

Берсен алып китәр идем,

Сакчылары бар, бар».

***Кояшка***

Кояш, чык!

Болыт, кач!

Без уйнарбыз җылыткач .

Кояш, чык, чык,

Майлы ботка бирермен,

Майлы ботка казанда,

Тәти кашы к базарда.

Әти китте базарга,

Тәти кашы к алырга.

Тәти кашы к сабы алтын,

Кирәкми безгә салкын.

***Бишекҗырлары.***

*******

Әлли-бәлли итәр бу,

Йокыларга китәр бу,

Йокыларга киткәчтен,

Бик дәү булып үсәр бу.

***«Песи нечкә бил»***

Песи – матур, нечкә бил,

Бала тирбәтергә кил.

Җылы җирдә яшәрсең,

Тәмле сөтләр эчәрсең,

Ап-ак кумәч ашарсың,

Ашап туйгач уйнарсың,

Уйнап туйгач йокларсың,

Бәлли-бәү! Бәлли-бәү!

***Әкиятләр.***

***Кем нәрсә ярата?***

*(Татар халык әкияте)*

Бер йортта Песи белән Эт, Әтәч һәм Кәҗә яшәгәннәр. Кич белән алар ишек төбенә җыелалар да үзләренең эшләре турында сөйләшәләр икән. Сөйләшәләр дә бәхәсләшеп тә китәләр икән. «Кем нәрсә ярата? Нинди азык тәмлерәк?» дип бәхәсләшәләр икән.

— Иң тәмле сый,— сөт,— ди Песи.— Сөттән соң бер Тычкан да тотып кабып җибәрсәң, бигрәк тә шәп була инде! Тик Тычканны тотуы кыен.

— Сөт нәрсә? Ул бит сыек, тамак туйдырмый. Ә менә ярма бөртекләрен, солы орлыгын тук-тук итеп чүпләсәң — менә шунда тамак тук-тук-тук була! — ди Әтәч.

— Юк-юк! — дип сүзгә кушыла Акбай.— Бөртек чүпләп кенә туеп бул-бул-булмый. Менә сөяк кимерсәң, чынлап та әйбәт була, шунда ук тук буласың. Нинди азык тәмле, нинди азык файдалы икәнен миннән дә әйбәт белгән хайван юк.

— Нәрсә-ә-ә сөйлисең син,— дип каршы килә Кәҗә.— Менә кәбестә-ә-ә булса икән. Иң тәмле азык — кәбестә-ә-ә! — Ди ул.

Алар бәхәсләшәләр икән әле — һаман килешә алганнары юк, ди.

***Төлке белән каз***

*(Татар халык әкияте)*

Бервакыт Төлке Казны тотып алган да:

— Каз, мин сине ашыйм,— дигән. Каз боегып калган.

— Мин риза, Төлке. Тик син миңа бер биеп калырга рөхсәт ит,— дигән Каз.

— Әйдә, бие,— дигән Төлке.— Ашарга өлгерермен әле. Каз, канатларын җилпеп, бер урында тыпырдый башлаган. Төлке:

— Әй оста биисең, Каз,— дип көлә икән.

Ә Каз, канатларын җилпеп, бер урында торган-торган да очкан да киткән.

Төлке авызын ачып калган.

***Бармак уеннары.***

***

Бу бармак-бабай,

Бу бармак -әби,

Бу бармак -әти,

Бу бармак -әни,

Бу бармак-нәни бәби,

Аның исеме - чәнти!

***

— Бармак, бармак,

Кайда булдың?

— Бу абый белән

Урманга бардым.

Бу абый белән

Кырда йөгердем.

Бу абый белән

Ботка ашадым.

Бу энем белән

Җыр җырладым.

***Татар халык уеннары.***

***Хәрәкәтле уен: «Күрсәт әле, үскәнем»***

-Күрсәт әле, үскәнем, ничек сыер мөгри?

-Му-му-му,- диеп,

Безнең сыер мөгри.

-Күрсәт әле, үскәнем, ничек кәҗә кычкыра?

-Мә-мә-мә,- диеп,

Безнең кәҗә кычкыра.

-Күрсәтәле, үскәнем, ничекпеси мияулый?

-Мияу-мияу-мияу,- диеп,

Безнең песи мияулый.

-Күрсәтәле, үскәнем, ничекэтләрөрәләр?

-Һау-һау, ау-ау, -диеп,

Безнең этләр өрәләр.

***«Кәккүк — чыпчык» уены.***

Кәккүк, чыпчык,

Тәрәзәдән очып чык,

Галиянең өстенә

Матур күлмәк биреп чык.

***«Җилэк җыям, как коям» уены.***

Балаларның берсе аю яки бүре булып берәр җирдә посып тора. Башкалары урманга «җиләк җыярга» китәләр. Берәү аларга каршы очрап сораша:

— Дуслар, кая барасыз?

— Кара урманга барабыз.

— Кара урманда нишлисез?

— Кура җиләк җыябыз.

— Җилә к белән нишлисез?

— Җиләктән как коябыз.

— Бүре килсә нишлисез?

— Урман буйлап чабабыз.

Аннан соң барысы да күмәкләп җырлыйлар:

*Җиләк җыям, как коям,*

*Дәү әнигә бүләккә;*

*Монда җиләк күп икән,*

*Аю-бүре юк икән.*

Бүре яшеренгән җиреннән сикереп чыга да аларны куа башлый. Кемне тотса, шул бүре була.

Уен йөгереклек һәм җитезлек сәләтен үстерүгә ярдәм итә.

**Кулланылган әдәбият**


1. Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы / төз.: К. В. Закирова, Р. А. Борһанова. — Казан : Хәтер, 2000.
2. Гөлбакча : балалар бакчалары өчен хрестоматия : балалар бакчаларында эшләүче тәрбиячеләр өчен кулланма. — Казан : Татар. кит.нәшр., 1990.
3. Закирова,К. В. Иң матур сүз. – Казан : Мәгариф,2000.
4. Закирова, К. В. Балачак аланы: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия. – Казан : РИЦ, 2011.
5. Исәнбәт, Н. Балалар фольклоры һәм җырлы-сүзле йөз төрле уен. – Казан : Тат.китап нәшер.,1984.
6. “Мәгариф” журналлары белән танышып бару.
7. Хәзрәтова, Ф. В. Туган телдә сөйләшәбез / Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина. – Казан : Татар.кит. нәшр., 2012.



*Валеева Лейсан Мидхат кызы,*

*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Адымнар – Түбән Кама полилингваль гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең туган тел һәм әдәбияты укытучысы*


**Укучыларда ватанпәрвәрлек хисләре тәрбияләү – һәрберебезнең бурычы**

**(эш тәҗрибәсеннән)**

*Яшь буынны халкыбызның рухи һәм мәдәни хәзинәләре нигезендә тәрбияләү, балаларда милли үзаң формалаштыру һәм шуның аша туган телен, халкын ихтирам итүче, аның тарихын өйрәнүгә, үстерүгә сәләтле, рухи-әхлакый һәм белем дәрәҗәсе ягыннан камил, киң карашлы патриот шәхес тәрбияләү – безнең төп бурычыбыз.* Гомеренең башлангыч чорыннан ук балага туган җиргә карата мәхәббәт уятырга, ныклы характер тәрбияләргә кирәк. Бу сыйфатлар аңа үз Ватанының гражданы булырга ярдәм итәчәк. Граждан булу – җәмгыять һәм Ватан алдындагы гражданлык бурычларын аңлы һәм актив үтәү,

ватанпәрвәрлек, кешеләргә һәм табигатькә гуманлы мөнәсәбәт кебек шәхес сыйфатларына ия булу дигән сүз. Бу уңайдан мәдәниятkә һәм тарихи кыйммәтләргә дә игътибар итү мөһим.

Патриотизм хисе эчтәлеге буенча күпкырлы: туган телгә, туган якка мәхәббәт, үз халкың белән горурлану, үз илеңнең байлыгын арттыру һәм аны сакларга теләк булдыру. «Әгәр дә милләтне көчле итеп, бөек итеп күрәсең килә икән, иң беренче булып аның көчен таны, шул милләтнең баласы булуың белән горурлан», - дип язган бөек шәхесебез Т.Миңнуллин. Чыннан да, балаларга патриотик тәрбия бирү туган телдән башка мөмкин түгел. Шуңа күрә баланың аңы үсү, белеме арту, чынбарлыкны танып белүе һәм чын кеше булып тәрбияләнүе аның туган телен – ана телен белүенә бәйле. *Үз илен, туган җирен, халкын, аның гореф – гадәтләрен, милли традицияләрен хөрмәт итүче, аны яратучы шәхес тәрбияләүгә, без, укытучылар, кулдан килгәнне эшләргә тиешбез.*

Туган тел – туган җир, туган ил төшенчәләренең төп мәгънәсен бала аңына җиткерүче иң мөһим корал. Гимназиябезнең күркәм традициясенә әйләнеп барган «Татарча җомга», һичшиксез, балаларны татар телендә сөйләшергә теләк уятучы матур бер чара. Бу көнне озын тәнәфесләр чын мәгънәсендә бәйрәмгә әверелә. Милли калфаклы кызлар, түбәтәйләр кигән малайлар дәртле-моңлы татар җырлары яңгыраган мәйданчыкка ашыга-ашыга җыела. Аларның шатлыклары йөзләренә чыккан.  Бу көнне бөтен кеше татарча гына сөйләшә. Укытучы апалары балаларга яңа сүзләр өйрәтә. Балалар бик тырышып татарча сүзтезмәләр, җөмләләр  төзиләр. Заманча татар җырларына флешмоб бию чараны аеруча да бизи. Ә инде «Адымнар»ның гимнына әверелгән җырны башкару моментын балалар көтеп җиткерә алмый. Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Эльвина Айрат кызы Унверен бу җырында телебезнең матурлыгын, гореф-гадәтләребезне саклау кирәклеген, әдәпле булуның яхшы сыйфат икәнен әйтеп бирә алган. «Татулыкта һәм дуслыкта яшик әле «Адымнар»да дигән сүзләр белән тәмамланган җыр сүзләре һәркемне яңадан-яңа очрашуларга рухландыра, берләштерә һәм дуслаштыра. Без балаларны милли рухта тәрбияләп, үзебезнең бәхетле киләчәгебезне хәзерлибез, шуңа күрә тел өйрәтүдә мондый чараларны күбрәк булдырырга дигән нияттә калабыз.

*Балаларны илебезнең ватанпарвәрләре итеп тәрбияләүдә тагын нинди үтемле чаралар кулланырга була соң?* Мин әдәбият дәресләрендә балаларга герой әдипләребезнең тормышлары, аларның иҗат эшчәнлекләре турында мөмкин кадәр тулырак мәгълүмат бирергә тырышам. Укучыларның үзләренә дә эзләнергә җирлек тудырам. Шул рәвешле фәнни-эзләнү эшләре барлыкка килә. Мәсәлән, герой-шагыйрь Муса Җәлилнең иҗатын, тормыш юлын өйрәнгәч, М.Җәлилгә куелган һәйкәлләрне барлау уе килде. Шул рәвешле «Һәйкәлләрдә – ил тарихы» дигән эш язылды. «М.Җәлил – батырлык һәм иҗат көче символы» бүлегендә шагыйрь М.Җәлил язмышы һәм Җәлил истәлегенә куелган һәйкәлләр хакында сүз барды. «М.Җәлил һәйкәленең рухи кыйммәте» дип аталган икенче бүлектә Түбән Кама шәһәрендә куелган һәйкәлнең

үзенчәлекле тарихы турында, М.Җәлил образын мәңгеләштерүнең идея-эстетик кыйммәте анализланды. М.Җәлил образын мәңгеләштерүнең идея-эстетик кыйммәте чиксез. Беренчедән, М.Җәлил – татар егете, милләтебез аның батырлыгына, гаҗәеп киңкырлы иҗатына соклана. Икенчедән, совет солдатларының һәм барлык татар халкының батырлык символы, патриотик тәрбия чарасы. Герой татар егете сынын мәңгеләштергән һәйкәлләрнең бөтен Россия буйлап урнашуы – татар кешеләре өчен олы горурлык. Һәйкәлләрдә образы мәңгеләштерелгән Муса Җәлил – ул чордагы совет солдатларының һәм барлык татар халкының батырлык үрнәге. Муса Җәлил истәлегенә куелган һәйкәл батырлык, патриотизм төшенчәсен безнең заман балаларына, киләчәк буынга аңлатырга таяныч булып та хезмәт итәчәк. Шәһәребездәге һәйкәлнең идея-эстетик эчтәлегенә салынган тагын бер мөһим юнәлеш – аның рухи мирас булуы. Җәлил туган көндә, җәлилчеләрне искә алу көннәрендә, Җиңү бәйрәмендә һәйкәл янында төрле милләт вәкилләре җыела. Һәйкәлнең идея-эстетик вазыйфасы патриотик тәрбия чарасы буларак та көчәя. Биредә иҗади фикерләр дә, сугышка каршы булу, тынычлык яклау теләкләре дә яңгырый. Бүгенге көндә актуаль булган толерантлык тәрбиясен, сугышның куркыныч афәт икәнен үтемле итеп аңлату өчен иң кулай урын. Түбәнкамалылар өчен М.Җәлил һәйкәле – шәһәрнең затлы, эчтәлекле һәм кадерле бизәге һәм тирән эчтәлекле рухи мирасы.

Ватанпәрвәрлек ул барлык гражданнар да, кемнең - кем булуына карамыйча, илгә файда китерү өчен тырышып эшләгән җәмгыятьтә генә була ала. Балалар күңелендә өмет, киләчәкнең матур булуына ышаныч ояту - укытучының төп вазифасының берсе. Үзенең үткәненә һәм тарихына хөрмәт белән караган халыкның гына киләчәге бар. Шуңа күрә без олы шәхесләребез, күркәм затларыбыз, халкыбыз үткән олы тарихыбыз, гүзәл туган җиребез белән горурланырга, алар рухы белән яшәргә, илебезнең чын патриотлары булырга һәм укучыларда да шушы сыйфатларны тәрбияләргә тиешбез.

1. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда. 1нче том. – Казан : Татар кит. нәшр., 2020.
2. Әхәт Садриев.Патриотлар тәрбиялибез. - “ Мәгариф” журналы, №3, 2010.
3. Әдипләребез: библиографик белешмәлек: 2 томда: 1 том / төз. Р.Н.Даутов, Р.Ф.Рахмани. – Казан: Тат.кит.нәшр.,2009. – 511-515 б.
4. Интернет-чыганак материаллары.

*Валиева Гульназ Расим кызы,*
*Татарстан Республикасы Казан шәһәре Совет районының «211 нче балалар бакчасы» муниципаль автономияле мәктәпкәчә белем учреждениесенең өлкән тәрбиячесе,*
*Фазылзанова Лилия Рифкат кызы,*
*Татарстан Республикасы Казан шәһәре Совет районының «211 нче балалар бакчасы» муниципаль автономияле мәктәпкәчә белем учреждениесенең татар теле тәрбиячесе*

## Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда гражданлык һәм патриотик хисләр тәрбияләүдә эш алымнары

Балаларны тәрбияләүнең иң мөһим бурычларның берсе булып балаларда югары әхлакый сыйфатлар, шул исәптән патриотизм хисе тәрбияләү тора.

Патриот булу – ул үзеңне Ватанның аерылгысыз өлеше итеп хис итү. Патриотик тәрбия бирү төшенчәсе киң мәгънәне аңлата, ягъни ул бала күңелендә Туган илнең табигатенә, туган йортына, туган авылына яки шәһәренә, халкының тарихына, аның мәдәниятенә мәхәббәт уятудан гыйбәрәт.

Ватапәрвәрлек хисләре тәрбияләү процессын кечкенәдән үк башларга кирәк, нәкъ менә шул вакытта балаларга шәхси ориентир нигезләре салына. Патриотик тәрбия белән бәйле якты хатирәләр һәм хис-кичерешләр аны үз иленең чын яклаучысы итәчәк. Яшь патриотларны тәрбияләү өчен без үз эшебездә практикада яхшы билгеле булган төрле технологияләр, формалар, ысуллар һәм алымнар кулланабыз. Ләкин вакыт узу белән, заманча таләпләрне һәм педагогик практика тенденцияләрен исәпкә алып, уңай нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек биргән инновацион алымнар кертәбез.

Балалар бакчасында инновацион технологияләр ул - яңаларын булдыру һәм кертү, укыту һәм тәрбияләү алымнары. Төп максат - барлык белем бирү процессларын модернизацияләү. Балалар бакчасының педагогик коллективы яңа методикалар эшли һәм мәктәпкәчә яшьтәге балаларны патриотик тәрбияләү модельләрен төзи.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны патриотик тәрбияләүнең инновацион технологияләре:

проект технологияләре;

очрашулар үткәрү

музейларга экскурсияләр;

музей педагогигасы;

тематик акцияләр;

семинарлар үткәрү.

Хәзерге балалар суперменнар, компьютер уеннары турында бик күп беләләр.

Ә балаларны ничек итеп туган җирләре өчен гомерләрен кызганмаган Ватанны саклаучыларны истә тотарга, совет солдатларының батырлыгы, ныклыгы белән горурланырга өйрәтергә соң? Балаларга җиткерү өчен бу белемнәрне кайдан алырга?

Нәкъ менә хәзер халкыбызның сугыш елларындагы фидакарьлеге, ныклыгы, ватанпәрвәрлеге турындагы хәтер җепләрен өзмичә, балаларда бабалары турындагы хәтер үсентеләрен кадерләү бик мөһим булып тора.

Үз эшебезне без балалар һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары белән очрашулар оештырып, алар белән әңгәмәләр уздырып, балалар үзләре ясаган кул эшләрен бүләк итү белән башлап җибәрдек. Безнең бистәбез тарихы Ленинград шәһәре белән нык бәйләнгән. Бөек Ватан сугышы башлангач Ленинградтагы оптика-механик заводы безнең бистәгә күчерелә. Шул исәптән бик күп гаиләләр дә эвакуацияләнә. Әти-әнисе белән шул вакытта күченеп килеп бистәбездә гомер иткән Карпова Галина Викторовна белән дә җылы очрашу уздырдык. Балалар аларның нинди авырлыклар белән очрашып, ничек көн күргәнлекләре турында ишеттеләр. Бистәбез турында куп кенә кызыклы фактлар ачыкланды.

Район күләмендә семинарлар үткәреп үзебезнең эш тәҗрибәбез белән уртаклашабыз. Шулай ук бистәбездәге “Хәрби дан” музееның да даими кунаклары без. Балалар Бөек Ватан сугышы вакыйгалары турында күп кызыклы мәгълүматләр алалар. Сугыш чоры экспонатларын тотып карап кына калмыйлар, ә үзләре шигырьләр сөйлиләр, сораулар бирәләр. Һәр яз саен балалар белән бергәләшеп “Үлемсез полк” акциясендә катнашабыз. Бөек Ватан сугышы геройларына һәм Ленинград блокадникларына куелган һәйкәлләргә чәчәкләр салабыз. Советлар Союзы Герое, якташыбыз Николай Липатов һәйкәленә дә балаларны еш алып барабыз.

Балаларны патриотик тәрбияләүнең мөһим бер шарты булып ата-аналар белән тыгыз бәйләнеш тора. Гаилә тарихына кагылу балада көчле эмоцияләр уята. Үткәннәрнең хәтеренә, тарихи тамырларына игътибарлы булырга мәҗбүр итә.

Электрон “Хәтер китабы” нәкъ менә шуны күздә тотып булдырылды. Тәрбияләнүчеләрнең әти-әниләре, туганнары безгә зур теләк һәм кызыксыну белән ярдәм иттеләр. Ни кадәр альбом, фотографияләр каралды, ә иң мөһиме хәтер төбендә яткан язмышлар, хатирәләр яңартылды. Никадәр балада бабалары, туганнары язмышы белән танышып, “Хәтер китабы”на үзләреннән керткән өлеш белән горурлану хисләре барлыкка килде.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга гаиләгә, туган якка, кечкенә ватанына мәхәббәт хисе бирелә. Ә бу-танып белүдә туа торган, ә максатчан тәрбия процессында формалаша торган патриотизмның башы.

“Дәрвишләр бистәсе – горурлыгым” проектында да актив катнашып әти-әниләр безнең зур ярдәмчеләребез булдылар. Бистәбезнең тарихи урыннарына әти-әниләре белән экскурсияләргә барып, аларны безгә фото-видео форматы аша җиткереп, яшьтәшләренә сөйләп балалар әйтеп бетергесез кичерешләр алдылар.

Бакчабызга 60 яшь тулу уңаеннан бакчаның беренче мөдире Альбина Павловна белән очрашып тәрбиячеләр һәм балалар үзләрен кызыксындырган сорауларга җавап таптылар. Бу очрашу да балалар күңеленең бер почмагында үз эзен алгандыр дип ышанабыз.

Патриотик тәрбиянең асылында да балаларның күңелендә туган йортка һәм гаиләгә, туган җир, туган илнең тарихына һәм мәдәниятенә мәхәббәт орлыклары чәчү һәм үстерү ята бит. Шулай итеп без тарихны, мәдәни мирасны өйрәнү нигезендә балаларда париотик хисләр тәрбияләп үткәнгә, бүгенгегә һәм киләчәккә мәхәббәт формалаштырабыз.

Һәрбер эшләнгән эшебезнең нәтиҗәсе белән видеофильмнар, видеороликлар ярдәмендә уртаклашабыз. Үз чиратында без аларны актив ссылкалар һәм QR –кодларга урнаштырып әти- әниләргә тәкъдим итәбез.

Балалар бакчасында югары әхлакый сыйфатлар һәм патриотизм хисе тәрбияләү иң төп бурычларыбызның берсе. Күп еллар дәвамында без эшебезне әлеге юнәлештә алып барабыз. Эшнең нәтиҗәлелеген арттыру максатыннан практикада яхшы билегеле булган технологияләр, ысуллар белән беррәттән инновацион алымнар да кулланабыз. Патриотик тәрбия бирү юнәлеше бакчабызда инде системага салынган. Системалы рәвештә алып барылган очракта гына эшләнгән эшнең нәтиҗәсен күрергә мөмкин. Һәрбер проект, үткәрелгән чара видеофильм, презентация буларак туплана. Без аларны актив ссылкалар формасында яки QR кодларга урнаштырабыз һәм әти- әниләргә тәкъдим итәбез.

*Валеева Суфия Васил кызы,*
*Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәренең «Мулланур Вахитов исемендәге 2нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Шагыйрь Кадыйр Сибгатуллин иҗатында шәфкатьлелек мәсьәләләре

Кеше рухы... Кадыйр Сибгатуллинның бөтен иҗаты кеше рухының асыл кыйммәтен ачуга хезмәт итә. Кеше рухының асылын тәшкил иткән сыйфатлар — игелекле

булып усү, кыюлык, батырлык, тугрылык, гаделлек, шәфкатьлелек һ. б. — халкыбызның чын мәгънәсендә рухи хәзинәләре. Без Кадыйр Сибгатуллин шигырьләрендә шушы мәсьәләләрнең чагылышын күзәтербез.

Бугенге көн кешесе нинди? Алар нәрсә белән шөгыльләнә? Киләчәккә уй-фикерләре нинди? Алар күңеленә рухи оеткыны ничек салырга? Халкыбызның мең еллар дәвамында тупланган рухи хәзинәсен — шәфкатьлелек, игелеклелек сыйфатларын, башкаларга ярдәм итәргә һәм шатлык китерергә әзер торучы шәхесләрне ничек тәрбияләргә? Шагыйрьләрне әнә шул сораулар борчый.

Бүгенге заманда ата улны, ана кызны белми. Кешеләр бер-берсенә гади генә «рәхмәт» сузен дә бик сирәк әйтә. Һәркем үзенә бикләнеп, дөнья мәшәкатьләренә чумып, шушы соры томанга төренгән деньяда яшәвен дәвам итә. Мөлаемлылык, ярдәмчеллек, эчкерсезлек, саф йөрәклелек кебек матур сыйфатлар безгә әби-бабаларыбыздан мирас булып калган. Юкса, безнең халкыбыз әдәп сакларга, ата-ана хакын хакларга, миһербанлы, шәфкатьле булырга, кеше кайгысын уртаклашырга тырышкан. Кызганыч, яшәешебезнең гузәл бер символы бул ган бу сыйфатлар акрынлап югала бара. Бәгырьне телгәли торган төссезлек, шәфкатьсезлек куңелебезне тизрәк яулый.

Яшь буынга өлкәннәрнең йогынтысы хәлиткеч әһәмияткә ия. Бу инде күптән исбатланган. Алма агачыннан ерак тешми, ди халык. Ата- ананың мәгънәле мәхәббәте балада мохиткә, кешегә кирәкле Һәр нәрсәгә карата сизгерлек, намуслылык, кешелеклелек сыйфатлары тәрбияли. Балада мондый күркәм сыйфатлар булдырырлык тәрбиялеме үзләре елкәннәр? «Тәрбия турында бер сүз» шигырендә шагыйрь болай ди:

*Балаларның әле вакыты бар: бала чагы; үсеп җитәсе; яшьлекләрен*

*үтеп, олы булып,шактый гына гомер итәсе.*

*Шуңа курә, ашыкмыйча гына, тәрбияләнгәнне көтәләр.*

*Балаларга һаман чират җитми, тәрбиягә мохтаж; өлкәннәр.*

Димәк, балаларына тиешле тәрбия бирерлек итеп, өлкәннәрнең үзләрен тәрбияләргә кирәк әле.

Бала тәрбиясенең иң күреклесе — әбиләр тәрбиясе. Әлек ул шулай булган да. Сабый балакы тәрбия итүдә вакыты белән әби ананы да алыштырган. Кызганыч, буыннар чылбыры өзелде, әби-бабай тәрбиясе бөтенләй юкка чыкты диярлек.

Кеше буларак, Кадыйр Сибгатуллин сабый чактан ук үзен дөрес юнәлештә тәрбия кылуда, чыныктыруда «үз догасы белән намазлыкта җаны чыккан», илаһи кодрәткә ия иманнан бер генә мизгелгә дә аерылмаган әбисенә рәхмәт укый. Аның бер шигыре хәтта «Рәхмәт, әби!» дип атала.

Соңгы алабута күмәчен сукыр теләнчегә биреп чыгарган әбиләренә ач оныклары бик үпкәлиләр. Еллар уткәч, шагыйрь әбисенең  мең мәртәбә хаклы икәнлегенә төшенә, үзе үрнәгендә оныгында кешеләрне кызгану, миһербанлылык, шәфкатьлелек сыйфатлары тәрбияләвенә рәхмәт укый:

*Суынып беткән*

*у л бер кумәч кенә*

*коткара алмас иде ачлыктан.*

*Сак лап калган әби рухыбызны, җаныбызны ялангачлыктан.*

Җәмгыятебез, халкыбыз үзгәреш чорын кичерә, ыгы-зыгылы, шау-шулы, борчулы заманда яши. Бу процесс байтак кына ямьсез күренешләрне китереп чыгарды. Мондый хәлгә китергән сәбәпләр һәркемгә мәгълүм. Болар—сугышу, үтерешу, асу, ату картиналары; театр сәхнәләрендә һәм кино сәнгатендә  ятак мәсьәләләре, тотнаксызлык, әдәпсезлек, рәхимсезлек үрнәкләре белән шыплап тутыру һ.б., һ.б. Нәкъ менә шулар шәфкатьлелек, олыны олылау, кечене кече итеп күрү дефицитын китереп чыгарды да инде.

Ә нәтиҗәләр әнә куз алдында: урамнарда оешкан төркемнәр, рекетчылык, җинаятьчелек, әхлаксызлык, рухи бушлык, битарафлык. «Кыйбла», «иман» төшенчәләреннән һич хәбәре булмаган рәхимсез буын кабер ташларын ватып йөри, туганнар каберлекләрен мәсхәрәли, талый, зираттагы язмаларны укымый, андагы сурәтләргә куз сал мый. Баласы каберләр туздырып йөргән, бабалары турындагы хәтере үтерелгән гаилә дә, андый гаиләләрдән торган җәмгыять тә бәхетле була алмый.

*Нинди хәсрәт?*

*Нинди афәт килә?*

*Шатлыкларны кемнәр урлады?*

*Кая безнең балкып торган куңел?*

*Күзебезнең кая нурлары ?*

*Җылы суздән курка Кеше бүген.*

*Елмаю да безгә килешми.*

*Калырмы у л шулай?*

*Терелерме?*

*Ташка әйләнеп тәмам бетәрме?*

— дип үрсәләнә шагыйрь «Кая таба...» шигырендә.

«И Тәңре!» шигырендә ул, Тәңрегә дәшеп, кешелекне бу шакшылыктан коткаруны сорап ялвара,

*Балаларым сиңа табынганнар, сиңа карап мин дә ялварам.*

*Кеше булып шуган бит мин.*

*Яшим*

*һәм яшәргә телим мин мәңге.*

Әйе, кешеләрнең җаны суынды, куңелле катты, игелек кылуны хәтта аңлый алмаслык хәлгә килдек түгелме? Шагыйрьнең «Игелекле бәндә» шигырендә әйтелгән фикерләр нәкъ менә шул турыда.

Шагыйрь һәр адымда шәфкатьсезлек белән очраша. Кешеләрнең табигатькә, хайваннарга булган рәхимсезлеге, битарафлыгы, миһербансызлыгы изә-сыта аны. Коргаксыган, имгәтелгән, таланган, юкка чыгарылган табигатьне күреп йөрәге сызлана. «И табигать» шигырендә бол ай ди:

*Бер әйләнәм таныш су буйларын.*

*Буасы юк.*

*Таллар корыган.*

*Сазлык кына калган без муеннан*

*балык сөзеп йөргән урыннан.*

*Ишелгәннәр ярлар.*

*Беткән камыш.*

*Бәгыръләрем китә өзелеп.*

*Кайчан гына әле чыктык бит без Бу суларда атлар йөздереп.*

*Су буйлары ятим...*

(«Мин танымыйм сезне»)

Әйе, Татар иленең йөзләгән авыллары, зиратлары да су астында калды. Анда безнең үткәнебез, тарихыбыз, бүгенге көнебез, киләчәгебез ята. Хак Тәгалә алдында без үзебез гөнаһлы; коткыга бирелеп, үзебез үк табигатькә зыян салабыз. Аны да Ходай Тәгалә яраткан, яшәргә тиеш, югыйсә. Бернәрсә дә артык йә ким итеп яратылмаган. Нәрсәнедер бетерергә кешенең хакы юк. Бу — шәфкатьсезлек. Бу — гөнаһ. Ул аңа каргыш булып кайта.Кешеләр тарафыннан кылынган шәфкатьсезлекнең, кансызлык ның иң югары үрнәге «Кабер ташы» шигырендә сурәтләнә. Бөек Болгар җиренә салынган чиркәү нигезенә безнең бабаларыбыз каберлекләреннән алынган ташлар түшәлә. Шагыйрьнең җаны шуңа әрни:

*Кабер ташын —*

*Болгар һәйкәлләрен, йолкып үлгәннәрнең күкрәгеннән, канга манып, чиркә ташы иткән, сөякләрне сытып күтәрелгән.*

*Залим кансыз!*

*Ирек бирсәң, түшәр кемнекен дә — мәлгунь өчен дин дә,*

*Алла да юк.*

*Болгар ташы чиркәү асларында.*

Баланы рухи яктан сәламәт, һәряктан камил шәхес итеп тәрбияләүнең нигезендә халык пфедагогикасы ята. Ә анда халкыбызньң бала тәрбияләү белән багланышлы карашлары, фикерләре, ысуллары тупланган һәм бу гаҗәеп рухи хәзинә, өзлексез камилләшә барып, буыннан буынга тапшырылган.

Яңа буын уз чиратында меңәр ел тупланган гореф-гадәтләрне, йолаларны саклап, телен-динен хөрмәтләп яшәгән. Олыны — олы, кечене — кече дип караган. Картайган ата-анасын тәрбия кылуны, тудырган баласын багып үстеруне изге бурычы итеп санаган, бәндәнең рәнҗеш- каргышыннан, ананың бәддогасыннан уттан курыккан кебек курыккан. Хак хаклый белгән безнең халык: Алла хакын, ата-ана хакын, күрше хакын, тол-ятимнәр, ярлы-ябагайлар хакын, милләт хакын...

Безнең татар халкы узенең кешелеклеге, шәфкатьлеге белән аерылып торган. Татар халкында «приют» дигән сүз дә юк. Чөнки бу сүзгә мохтаҗлык та булмаган. Әгәр авылда ятим бала калса, аны авыл белән карап үстергәннәр; әгәр карт кеше ялгыз булып авырып ятса, бетен авыл халкы аны ашаткан, тәрбия кылган, соңгы юлга озаткан. Татар халкында мунча яксаң да, куршедә яшәүче ялгыз карчыкка мунчага әйтү гадәте хәзергә кадәр яши. Һәр җомга көнне күршегә сөт, каймак, күчтәнәч кертү күркәм гадәт булып яшәвен дәвам итә. Димәк, шәфкатьлелек безнең геннарда, каныбызда. Әгәр бу яктылыкның нурын без киләчәк буынга да буләк итсәк, аларның да куңеле изгелек нуры белән тулыр һәм безнең илебездә картлар йортына да, ятим балалар интернатына да, гарипләр йортына да ихтыяҗ тумас.

Халкыбызның күренекле улы Р Фәхретдин алтын хәрефләр белән язып элярлек сүзләр язган: «Бала чакта алынган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас».

Балаларның күңеленә шәфкатьлелек орлыкларын кече яшьтән ук салырга, аларны динле-иманлы итеп тәрбияләргә иде. Бу фикер К. Сибгатуллин иҗатында кызыл җеп булып сузылган.

*Имансызлар артты, шәфкатьсезләр...*

*Болай яшәү, Ходa, мөмкин түгел.*

*Кичер безне!*

*Борыл безгә таба.*

*Туктата күр безнең вәхшилекне.*

*Соңгы өмет синдә.*

*Тик син генә*

*коткарырсың безне — кешелекне*!

*(«Дога»)*

К. Сибгатуллин әдәбиятка бай мирас калдырып китте. Аның шигырьләрен укыганда, чыннан да аның иманлы шагыйрь булуына, уз иманыңа тугры калган шәхес булуына инанасың.

Иҗатының иң бөек ноктасына менеп җитеп, шигърият күгендә якты йолдыз булып кабынган Кадыйр Сибгатуллин, әгәр кара үлем арабыздан вакытсыз элек йолкып алмаган булса, безне үзенең ижат җимешләре белән тагын да ныграк куандырган булыр иде.

Кулланган әдәбият исемлеге:


1. Мәйдан. — 2002. — № 2. — 208 б.
2. Сибгатуллин, К. И. Осенняя весна: Стихи. — Казань : Татарское газетно-книжное издательство, 1999. — 224 б.
3. Сибгатуллин, К. И. Гомерем дулкыннары. — Казан : Татар, кит. нәшр., 1993. — 239 б.



*Гайнутдинова Зальфира Рашид кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 16 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең туган тел һәм әдәбияты укытучысы,*
*Шарифуллина Алсу Ильнур кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 16 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы*


## Әдәби әсәрләр аша яшь буынга патриотик тәрбия бирү.

Матур әдәбиятта халыкның яшәү рәвеше, теләк-омтылышлары, барыннан да бигрәк гасырлар дәвамында тупланып килгән әхлакый кыйммәтләре чагылыш таба һәм сакланып килә. Шул ук вакытта әлеге рухи мирасны буыннан буынга күчерүгә дә хезмәт итә. Һәрбер халыкның рухи кыйммәтләре арасында туган ил, туган җир, ата-ана белән бәйле булганнары киң урын алып, яшь буынны тәрбияләүдә нигез булып сакланалар. Туган җир кече ватан, ә инде туган ил зур ватан төшенчәләре белән бәйле. Икенчесе илне яклау һәм саклау белән дә тыгыз бәйле. Патриотик тәрбия нәкъ менә әлеге төшенчәне, күренешне алгы планга чыгарып куя.

Билгеле, әдәби әсәрләрдә туган илне саклау мәсьәләсе киң урын алган кебек, аларны өйрәнү дә мәктәптә үк башлана. Мәктәптә белем бирү системасында ул тагы да үстерелә, баетыла. 13-16 яшьлек яшүсмерләрнең бу төшенчәләрне тулы һәм бөтен эчтәлегендә аңлавы һәм күңелләренә сеңдерүе тәрбияви процессның бер өлеше. Әдәбият дәресләре, сыйныф сәгатьләре, китапханә һәм музей дәресләре, төрле дәрестән тыш чаралар моның өчен яхшы җирлек булып тора.

Без төрле купшы сүзләрне еш кулланабыз, ә кайвакыт аның эчтәлегенә игътибар итмибез. Мәктәп укучылары белән эшләгәндә моның кирәклеге аеруча күзгә ташлана. Төрле гаиләдә тәрбияләнгән, төрле мохиттә яшәгән яшүсмерләр бит. Сүзне “патриотизм” төшенчәсен аңлатудан башлыйк. “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә бу төшенчәгә мондый аңлатма бирелә: “Патриотизм – патриотларга хас булган күренеш (эш, теләк, хис); үз иленә, халкына мәхәббәт”. Икенче төрле, патриотизм – үз илеңә, туган телеңә, халкыңа, табигатькә, милли традицияләргә, мәдәниятkә мәхәббәт ул. Нәкъ шулай, туган телеңне, халкыңны ярату да патриотизмның җитди бер сыйфаты. Милләтне ярату да туган җир һәм туган ил төшенчәләреннән аерылгысыз.

Яшь буында патриотизм хисе тәрбияләүдә матур әдәбият зур урын алып тора. Бу яктан бигрәк тә Бөек Ватан сугышы турындагы әсәрләр укучылар өчен тәрбияви яктан әһәмиятле. Патриотизмның иң матур үрнәкләре белән Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Гадел Кутуй, Габдрахман Әпсәләмов кебек әдипләр иҗатында очрашабыз. Мисал өчен, Ф. Кәримнең “Ант”, “Ватаным өчен” шигырьләре, “Кыңгыраулы яшел гармун”, “Үлем уены”, “Партизан хатыны” поэмалары аша укучылар туган җир, тынычлык, ирек кадерен, яшәү ямен аңлыйлар. Гомумән, Ф.Кәрим иҗатына мәктәптә дәрестән тыш чаралар үткәргәндә киң урын бирелә. Аның иҗаты Бөек Ватан сугышы чоры татар әдәбиятының иң матур үрнәкләреннән берсе һәм укучылар бик тә теләп, яратып өйрәнәләр.

Ә инде патриотизмның аеруча тәэсирле үрнәге булып герой-шагыйрь М. Җәлилнең тормышы һәм иҗаты тора. Җәлил иҗатын өйрәнгәндә укытучының бурычы – герой шагыйрьнең һәм җәлилчеләрнең палач балтасы алдында да үзләрен горур тотулары үрнәгендә патриотизм хисенең асылын аңлауга китерү һәм шуңа омтылыш формалаштыру. Моның өчен иң үтемле чыганак булып “Моабит дәфтәрләре” җыентыгы тора. Фашист тоткынлыгында язылган “Моабит дәфтәрләре” җыентыгындагы шигырьләрдә кеше рухының зур эмоциональ көч һәм камиллек белән сурәтләнгән бөеклеге, гуманистик табигате, хакыйкатьнең ачылуына ышанычы, туган иленә, халкына чиксез мәхәббәте күрсәтелә. Укытучы ярдәмендә әлеге шигырьләр аша укучыларда үз-үзенә ышаныч, ихтыяр көче, ватанпәрвәрлек сыйфатлары турында сүз алып барыла, әңгәмә корыла, әлеге хисләр чагылышына мисаллар китерелә. Иң мөһиме – укучыларның үзләрен аерым бер нәтиҗәләргә китерү.

Гадел Кутуй иҗатын да укучылар яратып укый. Әдипнең туган илгә карата мәхәббәт хисе белән сугарылган иң матур әсәре берсе – “Сагыну” нәсере. Нәсердә лирик геройның сагыну хисе үзәккә куелып, ул яңадан-яңа төсмерләр белән үстерелә, күпертелә һәм туган илне, туган җирне ярату булып үсә. Бу әсәрдән укучылар шуны аңлый: кендек каны тамган туган җирне чит илнең бернинди матурлыгы да алыштыра алмый. “Сагындым, бик сагындым сине, Туган ил!” Әлеге фикер бөтен әсәр аша үтеп, яшүсмер күңеленә дә үтеп керә, аны уйланырга этәрә. Әсәрдән солдатның туган иленә булган иң көчле хисләрен туплаган өзекне ятлату да уңышлы алым. Текст аша укучы гыйбрәтле үрнәк ала: туган ил, туган җир һәркем өчен, эти-әни кебек, бар нәрсәдән дә газиз һәм кадерле!

Талантлы прозаик Г.Әпсәләмов әсәрләре дә укучыларда кыюлык, җаваплылык, олы җанлылык, ватанпәрвәрлек кебек сыйфатлар формалаштыруда җитди таяныч булып тора. Әсәрләренең геройлары – яшүсмерләр өчен үрнәк булырлык тәвәккәл, осталык таләп итә торган һөнәр кешеләре. Алар үзләренә тапшырылган бурычны намус белән башкарып чыгучылар. Ә инде әлеге бурычны үтәү өчен никадәр түземлек, батырлык, максатка ирешү теләге, рухи көч кирәклеге текстны өйрәнү барышында аңлатыла, мисалларда дәлилләнә.

Г. Әпсәләмов сугыш елларында “Төньяк балкышы”, “Бөркет токымы”, “Давыл”, “Хайбулла солдат”, “Зәңгәр кыя”, “Егетнең асылы”, “Зәңгәр иртә”, “Уссури карурманнарында”, “Ак төннәр” исемле хикәя-повестьлар иҗат итә. Санап кителгән әсәрләрнең геройлары гаҗәеп кыю, батыр сугышчылар, ватан өчен, туган ил азатлыгы өчен гомерләрен бирергә әзер солдатлар булып алга килеп баса. Алар үзенең гаиләсен, йортын гына түгел, илен якларга ант иткән кешеләр. Җинүгә ышаныч аларга көч бирә һәм еш кына үлемнән дә саклап кала. Төрле милләт халыкларының туганнарча дуслыгы бер-берсенә көч бирә, ышаныч тәрбияли. Дошманга нәфрәт хисе исә батырлыкка, әлеге дошманны үз өнендә юк итүгә чакыра.

Г.Әпсәләмовның “Газинур” романы тормышчан вакыйгаларга, чынбарлыкта булган кеше образына мөрәҗәгать итүе белән игътибарга лаек. Газинур образы авторның әдәби табышы булып тора [3: 398]. Гади авыл егетенең сугыш кырында батырлыклар күрсәтүе – белә торып үлемгә баруы – моның гыйбрәтле мисалы. Романда әйтелгәнчә, Газинур Гафиятуллин үлем белән үлемсезлек арасын үтеп, гасырлар буе яши торган батырлык кыла.

Патриотизм, илне саклау темасы киң урын алган әсәрләр гасырлар дәвамында китап укучылар тарафыннан яратып укыла. Аның нигезе – гыйбрәтле үрнәк булуда.

Без югарыда сугыш батырлыгы турында сүз алып бардык. Милләткә фидакарьләрчә хезмәт итеп тә халык күңелендә калып була. Мисал өчен, татар халкының батыр уллары, милләтпарвәр кешеләре дип Садрый Максуди, Йосыф Акчура, Ризаэтдин Фәхретдин, Гаяз Исхакый һ.б. атый алабыз. Бөек Тукаебыз да – татар патриоты. Замандашларыбыздан

танылган драматург Туфан Миңнуллин да – Татарстан патриоты. Аның иҗаты, эшгамәлләре халкының бүгенгесе һәм киләчәге өчен башкарылып, яңа буын күңелендә өметышаныч хисләре тәрбияләргә ярдәм итә. Милләтнең мондый батыр уллары халык хәтерендә озак саклана.

Шулай итеп, татар әдәбиятының иң матур үрнәкләре нигезендә укучылар күңелендә туган илне, туган җирне ярату, аның киләчәгенә хезмәт итү хисләре тәрбияләү изге бурыч булып тора. Каршылыклы заман шартларында, әхлакый кыйммәтләргә караш шактый үзгәреш кичерсә дә, әхлакый кыйммәтләр белән бергә, патриотизм хисе дә кешелекнең асылын билгеләүче сыйфат буларак укыту-тәрбия эшендә гаять җитди урын алып тора.

Әдәбият

1. Бөек Ватан сугышы чоры поэзиясе: шигырьләр һәм поэмалар. – Казан : Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты, 2005. – 189 б.

2. Мостафин, Р. Ә. Җәлилчеләр: очерклар, җәлилчеләр иҗаты. – Казан : Татар. Кит. нәшр., 1988. – 215 б.

3. Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. 5 нче том: Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы еллар әдәбияты (1941 – 1960). – Казан : Татар. Кит. нәшр., 1989. – 563 б.

4. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда. 2 том. – Казан : Татар.кит.нәшр., 1979. – 726 б.

*Галиева Энҗе Илһам кызы,*
*Юнысова Гөлназ Рамир кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «36 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең беренче һәм югары категорияле туган тел һәм әдәбияты укытучылары*

**Уйный, уйный укыйбыз (телнең лексикасын һәм грамматикасын уеннар аркылы, проблемалы укытуга нигезләнеп, укучыларга җиткерү).**

Максат: проблемалы укытуны уен технологияләрен кулланып оештыру, отышлы якларын күрсәтү, туган тел һәм әдәбият дәресләрен кызыклы итеп үткәрү ысулларын билгеләү.

Җиһазлау: ноутбук, колонка, экран, презентация, релаксация өчен музыка, хайван, җиләк-җимеш, кирпеч, түбә, тәрәзә, Маша, Күмәч рәсемнәре, ашамлыклар сүзе язылган карточка.

Мастер-класс барышы.

I. Ориентлашу-мотивлаштыру этабы.

а) Исәнләшү.

- Исәнмесез, хөрмәтле коллегалар, хәерле көннәр сезгә! Без 36 нчы мәктәпнең туган тел һәм әдәбияты укытучылары Галиева Энҗе Илһам кызы, Юнысова Гөлназ Рамир кызы булабыз.

ә) Уңай психологик халәт тудыру.

Сез барыгыз да аргансыздыр инде, шуңа да мин сезгә бераз ял итеп алырга тәкъдим итәм. Ләкин бер шарт белән: барыбыз бергә күңелле ял итәбез. Мин бер хикәят сөйләрмен, ә сез булышырсыз. Сөйләү барышында хәрәкәтләр күрсәтермен, сез минем арттан кабатлап барырсыз.

Шулай итеп, башлыйбыз! Яшәгән, ди, булган, ди, бер бакчачы. Бакчачы агачларны яраткан һәм ел саен үзенең бакчасына берничә төр яңа агачлар утырта торган булган. Бервакыт дуслары аңа орлыклар бүләк иткәннәр. Бу имән, чикләвек, өрәңге, алмагач, груша агачларының орлыклары икән. (Яхшылап утырыгыз, күзләрегезне йомыгыз һәм күзалдыгызга китерегез: сез шушы орлыклар).

Бакчачы әлеге орлыкларны үз бакчасына утырткан, аларга су сипкән, җирне йомшарткан, хәтта алар белән сөйләшеп тә йөргән. Менә яз җиткән (күзләрне ачабыз), бакча уянган, беренче кояш нурлары төшү белән яшь үсентеләр калкып чыккан. (Әкрен генә кулларны өскә күтәрәбез).

Үсентеләрнең яшь яфраклары чыккан (куллар баш өстендә, уч төпләрен алга юнәлдерәбез), бөреләнгән агач ботаклары күренә башлаган (кулларны йодрыклыйбыз), ниһаять, бөреләр ачылган (йодрыкларны кисәк ачабыз), шулай итеп, үсентеләр яшь агачка әверелгән (кулларны аска төшерәбез, арканы туры тотып утырабыз).

Яз эссе җәй белән алмашкан. Бакчачы эшен дәвам иткән, агачларны корткычлардан саклаган, эссе кояш нурларыннан каплаган. Яшь агачлар үскән (торабыз), елмайганнар (елмаябыз), иртәнге якта бер-берсен сәламләп, яннарында үскән агачларга баш игәннәр (бер-беребезгә карап, елмаеп баш иябез).

Көз җиткән (әкрен генә үз урыннарыбызга утырабыз). Һәрбер агач бакчачыга, рәхмәт әйтеп, үзләренең уңышларын, орлыкларын биргән (үз-үзебезгә кул чабабыз).

Барыгызга да рәхмәт.

II. Проблемалы сорау кую.

Хөрмәтле коллегалар! Без һәрберебез бакчачы. Мул уңыш алуыбыз бары тик осталыгыбыздан, теләгебездән генә тора. Ә бүген мин сезнең алда бакчачы ролен башкарам, шуңа күрә бик тырышам, ләкин бераз каушыйм да, чөнки яхшы уңыш җыясым килә. Аның нинди булуы, тәкъдим ителгән мастер-классның файдалыгыннан тора.

- Дәресне ничек кызыклы итеп үткәрергә? Кечкенә сабый күңеленә ничек юл табарга? Бу сораулар барлык укытучыларны да борчый. Сезнең фикерегезчә, ничек?

- Дөрес, кызыксындырырга, мавыктырырга. Ә ничек соң баларны бүгенге көндә мавыктырып була?

- Килешәм, уеннар аркылы. Чөнки замана нинди булуына карамастан, бала бала инде ул, уйнап үсә.

- Ә хәзер тагын бер сорауга җавап бирегез: нинди генә телне өйрәнсәк тә, иң беренче без нәрсә белән танышабыз? (авазлар, хәрефләр, әлифба, сүзләр)

- Дөрес, сүзләр белән танышабыз. Балага сүзләрне бирдек, ди, алар аны өйрәнәчәкме соң? (ятлый, юк, исендә калдырырга тырыша)

- Ә уен аркылы сүзләрне истә калдырып буламы икән? (Була).

- Әйдәгез тикшереп карыйк.

(Уеннарда дөрес җавап өчен җиләк-җимеш рәсемнәре таратыла)

III. Проблемалы сорауны чишү ысулын күрсәтү.

1. "Нәрсә качкан?"

- Тактага игътибар итегез әле. Анда хайваннар. Минем арттан кабатлыйбыз.

- Хәзер үзегез әйтеп карагыз.

- Күзләрне йомдык. Ә хәзер ачыгыз, нәрсәләр качкан?

2. "Чайнворд" (ашамлык сүзе булачак)

- Монда бер сүз язылган. Аның соңгы хәрефе нинди, шул хәрефкә башланган сүз әйтергә тиеш буласыз. Алдагы укучы икенче сүзнең соңгы хәрефенә сүз уйлый һәм шулай дәвам итә.

3. “Чуар йорт”

-Безнең ике төркем бар. Без хәзер төзүчеләр. Кемнәр әле ул төзүчеләр?

- Ә сезнең төзүче буласыгыз киләме?

-Ярый алайса, бүген Карлсон һәм Винни-Пухка йорт төзербез. Һәрбер төркемнең бригадиры булырга тиеш. Сезнең төркемнең бригадиры кем?

-Яхшы алдыгызда төрле төстәге кирпечләр бар. Һәрбер төзүче кирпечнең төсен дөрес әйтеп сала. Бригадир карап, тикшереп тора. Кем дөрес әйтми, кирпеч салынмыйча кала. Башлыйбыз.

4. “Фоторобот төзе”

- Без хәзер полиция хезмәткәрләре. Ике мультфильм герое югалган. Безгә аларның фотороботын төзергә кирәк.

Төркемнәр уйлагыз, кем югалган.

-Хәзер, беренче төркемнән һәрбер кеше югалган геройны бер җөмлә белән тасвирлый. Икенче төркем кем югалганлыгын атарга тиеш. Башлыйбыз.

(Маша, күмәч (колобок))

- Хәзер икенче төркем тасвирлый.

- Ә уеннар аркылы грамматиканы өйрәнеп буламы икән? Әйдәгез әле тикшереп карыйк.

5. "Капка" – (кая? кайда? кайдан? сорауларына җавап бирүне камилләштерү)

Һәрбер төркемнән берәр кешене такта алдына чакырам. Сез кулларыгыз белән капка ясыйсыз һәм кая? кайда? кайдан? сүзләрен кулланып төрле сораулар бирәсез. Ә утыручылар чиратлашып җавап бирәләр. Кем дөрес җавап бирә, капка аша уза, ялгышканнар кире урыннарына утыралар.

IV. Рефлексия

- Хәзер мастер-класс башында сөйләнгән хикәятне искә төшереп, бакчачының эшенә бәя биреп, уңышларның ниндилеген билгеләп, нәтиҗә ясыйк.

(Уеннар дәресне кызыклы итә, телне өйрәнү теләге туа)

- Балалар мондый дәресләрне бик яхшы кабул итерләр кебек, чөнки үзебезгә дә бик кызык булды.

- Мин үземә яңа мәгълүмат алдым.

- Дөрес, дәресләрдә уен технологиясен куллану уңай нәтиҗә бирә. Сүзләрне, грамматик билгеләрне өйрәнүне җиңеләйтә, укучыларны кызыксындыра, теләкләрен уята, шул ук вакытта күзәтүчәнлек, игътибарлылык, сабырлык кебек сыйфатларын, хәтер һәм зиһенен үстерә, фикерләү сәләте үсеше белән бергә, туган телгә мәхәббәт тә тәрбияләнә.

*Галимова Гөлфинә Салихҗан кызы,*

*Гыйздәтуллина Эльмира Мирзәгыйть кызы,*

*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге «1 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты, инглиз теле укытучылары*

## I сыйныф укучыларында игътибарлылык тәрбияләү

Дәресне игътибар белән укучы яңа материалны җиңелрәк кабул итә, анлый һәм хәтердә калдыра, шуның белән үзенең алдагы эшләрен җиңеләйтә. «Игътибар!» Бу сүз дәресләрдә еш кулланыла. Шушы сүз белән кечкенәләрне фикер тупларга, эшчәнлекләрен максатчан файдаланырга өнди. Ләкин бер тапкыр эндәшү генә һәрвакытта да тиешенчә

нәтиҗә бирә дип әйтеп булмый. Шуңа күрә көндәлек хезмәттә балаларның ирекле фикер йөртү сәләтен үстерүгә игътибар итәргә. Моның өчен дәресләрдә һәрвакыт игътибар туплау, фикерләү эшчәнлеген үстерү максатыннан телдән исәпләү күнегүләре уен элементларын кулланырга, дифференциаль һәм индивидуаль эшләр оештырырга була.Кызыксыну булса, игътибар да артачак.

I сыйныф укучылары уенга бик мохтаҗ булганлыктан, уен элементларын яшь үзенчәлекләренә туры китереп сайларга кирәк. Уенның дәрес темасы белән бәйле булуы шарт.

Мәсәлән, **«Барысына да игътибар ит!»** уены. Җыю полотносына бер рәткә 7-8 предмет –алма, кыяр, груша төшерелгән рәсемнәр куям. Балаларга аларны игътибар белән карарга кушам. Моның өчен 10 секундлап вакыт бирелә, ә аннан предметларны ябам һәм балаларга аларны мин куйган эзлеклелектә санарга кушам. Ике-өч рәсемнең урынын алыштырам һәм җыю полотносында нәрсә үзгәргәнен сорыйм. Бер картинаны алып куям һәм кайсы рәсемнең юкка чыгуын ачыклыйм.

Бу уенны, шул ук биремнәрне кулланып, предметлы картиналарны геометрик фигуралар белән алыштырып та үткәрергә була. (Рәсемдә нинди фигуралар ясалган?Алар ничә? Нинди төстә? Нинди эзлеклелектә ясалган?һ.б. ш.)Фигураларны, индивидуаль санау материалы кулланып, парталарда да шушы ук эзлеклелектә урнаштыруларын үтенәм. Һәр баланың да бу эшне үтәвенә ирешергә кирәк.

Саннар һәм аларның төзелешен өйрәнгәндә табышмаклар, шигырьләр файдаланырга була һәм балалар кайсы сан белән танышуыбызны аңлап алалар.

Сан төзелешен өйрәнгән саен шигырь рәвешендә мисаллар төзибез.

**Айдар китте урманга,**
**Тәмле җиләк җыярга.**
**Менә 10 җиләк тапты,**
**5 не авызга капты,**
**Ничә калыр чиләктә?**

Сорау бирәм: Ничә җиләк бар иде? Ничәсен Айдар ашады? Чиләктә ничә җиләк калганын каян беләбез? Күбрәкме, әллә азрак каламы? Ни өчен азрак? Сез нәрсә эшләргә тиеш?

Тактада мисалын язам һәм геометрик фигуралар белән бер укучы җыю полотносында күрсәтә. Шулай итеп, 10 саны 5кә 5не кушкач килеп чыгуын ачыклыйбыз.

Шигырь формасындагы мәсьәләләр балаларга бик ошый. Алар биремне тиз истә калдыралар. Җавабын әйтергә тырышалар. Мондый мәсьәләләр куллану дәресне җанландырып җибәрә. Аларны балалар арып, игътибарлары читкә тайпыла башлаган вакытта куллану файдалы.

Һәр биремне үтәү зур игътибар сорый, шуңа күрә I сыйныфта математика дәресләренең һәр темасын өйрәнгәндә дә шундый күнегүләрне куллану файдалы.

Һәр эшкә нәтиҗә ясыйм, игътибарлылыкта җибәрелгән хаталарны аңлатам, белемнәрен бәялим.

**Файдаланылган әдәбият.**

1.Хуҗиәхмәтов, Ә. Н. Тәрбия дәресләре. - Казан, «Матбугат йорты» нәшр., 1998

2. Халиков, Х. Сакчы күркә. – Казан, «Татарстан- китап» нәшрияты, 2000

*Галямова Гулия Илгиз кызы,*
*Татарстан Республикасы Нурлат шәһәренең*
*«9 нчы урта гомуми белем мәктәбе» муниципаль*
*автоном гомуми белем учреждениесенең беренче*
*категорияле туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

## Үсеп килүче буынга патриотик белем бирүдә милли гореф-гадәтләрне саклауның роле

Үсеп килүче буынга патриотик тәрбия бирү һәрвакытта да мәктәпнең иң мөһим бурычларыннан берсе булды.

Патриотлык - һәрьяклап үскән шәхеснең иң мөһим сыйфатларыннан берсе. Укучыларда үз Ватаннары һәм халкы өчен горурлык хисе, аның бөек казанышларына һәм үткәненә хөрмәт уяныргa тиеш.

Ватанпәрвәрлек тәрбияләү халык фольклорын, халык поэзиясен, әкиятләрне, туган телнең фразеологиясен халык йолаларын һәм традицияләрен, ягъни бөек Ватаныбыз бай булган, милли характерның нигезен тәшкил иткән барлык рухи кыйммәтләрне кулланырга мөмкин.

Патриотлык - һәрьяклап үскән шәхеснең иң мөһим сыйфатларыннан берсе. Хәзерге вакытта этномәдәни традицияләр контекстында патриотик тәрбия теориясе һәм практикасы мәсьәләләре белән кызыксыну аның шәхеснең рухи үсешендә һәм буыннарның мәдәни дәвамчанлыгын саклауда мөһим функцияләре белән аңлатыла.

Традиция дигәндә:

1. Буыннан-буынга телдән күчкән бар нәрсә;

2. Көнкүрештә урнашкан гадәт, тәртип.

Заман халык педагогикасы традицияләренең кирәклеген һәм нәтиҗәлелеген исбатлады, халык сәнгатенең барлык төрләренең гаять зур патриотик потенциалын ачты. Мәсәлән, уен һәм бию җырлары - образлы якты, көйле шигърләр. Балалар белән бу җырларны башкарганда, импровизацияләнгән әйлән-бәйлән биюләр оештырырга була, барыннан да элек, ачык чагылдырылган уен башлангычын аерып күрсәтеп була. Уенга,

актерлыкка омтылу балаларга хас. Уен аларга шатлык китерә. Шуңа күрә уен элементлары теге яки бу дәрәҗәдә теләсә кайсы җырга диярлек кертелергә мөмкин. Ул чагында җырлау озата барырга да мөмкин .

Ә әкиятләр гасырлар сөйләмендә халык тарафыннан эшләнгән һәм сыналган мөһим тәрбия чаралары булып тора. Тормыш, тәрбияләүнең халык практикасы әкиятләрнең педагогик кыйммәтен ышандырырлык итеп исбат итте. Балалар һәм Әкият-аерылгысыз, алар бер-берсе өчен яратылган һәм шуңа күрә үз халкының әкиятләре белән танышу һәр балага белем һәм тәрбия бирү иң мөхиме. Күп кенә халык әкиятләре дөреслекнең тантана итүенә, яхшылыкның яманлыкны җиңүенә патриотк тәрбия уята. Әкиятләрдә патриотизм темасы күтәрелү, балаларның тәрбияви әһәмиятен арттыра.

Әкиятләрнең мөһим үзенчәлеге-образлылык. Гадәттә геройда характерның төп сыйфатлары: батырлык, хезмәт сөючәнлек, тапкырлык; физик көч, кыюлык, кыюлык сыйфатлары ачык күренә. Балада туган илгә мәхәббәт хисе, әйләнә-тирәдәге табигатькә, туган авылына, шәһәренә булган мәхәббәттән башлана. Патриотик хисләрнең үсеше, тирәнәюе туган як белән тыгыз бәйләнгән. Мәсәлән, Россия Федерациясе гражданнарына патриотик тәрбия бирү концепциясендә ул болай дип билгели: “Патриотлык — кешелекнең гасырлар һәм мең еллар дәвамында ныгытылган иң тирән хисләренең берсе. Ул үз Ватаныңа, үз халкыңа тугрылык һәм мәхәббәт, аларның үткәне һәм бүгенгесе өчен горурлык, аларны яклауга әзерлек дигәнне аңлата»

Балаларны хәзерге җәмгыятьтә халык мәдәниятенә тарту-яшь буынны патриотик тәрбияләүдә бик мөһим аспект. Бүгенге ситуациядә үз халкының традицион мәдәниятен танып белү, башка халыкларның мәдәниятен өйрәнү һәм тану, аңа сакчыл караш, төрле халыкларның милли мәдәниятендә уртак тамырларга төшенү юлларның берсе булуы бәхәссез булып тора.

Укытучы эшенең максаты-баланың әхлакый тәрбиясен камилләштерү, аның Ватанга мәхәббәте нигезләре буларак, аның шәхси культурасын үстерү. Ләкин шуны да онытмаска кирәк, балаларда әхлакый сыйфатларның үсеше, беренче чиратта, ата-аналардан, аларның аны ничек тәрбияләүләреннән, нинди тәэсирләр белән баетуларыннан тора. Баланың шәхесе салынган чорда гаилә: иҗтимагый-сәяси аң, хезмәт сөючәнлек тәрбияләүдә хәлиткеч роль уйный.

Ләкин шуны да онытмаска кирәк, балаларның ата –аналары белән тыгыз элемтә урнаштырылган булса ,нәтиҗәлерәк була.

Балаларны балачактан ук үзен яхшы тота белергә өйрәтү мөһим. Ватан хисе гаиләгә, иң якын кешеләргә - әтигә, әнигә, әбигә, бабайга мөнәсәбәттән башлана. Һәр гаиләдә гореф-гадәтләрне,традицияләрне саклап, аларны үз балалары аша буыннан-буынга җиткерә алганда гына, милли-гореф гадәтләр сакланып кала.

Патриотик тәрбия буенча эш матур әдәбият белән танышу аша да алып барыла. Туган як тарихы, көнкүреше, мәдәнияте турында шигырьләр, экиятләр, хикәяләр белән танышабыз, мәсәлән әдәбият дәресләрендә Гомәр Бәшировның “ Туган ягым яшел бишек”, Гадел Кутуйның “ Сагыну” нәсерендә дә, Муса Җәлил,Фатих Кәрим, Абдулла Алиш шигырләрендә дә болар чагыла. Балаларда патриотизм тәрбияләү эшендә халык авыз иҗаты әсәрләрен куллану, чөнки ул танып белү һәм әхлакый үсешнең бай чыганагы булып тора. Мәкальләрдә, әйтемнәрдә, экиятләрдә, бәетләрдә тормышның төрле позицияләре төгәл бәяләнә, кешеләрнең уңай сыйфатлары мактала.

Йолалар, традицияләр һәм бәйрәмнәр-балаларны патриотик тәрбияләүнең мөһим үзенчәлеге. Шулай итеп, тарихи хәтер ул-халыкның үз-үзен тәэмин итә алуын, милли абруен, үз көчеңә һәм үзбилгеләнү шартларына ышанычны раслау чарасы. Балаларны һәм яшүсмерләрне патриотик тәрбияләү, халык педагогикасы традицияләренә нигез булып тора, ул катлаулы, системалы һәм эзлекле педагогик процесс, ул халык мәдәнияте кыйммәтләренә, кече Ватанга, аның тарихына, туган теленә, халкыңа, аның гореф-гадәтләренә һәм идеалларына мәхәббәт һәм хөрмәт тәрбияләүнең субъектив әһәмиятле тәҗрибәсен формалаштыруга юнәлдерелгән.

Әлеге тема буенча эшне планлаштыру нәкъ менә хәзерге вакытта бик актуаль, чөнки патриотлык-халыкның төп сыйфаты, ул туган якка һәм әйләнә-тирә дөньяга мәхәббәт хисләре тәрбияләргә ярдәм итә. Һәм бездән, өлкәннәрдән, безнең балаларның нинди булулары, аларның балачактан нәрсә алып китүләре тора.

Бүгенге көндә милли бәйрәмнәребезне, йола, гореф-гадәтләребез яңадан торгызылып, яңартылып, заман төсмерләре белән бергә үткәрелә башлады. Аларны халык белә, хөрмәт итә икән милләт яши, милләт яшәгәч, тел яши, ягъни тормыш дәвам итә, анда яшәүче һәр кеше гореф-гадәтләрне, йолаларны ихтирам итәргә тиеш.

*Гараева Айгуль Миншакир кызы,*
*Шарафеева Рамия Анас кызы,*
*Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «20 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең беренче һәм югары категорияле туган тел һәм әдәбияты укытучылары*

**Милли гореф - гадәтләрне саклау – укучыларга патриотик тәрбия бирү нигезе**

Үсеп килүче буынга патриотик тәрбия бирү мәктәптә һәрвакыт игътибар үзәгендә тора. Ул иң элек укучыларда туган илгә, туган җиргә, туган телгә карата мәхәббәт тәрбияләүне, патриотизмны күздә тота.

Патриотизм нәрсә ул? Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә: “Патриотизм – ул үз илеңне, халкыңны өзелеп ярату һәм үз Ватаның өчен армый-талмый көрәшергә әзер тору. Патриотизм – гасырлар буе тәрбияләнеп килгән тирән хис” – дигән мәгънәдә. Бүгенге көндә безнең алда торган мөһим бурычларның берсе – тормышка әзер булган, үз Ватанына чын күңелдән бирелгән Кеше, Гражданин һәм Патриот тәрбияләү. Ә кем соң ул патриот? Патриот – үзенең туган җирен, халкын, Ватанын сөючe, шулар өчен һәртөрле корбаннарга да әзер булган кеше.

Үз халкыңның улы-кызы булу өчен аның гореф-гадәтләрен, җыр-моңнарын, әкиятләрен ана сөте белән дә сеңдереп үсү кирәк. Әдәпле, әхлаклы булырга өйрәтүләр бишек җырларыннан ук башлана. Бишек җырлары тирән мәгънәгә ия. Шул мәгънә кешеләр күңелендә гади генә сүзләр һәм моң белән гасырлардан-гасырларга сакланып килгән. Бишек җыры тыңлап бала беркайчан да таш бәгырьле булмас, ә киресенчә алар туган илгә, туган телгә мәхәббәт уятыр, аларны кадерләргә өйрәтер.

Бүгенге көндә, татар гаиләләрендә гореф-гадәтләр югалып бара, милли үзаң җитешми һәм кайберләрендә ул бөтенләй юк та. Шуннан соң бала кемгә карап, кемнән үрнәк алып үсәргә тиеш соң?

Телне өйрәтү өчен мәктәп тырышлыгы гына җитми, ата-ананың да кайгыртуы, булышлыгы кирәк. Без моны әти-әниләрнең кимчелеге дип түгел, ә хәзерге көннең ачы нәтиҗәсе дип саныйбыз. Телне, гореф-гадәтләрне күп ата -ана бүгенге көндә өйрәтми, чөнки ул аны үзе дә юньләп белми. Мәктәпләрдә, әти-әнисе татар булган, татар баласы татар теле дәресен сайламый, ә туган тел итеп рус теле дәресенә йөри. Бу бит нинди зур фаҗига! Зур шәһәрләрдә татар теле бөтенләй югалып бара, татар мәктәпләренең аз булуы бик кызганыч, чөнки татар мәктәпләрендә укучы балалар күпкә тәрбиялерәк һәм бары тик алар гына милли традицияләрне саклап кала ала дип уйлыйбыз. Без, укытучылар, барлык укучыларга, аларның әти-әниләренә үзләренең яшәешләре турында уйланырга, һәр көннең кадерен белеп, җәмгыять өчен файдалы шәхесләр тәрбияләп үстерергә, динебезне, телебезне, гореф-гадәтләребезне сакларга кирәклеген аңлатырга, татар теле һәм әдәбият дәресләрендә, сыйныфтан тыш чараларда патриотик тәрбия бирүгә зур игътибар бирергә тиешбез.

Мәсәлән, 6 нчы сыйныфның әдәбият дәресләрендә Р. Рәкыйповның “Мин яратам сине, Татарстан!”, Г. Тукайның “Туган авыл”, Ф. Кәримнең “Ватаным өчен” әсәрләре өйрәнелә. Бу әсәрләр укучыларда туган ил белән горурлану хисе тәрбияли, туган җир тарихына карата кызыксыну уята. Балалар үзләре теләп туган яклары турында легендалар табып чыгышлар, презентацияләр әзерләп киләләр.

8 нче сыйныфта Г.Кутуйның “Сагыну” нәсерен өйрәнгәндә дә укучыларга патриотик тәрбия бирергә мөмкин. Әсәрдә солдатның туган илен сагыну хисләре чагылдырыла. Туган

ил һәркем өчен кадерле һәм якын. Шулай ук М.Җәлил, А.Алиш иҗатларын өйрәнү дә укучыларга патриотик тәрбия бирүдә матур үрнәк булып торалар.

Һәр ел мәктәбебездә төрле милли бәйрәмнәр үткәрәбез: Сөмбелә, Нәүрүз, Сабантуй, Карга боткасы, Каз өмәсе, Аулак өй һ.б. Төрле милләт балалары укыса да, бәйрәмнәрдә бик теләп катнашалар.

Мондый бәйрәмнәр буыннар арасындагы элемтәне ныгыта, туган якка мәхәббәт тәрбияли һәм башка милләтләрнең гореф-гадәтләрен өйрәнүгә кызыксыну уята. Алар балаларның эмоциональ өлкәсенә йогынты ясый һәм аларның хәтерендә тирән эз калдыра.

Уку елы башында башлангыч сыйныф укучылары белән Сөмбелә бәйрәмен үткәрәбез. Сөмбелә - татарларда көзге көн-төн тигезлеге (22–23 сентябрь), яучылык һәм уңыш бәйрәме.

Мәктәптә “Сөмбелә” бәйрәмен үткәрүнең роле яшь буынны халкыбызның әхлакый кыйммәтләренә, экологик культурасына, гореф-гадәтләренә җәлеп итүдән гыйбарәт. Чараның бурычлары:

1. Балаларны «Сөмбелә» милли бәйрәме белән таныштыру.

2. Ата-баба традицияләре өчен Хөрмәт, Мәхәббәт һәм горурлык хисе тәрбияләү.

3. Төркемдә, коллективта аралашу сыйфатларын һәм үзара хезмәттәшлек тәҗрибәсен, башка кешеләрне аңлау һәм кабул итү сәләтен, укучыларның иҗади һәм актерлык сәләтләрен үстерү.

Бәйрәмдә шулай ук Көз бүләкләре, милли ашлар, яшелчә һәм җиләк-җимешләрдән ясалган әйберләр, букет композицияләре күргәзмәсен оештырабыз.

Мәктәптә Нәүрүз бәйрәмен үткәрү үзенә аерым урын алып тора.

Балалар коллективын туплау, күпмилләтле мәктәптә уңай социаль-психологик климат тудыру, бер-береңә, төрле халыкларның гореф-гадәтләренә һәм мәдәниятенә хөрмәт тәрбияләү-төп бурычыбыз булып тора.

Уку елы азагында мәктәп күләмендә Сабантуй бәйрәмен үткәрәбез. Бу бәйрәмдә барлык сыйныф укучылары да катнаша. Сабантуйны мәктәптә үткәрү берничә этаптан тора: әзерлек этабында татар халкының гореф-гадәтләре турында әңгәмәләр, кием-салым, аш-су, милли уеннар һәм фольклор белән танышу бара.

Бәйрәмне саф һавада үткәрәбез. Төрле төстәге флаглар һәм тасмалар, рәсемнәр һәм кыңгыраулар белән бизибез. Чара вакытында барлык катнашучылар җыела. Алып баручылар бәйрәмнең башлануын игълан итәләр һәм Сабантуйны үткәрү шартлары турында сөйлиләр. Аннары балалар үзләренә ошаган ярышларга таралышалар. Һәр этапта җиңүчегә төсле жетон тапшырыла, аны бүләкләргә алыштыралар.

Сабантуйны мәктәптә үткәрүнең роле бик зур. Укучыларның физик сәламәтлеген ныгытабыз һәм спорт уеннарына кызыксыну уятабыз. Катнашучыларны халыкның гореф-гадәтләре, халык иҗаты үрнәкләре, милли киемнәр белән таныштырабыз. Сабантуйда ватанпәрвәрлек, Ватанга, табигатькә, кешеләргә мәхәббәт, аның тарихына хөрмәт, хезмәт сөючәнлек, намуслылык һәм яхшылык тәрбиялибез.

Шулай итеп, без укытучылар, тәрбияле, сәламәт, тормышта үз юлын таба алырлык, үз-үзен хөрмәт итә торган шәхесләр тәрбияләп чыгарырга тырышабыз. Укучыларны халкыбызның гореф-гадәтләре, бәйрәмнәре белән таныштырып, аларда әхлак һәм патриотизм, милли үзаң нигезен формалаштырырга ярдәм итәбез.

*Гарипова Лилия Рауф кызы, Гарипов Рәсим Фаиз улы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Каенлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты, тарих һәм җәмгыять белеме укытучылары*

**Рисаләи Газизә – милләт сандыгы**

Халкыбызның мәшһүр шәхесе, мөгаллим, журналист, җәмәгать эшлеклесе, мәгърифәтче, тәрбия, тарих, дин гыйлемен яктырткан 148 китап авторы - Ризаэддин Фәхреддиннең гыйбрәтле сүзләре бүгенге көндә дә бик актуаль. Шуларның берсе – “Гыйлем тарату, халыкка ярдәм бирү өчен тырышу, иң гүзәл гайрәттер”. Галимнең бу сүзләре 1768-1838 нче елларда яшәгән татарның мәшһүр шәхесе- Таҗетдин Ялчыголга туры килә дип әйтергә ярыйдыр.

Т. Ялчыгол үзе яшәгән чорда традицион ислам кыйммәтләрен пропагандалаган. Ул – үз халкын агартуга юнәлтелгән хезмәте белән искелекне чатнатуга, яра башлауга чөй кагучыларның берсе санала.

1. Таҗетдин. Ялчыголның биографиясен сөйләргә җыенмыйм. Гомеренең 33 елын безнең төбәктә яшәгәненә дә тукталмыйм. Шулай да аның күпкырлы талант иясе булуын ассызыклап китәсе килә. Язучының ике гасыр элек язылган “Рисаләи Газизә” әсәренең бүген дә хәзинә булган ядкяр икәнен исбатлау тора минем алда.

Таҗетдин Ялчыгол- иң беренче чиратта **укытучы-педагог**. 17 яшеннән башлап, бөтен гомерен балалар укыту һәм халыкны агарту эшенә багышлаган. Кайда яшәсә дә аның дәрес бирүе, мөдәррис булуы мәгълүм, күп кенә хезмәтләре дә уку-укыту, белем бирү ихтыяҗларын күздә тотып язылган.

Ул хәрәкәт итәргә, **сәфәр кылырга** яраткан. Күбрәк җәяү йөргән. Хәтта өлкән яшьтә дә Әстерхан, Кавказ якларына барып кайта. 1827 елда Дагстанда Җаксай мәдрәсәсендә күчереп язган китабы барлыгы билгеле. Керәшеннәр арасында исламга кайту хәрәкәте көчәйгән еллар. Кызыл Чапчакта яшәгәндә эзәрлекләүләрдән качып 1-2 ел Дагстанга китеп яшәве дә ихтимал.

Ул үзенә күрә бер **татар “народнигы”** да була. Әдип халыкны дингә, белем-мәгърифәткә өнди, иманны сакларга булыша. Аның тырышлыгы белән көчләп чукындырылганнарның кире мөселманлыкка кайту очраклары да билгеле. Бу – фидакарьлек, империя законнары тыйганны эшләү. К.Чапчакта яшәгәндә земский судта аннан сорау алулар да нәкъ менә шул уңайдан була. Халык арасында күп йөри, дәвалый, сөйләшергә өндәргә җае була.

**Халык табибы** да. Авыруларны үләннәр, дегет белән дәвалаган дигән мәгълүмат та бар.

Т. Ялчыгол **музыка коралларында уйнарга да сәләтле** булган. Татар кыллы музыка инструментларын аеруча үз иткән. Ул милли әдәбиятыбызда беренчеләрдән булып татар кыллы музыка коралларына игътибар итә. Мәсәлән, аның Сарман районында табылган бер кулъязма әсәрендә татарлар арасында киң таралган гөслә, скрипка, думбра, ариләнең рәсемнәрен бирүе карашларының киңлеге, татар мәдәнияте белән якыннан таныш булуы турында сөйли.

Әлбәттә, ул **язучы** да, белем бирү белән беррәттән, иҗат белән шөгыльләнгән. Тәрбияви, дини-әхлакый, тарихи, тел ягыннан бай фәлсәфи әсәрләр иҗат иткән. Шәрык шагыйрьләренең әсәрләренә шәрыхләр (гарәпчә һәм фарсыча әсәрләргә аңлатмалар) язып шөһрәт казанган. Ул әле гомере буе китаплар күчереп язган, ягъни хәттат булган. Мәшһүр “Кыйссаи Йосыф”ны халыкка таратуга да күп көч куйган. “Тәвәрихе Болгария” китабында үзе язган 15 ләп китап исемен телгә ала. Алар барысы да табылмаган.

Безнең якларда яшәгәндә дә гыйльми хезмәтләрен, әсәрләрен язган. Галимнәр фикеренчә, “Хәдисел-баб”ка шәрехне Каенлыда яза. “Рисаләи Газизә” әсәрен 1806 нчы елда Кызыл Чапчакта төгәлләгән дип саныйлар. Таҗетдин Ялчыголның кайда яшәвенә игътибар итсәң, әлеге иң танылган әсәре – “Рисаләи Газизә» Каенлы авылында языла башланган дип әйтеп була. Язучының ике гасыр элек язылган “Рисаләи Газизә” әсәренең бүген дә хәзинә булган ядкяр икәнен исбатлау тора безнең алда.

2. “Рисаләи Газизә”- мәшһүр әсәр

Әсәр 1806 елда тәмамланып, әүвәл кулъязма нөсхәләрдә тарала. “Таҗетдин Ялчыгол Каенлы , Кызыл Чапчакта да яшәгән” дигән тикшерү эшендә мин “Рисаләи Газизә” язылып беткәч, кулъязманы бик күп авыллардан килеп күчереп язганнар дигән идек.

Китап буларак, беренче тапкыр 1847 елда Санкт-Петербургта басылып чыга, ул 372 битле була. Казанда беренче тапкыр 1850 елда басылып чыга. Аннары күп мәртәбәләр нәшер ителә, кайбер елларда икешәр мәртәбә. Бу әсәрне басып тарату белән, нигездә, инкыйлабка кадәр Хөсәеновлар, Кәримовлар кебек күренекле матбагачылар шөгыльләнә. 1917 елга кадәр китапның 39 мәртәбә зур тиражлар белән нәшер ителүе мәгълүм. “Рисаләи Газизә”не халык яратып укыган, ә мәктәп-мәдрәсәләрдә башлангыч сыйныфларда дәреслек итеп файдаланганнар, балалар әдәбияты үрнәге итеп каралган. Аның гаять популярлыгына бер мисал: Тукай үзенең “Исемдә калганнар” әсәрендә: “... Кырлай авылыннан Җаек каласына алырга килгәндә, мин ян тәрәзә төбендә “Рисаләи Газизә” укып утыра идем", - ди. [3- 23 ]

“Рисаләи Газизә” китабы һәр йортта сакланып, үтемле үгет-нәсыйхәт буларак файдаланылган, мәдрәсәләрдә иң күп укыла торган әсәрләрнең берсе булган. Китап халкыбызга белем, тәрбия, әхлагыбызны күтәрергә булышкан. 19нчы гасырның 60нчы елларында яшәгән өлкәннәребез дә аны яхшы белгәннәр. Мисал итеп, Каенлы авылында 100 яшен тутырып ахирәткә күчкән Махиҗамал әби – Гариф мулла мәктәбенә 7 яшеннән алып 17 яшенә кадәр укыган. Укып бетергәч, Тоба авылында бераз үзе укытучы булып эшләгән. Менә аның сөйләгән дини хикәятләре, мөнәҗәтләрен искә төшереп оныгы Ранизә апага дини хикәятләре сөйли, мөнәҗәтләр әйтә торган булган. Менә хәзер Ранизә апа әбисенең истәлекләре “Рисаләи Газизә” китабыннан булуын бик яхшы аңлый.

Ялчыголны, татар халкына, язучы буларак, таныткан бу әсәр Урта Азиядә яшәп иҗат иткән төрки телле нугай-татар шагыйре Суфи Аллаһиярның “Сөбәтел-гаҗизан” (“Гаҗизләрнең, көчсезләрнең ныклыгы”) исемле поэмасына җәенке шәрых-аңлатма итеп язылган. Китапның тулы исеме “Рисаләи Газизә фи-шәрх Сөбәтел-гаҗизин”. Халык телендә бу озын исем кыскартылып “Рисаләи Газизә” дип кенә атала башлый.

Язучы Аллаһияр әсәрен шәрехләсә дә, аны Т.Ялчыголның үз әсәре дип тә әйтергә була. Ул әсәргә үзенең уйларын өсти, аңлатмалар, материаллар, үз шигырьләрен кертә. “Рисаләи Газизә” халык арасында кульъязма һәм басма килеш бик киң таралган. Әсәр мавыктыргыч сюжетлы, күп төрле жанрлардан тора: экият, бәян, кыйсса, мөнәҗәт, бәет, хикәятләр – тәрбияви чимал урын алган, язучының үз шигырьләре.

“Собәтел-гаҗизан”га Казанда беренче тапкыр Габдерәхим Утыз Имәни гарәпчә шәрех төзегән була. Китап укучы өчен авыр аңлашылган. Т. Ялчыголдан “Сөбател – гаҗизан”нең аерым сүзләренә шәрех язуны сорыйлар, ул риза булмый Шулай да 1796 елда Т. Ялчыгол кызы Газизәнең соравы буенча“Сөбател – гаҗизан” га шәрехләр яза башлый. Бу шәрехтә авторның үз кызына хөрмәт һәм ярату хисләре бөркелеп тора. “Мәгәр үземнең күзем нуры, бәгърем парәсе, бер кыз балам илтимас әйләде”. [5- 26] “Рисаләи Газизә” яки “Газизләрдән-газиз” дип аталган әлеге китапны Ялчыгол кызы Газизә укый алырлык итеп язган.

“Рисаләи Газизә” традицион кереш белән башланып китә. Анда Аллага, пәйгамбәрләргә мактау бирелә, ә алга таба китапның язылу сәбәбе аңлатыла.

Китап җитмештән артык вак-вак бүлекләрдән тора, гомуми күләме 20-25 басма табак чамасы. Тулысынча Коръән рухы белән сугарылган лиро-эпик рухтагы әсәр. Ул чәчмә һәм тезмә юллар берлегеннән гыйбарәт. Анда Суфи Аллаһияр әсәренең төп өлеше гәүдәләнеш тапкан. Эчтәлеге ягыннан “Сөбател-гаҗизин” поэмасы кебек үк, суфичылык фәлсәфәсе рухы белән сугарылган. **Аллаһның бөеклегенә дан җырлана, диндар табигатле зат идеал итеп куела**. Әсәрдә җир йөзендәге беренче кеше – Адәм галәйһиссәламнән алып Мөхәммәд пәйгамбәргә кадәр исемнәре Коръәнгә кереп калган изге затларның тормышларына, эш-гамәлләренә бәйле күп төрле гыйбрәтле хәлләр, хикәятләр, риваятьләр китерелә. Аларның гыйбрәтле тормышын укучыга үгет-нәсыйхәт итеп, үрнәк итеп яктырта. Аның хикәятләрендә Лут пәйгамбәр, Юныс пәйгамбәр, Салих пәйгамбәр, Муса пәйгамбәр, Сөләймән пәйгамбәр турында кыйссалар, бәяннар бар.

Т.Ялчыгол мөгаллим буларак, ата-анага хөрмәт, балаларның хакы турында бик матур яза, Коръән аятьләрен аңлата. Таҗетдин Ялчыгол күрергә теләгән камил кеше – иманлы, укымышлы, күркәм холыклы, инсани эш-гамәлле зат.

Әдип “ачкүзлелек”, икейөзлелек, “гафил”лек, нәфес колы булу һәм башка шундый сыйфатларның кешене тугры юлдан читкә сөйрәвен, әхлаксызлык упкынына алып баруын үтемле итеп тасвирлый. Тәрбияви яктан кызыклы гына фикер-киңәшләр күп: “Яманнарның яманы – кинә тотмак”, “Ямандин кач, ямандин кач, ямандин...”, “...күңел милкенең падишаһы булсаң, сиңа хаҗәт дәгелдер йир йөзенең падишаһы улмак”, “сары май кеби “мөлаем” булырга,” сөт өстендә каймак кеби” тотарга өнди. Нәфескә иярүне, мал-мөлкәткә, хакимияткә чиктән тыш кызыгуны кискен тәнкыйтьли. Укучыларга мөмкин кадәр үтемлерәк җиткерү өчен, Таҗетдин Ялчыгол өстәмә чыганакларга мөрәҗәгать итә. Болар арасында гарәп, фарсы, төрки телләрдәге китаплар да бар. Арага аятьләр, хәдисләр, гыйбрәтле сюжетлар кертеп җибәрә.

“Рисаләи Газизә” – өйрәтү-аңлатуны, кабул итү-үзләштерүне, ягъни педагогик процессны күздә тотып язылган әсәр. Текстта бәхәс, сорау-җавап формасы, кабатлау, төрле искәрмәләр бирү еш күзәтелә. Әсәрдә һәр чор өчен характерлы булган мәсьәләләрнең берсе – хатын-кызга караш, аңа мөнәсәбәт, гомумән, аның җәмгыятьтәге урыны мәсьәләсе. Изге хатын-кыз образына кат-кат басым ясала. Изге хатын-кыз образының гүзәл үрнәге итеп Хәзрәте Фатыйма күрсәтелә.  Мәхәббәткә килгәндә, автор суфый әдип-шагыйрьләргә хас булганча иляһи мәхәббәтне зурлый.

Ата-ана һәм балалар темасын да автор читләтеп үтми. Мәсәлән, Нух пәйгамбәр мисалында “атадан ала да туа, кола да туа” дигән халык мәкаленә туры килә торган

иллюстрация кертеп җибәрә. Ата-анага хөрмәт, ата-ананың баласы алдында бурычы, балаларның хакы турында бик матур яза, Коръән аятьләре белән аңлата. Бу әсәр, һичшиксез, халыкка тәрбия чарасы, рухи азык аларның олылыгы хакында әсәрдә матур тел белән сөйләнә.

Әсәрдә гаиләсе өчен ир-ат һәрдаим тырышып, аның иминлеген тәэмин итеп, хатыны, балаларының төп таянычы, саклаучысы булуга төп басым ясала. Таҗетдин Ялчыгол гаилә коруны, бала тәрбияләүне һәркемгә зарури саный. "Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйде ки, ди ул, - һәркем хатындан вә балачыкларындан качыб, аларны туендырмыйча, тәрбияләмичә йөрсә, ул кемсәнәнең аслан кылдыкы гыйбадәте кабул дөгелдер."

Әдип үзе бу яктан үрнәк. 7 баласын тәрбияли, укыта, кеше итә. Үз китабын кызы Газизә хөрмәтенә "Рисаләи Газизә" дип атавы да бик мәгънәле. Кызын хөрмәтләп язган "Рисаләи Газизә" ядкарь, милләтебезнең сандыгы булып, вакытның агышына, җил-яңгырларга бирешмичә һәйкәл кебек яшәвен дәвам итә.

"Рисаләи Газизә" китабы бүгенге көнгә килеп җиткән. Халык арасында танылуы ягыннан "Рисаләи Газизә" әсәре "Кыйссаи Йосыф"тан гына калыша. Гомумән, ул халык китабына әйләнә. Ул дөнья һәм кеше турындагы фикер-күзәтүләрне, төрле уй-кичерешләрне, вакыйга-хәлләрне үз эченә алган. Аны татарның дини-әхлакый кодексы дип тә атарга мөмкин. "Рисаләи Газизә" уку йортларында, аеруча хатын-кызлар укый торган мәдрәсәләрдә төп уку китабы булган. Шулай ук ул шул чор мәктәпләрендә тел-әдәбият дәреслеге сыйфатында кулланылган. "Рисаләи Газизә" динне, телне, мәгарифне, гореф-гадәтләрне өйрәнүдә мөһим чыганак. Аны белү, уку рухи кыйммәтләрне сакларга һәм буыннардан- буыннарга тапшырырга этәрә. Менә шул максаттан, "Рисаләи Газизә" китабына багышлап, 2023 нче елның көзендә Каенлы авылы китапханәсендә "Рисаләи Газизә"- милләт сандыгы" дигән укулар үткәрелде. Чарага Т. Ялчыгол нәселеннән булган Зәй шәһәрендә яшәп ятучы Гамир абый Таҗетдинов та килгән иде. Очрашу бик эчтәлекле булды. "Рисаләи Газизә" китабындагы мөнәҗәтләр, бәяннар укылды, пәйгамбәрләр турында язылган хикәятләр тыңланды.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә, мәдрәсәләрдә балалар укыткан, шигъри парчалар иҗат иткән, борынгы язучыларның әсәрләренә шәрехләмәләр язган Таҗетдин Ялчыголның XVIII йөз әдәбиятында үз урыны булган. Аның тәрбияви, дини- әхлакый, тарихи әсәрләре җәмәгатьчелек арасында киң таралган, укылган, кулланылган. Бүгенге көндә дә Т. Ялчыголның иҗаты өйрәнелә. Бу урында филология фәннәре докторы, Ялчыголның иҗатын тирәнтен өйрәнгән, гарәп- фарсы сүзләре белән язылган "Рисаләи Газизә" әсәрен тәрҗемә иткән Хатыйп абый Миңнегуловның сүзләрен китерәсе килә: "Ялчыголның язганнары бүгенге көнгә дә аваздаш. Бүген Ялчыголлар, Риза Фәхреддиннәр кебек мәгърифәтчеләребезне өйрәнмибез икән, безнең киләчәгебез юк!"[2]

**Кулланган әдәбият**

1. Гарифуллин Д. “Чырагы нур сибә бүген дә” - Казан, “Сүз”нәшрияты, 2009, 36 б.

2.Кашапова, С. “Ялчыгол мирасы- халык хәзинәсе” - “Мәдәни җомга” 27 октябрь, 2023. - №42.

3.Тукай, Г.“ Исемдә калганнар”. - Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2005. – 23 б.

4.Шамсетдинова, Л. “Таҗетдин Ялчыголның “Рисаләи Газизә” әсәре : проблематикасы һәм сәнгатьчә эшләнеше” - Казан : ИЯЛИ АН РТ, 2007. – 135 б.

5. Т. Ялчыгол “Рисаләи Газизә”. - Казан, “ Хозур”, 2014. – 26 б.

*Гәрәева Маһинур Абрам кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «2 нче Кама Аланы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең беренче категорияле туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

## ТУГАН ТЕЛ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ СӘЛӘТЛЕ БАЛА ШӘХЕСЕ ФОРМАЛАШТЫРУ ӨЧЕН ШАРТЛАР

Сәләте булмаган бер бала да юк. Аларның иҗади мөмкинлекләрен ачарга һәм камилләштерергә булышу – һәр укытучының бурычы, дип саныйм мин. Белгечләр исбатлавынча, сәләтле балаларның нәрсәгә сәләтле булулары билгеле бер шартларда ачыклана. Сәләтле булу нәселдәнлелеккә генә бәйле түгел, монда баланың тирә-ягындагы кыймматләр системасы да зур әһәмияткә ия. Билгеле бер шартлар тудырганда, укучыларның күбесендә теге яки бу сәләтне үстерергә мөмкин.

Безнең кулларыбызда – балалар язмышы. Укчыларның үзләрен яраткан, кирәкле, уңышлы итеп тоюлары бик мөһим. Безнең бурычыбыз баланың кечкенә генә булса да алга китешен күрү, аның уңышларына сөенү һәм баланы да сөендерә белү.

Сыйныфны кечкенә төркемнәргә бүлеп, тиешле оештырылган эшләр, уеннар һәм күмәк эш формаларына нигезләнеп укучыларның нинди сәләткә ия булуларын күзәтеп була.

Уен - балалар өчен уку да, хезмәт тә, уен – ул җитди тәрбия формасы да. Дәресләрдә, класстан тыш чаралар составында кроссвордлар бик еш кулланыла торган чара булып тора. Бигрәк тә башлангыч сыйныфларда. Кроссвордлар бер төрлелектән котылу чарасы да. Әйтик, дәрес барышында укучыларга кроссворд чиштерү аларны “уятып” җибәрә, кызыксынучанлыкларын арттыра, белемнәрен баета. Кроссвордларны төрле тема буенча төзергә мөмкин. Мәсәлән, дәрестә билгеле бер теманы өйрәнгәндә шул тема буенча (грамматик теорияне яки лексик минимумны үз эченә алган).

Рус телле балаларны татар теле белән кызыксындыру зур көч сорый. Аларның телне өйрәнүгә теләген сүндермәү, дәрескә кызыксыну һәм стимул булдыру өчен, дәрестә уеннар куллану нәтиҗәле. Уен вакытында укучының иҗат мөмкинлеләре ачыла, мөстәкыйльлеге арта, оештыру сәләте үсә. Уен кайбер балалар өчен хыяллану, кайберләренә күңелле ял итү чарасы да булып тора. Ә укытучы өчен ул – балаларны яхшырак аңлау, аларга тагын да ныграк якынаю чарасы да. Чөнки нәкъ менә уен вакытында укытучы һәр баланың нәрсәгә сәләтле булуын, аның оештыру мөмкинлекләрен яхшырак күрә ала, холкын, гадәтләрен яхшырак аңлый. Уен ярдәмендә оялчан, үз эченә бикләнгән балаларны да уятырга мөмкин. Уендагы текстка, җырга кушылып, аның кагыйдәләрен үтәп, я булмаса, ниндидер роль башкарып, бала үз көченә ышанырга, эшләгән эшенә бәя бирергә өйрәнә, анда ярдәмләшү, игътибарлылык кебек сыйфатлар тәрбияләнә.

Әйткәнемчә, мин үз дәресләремдә уеннарның төрлесен һәм дәреснең төрле этапларында кулланам. Уеннар җитезлек, зирәклек, күмәклек сыйфатлары тәрбияли. Бер-берсен хөрмәт итәргә өйрәтә, көй аша, хәрәкәт аша бала күңелендә иҗат уты кабына. Бала якты күңелле булырга омтыла, йөрәгендә кешегә яхшылык эшләү “капкасы” ачыла.

Смайликлар ярдәмендә кәефләребезне, дәрескә булган мөгалләмәбезне күрсәтүне мин һәр дәресемнең оештыру өлешендә кулланам. Кечкенә генә бу уен төре дәрес башында ук балаларны җыя, уңай психологик халәт тудыра.

Фонетик күнегү үткәрү өчен “Әйтеп бетер”, “Сүз уйлау”, “Исем уйлау” кебек фонетик уеннар отышлы. Мәсәлән, кисмә хәрефләр белән конвертлар бирелә. Сузык аваз белдергән хәрефләрне аерып алалар. Шушы аваз кергән сүзләр уйлыйлар. Бергәләп кабатлау. [у] авазы кергән сүз ишетсәләр, кул чабалар. (Урман, куян, үрдәк, аю, күлмәк, урындык, ...).

Бу уеннарны мин авазларны, сүзләрне дөрес әйтү күнекмәләре формалаштыру, игътибарлылык өчен кертәм. Фонетик уеннар сөйләм органнары артикуляциясенең дөрес куелышын тәшкил итә.

Алган белемнәрне актуальләштергәндә “Нәрсә югалды”, “Кар өеме” (Билгеле бер грамматик форманы үз эченә алган җөмләне бер укучы әйтә, икенчесе шул җөмләне кабатлый һәм үзенекен өсти, өченче укучы алдагы ике җөмләне кабатлап, үзенекен өсти) кебек уеннар бик отышлы. (Укучы укый. Укучы мәктәптә укый. Укучы икенче мәктәптә укый. ...) Бу уен грамматик формаларны, җөмләдә сүзләр бәйләнешен һәм җөмлә төзү күнекмәләрен ныгыта. Актуальләштергәндә яңа информацион технологияләр дә кулланам. Укытучылар өчен булган белем бирү ресурслары битендәге тема буенча булган уен формасындагы биремнәр укчыларда татар теленә кызыксыну уята.

Уку мәсьәләсен куйганда, яңа тел материалын презентацияләүдә дә күп төрле уен элементлары кертергә мөмкин. Мәсәлән, мультфильмнан, җырдан өзек тыңлау. Рәсемнәрне күрсәтәм, балалар татарча әйтеп беренче хәрефләреннән сүз төзиләр. (Авыл, шәһәр, хат, ...). Нинди сүз барлыкка килде? (Ашханә.) Димәк, без бүген дәрестә ашханә турында сөйләшәчәкбез.

Яңа теманы аңлатканда русча табышмаклар да кулланам. Уенның бу төре дә укучыларның логик фикерләү дәрәҗәсен үстерә, игътибарлылыкны арттыра, лексик материалны эшкәртүгә зур өлеш кертә.

Ял минутлары уздырганда балаларның яшь үзенчәлекләрен истә тотып тыныч уеннарга да, хәрәкәтле уеннарга мөрәҗәгать итәм. Мәсәлән, күзләр өчен булган күнегүләр язу дәресләрендә урынлы кулланыла.

Үтелгән лексик һәм грамматик материалны ныгыту һәм активлаштыруда “Кайтаваз” (Укытучы акрын гына сүзне әйтә. Укучыларның бурычы – аны ишетү һәм кабатлау. Бер үк җөмләне берничә укучыдан кабатлаттыру.), “Акыллы попугай” (Укытучы нинди дә булса предметны белдергән рәсем күрсәтә, сүзне атый, укчылар дөрес булса гына кабатлыйлар) уеннары бик отышлы. Шулай ук “Әйтеп бетер”, “Рифмалаштыру” уеннары өйрәнелгән лексиканы ныгытырга ярдәм итә. Бирелгән җөмләне рифмалап дәвам итү. (Җылы, ямьле җәй җитте, болында үлән кипте). “Охшаш сүзләр уйлап тап”, дип атарга да мөмкин: итек-читек, иләк-чиләк, төлке-көлке, көн-төн.

“Иреннән укы” дигән уенда исә, тавышсыз гына сүзләр әйтелә. Укучылар аны ирен артикуляциясе буенча аңларга тиешләр. Бу уен өйрәнелгән лексиканы ныгыту өчен кулланыла. Бу сүзләрне тагын бер тапкыр кабатлатыр өчен “Балык тоту” уенын уйнарга мөмкин.

Шулай ук укчыларның күзәтүчәнлеген үстерү өчен, дәрестә кулланган материалны яңадан таратам. Моның өчен алар ахырдан кергән тәртиптә предметларны әйтергә тиеш булалар. Бу максат белән “Нәрсә бар?” (Әйләнә-тирәдә мөмкин кадәр күбрәк әйбернең исемен атыйлар.) “Кем күбрәк күрде?” уеннары да дәресне җанландырып җибәрәләр.

Рус телле балаларны татар теленә өйрәтүдә рольле уеннар актив кулланыла. Аларның өйрәтү мөмкинлекләре зур һәм тәкъдим ителгән ситуацияләрдә укучылар аның белән иркен эш итәләр. Балаларда табигый рәвештә нәрсәдер әйтү, сорау ихтыяҗы яки әңгәмәдәшенә җавап бирү теләге туа. Рольле уеннар диалогик сөйләмне үстерүдә бик нәтиҗәле чара булып тора.

Һәр уен укучының танып белү эшчәнлеген активлаштыра. Уен аша өйрәнелгән материал тиз үзләштерелә һәм күпкә ныклы була. Дәресләрдә уен алымнарын куллану укучыларның белем дәрәҗәсен генә күтәреп калмый, телебезгә тирән мәхәббәт тә тәрбияли.

Рефлексия вакытында да минем укучыларым үзләренең дәрескә булган мөнәсәбәтләрен, үзләренең эш нәтиҗәләрен, үзләренең кәефләрен күрсәтеп дәрес башында

өләшенгән смайликлардан файдаланалар. Темадан чыгып синквейн яки модель төзиләр. Синквейн - иҗади фикерләүне үстерүче методик алым.

Дәрес
Кызыклы, файдалы.
Тыңлыйбыз, уйлыйбыз, иҗат итәбез.
Миңа дәрестә эшләү ошый.
Белем, иҗат, кәеф.

Мастер классымны Галимҗан Ибраһимовның сүзләре белән төгәллисем килә: “Күп белдерүгә караганда, аз белдереп, эзләнү орлыгын салу һәм эзләгәнен үзе табарга юллар күрсәтү – мөгаллим бирә ала торган хезмәтләрнең иң кадерлесе, иң зурысыдыр”.

*Гарифуллина Ләйсән Әнәс кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «20 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле туган тел һәм әдәбияты, рус әдәбияты укытучысы*

**Этнографик компонентны дәрестән тыш эшчәнлек аша тормышка ашыру**

«Толерантлык һәм милләтара татулык - республика имиджының аерылгысыз өлеше. Республикада милләтара һәм конфессияара татулыкны һәм тынычлыкны саклау элеккечә үк өстенлекле юнәлеш булып тора», - ди Татарстанның рәисе Рөстәм Миңнеханов.

Чыннан да, бүген республикабызда яшәүче халыклар арасында дуслык, үзара мөнәсәбәт күп кенә чит илләрдә соклану һәм ихтирам хисе уята. Чөнки бүген республикабызда яшәүче күпмилләтле халкыбыз үзара дус һәм тату гомер итә, республикабызның нәтиҗәле үсеше өчен тырыш хезмәт куя. Республикабыздагы әлеге тенденция муниципаль районнар, авыл җирлекләрендә дә чагылыш таба. Безнең Түбән Кама җирлегендә дә бик күп милләтләр яши. Алар үз традицияләре, милли гореф - гадәтләре белән көнкүрешләрен алып баралар. Түбән Камада да милләтләр арасындагы дуслык чыннан да сокланырлык.

Мәгариф системасында хәзерге урта һәм югары белем бирү реформаларын тикшергәндә бәхәсле темаларның берсе булып Россия һәм дөнья халкының мәдәни күптөрлелеге турында сөйләүче этнографик программалар һәм курслар кертү тора. Мондый курслар һәм программалар кирәклеге гадәттә теге яки бу халыкның «традицион мәдәнияте» турында белемгә ихтыяҗ белән нигезләнә, бу яшь буынга мәдәни үзенчәлек табуда, этник кыйммәтләрне аңлауда, этник мәдәниятләрне танып белүдә ярдәм итәргә тиеш. Икенче

дәлил - «халыкның иң киң даирәләрендә этнологик белемнәрне актив пропагандалау милләтләр арасында аралашу культурасын тәрбияләүгә ярдәм итәргә, этник конфликтларны хәл итәргә ярдәм итәргә тиеш».

«Җәмгыять әхлакый ориентирларның уртак системасы булганда, илдә туган телгә, үзенчәлекле мәдәни кыйммәтләргә, ата-бабаларыбыз истәлегенә, безнең Ватан тарихының һәр битенә хөрмәт саклаганда гына масштаблы милли бурычлар куя һәм хәл итә ала»,- ди илебез Президенты В.В. Путин.

Федераль дәүләт белем бирү стандартлары кертелү белән бәйле рәвештә, мәгарифнең этномәдәни компоненты роле бүген бик актуаль .Тәрбия идеалы һәм төп милли кыйммәтләре стандартның методологик нигезе булган «гражданның рухи-әхлакый үсеше һәм шәхес тәрбияләү концепциясендә» билгеләнгән.

Халыкның рухи мәдәниятен, үз тарихына кызыксынуын, милли традицияләргә сакчыл мөнәсәбәтен торгызу бик актуаль. Үткәнне белмичә, аңа хөрмәт күрсәтмичә, ата-бабаларыбызның бөек мирасын саклап калмыйча, кеше рухи яктан бай була алмый.

Этномәдәни тәрбия, мәктәп укучысына ул яшәгән этносның мәдәни кыйммәтләрен, традицияләрен, социаль нормаларын тапшыруның бербөтен процессы буларак, үсеп килүче кешене тәрбияләү системасының аерылгысыз өлеше булып тора. Мәктәп укучыларының этномәдәни тәрбиясен формалаштыруда традицияләрне һәм гореф-гадәтләрне куллану аның социаль, рухи, әхлакый, психик, физик үсешенә йогынты ясарга мөмкинлек бирә.

Шуңа күрә 20 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе эшенең иң мөһим юнәлешләренең берсе - белем бирүнең этномәдәни компонентын тормышка ашыруның яңа юлларын эзләү, үсеп килүче буынга үз халкының рухи кыйммәтләренә кушылу.

Укучыларның иҗади потенциалын тормышка ашырырга мөмкинлек бирүче тәрбия киңлегенең бер формасы - укучыларның дәрестән тыш эшчәнлеге. Хәзерге заман мәктәбенең, шул исәптән безнең 20 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең бурычы - милли мәдәниятне торгызу, кыйммәтләрне саклау.

Үз практикабызда без халкыбызның мәдәнияте белән танышуның төрле ысулларын һәм алымнарын кулланабыз: әңгәмәләр, халык бәйрәмнәре, гореф-гадәтләр һәм йолалар белән утырышлар, укучыларның декоратив-кулланма иҗаты күргәзмәләрен оештыру, халык һөнәрләре буенча рәсем конкурслары һәм, әлбәттә, туган якны өйрәнү музейларына экскурсияләр.

Этномәдәни юнәлештәге дәрестән тыш эшчәнлек шулай ук төрле бәйрәмнәр үткәрү белән дә күрсәтелә. Безнең мәктәптә иң хөрмәтле бәйрәмнәр булып «Май чабу» , «Дөнья халыклары фестивале» , «Карга боткасы», «Татар халкының милли ризыклары - халкыбыз хәзинәсенең бер тармагы» бәйрәмнәре санала.

20 нче мәктәп күп еллар инде 6 нчы шәһәр китапханәсе белән бик тату хезмәттәшлектә. Бу китапханә базасында төрле проектлар гамәлгә ашырыла, аның максаты - төрле милләт халыкларының һөнәрләрен торгызу һәм тарихи хәтерен һәм мәдәни мирасын саклау.

Һәр этносның үз туган теле бар. Һәр халыкның үз гореф-гадәтләре. Төрле милләт балаларын тәрбияләүнең уникаль үзенчәлекләре бар.

Сухомлинский ассызыклаганча «Туган илгә мәхәббәт туган телгә мәхәббәтсез мөмкин түгел! Ул гына үз йөрәге һәм акылы белән туган телен кадерләгән күпмилләтле Ватаныбызның матурлыгын, бөеклеген һәм куәтен аңлый ала».

Югарыда әйтелгәннәргә йомгак ясап, этномәдәни компонентны укучыларның дәрестән тыш эшчәнлеге аша тормышка ашыру балаларыбызга үз - үзләрен тормышка ашырырга, милләтара дуслыкны ныгытырга, күпмилләтле дәүләттә башка мәдәниятләрнең һәм традицияләрнең, тормыш нигезләренең үзенчәлекләренә сакчыл һәм түземле булырга, үз халкының гореф-гадәтләрен һәм мәдәни мирасын саклап калырга мөмкинлек бирә дигән нәтиҗә ясарга була.

Кулланылган әдәбият:


1. Злобина, Е. А. «Реализация этнографического компонента через внеурочную деятельность». Школа сегодня – URL : WWW.школасегодня.РФ
2. Кабуш, В. Т. Человек: Программно-методические рекомендации по воспитанию учащихся. - Минск, 2000.
3. Караковский, В. А. Воспитательная система школы: педагогические идеи и опыт формирования. - Москва, 1991.
4. Новикова, Л. И. Воспитательная система школы: исходные позиции // Сов. Педагогика, 1991. - № 11. - С. 61-64.



*Гизатуллина Гульнара Хамис кызы,*

*Нуртдинова Гульсиня Асхат кызы,*

*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы "Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 15 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучылары*


## Дәрестә һәм дәрестән тыш чараларда укучыларда патриотик хисләр тәрбияләүнең кайбер юнәлешләре

Безнең чорда яшь буын Александр Матросов, Газинур Гафиятуллин, Муса Җәлил кебек күренекле шәхесләргә сокланып, алар турында шигырьләр һәм җырлар өйрәнеп, батырлар үрнәгендә тәрбияләнде. Аларның биографиясен, батырлыгын, әсәрләрен яттан белдек. Сугыш турында кинолар караганда да йөрәк сыкрый, күңел елый иде. Кызганыч, данлы еллардан ерагая барган саен, яшьләр үткәннәрне оныта бара. Яшьләрнең табынырга, тигезләнергә, үрнәк алырга тиешле кыйбласы буталды. Мәктәпнең укыту – тәрбия системасына нинди генә үзгәрешләр кертелсә дә, хәзергә рухи – әхлакый тәрбия бирүдә тиешле нәтиҗәгә ирешеп булмый әле. Югыйсә, яшьләрнең бүген алган тәрбиясе халкыбызның киләчәген билгели бит. Яшь буынга әхлак, патриотик һәм рухи тәрбия бирүдә нинди үтемле чаралар кулланырга соң?

Дәрестә һәм дәрестән тыш чараларда укучыларда патриотик хисләр тәрбияләү – әдәбият укытучыларының мөһим бурычы. Патриотик тәрбия дигәндә, без балаларны милли үзаңга һәм гражданлык хисенә ия булган шәхесләр, Ватанның лаеклы уллары, кызлары итеп тәрбияләүне күз алдында тотабыз. Кеше кече яшьтән үк яхшы белән начарны, түбәнлек белән бөеклекне аерырга, үз иленең гражданины, патриоты булып үсәргә тиеш.

Укучыларда гражданлык һәм патриотик хисләр тәрбияләү уңаеннан мондый юнәлештә эшләү максатка ярашлы:

- республика, туган як турында мәгълүмат бирү;
- төбәктә яшәүче язучылар, сәнгать кешеләре, ветераннар, батырлар белән очрашулар үткәрү, аларның тормыш юлын өйрәнү;
- мәктәп, микрорайон күләмендә чаралар үткәрү;
- батыр милләттәшләребезнең исемен мәңгеләштерү йөзеннән эзләнү – тикшерену һәм проектлар эшләрен башкару;
- мәктәп музеен тулыландыру һ.б.

Әйтергә кирәк, хәзерге шартларда балаларда ватанпәрвәрлек хисләре тәрбияләү җиңел эш түгел. Ләкин без, әдәбият укытучылары, Ватаныбызның олы җәүһәрләре, халкыбызның данлы үткәне, күренекле шәхесләре һәм фидакяр батырлары турында мәгълүматны балаларга ачык һәм аңлаешлы итеп җиткерергә тиешбез.

Соңгы елларда туган җиргә, Ватанны саклауга карата әхлаксызлык күренеше тормышыбызның күп ягына үтеп керде. Мондый шартларда әдәби әсәрләрнең яшь буынга әхлак тәрбиясе бирүдә әһәмияте гаять зур. Матур әдәбият әсәрләре арасында Г.Тукай, Дәрдмәнд, Х.Туфан, С.Хәким, М.Җәлил, Ф.Кәрим лирикасы, Т.Миңнуллин, Н.Фәттах, М.Мәһдиев, Г.Әпсәләмов, Н.Дәүли һ.б. язучыларыбызның хикәя, повесть, романнары да бүгенге яшьләргә патриотик, гражданлык тәрбиясе бирүдә ачык мисаллар. Шунысы бәхәссез: әлеге шагыйрь, язучы, драматургларны укып, батырлыкка дан җырлаган спектакльләр карап

үскән буын киләчәктә үз иле, теле, милләте өчен файда кылудан, горурланудан туктамас. Яшьләребезне никадәр гаепләсәк тә, алар арасында да Муса Җәлил, Газинур Гафиятуллиннар батырлыгын кабатлаучылар аз булмас. Яшь буынны әлеге адымнарга, һичшиксез, милләттәшләренең батырлыгы илһамландырыр. Мусаның үлемсез җырлары безгә фашистлар җәзалаган миллионнарча көрәшчеләрнең васыятьләре булып килеп җитте, алар үтәлергә тиеш. Менә шуңа да халкыбызның батырларын барлау, халыкның үткәнен өйрәнү — мөһим бурыч.

Эш практикабызда проект эшләре темасын тәкъдим иткәндә игътибарны күбрәк Муса Җәлил, Фатих Кәримнең иҗатын һәм батырлыгын өйрәнүгә юнәлдерәбез. Муса Җәлил иҗатын өйрәнгәндә, түбәндәге проектларны кулланып була:

- тикшеренү (хезмәтнең актуальлеген нигезләү, тикшерүнең максаты әйтү, бурычлар кую, аларны чишү юлларын күрсәтү);

- иҗади (кичә яки бәйрәм үткәрү өчен сценарий төзү, м-н “ Каләмне корал итеп”, “Бөек Җиңү көне” бәйрәме, мәкалә язу “Муса Җәлил – батыр сугышчы”);

- гамәли юнәлешле (һәр укучының, төркемнең бөтен эшчәнлеген яхшы нәтиҗәләргә ирешү максатыннан чыгып планлаштыру). М-н, М.Җәлил иҗаты буенча рәсемнәр, коллажлар ясау, китапчыклар чыгару, библиографик даталар буенча ярдәмлек чыгару, ”Татар каһарманы” дигән темага презентация ясау, бер төркемгә яралы сугышчылар турында шигырьләр табып килергә, икенче төркемгә – Җәлил иҗатына багышланган стенгазета чыгарырга, өченчеләренә – Җәлилгә багышланган мәкалә язарга тәкъдим итәргә була);

- мәгълүмати (темага караган мәгълүматларны җыю, аларны катнашучыларга тәкъдим итү, фикер алышу, йомгаклау). Эшемдә бер яки өлешчән дәрестә мини-проектлар планлаштырам, м-н, котлаулар язу, минем яраткан шагыйрем турында мини – эзләнү проект ясау, хронологик таблица төзү, М.Җәлилнең гаилә альбомын ясау);

- предметара (берничә предметка нигезләнү). М-н, «Батыр көрәшчеләргә багышланып куелган һәйкәлләр» (рәсемле таблица), “Герой-шәһәрләр” (карта).

Безнең сезгә “Җырлый белгән бөркет ул, сугыша белгән былбыл” исемле - мини проект паспортын тәкъдим итәсебез килә.

Бу проектны тормышка ашыру өчен күрсәтмә материаллар - китаплар, кулланма материаллар - альбом битләре, төсле карандашлар кулланылды. Проект эшчәнлеге белән ата-аналар да таныш булды. Без балалар белән әдәбият дәресләрендә М.Җәлил биографиясен, шигырьләрен өйрәндек, җырлар өйрәндек, М. Җәлил турында фильм карадык, рәсемле китаплар белән таныштык, өйгә эш итеп балаларга М.Җәлилнең тормыш юлы һәм иҗаты белән тирәнрәк танышырга тәкъдим ителде.

Эш юнәлеше: Иҗатын нинди чорларга бүлергә була? Шигырьләре нинди темага язылган? Ни өчен герой исеме биргәннәр? Укучылар үзләре теләгән юнәлеш буенча

фотосурәтләр эзләде, аларга кыскача мәгълүмат туплады. Тупланган күрсәтмә материал альбомга теркәлеп, укучыларның күмәк эше ясалды. Проект эшен яклау вакытында укучылар үзләренең сайлап алган юнәлешләре буенча чыгыш ясады. Без бу проект өстендә эшләп балаларда кызыксыну, күмәк эшләү, бер-берсе белән дус-тату эшләүне тәрбияләдек дип уйлыйм. Чөнки, аларның яңа сораулары, яңа фикерләре туа торды. Шуңа күрә без үзебезнең алга куйган бурычыбыз үтәлде дип уйлыйбыз һәм проект методының балаларның иҗади сәләтен үстерүдә отышлы алым икәнен үз тәҗрибәбездә күрдек.

Патриотизм – ул кешеләрнең рухи һәм әхлакый сыйфаты: туган йортыңа, җиреңә, телеңә, мәдәниятыңа мәхәббәт, илеңнең героик үткәне һәм хәзергесе белән горурлану. Укучыларда патриотик аң формалаштыру үзеннән үзе генә түгел, эзлекле алып барылырга тиеш. Ул өйдә башланып, балалар бакчасы, мәктәп һәм кешенең гомере буе ныгытыла.

Татарны ничәмә гасырлар иманлы, гуманлы, көчле рухлы итеп яшәткән нәрсә – ислам дине, шәригать кануннары. Тәрбия кылу ата-бабаларыбыздан килгән гореф-гадәтләр, дини һәм дөньяви йолалар, хезмәт, гаилә һәм милли традицияләребез, җәмгыять тормышында урнашкан әдәп, әхлакый кыйммәтләр, ислам диненә салынган әхлакый һәм гуманистик идеяләр шәригать кануннарына нигезләнгән булган.

Без, тәрбия кылуда асылыбызга кире кайтмый торып, милләтебезне бүгенге фаҗигале халәттән чыгару мөмкин түгеллеген аңларга тиеш. Бу гореф-гадәт, тел, халыкның рухи байлыгы, өлкәннәргә хөрмәт, киң күңеллелек мәсьәләсе, халыкның ерактан килә торган яшәү рәвеше, рухи байлыгы, әхлак кагыйдәләрендә чагыла.

Җирдә тереклек дәвам итә. Изге куәткә ия булган орлыклар мәктәптә шытым биреп, алар һаман да үсеп җимешләрен бирсен иде. Без, укытучылар, балаларны маңгай күзе белән генә түгел – күңел күзе белән дә “укырга” өйрәтергә тиешбез. Укучы әйләнә-тирәдәгеләрнең шатлыкларына һәм хәсрәтләренә игътибарлы булырга, ямьсезлектән йөз чөерергә өйрәнергә тиеш.

*Гыймранова Илсөяр Гарәфетдин кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 27 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең беренче категорияле татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Сәләтле укучылар белән эшләү алымнары

*Һәр кешедә кояш бар.*
*Аңа яктыртырга ирек бирергә кирәк.*
***Сократ***

Галимнәр сәләтсез балалар юк, һәркемнең нәрсәгә дә булса сәләте, омтылышы була диләр, ә безнең – укытучыларның бурычы – баланың сәләтен ачыклау, ихтыяҗын төрле яктан канәгатьләндерү, сәләтен үстерү.

Минем һәр яңа дәресем балалар өчен яңа ачыш алып килергә, белем алуга теләк уятырга, аларны иҗатка этәрергә тиеш. Мәктәп - иҗат мастерское бит ул.

Хәзерге заман мәктәбе узенең үсешендә катлаулы чор кичерә. Иҗтимагый мәгариф икътисади үзгәрешләр: магариф системасында яңарту, төрле типтагы магариф учреждениелерендә укыту-тәрбия эшенә күп өстенлек бирелә.

Хәзерге чорда дөнья күләм мәсьәләләр хакында фикер йөртерлек шәхес тербияләү аеруча әһәмиятле. Төрле телдәге фәнни чыганаклардан мәгълуматлар туплап, үз карашын берничә телдә аңлатып бирә алырлык. Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Рәзил Валиев болай дип әйтте: «Сәләтле балалар белән эшләү мөһим. Чөнки әлеге яшьләр безнен икьтисадны, сәнгатьне, фәнне алга жибәрәчәк». Әлеге әйткан сүзләр бик дөрес дип саныйм. Безнең балаларыбыз тиз үсә. Укыту өлкәсендә сәләтле балаларны табу һәм аларның эшчәнлеген үстерү - хәзерге көндә төп бурычларның берсе булып тора. Без баланың сәләтен никадәр тизрәк күреп алабыз, үстеребез, уңай шартлар тудырабыз, шул очракта гына көтелгән уңышларга ирешә алабыз. Хәзерге заман шартларында сәләтле балалар белән эшләү системасы зур җаваплылык сорый дип әйтергә кирәк. Ни өчен дигәндә, һәрбер кеше үзенең мөмкинлекләреннән, үзе кызыксынуларыннан чыгып, киләчәк һөнәр сайлый, олы тормыш юлына аяк баса. Һәр уңышка ирешүнен сәләт-талант нәтиҗәсе генә түгел, зур тырышлык нәтиҗәсе икәнен беләбез. Баланың сәлетен дөрес юнәлештә үстергәндә ул берничә өлкәдә үзенең талантын күрсәтә ала. Укытучыларга балаларның ни дәрәҗәдә сәләтле булуын белү бик мөһим. Алардан сәләтле балаларның күңелен аңлау, аларның үсешенә көч-куәт бирерлек эшләр башкару, шәхси якын килу таләп ителе. Укучылар белән эшләгәндә берничә принципны күздә тотарга кирәк. Аларнын беренчесе – укучыларның белем үсеше дәрәҗәсен бик тиз һәм төгәл билгеләү һәм шуның белән бәйләнешле рәвештә, дәреслернең тема һәм формаларын планлаштыру вариантларын төгәл фәнни нигезләр сайлап алу. Икенчесе - дәрестә дифференциалле укытуны фәнни нигездә гамәлгә ашыру, үсеш дерәҗәләре хәзерлекләре төрлечә булган укучыларны тиешле белем алуына ирешу, дәресләрдә нинди алым һәм эш формалары кулланырга кирәклеген билгеләү. Өченчесе - дәрестә укытучы-укучы дуслыгын тагын да нәтиҗәле итү, юлларын табу. Акыл сәләтен эшкә җигү - шулай ук хәл итәсе масьәләләрнең - берсе. Бу - туктаусыз алга бару мөмкинлеге тудыру дигән сүз. Сәләтле балалар белән эшләгәндә нинди алымнар кулланыла һәм аларның нәтиҗәлелеге нинди?

Терек схемалар (конспектлар) - үзара нык бәйленештәге сораулар яки тема буенча кыскача нәтиҗәләр системасы ул. Алар укучыларга теманы аңлату алдыннан өләшенә һәм балалар укытучы сөйләгәннәрдән җавап эзлиләр яки тема нәтиҗәләрен таба баралар. Әлеге

конспектларда көчлерәкләр өчен текстлы биремнәр яки өстәмә сораулар бирелә. Мондый укытуның уңай нәтиҗәсе бар. Сәләтле балалар да, уртача белем алучылар да биремнәрне бик теләп үтиләр, сорауларга җавап табалар. Шулай итеп аларның белеме тирәнәя.

Текстлы биремнәр, шулай ук тестлар да киң кулланыла. Укучы үзе дөрес дип санаган җавапның берсен сайлап ала. Сәләтле балаларга катлаулырак, эзләнә торган сораулар яки җаваплар тәкъдим итергә мөмкин.

Балаларның ни дәрәҗәдә сәләтле булулары укучыларның бер-берсенең белемен тикшеру, проектларны яклау, дөрес-конференциялердә, семинар-ларда ачык куренә. Мәсәлән, дәрес-семинарларны алыйк һәр баланы актив катнаштыру - дәреснең төп таләбе. Алардан өстәмә әдәбият белән җитди мөстәкыйль эш (яңа чыганакларны уку, материалларны чагыштыру, кызыклы мәгълуматлар сайлап алу) таләп ителә.

Эшләү методларының тагын берсе - кроссвордлар. Кроссворд чишү -җиңел эш. Аны тезү - авыр, катлаулы; укучыдан тырышлык һәм эзләнү сорый. Сүз теркемнәрен, кош-корт, җәнлек, агач исемнерен өйрәнгәндә укучылар кроссвордларны бик рәхәтләнеп төзиләр. Аларны төзегәндә табышмаклар куллану тел дереслерен әдәбият дәресләре белән бәйли.

Элеге кроссвордларны халык авыз иҗаты әсәрләрен үткәндә куллану яхшы нәтиҗә бирә. Шулай ук сочинение язу, шигырь, хикәя, әкиятләр уйлап чыгару укучыларны иҗади фикерләү дәрәҗәлерен үстерә, сүзлек запасын баета, сөйләм телләрен үстерә.

Сәләтле балалар белән эшләүнең төп максаты: һәр укучының сәләтен, иҗади башлангычын үстерә. Мондый укучылар белен эшләгәндә эзләнергә, яңа мөмкинлекләрдән файдаланырга туры килә.

Шактый еллар инде мәктәпләрдә татар теле һәм әдәбиятыннан олимпиадалар үткәрелә. Олимпиадаларга әзерләнгәндә, төрле эш алымнары кулланыла. Укытучы белән укучы арасындагы әңгәмәләр, фикер алышулар, тест биремнәрен үтәү, яңа чыккан фәнни китаплар, методик кулланмалар белән танышып, өйрәнеп бару зур әһәмияткә ия. Дәресләрдә бу укучыларга, темаларны үткән вакытта, өстәмә чыганаклардан файдаланырга, иҗади эзләнергә кушыла.

Фәнни конференцияләргә әзерләнүне дә укучылар сәләтен үстерүдә зур әһәмияте бар. Бирелән тема буенча укучы өстәмә чыганаклардан файдаланып әзерләнә. Үзен кызыксындырган сорауларга җавал эзли. Теманы тулысынча ачып биру өчен, берничә чыганактан файдалана. Үзенен дәлилләрен берничә галимнең фикерләре белән ачыклый. Монда укучының мөстәкыйль фикер йөртүен, эзләнүен, нәтиҗә ясавын ассызыклап үтәргә кирәк.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: дәресләрдә кулланылган эш алымнары (карточкалар белән эш, рәсем, картиналар буенча иҗади эшләр, компьютерда эшләү) - барысы да укучыларның сәләтләрен үстерүгә юнәлтелгән. Бары тик үз эшеңне чын кунелден яратып,

вакытыңны кызганмыйча эшләсәң, балалар тагын да зур уңышларга ирешәчәк һәм калган укучылар арасында сәләтле балалар саны, һичшиксез, артачак, әлбәттә.

*Заляилева Лейсан Равил кызы,*
*Минзянова Гульсум Абдулгазиз кызы,*
*Татарстан Республикасы Казан шәһәре Совет районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 144 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле туган тел һәм әдәбияты укытучылары*

**Үсеп килүче буынны тәрбияләүдә милли традицияләрне саклауның роле.**

Бүген мәктәптә баланы ата - бабаларыбызның гаҗәп бай акыл хәзинәсенә нигезләнгән һәм мең еллар буенча тупланып, камилләшеп килгән милли гадәт, йолаларыбыз, гаилә, әдәп, әхлак кануннары нигезендә тәрбияләү зур әһәмияткә ия.

Мәктәп яшь буынга белем һәм тәрбия бирүдә халыкның милли традицияләренә нигезләнгәндә генә үзенең тәрбияви һәм белем бирү бурычларын уңышлы хәл итә ала.

Бала аңына үз халкыңның үсеш тарихын, мәдәниятен, милли үзенчәлекләрен, хәзерге көндәге халәтен, дөнья халыклары арасында тоткан урынын, зыялылары, галимнәре турындагы мәгълүматны, гаиләсенең “нәсел агачын”, гореф-гадәтләрен, йолаларын, бәйрәмнәрен үз туган телендә сеңдергәндә генә үз милләтеңә хөрмәт, мәхәббәт тәрбияләнә.

Тәрбия эшебезнең максатлары һәм бурычлары:

- халкыбызның милли үзенчәлекләрен, күркәм сыйфатларын, йола-гадәтләрен, гаилә төшенчәсен кече яшьтән үк төшендереп, укучыларны өлкәннәр үрнәгендә тәрбияләү;
- әхлакый сыйфатларга, балаларны кешеләр белән аралашу кагыйдәләренә өйрәтү;
- югары әдәп, әхлак сыйфатларын булдыру;
- туган телебез, мәдәниятебез үсеше өчен җаваплылык хисе тою.

Туган телгә мөнәсәбәт үзгәргән, мәктәпләр эшчәнлегенә хәлиткеч үзгәрешләр кертелгән чорда милләтебезне нинди юллар белән саклап калырга мөмкин соң? Һәм бу эшкә кемнәрне җәлеп итәргә кирәк?

Әлбәттә, милләтебезнең бердәмлеген саклау, аның киләчәген тәэмин итү өчен, беренче чиратта, яшь буыныбызны милли рухта тәрбияләү мөһим. Милли тәрбиянең эчтәлеге нидән гыйбарәт? Бүгенге шартларда аны нинди юллар белән алып барырга мөмкин? Бу сораулар бүген күпләрне уйландыра торгандыр.

Мәктәпләрдә тәрбия бирү рәсми рәвештә кабул ителгән концепция һәм программа нигезендә алып барыла.

Милли тәрбия бирүнең эчтәлеге, нигездә, өч өлештән тора, дип әйтергә була. Беренчесе – балаларга гомумкешелек кыйммәтләренең асылын аңлату һәм аларның бу кыйммәтләрне тануына ирешү. Икенчесе – балаларда гомумкешелек сыйфатларын формалаштыру. Өченчесе – балаларның татар милләтенең төп сыйфатларына ия булуларына ирешү.

Галимҗан Ибраһимовның әле 1919 елда ук язган гыйбрәтле һәм акыллы сүзләре бар: «Сабыйның рухы ни бирсәң шуны алучан; ни салсаң шуны үзенең гомерлек хәзинәсе итеп урынлаштыручан. Бирелгән нәрсәләр милли тәрбиягә нигез булсын өчен, аңа иң элек үз анасының теле билгеле бер ысул белән йөрәгенә ярып салынырга тиеш: бала иң элек үз халкының хәрефләрен күрсен; үз авазын ишетсен; үз сүзләрен, үз җөмләләрен тикшерсен; кечкенә куллары иң элек үз хәрефләре белән үз ана теленең сүзләрен язсын! Һәрнәрсәне йотып алырга әзер торган сабый йөрәгендә болар, каты мәгъдәнгә үткен корыч белән казып язылган кебек, мәңге бетмәслек тирән эз салачаклар, һәм шул беренче нигез булачак. Сабыйның гакылы икенче дәрәҗәдә тора, һәрнәрсәне ул тойгысы белән каршы ала. Аның тойгысына азык булачак нәрсәләр дә милли телнең асыл җәүһәрләре булсын; иң элек сөеп укыган әкиятләре үз телендә, үз бабаларыннан калган, үзенә таныш каһарманнар хакында булсын, иң элек ишеткән зур вакыйгалары, олуг каһарманнары, иң элек исемен күргән, исемен ишеткән язучылары үз халкыннан булсын — болар аның хыялын үз халкыбыз хәятына, уйларын-тойгыларын үз каһарманнарына бағлар, һәм бала боларны ихтыярсыз сөяр, рухы белән шуларга багланыр. Милли тәрбиянең төп нигезе дә шундадыр”. Моннан чыгып, милли тәрбия бирүдә беренчел таләп туган телгә өйрәтү икәнен яхшы аңлыйбыз.

Моннан бүгенге көндә туган тел укытучысы алдында торган төп **бурычларыбызның** берсе чыга, ул - – телебезне яратучы, үз милләте белән горурланучы, халыкның әдәбиятын, мәдәниятын, гореф – гадәтләрен, изге матур йолаларын, тарихын, туган республикасын, туган шәһәрен хөрмәт итүче, тирән милли үзаңы формалашкан шәхес тәрбияләүгә өлеш кертү.

Укытучы - белем бирүче генә түгел, чын мәгънәсендә тәрбияче дә.Ул яшь кешенең эчке дөньясын, сәләтен, әхлакый сыйфатларын, психологик үзенчәлекләрен күздә тотып эшләргә бурычлы.

Укытучы алдында шәхеснең акыл эшчәнлеген төрле яклап үстерүне күздә тотып, никадәр яңа алымнар, шартлар, технологияләр барлыкка килде. Шулар арасында милли рухлы хәзинәбез күмелеп калмасын иде. Безнең рухи байлыгыбыз, милли традицияләребез исән. Алар безгә бүгенге һәм киләчәк өчен кирәк.

Без рус мәктәбендә эшләүче туган тел укытучылары, инде 4 нче ел үткәрелеп килә торган “Калфак һәм түбәтәй көне” проекты белән таныштырып үтәсебез килә. Безнең чыгышыбызның максаты, милли проектыбызны башкаларга да җиткерү.

*Куряева Людмила Петр кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «8 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

**Мәктәптә патриотизм тәрбияләүдә милли традицияләрнең роле**

Яшь буынга патриотик тәрбия бирү мәктәптә һәрвакыт игътибар үзәгендә тора. Ул иң элек укучыларда туган илгә һәм туган җиргә карата мәхәббәт тәрбияләүне, патриотизмны күздә тота.

Бүгенге көндә безнең алда торган мөһим бурычларның берсе – тормышка әзер булган, үз Ватанына чын күңелдән бирелгән Кеше, Гражданин һәм Патриот тәрбияләү. Ә кем соң ул патриот? Патриот – үзенең туган җирен, халкын, Ватанын сөюче, шулар өчен һәртөрле корбаннарга да әзер булган кеше.

Җәмгыятьнең мораль кризис кичерүе, әхлак нормаларының таркала баруы, игелек, мәрхәмәтлелек сыйфатларының кими баруы яшьләргә тискәре йогынты ясый. Хәзерге балаларга совет чоры әсәрләрен, бигрәк тә патриотик рухта язылганнарыннарын аңлау кыенлашты. Ләкин җәмгыять ничек кенә үзгәрмәсен, кеше яхшы белән начарны, ак белән караны, бөеклек белән түбәнлекне аерырга, үз иленең гражданины, патриоты булып үсәргә тиеш. Чөнки бәхетле тормышны үз илебездә үзебезгә төзергә туры киләчәк.

Яшьләрне патриотик рухта тәрбияләүдә төп рольне укытучы үти. Укытучы - ул буыннарны тоташтыручы, белем биреп кенә калмыйча, укучыларга өлкән буыннарның рухи байлыгын җиткерүче дә, шәхес тәрбияләүче дә. Ә шәхес - җәмгыятебезнең җимеше. Җимешне өлгертер өчен күпме вакыт һәм көч кирәк: җирен йомшартып орлык чәчәргә, кибәргә бирмичә суын сибеп торырга. Заманча технологияләр никадәр генә алга китмәсен, күпме генә аларны мактамасыннар, барыбер укучыга рухи тәрбияне укытучы бирә.

Укучыларда гражданлык һәм патриотик хисләр тәрбияләү юнәлешләре:

а) республикабыз, туган ягыбыз тарихы, мәдәнияте турында мәгълумат бирү;

б) төбәктә яшәүче язучылар, сәнгать кешеләре белән очрашулар үткәрү;

в)халкыбызның гореф-гадәтләре,традицияләре белән тулырак таныштыру;

г)хезмәт һәм сугыш ветераннары белән очрашулар үткәрү.

Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк, диләр. Безнең бай тарихыбыз, мәдәниятебез, мәгарифебез, батыр, эшчән халкыбыз бар. Шәһәребезнең тарихы – халкыбыз тарихының аерылгысыз бер мөһим өлеше ул. Аларны өйрәнү, үзең яшәгән төбәк белән горурлану хисләре тәрбияләү – һәрберебезнең бурычы.

Әдәбият һәм татар теле дәресләрендә патриотик тәрбия бирүгә зур игътибар бирергә тырышабыз. Татар теленнән укыту  планы буенча рус төркемнәрендә укучы балалар өчен “Татарча да яхшы бел” дәреслекләрендә туган як темасына “Мин яратам сине Татарстан”, “Туган җиреңнән китмә”, “Истәлекле урыннар”, “Башкалабыз яңарды, матурайды, зурайды” кебек темалар кертелгән. Бу дәрес темалары укучыларда тарихи һәм истәлекле урыннарга сакчыл караш,Татарстан республикасы белән горурлану хисе тәрбияли, Казан тарихына карата кызыксыну уята. Балалар үзләре теләп туган якка, Казан ханлыгы чорына багышланган легендалар табып докладлар, презентацияләр әзерләп киләләр.

Туган ил тарихының һәрнәрсәгә, һәркемгә, шул исәптән үзләре яшәгән гаиләгә дә, кагылышлы булуын тирән аңлату, төшендерү кирәк. Шул максаттан укучыларга әби-бабайларының Бөек Ватан сугышы чорындагы тормышы белән кызыксындыру өчен сочинение язып килергә, нәсел шәҗәрәләрен төзеп килергә кушабыз.

Г.Кутуйның “Сагыну” нәсерен өйрәнгәндә дә укучыларга патриотик тәрбия бирергә мөмкин. Әсәрдә солдатның туган илен сагыну хисләре чагылдырыла. Туган ил һәркем өчен кадерле һәм якын. Шулай ук М.Җәлил, А.Алиш иҗатларын өйрәнү дә укучыларга патриотик тәрбия бирүдә матур үрнәк булып торалар.

Башлангыч сыйныфларда  әлеге максатка ирешү өчен, яңа материал аңлатканда, диалоглар уздырганда, укучыларның белемнәрен тикшергәндә, туган шәһәребез турында җөмләләр, текстлар файдаланабыз . Өйдә эшләп килер өчен “Минем  шәһәрем” темасына инша язу уңышлы бер алым дип саныйбыз. Рухи кыйммәтләребез үз төсен югалта, онытыла барган бу чорда туган якны өйрәнү шул максатка ирешү юлы булып тора һәм мөстәкыйль, ирекле, намуслы, үз Ватанының лаеклы улы яки кызы булырлык шәхес тәрбияләргә ярдәм итә. Шул максаттан чыгып, без укучыларда милли тарихыбызга, туган телебез һәм әдәбиятыбызга, мәдәниятебезгә мәхәббәт тойгысы, үз халкың белән горурлану хисләре, аның тарихын, уңай гореф – гадәтләрен, традицияләрен өйрәнү белән кызыксындыру шикелле сыйфатлар булдыруны күз алдында тотабыз. Һәр дәрес, бигрәк тә әдәбият дәресләре, класстан тыш чаралар патриотик тәрбия бирү мәктәбе булырга тиеш.

Безнең мәктәптә күп еллардан бирле бик күп экспанатларга бай булган музей эшләп килә. Беренче зал  татар халкының милли традицияләре, гореф - гадәтләре, йолаларына, ә икенче зал Бөек Ватан Сугышы чорына багышланган. Без кайбер класстан тыш чараларны, тәрбия сәгатьләрен музейда үткәрү гадәтен алдык. Биредәге татар халкының көнкүреш җиһазлары, милли киемнәре укучыларда халкыбыз тарихына кызыксыну уята, милли тәрбия бирүдә зур роль уйный. Ветераннар белән очрашу чараларын шулай ук музейда үткәрергә тырышабыз. Балалар ветераннардан сугыш турында күп мәгълүмат алалар, алар белән әңгәмә коралар. Ил өчен барган аяусыз көрәш барганда да, Ватаныбызга булган чын

ярату, Ватан өчен көрәшнең изге, хак булуына ышанудан көч алып җиңүгә ирешкән ветераннар яшь буында патриотизм, гражданлык хисләре уяталар.

Шулай итеп, бүгенге авыр, катлаулы чорда әдәпле һәм итагатьле патриот шәхес тәрбиялим дисәң, эшне, балага кечкенәдән үк туган ягы, халкы тарихын өйрәтүдән башларга кирәктер.

*Мавлютова Ранилә Хәмәтгали кызы,*
*Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Көек авылы «Елмай» 3-нче номерлы билингваль балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениясенең беренче категорияле тәрбиячесе*

**XXI гасыр баласын тәрбияләүдә мәктәпкәчә белем бирү оешмасының роле**

Мәктәпкәчә белем бирү оешмасында тәрбия системасының ни дәрәҗәдә **мөһим һәм актуальлеге** көннән-көн арта. Массакүләм мәгълүмат чараларыннан яшүсмерләр, яшьләр тарафыннан кылынган коточкыч җинаятьләр турында еш ишетергә, күрергә туры килә һәм әлеге балаларның (әйе, аларның күбесе балалар) гамәлләрен бәяләгәндә, сәбәпләрне эзләгәндә, иң беренче эш итеп, бала чакларын өйрәнү, тикшерү башкарыла. Кечкенәдән үзен ничек тотуы, хорлык-фигыле, сөйләшү рәвеше, аралашу даирәсенә басым ясала. Ә боларның барысы да диярлек балалар бакчасында формалаша, баланың шәхес буларак формалашуына тәрбияче җавап бирә кебек. Билгеле, төп җаваплылык һәрвакыт эти-әниләр җилкәсендә. Әмма хәзерге заманда баланың тәрбиясе, белеме күп очракта нәкъ менә балалар бакчасы, мәктәп кысаларында гына каралырга мәҗбүр. Эш белән артык мәшгүль ата-аналарның балалары белән ачыктан-ачык аралашу, аңлашуга вакытлары бик аз кала, кызганыч, еш кына тәрбия бирү, шәхси үрнәк күрсәтү турында да сүз алып барып булмый.

Шунысын аерып билгеләп үтәсе килә: баланың шәхес буларак формалашуы, холык үзенчәлекләре һәм алга таба аның физик, психик яктан үсешендә кайбер сыйфатлары нәкъ менә мәктәпкәчә белем бирү оешмасында башкарыла. Әгәр дә шушы яшьтә баланың үсеш үзенчәлекләренә игътибар юнәлтелмәсә, бу хәл киләчәк тормышында начар чагылыш табарга мөмкин. Кечкенә баланың үсеш үзенчәлекләре, уйлары, фикерләве кирәкмәгән юнәлеш алудан куркырга кирәклеген уку йортларында булган барыбызга да билгеле аяныч вакыйгалар искәртә.

Без тиз үзгәреп торган, яңалыкларга бай, кайчакларда тотрыксызлык күзәтелгән заманда яшибез. Шуның өчен дә баланы дөрес һәм лаеклы итеп үстерү, тиешенчә тәрбияләү эше күп сораулар тудыра. Бигрәк тә балалар бакчасы тәрбиячеләренең хезмәтен тагын да

катлауландыра, җаваплылык хисен арттыра. Кечкенә бала белән эшләүче тәрбияче алдында көн саен яңа сорау, катлаулы мәсьәлә туып тора. Бүгенге бала да, заман кебек үк, катлаулы – еш үзгәреп торган кызыксынулар, авыр холыкка ия. Кайчак үз әти-әнисе белән уртак тел тапмыйча, тыныша алмаган бала белән тәрбияче сөйләшә, аңлаша алырга тиеш һәм мәҗбүр. Чөнки иртән өйдән начар кәеф белән килгән баланың көне буе балалар бакчасында буласы, өч дистәгә якын төркемдәшләре белән көнен уздырасы бар. Шунлыктан тәрбияче баланың әти-әнисе, гаиләсе белән дә турыдан-туры эшләргә мәҗбүр. Чөнки балалар бакчасыннан уңайланып кайтып киткән баланың икенче көн иртәдән кабат начар кәеф белән килүе ихтимал һәм моның сәбәпләре дә төрле булырга мөмкин. Тәрбияче бала белән ата-аналар арасында ныклы элемтә тудыручы психолог роленә керергә тиеш.

Шуны онытмаска кирәк: җәмгыятьтәге һәм гаиләдәге тәрбия бирүнең үзара элемтәсе норматив-хокукый документларда да чагылыш тапкан. Мисалга “Мәгариф турындагы закон”ны алыйк. Анда ата-ананың бала өчен иң беренче мөгаллим булуы, кече яшьтән үк баланың физик, рухи һәм интеллектуаль үсешенә нигез салырга тиешлеге турында искәртеп үтелгән. [18 Матдә. п.1.] Шуның белән  бәйле рәвештә, тәрбияче баланы тәрбияләп кенә калмый, ә ата-аналарны үз баласы белән аралашырга, аларны ишетергә дә өйрәтә. Тәрбияче, оста психолог булу белән бергә, бала тәрбияләшүдә ата-ананың төп ярдәмечесенә әверелә.

Мәктәпкәчә яшьтәге баланы тәрбияләүдә төп мәсьәләләрнең берсен югарыда ачыклый башлаган идек, ул – тәрбия эшендә иҗтимагый-әхлакый  сораулар. Аларның заман, замандагы үзгәрешләр белән бәйле булуын да атадык. Җәмгыятьнең балага тәэсире турында сөйләшкәндә, уңайга караганда, тискәре тәэсир өстенлек ала. Баланың әлегә ныгып бетмәгән акылы, фикерләве, хисләре ул тәэсирләргә тиз бирешә.

Кызганычка, безнең заманда гаиләләрнең күбесендә авыр хәлләр күзәтелә: биредә тулы булмаган гаиләләр, аерылулар, мал-мөлкәт һәм бала (!) бүлешү сорауларын күтәреп була. Ата-аналарда баланы тәрбияләүгә карата җаваплылык хисе зур булган саен, балалар бакчасындагы тәрбиянең эше дә нәтиҗәлерәк булыр иде.

**Нәтиҗә ясап**, шуны ассызыклыйсы килә: мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына нинди генә югары таләпләр куелмасын, иҗтимагый-әхлакый сорауларны балалар бакчасы кысаларында гына хәл итү мөмкин түгел. Ата-аналар тәрбиячеләргә, мөгаллимнәргә терәк-таяныч булырга тиешләр. Гаиләдәге җылылык, үзара аңлашу, мәхәббәт хисләрен бала күреп, сизеп үссә, күп сорауларны җиңелрәк хәл итеп булыр иде.

**Кулланылган әдәбият:**

1. Гребешова, С. В. Актуальные проблемы современного дошкольного образования. Текст: непосредственный // Молодой ученый, 2016. - № 13.3.

2. Дубенский, Ю. П. Воспитание и социализация личности. Нижний Новгород: Нижегородский гуманитарный центр, 2011. - 259 с.

3. Федеральный закон от 5 апреля 2021 г. № 85-ФЗ “О внесении изменений в Федеральный закон “Об образовании в Российской Федерации” – URL : https://www.garant.ru/products/ipo/prime/doc/400442027/

*Минегалиева Ләйсән Ризат кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге «1 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле башлангыч сыйныф укытучысы*

**Дәрестән тыш эшчәнлектә функциональ грамоталыкны үстерү.**

Һәр баланың уңышы аның сәләтләренә генә түгел, ә функциональ грамоталылыгына да бәйле. Функциональ грамоталылык нигезләре башлангыч сыйныфларда салына. Нәкъ менә шул чорда сөйләм эшчәнлегенең төрле төрләренә — уку һәм язу, сөйләү һәм тыңлауга интенсив өйрәтү бара. Функциональ грамоталылыкның төп күнекмәсе булып укучыларның грамоталылыгы тора.

Белгәнебезчә, функциональ грамоталылык күпкырлы төшенчә. Ул үз эченә:

- *уку грамоталылыгын,*
- *математик грамоталылыкны,*
- *табигый-фәнни грамоталылыкны,*
- *финанс грамоталылыгын һәм*
- *креатив фикерләүне* ала.

Уку грамоталылыгы – функциональ грамоталылыкның иң мөһим төрләренең берсе, аның нигезендә фикерләү эшчәнлеге ята. Уку күнекмәләре бик мөһим, чөнки көндәлек тормышта без еш кына язу үрнәкләре белән хәл итәбез: китаплар, матбугат басмалары укыйбыз, интернет челтәрләрендә төрле мәгълүмат эзлибез.Уку кешенең культурасын үстерә, аны шәхес буларак тәрбияли.

Уку грамоталылыгын күтәрүдә укытучының компетентлыгы да зур роль уйный. Укытучы функциональ грамоталылыкны формалаштыруның теоретик-методологик нигезләрен өйрәнеп барырга, кирәкле хокукый документларны төгәл үзләштерергә бурычлы. Функциональ грамоталылык төшенчәсен ачканда, функциональ грамоталылык һәм метапредмет нәтиҗәләр арасындагы аермалы үзенчәлекләрне билгелибез. Туган телендә укучыларның уку грамоталылын күтәрүнең төрле алымнар табарга, өйрәнергә,

эзләнергә тырышабыз. Укучы үзендә белем алу процессында алган күнекмәләрне теләсә нинди предмет материалы белән эшләгәндә иркен куллансын өчен, без гомуми алымнарга, техникаларга, схемаларга, фикерләү эшчәнлеге үрнәкләренә өйрәтергә тиешбез. Ул күнекмәләрне формалаштыру мөһим, чөнки метапредмет нәтиҗәләре югары предмет нәтиҗәләренә ирешү мөмкинлеге тудыра. Шулай ук функциональ грамоталылыкны формалаштырганда, төрле типтагы белемнәрне гуманитар фәннәрдә кулланырга өйрәнеп, практикага белемнәргә өстенлек бирү кирәк.

Функциональ грамоталылыкны үстерү өчен дәрестә төрле алымнар кулланырга мөмкин. Шуларның берничәсе белән сезне дә таныштырып китәм.

Әлеге биремнәр балаларның игътибарлылыкларык үстерергә, сүзләрне дөрес укырга һәм язылышларын хәтердә калдырырга булыша. Укучыларны мөстәкыйль рәвештә авырлыктан чыгарга, үзеңнең эш нәтиҗәң белән горурланырга этәргеч бирә.

1. А хәрефенә башланган 6 сүзне укы. абаганарбакчалмалка (абага,ана,арба,акча,алма,алка).
2. Беренче иҗекләрен генә укы. Нинди сүзләр килеп чыкты?

Кишер,тапкыр,такмак,тавыш,үрдәк,мәкаль,күчмә (китап,такта,үрмәкүч).

3. Татар алфавитында гына булган хәрефләрне укып мәкальне укыгыз.Кем тизрәк укый? Dбgkqerpzduәtiүsregrлkfbbirлudkәhkdөvч (Бердә түгел, илдә көч)

Шулай итеп, дәресләрдә төрле укыту алымнарын куллану укучыларның үз-үзләрен уйлау, анализлау, материалны сайлап алу, яңа ситуациядә ориентлашу, тормыш киңлегендә практик мәсьәләләрне хәл итү өчен эшчәнлек ысулларын табу күнекмәләрен үстерү өчен кирәкле шартлар тудыра. Бу укучыларның функциональ грамоталылыгын формалаштыруга ярдәм итә.

*Мифтахова Эльмира Флур кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «14нче лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Матурлык (Критик фикерләү технологиясе)

**Укытучы сүзе:** *Исәнмесез, хәерле көн, хөрмәтле хезмәттәшләр! Мин дәресләремдә критик фикерләү технологиясен уңышлы кулланып эшлим. Сыйныфта фикерләргә иренгән, фикере булса да, ялгыш җавап бирүдән курыккан балалар байтак иде. Максатым аларны “уяту” һәм иҗади эшкә тарту булды. Бу технологияне кулланып эшли башлагач, укучыларым мөстәкыйль фикер йөртүдән курыкмый башладылар.*

**Тема:** Матурлык

**Максат:**

1. “Матурлык” төшенчәсен ачыклау, төрле аспектлардан күзаллау;

2. Сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча эш барышында телдән сөйләм күнекмәләрен ныгыту; аларда мөстәкыйль һәм иҗади фикер йөртү, чагыштыру, нәтиҗә ясау кебек күнекмәләрне формалаштыру.

**Җиһазлау:** презентация “Матурлык”, аудиозапись, индивидуаль битләр, кәгазъ битләре, карандаш.

**1.Оештыру.**

Дәрестә укучыларның эшчәнлеген активлаштыру өчен кечкенә психологик тренинг уздырып китәсем килә. Һәр кешегә бер формада кәгазь битләре таратыла.

**Укытучы:**

Күзләрегезне йомыгыз һәм кулыгыздагы кәгазъ битләрен ертыгыз. Күзләрне ачтык, кәгазъ битендәге бизәкләр бер-берсенә охшаганмы? (*Без һәрберебез төрле-төрле, шулай ук фикерләребез дә төрле. Бүгенге дәрестә сез миңа булышырсыз һәм үз фикерләрегезне, серләрегезне әйтергә оялмассыз дип уйлыйм*)

**2.Төп өлеш.**

- Мастер классыбызны видео караудан башларбыз. Видеодагы күренешләрне нинди сүз берләштерә? (*Матурлык сүзе)*

-Мастер – классның темасы? (*Матурлык)*

- “Нәрсә соң ул матурлык?” дигән сорауга җавап эзләп карый әле. *(Укучыларның фикерләре тыңлана).*

- Матурлык ул табигать, тыныч тормышта, ул матур йөз, буй-сын, матур эшләр.

А) – Алдагы видеоязманы карыйк әле. Бу язмада нинди күренеш күрсәтелә? (Табигать) видеога карап нәрсәләргә сокландыгыз? *(Сихри күлгә, аллы-гөлле чәчәкләргә, биек тауларга, саф чиста һавага, кошлар сайравына)*

- Бу күренеш кә *ыргытылган таш алымы кулланып* җөмләләр төзик инде.

**Укытучы сүзе:** *бу алымы укучыларның иҗади фикерләвен үстерә, фантазияләрен баета, укучыларның бәйләнешле сөйләм телләре үсә.*

- Без сезнең нинди матурлык турында сөйләштек?

*Нәтиҗә: димәк, бу язмада табигатьнең матурлыгы сүрәтләнгән.*

Б) – Рәсемдәге кызның портретын төзеп карыйк әле. Портрет төзү аша нинди матурлык турында сөйләштек.

Кыйгач кашлы, бөдрә чәчле

Чибәрләрнең чибәре.

Сөрмә күзле, зифа буйлы

Гүзәлләрнең гүзәле...

- Дөрес, сылу кызның тышкы кыяфәте турында.

*Нәтиҗә: бу рәсем безгә кешенең тышкы матурлыгы турында сөйли.*

В) Ә хәзер мин сезгә әсәрдән өзек укырмын, игътибар белән тыңлагыз.

“Бәдретдин әнисенең ямьсезлегеннән, гариплегеннән, бабасының сукырлыгыннан, этисенең мескенлегеннән дә уңайсызланмый. Бу кимчелекләрне ул бөтенләй күрми. Өйдәге бу мескенлекләр зур мәхәббәт астында күмелеп калалар. Шушы өй эчендәге хәерчелек, ятимлек эченнән, чәчәк кебек, бу кешеләрнең үзара татулыгы, яратышуы дөньяга ямь, гүзәллек өсти.”

- Бу өзек кайсы әсәрне искә төшерә?

- Өзектә нәрсә турында сүз бара? (Әйе, гаиләдәге татулык, тормыш матурлыгы турында) Бу нинди матурлык икән?

*Нәтиҗә: күңел матурлыгы, эчке матурлык*

Без карап үткән видео, рәсем укылган өзек буенча туган фикерләребезне модельгә урнаштырыйк инде.

Укытучы сүзе: *Кластер ысулын кулланып матурлык турындагы фикерләребезне бергә туплык инде. Бу инглизчә “тәлгәш”, “бер үзәктә туплану”, фикерләрне, төшенчәләрне график сурәттә күрсәтү дигән сүзне аңлата.*

Матурлык

Күренеш | Тышкы | Эчке

- Ә матурлык сүзенең кагыйдәсе, фәнни аңлатмасы бар микән? Әйдәгез әле сүзлекләрне ачыйк һәм матурлык сүзен эзлик. Ул фәнни телдә нәрсәне аңлата икән?

- Матурлык – 1) Барлык матур, гүзәл, күңелгә рәхәтлек, ләззәт бирә торган нәрсә;

- 2) Матур, ягымлы, сөйкемле, үзенә нык җәлеп итә торган тышкы кыяфәт,чибәрлек;

- 3) Кешенең характерындагы, эшчәнлегендәге уңай, хуплана торган сыйфат, кешенең эчке матурлыгы.

- Бу аңлатмалар безнең модельгә туры киләме? Эйе әлбәттә....

- Ә хәзер матурлык сүзенә синквейн төзеп карыйк.

**Укытучы сүзе:** *Синквейн француз теленнән кергән сүз, синк “биш” дигәнне аңлата. Ул рифмалашмаган бишьюллык шигъри формада язылган кыска әдәби әсәр. Ул кыска төшенчәләр кулланып, укыган материал буенча нәтиҗә чыгарырга ярдәм итә.*

| | | |
|---|---|---|
| Матурлык<br>Ягымлы, игелекле.<br>Шатландыра,кызыктыра, күңелгә рәхәт бирә.<br>Адым саен бездә матурлык!<br>Гүзәллек. | Матурлык<br>Зифа, нәфис<br>Дулкынландыра, рухландыра, хыялландыра<br>Матурлык туйда кирәк!<br>Чибәрлек | Матурлык<br>Сылу, файдалы.<br>Явызлыктан саклый, коткара кара уйлардан.<br>Бай безнең заман матурлыкка!<br>Ямьлелек. |

- Укучылар, димәк без бүген сезнең белән нәрсә турында сөйләштек? Хәзер *Блум ромашка алымы, бу алым килеп туган проблеманы төрле яктан фикер йөртеп чишәргә ярдәм итә.* Чәчәк таҗындагы сораулар буенча матурлык төшенчәсенә аңлатма биреп карыйк.

- Әгәр бу таҗларның берсе генә булмаса да чәчәк матур булырмы? Әйе, бу таҗларның берсе генә югалса да, чәчәк матурлыгын югалта, димәк кеше дә үзенең матурлыгын югалта.

- Димәк, Матурлык һәркайда, аны күрә, тоя белергә генә кирәк. Мастер классымны *А.П.Чеховның сүзләре белән тәмамлыйсым килә "Кешенең бөтен нәрсәсе дә матур булырга тиеш: киеме дә ,йөзе дә, күңеле дә, фикере дә", сездә бу фикерләр белән килешәсездер. Шулай бит.*

*Матур булыйк барыбыз да,*
*Матурлыйк без дөньяларны.*
*Матур җырлар яңгырасын,*
*Сөендерик аналарны.*
*Матурлыкны күреп була,*
*Матурлыкны тоеп була.*
*Матурлыкка мәңгелеккә*
*Матур һәйкәл куеп була.*

*Мулламөхәммәтова Рәсимә Риф кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге «1 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле химия укытучысы*

**Кеше химия мөхитендә**

Укучылар эшчәнлеген оештыруның бер формасы булып тикшеренү эше тора, ул укучыларның иҗади эшчәнлеген үстерә. Балалар нинди дә булса мәгълүмат алып, аны үзләре дә тормышта куллана алалар.

Әгәр дә балачак дөньясына әйләнеп кайтсак, элек без кызыксынучан булдык, нинди булса да тәҗрибәләр уздырырга теләдек. Чөнки тәҗрибә балага ниндидер яңалык, мәгълүмат өчен ишек ача. Шулай итеп бала үзе нәрсәдер уйлап чыгарса, уйлап тапса, гомер буе ул аны онытмаячак. Монда Сухомлинскийның сүзләрен искә төшерү урынлы булыр: «Парта артында эшсез булу- иң куркынычы; көн саен 6 сәгать эшсезлек, айлар, еллар буе эшсез булу- бу кешенең рухын сындыра, фикер йөртү сәләтен , эшчәнлеген юкка чыгара».

Укытучының бурычы-баланы фикер йөртергә өйрәтү. Моның өчен эшне кызыксындырырлык, уйланырлык итеп төзергә, укырга этәргеч бирергә кирәк. Укыганда, уйлаганда, фикер йөрткәндә кеше мәгълүматны биш сенсор канал аша кабул итә: ишетү, күрү, ис һәм тәм сизү, тоемлау. Психологлар 4 төп үзләштерү төрләрен аерып күрсәтә: аудиаллар, визуаллар, кинестетиклар, һәм дигиталлар.

Аудиаллар- мәгълүматны ишетү каналы аша кабул итә.

Визуаллар- мәгълүматны күбесенчә күз күреме белән кабул итә торган кешеләр.

Кинестетиклар- мәгълүматның күп өлешен башка тойгылар – тоемлау, хәрәкәтләр,сизү аша үзләштерәләр.

Дигиталлар- мәгълүматны, күбесенчә, логик фикерләү, тамгалар, саннар, логик дәлилләр аша кабул итүче кешеләр.

Укытучы дәрескә әзерләнгән очракта сыйныфта үзләштерү ягыннан шушындый төр укучылар барлыгын истә тотарга тиеш. Мин дәресләрдә химик тәҗрибәләр ярдәмендә укучыларны күрү, ишетү, сизү, тоемлау сәләтләрен үстерүне максат итеп куям. Дәреснең бу этабында укучылар төркемнәргә бүленәләр: визуаллар, аудиаллар, кинестетиклар, дигиталлар.

Химик тәҗрибәләр үткәрү сәбәпле, куркынычсызлык кагыйдәләрен искә төшереп китү зарури.

Кинестетиклар-тәҗрибә үткәрү өчен кирәк булган матдәләр белән таныштыралар һәм тәҗрибә үткәрәләр. Визуаллар тәҗрибә турында аңлатма бирәләр, үзгәрешләрне билгелиләр. Аудиаллар тәҗрибәнең химик реакцияләрен язалар. Дигиталлар шушы тәҗрибә турында реклама рәвешендәме, шигырь форматындамы, тормышта кулланылу дәрәҗәсендәме сөйлиләр.

Тәҗрибә үрнәкләрен китерик: беренчесе: кинестетиклар тәкъдим ителгән матдәләрне (тимер(III)хлориды эремәсе, калий роданиды эремәсе)бергә кушалар. Визуаллар реакциянең барышына аңлатма бирәләр һәм реакциядә килеп чыккан матдәнең кан кебек кызыл төскә үзгәрүен күзәтәләр.

Аудиаллар тигезләмә язалар: $FeCI_3+3KCNS \rightarrow Fe(CNS)_3+3KCI$

Дигиталлар фикерләрен реклама рәвешендә тәкъдим итәләр: үзгәрүчән, төсе кызгылт –куе, туендырылган була, яңа төс барлыкка килә.

Икенчесе: кинестетиклар тәкъдим ителгән матдәләрне (бакыр (II) сульфаты эремәсе, натрий гидроксиды эремәсе) бергә кушалар.

Визуаллар реакциянең барышына аңлатма бирәләр һәм реакциядә килеп чыккан матдәнең зәңгәр төстәге утырым булуын күзәтәләр.

Аудиаллар тигезләмә язалар: $CuSO_4+2NaOH \rightarrow Cu(OH)_2+Na_2SO$

Дигиталлар фикерләрен реклама рәвешендә тәкъдим итәләр: утырым зәңгәр күк төсендә барлыкка килә, каплый, мөһим эш башкара.

Дәреснең икенче этабында төркемнәрне урыннары белән алмаштырырга мөмкин.

Өченчесе: кинестетиклар тәкъдим ителгән матдәләрне ( натрий карбонаты, хлорид кислотасы эремәсе) бергә кушалар.

Визуаллар реакциянең барышына аңлатма бирәләр һәм реакциядә газ барлыкка килүен күзәтәләр.

Аудиаллар тигезләмә язалар: $Na_2CO_3+2HCl \rightarrow 2NaCl+H_2O+CO_2\uparrow$

Дигиталлар фикерләрен реклама рәвешендә тәкъдим итәләр: газ төссез, чыҗлый, тавыш чыгара, өскә менә.

Дүртенчесе: кинестетиклар тәкъдим ителгән матдәләрне( коры ягулык, магний порошогы) бергә кушалар.

Визуаллар реакциянең барышына аңлатма бирәләр һәм реакциядә якты очкыннар барлыкка килүен күзәтәләр.

Аудиаллар тигезләмә язалар: $2Mg+O_2 \rightarrow 2MgO$

Дигиталлар фикерләрен реклама рәвешендә тәкъдим итәләр: якты төсле очкыннар ялтырый. Монда шигырь дә төзеп була: реакция ахырга хәтле бара, әгәр дә утырым барлыкка килсә, газ аерылып чыкса, төсе үзгәрсә, яисә җылыну бүленеп чыкса. Ягъни сизү, күрү, тоем органнары аша реакцияне билгеләп була.

Нәтиҗә ясап шуны әйтәсем килә: балалар белән эшне төзегәндә ,укучылар дәрес буе информацияне барлык сенсор каналлар буенча кабул итәрлек итеп төзергә кирәк. Дәрес ахырына укучылар күреп кенә калмыйлар, сөйләп тә күрсәтәләр, нәтиҗә дә ясыйлар, анализлыйлар, тормыштан кулланырга, сизгерлеккә өйрәнәләр. Аларга укырга да җиңел һәм кызык булачак, һәм әйләнә-тирәне дә тулы бер бөтен дөнья итеп кабул итәчәкләр.

*Насртдинова Гүзәлия Сәлимҗан кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 16 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең беренче категорияле туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

**Халык традицияләрен киләчәк буынга җиткерү.**

Киләчәк турында кайгыртучы һәр халык үз традицияләрен саклый. Тарихи традицияләрне саклап һәм алдагы буыннарның бай тәҗрибәсеннән файдаланып XXI гасырда халык традицияләрен саклау, үстерү һәм торгызу проблемалары көннән-көн актуальләшә бара. Бу уңайдан этник проблемалар аеруча кискен характер ала. Кеше үзен яңадан ниндидер бербөтеннең бер өлеше итеп тоярга, үз халкының традицион мәдәниятендә психологик ярдәм табарга мөмкинлек бирә торган этник кыйммәтләргә мөрәҗәгать итә. Традицион мәдәният Россия халыкларының күп гасырлык мәдәниятенең тамыр нигезе булып тора, үзенең яшәү сәләтен, халыкның патриотизм формалаштыруга, һәрьяклап үскән, милли юнәлешле кеше тәрбияләүгә юнәлдерелгән рухи кыйммәтләре системасын саклый.

Мәктәпләрдә татар халык традициясе белән танышу өчен зур мөмкинлекләр бар. Мин милли мотивларны һәм сюжетларны дәресләрдә, уен эшчәнлегендә, сыйныфтан тыш чаралар әзерләгәндә кулланам. Безнең мәктәп музеенда татар халкы тормышын чагылдырган этнографик материаллар бар. Без алар белән дәрестә, төрле дәрестән тыш чараларда танышабыз, кулланабыз.

Татар теле һәм әдәбияте дәресләрендә без татар халкының төрле бәйрәмнәре белән бәйләп гореф-гадәтләр, халык уеннары, халык җырларын да өйрәнәбез.

Мин кубрәк башлангыч сыйныфларда эшлим, шуңа күрә тел өйрәнүдә халык уеннары кулланам.

Сүзле уеннар уйнау балаларның сүз байлыгын арттыра, сүзләрне истә калдырырга булыша. Бу уеннар халкыбызның гореф-гадәтләрен үз эченә ала. Мондый уеннар балаларның хәрәкәткә, аралашуга, әдәби сүзгә булган ихтыяҗларын канәгатьләндерә. Хәрәкәтнең сүз белән аралашып баруы балага уенның эчтәлеген аңларга ярдәм итә.Сүзле уеннардан “Әйе, юк димәскә”, “Мин дә” уены. Төсләрне өйрәнгәндә “Буяулы”, ә саннарны өйрәнгәндә “Бер алма, ике алма...” санамышын куллану отышлы.

Халык иҗатында балаларның сүз белән уйнап кызык табуларына корылган бер үзенчәлекле җанры -тел көрмәкләндергечләр. Тел көрмәкләндергечләрнең хикмәте авыр әйтелештә. Аларның бер ишләре охшаш яңгырашлы сүзләрне еш куллану юлы белән ясала. Икенчеләре – сөйләмнең һәр сүзен билгеле бер авазлан башлау юлы белән оештырыла. Тел көрмәкләндергечләр ярдәмендә без авазларны дөрес әйтергә өйрәнәбез.

Мәсәлән:

1. Абагага бага бага башым бәрдем баганага.

2. Өйгә кергән бер чыпчык,

Очып йөри чып-чып. Чыпчык, чыпчык очып чык.

Әдәби уку дәресләрендә укучылар әдәплелек кагыйдәләре белән бик күп очрашалар. Сөйләм, киенү, өстәл янында, кунак, туганннарга карата әдәплек кагыйдәләрен тыңлап кына калмыйлар,ә бәлки үзләре дә бер-берсенең кимчелекле якларын күрсәтеп, шул кимчелекләрне төзәтү өстендә эшләргә тырышалар.

Мин системалы рәвештә укучының сөйләме өстендә эшләү, текстның эчтәлеген сөйләгәндә дөрес итеп фикерли белергә өйрәтү, төрле дидактик уеннар аша сүзлек запасын баету максаты куям. Бала бу яшьтә төрлечә фикерли ала. Шуңа да төрле КВН, ярышлар уздыру балаларның логик фикерләү сәләтен арттыралар. Эш төрләренең яңартылып торуы укучыларның дәрескә кызыксынуларын арттыра. Халык авыз иҗаты үрнәкләре аркылы да укучыларны уйларга өйрәтергә мөмкин. Минем укучыларым дәресләрдә мәкальләр белән бирелгән эшләрне бик теләп башкаралар. "Мин башлыйм, син дәвам ит", "Мәкальнең ахырын тап"," Шигъри мәкальләр" уеннары зирәклек, җитезлек тә сорый. "Әкият геройларын таны", "Бу кайсы әкияттән?" уеннары төрле дәрес элементлары итеп кертелә. Бу эш төрләре укыту процессының максатына, урынына, укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә карап, төрле вакытта, төрле очракта кулланыла.

Шулай ук, бу уку елында 15нче мәктәптә уздырылган “Виражи науки” конкурсында “Традицияләрне саклаучылар”секциясендә катнаштык. Анда алъяпкычны балалар бизәп проект якладылар. Балаларга бу конкурс бик ошады. Алга таба да мондый конкурслар булып торсын иде дигән теләктә калам.

Халык традицияләрен кулланып уздырылган дәресләр, чаралар баланың актив үсешенә өстәмә чыганак итеп кулланыла. Һәр укытучы үзенең педагогик эшчәнлегендә аларны куллануның күпләгән юлын һәм ысулларын таба ала.

Безнең рухи байлыгыбыз, милли традицияләребез исән. Алар безгә бүгенге һәм киләчәк өчен кирәк. Гореф- гадәтләребез, матур йолаларыбыз бөтенләй онытылса, без үзебезнең татарлыгыбызны саклап кала алмыйбыз. Шуңа күрә, безнең бурыч бу традицияләрне киләчәк буынга тапшырырга кирәк, дип уйлыйм.

Кулланылган әдәбият

1.Бәшәр? Р. Татарча сөйләшергә өйрәнәбез. – Чаллы, 1992

2.Галиева, Э.,Ханбиков Я. Татар халык уеннары һәм бәйрәмнәре / Галиева, Э.,Ханбиков Я..- Казан-2006

3.Ганеева Ф.А. Русча-татарча сүзлек.-1991

4.Нәкый Исәнбәт. Балалар фольклоры.-Казан-1984

*Низамеева Ландыш Фәрит кызы,*
*Татарстан Республикасы Казан шәһәре Совет районының «Билингваль төрдәге 178 нче номерлы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениясенең дефектолог укытучысы*

**ИКТны РАС белән авыручы балалар мәгарифендә куллану**

Махсус мәгарифтә торган саен киңрәк кулланыла торган заманча технология булып, информацион-коммуникацияле технологияләр (ИКТ) тора. Махсус мәгарифтә ИКТның уникаль мөмкинлекләреннән файдалану, баланың уртача тайпылышларны булдырмый калу һәм төзәтергә сәләтлелеген максимальләштерергә мөмкинлек бирә. Әлеге технология ярдәмендә укыту шартлары спектрын киңәйтергә һәм традицион уку пособиеләрен өстәргә мөмкин була.

Мәгълүмати-коммуникация технологияләре мәгълүматны җыю, эшкәртү һәм саклау ысулларын, алардан файдалануның катлаулылыгын киметү, шулай ук аның ышанычлылыгын һәм нәтиҗәлелеген арттыру максатын күздә тота.

ИКТны РАС белән авыручы балалар мәгарифендә куллану техник чаралар белән таныш булган студентлар белән әзерлек эшләрен таләп итә. Бу уеннар, виртуаль экскурсияләр, танып белү видеофрагментлары һ. б. булырга мөмкин.

ИКТнын санап үтелгән инструментлары белем бирү процессына, сурәтләрнең чынбарлыклылыгы һәм динамикасы, аниомацияләнгән сурәтләрне куллану ярдәмендә яңалык һәм төрлелекне кертә. Алар сезгә белем бирү һәм үстерү уеннарын һәм сыйныфтан тыш дәресләрне кулланырга мөмкинлек бирә, бу исә балаларның кызыксынуын арттыра. ИКТ технологиясен кулланганда тәкъдим ителгән мәгълүмат психик процессларны (хәтер, игътибар, кабул итү, фикер, сүз һ.б.) үстерүгә ярдәм итә, шулар ярдәмендә белем үзләштерелә.

ИКТның иң киң таралган һәм һәркем файдалана алырлык чараларының берсе булып презентация тора. Практика күрсәткәнчә, презентацияләр куллану дәреснең төрле этаплары өчен методик һәм дидактик ярдәм тәэмин итәргә ярдәм итә; студентлар реакциясен күзәтү өчен, дәрес вакытын оптимальләштерергә мөмкинлек бирә. Шул ук вакытта, югарыда күрсәтелгән максат, әгәр презентация дөрес эшләнгән һәм студентка тәкъдим ителгән булса ирешелә.

РАС белән авыручы балалар өчен презентациянең үзенчәлеге - өйрәтүче (стимуллар) кабатлана торган элементларның булуы. Шуңа күрә презентацияне үз эченә алган мәгълүмати һәм коммуникация технологияләре аутистик спектрның тайпылышлары булган студентлар белән корректлаучы эшне оештырганда уңышлы кулланылырга мөмкин

Дорошева Наталья Васильевна үз эшендә "Балаларны иртә балалар аутизмында укыту процессын оптимальләштерү һәм индивидуализацияләү өчен ИКТ куллану" РАС белән авыручы

балалар укыту процессында компьютер технологияләрен куллану балаларны үстерү, тәрбияләү һәм укытуның нәтиҗәле чараларының берсе булып тора, дип раслый. ИКТ куллану ишетү, күрү, мотор-хәрәкәт һәм сөйләм эшчәнлеге дефектларын киметергә мөмкинлек бирә. Компьютер үз-үзен тормышка ашыруны, аралашуны һәм укытуны җиңеләйтүче чара булып тора.

РАС белән авыручы балалы тәрбияченең шәхси тәҗрибәсе ИКТның белем бирү процессында кулланылырга тиешлеген күрсәтә. Шунысын билгеләп үтәргә кирәк, тәртипкә дәрт һәм балаларны РАС белән компьютерлар белән таныштырырга ярдәм итә. Мондый балалар үз тормышында бары тик алгоритм буенча гына эшчәнлек алып баралар бит.

Хис-кичерешле һәм үз-үзеңне тотышлы бозуларны (үз-үзеңне агрессия һәм агрессия, йомык, иминият) коррекцияләгәндә аутик балаларда уен кушымталарын куллану иң яхшы нәтиҗә бирә. Компьютер уеннарында, балалар, сюжет-рол уеннарындагы кебек үк, кешенең социаль-мәдәни эшчәнлегенең төрле төрләрен модельләштерү бара. Бала олылар эшчәнлегенең төрле төренә охшарга тырыша, шуның барышында балаларда сүз һәм интеллект, кеше мәдәнияте, һөнәри эшчәнлек турында база күзаллаулары формалаша.

«Дорошева Н.В. үз хезмәтләрендә күңел ачу, өйрәтүче, диагностик һәм челтәр уеннарын файдалана. Балаларга бигрәк тә математик белемнәр һәм фонематик ишетү сәләте үсешенә уеннар ошый: «Баба яга укырга өйрәнә», «Сабыйлар өчен математика» һ.б. Автор билгеләп үткәнчә, балалар дәресләрен күзәтеп, ул компьютер белән аралашу аутизм белән интегүче балаларда башта уен буларак, ә аннары уку эшчәнлеге буларак кызыксыну уята. Компьютерларны аутистларга өйрәтү процессында куллану мәгълүматны алар өчен кызыклырак формада бирергә ярдәм итә, бу истә калдыру процессын аз гына тизләтә, әмма бу белемнәрне хәтердә озак вакытка кичектерә.

Мультимедиа уку әсбапларын куллану балаларга аутизм белән уку планының катлаулы элементларын үзләштерергә җиңелрәк ярдәм итә; әйләнә-тирә дөньяда уңышлы җайлашу өчен кирәкле күнекмәләр бирә. Мәгълүмати-коммуникация технологияләре һәр баланың индивидуаль үзенчәлекләрен һәм мөмкинлекләрен исәпкә алырга мөмкинлек бирә (мәсәлән: эшчәнлекнең индивидуаль темпы, белемнәрне, мәнфәгатьләрне үзләштерү ысуллары һ.б.); ресурслар вакытын янга калдырырга; Үсешнең дөрес бозылуы. Компьютер программаларын куллану укытуның нәтиҗәлелеген күтәрүгә, уңай укыту мотивациясен формалаштыруга; интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрне, когнитив сәләтләрне үстерүгә ярдәм итә.

Аутизм белән интегүче балалар белән эшне оештырганда, берничә пунктка аерым игътибар бирергә кирәк: компьютер клавиатурасы экранга якын булырга тиеш. Бу балаларга клавиатураны да, экранны да күрергә мөмкинлек бирә. Кайвакыт аерым төймәле тычкан кулланыла, чөнки хәрәкәт проблемалары булган балаларга бер үк вакытта тычканны

тотып тору һәм кысу бик кыен. Кайбер аутизмы булган балалар укларның экрандагы тычкан ярдәмендә хәрәкәт итүен аңлый алмыйлар.

Әгәр укытучы нәкъ шундый ук укны тычканга ябыштырып куйса, алар моны тиз аңлый алалар. Тамаша кабул итү проблемалары булган балалар, кагыйдә буларак, телевизион мониторларны куллана алмый, чөнки аларның даими җемелдәвен күрәләр. Аларга тирбәнешләре азрак булган яссы экраннарны кулланырга кирәк. Төсле биттә кискен контраст булдырмас өчен кара хәрефләр басылса, балаларны карау җиңелрәк. Н.В. Дорешева билгеләп үткәнчә, төрле төсләр кулланыла: ачык яшел, ачык көрән төстә һ.б. Тәҗрибәдән чыгып, ул күз өчен артык кискен булганга сары төс кулланмый.

Аутизмнан интегүче балаларны укытканда укытучы, шунда ук балаларга әзер үрнәк бирә, бернинди арадаш эшләрсез. Шатлыклы балалар образлар белән фикер йөртәләр, әзлеклелекне начар истә калдыралар, шуңа күрә аларны укыту өчен сүзне һәм предметны чагыштырырга, эзлеклелекне язарга кирәк, ә моның өчен компьютердан файдалану бик уңайлы. Алар өчен экранда бер үк вакытта бастырылган сүз һәм картина күрсәләр, сүзне картина белән чагыштыру күпкә җиңелрәк. Кайберәүләр абстракт рәсемнәрне аңламый, шуңа күрә мин башта реаль объектлар сурәте яки фотосурәтләр белән эшләргә тәкъдим итәм.

Компьютерда дәресләр кулларның ирекле моторикасын үстерүдә зур роль уйный. Балаларда бу диагноз белән еш кына вак моторика белән проблемалар туа. Шуңа күрә матур һәм төгәл почерк еш кына алар өчен баланы депрессиягә китерергә мөмкин булган зур проблема булып тора. Моны булдырмас өчен, бала компьютерда бастыра ала, һәм күңелле язачак. Мондый балалар өчен хатларга өйрәтүдәге кыенлыкларны Microsoft Word ярдәмендә хәл итәргә мөмкин. Монда бала басарга һәм орфографик хаталарны тикшерергә өйрәнә. Хәтта интеллектуаль мөмкинлекләре чикләнгән аутик балалар да клавиатура һәм тычкан кулланырга тиз өйрәнә.

Аутистлар спектры бозылган балалар өчен әйләнә-тирә дөнья турында белемнәрне киңәйтергә ярдәм итүче дәресләр бик мөһим. Монда, һәркайда кебек үк, аларга формаль белемнәр түгел, ә аларның компьютер мөмкинлек бирә торган чын тормыш белән элемтәсе кирәк. Тәрбияче билгеләп үткәнчә, бу балага башка балалар алдында яхшы репутация тудырырга ярдәм итә. Гадәттә бу шактый сәер, бу начар тәэсир ясарга мөмкин. "Дәресләрдә мин аның көчле якларына игътибар итәргә тырышам: җитди белемнәр, билгеле бер өлкәләрдә талант; аңа булган мәхәббәтегезне ассызыклагыз, баланы аның катнашуы һәм игътибары өчен, өстәмә уңай аралашу өчен алшартлар тудыручы нәтиҗәләргә бәйсез рәвештә, мактагыз", - дип билгеләп үтә укытучы.

Компьютер һәм традицион алымнарның ярашуы нәтиҗәсендә коррекцион белем бирүнең максималь нәтиҗәлелеге дә ирешелә. Уку-коррекция эше нигездә балаларның эмоциональ контактын һәм балаларның өлкәннәр һәм әйләнә-тирә мохит белән үзара хезмәттәшлеген

үстерүгә, эмоциональ үсешкә, эчке җайлашу механизмнарын формалаштыруга юнәлтелергә тиеш, бу исә үз чиратында аутик баланың гомуми социаль адаптациясен арттыра.

*Набиуллина Резеда Хайдар кызы,*
*Садыкова Лидия Хамдегали кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «А.А.Шаповалов исемендәге 31нче лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

**Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә, дәрестән тыш эшчәнлектә патриотик тәрбия бирү**

Халык элек - электән үк кешеләрдә (бигрәк тә яшь буында) туган җиргә, Ватанга мәхәббәт һәм бирелгәнлек, ата - анага, өлкәннәргә хөрмәт- итагать , хезмәт сөю, һөнәргә, белемгә омтылу, батырлык, гаделлек, сабырлык, тыйнаклык, юмартлык, пөхтәлек кебек күркәм сыйфатлар тәрбияләп килгән.

Укучыларга патриотик - әхлак тәрбиясе бирүдә татар теле һәм әдәбияты укытучылары тарафыннан зур эш алып барыла. Мин дә үземнең педагогик эшчәнлегемдә дәресләрдә һәм дәресләрдән тыш чараларда укучыларны патриотик рухта тәрбияләргә тырышам. Укучыларда милли горурлык, патриотлык хисләре тәрбияләү максатын куям. Кайсы язучыны, аның кайсы гына әсәрен алсаң да, патриотик рух ярылып ята - туган җирне, туган халкыңны, туган иленне, әти- әниеңне ярату, хөрмәт итү һ.б. Ватанпәрвәрлек тәрбияләү - сугыш һәм хезмәт геройлары, талантлы язучылар, дәүләт эшлеклеләре һ.б. мисалында алып барам. Туган як тарихын, аның кешеләре язмышын өйрәнү максатыннан 9нчы сыйныфларның шәхси проектларын яклау мохтаҗлыгы тугач, туган телдән проект алырга теләгән укучыларга, бигрәк тә үзен күрсәтергә яратучыларга, туган шәһәребезнең тарихын, аның күренекле шәхесләре турында эзләнү эшен алып барырга тәкъдим ителде. Әлеге укучылар туган шәһәребезнең тарихы, шушы җирлектән чыккан күренекле шәхесләребезнең тормыш юлы, иҗаты белән танышып, бик күп кызыклы мәгълумат туплап системага салганнар. Аларның бу теманы яратып сөйләүләреннән, мин бит бу турыда белми идем, дия-дия үз фикерләрен дәлилләүләре, мин 9дан соң шәһәрдән китәм дип уйлаган идем, хәзер кире уйладым, яшь шәһәребезнең дә бай тарихы, теләгән кешеләргә бар мөмкинлекләре дә бар икән бит, дип сүзләрен йөомгаклаучылар да булды...

Укчылар шулай ук үзләре укыган мәктәпнең тарихын белергә, мәктәп, аның укытучыларына карата горурлану, хөрмәт хисләре тәрбияләү дә безнең бурыч. Мәктәбебезнең 30 еллык юбилее, аның статусы үзгәрүе уңаеннан укучылар мәктәп

тарихы буенча эзләнү эшләре алып бардылар. Бу эш тә аларның лицеебыз турындагы фикерләрен уңай якка үзгәртүгә бер этәргеч булды.

Бөек Ватан сугышы тәмамлануга 80 елга якын вакыт узса да, сугыш хатирәләре, туган җиребезне, туган илебезне илбасарлардан саклап калган, аның иминлеге өчен гомерләрен дә кызганмаган каһарманнар һичкайчан онытылмый. Укучыларны кечкенәдән аларның батырлыклары белән таныштырабыз. Музейларга экскурсияләр оештырыла. Укучылар үзләренең гаилә архивларын өйрәнәләр, әби-бабаларының Бөек Ватан сугышы чорындагы тормышы турында эзләнү эшләре алып баралар һәм сыйныфташлары алдында чыгыш ясыйлар. Укучылар үз гаиләләрендә олылардан ишеткәнне йөрәкләре аша кичереп сөйлиләр. Бу проект алымы укучыларда патриотик хисләр генә түгел, ә гаилә әгъзаларын гына түгел, тулы бер ыру вәкилләрен бер-берсенә якынайта. Чөнки мондый зур темаларны өйрәнгәндә әти-әни белән генә тугел, ә барлык нәсел-нәсәп җепләрен барларга туры килә. Мәсәлән, Инзилә исемле укучыбыз үзенең туганнан туганы - Советлар Союзы герое - Зәки Шәймәрданов турында горурланып сөйли. Үзе әйтмешли, проект уңышлы булсын өчен аңа барлык туганнарын аякка бастырырга кирәк була.

“**Илен белмәгән - игелексез,**

**халкын белмәгән холыксыз,**

**нәселен белмәгән-населсез”** дигән гыйбарәгә таянып “Туган як” музее материалларын тулыландыру максатыннан укучылар арасында “Үз нәселеңне беләсеме?” дигән эзләнү-тикшеренү эшләре даими алып барыла. Шушы темага сыйныф сәгатьләре, әңгәмәләр үткәрелә. Мәсәлән, Газизова Диананың, Бәдретдинова Айзиләнең гаилә шәҗәрәләре зур игътибарга лаек.

Балаларга Бөек Ватан сугышы чорының дәһшәтле вакыйгаларын хисси якын кичерергә булышу; Туган ил тарихының һәрберебезгә, шул исәптән үзләре яшәгән гаиләгә дә, кагылышлы булуын тирән аңлату, төшендерү дә безнең бурыч дип саныйм. Бу темага мәктәбебездә “Өлкәннәр көне” уңаеннан да, Җиңү көне уңаеннан да булган очрашуларда тыл батырларыбыз - тырыш та, эшлекле дә, һәр яктан җитез дә булган әбиләребез, апаларыбыз шул чор тормышы авырлыклары, михнәтләре турында таныштыралар. Балаларга хәзерге тормыш кадерен белергә, якты, җылы мәктәпләрдә тырышып белем алып илебез киләчәгенә кирәкле кешеләр булып үсүләрен телиләр. Сугышның үзе, михнәтләре, газаплары турында да музеебызда тупланган материалларга нигезләнеп күз алдына китерергә мөмкин. Әфган, Чечня, Украинада барган хәрби операция корбаннарының батырлыклары турында сөйләүче язмалар, фотолары балаларны уйлануга этәрә. Ә инде сугыштан исән-имин йөреп кайткан бик аз санда калган

ветераннарыбыз, тыл ветераннары белән очрашулар, өйләрендә булып хәлләрен белешүләр вакытында да, һәйкәл янында батырларны искә алып, батырлыкларына, безгә шушы матур тормышны яулап алуда үзләрен корбан итүләренә рәхмәт белдереп чәчәкләр куйганда да укучылар күңеленә горурлык орлыклары салына дип уйлыйбыз, шуңа ышанып эш йөртәбез.

Укучыларны патриотик рухта тәрбияләүдә санап кителгән чаралар педагогик эшчәнлекнең бер өлеше генә.

Әйе, хәзерге шартларда туган илгә мәхәббәт тәрбияләү җиңел эш түгел. Бүгенге чорның катлаулы, авыр мизгелләре кешеләрнең байтагын өметсезлеккә этәрде һәм ул, пессмизм булып, үсеп килүче буынга күчте. Ватанпәрвәрлек ул барлык гражданнар да, кемнең-кем булуына карамыйча, илгә файда китерү өчен тырышып эшләгән җәмгыятьтә генә була ала. Ватанпәрвәрнең хезмәте илгә бәла китермәскә тиеш; ул бүгенге уңыш, отыш белән яшәмичә, киләчәге турында кайгыртырга бурычлы. Балалар күңелендә өмет, киләчәкнең матур булуына ышаныч уяту - укытучының төп вазифасының берсе.

*Сагитдинова Рәсимә Наиль кызы,*
*Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Байкиев К.С. улы исемендәге Икшермә кадет интернат-мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем учреждениесенең югары категорияле инглиз теле укытучысы*

**Инглиз теле дәресләрендә милли гореф-гадәтләр һәм йолалар аша патриотик тәрбия бирү.**

Хәерле көн, хөрмәтле коллегалар, жюри әгъзалары.

Мин, Сагитдинова Рәсимә Наил кызы Байкиев Кави Сәлим улы исемендәге Икшермә кадет интернат-мәктәбенең югары квалификацияле инглиз теле укытучысы.

Ризаэтддин Фәхреддин :"Укытучы гыйлем өйрәтүче, дәрес укытучы һәм балаларның җаннарын тәрбияләүче дип атала,"-дигән. Безнең мәктәптә Рәсәйнең, Татарстанның торле төбәкләреннән килгән балалар укый. Килгән укучыларның күбесе татар теле, татар милләте аның гореф гадәтләре белән безнең мәктәпкә килгәч кенә таныша башлыйлар. Һәр фән иясе алдында патриотик тәрбия, милли-гореф гадәтләрне үстерү максаты югары катлаулы баскычка менә.

Безнең киләчәк, халыкның алдагы язмышы яшьләрнең бүгенге тәрбиясе белән бәйләнгән. Мине борчыган мәсьәләләрнең берсе- татар баласының ана теленә мөнәсәбәте.Урамда еш кына ана телен белмәгән татар балаларының сөйләмен ишетергә

туры килә. Я туган телләрен бөтенләй белмиләр, я бозып сөйләшәләр. Балаларга ана телен өйрәтүдә төп бурычларның берсе – халкыбызның әдәби байлыгына, фольклор мирасына, аның гореф гадәтләренә таяну. Үз телен яратучы, милләтен хөрмәтләүче кешене тәрбияләүне халык педагогикасына таянып эш итү зарур. Шуңа күрә һәр дәресемдә Татарстан, татар теле турында нинди дә булса мәгълүмат бирәм.

Инглиз фәнең укыту максатларына килгәндә патриотик тәрбия мөһим урын алып тора.

патриотик тәрбия:

күпмәдәни һәм күпконфессиональ җәмгыятьтә Россия гражданлык үзенчәлеген аңлау, туган телне, Россия Федерациясенең тарихын, мәдәниятен, туган ягыңны, Россия халыкларын танып белү белән кызыксыну;

үз Ватаныңның – Россиянең казанышларына, фәнгә, сәнгатькә, спортка, технологияләргә, сугышчан батырлыкларга һәм халыкның хезмәт казанышларына кыйммәтле мөнәсәбәт; Россия символларына, дәүләт бәйрәмнәренә, тарихи һәм табигый мираска һәм һәйкәлләргә, туган илдә яшәүче төрле халыкларның гореф-гадәтләренә хөрмәт.

Социомәдәни белем һәм күнекмәләр:

Өйрәнелә торган телнең туган иле һәм Иле (илләренең) социомәдәни портретын белү: төп милли бәйрәмнәрне (Раштуа, Яңа ел, Әниләр көне, Рәхмәт көне һәм башка бәйрәмнәрне) үткәрү традицияләре, өйрәнелә торган телнең яшәү рәвеше һәм мәдәнияте үзенчәлекләре (танылган истәлекле урыннар; кайбер күренекле кешеләр), инглиз телендә яшүсмерләр өчен тел ягыннан аңлаешлы шигърият һәм проза үрнәкләре белән танышу.

Инглиз теле фәне эчтәлеге һәр сыйныфта шушы темалардан тора:

Сөйләмнең предмет эчтәлеге:

1. Гаиләдә, яшьтәшләр белән үзара мөнәсәбәтләр; конфликтлы ситуацияләрне хәл итү. Кешенең тышкы кыяфәте һәм характер сыйфатлары. 2. Ял һәм мавыгулар (уку, кино, театр, музейлар, музыка, дискотека, кафе). Ял итү, сәяхәт итү төрләре. Яшьләр модасы. Сатып алулар. Кесә акчасы.

3. Сәламәт яшәү рәвеше: хезмәт һәм ял режимы, спорт, баланслы туклану, зарарлы гадәтләрдән баш тарту.

4. Мәктәп белеме, мәктәп тормышы, өйрәнелә торган фәннәр һәм аларга мөнәсәбәт. Халыкара мәктәп алмашулары. Чит ил яшьтәшләре белән язышу. Елның төрле вакытында каникуллар.

5. Һөнәр дөньясы. Һөнәр сайлау проблемалары. Киләчәккә планнарда чит телнең роле.

6. Галәм һәм кеше. Табигать: флора һәм фауна. Экология проблемалары. Әйләнә-тирә мохитне саклау. Климат, һава торышы. Шәһәр/авыл җирлегендә яшәү шартлары. Транспорт.

7. Массакүләм мәгълүмат һәм коммуникация чаралары (матбугат, телевидение, радио, Интернет).

8. Өйрәнелә торган телнең иле/илләре һәм туган иле, аларның географик урыны, башкалалары һәм эре шәһәрләре, төбәкләре, истәлекле урыннары, мәдәни үзенчәлекләре (милли бәйрәмнәре, истәлекле даталары, традицияләре, гореф-гадәтләре), тарих битләре, күренекле кешеләр, аларның фәнгә һәм дөнья мәдәниятенә керткән өлеше.

Инглиз теле дәресләрендә кайсы теманы гына алма – патриотик тәрбия, рус, татар һәм башка милләтләрнең тарихы, милли гореф-гадәтләре турында сөйләшеп була. Халкыбыз иҗат иткән табышмаклар, экиятләр, җырлар – тел өйрәнүдә иң бай чыганак.

Лучше поздно, чем никогда. – Соң булса да уң булсын. - Better late than never

*Everything is good in its season.* - Всему свое время.- Һәрнәрсәнең үз вакыты.

Халык бәйрәмнәре ул халыкны милләт итеп берләштерә торган чараларның берсе. Һәр милләтнең үзенә генә хас бәйрәмнәре бар. Celebrations.Holidays.Праздники. Бәйрәмнәр темасын үткәндә укучылар үз милләт бәйрәмнәре турында инглиз телендә бирелгән план буенча проектлар эшлиләр. Чит ил бәйрәмнәрен үткәндә үзебезнең бәйрәмнәр белән чагыштыру үткәрәбез. Мәсьәлән, 6нчы класста Шотландиядә үтә торган милли бәйрәм **Игры горцев** (англ. Highland games) турында текст укыганда укучылар белә аркан тарту - **Перетягивание каната** (tug of war) икәнен әйтеп китәбез. Бу бәйрәмгә милли киемдә киләләр, милли биюләр башкарыла. Сыйныфтагы бар укучылар диярлек безнең Сабантуйлар да шулай үтә диләр. Бу бәйрәмнәрне халыкның олысы-кечесе бергәләп уздыра. Яшьләр бәйрәмнәрнең тәртибен, йоласын кечкендән үк белеп, күреп, өйрәнеп үсәргә тиеш. Балаларга кечкнәдән үк әдәплелек, инсафлык, мәрхәмәтлелек тәрбияләүдә әти-әниләр, тәрбиячеләр, укытучылар зур эш алып барырга тиеш.

My country –Укучылар үз туган авылы, туган ягы, туган иле турында сөйлиләр. Әлбәттә алар барсында инглиз телендә сөйләп чыга алмыйлар, бу эшнең максаты – авыл исемнәрен инглиз телендә язу.

My family - Баланың рухи сәламәтлеге гаиләгә бәйле. Әхлак тәрбиясе, әдәплелекнең (өстәл әдәбе, киенү әдәбе, зиһен үсеше, ата- анага хөрмәт һ.б.) беренче дәресләрен бала гаиләдә ала, ә мәктәптә рухи байлык тулыландырыла, шулай итеп, тәрбиядән тәрбия ярала. “Минем гаилә” темасын үткәндә укучылар үз гаиләләре турында төрле проектлар эшләп киләләр.

Animals. Хайваннар – проект итеп Татарстанда Кызыл китапка кергән хайваннар турында эш кушам.

Табигать: флора һәм фауна – Чәчәкләргә заказ бирү темасын үткәндә без укучылар белән тюльпан – лалә чәчәге турында сөйләшәбез. Чәчәкнең әһәмиятен әйтеп китәм.

Famous people – бу тема үзебезнен күренекле шәхесләр белән таныштыру, алар белән горурлану хисен үстерүдә иң зур өлеш кертүче тема.

Г. Тукай – аның шигырьләре, әкиятләре.

М. Җәлил – патриотизм, шигырьләре “Кызыл ромашка”.

М. Ш. Шәймиев, Р. Н. Миниханов һәм бик күп күренекле шәхесләр турында укучылар инглиз телендә проект эшләп, дәрестә чыгыш ясыйлар.

Sightseeing. Landmarks. Достопримечательности. Истәлекле урыннар.– Сюембикә манарасы, Казан Кремле, Кол Шәриф мәчете, якын-тирәдәге истәлекле урыннар турында укучылар бер-берсен таныштыралар.

Нәтиҗәдә, кайсы теманы гына алсакта, инглиз теле дәресләрендә милли-гореф гадәтләр белән танышу аша балаларның тапкырлыгы арта, фольклор буенча гыйлемнәре үсә. Балаларга үз-үзен тота белү, аралаша белү күнекмәләрен балалар бакчасында һәм гаиләдә өйрәтергә кирәк. Әгәр дә без балаларны шушы тәртиптә тәрбияләсәк, шул чагында гына милләт, халык өчен тәрбияле балалар үстерербез **.**

Киләчәк буынның язмышы безнең куллар аша үтә һәм без балаларга дөрес әхлакый, патриотик тәрбия бирү турында кабат-кабат уйланырга, вакытында кулай, файдалы, заманга ярашлы ысулларын табып яңартырга тиешбез.

*Садыкова Сирина Илсур кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге «1 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Татар әдәбияты дәресләрендә укучыларда патриотизм тәрбияләү**
**(Гариф Гобәй әсәрләрен өйрәнү мисалында)**

Патриотизм (Ватан өчен горурлык, шәфкатьлелек, гомумкешелек кыйммәтләре, туган илгә мәхәббәт) – җәмгыять һәм дәүләт тормышының барлык өлкәләренә хас иң мөһим, мәңгелек кыйммәтләрнең берсе. Ул шәхеснең иң мөһим рухи байлыгы булып тора. Ә рухи кыйммәтләр, беренче чиратта, балаларга әдәбият фәне аша җиткерелә.

Бөек Ватан сугышы чорында балалар язмышы күләмле әсәрләрдән, Г. Кутуйның “Рөстәм маҗаралары”, М. Мәһдиевнең “Без – кырык беренче ел балалары”, А. Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар”, “Дүртәү”, В. Нуруллинның “Шинельсез солдатлар”, Г. Гобәйнең “Маратның язмышы”, “Замана балалары”, Г. Бакировның “Партизан малай”, З.

Зәйнуллинның “Сугыш алды малайлары”, А. Әхмәтнең “Солдат хикәяләре” һ.б. сәнгатьчә чагылыш тапты. Әлеге әсәрләрдә балаларның җиңү өчен көрәштә үзләреннән зур өлеш кертүләре турында сүз бара. Алар фронтка ярдәм итү йөзеннән бихисап эшләр башкаралар: күтәрәмгә калган атларны тәрбиягә алалар, урман кисүдә катнашалар, чәчү вакытында орлык сатып алу өчен, концерт куеп акча эшлиләр, ашлыкны аркаларында күтәреп, озын юллар узалар һәм, ниһаять, тырышып укыйлар, фронтовик гаиләләренә ярдәм итәләр һ.б. Бу эшләрнең барысы да Ватанга карата булган тирән мәхәббәт, олы хөрмәт, ил алдында үзеңне җаваплы тою хисе белән башкарыла.

Федераль дәүләт белем стандартларына бәйле рәвештә патриотик тәрбия бирү мәсьәләсе төрле сыйныф программаларында чагылыш тапкан. Әдәбият программаларында М. Җәлилнең «Ана бәйрәме», «Моабит дәфтәре», М. Мәһдиевнең «Без – кырык беренче ел балалары», Г. Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр», Фатих Кәримнең «Сибәли дә сибәли», «Ант», «Ватаным өчен», «Теләк», «Сөйләр сүзләр бик күп алар», «Бездә яздыр», «Газиз әнкәй» шигырьләре, Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» әсәре, «Сагыну» нәсере урын алган.

Татар совет балалар язучысы, редакцияләрдә һәм радиода эшләгән журналист, күренекле әдип, тәрҗемәче Гариф Гобәйнең «Маякчы кызы» һәм «Маратның язмышы» әсәрләре нәкъ менә патриотик рухта язылган. Мәрдан, Илсөяр, Бикмүш карт, Марат, Гөлсем образлары үрнәгендә автор үз иленең чын ул-кызларын, патриотларын уңышлы сурәтли.

Равил Рахмани билгеләгәнчә, Гариф Гобәйнең бу әсәрләрендә без ике төп башлангыч – тарихи реаль вакыйгалар һәм революцион көрәш пафосының балалар күңелендә чагылыш тапкан героик романтикасы белән очрашабыз. Аның бөтен повестьлары да шул ике башлангычның синтезы булып тора. Бу яктан Г. Гобәй әсәрләре күпмедер дәрәҗәдә рус совет балалар әдәбияты классигы Аркадий Гайдар иҗатын хәтерләтә, ди Р. Рахмани.

“Маякчы кызы” – Г. Гобәйнең авторга популярлык китергән зур күләмле әсәрләренең берсе. Әсәр 1938 елда языла һәм гражданнар сугышы чоры вакыйгаларын чагылдыра. 1951 елда әсәрнең русчага тәрҗемәсе – “Дочь бакенщика” басылып чыга. Гомуми белем бирү оешмаларында программа нигезендә бу әсәр татар төркемнәрендә 6 сыйныфта өйрәнелә.

“Маякчы кызы” әсәрен өйрәнүгә кереш дәресендә укытучы түбәндәге максатларны куя: язучының эшчәнлеге белән таныштыру, сәнгатьле уку күнекмәләрен бирү, укучының танып белү сәләтен, мөстәкыйль фикерләвен, сөйләм телен һәм язу культурасын үстерү, эстетик тәрбия бирү, әхлак тәрбиясе бирү. Җиһаз буларак Г. Гобәй портреты, әсәрләре, тормыш юлы, иҗаты белән бәйле рәсемнәр, гражданнар сугышы геройларына багышланган күргәзмә (“Кызыл чәчәкләр” әсәрендәге биш дус малайга карата альбомнар, хатлар), “Гражданнар сугышы” китабы, карта, иллюстрацияләрне куллану максатка ярашлы.

Дәресне традицион калыпта актуальләштерү, яңа теманы үзләштерүгә ихтыяҗ тудыру, танып-белү эшчәнлеге, ял минуты, уку мәсьәләсен чишү, белем һәм күнекмәләрне тикшерү, рефлексия этапларына нигезләнеп төзү урынлы.

Яңа теманы үзләштерүгә әзерлек этабында тарих укытучысы Гражданнар сугышы турында чыгышын тыңлау уңышлы булыр дип саныйбыз. Алга таба исә әдәбият укытучысы бик күп язучылар үзләренең әсәрләрендә чагылдыруын, шул исәптән Гариф Гобәй дә бу темага мөрәҗәгать итүен искәртә. Алдан әзерләнгән укучы Гариф Гобәйнең тормышы һәм иҗаты турында сөйли, презентация күрсәтә.

Предметара бәйләнешләргә нигезләнеп, укучыларның рус әдәбиятыннан үткән әсәрләрен искә төшерү дә урынлы:

– Укучылар, сез илебез тарихында тирән эз калдырган гражданнар сугышын чагылдырган тагын нинди әдәби әсәрләр беләсез?

Укучылар рус әдәбиятыннан А.Фадеевның “Разгром”, Д. Фурмановның “Чапаев” әсәрләрен атыйлар, татар әдәбиятыннан И. Гази “Онытылмас еллар” трилогиясе, Г. Бәширов “Сиваш” повесте, Ш. Усманов “Памирдан радио” әсәрләрен искә төшерәләр.

Укучыларның татар әдәбиятын тирән аңлавы өчен, җитди шартларның берсе – әдәбиятны яхшы үзләштерүдән тыш, укучыларны образлы күзалларга, образлы яки сәнгати фикерләргә өйрәтү, ә бу исә эстетик тәрбия бирүнең бер компоненты. Моңа нигездә туган әдәбият, милли мәдәният, милли традицияләр, гореф-гадәтләр йогынтысында ирешелә. Бу өлкәдә әдәбиятны сәнгатьнең башка төрләре белән чагыштырып өйрәнү максатка аеруча ярашлы. Бу нисбәттән Гражданнар сугышы турында кинолардан өзекләр күрсәтергә мөмкин. Мәсәлән, “Чапаев”, “Тын Дон” фильмнарын карау укучыларда патриотик хисләр формалаштыруга этәрә. “Дан приказ ему на запад”, Мансур Мозаффаров иҗат иткән “Мулланур Вахитов истәлегенә поэма” композициясен аудиоязмада тыңлау да үзен аклый.

Дәрескә тарих укытучысын чакыру да максатка ярашлы булачак. Аның Гражданнар сугышы чоры турындагы чыгышы укучыларда шул чорны реаль күз алдына китерергә мөмкинлек бирәчәк.

Уку мәсьәләсен чишү этабында укучылар әсәрне сәнгатьле итеп укыйлар. Тыңланылган, укылган бүлек буенча фикер алышалар. Бүлектә төп геройлар, вакыйгаларның кайда һәм кайчан баруы, сурәтләнгән табигать, илдәге тормышның баштагы һәм хәзерге хәле, төп герой Илсөяргә хас сыйфатлар, аның туганнарына мөнәсәбәте хакында сөйләшәләр. Безнең фикеребезчә, Илсөяр образына аерым тукталырга кирәк. Илсөяр образына сурәтләмә бирүне әңгәмә бирү рәвешендә оештырырга мөмкин.

Бөек Ватан сугышы чоры күпчелек язучылар иҗатында сугыш нәтиҗәсендә яшьли балалыктан мәхрүм ителгән, газап чиккән герой дошманнарга карата нәфрәт, үч уяту

юнәлешендә уңышлы файдаланыла. Шундый әсәрләрнең берсе – Г. Гобәйнең “Маратның язмышы” повесте. Бу әсәрен Г. Гобәй 1956 елда төгәлли. Русчага тәрҗемәсе – “Судьба Марата” 1963 елда басылып чыга. Дәһшәтле чор балалары образларын ачкан мондый әсәрләрдә төп үзәк ул – балалык һәм сугышның капма-каршы көч булуын, аларның бергә була алмавын, идеология бәрелешендә яшь буынның корбан икәнен ассызыклау.

Г. Гобәй нинди генә хәлдә дә “совет кешесе”нең бәхетле булырга хакы булу, матур киләчәк идеясен романтик рухта сурәтли. Авырлыкларны кичеп чыгарга сәләтле бәхетле бала образын бирә. Бу әсәрне өйрәнүне без проект методы кулланып өйрәнергә тәкъдим итәбез.

Г. Гобәйнең “Маратның язмышы” әсәрен өйрәнгәндә, укучыларга түбәндәге проект темалары тәкъдим итәргә мөмкин:

1. Патриотизмны мин ничек аңлыйм.

2. Г. Гобәйнең “Маратның язмышы” әсәрендә татар халкының батырлыгы.

3. Гөлсем образы турында тәэсирләрем.

4. Гөлсем Маратны тәрбиягә алмаса, Маратның язмышы ничек булыр иде?

5. Әсәрдә бала тәрбияләү мәсьәләсе.

6. Бөек Ватан сугышында катнашкан туганым.

7. Г. Гобәйнең “Маратның язмышы” әсәрендә ил язмышы.

8. Маратны мин ничек күз алдына китерәм?

9. Г. Гобәйнең “Маратның язмышы” әсәрендә символлар.

10. Г. Гобәйнең “Маратның язмышы” әсәрендә табигать тасвиры.

11. Г. Гобәйнең “Маратның язмышы” әсәрендә метафоралар.

12. Г. Гобәйнең “Маратның язмышы” әсәрендә автор образы.

Мәктәптә татар әдәбияты дәресләрендә бу әсәрләрне өйрәнеп, патриотизм формалаштыруда предматара бәйләнешләрне кулланырга мөмкин: сугыш турында видеосюжет я фильмнардан өзекләр карау, сугыш турында җыр тыңлау, күренекле рәссамнарның шул тематикага караган рәсем-иллюстрацияләрен карау максатка ярашлы. Шул ук вакытта дәрескә тарих укытучысын чакырып, аның чыгышын тыңлау яисә фронт я тыл ветераны фикерләрен тыңлау да укучыларда патриотик хисләр формалаштыруга этәрәчәк.

*Сахабиева Люция Заһит кызы,*
*Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Олы Мишә урта гомуми белем бирү мәктәбенең беренче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

***Сәлам юллыйм сезгә, күпмилләтле халкым!***

Татарстанда төрле милләтләрнең дус-тату булып яшәүләрен бер вазада үсүче төрле матур чәчәкләр белән чагышырып булыр иде, алар барысы бергә-күркәм һәм бербөтен.

Бездә яшәүче милләтләрнең барысына да хас гамәл –ул тормыш–көнкүрештә билгеле бер йолалар үтәү, гореф-гадәтләрне тоту һәм бәйрәмнәр үткәрү. Алар һәр милләт мәдәниятенең мөһим бер өлеше булып исәпләнә. Билгеле бер йолаларның үтәлеп килүе җәмгыятьне дә тотрыклы итә, алардан башка халык тулы кыйммәтле тормыш белән яши алмый.

Татарстанда яшәүче һәр милләт, үзенең күршесенең хәлен белү белән беррәттән, аның гореф-гадәтләрен хөрмәт итәргә, белергә һәм үтәчәк бәйрәмнәре белән котлап, күңелләрен дә күрергә тиеш. Элекке вакытларны искә төшереп, аларга бәйрәм открыткалары һәм хатлар юлласа, тагы да күңеллерәк булачак һәм туганлык җепләре артачак, ныгаячак. Проект эшенең актуальлеге һәм яңалыгы да шунда.

**Проектның максаты:**

1. Укучылар белән берлектә туган төбәгебездә яшәүче төрле милләт вәкилләренең милли гореф- гадәтләрен, бәйрәмнәрен өйрәнү.

2. Онытыла барган дуслык хатлары язышу, бәйрәмнәр белән котлау открыткалары җибәрүне кире кайтару өстендә эшләү.

3. Татарстанда яшәүче күпмилләтле халкыбыз көче - аның бөтенлелегендә икәнлеген киң җәмәгатьчелеккә күрсәтү(таныту).

**Проектның бурычлары :**

- тәрбия традицияләренә нигезләнеп халкыбызның гореф- гадәтләрен, бәйрәмнәрен белү, алар белән кызыксынуларын үстереп башкаларга эстетик һәм әхлакый тәрбия бирү.
- татар халкының милли бәйрәмнәре, йола уеннары, гореф- гадәтләре аша
- башкаларның аралашу, коммуникатив осталыгын, сөйләм телен үстерү.
- Хатлар, открыткалар ярдәмендә халкыбызны берләштерү.

**Проектың методлары:**

- - открыткалар ясау;
- - танышу;
- - хат аша әңгәмә;
- -очрашулар;

**Проектның төре:** мәгълүмати юнәлештә, иҗади-эзләнүле.

**Гамәлгә ашырылу вакыты:** озак вакытлы, 2024-2025 нче уку елларын сыйдырган вакыт аралыгында үтүче проект.

**Проект эшчәнлегенең тәэмин ителүе:**

- -Татарстандагы халыкларның милли бәйрәмнәре турында материал туплау.

- \- Проектта куллану өчен кирәкле адресларны һәм милләтләрнең яшәү урынын билгеләү.

**<u>Проекттан көтелгән нәтиҗә:</u>**

- -Татарстанда яшәүче күпмилләтле халыкның электән сакланып килгән бәйрәмнәрен, йолаларын өйрәнү.
- -Хат-открыткалар ясап, күрше милләт вәкилләрен бәйрәмнәре белән котлау һәм дуслык җепләрен ныгыту.

Татарстанда 120 дән артык милләт вәкиленнән этник төркемнәр бар икәнен без инде беләбез. Шул нияттән 2021 ел да Татарстанда туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы буларак уздырылды. Күпмилләтле республикабыз өчен бу – гаять мөһим чара иде. Татарстан халыкларының үзара дус, тату яшәве – бөтендөнья өчен толерантлык үрнәге булып торуын да күрсәтте. Халыклар арасында дуслык бәйләнешләрен ныгытуда бәйрәмнәрнең роле зур, чөнки алар аша халыклар бер-берсенең мәдәниятен, яшәү рәвешен, гореф-гадәте, йолаларын өйрәнде һәм шулар аша бер-берсенә хөрмәт тәрбияли, үз итә, дуслыгын ныгытты.

Бүгенге көндә милли бәйрәмнәребезне, йола, гореф-гадәтләребез яңадан торгызылып, яңартылып, заман төсмерләре биреп үткәрелә башлады. Аларны халык белә, хөрмәт итә икән милләт яши, милләт яшәгәч, тел яши, ягъни тормыш дәвам итә.

Татарстанда яшәүче күпмилләтле халкыбыз белән укучылар белән аралашасыбыз, фикерләр алышасыбыз, элекке гадәтләрне кире халыкка күрсәтәсебез килде. Шул нияттән без аны укучылар белән проект эше итеп башлап та җибәрдек.

Хәзерге интернет заманында бу нәрсәгә инде диярсез! Әмма хатлар- открыткалар язып аралашу җанлы килеп чыга. Күңелеңдәге барлык хисләреңне җиткереп, үз кулларың белән язылган хатларны уку үзе бертөрле рәхәт тә, матур да килеп чыга.

Безнең кебек фикер йөртүчеләр дә бар дип әйтер идек, чөнки Татарстаныбызда Энҗе Садыйкова җитәкләгән “Хатлар йорты” проекты да эшләп килә. Ул үзенең открыткаларын “Печән базары”, “Җәдит фест” фестивальләрендә тәгъдим итте. Хәтта Кремльгә Рөстәм Миннехановка да яхшы кәеф теләп открытка ясап, язып җибәргән. “Инстаграм битләрендә үземнең открытканы күреп, шатландым. Тагы да дәртләнеп эшли башладым”[1],-дип яза ул “Атна вакыйгалары”(Теләче газетасының кушымтасы) газетасының “Җандашларга хат языгыз” мәкаләсендә.

Кибеттә төрле бәйрәмнәр белән язылган открыткалар сатыла, әмма халыкларның милли бәйрәмнәре, йолалары белән котлап язар өчен юк.

Проект эшендә дә шушы юнәлешне үстерергә кирәкле турында аңлатасы килде.

1. “Атна вакыйгалары”(Теләче газетасының кушымтасы) газетасы,- “Җандашларга хат языгыз” мәкаләсе.-№12 (371) ,( 2-8 апрель, 2021 ел).

Иң беренче эш итеп, Татарстанда яшәүче халыкларның милли йола һәм бәйрәмнәрен өйрәнеп чыктык. Аларны елның кайсы вакытында уздырылуы,

бәйрәмнәрнең тарихы кызыклы тоелды. Татар халкының-Сабантуй, рус

халкының-Каравон фестивале, чуаш халкының-Уяв, мордва халкының-Балтай, мари халкының-Семык, керәшен халкының-Питрау, удмурд халкының-Гырон-быдтон бәйрәмнәре төрле төсмер ала .

Интернет челтәреннән алынган мәгълүматларда бу бәйрәм һәм йолалар ничек үтә, шуларны өйрәндек.

***“Питрау үтте-җәй бетте”- керәшен халкы бәйрәме***

Питрау керде,

Җәйнең кыл уртасы,

Их, барасы иде урманга

Их, җыясы иде мәтрүшкәләр,

Җәй үзәге эзләп торганда *(Клара Булатова шигыреннән)*

- җыры бәйрәмнең символы буларак яңгырый.

Питрау ул – табигатьне олылау. Аңа табыну, биргәннәренә шөкерана итү, матурлыкка, табигатьнең иркенлегенә мәдхия җырлау. Шулай ук халыкның алда торган олы һәм җаваплы эшләре – игеннәрне урып-җыю алдыннан ял итеп алу бәйрәме дә.

Бу бәйрәм Татарстанның керәшеннәр яшәгән барлык өлкәләрендә дә үткәрелә. Ул һәр елны 12 июль көнне билгеләп үтелә.

Питрау – ул җәйнең нәкъ кыл уртасы. Бу көнне тереклек һәм үсемлекләр дөньясында үзгәреш чоры башлана, нәкъ көн уртасында кошлар сайраудан туктый. Бу көнне җыеп киптерелгән кыр чәчәкләре, барлык авырулардан

файдалы диләр. Шуңа күрә иртәнге якта басу- кырлардан, урманнардан җыеп кайтылган кыр чәчәкләре белән өй эчен, капка һәм коймаларны бизәгәннәр. Бу гадәт бүген дә сакланган. Бер- берсенә кунакка йөрешкәннәр.

***Рус халыкларының Каравон фестивале***

Хәзерге Татарстан территориясендәге рус авылларында XVI гасырдан үткәрелеп килә. Бәйрәмнең 300 елдан артык тарихы бар. Элгәре православие дине изгесе Николай Чудотворецның престол бәйрәменә (22 май) өстәмә буларак үткәрелгән. Аннары (татар халкындагы Сабантуй кебек үк) язгы кыр эшләре тәмамлануны бәйрәм итү элементлары да өстәлгән. Советлар хакимияте урнашкач, Каравон фольклор бәйрәме буларак уздырылып килсә дә, сугыштан соң диннәрне кысу сәясәтенә бәйле, 1955 елдан

Каравонны да үткәртми башлыйлар. Узган гасырның 90- елларында матур традицияне яңарталар: 1988 елда «Каравон» фольклор ансамбле оеша.

2003 елда Татарстан президенты указы белән бәйрәмгә дәүләт бәйрәме рәсми статусы бирелә.

2011 елдан Бөтенрусия фестивале рәсми статусын ала.

2017 елның 21 маенда XXV Бөтенроссия «Каравон» рус фольклоры фестивале ачылды.

Лаеш районы Рус Никольское авылына Татарстаннан, Удмуртиядән, Мари Элдән, Русиянең башка төбәкләреннән фольклор иҗат төркемнәре (берничә мең кеше) килә. Аларның күпчелеге рус милли киемнәре кия. Фестивальдә катнашучылар бәйрәм кунакларына Идел буе православие дине традицияләренә нигезләнгән этник театральләштерелгән тамашалар, җырлар, биюләр күрсәтәләр. Борынгыдан килгән һөнәрчелек кәсепләре буенча мастер-класслар күрсәтелә. Авылның үзәк урамы ярминкә урамына әверелә. Урамның үзәгендә, Никола чиркәве тирәсендә бәйрәмнең символы булган зур хоровод – каравон оештырыла. Каравонда биючеләр, чәнти бармакларыннан тотынышып, кояш йөреше буенча «үрдәк адымы» белән әйләнәләр, түгәрәкне я зурайталар, я кыса баралар.

***Удмурд халкының Гырон- быдтон бәйрәме***

**Гырон быдтон** – «сабан бетте» дигән мәгънәгә туры килә. Сабантуй кебек, удмуртларның зурлап үткәрә торган бәйрәмнәре. Бәйрәмне үткәрү өчен төгәл билгеләнгән календарь көн юк. Монда бөтенесе елның нинди булуына, карның ничек эрүенә бәйле.

Шушы көндә алар әйбәт уңыш сорап үзләренең Аллаларына мөрәҗәгать итәләр. Бәйрәм болында, табигатьнең чәчәк ату вакытында үткәрелә.

Хуҗабикәләр милли ризык – *куарнянь* пешерәләр, кунакларны милли эчемлек көмешкә (*кумышка*) белән сыйлыйлар.

Бәйрәм башланып китәр алдыннан капкадан атка атланган егет белән кыз керәләр. Алар Кояш белән Яз символлары.

Мәйданда берсеннән-берсе кызыклы уеннар, бәйгеләр гөрли. Сабан туеннан аермалы буларак, әлеге чарада удмурт халкына гына хас ярышлар да урын алган.

- Җирдән йомырка тәгәрәтү, күзне бәйләп йомырка эзләү,
- Яр буенда балык тоту уены.
- Чаңгыда йөгерү.
- «Чеберина-чеберай» – «Удмурт чибәре» бәйгесе. Әлеге бәйгедә кызлар катнаша. Алар үзләре һәм туган яклары белән таныштырырга, милли киемнәрен якларга, милли ризык, иҗади номер тәкъдим итәргә тиеш.

Бу бәйрәм тулысы белән Сабан туена бик якын. Зур аермаларның берсе булып, Гырон- быдтон бәйрәмендә көрәш уздырылмый.

Һәр бәйрәмнең үзенчәлекле ягы бар. Төрле йолалар, бәйрәмнәр булмаса, безнең тормышыбыз күңелсез, нурсыз булыр иде. Гореф – гадәтләр элек – электән, буыннан – буынга күчеп килгәннәр. Кайсы халык вәкиле булсак та, без бу йолаларны сакларга тиешбез. Алар – халыкның көзгесе!

***Чуаш халкының Уяв бәйрәме***

**Уяв** язгы кыр эшләре тәмамланганнан соң башлана, җәйге кызу эш вакыты – печән өсте, уракка төшү алдыннан төгәлләнә; еш кына Питрау көненә туры китерелә. Уяв 3, 5, 7 (так сан булуы мәҗбүри) атна дәвам итә.

Гадәттә көндезге һәм төнге уявлар уздырыла.

Бу вакыт аралыгында җир эшләре башкару, караңгы төсләрдәге һәм чуар тукымадан тегелгән киемнәр кию, кер юу, биналарны җыештыру һәм юу тыела. Шулай ук ут кабызу, самавар кую, кайнар азык ашау рөхсәт ителми. Алдан әзерләгән ризыкны җылытмыйча ашыйлар.

Алар һәр көн иртәдән алып кичкә кадәр күңел ачканнар. Кичләрен елга буйларында учаклар якканннар, шуның тирәсендә берничә катлы әйлән- бәйлән уены уйнаганнар. Бәйрәм җиргә каен казыгын сугып кертү белән башлана, бу изге эш башлануын күрсәтә. Ә аңа кадәр Тәңрегә мул уңыш, гаилә бәхете сорап дога белән мөрәҗәгать итәләр. Уяв мул уңыш сорап гыйбадәт кылудан башлана, корбан чалу белән дәвам итә, чама белән бер атнадан яңгыр сорап гыйбадәт кылу белән төгәлләнә.

Уяв мул уңыш сорап гыйбадәт кылудан башлана, корбан чалу белән дәвам итә, чама белән бер атнадан яңгыр сорап гыйбадәт кылу белән төгәлләнә.

Татарстан Республикасында бәйрәм чуашлар тупланып яшәгән Аксубай, Чүпрәле, Нурлат һ.б. районнарда үткәрелә.

1993 елдан Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Чуаш милли-мәдәни автономиясе ярдәме белән Татарстан Республикасында ел саен (2006 елдан Нурлат районында) республика күләмендә «Уяв» чуаш милли бәйрәме уздырыла.

***Татар халкының Сабантуй бәйрәме***

*Сабантуй – чын-мәгънәсендә милли рух җәүһәре, татар халкының үзенчәлекле мәдәниятының бетмәс-текәнмәс чишмәсе, аның рухи торышы, һәм талантларны ачу өчен бик яхшы мөмкинлек, җитезлектә, тапкырлылыкта көч сынашу…*

Бәйрәм атамасы борынгы төрки “сабан” һәм “туй” сүзләреннән килеп чыккан. Элегрәк Сабантуй карлар эреп беткәч, язгы кыр эшләренә 2-3 атна кала үткәрелгән, хәзер аны кыр эшләре тәмамлаганнан соң бәйрәм итәләр.

Сабантуй тамырлары белән ерак гасырларга барып тоташа. Бу бәйрәм турында 921 нче елда ук Багдад хәлифеннән Болгарга илче булып килгән атаклы Ибн Фадлан үзенең бөтендөньяга танылган хезмәтләрендә язып калдырган.

Иске заманда Сабантуй бәйрәме зур вакыйга булып исәпләнгән һәм аны бәйрәм итүгә хәзерлек эшләре озак барган. Кыш буена хатын-кызларыбыз бәйрәмгә бүләк әзерләгән, теккән, чиккән. Яз җитү белән малайлар йомырка, ә егетләр сөлге җыйган. Милли бизәкләр белән чигелгән сөлге иң кадерле бүләк булып саналган. Сөлге җыю, гадәттә, җыр-бию, уен-көлке белән бергә алып барылган. Бүләкләр колга башына эленгән, ә кайчакта егетләр үзләрен урап бәйләп куя торган була. Үзенә күрә Сабантуй шурасы булып саналган аксакаллар, ярышлар вакытында тәртип саклаган һәм җиңүчеләрне бүләкләү өчен жюри әгъзаларын билгеләгән. Бәйрәмнең кульминациясе - мәйдан. Биредә йөгерү, сикерү, милли көрәш буенча ярышлар, ат чабышлары үткәрелгән.

Акрынлап Сабантуй гомуми һәм милләтара бәйрәмгә әйләнә бара. Бүген аны Татарстан авылларында, поселокларында, районнарында, шәһәрләрендә генә түгел Мәскәүдә дә, Санкт-Петербургта да һәм татар диаспоралары яшәгән Россиянең һәм дөньяның башка төбәкләрендә дә бәйрәм итәләр.

Хәзерге вакытта Сабан туена дәүләт бәйрәме дәрәҗәсе бирелде. Аңа хәзерләнү һәм бәйрәм итү буенча указлар, карарлар чыгарыла, бәйрәмне финанслау чыганаклары...билгеләнә.

Борынгы Сабантуй бәйрәме акрынлап матур, заманча традицияләр белән тулыландырыла. Шулай да бәйрәмебезнең асылы гасырдан-гасырга күчеп, сакланып килә.

Татарстан Республикасында Сабантуй бәйрәме июнь аенда, гадәттә 3 этапта үткәрелә. Язгы кыр эшләре тәмамлануны башта авыл халкы бәйрәм итә, аннан Сабантуй республикабызның зур шәһәрләрендә гөрләп уза. Соңгы этап башкалабыз – Казанда, шәһәребезнең барлык административ районарында үткәрелә. Зур-зур мәйданнарда спортчылар, сәнгать осталары ярыша. Үзәк ипподромда ат чабышлары үткәрелә. Халык күңел ача. 2003 елда үзенең Татарстанга визиты вакытында ЮНЕСКО Генераль директоры К.Мацуура Татарстан Республикасы Президенты М.Ш. Шәймиевнең татар халкының милли «Сабантуй» бәйрәмен ЮНЕСКОның кешелек мирасы сөйләмә һәм матди булмаган шедеврлары исемлегенә кертергә кирәклеге турындагы тәкъдимен хуплап чыкты.

### ***Мордва халкының Балтай бәйрәме***

**Балтай,** «Балтай» ирзә бәйрәме (эрз. *эрзянь праздникесь Балтай*, шулай ук эрз. *Овто чи*) — мордва (ирзә) халкының милли бәйрәмнәренең берсе, ирзә традицион мәдәнияте бәйрәме. Татарстанның Лениногорск районы Мордва Кармалкасы авылында

июнь ае ахырында уздырыла. 1902 елдан билгеле. Бәйрәм тотем җәнлеге — аюга табынуга багышланган.

«Балтай» бәйрәме — Татарстан территориясендә бер генә авылда үткәрелүче бәйрәм. Бәйрәмгә Татарстан (*Әлмәт, Чирмешән, Бөгелмә, Тәтеш, Лениногорск, Кама Тамагы*) районнарыннан, Мордовиядән, Самар өлкәсеннән мордва иҗат төркемнәре (*«Эрзянка», «Мастор ягида», «Валда чи», «Умарина», «Пейделька», «Пизёлне», «Моро», «Кудо атя» һ. б.*) килә. Гадәттә, июнь ае ахырында, Троица(рус.)татар. бәйрәме узганнан соң беренче якшәмбе көнендә Татарстанның Лениногорск районы Мордва Карамалысы авылында гына уздырыла (Ижевскида да уздырыла башлаган). Әлеге авылда мордва халкының ирзә төркеме вәкилләре яши.

Алар табигать көчләреннән, үзләренә бәхет, сәламәтлек һәм иген уңышы бирүләрен сорап, ел буе гыйбадәт кыла, келәү кели. Июнь ахырында *Веле озномс* (эрз. *веле* – «авыл», эрз. *озномс* – «гыйбадәт кылу, келәү әйтү») дип аталган җәмгыять бәйрәме уздыралар. Ирзәләр Югары илаһ (эрз. *Вярде шкай*) булган Шкайдан(рус.)татар. (әүвәлге һәм башка исемнәре *Инешке*, Инешкипаз(эрз.)татар., *Инешки, Паз*) бай иген уңышы һәм эштә уңайлыклар сорый. Ирзәләр шулай ук урманда яшәүче тереклек ияләренең –– кешеләрнең борынгы бабалары булуына ышана. Мәсәлән, урман хуҗасы аюдан сорасаң — ул сәламәтлек, саулык бирә ала. Шуңа күрә аю хөрмәтенә гыйбадәт кылганнар, келәү келәгәннәр.

«Балтай» бәйрәме һәр елны борынгылар билгеләгән бер үк тәртиптә уза. Аның сценарие язылмый, режиссеры булмый. Бәйрәмнең бар йолаларының да төгәл һәм бердәм үтәлүен күзәтеп баручы җитәкчесе – тәртип саклаучысы гына була. Бәйрәмдә катнашучылар (*бигрәк тә, хатын-кызлар*) махсус бәйрәм киемнәре кияргә тырыша: *покай* (чигүле йон күлмәк), *сюлгам* (күкрәк перәшкәсе), *каркс* (билбау), *пулагай* (билгә арттан бәйләнә торган бизәкле киндер тукыма), *ашкоркс* (кызларның баш киеме), *сорока, панго* (кияүдәге хатыннарның баш киеме) һ.б.

- Бәйрәм «Балтай аланы» дип аталучы урман аланында башлана. Бәйрәмдә катнашучылар һәм кунаклар барысы да биредә җыела.
- Аюларны киендереп бетергәч, бәйрәм кунаклары, биюче аюларны уртага алып, «Кий чиресэ репст видезь» халык җырын җырлый-җырлый, әйлән-бәйлән ясый.
- Балалар коедан савытларга су алып, барлык кунакларны су белән коендыра. Иген уңышы мул булсын өчен, табигать көчләреннән яңгыр сорау йоласы шулай уздырыла.

***Мари халкының Семык бәйрәме***

**Семык** – мари милли бәйрәме, йола бәйрәме, җәй аеның башлануын хәбәр итә, җәй ае фасылын ачып җибәрә. Бәйрәмнең төп максаты булып вафат булган кешеләрне искә алу һәм йорт эшләрендә уңышларга ирешү өчен, әрвахлардан гафу сорау тора. Семык –

мари халкының иң көтеп алган һәм яраткан бәйрәмнәреннән санала. Авыл халкының оешып, туган-тумачаның бергә җыелуын күздә тотып эш итела.

Семык бәйрәме Пасха бәйрәменнән соң җиде атна узганнан соң башланып китә һәм якшәмбе көнне Троица бәйрәмендә тәмамлана. Православие динендәге марилар Семык бәйрәмен пәнҗешәмбе көннән бәйрәм итәләр.

Чәршәмбе төненнән алып пәнҗешәмбе көненә кадәр начар, явыз көчләрдән арындыру көне булып саналган. Явыз көчләрнең йортка үтеп керүенә каршы итеп, йорт хуҗалары төрле саклану гамәлләре эшләгәннәр: учаклар яндырганнар, төрле тавышлар чыгарганнар, йортларны ялгыз калдырмаганнар. Яшьләр бу төнне төрле әкәмәт эшләр эшләгәннәр: морҗа авызларын каплаганнар, мунчада су мичкәләрен әйләндереп куйганнар. Аннан соң су буена, үзәнлеккә төшеп, таң атканга кадәр күңел ачканнар, кызлар болыннан чәчәк букетлары җыйганнар. Шимбә яки якшәмбе көнне бәйрәм тәмам булган.

Төрле халыкларның бәйрәмнәрендә охшашлыклар да күп, әммә аермалыклар да җитәрлек. Әмма бәйрәмнәрнең максаты бер- халыкны берләштерү, дуслык, татулык хисләре тәрбияләп киләчәк буынга үзләренең гореф-гадәтләрен онытмаска өндәү тора.

Һәр халыкның – үз тарихы, үз кыйбласы, үз гореф-гадәтләре, үз теле. Аларның һәркайсы бик тә кадерле, бик тә якын. Һәркемнең туган теле, аның әнисе кебек аеруча сөекле, шуңа да мәңге аерылгысыз, изге төшенчә. Адәм баласының иң изге, иң мөкатдәс хисләренең берсе – туган телгә гаме, хөрмәте булу. Тел – халыкларның тәҗрибәләрен үз эчендә саклый торган бер хәзинә. Шушы истә тотып, без күрше халыкларыбызны да туган телебез, татар телендә котлыйсыбыз килде. Проект эшенең нәтиҗәсе буларак **беренчедән**, башка милләт вәкиленә үзебезнең туган телебезне яратуыбызны шушы хатлар аша күрсәттек; **икенчедән** аларның гореф-гадәтләре, бәйрәмнәре белән дә якыннанрак таныштык һәм өйрәндек; **өченчедән**, үткән тарихыбызны онытмыйча күрше милләтләрне бәйрәмнәре белән котлап, бердәм- дус яшәргә теләвебезне җиткердек.

Проект эшендә төрле милләтләрнең бәйрәмнәре турында алынган мәгълүматлар аша, һәр халыкның күпләп яшәү урыннарын өйрәндек.

Хат һәм открыткалар җибәрү өчен адреслар язылган “Справочник почтовых индексов Республики Татарстан, Казань, официальное издание ФГУП УПС «ТАТАРСТАН ПОЧТАСЫ» китабын кулландык.

Хат язу өчен күрше авылда яшәүче керәшен халкын сайладык. Чөнки анда мәктәбебездә укытып киткән укытучы Семенова Елена Петровна яши иде. Аның хәлләрен белештек, үзебезнең яңалыклар белән уртаклаштык. Питрау бәйрәме турында эзләнүләребезне, яңалыкларыбызны аның белән дә бүлештек.

Ә ясаган открыткаларда төрле халыкларның бәйрәм исемнәре, милли киемнәре ачык итеп күренеп торырга тиеш дип максат куйдык. Ә инде котлау открыткасын язганда, чыннан да күрше милләтләребезнең бәйрәмнәрен, йолаларын белүебезне күрсәтеп, кыскача гына аңлатма биреп киттек. соңыннан аларны котлап, күңелебездән чыккан изге теләкләребезне юлладык.

Теләкләребез барлык милләтләргә дә бертөрле:

“Һәр бәйрәмнең үзенчәлеге ягы бар. Бердәмлек бүгенге Татарстан өчен мөһим. Ихлас күңелдән һәммәгезгә дә исәнлек-саулык, иминлек, игелекле хезмәтегездә зур уңышлар телибез!”

Открытка һәм хатларны конвертка урнаштыргач, адресларын яздык. Ә конвертыбызның тышына “Праздничный круг народов Татарстана” тамгасын куеп чыктык.

Проект эшен йомгаклап, М.Ш.Шәймиев “Кем ул иң бәхетле? Кемнең татар, рус, чуваш, керәшен, урмурд һ.б. милләт кешеләре арасында дуслыгы күп, шул бәхетле,”-дигән сүзләре белән тәмамлыйсы килә. Чыннан да “күрше хакы- тәңре хакы”,- дип юкка гына әйтмәгән борынгылар. Без үзебезнең күршеләребез белән дус-тату, хөрмәтләшеп яшәсәк- бәхетле булырбыз! Илебездә тынычлык хөкем сөрер, алдыбызга куелган максатларыбызга һичшиксез ирешербез дигән теләктә калабыз.

Кулланылган әдәбият:

1.Уяв бәйрәме турында. – URL : https://tatarica.org/tat/razdely/narody/chuvashi/uyav Онлайн - энциклопедия Tatarica

2. Чуаш халкының уяв бәйрәме турында. - URL : https://tatarica.org/tat/razdely/narody/chuvashi/uyav

3.Мари...халкы..турында..мәгълүмат. - URL : https://tatarica.org/tat/razdely/narody/mari/marilar Онлайн - энциклопедия Tatarica

4. Каравон рус фестивале. - URL : https://tt.wikipedia.org/wiki/

5. Справочник почтовых индексов Республики Татарстан: официальное издание ФГУП УПС «ТАТАРСТАН ПОЧТАСЫ». - Казань, 2010.

6. Уразман, Р. Татар халкының йолалары һәм бәйрәмнәре / Татарсан Милли китапханәсе. - Төз.З.Ә.Җамалиева. – Казан : Милли китап. - 2000.

7. Баязитова, Ф. Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары. – Казан : Татар кит.нәшр., 1995.

8. Атна вакыйгалары. “Теләче” газетасына кушымтасы.- Җандашларга хат языгыз.- №12 (371), (2-8 апрель, 2021ел).

9. “Ватаным Татарстан” газетасы.- Сөнчәледә бер көн. Чуаш халкы ничек яши? - № 45 (2 апрель, 2021ел).

*Сөнгатуллина Ләйлә Мөхәмәт кызы,*
*Хәйруллина Гөлназ Рәшит кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге «1 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

**Ф.Яруллинның "Кояштагы тап" әсәрендә намус төшенчәсе**

| | |
|---|---|
| Тема | Ф. Яруллинның "Кояштагы тап" хикәясендә намус мәсьәләсе |
| Класс | 5 |
| Предмет | татар әдәбияты |
| Дәреснең максатлары | 1. Хикәяне анализлау өчен шартлар тудыру<br>2. Намуслы яшәү юллары төрле булуын ачыкларга ярдәм итү<br>3. Ата-ананы хөрмәт итү, алар алдында намусың чиста булу кирәклеген аңларга булышу |
| Дәреснең бурычлары | 1. Белем бирү максаты: хикәянең төп фикерен укучы аңына җиткерү өчен шартлар тудыру<br>2. Фикерләү сәләтен үстерү максаты: анализлау, чагыштыру, гомумиләштереп, нәтиҗә ясау күнекмәләрен үстерүне дәвам итү<br>3. Тәрбия бирү максаты: бәхетле булу кешенең үзеннән тора икәнлегенә ышандыру |
| Планлаштырылган нәтиҗәләр | 1. Предмет нәтиҗәләре: хикәянең темасын аңлау һәм формалаштыру, идеясен күрсәтү<br>2. Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр: герой кылган гамәлләр аша яхшыны начардан аерырга өйрәнү<br>3. Метапредмет нәтиҗәләр:<br>- регулятив: әсәрнең төп проблемасын табу, герой эшчәнлеген бәяләгәндә, үзеңнең һәм башкаларның фикерен дөрес бәяләү, төп нәтиҗәне чыгару эшчәнлегендә катнашу өчен тырышу.<br>- танып-белү: булган белемнәргә таянып, "намус" төшенчәсенә кагылышлы мәгълүматны табу һәм анализлау аша аны бәяләү, гомуми нәтиҗәне чыгару<br>- коммуникатив: намус турында төп фикергә килгәнче, төрле җавапларны тыңлау; төркемнәрдә эшләгәндә, төрле мисаллар белән |

| | |
|---|---|
| | үз фикереңне дәлилләү, әсәрнең төп фикерен табу һәм формалаштыру |
| Предметара бәйләнеш | Рәсем сәнгате, татар теле, музыка |
| Эшне оештыру | Төркемнәрдә һәм индивидуаль эшләү |
| Төп төшенчәләр | Тема, идея, намуслы булу проблемасы, анализлау, чагыштыру, гомуми нәтиҗә |

| **Дәрес этаплары** | **Укытучы эшчәнлеге** | **Укучы эшчәнлеге** | **Белем бирү һәм фикерләү сәләтен үстерү** | **Универсаль уку гамәлләре (УУГ)** | **Эшкә этәргеч бирүче сораулар һәм тәкьдимнәр** |
|---|---|---|---|---|---|
| Мотивлаштыру<br>2 мин.<br>Максат: уңай психологик халәт тудыру. | Укучыларны уку эшчәнлегенә тарту. | Дәрестә төркемнәрдә эшләү кагыйдәләрен искә төшерәләр: башкаларны тыңла, үз фикереңне ачык әйт, игътибарлы бул. | Шәхси эшчәнлек: дәреслек һәм эш дәфтәрләрендәге язмаларны барлау. | Шәхси: әдәп-әхлак кагыйдәләрен искә төшерү, бер-берсенә уңышлар теләү. | Өйнең яме ана белән;<br>Яктылык - кояш янында,<br>яхшылык - ана янында;<br>Ана җылысы – кояш җылысы;<br>Әни суккан авыртмый мәкальләре н нәрсә берләштерә ? |
| Актуальлә | Белем | Узган дәрестә Ф. | Ул | **Шәхси**: уку | Узган |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| штерү<br>6 мин.<br><br>Максат: яңа белем алуга әзерлекне тикшерү, аның темасын формалаштыру. | алуга эчке ихтыяҗ булдыру өчен, шартлар тудыру.<br>Искәрмә: хикәя алдан ук өйдә укыла, шуңа таянып, яңа белем алуга әзерлек эше алып барыла. | Яруллинның “Кояштагы тап” әсәре, аның төп герое белән таныштык. Малай, әнисенең авыру икәнен онытты, суны якындагы чишмәдән генә алды. | дәреслектәге өзек буенча чорга автор исеменнән бәя бирү. | эшчәнлегендә бер-берсе һәм укытучы белән хезмәттәшлек оештыру.<br>**Регулятив**: һәр төркемнең бәясен тыңлап, нәтиҗә чыгару, алдагы адымнарны фаразлау.<br>**Коммуникатив:** геройның эш-гамәлләренә бәя биргәндә, ике төркем хезмәттәшлегенә ирешү. Хикәядә сөйләнә торган вакыйганы тормыш белән бәйләп, нәтиҗә чыгаруны оештыру. | дәрестә нинди хикәя укыдыгыз? Төп герой кем? Башка геройлар белән мөнәсәбәтен, бәйләнешен ачыклагыз. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Һәр өлешнең кыскача эчтәлеге сөйләнеп, төп фикерләр әйтелгәч, презентациядә төрле рәсемнәр ачыла | Өч өлешкә бүлүләре турында әйтәләр. Укучылар берничә җөмлә белән сюжетны сөйләп чыгалар, төп фикерне әйтәләр. | Үз фикереңне әйтү өчен, төрле дәлилләр сайлый белү, аларны раслау. | | Хикәяне ничә өлешкә бүлдегез? Сюжет буенча эшләп алыйк. |
| | **Слайд №1.** Бик тырыш, эшчән хатын-кыз сурәте | 1 нче өлеш: Әнисе улына һәрвакыт яхшы булсын дип, көне-төне эшли | Фикереңне кыска һәм матур итеп әйтү, дәреслектән мисаллар китерү. | **Танып-белү:** гади ситуацияләрне бәяләп, геройның конкрет гамәлен күрә белү, аны дөрес бәяләү. | |
| | **Слайд №2.** Су тулы чиләкләр | 2 нче өлеш: малайның әнисе авырып китә, малайдан су алып кайтырга сорый. Малай бик дорфа гына җавап бирә. | Булган белемнәрдән чыгып, яңа фикерне формалаштыру. | **Шәхси:** намус, әти-әнигә карата хөрмәт турында үз фикереңне әйтә белү. **Коммуникатив:** төркемнәрнең фикерләренә мөнәсәбәтеңне белдерү. | Малай дөрес эшләдеме? Әни белән сөйләшү дөрес тонда булдымы? |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | **Слайд №3.** Уйнап йөрүче малайлар | 3 нче өлеш: әнисе авырып ята, малаен көтә, ә малае уйнап йөри.<br><br>Һәр төркемнең җавабыннан соң, уртак фикер тыңлана: | Фикерләрне үз мисаллары на таянып раслау. | **Танып-белү:** һәр төркем үз фикерен белдерә, аларның җаваплары тыңлана, чагыштырып, уртак нәтиҗә чыгарыла. **Регулятив:** тиешле нәтиҗәгә килүдә эзлеклелекне саклау. | Хикәянең ошаган өлеше кайсы? |
| | **Слайд №4.** Ачык кояш һәм болыт астындагы кояш рәсеме | Бүгенге тема намус, эти-әниләргә карата мәрхәмәт турында. | Кояшта тап барлыкка килүне аңлату | **Шәхси:** һәр укучы дәреснең темасын мөстәкыйль формалаштыра. **Коммуникатив:** уртак фикергә килү. | Ничек уйлыйсыз: бүгенге дәреснең темасы нинди? |
| Аңлау өчен авыр тоелган сорауны ачыклау өчен сынап карау этабы.<br>4 мин. | Сөйләгәннәрдән чыгып, проблемалы сорау куела.<br><br><u>Укучыны</u> | Төркемнәрдәге аерым укучылар фикерләрен белдерәләр. Сорауга берьяклы гына җавап бирергә авыр, төп фикергә килергә | “Намус” төшенчәсенең мәгънәсен сүзлек ярдәмендә ачыклау | **Регулятив:** хикәя вакыйгаларын хәзерге тормыш белән бәйләп чагыштыру. **Шәхси**: “Намус” | “Намус” төшенчәсен ничек аңлыйсыз? Кешеләрнең намуслы яшәве нидән тора? Эти- |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Максат: укучының нинди авырлык белән очрашуын билгеләү | ң шәхси фикере формалашуга юнәлеш бирә. | кыенсыналар. | | төшенчәсен элек һәм хәзер ничек аңларга? соравы буенча фикер белдерү. | әнигә карата бу төшенчә ничек бәяләнә? |
| Физминутка.3-4 минут<br>Максат: укучыларны ял иттерү. | Төркем эшчәнлеген оештыру.<br>Физминутка үткәрүгә җаваплы укучының эшен оештыру. | Тәкъдимнәрен әйтәләр, төп нәтиҗәгә киләләр: алгоритмнарга нигезләнеп, алдагы эш планы төзергә.<br>Күнегүләр ясыйлар. | Һәр төркемнең, дәреслек мисалларын файдаланып, аерым детальләр аша үз фикерен әйтүе. | **Коммуникатив:** төркемнәрдә хезмәттәшлеккә ирешү.<br>**Шәхси:** төрле ял итү күнегүләре ясау.<br>**Регулятив:** күнегүләрне дөрес эшләүне контрольдә тоту. | Укучылар, бу сорауга җавап бирергә авырсынасыз.<br>Без нишли алабыз? |
| Кыенлыктан чыгу планы. (яңа белемнәрне куллану).<br>5 мин.<br>Максат: кыенлыктан чыгу | Эшкә юнәлеш бирүче сораулар куя. | Планың төп алгоритмы билгеләнә: сәбәп-эшчәнлек-нәтиҗә.<br>Төркемнәрнең тәкъдимнәре тыңлана, план төзелә: | Һәр укучының үз эшчәнлеген мөстәкыйль оештыруы, төркемнәрд | **Регулятив**: иҗади фикер йөртеп, алдагы эшчәнлекне күрә белү күнекмәләрен үстерү. | Малайның бик нык уйныйсы килгән. Бу гаепле эшме? |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| юлларын ачыклау һәм план төзү. | | хикәянең төп өлешләреннән чыгып, һәр геройның бәхетне күзаллавын ачыкларга. күрсәтергә, һәр эшчәнлеккә бәя бирергә, нәтиҗә ясарга. | ә фикерләшү һәм төп нәтиҗә ясау күнекмәләрен ныгыту. | **Шәхси:** бу өлкәдә һәр укучының үз фикерен булдыруга ирешү, дәлилләү. **Танып-белү:** төп фикергә килү юлындагы проблемаларны кую һәм чишү. | |
| <u>Планны тормышка ашыру/яңа белемне куллану.</u> 7 мин. Максат: “Намус” төшенчәсенең асылына төшенү һәм хикәя персонажлары мисалында аңлату. | Сораулар бирә, эшнең эзлеклелеген тәэмин итә. **Слайд №5.** Укучылар игътибарына тактага кагылган кадаклар турында парча тәкъдим ителә. | Индивидуаль фикерләр тыңлана, төркемнәрдә тикшерелә, нәтиҗә ясала: малай эшнең нәтиҗәсен уйлый беләме икән? | Хикәя буенча һәм тормыштан алган фикер-карашларга, хис-кичерешләргә нигезләнеп, фикер җиткерү, аны расларга тырышу. | **Регулятив:** автор карашын аңлата торган сүзләр аша объектив һәм субъектив мөнәсәбәтләрне ачыклау. **Коммуникатив:** фикернең ачык итеп әйтелүенә ирешү. **Шәхси:** дәлилләү, логик фикерләп, нәтиҗә ясау. | Парча буенча фикер йөртик. Тактадан кадакларны алгач, ул элеккечә үк калдымы? |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | **Слайд №6.** | Төркемнәрдә эшләү.<br>1 нче әнисенең малайга мөнәсәбәтен ачу.<br>2 нче малайның әнисенә мөнәсәбәтен ачу | Дәреслекнең тиешле өзекләреннән мисаллар китерү. | **Шәхси:** герой халәтен тоеп, үз кичерешләреңне чагылдыру.<br>**Танып-белү:** әйтелгәннәргә нигезләнеп, чираттагы нәтиҗәне чыгау. | Мөнәсәбәтләр ике яктан да тигезме? |
| | Сорау куела. | Уйнарга ярата, әнисе белән дорфа сөйләшә, суның салкынын яратса да, алып кайтырга авырсына... | Характеристика бирү күнекмәләрен үстерү. | **Шәхси:** эпитет һәм чагыштырулар аша эмоциональ мөнәсәбәт белдерү.<br>**Регулятив:** төп геройга хас характер билгеләрен күрсәтү, шулар аша геройның тормышта тоткан урынын һәм аның шәхси мөнәсәбәтен объектив бәяләү.<br>**Коммуникатив:** төрле фикерләрне | Малайның характерына хас нинди уңай һәм тискәре сыйфатлар бар? |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | тикшерү, уртак нәтиҗәгә килү. | |
| | Сораулар куела. | Төркемнәрдәге укучылар бәхәсләшеп, бер-берсенә ярдәм итешеп, фикерләрен белдерәләр: малай үзе турында уйлады, шуңа күрә әнисе әйткәннәрне онытты. | | **Танып-белү:** төркемнәрдә сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен китереп чыгару һәм аны мисалларга нигезләнеп исбатлау. **Шәхси:** фикереңне дәлилләү. | Хикәядә сөйләнгән хәлнең сәбәбе нәрсәдә? |
| <u>Беренчел ныгыту</u> 4 мин. Максат: яңа белемнәрне биремнәрдә куллану/тышкы сөйләмдә әйтеп күрсәтү | Сораулар куела. Тикшерү соравы куела. Ул дәреслектә каралмаган һәм көтелмәгән җаваплар бирүне таләп итә. | Авыру әни салкын су эчәсе килүен малаена әйтте | Дәреслеккә таянып, андагы фразаларны кулланып сөйләү, эмоциональ кичерешләрне сөйләмдә дөрес бәяләү. | **Коммуникатив:** ситуацияләрне бәйли белү, төркемнәрдә уртак фикергә килү өчен, эзлекле хезмәттәшлек булдыру. | Бу нинди нәтиҗәгә китерде? |
| | | Төркемнәрдәге һәр укучының фикере тыңлана һәм системага | Дәреслектәге “Каф тау артында” сүзен | **Регулятив:** вакыйганы үз гаиләләрендәге хәл белән | Сезнеңчә, малай ни өчен дөньясын |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | салынып, дәфтәрләргә язылa: авыру әнисенең хәленә керә белми, үзе авырлык кичермәгән, әнисе аңа беркайчан да уңайсызлык китермәгән... | мисалга китереп, бу вакыйганың теләсә кайда булырга мөмкинлеген билгеләү. Фикерләрне гомумиләштерү, уртаклыкларын табу. | чагыштырып карау, нәтиҗә ясау. **Танып-белү**: укучыларның тормышка карашларын формалаштыру. **Шәхси:** һәр баланың үз фикерен ачык белдерүе, дәлилләп, үз нәтиҗәсен ясавы. | онытып уйнаган? |
| <u>Үз-үзеңне тикшерү өчен мөстәкыйль эш.</u> 4 мин. Максат: үзләштерелгән белемнәр буенча нәтиҗә ясау. | Хикәянең төп фикерен (идеясен) табарга юнәлеш бирүче сорау куела. | Һәр төркем аерым эшли, аннан соң берәр укучы тыңлана: малай хатасын аңлаган, ялганлаганын әнисенә әйткән. Шуңа да карамастан, әлеге вакыйг әнисенең күңелендә авыр эз калдырган. | Чыгарылган нәтиҗәләрне дәфтәрләргә язып кую. | **Танып-белү:** алган белемнәрдән тиешле нәтиҗәләр чыгару күнекмәләрен формалаштыру. **Коммуникатив:** төркемнәрдә ярдәмләшеп эшләү. **Шәхси:** эш барышында үз фикереңне белдерү. | Малай үз хатасын аңлаганмы? Ул нинди сабак алган? |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Белемнәрне системага салу.<br>4 мин.<br><br>Максат: алган белемнәрне куллану һәм ныгыту. | Үз эшеңне бәяләүгә юнәлтелгән сораулар куела. | Һәр төркемнең үз җавабы:<br>– Намуслы яшәргә кирәлекне аңадык.<br>– Әниләрне алдарга ярамаганны, ул күңелдә уелып калганны аңладык. | | **Регулятив:** аңлашылмаган якны ачыклау, бергәләп эшләгәндә, бердәм карар кабул итә белүнең әһәмиятен аңларга булышу. | Укучылар, сез бүген нәрсә турында өйрәндегез? |
| Рефлексия<br>2 мин.<br>Максат: үз эшчәнлегенә кире кайтып бәя бирү. | **Слайд № 7.** Әти-әниеңнең сүзен тыңлау бәхет китерә. Алар алдында намусыңның чиста булуы кирәк | Төп нәтиҗә: әнинең сүзен тыңларга, аның хәленә керергә, алдамаска кирәк. Намуслы яшәүгә берни дә җитми. | Барлык эш процессын күздән кичереп, төп нәтиҗәне чыгару. | **Шәхси:** һәр баланың шәхси нәтиҗәгә ирешүе.<br>**Коммуникатив:** әңгәмәдә актив катнашу. | Нинди нәтиҗә ясадыгыз? |
| | Укытучы укучылар белән берлектә эшкә йомгак ясый. | Һәр төркемнең эшенә һәм индивидуаль чыгышларга, үз эшләренә укучылар алдан билгеләнгән критерийлар буенча бәя бирәләр, билге | Укучылар бер-берсенә рәхмәт белдерәләр. | **Шәхси:** үз эшеңә объектив бәя бирә белү һәм тәнкыйть күзлегеннән карау. | Укучылар, үзбәяләрегезне карагыз һәм билгеләрегезне куегыз. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | куялар. | | | |
| Дәресне йомгаклау. 2 мин. Максат: бер-береңнең эшен бәяләү, билгеләр кую. | “Намуслы булуны ничек аңлыйсың?” темасына 2-3 сүз белән мисал китерү. Билге кую. | | | **Шәхси:** үз мөмкинлегеңнән чыгып, өй эше алу. | Укучылар, дәрес тәмам. Дәрестә яхшы эшләвегез өчен рәхмәт. |
| Өй эше бирү 1 мин. | | 1. Әсәргә карата “Әйе-юк” җавабы таләп ителгән 5 тест соравы төзергә. 2. Әсәргә кыскача план төзергә. 3. “Әни һәм намус – янәшә төшенчәләр” темасына үзфикереңне белдереп 4-5 җөмлә язарга. | | | |

*Фалахиева Ильмира Ризатдин кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге «1 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле биология һәм география укытучысы*
*Миннегалиева Гөлназ Сәләхетдин кызы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Мамадыш шәһәре беренче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү оешмасының югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Проект эшчәнлегенең өстенлеге

Федераль дәүләт белем бирү стандартларына күчү шартларында укытучы эшчәнлегенең нәтиҗәле юнәлешләреннән берсе булып проектлар методы санала. Бу метод укучыларның өйрәнгән белемнәрен гамәли куллана белүләренә, мәгълүмати тирәлектә ориентлашу осталыкларына, иҗади фикерләү сәләтләренә нигезләнә.

Проектлар методы – укучы шәхесенең белем алуга иҗади якын килүенә юнәлтелгән укыту системасы ул. Ул мәктәптә укытучы җитәкчелегендә эшләнә торган мөстәкыйль иҗади эш. Проект эшчәнлеге – төпле фикере булган балалар тәрбияләү технологияләреннән берсе.  Аның нигезе - тикшеренү эше.

Максаты: укучыларның шәхси үсешенә, уңышлы аралашуларына ирешү, аларны һәртөрле эшчәнлеккә иҗади якын килергә өйрәтү.

Проект эшчәнлеге укучыларда да, укытучыда да зур кызыксыну тудыра. Ул фикерләүне, сөйләмне, үз уйларыңны формалаштыра белү сәләтен үстерә. Проект эшчәнлеге барышында укучы коллективта эшләргә, үзенә бирелгән эшкә җаваплы карарга, куелган сорауларга җавап табарга өйрәнә.

Башлангыч сыйныф укучысы өчен проект эшчәнлеге шактый катлаулы. Балада көтелгән нәтиҗәгә ирешүгә кызыксыну булганда гына, проблеманы чишүдә уңай мотивация тудырып, аның эшкә дәртен, мөстәкыйльлеген үстерергә мөмкин. Кече яшьтәге мәктәп балалары белән проект-эзләнү эше алып барганда, аларның белем дәрәҗәсенең югары булмавын, дөньяны күзаллауларының, мөстәкыйль анализлау һәм игътибар туплау сәләтенең тиешенчә формалашып җитмәвен истә тотарга кирәк. Шуңа күрә укытучы башлангыч сыйныф укучыларын эзләнү эшчәнлегенең беренче адымнары һәм алгоритмнары белән таныштыра. Проект методының төп өстенлеге, минемчә, укучыларның

яңа белем туплап кына калмыйча, белем туплауның, бердәм хезмәтнең нәтиҗәсен булдыруда.

Башлангыч сыйныфларда түбәндәге төрдәге проектларны кулланып була:

тикшеренү (проблемалы ситуацияләрдән чыгу юлларын эзләү, көндәлек тормышта кирәк булырдай программалар тәкъдим итү); иҗади (бәйрәмнәр яки конкурслар өчен презентация, музыкаль бизәлеш, фото коллаж, видеоклип һ.б.);

мәгълүмати (темага караган мәгълүматларны җыю, аларны катнашучыларга тәкъдим итү, фикер алышу, нәтиҗә ясау); уен-проектлар.

Проект эшләүнең түбәндәге этапларын билгеләп үтәргә мөмкин.

1. Әзерлек этабы, аны “кереш өлеш” яки “проектка кереп китү” дип тә атарга мөмкин:

-проектның темасын, максатын һәм проблемасын билгеләү;

-проблеманың әһәмиятен нигезләү;

-проект башкару өчен укучыларның шәхси теләкләрен искә алып, төркемнәргә бүлү.

Укытучы бу этапта укучыларга проект өчен төрле темалар тәкъдим итә. Укучылар үзләре тәкъдим иткән темалар карала. Бу этап проектның иң демократик өлеше булып тора.Теге яки башка теманы сайлату өчен укучыга басым ясау, укучы башкарырга теләгән проектны кире кагу рөхсәт ителми.Укытучы ярдәме белән, укучылар үзләре кабул иткән проектның проблемасын, сюжетын, максат һәм бурычларын билгелиләр, куелган максатны тормышка ашыру юлларын эзлиләр.

2.Эшчәнлекне планлаштыру һәм проблемаларны чишү этабы яки “эшчәнлекне оештыру” дип тә атасак була (информация эзләү да шушында керә ала):

-мәгълүмат чыганакларын барлау, аны җыю  һәм туплау;

-проблемалы ситуацияләрдән чыгу юлларын эзләү;

-киләчәк нәтиҗәне презентацияләү формасын һәм алымын сайлау.

Укучылар бу этапта мәгълүмат эзлиләр, җыялар, тәртипкә китереп анализлыйлар, эшне планлаштыралар; укытучы белән киңәшләшеп, киләчәк нәтиҗәне презентацияләү формасын һәм алымын сайлыйлар; әзерлек һәм планлаштыру эшенә үзбәя бирәләр.

3.Проектны тормышка ашыру:

-анализ юлы белән табылган мәгълүматларны бер бөтенгә берләштерү, нәтиҗәне дәлилле аңлату. Укучылар үзләре башкарган эшкә анализ ясыйлар, уңышларын һәм кимчелекле якларын ачыклыйлар, нәтиҗә чыгаралар.

4.Проектны яклау, проект эшчәнлегенең нәтиҗәләрен бәяләү этабы.

Укучылар проектны презентациялиләр, башкаларны эш нәтиҗәләре белән таныштыралар, сорауларга җавап бирәләр, эшчәнлекләренә үзбәя бирәләр.Бу этап бигрәк

тә әһәмиятле булып тора.Һәрбер проект уңышлы тәмамланырга тиеш. Проект эшенә ата-аналарны да җәлеп итү бик отышлы, ата-ана бала тормышында актив катнаша башлый.

Укытучы: киңәшче, юнәлеш бирүче, төзәтмәләр кертүче, рухландыручы,

илһам өстәүче.

Укучы: эзләнүче, идеяне тормышка ашыручы, мәгълүмат җыючы, фикерләүче,күзәтүләр нигезендә модель төзүче, барлыкка килгән нәтиҗәләрне анализлаучы, тәҗрибәләр үткәрүче, интернет материалларын кулланучы, проектны яклаучы.

Ата- ана: укучыга кирәкле мәгълүматны табарга ярдәм итүче, идеяләрне тулыландыручы, иҗади бала белән бергә кызыксынучы, бала белән көндәлек аралашучы ролен үтәүче.

Балалар эшенең күрсәткече: 1-4 классларда рәсем, инша,табышмак, шигырь, сүзлек һәм башкалар булырга мөмкин.

Проект эшенең нәтиҗәсе: 1-2 классларда мәгълүмат тупланган китап яисә альбом, 3-4 классларда проект эше презентация, сценарий, фильм, каталог һ.б ярдәмендә башкарылырга мөмкин.

Укучыларга проект эшчәнлегенә йомгак ясаганда:

1.Проект эшендә нәрсә кызыклы булды?

2.Аеруча нәрсә ошады?

3.Нинди яңалыклар белдең?

4.Бу теманы өйрәнүне дәвам итәр идеңме?

5.Киләчәктә нинди проект эшен дәвам итәр идең? -кебек сораулар бирергә була.

Йомгаклап шуны әйтәсебез килә: проект методын кулланганда уйлау мөмкинлекләре киң ачыла, логик фикерләү дәрәҗәсе үсә, төрле чыганаклар белән мөстәкыйль эшләргә, төрле чыгышлар ясарга өйрәтә. Ә иң кыйммәте - аларда үз нәтиҗәләрен күргәннән сон иҗат дәрте кабынуы.

*Фатхуллина Гузял Фагим кызы,*
*Халикова Нурсина Далиф кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 15 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

**Укучының гражданлык үзенчәлеген формалаштыруда патриотик тәрбиянең роле**

Балаларга патриотик тәрбия бирүнең кирәклеге хәзерге вакытта беркемдә дә шик тудырмый, чөнки соңгы елларда җәмгыятьнең һәм үсеп килүче буынның рухи культурасы кими.

Яшьләрнең яңа буыны Америка боевикларында һәм Азия наркотиклары турындагы мәгълүматне белеп- күреп үсә. Һәм котылгысыз нәтиҗә буларак-наркомания, тәмәке тарту, спиртлы эчемлекләр куллану һәм балалар җинаятьчелеге үсә. Хәрби хезмәтнең дәрәҗәсе төшүе күренә.

Ватанпәрвәрлек, Ватанга мәхәббәт хисе, аның бай тарихи традицияләренә хөрмәт тәрбияләү - хәзерге заман җәмгыятенең иң мөһим проблемаларының берсе. Һәр укучы үз ватанының тарихын, халкының үткәнен белергә, гражданлык позициясенә ия, көчле һәм кыю, һәрвакыт Ватанының мәнфәгатьләрен якларга әзер булырга тиеш.

Безнең чыгышыбызның максаты, федераль дәүләт белем бирү стандарты нигезендә рухи - әхлакый һәм социаль кыйммәтләр буларак, мәктәп укучыларында патриотизм формалаштыру шартларын тудыру өчен, дәресләрдә һәм дәрестән тыш чараларда проблемалы мәсьәләләрне билгеләү һәм аларны хәл итү юлларын тәкъдим итү.

Ватанпәрвәрлек - ул Ватанга, туган якка мәхәббәт, үз Ватаныңа тугрылык, аның мәнфәгатьләренә хезмәт итәргә омтылу һәм аны яклауга әзерлек. Хәзерге вакытта мәктәп алдында торган иң мөһим мәсьәлә - Россиянең рухи традицияләрен, үз төбәген, халыклар мәдәниятен торгызу, баланың Ватан, Туган як, Гражданин, Патриот, Герой, сугыш һәм хезмәт ветераны кебек төшенчәләрне ачык аңлавы.

15 нче мәктәпнең 7, 9 нчы сыйныф укучылары арасында “Син үзеңне патриот дип саныйсыңмы?” дигән темага анкета үткәрдек.

Анкета нәтиҗәләреннән укучыларны патриотик тәрбияләүнең рухи-әхлакый, тарих-туган якны өйрәнү, гражданлык-патриотик юнәлешләрен аерып күрсәтүләре куренде.

Патриотлык тәрбияләүдә әлеге юнәлешләрне гамәлгә ашыру өчен төп бурычларны билгеләдек:

- милли мәдәниятнең чыганаклары, гореф-гадәтләре белән таныштыру;
- туган якка, әйләнә-тирә табигатькә ярату хисе тәрбияләү;
- үз илеңә мәхәббәт һәм горурлык хисе тәрбияләү;
- үз халкының үткәнен һәм бүгенгесен өйрәнү.

Алга куелган бурычларны тормышка ашыру өчен без нәтиҗәле технологияләр сайладык. Алар мәгълүмати-коммуникацион, уен, проект, төркем, хезмәттәшлек технологиясе һәм актив эш формалары (өйрәтү экскурсияләре, тематик күргәзмәләр, тарихи-патриотик конкурслар, викториналар, халык әкиятләре һәм риваятьләре буенча театраль тамашалар, кызыклы кешеләр белән очрашулар, патриотик инсценировкалар һәм бәйрәмнәр).

Ә матур әдәбият гражданлык-патриотик хисләр тәрбияләүнең көчле чараларның берсе булып тора. Ватанны саклаучылар турындагы китаплар зур роле уйный. Батырлык яшүсмерләрне дулкынландыра һәм үзенә тарта, үрнәк алырга омтылыш тудыра. Шуңа күрә, сыйныфларның тәрбия эшчәнлеге системасына 5 нче китапханә белән хезмәттәшлекне керттек.

Дәресләрдә балаларны шәһәр, дәүләт символикасы, бәйрәмнәре, гореф-гадәтләре, РФ Конституциясе белән таныштырам. Дәрестән тыш эшчәнлек буенча төзегән программа дәрестән тыш вакытта тикшеренү, проект эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, музейларга экскурсияләр үткәрергә, шәһәрнең истәлекле урыннарын өйрәнергә ярдәм итә.

Балаларны гражданлык-патриотик тәрбияләүдә ата-аналар да актив катнаша, патриотик тәрбия чараларын оештырырга һәм үткәрергә ярдәм итә. Класс җитәкчесе буларак, узебез педагогик хезмәт ветераннары һәм хәрбиләр белән очрашулар уздырабыз.

Шулай итеп, максатчан һәм нәтиҗәле эш укучыларның кызыксынуын, якыннарына, гаиләләренә, Ватанга мәхәббәтен арттырырга ярдәм итә. Үз төбәгеңнең тарихын белү укучыларны рухи яктан баета, үз халкы, туган иле өчен горурлык хисе үстерә. Туган шәһәрләре буйлап экскурсияләр, музейларга чыгу укучыларга үз төбәкләре белән танышырга, үз мәдәниятләрен өйрәнергә генә түгел, ә халыкларның патриотик, хезмәт, рухи - әхлакый традицияләрен өйрәнергә һәм республика конференцияләрендә, конкурсларында, чараларында лаеклы чыгыш ясарга мөмкинлек бирә.

Һәрдаим безнең укучылар “Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!” темасына Бөтенрәсәй Форумында, республикакүләм “Хикмәтле дә, бизәкле дә туган тел”, республикакүләм “Фәнни потенциал-XXI”**,** Каюм Насыйри исемендәге Халыкара яшьләр, республикакүләм “Туган җир сулышы” фәнни – гамәли конференцияләрендә, “Халыклар дуслыгы” Халыкара фестивалендә, регионара “Туган телем - серле тел» шигырь сөйләүчеләр бәйгесендә һәм башка күп чараларда лаеклы чыгыш ясыйлар.

*Хайруллина Гөлнара Илсур кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге «1нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле*
*информатика укытучысы,*
*Апсагитова Аделя Ильяс кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге «1нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең математика укытучысы*

## Дәрестә информацион технологияләрне куллану

Соңгы елларда мәктәптә яңа педагогик технологияләр көннән-көн активрак кулланыла бара.

Бүгенге уку-укыту процессы укытучылар алдына педагогик технологияләрнең принципларына таянып эшләү, уку-укыту эшендә әлегә кадәр булган технологияләрнең барсын да теге яки бу дәрәҗәдә куллану максатларын куя. Шулар белән бергә, заман алга барган саен, бүгенге уку-укыту процессында иң әһәмиятле урынны заманча технологияләрнең берсе булган компьютер технологиясе алып тора. Хәзер әлеге технология кеше эшчәнлегенең барлык өлкәләренә дә нык үтеп керде. Бер генә белгечлекне, профессияне дә аңардан башка күз алдына китереп булмый. Мәгариф оешмаларын компьютерлаштыру – мәгариф үсешендәге өстенлекле юнәлешләрнең берсе. Шунлыктан мәктәпләр интерактив такталар, мультимедиа проектлары белән җиһазлана, дәресләрдә компьютерлар кулланыла. Башка күп кенә һөнәрләр кебек үк, укытучы һөнәре дә компьютер технологияләрен нәтиҗәле куллануны күз алдында тота. Компьютер технологиясеннән нәтиҗәле файдалану – хәзерге көндә укыту методикасының мөһим бурычы. Яңа төр эшчәнлек, компьютерны “йөгәнли белү” гә кызыксыну булдыру бәрабәренә укытуның сыйфатын күтәрүгә ирешү - әлеге технологиянең иң өстенлекле ягы. Технологик алгарыштагы һәр яңалыкка балалар сокланып карый, һәм, әлбәттә, аларның кызыксынучанлыгын һәм танып-белү активлыгын үз шәхесләренең максатчан үсешенә юнәлдерү мөһим. Нәкъ менә дәрестә укучылар укытучылары җитәкчелегендә үз интеллектларын һәрьяклап үстерү, белем алу һәм тормыш мәсьәләләрен хәл итү өчен мәгълүмат туплау максатында компьютер технологияләрен кулланырга өйрәнә.

Дәрес – уку-укыту эшчәнлегенең иң төп урыны. Нәкъ менә дәрестә укучылар укытучылары җитәкчелегендә үз интеллектларын һәрьяклап үстерү, белем алу һәм тормыш мәсьәләләрен хәл итү өчен мәгълүмат туплау максатында компьютер технологияләрен

кулланырга өйрәнә. Компьютер – бүгенге заманда белем алу өлкәсендәге максатларга ирешү, укыту процессын баету, бала шәхесе һәм укытучының һөнәри осталыгы үсешенә йогынты ясау чарасы ул. Моның өчен мөгаллимгә:

- компьютердан файдалануның үзенә хас үзенчәлекләрен педагогик әсбап буларак аңлау, аның мөмкинлекләрен һәм җитешсез якларын билгели белү;
- уку материалын аңлата алу һм укучылар белемен тикшерүнең бер ысулы буларак веб-ресурслардан файдалана белү тәбрибәсенә ия булу;
- үзең укыта торган фән укытучылары өчен тәкъдим ителгән кулланма программа һәм ярдәмлекләр белән эш итә белү алымнарын үзләштерү кирәк.

Әлеге технологияләр яңа материалны өйрәнү дәресләрендә, осталык һәм күнекмәләрне үзләштергәндә, шулай ук практик дәресләрдә яхшы нәтиҗәләр бирә.

Дәресләрдә мәгълүмати технологияләрне куллануның өстенлеге бәхәссез. Барыннан да элек, әлеге технология – шәхескә юнәлтелгән, ныклы һәм вариатив булуы белән аерылып тора. Компьютер, күрсәтмәлелекне һәм контрольлекне тәэмин итеп, күп мәгълүмат биреп, укытуның сыйфатын күтәрергә ярдәм итә, этәргеч бирә. Дәресләрдә компьютер куллануның юллары һәм ысуллары күптөрле. Шуларның берсе – электрон презентацияләр. Дәрестә кулланылган теләсә нинди визуаль мәгълүматның уңай нәтиҗәсе бар. Һәрбер укыту чарасы дәрес материалын үзләштерүгә этәргеч бирә. Шулай да мондый чаралар кулланып үткәрелгән дәресләр гадәти, укучы өчен дә, укытучы өчен дә кулай булырга, тышкы бизәкләре белән укучы дикъкатен читкә юнәлдермәскә тиеш. Кайбер дәресләрдә кәгазьдән ясалган берничә таблица яки схема күрсәтү дә җитә. Әгәр дә инде алар искергән дә булса, ул чакта электрон презентация - әлеге мәсьәләне хәл итүнең заманча һәм кулай юлы. Аны куллану урынлы, чөнки ул балаларның игътибарын читкә юнәлдертми. Электрон презентация бары даими кулланылган очракта гына уңай нәтиҗә бирәчәк, шул ук вакытта аны һәр дәрестә куллану белән дә артык мавыкмаска кирәк.

Әлеге технологияләрдә уңышлы файдалану дәреснең нәтиҗәлелеген күтәрә, укучыларның кызыксынучанлыгын арттыра, аларны белем дөньясына җәлеп итә, өлгереш күрсәткечен һәм уку сыйфатын яхшырта.

*Хәйрутдинова Фәридә Илнар кызы,*
*Татарстан республикасы Казан шәһәре*
*Идел буе районының «114 нче урта мәктәбе»*
*муниципаль белем бирү учреждениесенең тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы*

## Татарстан Бөек Ватан сугышы елларында

Сынау чоры: Татарстан Бөек Ватан сугышы елларында 1941 елның 22 июнендә фашистлар Германиясе сугыш игълан итмичә Советлар Берлегенә басып керә. Икенче

бөтендөнья сугышында катнашкан бөтен халыкларның язмышында хәлиткеч роль уйнаган Бөек Ватан сугышы башлана. Татарстан Республикасы сугышның беренче көннәреннән үк илдәге мөһим тыл базаларыннан берсенә әйләнә. Биредә сугышлар бармаса да, республика халкының җиңүгә керткән өлеше бик зур була.

**Сугыш фронтларында**

Татарстан сугышның беренче көннәреннән үк Кызыл армия өчен хәрби резервлар әзерләү үзәгенә әйләнә. Фронтның хәлиткеч участокларына республикадан 7 укчы дивизия (18, 86, 120, 146, 147, 334, 352 нче), 91 нче аерым танк бригадасы, 37 нче зенит-артиллерия полкы, ТАССР ның Югары Советы исемендәге 202 нче бомба ташлаучы авиация дивизиясе һәм башка хәрби частьлар җибәрелә. Халыкны хәрби әзерләү буенча Осовиахим, физкультура оешмалары, Кызыл Хач һәм Кызыл Ярымай җәмгыятьләре зур эш башкара. 1941 елның октябреннән Дәүләт Оборона Комитетының махсус карары белән илнең бөтен гражданнары мәҗбүри рәвештә хәрби эшкә өйрәтелә башлый. ТАССРда сугыш елларында Всеобуч курсларында 186 мең кеше хәрби белгечлек ала. Татар халкының уллары һәм кызлары Бөек Ватан сугышының бөтен хәлиткеч яуларында сугыша. Хәрәкәттәге армиягә республикадан 700 меңләп кеше алына. Шулардан 350 меңгә якыны (һәр икенчесе) Ватаныбыз азатлыгын һәм бәйсезлеген яклап сугышканда һәлак була. Аларның исемнәре 27 томлы Хәтер китабына кертелгән. Китапның максаты изге – татарстанлыларның сугышта күрсәткән батырлыкларын мәңгеләштерү, тыныч күк йөзебез өчен башларын салучыларның исемнәрен киләчәк буыннарга илтеп җиткерү.

Сугыш елларында якташларыбыз үзләрен кыю һәм курку белмәс сугышчы итеп күрсәтә. Легендар патриот-шагыйрь Муса Җәлил, Брест ныгытмасының чыдам сакчысы Петр Гаврилов, кыю очучы Мәгубә Сыртланова, төз укчы, Александр Матросов батырлыгын кабатлаган Газинур Гафиятуллин, ару-талуны белмәс сапер Мотыйк Әхмәдуллин һәм тагын бик күпләрнең исемнәре Бөек Ватан сугышы елъязмасына мәңгегә алтын хәрефләр белән язылган. Илнең иң югары бүләгенә лаек булган 11519 совет сугышчысы арасында татарлар, рус, украин һәм белоруслардан гына калышып, сан буенча 4 нче урында тора.

Әмма тормыш бер урында гына тормый бит. “Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый” өндәмәсен эшләре белән дәлилләп, тарихчылар һәм журналистлар сугыштан соң да үзләренең фәнни эзләнүләрен дәвам итә. Эзләнүләрдә студентлар да, мәктәп укучылары да катнаша. Республикада ватанпәрвәрлек хәрәкәте киң колач җәя, аның кысаларында “Кар десанты” отрядлары, “Үзән”, “Ватан” яшьләр хәрәкәтләре оештырыла. Ветераннарның варислары ел саен эзләү экспедицияләре үткәрә, архив һәм хәрби комиссариатлардагы тикшеренү эшенә тартыла, чагыштырырга һәм фикерләргә өйрәнә. Аларның фронтовиклар

истәлегенә битараф калмавы нәтиҗәсендә сугыш каһарманнарының яңадан-яңа исемнәре җәмәгатьчелек хозурына кайтарыла.

Кайбер яңа ачышлар ватан историография фәнендәге тотрыклы нигезләмәләрне тамырдан үзгәртергә дә мөмкин. Әйтик, элегрәк матбугат “рус баһадиры” дип йөрткән Александр Матросовның чынлыкта Башкортстанда туган татар егете Шакирҗан Мөхәммәтҗанов булуы бүген дәлилләнгән, рус исемен аңа Мәләкәстәге балалар йортында гына кушканнар.

Күптән түгел генә татар батыры Гази Заһитов (ул да Башкортстаннан) исеме дә хәтерсезлек чоңгылыннан кире кайтарылды – ул үзенең сугышчан дуслары белән рейхстаг өстенә тәүге Җиңү Байрагын кадаучылардан берсе. Архив чыганакларындагы мәгълүматлар буенча, аның төркеме байракны М.А.Егоров һәм М.В.Кантариядән берничә сәгатькә алданрак кадаган. Төркемгә сугышчылар Г.К.Заһитов, А.П.Бобров, А.Ф.Лисименко, М.П.Минин кергән, җитәкчесе капитан В.Н.Маков булган. Әлеге вакыйгалар турында бай документаль дәлилләр китереп язылган зур материал 1995 елда “Гасырлар авазы” (“Эхо веков”) журналында бастырылган. Әле 1994 елда ук Татарстан һәм Башкортстан җәмәгатьчелеге, чын каһарманнарга Россия Федерациясе Герое исемен бирүне дәгъвалап, тарихи хакыйкатьне торгызу буенча шактый тырышлык куйган, әмма, кызганыч ки, бу РФ Оборона министрлыгында яклау тапмаган.

Тулаем алганда, сугыштан соң үткән елларда легендар каһарманнар исемлеге шактый тулыланган. Нәтиҗәдә, соңгы мәгълүматлар буенча, Бөек Ватан сугышында катнашучы Советлар Союзы Геройлары арасында татарлар саны 179 кеше тәшкил итә. Бөек Ватан сугышы фронтларында күрсәткән батырлыклары өчен Татарстанда туган 100 меңнән артык кеше орден һәм медальләр белән бүләкләнгән. 225 кеше иң югары бүләккә – Советлар Союзы Герое Алтын Йолдызына лаек булган. Дан орденының тулы кавалеры булган 2457 кешенең 50се – республикабызда туган кешеләр. Разведчиклар Даян Булатов һәм Рифкать Гайнуллин, артиллеристлар Каюм Җаббаров һәм Николай Зотов, танкистлар Рөстәм Хәмитов һәм Павел Михеев өчәр Дан ордены белән бүләкләнгән. 26 кеше Александр Матросов һәм Газинур Гафиятуллин батырлыгын кабатлаган. Алты очучы һава

*Хәйруллина Лилия Аркадий кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче Кама Аланы 2 нче урта мәктәбе»*
*югары квалификацион категорияле*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Функциональ грамоталыкның компоненты буларак уку грамоталыгы ( эш тәҗрибәсеннән)**

Без яңача фикерләүгә игътибар бирелгән, әледән-әле яңа ачышлар ясала торган заманда яшибез. Мәгариф өлкәсендә моңа кадәр билгеле булмаган ысуллар һәм эш алымнары кулланыла, алар тагын да камилләшә бара. Укучыларның белем сыйфатын күтәрүдә заманыбыз мөгаллимнәр алдында яңа бурычлар куя. Гомуми белем бирү системасында функциональ грамоталылыкны формалаштыру өстенлекле максатларның берсе булып тора. **Функциональ яктан грамоталы** бала, төрле ситуацияләргә эләгеп, практикада мәктәптә яки кайдадыр алган белемнәрен куллана башлый, бу аңа заманча дөньяда нормаль яшәргә мөмкинлек бирә. Бу глобаль максат — тормышта аңлаешлы мәгълүматны кулланырга һәм үзеңнең белем багажыңа таянырга өйрәнү.

Функциональ грамоталылыкның һәр төре нигезендә нинди дә булса өлкәдәге белемнәр ята-математика, рус теле һәм башкалар. Шул ук вакытта алар төрле өлкәләрдә, шул исәптән яңа белемнәр алу өчен дә кулланыла. Текстны аңларга кирәк булганда, күп кенә бурычларны үтәү өчен **уку грамоталылыгы** таләп ителә. Ә аңларга, алар арасында бәйләнеш табарга, юллар арасында нәрсә яшерелгәнен аңларга уку грамоталылыгы ярдәмгә килә.

**Табигый-фәнни грамоталылыкны** үстерү өчен балалар экспериментлар ясый, тикшерә һәм сораулар бирә алырлык шартлар тудырырга кирәк. Аларда шулай ук критик фикерләүне һәм табигатьтәге төрле күренешләр һәм процесслар арасындагы бәйләнешне күрү сәләтен үстерү мөһим.

Табигый-фәнни грамоталылык физика, химия, биология һәм география буенча белемнәрне тормышта куллану белән бәйле.

**Табигый-фәнни грамоталылыкны үстерү** буенча биремнәрне үтәп, укучылары зур булмаган мавыктыргыч экспериментлар үткәрәлә.

**Математик грамоталылык** — арифметик гамәлләр генә түгел, бәлки исәпләүләр логикасын аңлау да ул: нәрсәгә нәрсәгә өстәргә, нәрсәне нәрсәдән алырга, нәрсәне нәрсәгә тапкырларга яки бүләргә. Бу мәсьәләләрдә калькулятор ярдәм итмәячәк. Моңа шулай ук мәгълүматларны анализлау һәм интерпретацияләү, проблемаларны чишү өчен математик модельләрне куллану, үз фикерләреңне дәлилләү, логик нәтиҗәләр ясау сәләте кирә.

Бала математик грамоталылыкны коймаклар өчен ингредиентларның пропорцияләрен билгеләгәндә яки әбисенә индексациядән соң пенсиясе нинди суммага үсәчәген исәпләп чыгарырга ярдәм иткәндә куллана ала.

**Финанс белеме** үз эченә финанс инструментларын һәм хезмәтләрне аңлый белүне, бюджетны планлаштыра белүне, реклама тәкъдимнәренә тәнкыйди карауны, үз финанс максатларыңны аңлауны һәм аларга ирешү турында уйлауны ала.

Финанс яктан белемле укучы, мәсәлән, бер зур пицца яки ике кечкенә пицца сатып алуның отышлырак икәнен аңлар. Ул колакчыннарга бер ай эчендә күпме акча җыярга кирәклеген белә.

**Глобаль компетенцияләр** башка кешеләр белән ихтирамлы хезмәттәшлек итү, мәдәни төрлелекне аңлау һәм бәяләү, социаль тигезсезлек, климат кризисы кебек гомумкешелек проблемаларын аңлау һәм башкалар белән бәйле.

Мәктәп укучылары өчен мөһим булган мондый компетенциянең мисалы-конфликтлы ситуацияләрдән качу һәм буллинг очрагында үзеңне ничек тотарга икәнен белү.

**Креатив фикерләү** мәсьәләне стандарт булмаган юл белән хәл итәргә мөмкинлек бирә. Мәсәлән, ярышларда җиңүчеләрне бүләкләргә кирәк. Классик чишелеш: медальләр сатып алырга һәм финалда аларны балаларга тапшырырга.

Функциональ грамоталылыкның бу төрен бәяләү аеруча катлаулы, чөнки креативлык-субъектив төшенчә. Һәм аны балага матурлык турындагы күзаллауларыңны көчләп такмыйча, саклык белән үстерергә кирәк.

Мондый биремнәрне үтәгәндә балалар икътисади төшенчәләр белән танышалар һәм иҗади сәләтләрен күрсәтәләр. Димәк, күнегү финанс грамоталылыгын һәм креатив фикерләүне үстерә.

Россиядә **компьютер, яки цифрлы, грамоталылык** функциональ грамоталыктан аерым бүленә, чөнки грамоталылыкны тикшерә һәм үлчи белергә кирәк, ә критерийлар һәркем өчен төгәл һәм аңлаешлы булырга тиеш. Аларны эшләмәгәнче, бу күнекмәләрне бәяләмиләр һәм алар аерым торалар.

Цифрлы грамоталылык компьютерда эшли белүне, мәгълүмат эзләүне, фактларны фейклардан аеруны, цифрлы инструментларга ия булуны үз эченә ала-мәсәлән, сатып алу өчен QR-кодны ничек сканерларга икәнен белү. Технологияләр гасырында мондый күнекмәләр бик файдалы.

Мәктәбебездә узара тәҗрибә белән уртаклашу нияте белән функциональ грамоталылык атнасы үткәрелде.Анда функциональ грамоталыкның һәр төренә бер көн билгеләнде. Беренче көн уку грамоталылыгы булса, икенче көн табигый-фәнни грамоталылык буенча үтте.Уку грамоталылыгы көнне сыйныф сәгатьләре барышында 5-11

сыйныфлар өчен радиодан әсәрдән өзек тыңларга тәкъдим ителде. Өзекне тыңлап һәр укучы үзенең җавапларын кәгазьләргә теркәп барды. Укучылар өзекнең нинди әсәрдән булуын,авторын билгеләргә, төп геройлары, уңай һәм тискәре геройларны табарга тиешләр иде. Һәр сыйныфтан җиңүчеләр билгеләнде.Тәнәфесләрдә укучылар өчен төрле чаралар оештырылды." Фразеологизмнар илендә", "Әйләнгечләр", "Әкият геройлары эзеннән", "Әйтемнәр-чәчәк, мәкальләр- җимеш" уеннары үтте.Дәресләрдән соң һәр сыйныф өчен төрле чараларда актив катнашты. 7 сыйныфлар өчен " Китап укысаң, кош булып очарсың" (рус теленнән) чара узды. 5 сыйныфларда квест " Һәр укучы белергә тели"(инглиз теле) , ә 6 сыйныфларда дәрестән тыш чара " Кыш бабай шуклыгы"чаралары узды.

Туган тел буенча уку грамоталылыгы көне кысаларында рус телле балалар өчен « Кыш бабай шуклыгы »темасына дәрестән тыш дәрес үткәрелде.

6 нчы сыйныф укучылары арасында ярышу характерында чара үткәрелде. Командаларга этаплап башкару өчен биремнәр язылган маршрут битләре(китапчыклар) бирелде.

1. Бирем: видео («Кышкы табигать») карау һәм караганнардан нинди хисләр кичерүне язып куегыз.

**"Ыргытылган таш"** методик алымы. Нинди алым соң ул?Сүз иҗаты аша язма һәм сөйләм телен үстерү технологиясендә кулланыш тапты. Бу ысул балаларның иҗади фикерләвен, фантазиясен үстерергә ярдәм итә, предметлар, күренешләр, вакыйгалар арасында үзара логик бәйләнеш табарга өйрәтә. Шул ук вакытта,бу алым сөйләмне баета, хәтердә образлар, чагыштырулар һәм сәнгать әйләнешләрен уята. Еш кына "Ыргытылган таш" технологиясен тема буенча инша язарга әзерләнгәндә кулланалар.

Мәсәлән , без «Кыш» темасы буенча сочинениега әзерлек эшләре алып барабыз.«Балалар күргәннәрнең тойгысын язып баралар: Кояш балкышы, кар көртләре, кар ялтыравы һ.б. Укучылар 5 сүзтезмә язарга һәм бу сүзтезмәләрне нәрсә гомумиләштергәнен анализлап, нәтиҗә ясарга тиеш. ***Нәтиҗә: Кышкы матурлык.***

2. Бирем. Рәсем тәкъдим ителә.Рәсемдәге балалар турында сүзтезмәләр төзегез. Картинаны карагыз һәм картина буенча сүзтезмәләр төзегез.

**"Фикер болыты"алымын** кулланабыз. Тасвирлама: интерактив укыту алымы.Укучылар, тукталып тормыйча, башына килгән беренче фикерне җиткерәләр. Төп характеристикалар санап үтелгәннән соң, алар кәгазь битенә языла һәм бирелгән күрсәткечләр нигезендә системалаштырыла. Мисал. Туган әдәбият дәресендә инша язучы укучыларга «фикер болытлары» – тема белән бәйле рәвештә башына килгән бөтен нәрсәне язып куярга киңәш ителә. Нииндидер мәгънәдә мондый "болытлар" инша язу өчен хезмәт итә ала. Укучыларга өйрәнелгән лексика буенча "кышкы күңел ачулар"дигән темага

картина тәкъдим ителәэ. Картинаны карап, үтелгән теманың лексикасын искә төшереп, картина буенча 5 сүзтезмә төзергә һәм язып куярга тәкъдим ителәэ. Укучылар төзелгән сүзтезмәләр буенча нәтиҗә ясыйлар, гомуми тема чыгаралар. ***Нәтиҗә: "кышкы күңел ачулар".***

3. Бирем. Өзек белән танышыгыз, игътибар белән укыгыз, биремнәрне үтәгез.

Ап-ак карлар яудырып, кабат туган якка кыш килде. Көннәр бик нык суытты, салкын җилләр исә башлады. Көннәр кыскарды, төннәр озайды.Кыр өстенә ап-ак кар ятты. Елга, күлләрне шома боз каплады. Агачлар һәм куаклар ап-ак кар бүрекләре киде

Кышның җилсез көнендә матур итеп кар ява. Ак күбәләктәй карлар, тын гына җир өстенә куналар. Ул көнне балалар өйдә утырмыйлар, тизрәк тышка чыгалар. Кар бөртекләре балаларның өс киеменә, алсу йөзләренә, кара керфекләренә куна. Балалар урамда рәхәтләнеп чанада, чаңгыда шуалар. Җепшек кардан Кар бабай ясыйлар, туйганчы кар атышып уйныйлар.

Кышкы табигать бик матур. Ул  узенең аклыгы, сафлыгы белән сокландыра.

- Бу тест нәрсә турында?
- Өзектән кыш билгеләрен язып ялыгыз? С отрывка выписать в книжечку словосочетания  относящие к теме “ Зима”.

***Нәтиҗә: Кыш билгеләре***

4. Бирем: сконвордны чишегез. Кыш белән бәйрәм предметлары табыгыз. Сконвордны чишегез: кышка караган предметларны табыгыз.

**"Шкатулка" алымы**. Тасвирлама: әдәбият дәресләрендә субъект тәҗрибәсен актуальләштерү өчен. Укытучы шкатулканы тутырырга тәкъдим итә, аңа нәрсәдер сала. Мисал. Шкатулкага барлык кышкы киемнәрне җый, бу аңа киләчәктә ярдәм итәчәк. Ә син бу вәзгыятьтә үзең өчен нәрсә салыр идең?




<u>Сконвордта кышка кагылышлы сүзләр табарга.</u>

***<u>Нәтиҗә: кышкы кием.</u>***

5. Бирем.Каралган видеоны кулланып, рәсемнәр астына төрләрен язарга.



Видеоны карагач, укучылар кышкы спорт төрләренә язып куялар һәм видеода күрсәткән , әмма рәсемдә күрсәтелмәгәннәрен китапчыкка язалар.

***Нәтиҗә: Кышкы спорт төрләре***

6. Бирем. Каралган видео, башкарылган биремнәр буенча үзегезнең фикерләрегезне модельга урнаштырыгыз. Каралганны һәм тыңланганны йомгаклап, кластер төзергә кирәк.

**«Кластер» алымы** - материалны график оештыру, үзәктә төп төшенчә языла, ә аннан бу сүзне башка төшенчәләр белән тоташтыручы уклар ясыйбыз, әдәби уку дәресләрендә әлеге эш формаларын һәм методларын кулланганда, укучыларда фикерләү күнекмәләре формалаша, алар «укучының грамоталылыгы»төшенчәсен тәшкил итә.

**7. Бирем .Кыш турында ижади фикерләребезне язагыз.** «Синквейн”

**«Синквейн " алымы** (ингл. » фикер юлы") билгеле бер схемага ия, аның буенча без төшенчәләрнең, билгеләмәләрнең, кагыйдәләрнең асылын ачабыз. Синквейн-кыска формалы, рифмасыз биш юлдан торган ижади эш ул. Ул билгеле бер кагыйдәләр буенча языла: 1 юл-синквейнның төп темасын белдерүче бер исем; 2 юл – төп фикерне белдерүче ике сыйфат; 3 юл – тема кысаларындагы гамәлләрне тасвирлаучы өч фигыль; 4 юл – билгеле бер мәгънәле җөмлә; 5 юл - исем формасындагы йомгак (беренче сүз белән ассоциация). Бишенче юлга резюме-сүз керә, ул темага яңа интерпретация бирә, синквейн авторының темага шәхси мөнәсәбәтен чагылдыра. Синквейн язу кагыйдәләрен төгәл үтәү мәҗбүри түгел. Мәсәлән, текстны яхшырту өчен дүртенче юлда — өч яки биш сүз, ә бишенче юлда ике сүз кулланырга мөмкин.

| | |
|---|---|
| Исем (существительное) | |
| 2 сыйфат (прилагательные) | |
| 3 фигыль (глагол) | |
| Җөмлә (предложение) | |
| Сүз (слово) | |

8. Бирем. Алынган мәгълүматтан файдаланып, кыш турында 7-8 җөмлә төзергә. Төркемдә эшлиләр, бер укучы төзелгән текстны сөйли. **“Ромашка” алымы**




Дәрестән тыш чара ахырында башкарылган эшләргә йомгак ясала. Урыннар билгеләнә, укучылар Кыш бабайдан грамоталар һәм татлы бүләкләр кабул итә.

Креатив фикер йөртергә,уйларга өйрәнгән бала күбрәк иҗатка тартыла,андый баланың башына күбрәк матур фикер килә башлый.Әгәр балага бер генә китапның, бер генә әсәрнең матурлыгын,фикер тирәнлеген күрсәтә алсаң, аны мәңгегә китап укуны яратырлык, китап дөньясында йөзәрлек итеп тәрбияләргә мөмкин.Китап укыган баланың язу һәм сөйләм теле дә камил,эзлекле,тирән була.

*Хакимова Рамзия Риф кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 10 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Туган тел дәресләрендә функциональ грамоталылык.**

Укучыларның функциональ грамоталылыгын формалаштыру проблемасы соңгы елларда аеруча актуаль һәм әһәмияткә ия.

Функциональ грамоталылык нәрсә соң ул?

Функциональ грамоталылык-ул мәктәптә алган белемнәрне, көндәлек мәсьәләләрне хәл итү өчен куллану сәләте. Мәгълүматны аңлау һәм аның киләчәктә ни өчен кирәк булачагын аңлау мөһим.Туган тел һәм әдәбият дәресләрендә без тел функциональ грамоталылыгын да формалаштырабыз.

Укучының функциональ грамоталылыгы-кешенең текстны аңлау, тексттан мәгълүмат куллану, текстларны бәяләү, алар турында уйлану һәм үз максатларына ирешү, белемнәрен һәм мөмкинлекләрен киңәйтү, социаль тормышта катнашу өчен уку белән шөгыльләнү сәләте булдыру.

Укучыларның функциональ грамоталылыгы турында без күптән ишетеп беләбез һәм аны һәр дәрестә, текст белән эшләгәндә, шулай ук уку дәресләрендә формалаштырабыз. Әгәр киләчәктә безнең чыгарылыш укучысы инструкцияләрне аңлый яки төзелә торган килешү шартларын дөрес аңлый алса, димәк, мәктәптә функциональ уку грамоталылыгы формалаштырылган! Укучы инструкцияне дөрес һәм грамоталы итеп формалаштырып төзи алса яки эшкә урнашканда әңгәмәне уңышлы уза алса, димәк, аның тел функциональ грамоталылыгы формалаштырылган дигән суз.

Тел функциональ грамоталылыгы нәрсә ул һәм ул мәктәптә ничек формалаша? Тел функциональ грамоталылыгы-сөйләм культурасының норматив, эстетик һәм этик аспектларын белү ул. Сөйләм культурасы, тел культурасы — Совет һәм Россия лингвистикасында киң таралган, Телдән һәм язма телнең тел нормасына ия булуны, шулай ук «төрле аралашу шартларында сәнгатьле тел чараларын куллана белүне» берләштерә торган төшенчә икәнен искә төшерү урынлы булыр.

Тел функциональ грамоталылыгының формалашуы:

- аралашу максатларын тормышка ашыру өчен тел фактларыннан файдалана белү;
- хәзерге рус теленең нормаларын (орфоэпик, морфологик, сүз ясалышы, синтаксик һәм стилистик) үтәү;

- теге яисә бу сөйләм берәмлекләрен куллануны җайга сала торган конкрет социаль шартларга хас этикет нормаларын, сөйләм тәртибе кагыйдәләрен үтәү;

- тел чаралары ярдәмендә үз фикерләреңне дөрес белдерә белү, конфликтларны сүз ярдәмендә хәл итү;

- лингвистик мәгълүмат белән эшли белү, алган белемнәрне тормышта куллану.

- тел чаралары ярдәмендә үз фикерләреңне дөрес белдерә белү, конфликтларны сүз ярдәмендә хәл итү;

- лингвистик мәгълүмат белән эшли белү, алган белемнәрне тормышта куллану.

Әгәр дә без югарыда санап үтелгәннәрнең барысын да анализласак, бу белем һәм күнекмәләр УУД белән чагыштырыла, алар ФГОС таләпләре булып тора, дигән нәтиҗәгә килербез.

Шулай итеп, әгәр без РФ Мәгариф һәм Мәдәният министрлыгының урта гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартын раслау турындагы 413 нче боерыгы нигезендә эшләсәк, тел функциональ грамоталылыгын формалаштырачакбыз. Бернинди яңалык уйлап тапмыйча, бары тик инновацион белем бирү технологияләрен кулланып кына, без функциональ грамоталылыкны, шул исәптән тел белемен дә формалаштырабыз.

Югарыда санап үтелгән нәтиҗәләргә ирешергә укытучыга заманча инновацион технологияләр куллану ярдәм итәчәк, алар укучыларга яңа социаль тәҗрибәне аңлап һәм эшлекле үзләштерү юлы белән үз-үзләрен үстерергә, үз-үзләрен камилләштерергә, үз-үзләрен тормышка ашырырга мөмкинлек бирәчәк.

Үзебезнең педагогик практикабызда төрле инновацион технологияләрне: проект-тикшеренү эшчәнлеге технологияләрен, үстерешле укыту технологияләрен, мәгълүмат-коммуникация технологияләрен, проблемалы укыту технологияләрен, уен технологияләрен, тәнкыйди фикерләү технологияләрен һәм башкаларны актив кулланабыз.

Мин 5-9 сыйныфларда эшлим, рус теле һәм әдәбияты дәресләре алып барам. Китап авторлары: Александрова Ольга Макаровна, Загоровская Ольга Владимировна, Богданов Сергей Игоревич,2023, Русский родной язык

6 нчы сыйныфлар өчен темалар:

1 бүлек. **Тел һәм мәдәният** (20 сәгать).

Рус әдәби теленең кыскача тарихы.

Рус теле үсешендә чиркәү славян теле (иске славян) теленең роле.

Диалектизмнарның милли-мәдәни үзенчәлеге.

Диалектлар халык мәдәниятенең бер өлеше буларак.

Көнкүреш предметларының диалект исемнәре, сүзләрнең мәгънәләре, әдәби телгә хас булмаган төшенчәләр турында белешмәләр

Матур әдәбият әсәрләрендә диалекталь сузләр.

Рус теленнән Россия халкы телләреннән алынган лексика.

Славян һәм славян булмаган телләрдән кергэ алынмалар. Алынмаларның сәбәпләре.

Чит тел ликасын үзләштерү үзенчәлекләре

Хәзерге рус телендәге алынма лексикасының роле.

Проект эше. Хәзерге рус телендә алынмаларның роле һәм урынлылыгы.

Рус теленең сүзлек составын яңа сузлэр белән тулыландырылуы.

Рус телендә неологизмнар

Неологизмнар төркемнәре.

Рус фразеологиясенең милли-мәдәни үзенчәлеге. Фразеологизмнарның тарихи прототиплары.

Фразеологиядә гореф-гадәтләрнең, традицияләрнең, көнкүрешнең, тарихи вакыйгаларның, мәдәнияттә чагылышы.

Практик эш. Фразеологизмнарнын чыганаклары.

Контроль эш.

2 бүлек **Сөйләм культурасы**-20 сәг

Хәзерге рус әдәби теленең төп орфоэпик нормалары.

Рус телендә сөйләм темпына бәйле әйтелеш аермалары.

Әйтелешнең һәм басымның стилистик үзенчәлекләре

Аерым грамматик формаларны әйтү нормалары.

Фигыльләрдә, сыйфатларның кыска формаларында басым.

Хәзерге рус әдәби теленең төп лексик нормалары. Синонимнар һәм сөйләм төгәллеге.

Синонимнарны куллануның мәгънәви стилистик үзенчәлекләре.

Антонимнар һәм сөйләм төгәллеге.

Антонимнарны куллануның мәгънәви стилистик үзенчәлекләре.

Лексик омонимнар һәм сөйләм төгәллеге.

Лексик омонимнарны куллануның мәгънәви стилистик үзенчәлекләре.

Антонимнарның һәм омонимнарның куллануга бәйле типик сөйләм хаталары

Практик эш. Рус фольклорында антонимнар һәм синонимнар

Хәзерге рус әдәби теленең төп грамматик нормалары. Төрләнеш категориясе.

Алмашлыкларның, саннарның төрләнеше

Исемнәрнең норматив һәм норматив булмаган формалары.

Сөйләмдә типик грамматик хаталар.

Исем, сыйфат формаларын куллану нормалары.

Фигыль формаларын, төрле грамматик конструкцияләрне куллану нормалары

Исемнәрнең әдәби һәм сөйләм килеш формалары.

Сөйләм этикеты. Сөйләм этикетының милли үзенчәлекләре. Этикетлы аралашу принциплары.

Этика һәм сөйләм этикеты

Аралаша башлануынын һәм тәмамлануының этикет формулалары.

Этикет формалары, Рәхмәт хатлары, мактау сүзләре.

Теләктәшлек һәм юанычлы этикет формалары

Проект эше. »Ораторга зарарлы киңәшләр"

3 Бүлек **Сөйләм. Сөйләм эшчәнлеге.Текст.** (21сәг)

Тел һәм сөйләм. Сөйләм эшчәнлеге төрләре

Укуның нәтиҗәле алымнары. Эшнең текст алды, текст һәм аннан соңгы этаплары.

Текст тел һәм сөйләм берәмлеге буларак. Текст, текстның тематик бердәмлеге.

Тасвирлау тибындагы текстлар: билгеләмә, билгеләмә, асылда тасвирлама, аңлатма

Практик эш. Тасвирлау характерындагы текст язу

Телнең функциональ төрләре

Сөйләшү сөйләме. Вакыйга турында хикәя, «бывальщины».

Укыту-фәнни стиль.

Сүзлек мәкаләсе, аның төзелеше.

Фәнни хәбәр, аның структурасы.

Уку-укыту хәбәренең эчтәлеге һәм төзелеше.

Телдән җавап биру структурас

Җавапларның төрле формалары.

Уку-укыту хәбәренең төрле өлешләрендә кулланыла торган тел чаралары.

Компьютерда тәкъдир итү.

Практик эш. Компьютер презентациясен булдыру

Тыңлаучыларга презентация ясау һәм күрсәтүнең төп чаралары һәм кагыйдәләре.

Публицистик стиль.

Телдән чыгыш.

Матур әдәбият теле.

Контроль эш. Үтелгән темалар буенча Тест.

Кешенең тышкы кыяфәтен тасвирлау.

Практик эш. Рус халык әкиятләрендә кешенең тасвирламасы.

Шулай итеп, «рус теле» курсы Федераль дәүләт белем бирү стандартының төп нигезләмәләренә туры китереп эшләнгән һәм укучының функциональ тел белемен үстерүгә,

барыннан да элек, предмет белемнәрен, төшенчәләрен, предметның әйдәп баручы идеяләрен үзләштерүгә юнәлдерелгән дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

Проблемалы ситуацияләр тудыру иң яраткан һәм еш кулланыла торган алымнарның берсе булып тора. Укучы үз максатын формалаштырсын һәм үзләштерсен өчен, аны белемнәре һәм сәләтләре кытлыгын ачыклаган ситуация белән очрашырга кирәк. Бу очракта максат аларга проблема буларак кабул ителәчәк.

Проблемалы ситуацияләр тудыру алымнары төрлечә булырга мөмкин. Теге яки бу алымны сайлау уку материалының эчтәлеге, әлеге дәреснең максаты белән билгеләнә.

**Дәреснең максатына чыгыгыз.**

Укыту предметы күзлегеннән караганда иң эчтәлекле максатларны укытучы тактага язып куярга тиеш, укучылар аларны дәфтәрләренә язып куялар, бу исә үз максатларын куя алмаган укучыларның игътибарын җәлеп итәчәк. Максатларны билгеләү укытучыга дәрес дәвамында һәм дәрес ахырында аларга мөрәҗәгать итәргә, аларның казанышларын анализларга мөмкинлек бирә.

Дәрес азагында бу максатка кире кайтырга һәм укучыларга дәрестә нәрсә эшли алуларын анализларга гына түгел, ә максатларына ирешкәннәрен күрергә дә тәкъдим итәргә кирәк, ә шуңа бәйле рәвештә – өй эше формалаштырыла.

«Җавапларның төрле формалары»темасы

1. Аларны нинди билге буенча аерып була?

2. Монолог төзегез.

3. Сезне нәрсә борчый?

4. Сез ничек уйлыйсыз? Нигә?

5.Дәреснең төп соравын әйтегез

Һәм без **өй эшләренә яңа караш тәкъдим итәбез.**

Тел белемен үстерүгә өй эшләре дә ярдәм итәргә тиеш. Элек кулланылган өй эшләре формалары (Параграфны өйрәнү, күнегүләр башкару) икенче планга күчә. Бу «туган рус теле» һәм «туган рус әдәбияты»укыту предметларына гына кагылмый.

Өй эше формалары барлык предметлар өчен дә универсаль булырга мөмкин. Мондый формалар универсаль уку-укыту гамәлләрен үстерә, алар арасында бирелгән темага телдән һәм язмача әйтелмәләр төзергә әзер булу, алынган мәгълүматны эшкәртә, үзләштерә һәм куллана белү төп роль уйный. Аларның кайберләрен санап китик.

1. Монда «**шпаргалкалар конкурсы**»үткәрү урынлы булачак.

Шпаргалкалар конкурсы-укыту эше формасы, аны әзерләү процессында билгеле бер чикләү шартларында «мәгълүматны төрү һәм җәелдерү» күнекмәләре эшләнә. Бу конкурс

болай үткәрелә. Теманы өйрәнә башлагач, укытучы конкурс башлануын игълан итә һәм аның шартларын әйтә. Укучы өйдә әзерләнгән «шпаргалка» буенча җавап бирә ала, әгәр:

1)» шпаргалка " А4 форматындагы кәгазь битенә язылган;

2) шпаргалкада текст юк, ә мәгълүмат аерым сүзләр, шартлы билгеләр, схематик рәсемнәр, уклар, бер-берсенә карата мәгълүмат берәмлекләренең урнашуыннан гыйбарәт.;

3) сүзләр һәм башка мәгълүмат берәмлекләре саны кабул ителгән шартларга туры килә (мәсәлән, биттә 10 сүздән, өч шартлы тамгадан, җиде ук яисә сызыктан артык булмаска мөмкин);

4) укучы үз шпаргалкасы буенча дөрес бәйләнешле җавап бирә алачак.

Иң яхшы «шпаргалкалар» дәрестә кулланылган саен стендка эленә. Теманы өйрәнү азагында нәтиҗәләр ясала.

Өй эшләре торле вариатта булырга, мәктәп укучысының сәләтен, мәнфәгатьләрен исәпкә ала торган булырга тиеш. Мәсәлән, укучыга үзенә кызык булмаган нәрсәне көчләп тагарга ярамый (мәсәлән, Ода яки сценарий язарга, укыганны иллюстрацияләргә һ.б.). Шуны да истә тотарга кирәк, балалар бер үк биремне төрлечә үти алалар. Мәсәлән, бер укучыга күнегүне башкару өчен биш минут, ә икенчесенә егерме минут вакыт кирәк булачак.

Укучыларның игътибарын активлаштыра торган универсаль алым – «**хата тап**» алымы. Ул мәгълүматны анализлый белүне; стандарт булмаган ситуациядә белемнәрне куллана белүне; алынган мәгълүматны тәнкыйди бәяли белүне формалаштыра.

Соңрак укытучы, балаларны кисәтмичә, аңлы рәвештә хаталар ясый, һәм иң игътибарлылары аларны табалар, үз сайлауларын нигезлиләр һәм «5»белән бүләкләнәләр!

Бу өйрәнелә торган тема буенча биремле текстлар булырга мөмкин, ләкин аларда Орфографик, пунктуацион, сөйләм, стилистик хаталар да җибәрелгән. Балаларга башта текстны яки җөмләләрне төзәтергә туры килә, аннары гына дәрес темасы буенча текст белән эшләргә туры килә.

Укытучының «хәйләләренә " күнеккән игътибарлы балалар сөйләм хаталарын шунда ук күрәчәк. Шулай итеп, әлеге күнегүне башкарып, без теманы эшкәртеп кенә калмыйбыз, тел белемен дә формалаштырабыз.

Паронимнар белән эшне оештыру урынлы булачак.

Телнең функциональ грамоталылыгын формалаштыруның иң мөһим бурычы булып укучыларның теге яки бу сөйләм берәмлекләрен куллануны җайга сала торган конкрет социаль шартларга хас этикет нормаларын, сөйләм тәртибе кагыйдәләрен үтәве; тел чаралары ярдәмендә үз фикерләрен дөрес белдерә белүе тора.

Тормышта безнең һәркайсыбыз аңламаучанлык белән очраша һәм конфликтка үз теләге белән дә катнашмый. Күптән аңлашыла кебек, конфликтларны сүз белән хәл итү —

проблема турында фикер алышу, үз фикереңне әйтү, әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлау, компромисска ризалашу яхшырак. Ләкин барыбер синең тирәндә агрессиядән һәм кул тиюдән башка булмый дип ышанган кешеләр кала. Аларга физик көч кулланырга теләмәү — йомшаклык билгесе кебек тоела. Без еш кына кешенең ни өчен ачуланышуларны һәм аңлашылмаучанлыкларны тыныч кына, йодрыклар кулланмыйча, сүз ярдәмендә җайга салырга өйрәнергә тиешлеге турында сөйлибез. Әдәбият һәм сөйләм үсеше дәресләрендә **конфликтларны чишү алымын** кулланабыз.

*Һадиева Сиринә Әсхәт кызы,*
*Ильина Зоя Евдоким кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «А.А. Шаповалов исемендәге 31нче лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле туган тел һәм әдәбияты укытучылары*

### *Сәхнәләштерү эшчәнлеге аша балаларның сөйләм телен үстерү*

Хәерле көн хөрмәтле коллегалар! Бугенге көндә балаларның туган телдә бәйләнешле сөйләмнәре түбән булуы - хәзерге заман педагогикасында иң актуаль һәм катлаулы **проблемаларның** берсе булып тора**.**

**Сәбәбе**: безнең гомуми компьютерлаштыру гасырында өлкәннәр балалар белән компьютер, планшетлар, телефоннар аша эш итә. Ә китап арткы планга күчә. Безгә, укытучыларга, баланы нәкъ менә матур әдәбият белән кызыксындыру өчен күп көч куярга туры килә. Биредә сәхнәләштерү эшчәнлеге ярдәмгә килә.

Акыл үсеше белән сөйләм теленең үсеше нык бәйләнгән. Сәхнәләштерелгән уеннар сөйләм теле үсешенә нык тәэсир итә. Башкарылачак роль баланың чиста, аңлашылырлык итеп сөйләвен таләп итә. Сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәнү барышында, сизелмичә дә баланың сүз байлыгы арта, ул чиста, дөрес, аңлаешлы итеп сөйләргә өйрәнә. Сүзлек запасы формалаша- яңа сүзләр белән баетыла. Шулай ук аваз культурасы өстендә эшләнелә. Сәхнәләштергән уеннар аша хәтере үсә, ныгый. Рольне уйный-уйный, бала әкият дөньясына кереп китә, аңа татар телендәге сүзләрне истә калдыру да җиңеләя.

Менә шуңа күрә дә дәресләребездә сәхнәләштерү эшчәнлегенә зур әһәмият бирәбез. Укучылар да сәхнәләштерелгән уеннарда бик теләп катнашалар. Ләкин шөгыльләнә башлаганда кыенлыклар, каршылыклар да булып алды. Монда безнең ике проблема килеп чыкты:

- һәр балага рольләр житмәде - нишләргә?
- тискәре рольләрне уйнарга теләүче булмады.

Беренче проблеманы балаларны төркемнәргә бүлеп чишәбез яки барлык бала да катнаша алырлык уеннар уйлыйбыз. Ә икенчесен аңлату юлы белән чишәбез: әкияттә, сәхнәдә барысы да артистлар. Ә артист уңай рольне дә, тискәре рольне дә уйный белергә тиеш. Тискәре рольне уйнау күпкә катлаулырак та әле.

Балалар белән эшләгәндә, без аларның матур костюмнарга, әкият геройларына, битлекләргә кызыкканнарына игътибар иттек. Кием алмаштырып үзгәрү алар өчен бик күңелле күренеш. Шуннан файдаланып, аларда сәхнәләштерелгән уеннарга кызыксыну уяту теләге белән, эчтәлеге зур булмаган әкиятләрне курчаклар белән күрсәтә башладык. Балалар әкияттәге аерым фразаларны бик теләп кабатлый башладылар. Әкренләп алар кыска шигырьләр, әкиятләр өйрәнү процессына күчтеләр. Салмак кына балаларда актив сөйләм, уен осталыклары барлыкка килде (мимика, ишарә, төрле көчтәге тавыш куллана башладылар).

Сәхнәләштерү аша укучылар төрле халыкларның милли костюмнары турында да байтак кызыклы мәгълүмат алалар. Былтыргы уку елында татар теле декадасы кысаларында милли костюмнар күргәзмә-экспозициясе уңышлы гына узды. Укучылар берничә экспозиция тәкъдим иттеләр, алар безне төрле халыкларның милли костюмнары белән таныштырдылар. Дефиле аеруча кызыксыну уятты.

Бөек татар шагыйре Г.Тукайның туган көне уңаеннан лицеебызда ачык дәресләр вакытында рус телле укучыларыбыз татар телен кызыксынып һәм теләп өйрәнүләрен һәрвакыт күрсәтеп торалар. Тукай әсәрләрен яратып сәхнәләштерәбез. Күрсәтмәлелек итеп милли киемнәр тәкъдим ителә.

Үскән саен, балаларның сәхнәләштерү уеннарына кызыкынулары артты. Беренче спектаклебез балаларның үзләре өчен бик зур бәйрәм булды, алар матур татар киемнәрен киделәр, чиккән ашъяулыклар, сөлгеләр, самоварлар белән сәхнә бизәп, бик теләп уйнадылар.

Быел зуррак сәхнәгә чыгарга булдык, 38 нче лицейда балалар һәм яшүсмерләр театрларының татар телендә «Йолдызлы сәхнә» муниципаль фестивалендә Бөек Ватан сугышы темасына тамаша кылып икенче урын яулап кайттык. Балалар бик кәнагәть булып калдылар. Шуны әйтәсебез килә, чынлап та, сәхнәләштерү уеннары балаларның интонацияләрен яхшыртырга, башка катнашучылар белән аралашу осталыкларын артырырга ярдәм итә, килешү, конфликтлы ситуацияләрне чишә белергә өйрәтә.

*Хазиева Лилия Джаудат кызы,*
*Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль*
*районының «20 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе»*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү*
*учреждениесенең югары категорияле*
*туган тел һәм әдәбияты укытучысы,*
*Хузина Эльза Айрат кызы,*
*Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль*
*районының «20 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе»*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү*
*учреждениесенең беренче категорияле*
*чит теле укытучысы*

**Яшь буынга патриотизм тәрбияләүдә милли традицияләрнең роле**

Бүгенге көндә даими рәвештә балаларга патриотик тәрбия бирүгә игътибар арта бара, шуның өчен дәрестә дә, класстан тыш эшләрдә дә милли горурлык, патриотик хисләр тәрбияләү максаты куела.Яшь буынга патриотик тәрбия бирү мәктәптә һәрвакыт игътибар үзәгендә тора.Ул иң элек укучыларда туган илгә һәм туган җиргә карата мәхәббәт тәрбияләүне, патриотизмны күздә тота.

Патриотизм нәрсә ул?

Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә:

“Патриотизм - ул үз илеңне, халкыңны өзелеп ярату һәм үз Ватаның өчен армый – талмый көрәшергә әзер тору. Патриотизм-гасырлар буе тәрбияләнеп килгән тирән хис”- дигән мәгънәдә. Бүгенге көндә безнең алда торган мөһим бурычларның берсе– тормышка әзер булган, үз Ватанына чын күңелдән бирелгән Кеше,Гражданин һәм Патриот тәрбияләү.Ә кем соң ул патриот?

Патриот – үзенең туган җирен, халкын, Ватанын сөюче, шулар өчен һәртөрле корбаннарга да әзер булган кеше. Җәмгыятьнең мораль кризис кичерүе, әхлак нормаларының таркала баруы, игелек, мәрхәмәтлелек сыйфатларының кими баруы яшьләргә тискәре йогынты ясый. Хәзерге балаларга совет чоры әсәрләрен, бигрәк тә патриотик рухта язылганнарыннарын аңлау кыенлашты. Ләкин җәмгыять ничек кенә үзгәрмәсен, кеше яхшы белән начарны, ак белән караны, бөеклек белән түбәнлекне аерырга, үз иленең гражданины, патриоты булып үсәргә тиеш.Чөнки бәхетле тормышны үз илебездә үзебезгә төзергә туры киләчәк.

Татар телендә заманча белем бирүче мәктәпләрнең төп бурычы – Туган ягыңа, туфрагыңа һәм халкыңа карата хөрмәт, мәхәббәт хисе уяту, шулар нигезендә балаларны

тәрбияләү ул. Белем бирү системасында халкыбызның йолаларын, традицияләрен саклауны этнокультура компонентын кертү юлы белән тормышка ашыру мөһим. Укучыларны тәрбияләүдә халкыбызның борынгы гореф-гадәтләрен, йолаларын һәм бәйрәмнәрен өйрәтү мөһим чараларның берсе булып тора. Безнең мәктәптә дә бу эшкә аеруча зур игътибар бирелә. Эшчәнлекнең нәтиҗәсе дә күз алдында – даими оештырылган чараларда балалар туган телдә шигырьләр сөйли, җырлый, милли биюләр башкара. Ул гына да түгел, менә инде берничә ел рәттән әлеге балалар төрле бәйгеләрдә дә уңышлы катнашып килә.

Дөньяга караш, рухи кыйммәтләр үзгәрсә дә, Ватанны саклау төшенчәсе үзгәрешсез кала. Әтиләре, абыйлары, бабалары кебек үк бүгенге буын егетләре дә лаеклы рәвештә ил алдындагы изге бурычларын үтәргә тиеш. Шунысы да бар: егетнең хәрби хезмәткә китүе аның сәламәт, көчле булуын күрсәтә. Хезмәт итү чорында җитди сынаулар үтеп, тормыш тәҗрибәсе туплап, солдат егет физик яктан гына түгел, ә рухи яктан да ныгып кайта.Мәктәбебездә без һәрдаим шушы темага багышланган кичәләр,очрашулар үткәреп торабыз.Муса Җәлилнең туган көненә багышлап төрле кичәләр,очрашулар үткәрәбез. Кинофильмнар карау ,махсус чакырылган кунаклар белән очрашу да, балаларда үз илләренә хөрмәт,ватанпәрварлек хисләре тәрбияли. Уңышлы эшчәнлекнең нигезен бердәмлек тәшкил итә. Безнең 20 мәктәп укытучылары,нинди фәнне укытуларына карамастан, һәрвакыт бер-берсенә ярдәм кулы сузып, барлык эшләрне бергәләп башкара. Тәрбия эшендә Ватан темасы үлемсез. Ватан – халыкның тарихи үсеш үзенчәлекләре, үзенең теле, мәдәнияте, көнкүреше, гореф - гадәтләре һәм традицияләре белән бергә яши торган тарихи җире.” Ватан - кеше үзе туган һәм шуның гражданины булган ил, туган ил, кешенең туган ягы, туган җире”. Республикабызда яшәүче төрле милләт халыкларының гореф-гадәтләрен, йолаларын, бәйрәмнәрен саклау, тергезү, киләсе буынга тапшыру буенча да биредә эш җайга салынган. Берсен-берсе алыштырып торучы төрле чаралар да – шуңа ачык мисал.Бүген тәрбия эшендә милли төбәк компоненты киң кулланыла. Ул түбәндәге юнәлешләрдән гыйбарәт:

• халыкның рухи-әхлакый кыйммәтләре белән тулы һәм тирәнтен таныштыру максатыннан, тәрбия эшен туган телдә (рус, татар, чуваш телендә һ.б. телләрдә) оештыру; • туган якның тарихы, мәдәнияте, халыкның гореф-гадәтләре, милли уеннары, бәйрәмнәр • тәрбия системасында халыкның тормыш рәвешен өйрәнү; аучылык, терлекчелек, җәнлек үрчетү, халык һөнәрчелеге профильләре буенча төпле белем һәм күнекмә бирүгә ирешү;

• балаларның физик һәм әхлакый сәламәтлеген ныгытуда гаиләнең иң мөһим роль уйнавын төшендерү. Йорт һәм гаилә — иң әһәмиятле тәрбия чыганагы. Иҗади эшләүче педагогик коллективларның тәҗрибәсе күрсәткәнчә, яшь буынга заман таләп иткәнчә белем һәм тәрбия бирү өчен мәктәп үз эшчәнлеген өр-яңадан үзгәртеп корырга тиеш.

Укучыларга патриотик - әхлак тәрбиясе бирүдә татар теле һәм әдәбияты укытучылары тарафыннан зур эш алып барыла. Без дә үзебезнең педагогик эшчәнлегебездә, дәресләрдә һәм дәресләрдән тыш чараларда укучыларны патриотик рухта тәрбияләргә тырышабыз. Укучыларда милли горурлык, патриотлык хисләре тәрбияләү максатын куябыз. Кайсы язучыны, аның кайсы гына әсәрен алсаң да, патриотик рух ярылып ята - туган җирне, туган халкыңны ,туган илеңне, әти- әниеңне ярату, хөрмәт итү һ.б. Ватанпәрвәрлек тәрбияләү - сугыш һәм хезмәт геройлары, талантлы язучылар, дәүләт эшлеклеләре һ.б. мисалында алып барабыз . Туган як тарихын, аның кешеләре язмышын өйрәнү максатыннан “Туган ягым – яшел бишек”,”Шәһәрем чишмәләре” дигән кичәләр оештырдык. Бу кичәдә балалар туган шәһәребезнең тарихы, шушы җирлектән чыккан күренекле шәхесләребез , шагыйрьләр,күренекле шәхесләребезнең тормыш юлы, иҗаты белән таныштылар. Президентыбыз В.В.Путин инициативасы белән гамәлгә куелган “Разговоры о важном”, уңышлы эшләп килүче “Тормыш дәресләре” проектлары да патриотик тәрбия эшендә зур ярдәм итә, аны тагын да тулыландыра.Үз гаиләсен,туганнарын,укытучысын,Ватанын хөрмәт иткән, авырлыкларны җиңә белгән шәхес тәрбияләү- безнең изге бурычыбыз!

*Шайдуллина Миләүшә Рафаил кызы,*
*Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Кукмара шәһәре алтынчы номерлы «Салават күпере» гомумүсеш төрендәге балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесенең югары категорияле тәрбияче*

**Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны патриотик тәрбияләүгә заманча якын килү.**

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга патриотик тәрбия бирү - бүгенге Россия шартларында актуаль проблема. Актуальлек шунда ки, заманча балалар туган шәһәре, иле, халык традицияләренең үзенчәлекләре турында аз беләләр, еш кына якын кешеләренә битараф булалар, чит кайгыны сирәк уртаклашалар. Федераль программаның максаты балага кече яшьтән ук, баланың яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алып, Россия халкының рухи-әхлакый кыйммәтләре, тарихи һәм милли - мәдәни традицияләр нигезендә тәрбия бирү тора.

Патриотик тәрбиянең төп шарты - балаларны туган як тарихы белән таныштыру.

Туган якның тарихы, табигате, гореф-гадәтләре, иң яхшы кешеләре белән балалар никадәр иртәрәк танышсалар, туган якка мәхәббәт шулкадәр тирәнерәк була.

Академик Д. С. Лихачев болай ди: “Әгәр кеше әти-әнисенең иске фотосурәтләренә сирәк кенә булса да карарга яратмый икән, алар турындагы истәлекне, алар үстергән, аларныкы

булган әйберләрне яратмый икән, димәк, ул аларны яратмый. Әгәр кеше иске, начар булсада урамнарны яратмый икән, димәк, аның үз шәһәренә мәхәббәте юк. Әгәр дә кеше үз иленең тарихына, һәйкәлләренә битараф булса, - ул, кагыйдә буларак, үз иленә битараф”.

Шуңа күрә баланың инде мәктәпкәчә яшьтә үк туган җире һәм аның киләчәге өчен шәхси җаваплылыкны тоюы мөһим. Бу мәсьәләләрнең барысын да исәпкә алып, без «Минем Кукмара шәһәре: кичә, бүген, иртәгә» видеопроектын эшләтеп җибәрдек.

Әлеге видеопроектның максаты - балаларда Ватанга, Кукмара шәһәренә һәм аның тарихына мәхәббәт формалаштыру, шәһәр язмышы өчен җаваплылык хисе, аның иминлеге өчен хезмәт итү, аның байлыкларын саклау һәм арттыру хисе тәрбияләү, балаларда халык мәдәниятенә һәм традицияләренә карата кызыксыну уяту.

Проект өч этапны үз эченә ала: әзерлек, төп, йомгаклау. Йомгаклау этабында без әти-әниләр белән берлектә Кукмара тарихы турында видеоролик төзедек, ул өч өлешкә бүленде. Фото һәм видеоматериаллар эзләүдә безгә музей, китапханә хезмәткәрләре, әти-әниләр ярдәм итте.

1 өлеш. Инкыйлабка кадәр булган Кукмара тарихы.

2 өлеш. Кукмараның сугыш алды һәм сугыш еллары. Бу юнәлештәге эш дәверендә "Геройларны искә төшерик" хәрби фотогалереясы булдырылды. Анда бездә тәрбияләнүче балаларның Бөек Ватан сугышы чорында сугышкан һәм хезмәт куйган, әби- бабаларының фотолары тупланды.

3 өлеш. Кукмарам - минем туган ягым. Биредә безнең заманча шәһәрнең тарихы өйрәнелде. Махсус хәрби операция каһарманнарына аерым игътибар бирелде. Балалар белән берлектә бакчабызның һәлак булган укучыларының биографиясен өйрәнелде. Алар турында видеоальбомнар булдырылды. Бу эш хәзерге көндә дә дәвам итә. Безнең игътибардан читтә калган яңа мәгълүмәтләр тупланыла.

*Якупова Венера Бәдертдин кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «29нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Патриотик тәрбия бирүдә милли традицияләрнең роле

Патриотик тәрбия ул – кешенең үз Ватанына, туган иленә, тарихына, мәдәниятенә, гореф-гадәтләренә карата хөрмәт, ярату һәм горурлык хисләрен тәрбияләүгә юнәлтелгән педагогик процесс. Патриотик тәрбиянең төп максаты – җәмгыятьнең тулы хокуклы, актив һәм җаваплы әгъзасы буларак, үзенең гражданлык бурычын аңлаган шәхес тәрбияләү.

Хәзерге шартларда патриотизм – бер яктан, Ватанга тугрылык, икенче яктан, Россия составына керүче һәр халыкның мәдәни үзенчәлеген саклау ул. Нәкъ менә хәзер, хәзерге заманда кешеләрдә патриотлык, рухилык, шәфкатьлелек, кешелеклелек хисләрен яңартырга кирәклеге кискенләшә. Глобальләшү чорында, үз мәдәниятеңне, үз халкыңны саклап калу һәм киләчәк буыннарга тапшыру өчен, патриотик тәрбиянең роле бик зур.

Патриотик тәрбия юнәлешләренең асылына күз салыйк :

- Ватанга мәхәббәт һәм тугрылык тәрбияләү: бу юнәлеш үз эченә туган як табигатенә, җиренә, шәһәр-авылларына карата җирсү хисләр, ярату, Ватанның тарихи үткәнен, батырлык үрнәкләрен белүне һәм хөрмәт итүне, аның бүгенге казанышлары белән горурлануны таләп итә.
- Гражданлык хисләре тәрбияләү: бу юнәлеш үз эченә үз иленең Конституциясен, законнарын белүне, гражданлык хокукларын һәм бурычларын аңлауны, җәмгыятьтә актив һәм җаваплы позициядә торуны кертә.
- Мәдәни мираска хөрмәт тәрбияләү: бу юнәлештә үз халкының телен, мәдәниятен, сәнгатен, гореф-гадәтләрен, тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне белүне, аларны саклау һәм үзеңнән соңгы буынга тапшыру максатын аңлауны, хөрмәт хисләренең мөһимлеге ассызыклана.
- Башка халыкларга хөрмәт тәрбияләү: патриотик тәрбия үз эченә үз Ватаныңа булган мәхәббәтне генә түгел, ә башка халыкларның мәдәниятенә, гореф-гадәтләренә хөрмәт тәрбияләүне дә иң алгы планга куя.

Без, олы буын педагоглар, совет мәктәбендә белем алып, патриотик тәрбия белән сугарылган системада формалашкан кешеләр. Мәктәпләрдә эшли башлаган вакытларыбыз рухи кыйммәтләр саеккан, сәясәт үзгәреп алган бер чорга туры килсә дә, үзебезнең балачактан канга-җанга сеңгән рухи кыйммәтләрнең мөһимлеген үз укучыларыбызга җиткерергә тырышу гадәти кагыйдәгә кереп, һәрвакыт педагогик эштә кулланыла килде. Бүгенге вәзгыять белән генә туган таләп булмавын аңлыйк, чөнки патриотик тәрбия өзлексез процесс булып бара. Ул балачактан башлап, кешенең гомере буе дәвам итә. Патриотик тәрбия нәтиҗәсендә кеше үз Ватанына, милләтенә, мәдәниятенә карата тирән хөрмәт һәм мәхәббәт хисләре белән сугарыла. Ул үзенең гражданлык бурычын аңлый, җәмгыятькә файда китерүгә омтыла. Патриотик тәрбиянең мөһимлеге бүгенге көндә аеруча арта.

Патриотик тәрбия бирүнең әзер шаблоны юк, "туган илне яратыгыз, хөрмәт итегез, аңа тугры булыгыз" дип сеңдерергә тырышуның нәтиҗәсе дә аз булачак. Бала туганнан алып салынган тәрбияви көчләр, рухи кыйммәтләр, гореф-гадәтләр аша кергән, сеңдерелгән хиссият гомерлек булачак. Халык педагогикасының көче расланган, дәлилләнгән. Нәкъ менә патриотик тәрбия бирүдә татар халкының гореф-гадәтләрен куллану бик мөһим һәм

нәтиҗәле алым булып тора. Гореф-гадәтләр – ул халыкның күңел халәтен, тарихын, тормыш тәҗрибәсен, яшәү рәвешен чагылдыручы мирас. Алар аша балаларны һәм яшьләрне үз тамырларына, милли үзенчәлекләренә якынайтып, аларда Ватанга, туган телгә, мәдәнияткә карата мәхәббәт хисләрен тәрбияләп булуы исбатланган.

Татар милли гореф-гадәтләрен патриотик тәрбиядә куллануның төп юнәлешләре:

1. Гаилә кыйммәтләрен тәрбияләү:

- Гаилә бәйрәмнәре һәм йолалары: туйлар, исем кушу, бәби туе, мәҗлесләр – болар барысы да гаиләнең бергә булуын, бердәмлеген, олыларга хөрмәтне, кечеләрне кайгыртуны күрсәтә. Бу йолаларда катнашып, балалар гаилә кыйммәтләрен үзләштерә, туганнарын, якыннарын кадерле башларга өйрәнә.
- Нәсел: татар халкы элек-электән үз нәселе белән горурланган. Нәсел тарихын сакларга омтылган, буыннан-буынга тапшырырга тырышкан. Нәселендәге батырларны, эштә уңыш казанганнарны яхшы белгән. Үз нәселе, ыруы белән горурлана белгән шәхес үз иленә, милләтенә тугры кеше булып үсәчәк.
- Өлкәннәргә ихтирам: татарларда өлкәннәргә, ата-аналарга карата хөрмәт аеруча зур. Бу гореф-гадәтне тәрбияләү балаларда үз-үзен тотышында әдәплелек, зурларны тыңлау һәм фикерләрен хөрмәт итү кебек сыйфатларны үстерергә ярдәм итә.

2. Милли үзенчәлекләрне таныту:

- Тел: туган телне саклау, аның байлыгын, матурлыгын күрсәтү, туган телдә сөйләшү, җырлау, шигырьләр уку балаларда милли үзаң үсешенә зур этәргеч бирә.
- Кием: милли киемнәрне белү, тану, кию, аларның үзенчәлекләрен, тарихын өйрәнү балаларда милли горурлык хисен тәрбияли. Үзенең рухи асылын аңларга омтылыш тудыра.
- Җыр-бию йогынтысы: халык көйләрен, җырларын тыңлау, җыр-биюле йолаларны өйрәнү балаларда миллилекне аңлауга, төшенүгә зур адым булып тора, милли рухны, мәдәниятне тоярга ярдәм итә.

3. Рухи кыйммәтләрне үстерү:

- Хезмәткә карата хөрмәт: татар халкы элек-электән хезмәт сөючәнлеге белән дан тоткан. Хезмәттә уңыш казанган шәхесләрне үрнәк итеп күрсәтә белгән. Бу сыйфатны тәрбияләү балаларда тырышлык, җаваплылык кебек күнекмәләрне үстерергә ярдәм итә.
- Кунакчыллык: татар халкы кунакчыллыгы белән билгеле. Кунакларны каршылау, аларны сыйлау, алар белән арашу балаларда йомшаклык, кешеләргә карата игътибарлы булу сыйфатларын тәрбияли.

- Күркәм холык: татарларда яхшылык, шәфкатьлелек, ярдәмләшү, гаделлек кебек сыйфатлар бик кадерле. Бу сыйфатларны тәрбияләү балаларны яхшы кешеләр булып үсүенә ярдәм итә.

4. Милли бәйрәмнәрне үткәрү:

- Сабантуй – ул татар халкының иң зур һәм яраткан бәйрәме. Бу бәйрәм хезмәткә хөрмәт, патриотик хисләр тудыру белән тирәнтен бәйле. Бәйрәмне үткәрү, уеннарда, ярышларда катнашу балаларда да, өлкәннәрдә дә милли рухны күтәрә, бәйрәмнәрнең әһәмиятен аңларга ярдәм итә.
- Нәүрүз – язның башлануын, табигатьнең уянуын бәйрәм итү. Бу бәйрәмне үткәрү балаларда табигатькә мәхәббәт хисен тәрбияли.
- Корбан бәйрәме, Ураза бәйрәме: Бу дини бәйрәмнәрне үткәрү балаларда дини кыйммәтләрне, гореф-гадәтләрне аңларга ярдәм итә.

Патриотик тәрбиядә гореф-гадәтләрне куллануның иң мөһим асылы шунда: гаиләдәге бала, балалар бакчасында тәрбияләнүче бәләкәч, мәктәптә укучы - үз туган теленең, нәселенең, милләтенең, милли гореф-гадәтләрнең, йолаларның, җыр-биюенең, милли киеменең үзенеке һәм бик кадерле икәнен аңласын, үзенеке булуы белән горурлана белсен. Туган җиренә тугрылык, бирелгәнлек тә менә шул хисләр аша барлыкка киләчәк, кеше булып формалашуда сеңә барачак.

## Икенче бүлек. Укучылар эшләре.
## Төбәк тарихы, ономастика һәм топонимика

*Аскаров Адель, 9 нчы сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «6 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләре: Җиһаншина Венера Гавис кызы,*
*Шәйдуллина Тәнзилә Рәхимулла кызы,*
*туган тел һәм әдәбияты укытучылары*

### Әдип Маликовның “Яшьлек утравым” повестеның поэтик ономастикасы

### Кереш

Барлык төр ялгызлык исемнәренең килеп чыгышын, үсешен, ясалыш һәм кулланылыш үзенчәлекләрен өйрәнү белән тел белеменең ономастика дигән тармагы шөгыльләнә. Бу фән безнең илебездә бик нык үсеш алды. Татар телендәге ялгызлык исемнәрен һәм аларның килеп чыгышын өйрәнү белән Г.Ф.Саттаров, Р.И.Хаҗиев, Ф.Г.Гарипова, Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Һ.В.Йосыпов һ.б. галимнәр шөгыльләнәләр. Бүген дә татар ономастикасыннан фәнни-тикшеренү эшләренә зур игътибар бирелә.

Поэтик ономастика – матур әдәбият әсәрләрендәге барлык төр ялгызлык исемнәрен өйрәнә. Әдип Маликов татар прозасының поэтик ономастикасын үстерүдә матур үрнәкләр барлыкка китерә. Аның әдәби әсәрләрендәге атамалары, исемнәре, геройларның исемнәре мәгънәсенә туры килә, эчтәлекне дөрес һәм тулы ачарга ярдәм итә. Менә шуңа күрә Әдип иҗатындагы атамаларның, ялгызлык исемнәренең кулланылышын, аларның әдәби стильгә, әсәр теленә мөнәсәбәтен тикшерү һәм анализлау максатыннан фәнни-тикшеренү эшенең темасын “Ә.Маликовның “Яшьлек утравым” повестеның поэтик ономастикасы” дип алдык.

Хезмәтнең **актуальлеге** – атамаларның, ялгызлык исемнәрнең аталу тарихын, ясалышын, кулланылыш һәм үсеш эволюциясен, мәгънәсен өйрәнеп, аларның ясалыш-төзелеш структураларын, лексик-семантик үзенчәлекләрен, этнолингвистик катламнарын тарихи-лингвистик яссылыкта тирән анализ ясау.

Тикшерү **объекты** – Әдип Маликовның “Яшьлек утравым” повестендагы поэтик ономастикасы. Тикшерү **предметы** – Ә.Маликовның “Яшьлек утравым” повестендагы поэтик ономастикасын: атамаларның, ялгызлык исемнәрнең аталу тарихын, ясалыш-төзелеш структураларын, лексик-семантик үзенчәлекләрен, кулланылышын, мәгънәсен өйрәнү.

Әдип Маликовның “Яшьлек утравым” повестен, ономастика өлкәсенә керткән өлешен, әдәби әсәрендә атамаларның һәм ялгызлык исемнәренең кулланылыш үзенчәлекләрен өйрәнү, анализлауны фәнни эшнең **төп максаты** итеп куйдык. Максатка ирешүдә түбәндәге **бурычларны** үтәү күздә тотылды: Ә.Маликовның “Яшьлек утравым” повестенда исемнәрнең стилистик кулланылышын ачыклау, автор файдаланган поэтик антропонимнарга хас булган мәгънә үзенчәлекләрен билгеләү, атамаларның бирелүенә хас сыйфатларны ачыклау. Хезмәттә кулланылган **методлар**: эзләнү, тикшеренү һәм нәтиҗә чыгару методлары, ономастика турында китапханәдә, музейда, интернетта булган фәнни әдәбият белән танышу, өйрәнү, язмаларны редакцияләү.

**Төп чыганаклар** булып Маликовның Ә., Бәйрәмованың Ф.Ә., Гальцев-Безюкның С., Гарипованың Ф.Г., Саттаровның Г.Ф., Хаҗиевның Р.И. фәнни хезмәтләре торды.

Тикшеренүнең **әһәмияте**: ялгызлык исемнәрнең, атамаларның ясалыш-төзелеш структураларын, лексик-семантик үзенчәлекләрен, этнолингвистик катламнарын тарихи-лингвистик яссылыкта өйрәнеп, анализ ясау.

Ә.Маликовның “Яшьлек утравым” повестенда бик күп ялгызлык исемнәр очрый. Аларның күпчелек өлешен антропонимнар һәм топонимнар тәшкил итә. Язучы кулланган күп кенә герой исемнәре килеп чыгышлары белән төрле телләргә карый. Алар арасында ике компоненттан ясалганнары, хәтта беренче компоненты гарәп, икенчесе башка телдән булган исемнәр дә шактый. Әдәби исемнәр әсәр идеясен ачуда, геройларның холык-фигыльләрен һәм төп сыйфатларын күрсәтүдә әһәмиятле роль уйный. Үзләренә хас исем-фамилиягә ия булудан тыш, характерына, тышкы кыяфәтенә, физик кимчелекләренә, шөгыленә туры килердәй кушаматларны да Ә.Маликов сүз-сурәткә әйләндергән.

Хезмәтнең **структурасы** кереш өлешеннән, төп өлешнең ике бүлегеннән, йомгаклау һәм файдаланылган әдәбият исемлегеннән тора.

## I бүлек. Әдип Малик улы Маликовның тормыш юлы һәм иҗаты

***Әдип Малик улы Маликов*** (1921-2009) – татар шагыйре, прозаик.

1921нче елның 16нчы августында Башкортстанның Яңавыл районы Югары Чатавылында мөгаллим гаиләсендә туа. Башлангыч белемне ул үз әтисеннән ала, бишенче сыйныфтан башлап күршедәге Ямады авылы мәктәбендә укый. 1934нче елда әтисе Малик Гарифуллин Аксәет авылы мәктәбенә укытучы итеп күчерелгәч, Әдип анда ике ел, аннан Яңавыл урта мәктәбендә бер ел укып, сигез сыйныфны тәмамлый һәм Пермь шәһәрендәге Татар педагогия училищесының икенче курсына укырга керә. Училищеда укыган чорда әдәбият белән ныклап кызыксына башлый.

1939 нчы елда училищены тәмамлагач, Ә.Маликовны Пермь өлкәсенең Барда районы Солтанай авылы җидееллык мәктәбенә укытучы итеп җибәрәләр. Ләкин шул

ук елның көзендә аны армиягә алалар. Ватан сугышы башлану сәбәпле, Ә.Маликовның гаскәри хезмәт мөддәте җиде елга сузыла. 1945нче елның августында ул разведка төркеме командиры сыйфатында Сахалин утравының көньяк өлешен японнардан азат итү сугышларында катнаша. Бу операциядә үзенә йөкләнгән хәрби бурычны җиренә җиткереп үтәгәне өчен аны «Батырлык өчен» медале белән бүләклиләр. Хәрби тормышның кырыс шартларына карамастан, Ә.Маликов иҗат эшен дә онытмый, шигырьләр яза, дивизия газетасында очерк язмаларын даими бастыра. Аның шул дәвердә иҗат иткән зур шигъри әсәре – "Атаудагы хисләр" поэмасы (1945-1946) Армиядән кайткач, Әдип Маликов 1946нчы елдан 1949нчы елның августына чаклы Татарстан радиосында әдәби-драматик тапшырулар редакторы булып эшли. 1949нчы елның көзендә Татарстан Язучылар берлеге аны Мәскәүгә М.Горький исемендәге Әдәбият институтына укырга җибәрә.

1951-1960нчы елларда Ә.Маликов "Яшь сталинчы" газетасының үзхәбәрчесе сыйфатында Минзәлә һәм Әлмәт төбәкләрендә эшли. 1955нче елда Әлмәт шәһәрендә әдәби иҗат берләшмәсе оештырып, 1960нчы елга кадәр аңа җитәкчелек итә. 1963нче елда шушы әдәби берләшмә җирлегендә Әлмәт Язучылар оешмасы барлыкка килә. 1965-1967нче һәм 1972-1982нче елларда Әдип Маликов бу оешманың җаваплы сәркатибе булып эшли.

Әлмәт шәһәрендә яшәү, бу төбәктәге тормыш үзгәрешләрен үз күзе белән күрү, нефтьчеләр арасында кайнау Әдип Маликовның иҗатын яңа темалар, яңа хисләр, төсмерләр белән баета. Мәсәлән, "Ташчы" (1956), "Фәрдәнә" (1958), "Гайшә апа" (1959), "Салкын Алан" (1967), "Чигүле кулъяулык" (1968) кебек поэмалары һәм шигырьләре. "Сахалин язмалары" (1948), "Кайнар эзләр"(1956), "Без кояшны юлда каршылыйбыз" (1964), "Кембригә юл салучылар"(1965), "Гашыйклар юлы"(1978) кебек проза китаплары һәм, ниһаять, авторның солдат еллары белән бәйле Сахалин турындагы "Яшьлек утравым" исемле повесть-истәлеге (1972) заманның сәнгатьчә документаль елъязмалары буларак шул чор татар әдәбиятының үзенчәлекле бер сәхифәсен тәшкил итәләр.

Ә.Маликов – 1959 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы. Ә.Маликов 1945 нче елны "За отвагу" медаленә, 1981 елны "Знак Почёта" орденына һәм "Хөрмәтле Әлмәт гражданины" исеменә лаек була. Әдәбият өлкәсендәге хезмәтләре өчен Ә.Маликов 1979 нчы елда "Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре" дигән мактаулы исемгә лаек була. Ул 2009 нчы елның 23 нче апрелендә Әлмәт шәһәрендә вафат була һәм шунда җирләнә.

## II бүлек. Әдип Маликовның "Яшьлек утравым" повестеның поэтик ономастикасы

### 2.1. Әсәрнең антропонимиясе

Тел белеменең ономастика дип йөртелә торган бер тармагы бар. Ул кеше исемнәрен, фамилияләрен һәм кушаматларны, күк җисемнәренең һәм георгафик урыннарның, елга-

суларның, мифологик затларның һ.б. исем-атларын өйрәнә. Ономастика шундый күпсанлы һәм төрле-төрле исемнәрне җыю-туплау, тәртипкә салу, аларның килеп чыгышын, тарихи җирлеген аңлату кебек мөһим бурычларны гамәлгә ашыра. Ономастика фәнендәге табышлар һәм казанышлар тел тарихын өйрәнүдә генә түгел, бәлки халыкның этник тарихын яктыртуда да зур әһәмияткә ия. Поэтик ономастика – матур әдәбият әсәрләрендәге барлык төр ялгызлык исемнәрен өйрәнә торган тармак.

Топонимика белән антропонимика ономастиканың ике иң мөһим, иң зур бүлекләрен тәшкил итәләр. Топонимика барлык төр географик атамаларны (топонимнарны) өйрәнә.

Антропонимика – кеше исемнәре, ата исеме, кушамат, псевдоним, криптонимнарның (яшерен исем) килеп чыгышын, төзелеш-ясалыш, кулланылыш үзенчәлекләрен, үсеш-үзгәреш закончалыкларын, антропонимнар йөртә торган төрле мәгълүматны өйрәнә торган ономастиканың бер тармагы. Татар телендә антропонимика фәне XX гасырның 60-70 елларында үсә башлый. Моңа кадәр аерым мәгълүматлар тупланып килсә дә, тирәнтен фәнни тикшеренүләр Саттаров Г.Ф. тарафыннан башкарыла.

Әдип Маликовның "Яшьлек утравым" повестеның антропонимикасы шактый бай. **Әсәрдә төрки-татар чыгышлы исемнәр бар:** ***Биктимер*** – ир бала бәк кебек хаким һәм тимер кебек нык булсын дип теләп кушылган. ***Сөембай*** – Сөем бай, сөекле бай (бала). ***Тимеркәй*** – тимер сүзенә *-кәй* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ялганып ясалган исем. ***Такташ*** – 1. Гранит, кыя ташы; 2. Так таш, ягъни ялгыз таш. ***Тукай*** – "тук" (туенган, тулы, бөтен) сүзенә *-ай* атау-эндәшү-боеру кушымчасы ялганып ясалган.

**Татар исемнәре дә кулланыла:** ***Йолдыз*** – йолдыз кебек якты, нурлы, күркәм. ***Миңлекәй (-вич) –*** *миңле* сүзенә *–кәй* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ялганып ясалган исем.

**Әсәрдә гарәп-фарсы теленнән кергән исем дә бар:** ***Мөхәммәтша (Брангулов)*** – "Мөхәммәт" + "шаһ" сүзләреннән барлыкка килгән.

**"Яшьлек утравым" әсәрендә гарәп теленнән кергән исемнәр бик күп:**

***Афзал*** – иң лаеклы, иң кадерле. ***Әхнәф*** – иң дөрес сүзле; сер саклаучы. ***Баттал*** – 1. Батыр, каһарман; фидакарь сугышчы; 2. Буш, эшсез. ***Габдулла*** – Аллаһ колы, Аллаһ бәндәсе. ***Гали Хуҗи*** – бөек, олы, югары дәрәҗәле; кыйммәтле; куәтле, көчле, кодрәтле; һәрнәрсәдән өстен һәм бөек. Аллаһының эпитеты. ***Кәрим*** – юмарт, рәхимле, киң күңелле; кадерле; асыл зат. ***Мәҗит*** – гарәп теленнән "куәтле, бик көчле" дигәнне аңлата. ***Миңнулла*** – Алланың миңлесе. ***Салих*** – яхшы, изге, игелекле. ***Сәйфи*** – кылычлы кеше. ***Тимергалин*** – "Тимер" + "Гали", шушы исемнән Тимергалин фамилиясе ясалган. ***Фатих*** – ачучы, башлап җибәрүче; яулап алучы, җиңүче. ***Фәтхи*** – җиңүгә ирешкән; җиңү яулаучы; җиңү. ***Хәниф*** – тугры күңелле; чынны сөюче. ***Зөһрә*** – гарәп теленнән "ялтырый торган, якты" дигәнне аңлата. ***Мәйсәрә*** – байлык, муллык; иминлек. ***Сәгыйдә*** – бәхетле, рәхәт яшәүче; мул тормышлы.

**Әсәрдә грек теленнән кергән исемнәр кулланыла:** ***Алексей*** – бу исем борынгы грек “алекс” сүзеннән килеп чыккан һәм яклау, саклаучы, ярдәмче дигәнне аңлата. ***Анатолий*** – “көнчыгыш”; чыгышы - Кече Азиядән. ***Аркадий*** – чыгышы белән Аркадиядән (Пелопоннес ярым-утравындагы өлкә). Русларга Византиядән христианлык белән килгән. ***Леонид*** – “арыслан нәселе”. ***Петр*** – исем борынгы грек “Петра” сүзеннән чыккан, “кыя, таш кисәге”.

**Әсәрдә славян теленнән кергән исемнәр дә урын алган:** ***Люба*** (***Антошина)*** – бу исем славян сүзе “мәхәббәт” сүзеннән килеп чыккан. ***Володя (Владимир)*** **–** урта гасыр җыелма исеме, славян сүзеннән хуҗа булу һәм тынычлык дигәнне аңлата.

**“Яшьлек утравым” повестенда алынма исемнәр дә очрый. Француз теленнән кергән исем бар:** ***Марат*** – Француз буржуаз революциясенең юлбашчыларыннан берсе Жан-Поль Марат хөрмәтенә татарларда 1930 еллардан соң киң таралыш алган исем.

**Борынгы рим теленнән кергән исемнәр кулланыла:** ***Антон*** – Антонии нәселеннән борынгы рим исеме, шәхси исемгә әйләнгән. ***Валерий (Адмакин)*** – борынгы рим исеме (латинча “валериус” – “көчле”). Русларга Византиядән христианлык белән килгәннәр.

**Әсәрдә рус хатын-кыз исеме дә бар:** ***Нина (Заречная)*** – иң борынгы исем. 3000 елдан артык элек Двуречьеда (Месопотамия) документлаштырылган. Грузиядә әби патша исеме. Безнең эраның IV гасырында Грузиядә христиан динен керткән өчен аны әүлиялар исемлегенә язып куялар. XVIII гасыр ахырында йогынты ясау аркасында Грузия Россиягә кушылгач, бу исем русларга еш куела башлый.

Димәк, татар теле – бөтендөнья күләмендә кеше исемнәренә иң бай, кеше исемнәре хәзинәсе иң мул булган телләрнең берсе.

### 2.2. Әсәр топонимиясенә лексик-семантик анализ

Ономастиканың иң әһәмиятле тармакларыннан берсе – топонимика. Ул телебездәге географик атамаларны (авыл, шәһәр, урман, күл, тау һ. б. исемнәрен) тикшерә.

Әдип Маликовның “Яшьлек утравым” повестенда урын алган топонимнарны бу төр үзенчәлекләре буенча ике зур төркемгә аерып карыйбыз: 1) апеллятив лексикадан ясалган атамалар; 2) эпонимик ясалышка ия атамалар. Ономастика фәнендә күмәклек исемнәреннән ясалган ялгызлык исемнәрен апеллятив ясалышка, ә килеп чыгышлары башка класска караган ялгызлык исемнәрен эпонимик ясалышка кертәләр.

#### 2.2.1. Апеллятив лексикадан ясалган топонимнар

Апеллятив лексикадан, ягъни уртаклык исемнәреннән ясалган атамаларның үзләрен берничә лексик-семантик төркемгә бүлеп карый алабыз: географик терминнардан ясалган атамалар; фитонимик терминнардан ясалган атамалар; халыкның тормыш-көнкүреше белән бәйле атамалар; гидронимнар.

### 2.2.1.1. Географик терминнардан ясалган атамалар

Җирле географик терминнар бай сүзлек хәзинәсенең бер өлеше булып ята. Алар әйләнә-тирәнең табигате, халыкның теле, тормыш-көнкүреше, тарихы турында бай мәгълүмат бирәләр. Георгафик терминнарга нигезләнеп ясалган атамалар топонимиканың нигезен тәшкил итәләр, атамаларның мәгънәви эчтәлеген чагылдыралар.

Ә.Маликовның "Яшьлек утравым" повестенда *тау* орографик терминына нигезләнеп ясалган атамалар бар. ***Урал таулары.*** Урал таулары атамасының килеп чыгышы турында сүз күп булса да, бәхәсләр әле тынмаган, һәм соңгы сүз әйтелмәгән. Безнеңчә, Урал атамасы борынгы сүз, һәм аны иске сүзләр китабыннан эзләргә кирәк. Мәсәлән *ор, ур, үр* сүзләре төрки халыкларда *холм, гора, возвышенность, берег, обрыв* һәм тагын әллә ничә төрле мәгънәдә йөргәннәр. *Әл* сүзе элек шул ук *ил* сүзен белдергән. Шулай итеп, *ор әл, ур әл, үр әл* – болар барысы да "горная страна", "горный край" мәгънәсен аңлатканнар. ***Альп таулары*** – 1760-1794нче елларда швейцар О.Соссюр белән өйрәнелгән Көнбатыш Европадагы таулар, кельт сүзеннән "биек тау", "калкулык". ***Набил таулары*** – нивхларның үзгәртелгән "нга-биль" сүзеннән алынган, русчага "большие нерпы" дип тәрҗемә ителә. ***Хинган таулары*** – нивхлар теленнән тәрҗемә иткәндә "агач кирәмәт", кайбер халыкларның табыну урыны. ***Сихотэ-Алин таулары*** – маньчжур чыгышы - "яр умырткалыкны" аңлата; кытай риваяте буенча: "си" – көнбатыш, "хэ" – елга, "та" – зур һәм маньчжурның "алинь" – умырткалык ("көнбатыш елганың зур умырткалыгы"). ***Поронай үзәне*** – айнадан тәрҗемә иткәндә "зур үзән" дигәнне аңлата. ***Харамитогэ таулары*** – таулар исеме тезмәсе.

### 2.2.1.2. Фитонимик терминнардан ясалган атамалар

Фитонимика – урман, аның төрләрен, агач һәм агачлыкны, үләнне һәм аның төрләрен белдерүче терминнарны өйрәнүче тармак. Һәрбер төбәктә теге яки бу үсемлек, куаклык, яисә агачның күп булып үсүенә бәйле рәвештә төрле атамалар барлыкка килгән.

"Әдип Маликовның Яшьлек утравым" повестенда урман, аның төрләрен, агач һәм агачлыкны, үләнне һәм аның төрләрен белдерүче фитонимик терминнарга нигезләнеп ясалган түбәндәге топонимнарны күрсәтә алабыз. ***Камышлы тау*** – беренче күчеп килгән урыслар тау битләрендә котырып үскән бамбукларны камыш дип уйлаганнар һәм шундый исем биргәннәр. ***Брусничная сопкасы*** – әсәрдә сурәтләнгән тау атамасы. ***Камышлы районы*** – беренче күчеп килүче рус халкы белән бирелгән исем, рус халкы Курил һинд камышы куаклыкларын камышлар дип уйлаганнар. ***Курил лимоннигы*** – Курил утравында үсә торган агач исеме. ***Алма-Ата*** – Казахстанның иң зур шәһәре, "Южная Столица" исеме белән танылган. ***Кушимән авылы*** – Башкортстандагы авыл исеме. 2 компоненттан тора: -куш һәм -имән. ***Камышлы районы*** – Башкортстандагы район исеме.

### 2.2.1.3. Халыкның тормыш-көнкүреше белән бәйле атамалар.

Ойконимика – топонимиканың тармагы. Торак пункт атамаларын (авыл, шәһәр, поселок, станция һ.б.) барлый, аларны тарихи-лингвистик яссылыкта өйрәнү белән шөгыльләнә. Халкыбызның рухи тормышы белән бәйле терминнар меңәр еллар дәвамында географик атамалар ясалышында катнашканнар.

Әдип Маликовның "Яшьлек утравым" повестенда халыкның тормыш-көнкүреше белән бәйле атамалар бик күп. ***Кубань*** **–** Төньяк Кавказдагы тарихи регион. ***Себер*** **–** Россия Федерациясенең үзәгендә урнашкан зур географик регион. ***Татарстан*** – Россия Федерациясенең субъекты, республика. Идел буе федераль төбәгенә керә. ***Башкортстан*** **–** Россия Федерациясенең субъекты, Төньяк Урал һәм Урал буендагы республика. ***Мәскәү*** **–** Россиянең башкаласы. ***Ленинград*** – хәзерге Санкт-Петербург шәһәре. ***Казан*** – Казан елгасының атамасы беренчел, ә Казан шәһәре исеме икенчел. Димәк, шәһәр исеме Казан елгасы атамасыннан алынган. ***Уфа*** **–** Башкортстанның башкаласы. ***Минск*** **–** Белоруссиянең башкаласы. ***Прага*** **–** Чехиянең башкаласы. ***Хәйхә шәһәре*** **–** Япониядәге шәһәр исеме. ***Уральск*** **–** Казахстанның көнбатыш өлешендәге шәһәр. ***Караганда*** **–** Казахстан шәһәре, 1934 елның 10 февралендә шәһәр статусы алган. ***Маньчжурия*** – Кытайның Төньяк-Көнчыгышындагы тарихи өлкә. ***Харбин шәһәре*** **–** Кытайның төньяк-көнчыгыш өлешендәге шәһәр. ***Чүгәчәк*** **–** Кытайдагы шәһәр исеме. ***Портсмут*** **–** Америка Кушма Штатлары шәһәре. ***Тойохара*** – шәһәр исеме, япончадан "муллык чыганагы", "уңдырышлы кыр" дигәнне аңлата. ***Карафуто губернасы*** – японнар Сахалин утравын гасырлар буе Карафуто, дип атап йөрткәннәр. Карафуто – Көнчыгыш халыклары телендә "кара" – "черный" дигәнне аңлата. 1613 елны Сахалин утравының көньягында тикшерүләр үткәргән япон экспедициясе бу утрауны Татар иленең бер өлеше, дип уйлаган һәм аңа Карафуто исемен биргән. ***Тәтешле, Аксәет авылы, Җиремаз*** **–** Башкортстандагы район исеме. ***"Европа авылы"*** **–** самурайлар коллыгына төшкән татар авылы. ***"Галия" мәдрәсәсе*** **–** Дини уку йорты. Уфада 1906 елда эшли башлый. Мәдрәсәне тәмамлаучы шәкертләр арасыннан М.Гафури, Г.Ибраһимов, Ш.Бабич, Х.Туфан, С.Кудаш кебек атаклы шагыйрьләр һәм әдипләр чыккан. ***"Госмания" мәдрәсәсе*** **–** Казандагы "Кызыл мәчет" (Солтан мәчете, Җиһанша бай мәчете, Госман мәчете, Сигезенче җамигъ мәчет) мәхәлләсенең мәдрәсәсе. ***Курил утравы*** – утрау исеме, борынгы айналар үз-үзенә биргән төп халык исеменнән барлыкка килгән – "кур", "кури". ***Сахалин утравы*** – кайбер кытай чыганакларында Сахалин атавы Шуйдада, дип тә атала, бу да Ерак Көнчыгышта яшәгән борынгы татарларның бер атамасы, ягъни, "су татарлары" дигәнне аңлата. Сахалин утравының тагы борынгыдан маньчжур-татар телендә Сагалян ула, дип аталуы да билгеле, аның да тамырында саклар суы, сүзтезмәсе ята. ***Хоккайдо утравы*** **–** Япониядәге утрау исеме. ***"Тихая" тыкрыгы*** – Көньяк Сахалиндагы тыкрык исеме.

**2.2.1.4. Гидронимнар**

Гидронимика – топонимиканың бер тармагы. Су чыганакларының исемнәрен туплый, аларга тарихи-лингвистик яссылыкта анализ ясый. Гидронимнар ономастиканың иң борынгы тармагын тәшкил итәләр. Шуңа күрә аларны өйрәнү татар халкының килеп чыгышы мәсьәләләрен хәл иткәндә гаять әһәмиятле мәгълүматлар бирә.

Әдип Маликовның “Яшьлек утравым” повестенда гидронимик атамалар да бик күп. ***Тын океан*** – португалияле диңгез сәяхәтчесе Фернандо Магеллан 1520-1521 елларда 3 ай һәм 20 көн йөзү вакыты эчендә океанда тыныч һава торышы өстенлек иткәнгә күрә шундый исем кушыла. ***Охот диңгезе*** – бу исем эвенклар сүзе “охат” – “река” дигәнне аңлата. Шул җирлектә агып ятучы елганы эвенклар Ахоть, дип атаганнар, шуннан чыгып, урыслар ул коя торган диңгезне дә “Охотское” дип йөртә башлаганнар, елга үзе Охинкага әйләнгән, анда урнашкан шәһәр соңыннан Оха, дип аталган. ***Каспий диңгезе*** – килеп чыгышы турында төрле карашлар бар. Кайбер галимнәр аны борынгы фарсы телендә “ат” мәгънәсен аңлаткан *әсб* сүзе белән бәйләп карыйлар һәм атама “атлар иле” дигән сүз белдергән дип расларга тырышканнар. Каспий турында кызыклы мәгълүматлар иран тарихчылары хезмәтләрендә дә очрый. Бу чыганакларның берсендә сак һәм скифлар яшәгән урыннар һәм Мазандаран диңгезе, ягъни Каспий яры буйларына якын районнар Сакасена дип аталганнар. ***Кара диңгез*** – беренче фараз буенча: Азия илләрендә дөнья яклары төсләр белән билгеләнгәнгә, “кара” төньякны билгели, тиешенчә Кара диңгез – Төньяк диңгез. Башка фараз буенча: озак вакытка 150 м тирәнлектәге суга төшерелгән металл әйберләр хим күкертле водород аркасында кара төс белән каплана. ***Идел елгасы*** **–** болгар-татарларда “идел” термины “зур су, зур елга” төшенчәсен белдерә; елганың борынгы исеме – Итил, русчасы – “Волга”. Н.Исәнбәт **ат-ил** яки **ил-ат** (“ат менгән ирләр кулында идарә ителгән ил”) тәгъбиреннән Ат-ил мәмләкәте, Атил шәһәре һәм шул шәһәр янында диңгезгә койган Атил (Идел) елгасы атамаларын китереп чыгара. Әлеге тарихи мәгълүматлар, нигездә, чынбарлыкка туры килсә дә, Атил (Идел) елгасы атамасы **ат-ил** тәгъбиреннән алынган дип карау Атил гидронимы белән **ат-ил** тәгъбире әйтелешендәге охшашлыкка, аваздашлыкка, ягъни “халык этимологиясе”нә нигезләнеп фикер йөртүгә корылган. ***Агыйдел елгасы*** – “ак” һәм борынгы төрки Идел сүзләреннән ясалган. Агыйдел атамасы XVI-XVII йөз рус тарихи-географик чыганакларында Белая Воложка дип йөртелгән. ***Тол елгасы*** – риваять буенча: “Танып авылы –Тол елгасы үрге агымының иң иске авылы. Борынгылыкта Гайнетдин исемле бер кеше бу җиргә күчеп, йорт төзегән. Бераз вакыттан Ишим авылы булган җирдә, Тол елгасының агым суының түбәнендә аның кече энекәше күчеп килеп, йорт төзи. Соңыннан ул елга буйлап аккан чыраларны күреп, үзенең абыйсы Гайнетдинне таба. Соңыннан Гайнетдиннең кече энекәше елгада батып үлә, ә аның хатыны елга янына барып:

“Син миңа шундый кайгы китердең, - дип, - синең исемең “Тол” – “вдова” була, - дигән.” Шулай елга исеме барлыкка килгән. ***Амур елгасы*** – үз исемен солонский “амур” сүзеннән (“елга”) ала. ***Дуамал елгасы*** – көчле яңгырлар артыннан ул хәтәр дулап, шашынып, үзенең характерын күрсәтеп ала. ***Поронай елгасы*** – айна телендә “Поро” – зур, “Най” – елга дигәнне аңлата. ***Днепр елгасы*** – “агым су, елга”. Борынгы урыс елъязмачысы Нестор “кайчандыр борынгы бабаларыбыз монда Дунай ярларыннан килгәннәр” дип язган. Днепр исеме “Дунай-река” мәгънәсен белдерүче борынгы сүзтезмәдән барлыкка килгән. ***Одер елгасы*** – балтийский “ардас” сүзеннән – “бүлек, чик, бәхәс”. ***Синай-гава елгасы*** (елганың японча исеме). Харамитогэ тау итәге буйлап аккан саз елгасы. Авыр сугыш көннәрендә солдатлар аңа башка исем тагалар: Проклятая” – “йөзе кара”. ***Байкал күле*** – “бай күл”, төрки теленнән “бай” – “богатый” һәм “куль” – “озеро” сүзләреннән барлыкка килгән. Борынгыдан Байкал янында яшәүче һәр халык бу күлне үзенчә исемләгән: кытайлар – “Бэйхай” – “төньяк диңгез” дип, эвенклар – “Ламу” – “диңгез” дип, бурят-монголлары – “Байгаал-далай” – “зур сулык” дип атаганнар.

## Йомгаклау

Барлык төр ялгызлык исемнәренең килеп чыгышын, үсешен, ясалыш һәм кулланылыш үзенчәлекләрен өйрәнү белән тел белеменең ономастика дигән тармагы шөгыльләнә. Бу фәннең тикшеренү өлкәсе ифрат бай һәм кызыклы. Ул кеше исемнәрен, фамилияләрен һәм кушаматларны, күк җисемнәренең һәм георгафик урыннарның, шул җөмләдән елга-суларның, мифологик затларның һ.б. исем-атларын өйрәнә. Ономастика шундый күпсанлы һәм төрле-төрле исемнәрне җыю-туплау, тәртипкә салу, аларның килеп чыгышын, тарихи җирлеген аңлату кебек мөһим бурычларны гамәлгә ашыра. Ономастика фәнендәге табышлар тел тарихын өйрәнүдә, халыкның этник тарихын яктыртуда зур әһәмияткә ия.

Топонимика белән антропонимика ономастиканың ике иң мөһим һәм иң зур бүлекләрен тәшкил итәләр. Топонимика барлык төр географик атамаларны (топонимнарны) өйрәнә. Антропонимика – кеше исемнәре, ата исеме, кушамат, псевдоним, криптонимнарның килеп чыгышын, төзелеш-ясалыш, кулланылыш үзенчәлекләрен, үсеш-үзгәреш закончалыкларын, антропонимнар йөртә торган төрле мәгълүматны өйрәнә торган ономастиканың бер тармагы.

Әдип Маликов татар прозасының поэтик ономастикасын үстерүдә матур үрнәкләр барлыкка китерә. Аның әдәби әсәрләрендәге атамалары, исемнәре, геройларның исемнәре мәгънәсенә туры килә, эчтәлекне дөрес һәм тулы ачарга ярдәм итә. Атамаларның, ялгызлык исемнәрнең аталу тарихын, ясалышын, кулланылыш һәм үсеш эволюциясен, мәгънәсен өйрәнү, аларның ясалыш-төзелеш структураларын, лексик-семантик үзенчәлекләрен,

этнолингвистик катламнарын тарихи-лингвистик яссылыкта тирән анализ ясарга ярдәм итә.

Бу фәнни эштә Әдип Маликовның “Яшьлек утравым” повестен, ономастика өлкәсенә керткән өлешен, әдәби әсәрендә атамаларның һәм ялгызлык исемнәренең кулланылыш үзенчәлекләрен өйрәндек һәм анализладык. Максатка ирешүдә билгеләнгән бурычларны үтәдек: Ә.Маликовның “Яшьлек утравым” повестенда исемнәрнең стилистик кулланылышын ачыкладык, автор файдаланган поэтик антропонимнарга хас булган мәгънә үзенчәлекләрен билгеләдек, атамаларның бирелүенә хас сыйфатларны ачыкладык.

Ә.Маликовның “Яшьлек утравым” повестенда бик күп ялгызлык исемнәр очрый. Аларның күпчелек өлешен антропонимнар һәм топонимнар тәшкил итә. Повестьтагы атамалар, барлык төр ялгызлык исемнәре төп максатка ирешүгә – тормышны реалистик рәвештә сәнгатьчә югарылыкта сурәтләргә, дөрес һәм тулы итеп чагылдырырга ярдәм итә.

**Файдаланылган әдәбият исемлеге**


1. Бәйрәмова, Ф. Ә. Сахалин утравы һәм татарлар. – Фәнни-тарихи язма / Ф. Ә.Бәйрәмова. – Казан : “Аяз” нәшрияты, 2014. – 264 б.
2. Гальцев-Безюк, С. Топонимический словарь Сахалинской области / С. Гальцев-Безюк. – Южно-Сахалинск, 1992. – URL : http://www.balonline.ru/slovar.html
3. Гарипова, Ф. Г. Исемнәрдә – ил тарихы / Ф. Г. Гарипова. – Казан : Татар. кит. нәшрияты, 1994. – 264 б.
4. Гомәр Саттар-Мулилле. Татар исемнәре ни сөйли? (Татар исемнәренең тулы аңлатмалы сүзлеге). – Казан : “Раннур” нәшрияты, 1998. – 485 б.
5. Маликов, Ә. Яшьлек утравым: повесть-истәлек / Ә. Маликов. – Казан : Татар. кит. нәшрияты, 1998. – 192 б.
6. Хаҗиев, Р. И. Ата-бабаларыбыз мирасы: Монография / Р. И. Хаҗиев. – Яр Чаллы, 2010. – 203 б.
7. Хаҗиев, Р. И. Татар ономастикасыннан фәнни хезмәт язуга методик кулланма (югары сыйныф укучылары өчен) / Р. И.Хаҗиев. – Яр Чаллы, 2011. – 64 б.
8. URL : http://kitap.net.ru/hujin/9.php
9. URL : http://tt.wikipedia.org/wiki/Антропонимика
10. URL : http://tt.wikipedia.org/wiki/Әдип_Маликов

*Афанасьева Лиана, 10 нчы сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге «1 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Фалахиева Илмира Ризатдин кызы, биология һәм география укытучысы*

## Хуҗиәхмәт Мәхмүтов – милләтем горурлыгы

### I.Кереш

Татар милләте - тарихта тирән эз калдырган халык. Аның бай тарихы матди һәм рухи мәдәнияте, гүзәл гореф-гадәтләре бар. Иң зур байлыгы-бөек шәхесләре. Туган якка мөнәсәбәттә шәхес билгеләнә. Юкка гына галимнәр, язучылар Ватанның кайда һәм нидән башлануы, кайда тәмамлануы, үз эченә нәрсәләрне алуы турында элек-электән баш ватмагандыр. Бөек шәхесләр исемлеген туган ягым Мамадыш районында дөньяга килгән бөек затлар белән дәвам итәсем килә: Хуҗиәхмәт Мәхмүтов, Шәйхи Маннур, Мансур Сафин, Шаһинур Мостафин, Рафаил Газизов, Мингол Галиев, Нәкыя Йосыпова һәм тагын бик күп кенә шәхесләребез. Якташ шагыйрьләребезне һәм галимнәребезне барлау үзе бер горурлык. Бу исемлекне тагын да дәвам итеп булыр иде... Әнә шундый якташларым бар минем! Аларны белмәү зур хата булыр иде. Кешенең теле, рухи байлыгы, иң гүзәл сыйфатлары да турыдан-туры туган җиргә мәхәббәт, бирелгәнлек аша ачылырга мөмкин. Шуңа күрә теманы сайлавым бик урынлы: беренчедән, Мамадыш төбәгеннән булган фольклорчы-галим Хуҗиәхмәт Мәхмүтовның тормыш юлына күзәтү ясаганда, туган ягым өчен горурлану хисләре кичердем; икенчедән туган җиремә мөнәсәбәттә минем дә нинди шәхес булып формалашуым күренәчәк бит.

Максатым - тел, әдәбият язмышы белән кызыксынучыларны күренекле якташымның иҗаты, хезмәтләре белән таныштыру; галимнең иҗатына зур кызыксыну уяту. Мин туган ягымнан чыккан бөек шәхесләрнең исемнәрен чиксез горурлык хисләре белән телгә алам, аларның хезмәтләрен өйрәнәм. Тел галиме Хуҗа Бәдигыйга багышланган чарада катнашу теләге белән андагы “Районыбыз җирлегеннән чыккан тел галимнәре” дигән теманы сайладым Мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге күпьеллык нәтиҗәле фәнни мәгърифәтчелек эшчәнлеге турында, якташ галим Хуҗиәхмәт ага Мәхмүтовның тормышы һәм иҗаты белән таныштырып үтәм. Минем бурыч- сыйныфташларымны, мәктәбебез укытучыларын һәм укучыларын, фән белән кызыксынучыларны Мамадыш төбәге галимнәре белән таныштыру эшен ахыргача башкарып чыгу.

## II.Төп өлеш

### 1. Фольклорчы галим – Хуҗиәхмәт Мәхмүтов иҗаты

Фольклорчы галим... Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты баш гыйльми хезмәткәре, филология фәннәре докторы, Халыкара Төрки академиясенең хакыйкый әгъзасы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре Хуҗиәхмәт Шаһиәхмәт улы Мәхмүтов... Хезмәттәшләре аны эшсөяр бал кортына тиңлиләр. Әлбәттә, шулай. Чөнки, филология фәннәре докторы Нурмөхәммәт ага Хисамов язганча, "Менә инде 40 елга якын Х.Мәхмүтовның халык авыз иҗатына багышланган мәкаләләре газета һәм журнал битләрендә, төрле җыентыкларда даими рәвештә, гүя төгәл график буенча басылып киләләр. Аларның саны 600 дән дә артып киткән икән! 30 ел чамасы һәр айда ике тапкыр без аның чыгышларын "Тел күрке - сүз" радиотапшыруында тыңлап барабыз... Халык иҗаты буенча ул бастырып чыгарган 20 ләп китапның гомуми тиражы 130 меңгә якынлаша!.." Хәлбуки, дистәләгән елларга сузылган бу олуг хезмәткә күпме көч түгелгәнен Хуҗиәхмәт ага бары тик үзе генә беләдер. Акыллы күзләреннән нindидер җылы, рәхәт нур бөркелүче, чал чәчле олпат галим ул. Тыйнаклыкның Үзе! "Гади дә, гали дә", - диләр андыйлар хакында.

Ул 1933 елның 15 февралендә Мамадыш районы Түбән Ушмы авылында дөньяга килгән. Шунда ук җидееллык мәктәпкә укырга керә. Балачагы авыр сугыш елларына туры килә. 1944 елда гаиләләре белән Мамадыш шәһәренә күченәләр. Шунда урта мәктәпне тәмамлагач, Хуҗиәхмәт Мамадыш районы Көек Ерыкса җидееллык мәктәбендә физика-математика укыта. 1953—58 елларда КДУның тарих-филология факультетында укый һәм аны кызыл диплом белән тәмамлый. Уку дәверендә татар теле һәм әдәбияты кафедрасында өлкән лаборант булып эшли. 1960 елларда Буа районы "Яңа юл" газетасында бүлек мөдире, җаваплы секретарь вазыйфаларын да башкара әле ул. Фәннәр Академиясенең Тел, әдәбият һәм тарих институтындагы эшчәнлеген исә 1966 елда "фольклористика" белгечлеге буенча аспирант буларак башлап җибәрә, һәм бүгенгәчә шушы институтта баш гыйльми хезмәткәр дәрәҗәсендә җиң сызганып, кыйбласына тугрылыклы булып хезмәт куя.

Хуҗи Мәхмүтов исеме безгә балачактан ук таныш. Чөнки 12 томлык "Татар халык иҗаты" җыелмасын кулына алмаган бала сирәктер. Анда Х.Мәхмүтов туплаган йөзләрчә әсәр — мәкаль, табышмак, мәзәк, сынамыш, кереш мәкаләләре һ.б. урын алган. Мондый күпьеллык олы хезмәте өчен галим Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе белән бүләкләнә. Аны юкка гына атаклы К.Насыйри, Н.Исәнбәт, Г.Бәшировларның лаеклы дәвамчысы дип атамыйлар.

**2. Читтә яшәүче татарларның фольклорын туплаучы, өйрәнүче һәм матбугатка чыгаручы галим.**

Татарстанда гына түгел, аннан читтә яшәүче татарларның да фольклорын туплау, өйрәнү, матбугатка чыгару өчен нинди генә төбәкләрдә булмый галим?! Башкортостан, Чувашстан, Удмуртия, Мари Иле җөмһүриятләре, Омск, Киров, Новосибирск, Төмән, Пермь, Чиләбе, Свердловск өлкәләре дисеңме... Кыскасы, милләтебезнең рухи байлыгын барлау-туплауга, аның төрле тарафка чәчелгән күңел хәзинәсен җыйнап, тәртипкә китерүгә керткән өлеше искиткеч зур Хуҗиәхмәт аганың. "Гомумән, Х.Мәхмүтов — фольклорның "вак" төрләрен өйрәнүгә күп яңалыклар керткән, аларның эчке зурлыгын, мәгънәви тирәнлеген һәм шигъри гүзәллеген күпьяклап ачып биргән галим. Моңа аның, "Табышмаклар", "Мәкальләр һәм әйтемнәр" томнарыннан тыш, "Җомак әйтәм", "Кечкенә дә төш кенә", "Ел тәүлеге — 12 ай", "Язылмаган кануннар", "Канатлы сүз — хикмәтле сүз", "Мәңгелек яд-кяр", "Ай колакланса, ни була?", "Әйтем — чәчәк, мәкаль — җиләк" исемле китаплары һәм "Афористические жанры татарского фольклора" дигән докторлык диссертациясе ачык дәлил булып тора", — ди Н.Хисамов, галимнең әсәрләрне сайлаудагы таләпчәнлеген, тирән фикерләвен, шигъри җанлылыгын ассызыклап.

Хуҗиәхмәт Шаһиәхмәт улының фәнни эшчәнлеге афористик иҗат кысалары белән генә чикләнми. Әйтик, ул К.Насыйриның фольклор өлкәсендәге хезмәтләрен җентекләп өйрәнеп, мәкаләләр бастыра, аның әсәрләренең татарча икетомлыгын һәм русча бертомлыгын әзерләшә. Шулай ук Х.Бәдигый, Г.Камал, Г.Ибраһимов, Н.Исәнбәт, Ф.Урманче һ.б. фольклорчылар турында бихисап язмасы матбугатта дөнья күрә. Институтта әзерләнгән фольклор басмаларының мөхәррире буларак та шактый зур көч куярга туры килә аңа. Галимнең осталыгы, пөхтәлек-төгәллеге, үз-үзенә таләпчәнлеге күпләрне сокландыра, үрнәк-өлге булып тора.

Хуҗиәхмәт абый баш-аягы белән фән дөньясына чумган. Ул салмак кына, тыйнак кына, яңадан-яңа үрләр яулый-яулый үзе сызган юлдан мәгърур атлый. Җитмәгән җире юк. Казан, Алмата, Бишкәк, Анкара, Новгород, Тбилиси һ.б. шәһәрләрдә узган фәнни конференцияләрдә чыгышлар ясый, һәрдаим институтның Гыйльми һәм Диссертация советлары эшендә катнаша, яшь галимнәр белән җитәкчелек итә. Соңгы 5—6 ел дәвамында КДУ, КДПУ кебек мәшһүр югары уку йортларында Дәүләт аттестация комиссиясе рәисе булып эшли. Бу уңайдан университетларның Яр Чаллыдагы филиалларына да еш барырга туры килә аңа. Хөрмәт итәргә, яратырга өлгергәннәр үзен. Әнә КДПУ филиалының татар филологиясе факультеты деканы Әлфия ханым Шакирҗанова соклануын һич тә яшереп кала алмый:

— Зыялылык, затлылык үрнәге бит ул Хуҗиәхмәт әфәнде. Чын мәгънәсендә эчке культурага ия, тирән белемле, олы җанлы, ярдәмчел, кайгыртучан, хезмәттәшләрен дә, студентларын да ихтирам итүче кеше. Шулхәтле олы, затлы шәхеснең гадилеге гаҗәпләндерә. Гадилектә бөтен бөеклек, дип юкка гына әйтмиләр. Аның һәр эш-гамәлендә эчкерсезлек, изгелек ярылып ята.

Баксаң, безнең күренекле язучы-публицист Фаяз абый Дунай белән Хуҗиәхмәт ага сабакташлар булып, бер бүлмәдә яшәгәннәр икән бит. Яшьлек дустын "Белеп язуга ни җитә" исемле китабында бик җылы итеп искә ала Фаяз абый. "...Гомерләре буена шигырь яки хикәя язып та, аларны бастырып чыгарырга ният тә кылмыйча, тормышның башка өлкәсендә фидакарь хезмәт иткән асыл, фидаи шәхесләр аз түгел бу бай дөньяда! Мисаллар эзләп ерак барасы юк. Ярлы-ябык студент елларыбызда минем салмак-сабыр гына табигатьле бер дустым дүрт—биш ел матур-матур шигырьләр язып бастырды...

...Күп нәрсәне ачык, төгәл-конкрет белергә, бик томанлы, абстракт-теоретик фараз теоремаларны да тормышчан аңларга тырышучы бу зирәк акыллы сабакташымны мәрхүм шагыйрь Гали ага Хуҗиев бик ярата иде...

...Күпләр аның ихлас хисле, зирәк фикерле лирик шагыйрь буласына өмет багладылар.

Язмышына, бәхетенә кимлек китерердәй бәла-каза да булмады аның. Ул, үз табигатенә хас җитдилек белән укып, чын тирән белем белән университетны тәмамлады, берничә ел район газетасының эшлекле мәктәбен узды, тыйнак-ныклы гаилә корды. Әмма шул студент елларыннан соң, матбугатта бер генә шигырен дә күргәнем юк...

Аның каравы, ул фатирсызлыктан, гаиләсе белән кеше өстендә тору тарлыгыннан да курыкмыйча, янә Казанга килеп аспирантура тәмамлады, гыйльми дәрәҗә алды, әдәбият, тел, халык иҗаты, журналистика белгечләре арасында хөрмәтле шәхес, танылган галим булып үсте..."

Менә шулай бәяли Хуҗиәхмәт ага Мәхмүтовны дуслары-хезмәттәшләре. Үзе турында сөйләргә яратмый ул. "Үз-үзеңне мактама, дусларың сине мактасын", — диләрме әле? Шөкер, Хуҗиәхмәт аганың дуслары да күп, мактау-хуплауга лаеклы эшләренең дә очы-кырые юк. Әмма ирешелгәннәргә канәгать булып, эшсезлектән интегеп утырмый ул.Һаман да эзләнүдә, гыйлем дәрьясында йөзә.

"Соңгы вакытта мирасыбызның бик борынгы чыганакларын өйрәнү белән мәшгульмен. Мәгълүм ки, Кол Гали, Мәүла Колый чорында ук Коръән тәсфирләре, аять, хәдисләр татар халык иҗатына мәкальләшеп кереп киткән. Бу уңайдан Коръән нигезендә безнең татар халык афоризмнарының борынгы чыганакларын ачыклау максаты куйдым.

Урта гасыр шагыйрьләренең әсәрләрен өр-яңадан җентекләп өйрәнеп, "Коръәннән алынган тәгъбирләр" (якынча исеме) дигән китап чыгарырга ниятлим..." — ди галим, киләчәккә уй-планнарын барлап. Афәрин! Сәламәтлек, яңадан-яңа уңышлар телибез сезгә, Хуҗиәхмәт ага. Гыйлем-иҗат чишмәгез саекмасын... Акыллы, ягымлы күзләрегездә якты нур балкый. Илаһи көчкә ия гыйлем нуры ул!

Халык авыз иҗаты һәм урта гасырлар әдәбияты белгече — профессор Хуҗиәхмәт Мәхмүтов — бүгенге әдәби процессны да күз уңында тота, әдәбиятның үсеш кануннарын ачыклап, аерым әдәби күренешләргә һәм әсәрләргә бәя бирә.

Соңгырак буын вәкилләреннән Равил Рахмани, Сәгыйть Хафизов, Мансур Вәлиев, Галимҗан Гыйльманов һәм башкалар, әдәбиятыбызның үсешен күзәтеп, аерым язучылар иҗатларына һәм яңа әсәрләргә бәя биреп, бүгенге иҗади процесска уңай йогынты ясыйлар.

1966 елда Х. Мәхмүтов СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтына фольклор белгечлеге буенча аспирантурага керә, аны “Татар халык табышмаклары” дигән темага кандидатлык диссертациясе яклап тәмамлый һәм шушында ук эшкә калдырыла. Хәзер бу гыйлем йорты Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты дип йөртелә, Хуҗиәхмәт Мәхмүтов аның халык иҗаты бүлегендә баш фәнни хезмәткәр булып эшли.

Ул алып барган фәнни тикшеренүләрнең төп юнәлеше-татар халык иҗатының афористик жанрлары. Ул үзенең докторлык диссертациясен дә шушы тема буенча яклады. Татар фольклор белемендә беренче буларак, галим халык афоризмнарына җитди фәнни төркемләү үткәрде һәм аларны 14 мөстәкыйль төргә аерды (мәкальләр, әйтемнәр, канатлы сүзләр, ышанулар, юраулар, сынамышлар, алкышлар, каргышлар, ырымнар, антлар, әзер җаваплар, үртәвечләр, тизәйткечләр, җор сүзләр, табышмаклар). Бу жанрларның күбесе бездә әле бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән иде. Галим аларның һәркайсында билгеләмәләр бирде, жанрлык билгеләрен ачыклады. Халкыбыз авыз иҗатының гаять кызыклы бу өлкәсе буенча ул “Җомак әйтәм”, “Кечкенә дә, төш кенә”, “Ел тәүлеге-12 ай”, “Язылмаган кануннар”, “Афористические жанры татарского фольклора”, “Канатлы сүз-хикмәтле сүз”, “Болгар, Казан төшми телләрдән”, “Мәңгелек ядкарь”, “Ай колакланса, ни була?”, “Әйтем-чәчәк, мәкаль- җиләк” кебек мавыгып укыла торган китаплар язып бастырды.

Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге билгеләп үтелгән 12 тсмлык “Татар халык иҗаты” җыелмасының кайсы гына китабын ачып карасак та, анда Х.Мәхмүтов тарафыннан илебезнең татарлар яши торган төрле өлкәләрендә язып алынган йөзләрчә әсәрне табарбыз. Ул бу фундаменталь басманың редколлегия әгъзасы, биш томының фәнни мөхәррире булды, ә “Мәзәкләр”, “Табышмаклар”, “Мәкальләр һәм әйтемнәр” томнарын матбугатка турыдан-туры үзе әзерләде, аларга тирән эчтәлекле кереш мәкаләләр һәм фәнни искәрмәләр язды.

Хуҗиәхмәт Мәхмүтовның күп кенә хезмәтләрендә татар мәкальләрен борынгы төрки афоризмнар белән чагыштырып өйрәнүгә зур урын бирелә.8-14 йөзләргә караган төрки ядкарьләрдә (мәсәлән, Орхон ташъязмалары, Турфан текстлары, М.Кашгариның “Диване лөгатет төрк” сүзлеге, “Кодекс Куманикс” һ.б.) теркәлеп калган күпсанлы мәкаль, әйтем, табышмакларны җыеп, галим аларны беренчеләрдән булып татарча матбугатта бастырып чыгарды, борынгы текстларның бүгенге көнгә дә татар фольклорында сакланып килүче 300 гә якын тиңдәшләрен һәм вариантларын ачыклады, аларны җентекләп чагыштыру аша халык афоризмнарның туу, яшәү, үсү-үзгәрү юлларына кызыклы күзәтүләр ясады. Үзенең бу табышлары буенча Х.Мәхмүтов Казан, Анкара(Төркия), Бишкәк(Кыргызстан) шәһәрләрендә булып узган халыкара тюркологик конференцияләрдә докладлар ясады. Ә күптән түгел ул “Борынгылар әйткән сүзләр (8-17 йөз төрки-татар ядкарьләрендәге афоризмнар)” дигән яңа монография бастырып чыгарды. Хуҗиәхмәт Шаһиәхмәт улының Халыкара Төрки академиягә хакыйкый әгъза (академик) итеп сайлануы аның мондый тикшеренүләренең төрки халыклар фольклористикасында да киң танылуы турында сөйли.

Х.Мәхмүтов халык авыз иҗатын фәнни-теоретик яктан өйрәнү белән генә чикләнми, ул аны гамәли максатларда файдалану мәсьәләләренә дә җитди һәм даими игътибар бирә. Мәсәлән, аның “Язылмаган кануннар” дигән китабында татар халкына хас күркәм рухи сыйфатлар һәм аларның фольклорда гәүдәләнеше, яңа буыннарны әхлакый тәрбияләүдә бу төр әсәрләрнең мөһим роле бәян ителә. Хәер, мондый сүзләрне галимнең башка китапларына, матбугатта басылган 600 дән артык фәнни-популяр мәкаләләренә, радио буенча инде 30 елга якын аның катнашында бара торган “Тел күрке- сүз” тапшыруларына карата да һич икеләнмичә әйтергә мөмкин. Алар барысы да безгә халкыбызның бай рухи дөньясының тирәнрәк һәм тулырак аңларга, аның иксез-чиксез акыл-зиһен, тел-сүз хәзинәләрен, күп гасырлар буенча тудырып, туплап килгән югары әдәп-әхлак нормаларын, күркәм гореф-гадәтләрен яратырга һәм үзләштерергә ярдәм итәләр.

Тәрбия турында сүз чыккач, Х.Мәхмүтовның, остаз буларак, фәнни-педагогик кадрлар әзерләүдә катнашуын да әйтеп үтәргә кирәк. Аның җитәкчелегендә 2 докторлык, 5 кандидатлык диссертацияләре якланган. Менә 6 ел инде, ул Казан дәүләт университеты, Казан педагогика университеты һәм башка уку йортларына Дәүләт аттестация комиссиясе рәисе итеп чакырыла. Бу чорда әлеге вузлардан 800 гә якын кеше “Татар теле һәм әдәбияты укытучысы” дипломнары алып чыккан.

Әйе, Хуҗиәхмәт Мәхмүтов киләчәккә күркәм казанышлар белән килә. Ул- Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге лауреаты, академик, Татарстанның һәм Россия Федерациясенең

атказанган мәдәният хезмәткәре. Президентыбыз М.Ш.Шәймиев Указы нигезендә галим Татарстан Республикасының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

**3. Х.Мәхмүтовның фәнни хезмәтләре һәм китаплары.**

Җыр — татар сәнгатенең иң популяр һәм аеруча тиз үсә-үзгәрә торган жанрларыннан берсе. Ул менталитет чагылышы гына түгел, мәдәниятнең гомумторышы, халыкның рухи халәте күрсәткече дә. Шуңа күрә дә җырның асыл сыйфатларын, җыр текстында тупланган сүз сәнгате хәзинәсен өйрәнү көнүзәк әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе булып тора.

Күптән түгел Татарстанның "Мәгариф" милли нәшриятында әдәбият һәм фольклор галиме, филология фәннәре докторы, татар җыр шигърияте теориясенә, телләр сәясәте өлкәсенә багышланган фәнни хезмәтләр, уку әсбаплары авторы, Татарстан Хөкүмәтенең телләрне үстерү бүлеге башлыгы Ким Миңнуллинның "Һәр чорның үз җыры" исемле китабы дөнья күрде.

Әлеге хезмәтендә галим татар җырын сүз сәнгате буларак өйрәнә. Китапта җырларның өйрәнелү тарихы, сүз тылсымына ия булган әлеге синтетик жанрның үзенчәлекле функцияләре һәм яшәү закончалыклары, бай образлар һәм сурәтләү чаралары тикшерелә. Татар халык, профессиональ җырлары, татар җырларында образлар системасы, аларның композицион төзелеше, кулланылган поэтик алымнар өйрәнелә.

Хезмәт җыр сәнгатен өйрәнүче белгечләргә, укытучыларга, студентларга һәм гомумән милли сәнгатебез белән кызыксынучыларга тәкъдим ителә. Китапның фәнни редакторы — филология фәннәре докторы Х.Мәхмүтов.

Халыкның тарихи аңы да, милли горурлыгы да,  туган җиргә, Ватанга мәхәббәт һәм бирелгәнлек хисләре дә,рухи -әхлакый сыйфатлары да, гореф-гадәтләре, йола-бәйрәмнәре дә-барысы яшәү, тереклек тамырлары белән туган телгә барып тоташканнар.Борын-борын заманнарда ук, әле язу барлыкка килгәнче үк,сәләтле кешеләр төрле мәкаль-әйтемнәр, җыр-бәетләр,әкиятләр чыгарганнар.Алар телдән-телгә күчеп,әдәби яктан камилләшкәннәр һәм халыкның рухи хәзинәсенә, халкыбызның күңел көзгесенә әйләнгәннәр .Халкыбызның иксез-чиксез акыл-зиһен, тел-сүз хәзинәләрен,күркәм гадәтләрен яратырга һәм үзләштерергә ярдәм итүче,халык иҗаты серләрен ачучы,фольклорчы галим,язучы якташыбыз Хуҗиәхмәт ага Мәхмүтовның иҗаты күпкырлы. Милләтнең яшәеше, алга баруы өчен аның үз үткәнен белүе, тарихи хәтергә ия булуы, әби-бабаларының тереклек тәҗрибәсенә таянуы шарт. Боларның шактые исә фольклорда, халыкның сүз сәнгатендә, телендә тупланып, оешып калган. Каюм Насыйри, Габдулла Тукай, Нәкый Исәнбәт кебек олуг затлар, нәкъ менә шуңа күрә дә халык иҗаты әсәрләрен туплауга, аларны өйрәнүгә, халыкка кабат җиткерүгә җитди игътибар иткәннәр. Хуҗиәхмәт ага Мәхмүтов-әнә шул

игелекле традицияләрне дәвам иттерүчеләрнең берсе. Аның өчен фольклорны өйрәнү-гади шөгыль генә түгел, ә яшәешнең төп мәгънәсе.

Хуҗиәхмәт Мәхмүтов халык авыз иҗатын фәнни-теоретик яктан өйрәнү белән генә чикләнми, ул аны гамәли максатларда файдалану мәсьәләләренә дә җитди һәм даими игътибар бирә. Мәсәлән, аның ”Язылмаган кануннар” дигән китабында татар халкына хас күркәм рухи сыйфатлар һәм аларның фольклорда гәүдәләнеше яңа буыннарны әхлакый тәрбияләүдә бу төр әсәрләрнең мөһим роле бәян ителә.Китапның икенче бүлеге “Әдәп башы-тел”дип исемләнгән һәм “Тел дигән дәрья бар,төбендә энҗе-мәрҗән бар,белгәннәр чумып алыр, белмәгәннәр коры калыр” дигән халык мәкале белән башланып китә.Татар халкы чит телләр өйрәнүгә элек-электән уңай караштa торган.Ләкин бу әле үз туган теленнән йөз чөерү өчен нигез була алмый.Андый кыланчык,милли хисен югалткан кешеләрне халык үзенең мәзәкләрендә көлү объекты итеп ала,аларны төрле уңайсыз хәлләргә төшереп сурәтли.”Язылмаган кануннар”җыентыгында да шундый мәзәкләр һәм мәкальләр бик күп.

1.Иле барның теле бар, теле барның юлы бар.

2.Туган телен кадерләгән халык кадерле булыр.

3.Туган телен сөймәс, туган анасын белмәс.

4.Тел –ананың теләге, тел ананың баласына-иң кадерле бүләге.

5.Телнең зиннәте –туры сүз.

6.Сүзе хакның йөзе ак.

Табышмаклар:

1.Әйтермен миннән китәр, тыңламасаң синнән китәр. /сүз/

2.Теле юк үзе аңлата. /китап/

3.Иң ачы да, иң татлы. Ул ни? /тел/. Һәрбер кеше, кем булуына карамастан, үзе бер дөнья: аның үз тарихы, үз тормышы, үз офыклары бар. Якташыбыз Хуҗиәхмәт аганың дөньясы үзенең яктылыгы, җылылыгы, зурлыгы белән аеруча мөхтәрәм урынны били, башкаларга үрнәк булып тора. ”Мәкаль – тел ачкычы, мәзәк-күңел ачкычы, табышмак-зиһен ачкычы” дигән канатлы гыйбарә бар. Без Хуҗиәхмәт ага Мәхмүтовны, халкыбыз иҗатының әнә шул жанрларына фәнни ачкыч табып, аларның мәгънәви байлыгын һәм тылсымлы шигъриятен өйрәнүгә гомерен багышлаган талантлы галим, фольклорчы дип саныйбыз һәм аның белән горурланабыз.

**4.Гыйльми эшчәнлеге хакында фикерләрдән**

...Кереш сүзне (“Татар халык иҗаты. Мәзәкләр” 1979) томына Х.Мәхмүтов язган кереш мәкалә турында сүз бара. –мәзәкләр турында моңа кадәр язылган мәкаләләрнең иң бай эчтәлеклесе, әтрафлысы һәм остарак язылганы дияргә нигез бар... Автор бу хезмәтенә

сирәк табыла торган төрле чыганаклар җәлеп иткән, мәзәкнең моңа кадәр өйрәнелмәгән күп якларын ачыклап биргән.... Гомумән, бу кереш сүз татар фольклористикасына мөстәкыйль әдәби һәм фәнни кыйммәте булган игътибарга лаеклы махсус бер хезмәт булып өстәлде дип уйлыйбыз.

Гомәр Бәширов, Татарстанның халык язучысы. 1980

Соңгы елларда ул борынгы төрки чыганакларны җентекле өйрәнүгә аерым бер игътибар бирде.... Шунсын әйтмичә кала алмыйм: безнең арада татар афоризмнарының ерак тамырларын бу яссылыкта тикшерүче башка белгеч әлегә юк.

Илбарис Надиров, фольклорчы галим, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты. 2003

Мөхтәрәм Хуҗиәхмәт әфәнде!

Китабыгызны ("Мәңгелек ядкяр" монографиясе күздә тотыла.) алдым, укып та чыктым инде... Китап, күләме белән кечкенә булса да, бик эчтәлекле. Файдасы аның халыкка да бар, гыйлемгә дә бар! Яратып, ихлас күңел белән язгансыз. Ул беренче битләрдән үк күренә...

Әдһәм Тенишев, тел галиме. 2003

Аның өчен фольклорны өйрәнү –гади шөгыль генә түгел, ә яшәешенең төп мәгүнәсе. Х. Мәхмүтов, ничектер, һәр сүзнең, һәр гыйбарәнең кыйммәтен бөтен күңеле белән тоеп яза. Моңа, бер яктан, аның табигый таланты, сүзгә гашыйклыгы, икенче яктан, тирән белеме, мөгаллимлек, журналистлык тәҗрибә -күнекмәләре дә ярдәм итә. Гомумән, Х. Мәхмүтов- тапкыр, акыллы сүзле, язмалары белән генә түгел, сөйләме белән дә кешеләрне үзенә каратып торучы, көйле, ипле зат. Ул, ничектер, үзе көлмичә дә, үзгәләрне көлдерә, күңелләрне күтәрә белә.

Хатыйп Миңнегулов, әдәбият галиме. 2003

Х. Мәхмүтовның хезмәтләре ... безнең күз алдына Каюм Насыйри, Нәкый Исәнбәт, Гомәр Бәшировлар эшчәнлегенең лаеклы дәвамы рәвешендә килеп басалар.

Нурмөхәммәт Хисамов, шагыйрь, әдәбият галиме. 2004

**III. Йомгак**

Бу кечкенә генә фәнни эшемдә Мамадышымның горурлыгы –Хуҗиәхмәт ага Мәхмүтовның хезмәтен тулысынча бәяләү мөмкин түгел. Аның тормыш юлы, милләтебезгә кылган изге гамәлләре миндә зур соклану һәм горурлык хисләре уята. Бу асыл галимебез турында һәркем белергә тиеш.

Минемчә, Хуҗиәхмәт ага өчен фольклорны өйрәнү-гади шөгыль генә түгел, ә яшәешенең төп мәгънәсе. Ул афористик жанрларны хәзерге укучының күңел хәзинәсенә әйләндерергә омтыла.  Аның хезмәтләре безнең күз алдына Каюм Насыйри, Нәкый

Исәнбәт, Гомәр Бәшировлар эшчәнлегенең лаеклы дәвамы рәвешендә килеп басалар. Бөек мәгърифәтчебез Ризаэтдин Фәхретдиннең бик тә кыйммәтле һәм гыйбрәтле сүзләре бар: ”Әдип вә галимнәре булмаган халык бәхетсез ,мәшһүр кешеләрен онытkан халык көчсез...”

Без бик тә бәхетле, чөнки әдипләребез, галимнәребез чиксез күп безнең. Олуг затларыбызны онытырга, көчсез халык булырга хакыбыз юк!

**Кулланылган әдәбият**


1. Бәширов, Г. Көлкенең хикмәте бардыр. - Казан утлары,1980. - № 2.

2. Даутов, Р, Гамбаров, Н. Балачак әдипләре. – Казан : Мәгариф нәшр., 2005 нче ел.

3. Надиров, И. Хуҗи сүзләрендә хикмәт бар. - Мәдәни җомга ,2003 нче ел.

4. Мәхмүтов, Х. Канатлы сүз-хикмәтле сүз. – Казан : Мәгариф нәшр., 1999 нчы ел.

5. Хисамов, Н., Урманче, Ф. Халык иҗаты серләрен ачучы. - Нократ газетасы, 14 нче февраль 2003 нче ел.

6. Мәхмүтов, Х. Мәңгелек ядкяр. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2002 нче ел.

7. Миңнегулов, Х. Игелек иясе. - Казан: Мәгариф нәшр., 2004нче ел.



*Зиннәтуллина Рузилә, 8 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының*
*«Мөрәле төп гомуми белем мәктәбе»*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Шәрәфиева Ләйсән Әлхәт кызы,*
*туган тел һәм әдәбияты укытучысы*


## Туган авылым – чишмәләр иле

### Кереш

Туган як...Туган җир...Туган авыл... Нинди якын, нинди кадерле бу сүзләр. Безнең һәрберебезнең туган ягы, газиз туган йорты урнашкан туган авылы бар. Һәр авылның үзенә генә хас, истә кала торган урыннары күп.Сокланып туймаслык болыннар,челтерәп ага торган йөгерек чишмә буйлары,камышлы күлләр,туган ягыбызның кырлары,басулары,шаулап торган урманнары күңелләргә рәхәтлек бирә,туган якка мәхәббәт тәрбияли. Без ходай биргән бу байлыкны саклый белергә тиешбез. Чиста сулы елгаларын, күлләрен пычрату,урманнарны кисеп бетерү,чишмәләрне сакламау,аларның кибүенә, тапталып бетүенә юл кую-бу туган як табигатенә зыян салу дигән сүз.

Минем проект эшенең темасы «Туган авылым – чишмәләр иле” дип атала. Ни өчен бу теманы сайладым соң мин? Нәрсә соң ул чишмә? Кешеләргә чишмәләр кирәкме? Ни өчен? Кайбыч районы Мөрәле авылында нинди чишмәләр бар? Алар бүгенге көндә ни

хәлдә? Татар халкында чишмәләргә бәйле нинди гореф-гадәтләр бар? Шушы сорауларга җавап табу максатыннан мин әлеге эзләнү эше белән шөгыльләндем. Мин Мөрәле авылындагы чишмәләргә тукталырга булдым.

**Проектның максаты**: Авылыбыздагы чишмәләр турында мәгълүмат туплау.

**Проектның бурычлары:**

-чишмәләр турында мәгълүмат туплау;

-туган авылыбыз чишмәләрен барлау;

-төбәгебез тарихын өйрәнүгә кызыксыну уяту;

-чишмәләргә бәйле йолаларны, гореф-гадәтләрне ачыклау;

-туган җиребезгә, табигатебезгә, чишмәләребезгә карата игътибарлылык, сакчыллык һәм мәрхәмәтлелек тәрбияләү.

**Проектның актуальлеге**: чишмә атамаларның тарихын өйрәнеп, алынган нәтиҗәләрне авылның тарихын торгызуда файдалану.

**Тикшеренү объекты:** авылыбыздагы чишмәләр.

**Эзләнү гипотезасы:** без чишмәләрне сакламасак, алар корырга мөмкин.

**Эзләнү методы:** эзләнү, тикшеренү һәм нәтиҗә чыгару

**Алымнар:** фәнни әдәбият белән танышу, музейда, китапханәдә эшләргә өйрәнү; авылыбызның өлкән кешеләреннән атамалар тарихын сөйләтү, сораулар бирү,күзәтү,интернет куллану, язмаларны редакцияләү; чишмә, сулык күренешләрен фотога төшерү.

## Төп өлеш

## Чишмәләр-барлык сулыкларның башлангычы

Чишмәләр – барлык сулыкларның башлангычы, тукландыра торган чыганаклары. Кеше гомере башланып киткән кебек үк,инешнең дә башлангычы бар. Бу – чишмәләр.Чишмә, тау астыннан көмеш күзе белән җирне тишеп, бик зур кыенлыклар белән саркып чыга,бөдрә дулкыннар ясап,әкрен генә ага.Аның көмеш сыман тамчылары кояш нурлары астында энҗе бөртекләре кебек җемелдиләр. Чишмәләр турында:”Башы – тауда,аягы диңгездә”дигән табышмак бар.Зур елгалар үзләренең мул сулары белән чишмәләргә бурычлы бит. Һәр елга башы – чишмә,ә инеш-елгалар, диңгезләрне тулыландыра. Һәр чишмәнең үз тарихы,үз моңы,үз юлы бар.Беришесе шарлап ага,тавышы еракларга ишетелә,баннарны сөендерә,күңелне шатландыра.Икенчеләренең тавышы янына килгәч кенә ишетелә,әйтерсең ул үз-үзенә сөйләнә. Өченчеләре җир куеныннан кайнап, ургылып чыга, әйтерсең ул җир асты юлларын уза-уза ялыккан,арыган.Чишмәләр,кечкенә генә булсалар да,табигатькә җан кертүчеләр, елга, күл, инеш, океаннарга тормыш бирүчеләр. Чишмә яшәүдән туктаса,елга-күлләрдә су бетәчәк, табигатьтә ямь калмаячак.

**Чишмәләрнең әһәмияте**

Чишмәләрнең әһәмияте бик зур. Халык чишмәләрне бик зурлый. Бу тикмәгә генә түгел. Без көн саен чәй кайната, аш пешерә, юына һәм коена торган шушы гап – гади суның искиткеч гаҗәеп яклары, тылсымлы сыйфатлары бар. Күз алдына китерүе дә кыен булган дәрәҗәдә озын гомерле ул су! Без иртә торуга битне юа яисә ансат кына эчеп җибәрә торган шушы төссез сыекчада 60 тан артык химик элемент бар диләр. Сусыз яшәү мөмкин түгел. Кеше ашамыйча атналар буе тора ала. Әмма сусыз берничә көнгә дә түзә алмый. Әгәр кеше тәнендәге суның уннан бер өлеше генә кимесә дә, аның хәле начарлана, диләр галимнәр. Менә бит суда нинди тылсымлы көч бар. Чишмәләргә кешеләр борынгы заманнардан ук табынып яшәгәннәр. Чишмә суларын эчеп дәваланганнар. Чишмәләр сафлыкка, чисталыкка өндәгән. Чишмәләр янында кешеләр сафланып, чистарып киткәндәй була. Судагы могҗиза берни белән дә чагыштырыла алмый. Күз тигән һәм гомумән авырган кешеләрне таң суы алып коендыра торган гадәт тә суның илаһи көче турында сөйли. Таң суы белән коендыру йоласы төрле урыннарда төрлечә. Ләкин барлык җирләрдә дә ул кояш чыкканчы алына. Кирәкле догаларны укыгач, шунда ук яисә бер-ике төн кундыргач, авыруны шул су белән коендыралар. Авыру шушы гамәлдән соң, һичшиксез, сихәт ала.

Чишмәләр – суын эчәр һәм юыну өчен кирәк, табигатьне бизәр өчен кирәк.Әйе.Кеше сусыз яши алмый.Кеше организмы нигездә үзе дә судан тора, суы бетсә-үлә.Су-тормыш чыганагы.Чиста су,саф һава,икмәк безгә яшәү өчен кирәк.Өлкән кешегә көненә уртача 1,5-2литр су эчәргә кирәк.Бу матдәләр алмашынуын тәэмин итү өчен зарур.Хатын-кызларның гүзәллеген  озак саклау өчен табигый ысулларның иң тәэсирлесе-су эчү.Организмга кирәкле дәрәҗәдә су кермәсә,аш кайнату эшчәнлеге дә зарар күрә.Су ашыйсы килүне киметә,организмда җыелган кирәкмәс матдәләрне эретергә,кешегә ябыгырга ярдәм итә. Иртә белән торгач та, 1-2 стакан су эчсәгез, көне буе кәефегез күтәренке булачак. Менә бит суда нинди тылсым көче бар. Кеше организмындагы артык су җыелмасын да су кудыра. Кайбер чишмәләрне халык шифалы яки изге дип атаган. Тозы күп чишмәләр янында дәвалау үзәкләре дә төзелә.

Чишмәләр-безнең рухыбыз, Болгар бабаларыбыздан шушы көннәргә кадәр килеп җиткән бай мирас. Борынгы бабаларыбыз үз авыл, шәһәрләрен нәкъ менә чишмә, су буйларына корганнар, суның кадерен белгәннәр.

**Чишмәләр һәм гореф-гадәтләр**

Чишмәләр турында бик күп шигырьләр, җырлар, әдәби әсәрләр иҗат ителгән. Халык элек-электән чишмәләргә табынган. Чишмәләргә бәйле йолаларны сакларга тырышкан. Кайбер йолалар бүгенге көндә дә башкарыла. Әйтик, томыш юлына аяк басучы яшьләр

гаиләләре нык булсын өчен, тормыш чыганагы булган чишмәгә киләләр, аңа баш ияләр. Чишмә янын ямьләндереп агачлар утырталар.

Яшь кәләшләр килен булып төшкән көнне, иңнәренә көянтә-чиләк асып, чишмәгә суга барганнар. Йола буенча авылның берәр мөхтәрәм кешесе су юлы күрсәтүче булган. Чишмә янында җыр-биюле уен-көлке оештырганнар. Суын түкмичә алып кайтып җиткерүче кәләш яхшы тормыш иптәше, уңган килен булып саналган.

Егет-кызлар чишмә янында уеннар оештырганнар, йөрәкләренә ял тапканнар. Чишмәләр бик күп гашыйкларның серләрен саклаган. Чишмә янында корылган матур хыяллар тормышка ашкан.

Авыру кешеләр туган ягы чишмәсенең суына авыз тисәләр, савыга торган булганнар. Менә нинди сихри көч бар чишмә суында!

Чишмә буена язгы-җәйге коры көннәрдә авылның мөхтәрәм ак әбиләре Аллаһы Тагәләдән яңгыр сорарга бара торган булганнар. Бу йола җомга көнгә туры китерелә торган була. Ак әбиләрнең Ходайга ялваруы белән могҗиза була: бөтен дөньяны суга туендырып яңгырлар ява.

**Туган авылым чишмәләре**

Еллар үткән саен, кешеләрнең тормышы яхшыра бара. Чишмәләр онытыла. Алар янындагы агачлар киселә, сындырыла, тирәсен мал-туар таптый. Тирә-ягына чүп-чар ташлана, шул сәбәпле чишмәләр корый. Аның суы агып төшә торган елгалар, инешләр дә корый, кибә. Су, дым булмагач үләннәр,куаклар,болыннар да корый,бу тирәгә кошлар да оя кормый.Анда табигать үлә.Димәк,чишмәләрне сакларга кирәк.

Безнең арабызда табигатьне яратучы яхшы күңелле кешеләр дә бетмәгән. Соңгы елларда район һәм авыл советлары җитәкчелегендә авылыбыздан чыккан эшмәкәрләр ярдәме белән күп кенә чишмәләр төзекләндерелде. Туган авылымның шундый чишмәләре белән таныштырып китәсем килә.

Бүгенге көндә Мөрәле авылы җирлегендә чишмәләр шактый күп икән. Авылның иң газиз бер өлеше итеп, яратып, матур атамалар да кушканнар чишмәләргә: **Минбәян чишмәсе, Каен чишмәсе, Сәлах чишмәсе, Боламык чишмәсе, Мунчала күле чишмәсе, Изгеләр чишмәсе, Авыл чишмәсе...** Бу су чыганаклары халык тормышының истәлек—хатирәләре һәм олы тарихы турында сөйлиләр.

**“Боламык чишмәсе”**

Бу чишмәгә авылның аръяк урамын чыгып көнчыгышка таба барырга кирәк. “Иске йорт чокыры” дигән үзәнедә инеш агып чыккан. Анын кизләве да булган. Авыл халкы шушы кизләүдә Боламык пешереп бергә жыелышып ашаган."Боламык кизләве" атамасы да шуннан барлыкка килган. Әлеге чишмәнең суы бик тәмле һәм шифалы.

**“Каен“ чишмәсе**

Бу чишмә авылыбыздан бик еракта ага. Әлеге чишмә яр астыннан бәреп чыккан. Чишмәнең суы иң тәмлесе һәм иң йомшагы. Әлеге чишмә буена авылым кешеләре туган көннәрен, очрашу кичәләрен үткәрергә, “Сабантуй” бәйрәмнәрендә ял итәргә киләләр. Мәктәп укучылары яз көннәрендә экскурсиягә баралар. Бу чишмә буе ял итү өчен иң кулай урын.

**“Минбәян” чишмәсе**

Әлеге чишмә авылыбызга якын гына олы юл өстендә агып ята. Чишмәнең исеме Минбәян исеме белән йөртелә. Мөрәле авылы җирле үзидарә җитәкчесе Зиннатуллин Ринат Рифат улы әйтүенчә, элегерәк бу чишмәне Зиннәтуллин Габделкәрим бабай исән вакытта гел карап, төзәтеп торган. Соңрак, район оешкач, 1995-1996 елларда авылдашыбыз Фәргать Нәҗиев җитәкчелегендәге мелиорация оешмасы төзекләндергән.

Бу чишмәнең урыны сазлыклы. Элегрәк аннан ерак түгел күл дә, мул сулы чишмә дә булган. Еллар үтү белән, күл тирәсен агачлар чорнап алган, язгы ташулар вакытында ләм тулып, күл дә, чишмә дә күмелеп, сазлыклы урынга әйләнгән. Берничә ел элек бу чишмәнең суын суыртып, ләмен чистартканнар. Соңгы елларда мәктәп укучылары, җирле үзидарә чистартып, тәртиптә тоталар.2017 елда бу чишмәне эшмәкәр Руслан Хафизов төзекләндерде һәм әбисенең исеме белән атады. Минбәян бик батыр, эшчән хатын булган.

**Тау асты чишмәсе (Авыл чишмәсе)**

Авылның нәкъ уртасында инеш буендагы яр астыннан агып чыгучы бу чишмә авылдагы иң борынгы, шул ук вактта бүгенге көндә дә халык иң күп йөри торган чишмәбез. Элек чишмәнең суы бик көчле булган. Хәзер алай ук түгел инде. Чишмә янында яшел таллыклар. Бу чишмәгә игътибар, тәрбия аеруча зур – ул авылыбызның иң төп чишмәсе. Гомер -гомергә ул гел яңартылып, төзеклектә тотыла. Бүгенге көндә дә авылыбыз халкы чишмәгә даими су алырга һәм кер чайкарга йөри. Суы йомшак һәм тәмле дип әйтәләр олылыр. Без, укучылар, тирә ягын чүп-чардан чистартабыз, авылның хатын-кызлары яз көне бурасын эчке яктан юалар.

**“Сәлах абый” чишмәсе**

Исеменнән күренгәнчә, бу чишмә исеме шулай ук кеше исеме белән бәйле. Бу чишмәне авылның Сәлах дигән кешесе гел карап,чистартып торган.Үткән ел бу чишмә авылыбызның мәрхәмәтле кешеләре, ягъни Сәлах абыйның онык һәм оныкчыклары тарафыннан төзекләндерелде. Минһаҗев Илшат абый гайләсе белән чишмә буе ел әйләнәсендә карап,чүп-үләннәрдән арындырап торалар.Чишмәгә кыш көне дә юл өзелми.Аның суы бик шифалы һәм тәмле.

**Изгеләр кизләве**

Авылның көньягына таба чыгып киткәч "Изгеләр зираты" дип йөртелүче зират бар. Халык телендә "Иске йорт" урыны дип тә йөртелә. Авыл аксакларының сөйләвенә караганда, Мөрәле авылы элек хәзерге урыныннан бераз читтәрәк урнашкан иске зират янындагы Иске йорт дип аталган җирдә булган. Тора- бара авыл чик кизләве буена күчерелгән. Сазлыклы җир булу сәбәпле, халык хәзерге урынга күченгән.Авылның өлкән кешеләре зират өстеннән йөрмәсеннәр өчен аның дүрт ягына да баганалар утыртып билге ясап куйганнар. Халык иске авыл урынына хөрмәт белән карый.Менә шунда чишмә бәреп чыккан, шуңа күрә чишмәне Изгеләр кизләве дип йөртәләр. Читтә яшәүчеләр дә Изгеләр кизләвенә (Боламык кизләвен тагын бер терле атамасы) барып гыйбадәт кылалар,чүмеч, тастымаллар куялар.

**Мунчала күле чишмәсе**

Чишмә урман эченнән агып чыга. Урман читендәге чокырга җыелып. Күл хасыйл итә. Анда юкә агачының кабыгын салдырып, кабыкны суга өеп куя торган булалар.Бер ай шунда яткач кабык йомшый. Кабыкны судан алып, мунчаласын кубарып, яхшылап суда юып, элеп киптерәләр. Ул мунчала юынырга да, идән юарга да, арканнар, баулар ишәргә дә ярый торган була. Чишмә дә, күл дә шул исемне йөртә.

**Йомгаклау**

**Чишмәләрне онытмыйк!**

Яшел яфраклар шаулап, болыннардагы чирәмнәр хуш ис бөркеп, чишмәләр челтерәп аккан матур урында яшәү нинди зур бәхет, нинди шатлык! Шуның өстенә, сәламәтлеккә дә нинди файдалы! Бу матурлык югалмасын өчен табигатьне сакларга, чишмәләрне һәрвакыт чистартып торырга кирәк. Димәк, бүгенге көндә алар кеше ярдәменә, безнең ярдәмгә мохтаҗ.

Проект эшен башкарганнан соң мин түбәндәге нәтиҗәгә килдем:

Безгә чишмәләр кирәк. Безнең әби-бабаларыбыз да кадерләгән, хөрмәт иткән аларны. Ләкин табигать байлыгы чиксез түгел. Табигатькә һич кичекмәстән ярдәм итү юлларын уйларга кирәк. Киләчәктә дә чишмәләргә юл өзелмәсен иде! Алар озын гомерле булсын, һәм кешеләрнең дә гомерләрен озынайтсыннар иде! Сакчыл караш белән алдагы көндә дә чишмәләрне саклыйк! Туган йортын, туган авылын, туган ягын чын куңелдән яраткан кеше генә Ватанын ярата һәм кирәк вакытта, аны саклау өчен, үз – үзен аямыйча, көрәшкә күтәрелә. Аны исә чишмәләрдән, елга - күлләрдән башка күз алдына китереп тә булмый.

Проект эшемне "Чишмәләр" шигыреннән алган түбәндәге юллар белән тәмамларга телим:

Сакласыннар күз карасы кебек,

Телмәсеннәр җирнең бәгырен.

Саклыйк җирне, саклыйк табигатьне,

Белик, дуслар, чишмә кадерен!

Җир куеныннан көмеш балдаклар чыгарып ургылучы чишмәләр кемгә генә кадерле түгел икән?! Безнең балачагыбыз да гүя шуннан башлана, яшел чирәмле юлы безне олы тормышка алып чыга. Чишмәләрнең кайнап чыгуын без һәрвакыт йөрәк тибешендә тоябыз. Җиребезнең кабатланмас бу бизәге җырларыбыздан да, телебездән дә мәңге төшми.

Сусыз калсак әгәр, корыячак
Табигатьнең иркә гөле без,
Җилләр иссен, назлы гөлләр үссен, -
Чишмәләрнең кадерен белегез!
Изге чишмәләргә төкерсәк без,
Саегыр җан, корыр телебез,
Бездән соң да челтерәп – челтерәп аксын, -
Чишмәләрнең кадерен белегез!

Кулланылган әдәбият

1. Баязитова,  Ф. С. "Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары", 1995.

2. Гарипова, Ф. Г. Авыллар һәм калалар тарихыннан. – Казан: Тат. кит. нәш., 1997 ел.

3. Исхаки, Г. Идель. Урал. - Казань: Тат. Книж. из-во., 1991ел.

4. Саттаров, Г. Ф. Мәктәптә туган як ономастикасы. – Казан: Тат. кит. нәш. - 1984 ел.

*Ислямова Зарина, 8 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының*
*«Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче 2 нче Кама Аланы урта мәктәбе»*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Хайруллина Лилия Аркадий кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Авылымның данлы битләре (Болгар авылы тарихы)

### I.КЕРЕШ

Туган ил кайдан башлана? Бәлки, сабый беренче күргән авыл өстендәге зәңгәр күктәндер? Бәлки, Туган ил турындагы беренче хисләр, уйлануларданДыр? Бәлки туган йорттан, үзең белем алган мәктәптәндер...

Шулай да, Туган ил ул, минемчә, туган авылыңнан башлана. Кая китсәң дә, авылга тизрәк кайтасы килә, аны юксынасың. Кыскасы, туган авыл һәркем өчен дә бик кадерле ул.

Мәктәптә илебез тарихын, башка илләр тарихын өйрәтәбез, ләкин уку программаларында туган авылның тарихын өйрәнү каралмаган. Минемчә, үзен мәдәниятле, зыялы санаган хәзерге заман кешесе үз авылы тарихын белергә, аның белән кызыксынырга тиеш. “Үткәнен белмәгән кешенең киләчәге юк” диләр бит. Авыллар тарихы, аның күренекле кешеләре турында материалларны әзме-күпме табарга була. Ил тарихында зур роль уйнаган колхоз- совхозлар турында бик аз өйрәнелгән. Менә мин дә күп еллар укучыларга белем биргән мәктәп урнашкан Болгар авылы тарихында бай урын алып торган колхозлашу чоры, колхоз- совхоз булып торган вакытларын; иген- кырларында, терлекчелектә хезмәт иткән авыл батырлары турында мәгълүматлар туплый башладым. Табылдыклар белән уртаклашырга булдым.

**Эшемнең темасы**: «Авылымның данлы битләре»

**Проектның актуальлеге**: үз тарихын белмәгән халыкның киләчәге юк. Бала туган җиренең тарихын белергә, шуның аша халыкка якынаерга тиеш. Халыкка якынаю -Туган җиребездә, аның авыл тарихын, үткән тарихында- колхозлар-совхозлары турында эз калдырган - якташларыбыз, авылдашларыбыз турында сөйләү. Авылның 100 еллыгына материал туплау. Китап чыгаруга өлеш кертү.

**Проект эшенең максаты**: Болгар авылы тарихын, мәктәп тарихын, колхозлашу чорларын өйрәнү.

**Максатыма ирешү өчен түбәндәге бурычлар куелды**:

* Болгар авылы тарихын, авылның барлыкка килүен өйрәнү;

* Болгар мәктәбе тарихын, аның җитәкчеләрен барлау;

*авылым тарихындагы колхозлашу вакытына кагылышлы кайбер тарихи документларга, халыктан язып алынган мәгълүматларга таянып, 20 нче гасыр башы тарихын яктырту;

* ”Память Ильича” совхозы чоры турындагы истәлек - материалларны күбрәк туплау, эзләнүләр алып бару, совхоз эшчәнлегенә зур өлеш керткән авылдашларны барлау.

*югала барган тарихи материалларны яңарту; авылдашлар, якташлар, әби-бабаларымның үткәнен барлау.

Авыллар тарихы, колхозлашу чорлары материалларын анализлау, сораштыру, әңгәмә **алымнар**ыннан файдаландым. Әлеге хезмәтне эшләгәндә миңа Болгар авылы турындагы китаплар, авылның олы кешеләренең истәлекләре терәк булды.

**Теманың өйрәнелү дәрәҗәсе:** проект эшенә тәкъдим ителгән теманы укыгач та, минем күңелемдә бихисап фикерләр туды. Эчтәлекне төрлечә ачарга мөмкин. Тарихи китапларда, энциклопедияләрдә, интернет чараларында бу тема төрлечә яктыртылган. Кемдер колхоз- совхозлар турында уңай фикердә, икенчеләр тискәре уйларын да

җиткергән.  Нәрсә язсалар да, бу еллар тарих бит инде. Мин дә бу кызык та, шомлы да еллар, илгә яңалыклар алып килгән бу еллар турында үз фикеремне әйтергә булдым.

Проект эше традицион рәвештә кереш, төп өлеш, йомгаклау, әдәбият исемлеге һәм кушымтадан гыйбарәт.

Кереш үз эченә проект эшемнең актуальлеген, өйрәнелү дәрәҗәсен, максатын һәм бурычларын ала.

Төп өлешнең беренче бүлеге Болгар авыл тарихы турында мәгълүматларны үз эченә ала. Икенче, өченче бүлекләрдә Болгар мәктәбе тарихы һәм мәктәп җитәкчеләре турындагы эзләнүләр белән таныштырыла. Дүртенче, бишенче бүлекләрдә сугыштан соңгы елларда колхоз-совхозлар тарихы, "Память Ильича" совхозының алдынгылары турында материаллар туплана.

Йомгакта нәтиҗәләр ясала, ачыш-табышлар бәяләнә.

Әдәбият исемлегендә хезмәтне язу барышында файдаланылган әдәби, вакытлы матбугатка мөрәҗәгать итү дәлилләнде.

БОЛГАРЫМ

Кемнәр бирде бу исемне,
Нинди рәхмәтле бәндә?
Матди хәлен аз белсәк тә
Бай булгандыр ул менгә,
Бай булгандыр хыялларга,
Бай булгандыр өметкә.
Дөньядан киткән әйләнеп
Тарихи бер егеткә,
Шул егет дәрманы белән
Күчкән безгә бабамнар.
Ничек итеп бөек дәүләт
Өзелсен ди дәвамнан,
Жимерелеп җиргә чумып
Юкка чыккан җисеме.
Тик җиңеп мең үлемне
Исән калган исеме-
Әйтерсең лә, милләтемнең
Горурлыгы булганын,
Бабамнар дәүләте булып
Яшисең, син, Болгарым.

ХАТЫЙП КАСЫЙМ УЛЫ ИСРАФИЛОВ

(1932-2009)

**II. Төп өлеш**

**1. БҮЛЕК. Болгар авылы тарихы**

Чистай өязе Ширәмәт районы (хәзерге Түбән Кама районы) Болгар авылына 1926 нчы елда нигез салына. Ширәмәт районы Каенлы һәм Кызыл Чапчак авылы хуҗалыклары күчеп утырып Болгар авылы барлыкка килә. Каенлыдан 30 хуҗалык, Кызыл Чапчактан 60 хуҗалык күчеп утыра бу табигатьнең искиткеч матур урынына. Сәбәбе булып Кызыл Чапчак, Каенлы авылы крестьянннарына җир җитмәү аркасында аларга җирне Болгар – элекке Терентьев бай җиреннән биргәннәр. Башта кешеләр бу җирләргә атлар белән йөргәннәр, атналар белән шунда кунып эшләгәннәр. Ләкин мондый тормыш кешеләрне туйдырган һәм алар бу җиргә күчеп утырырга карар кылганнар. Бөек Болгар бабаларыбыз хөрмәтенә яңа авылга “Болгар” дип исем бирәләр. Авылга иң башта 4 кеше килә. Беренче яшәргә килүче кешеләре – Зиннатуллин Габдулхак, Хабибуллин Фатыйх, Салахиев Мотыйк һәм Калимуллин Һадиулла гаиләсе була. Авылга беренче булып Салахиев Мотыйк килеп шалаш корып яши башлый, яңа тормыш кору дип үзе белән кызыл әтәч алып килә һәм аны кычкырта. Икенче көнне аның артыннан 3 егет килә. Үзләрен беренче дип беләләр, ләкин әтәч кычкырганын ишетәләр, шунда Мотыйк абыйны күрәләр. Алар артыннан башка хуҗалыклар йортлар әзер булгач тартыла, 12хуҗалыкка җитә. Йорт салуны җирәбә салып хәл итәләр: бер Каенлы гаиләсе, ике Кызыл Чапчак гаиләсе урнаша.Авыл урамы киң, йорт араларын бик иркен итеп салганнар.Крестьяннарның мәчет саласы килгән.Фатыйх абый “Җәмәгать, башта мәктәп салыйк, аннан мәчетле булырбыз”, дигән. Крестьяннар риза булганнар. Шулай итеп, 1930 елда Болгарда мәктәп салына башлый.

1928-30 нчы елларда колхозлашу чоры башлана. Башта колхозга 12 хуҗалык кергән. Колхозга кабул итүне сорап беренче гаризаны Хәбибуллин Фатих, Зиннатуллин Габделхак, Хәбибрахманов Махмурахман, Галимов Барый биреп, колхозга керәләр. Шулай итеп, әкренләп, колхоз төзелә башлый. Колхозга "Болгар" дип исем кушалар. Аның беренче председателе дә, авылда мәктәп салдырып, балалар укытучы да Хәбибуллин Фатих була. Болгар авылда 1933 нче елда партия ячейкасы оешкан. Колхозны оештыру һәм аны ныгытуда авыл коммунистлары зур роль уйный. Колхоз башта 12 хужалыкны берләштергән, сонрак зурайган. Колхозда беренче председатель дә, беренче укытучы да Хәбибуллин Фатих абый була. Аның ярдәмчесе Зиннәтуллин Габделхак, бухгалтерлары Идиатуллин Мотыйк.

Башта җирләрне үгезләр, атлар белән сукалаганнар, тырмалаганнар, кул белән чәчкәннәр, урып җыйганнар. Дәрестән соң мәктәп балалары калган башакларны җыеп, амбарга илтеп тапшырганнар. Шулай да уңыш 1 гектардан 8-10 дән артмаган.

Игенчелек белән беррәттән, колхозчылар терлекчеләр белән да шөгыльләнгәннәр. Авылыбызның, югары очында тавык, дуңгыз, сарык һәм сыер фермалары төзелгән. Хәйруллин Исмәгыйль белән Исрафилов Касыйм фермага 4 дуңгыз алып кайталар. Шуннан дуңгыз фермасы төзелә. Исрафилов Касыйм 1941 нче елга кадәр фермада мөдир булып эшли. Ире сутышка киткәч, Хәдичә ханым аны алыштыра. 1934 - 1941нче елларда сарык фермасы мөдире булып Идрисов Минневәли эшли. Сугышка кадәр сыер фермасында 50 баш сыер, 2 үгез, 80ләп яшь тана, бозаулар була. Хөсәенов Ибраһим ферма мөдире булып эшли. Савымчылар: Валиева Бибиасма, Нурмөхәммәтова Миңкамал, Хисамова Минсылу була. Нигъмәтҗанова Мәрхәт каравылда тора. Әз генә соңрак атлар өчен дә ферма (конюшня) төзелә. Ул вакытта бөтен эш атлар белән башкарыла. Бу өлкәдә авылыбызның иң тырыш, иң мөхтәрәм карты Зәки Хәйруллин эшли. Ул 1934-36 нчы елларда хезмәт итә. 1941 нче елда сугышка китә, 1946 нчы елның май аенда кайта. 1946 нчы елдан 1972 нче елга кадәр, ягьни 24 ел атлар карый. Зәки абый:"Безгә бер ат өчен 200 гр. алабута оны бирәләр иде. Ундүрт-унбиш сәгать эшли идек. Атларны язгы чәчүгә төшкәнче мал булсыннар дип, тырыша идек", - дип искә ала.

**2 БҮЛЕК. Белем учагы йорты- Болгар мәктәбе тарихы**

Болгар мәктәбе авылның уртасында урнашкан. Ул менә 85 еллар авылга ямь биреп торды.Мәктәпнең алгы ягы киң тигез, матур урамга караган, ә икенче ягы биек-биек агачлар үсеп утырган, сап-салкын чишмәләрагып торган якка карый. Болгар авылында беренче башлангыч мәктәп 1930 елда Хәбибуллиннар йортында ачыла. Беренче укытучылар Хәбибуллин Фатих һәм Хәбибуллина Ситдика булалар. Бу мәктәпне 1932 елда Хәбибуллин Фатыйх абый төзетә.Мәктәп төзелгән урын мәчет өчен дип бүленеп алынган була. Ләкин Хәбибуллин Фатих авыл кешеләрен мәчеткә караганда иң беренче мәктәп кирәклеген аңлата. Авыл халкы ризалаша. Мәктәп салынганчы Ситдика апа балаларны үз өендә укыта. Мәктәп төзелгәч, Хәбибуллиннар гаиләсе мәктәпнең бер бүлмәсендә яшиләр. Мәктәпнең ипи пешерү өчен таш пекарнясы, аш бүлмәсе, аты, куяннары һәм дүрт сыеры, бакчасы була. Балалар өчен төшке ашны әзерләү, ипи, аш пешерү, сыерларны саву, мәктәпнең 11 мичен ягу эшен Сәлахова Фәрхибә эшли. Аннан соң бу эшләрне озак еллар Рәхилә апа башкара. Мәктәптә бушлай ашаталар. Ситдика апа балаларга белем бирү белән беррәттән укучыларга кул эшләре дә өйрәткән; саламнан эшләпә, талчыбыктан кәрҗиннәр үрергә, чигәргә өйрәткән.Алар авыл активистлары белән берлектә концерт, спектакльләр куйганнар, күрше авылларга да барганнар.1944 елга кадәр Ситдика апа белән Фатыйх абый мәктәптә икесе

генә эшли. Болгар 7 еллык мәктәбенә 3 авылдан (Явыш, Би авылы, Югары Чишмә(Ключ)) килеп укыйлар. 17 елдан соң, 1949 елда башлангыч мәктәп жидееллык мәктәпкә әверелә Мәктәп директоры итеп Рахматуллин Әгъзам Марданович билгеләнә. Җиңееллык мәктәп ачкач, 5 нче сыйныфка 55 бала керә. Җиденче сыйныфка 27 се барып җитә. 1955 нче елда 6 сыйныф укучыларының 16 сы комсомол оешмасына керә, ә 7 сыйныфта 27 укучы комсомол оешмасына алына. Мәктәп комсомол оешмасының беренче секретаре итеп Зиннатуллин Альберт сайлана.1960 елга кадәр 7 еллык булып тора. 1960-1961, 1961-1962 уку елларында өлкән сыйныф укучыларын Ширәмәт мәктәбенә күчерәләр. Ата-аналар үтенече буенча, ул 1962-1963 уку елында сигезьеллык мәктәп булып ачыла, укучылар мәктәпкә кайтарыла. 1963 елда мәктәптә барлыгы 189 укучы укый.

***Беренче укытучылар:***

Хәбибуллин Фатыйх

Хәбибуллина Ситдика

Евдокимова Ефимия Тихоновна,

Булатова Әнисә Ишметовна,

Сорокин Т.Т.,

Сорокина Варвара Васильевна,

Хәбибуллина Нажия Фатыйховна.

Хәбибуллина Ләйлә Фатыйховна

***Мәктәпнең беренче пионерлары:***

Шигапов Шавали

Бариева Зәйтүнә,

Хәйруллина Фәрдәнә,

Фаттахова Фариха була.

Беренче быргычы- Шигапов Шавали Шигапович була.

***Мәктәпнең пионервожатыйлары:***

Мәктәп ачылган елны беренче пионервожатый итеп Шигапов Гыйльметдин Шигапович билгеленә. Ул 1910 елны урта хәлле крестьян гаиләсендә Кызыл Чапчак авылында туа. 1925 елны мәктәп тәмамлап, әти-әниләре белән 1926 елны Болгар авылына күченәләр.1930 елны комсомолга керә, 1939 елга кадәр комсомол ячейкасының секретаре була. 1963 елдан пионервожатый булып Булатова Ә.И. эшли башлый.

***Мәктәп җитәкчеләре, мәктәп директоры булып:***

1930 ел- Хәбибуллин Фатих

1950-1965 елларда Рахматуллин Әгъзам

1965-1979 елларда Ибраһимов Рафаэль Ибрагимович,

1979-1981 елларда Муниров Гамиль Афзалович.,

1982-1985 елларда Бариев Шамил Бариевич

1985-2006 елларда Хәмитов Фоат Сальман улы билгеленә.

***Болгар мәктәбендә бик күп еллар эшләгән укытучылар:***

Булатова Әнисә Ишметовна,

Миннегалиева Рузалия Шәйхрази кызы,

Дәүләтшинә Сәрия,

Хәмитова Мөслимә Фәсхи кызы.

Булатов Азат Нурмөхәммәт улы

Балалар саны киму сәбәпле (34 укучы) Болгар мәктәбен 2006 елның октябрь аенда ябалар. Укучыларны район мәктәпләренә автобуслар йөртә башлый.

**3.БҮЛЕК.Болгар мәктәбен алар җитәкләгән!**

***Мәктәп җитәкчеләре, мәктәп директоры булып:***

1930 ел- Хәбибуллин Фатих

1950-1965 елларда Рахматуллин Әгъзам

1965-1979 елларда Ибраһимов Рафаэль Ибрагимович,

1979-1981 елларда Муниров Гамиль Афзалович.,

1982-1985 елларда Бариев Шамил Бариевич

1985-2006 елларда Хәмитов Фоат Сальман улы билгеленә.

**Хәбибуллин Фатих**

Фатыйх абый беренче булып авылга килә, мәктәп салдыра, балалар укыта һәм колхозның председателе, хисапчы була. Мәктәп ачканда аңа нибары 35 яшь була. Ватан алдында зур казанышлары өчен ул “ Ленин ордены” белән бүләкләнә.

Фатих абый 3 яшендә әтисез кала, әнисе тәрбиясендә үсә. Башта данлыклы” Иж-Буби” мәдрәсәсендә белем ала, аннары Уфада “ Галия”мәдрәсәсендә укый.(хәзер Уфа университеты).Аны тәмамлагач , туган авылы Кызыл Чапчакка укытучы булып кайта.Ул югары белемле мулла була, ләкин мулла булып эшләми.Берничә ел Ситдика апа белән укытучы булып эшлиләр.Аннан Фатих абыйны Каенлы мәктәбенә җибәрәләр.Каенлыда мәктәп салдыра. Аннан Болгар авылына җибәрелә. Аңа Болгар авылын оештыру бурычы куела.Фатих абый 49 ел укытып 1956 елда пенсиягә чыга.

Балалары да әти-әниләренең юлын дәвам итә.

Беренче кызы Ләйлә Фатиховна әниләре пенсиягә чыккач педучилищены бетереп укытучы булып эшли.Аннары Кызыл Чапчакта укыта, “ Мәгариф отличнигы” исемен ала.

Наҗия Фатиховна Учительский институт бетереп, Болгарда (20ел) рус теле һәм татар теле укыта. 1971 елда пенсияга чыга.

Уллары Нил Фатихович (техник фәннәр кандидаты) 2 институт бетерә, фәнни-тикшерү институтында 10 еллап директор булып эшли. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә. Кызы Энҗе апа бухгалтер булып эшләп пенсиягә чыга.

**Рахматуллин Әгъзам (1918-1978)**

Сугыш һәм хезмәт ветераны Ә. Рәхматуллин 1918 елда Мөслим районы Уразмәт авылында крестьян гаиләсендә туа. Туган авылында башлангыч белем алганнан соң 1932-37 елларда Мөслим урта мәктәбендә укый. Мәктәпне бик яхшы билгелергә тәмамлый. 1937-39 нчы елларда Минзәлә педагогия училищесында белем ала һәм башлангыч класс укытучысы квалификацияле диплом ала. 1939-40 нчы елларда Мөслим районы Кайтаваз башлангыч мәктәбендә укыта.1940 нчы елның ахырында фин сугышына алына, 781 нче укчы полкында хезмәт итә. Аннан сон Әгъзам абыйны авиоспециалистлар хәзерли торган мәктәпкә сайлап алалар. Бу мәктәпне тәмамлагач, 93 нче авиация полкында хезмәт итә башлый.1941 нче елны Әгъзам абый шушы полкта каршылый. Харьков, Воронеж, Сталинград өчен барган сугышларда катнаша. 1942 нче елның августында Дон буена каты яраланы сафтан чыга. Госпитальдә дәваланганнан соң, хәрби хезмәткә яраксыз булу сәбәпле, туган якларына әйләнеп кайта. 1943 нче елда Кызыл Чапчак авылында комсомол оешмасы белән җитәкчелек итә. Август аенда, шушы ук елны Түбән Уратма жидееллык мәктәбенә директор итеп билгеләнә. 1949 нчы елга кадәр авылда эшли; гаилә кора. 1950 нче елда Әгъзам абыйны яңа оештырылган Болгар жидееллык мәктәбенә директор итеп куялар. Пенсиягә киткәнче, 1978 елга кадәр шушы мәктәптә эшләде. Сугышта һәм тыныч төзелештә күрсәткән батырлыклары өчен Әгъзам орденнар һәм медальләр белән бүләкләнде.

**Бариев Шамил Бариевич**

Бариев Шамил Бариевич 1925 елның 17 июлендә Кызыл Чапчак авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Әтисе Бари беренче империалистик сугыштан яраланып кайткач, авылда староста булып эшли. Бөек Октябрь социалистик революция җиңгәннән соң Авыл Советында секретарь булып эшли. Шулай итеп, ул патша печатен Совет печатена алыштырган.

Шамиль абый истәлекләреннән ”Миңа 3 яшьтулган елларда әти гаилә белән Болгар авылына күчеп килгән.Миңа 6 яш тулганда әнкәй каты авырудан соң үлеп киткән. Без 4 бала калганбыз.1932 елда Болгар башлангыч мәктәбенә укырга кердем. Үземнең беренче укытучыларым Фатыйх абый белән Ситдика апа Хәбибуллиннарны зурлап, хөрмәтләп искә алам. Алар безне укырга, язарга,санарга өйрәтеп калмадылар, киләчәк тормышка юл ачтылар.Болгар башлангыч мәктәбен тәмамлагач 1936 елны Кызыл Чапчак урта мәктәбенә укырга киттем һәм 1942 елны 10 сыйныфны бетереп чыктым.Илдә сугыш бара иде.1943 елның гыйнварында Совет Армиясе сафларына алдылар һәм мине кече командирлар әзерли

торган частька Муром шәһәренә җибәрделәр.Бу вакытта Бөек Ватан сугышны фронтларында каты сугышлар бара, дошманны Совет җирләреннән куалар шәһәрләрне, авылларны азат итәләр иде инде. 1943 елның август аенда укуның бетүен көтмичә безне сугышка җибәрделәр. Чөнки сугышучы армия частьләренә яңа көчләр кирәк иде. Сугышка керүнең беренче көннәреннән алып яраланганчы мин дошманнарга каршы автоматчы, пулеметчы булып сугышырга туры килде.

Безнең гвардияче 65 нче стрелковый укчы полкы каты сугышлар белән Смоленский өлкәсеннән дошманны куды.Днепр елгасы буенда 1943 елның 2 декабрендә мин каты яраландым һәм мине этләр тартып йөри торган чанага салып сугыш кырыннан алып чыктылар һәм госпитальга , Мәскәү өлкәсенең Орехово-Зуева шәһәренә озаттылар.Анда 1944 елның маена кадәр дәваланганнан соңында яңадан фронтка киттем. 3 нче Белоруссия фронтының 5 армия һәм 215 дивизия составында Белоруссияне, Литваны, Көнчыгыш Прусияне немец фашистларын тармар иткәннән соң, Җинү көненә җиттек.Кыюлык һәм батырлык күрсәткән өчен “ Кызыл йолдыз”, ордены, 3 мәртәбә “ Батырлык өчен” медале һәм башка медальләр белән бүләкләндем.Совет Армиясе сафларында7 ел хезмәт итеп 1950 елның маенда туган авылына кайта.

Сугыш чорында 1945 нче елда партия сафларына керә.40 ел партия сафларында була.Сугыштан соңгы елларда партия Шамил Бариевичка җаваплы эшләр тапшыра.

1950-53 елларда ВЛКСМның ул вакыттагы Ширәмәт район комитетының икенче секретаре;

1953-1957 ел КПСС райкомының инструкторы;

1957-1961елларда районда чыга торган” Хезмәт байрагы” исемле газетасында редактор булып эшли.

1961 елны Болгар авылына партия оешмасы секретаре булып эшкә кайта. Башта Карл марк исемендәге колхозда, соңыннан” Память Ильича” совхозында партком серетаре булып эшли.

1970 елда Болгар 8 еллык мәктәбенә укытучы булып эшли.

1983-1984 уку елында мәктәп директоры итеп билгелиләр.

Тыныч тормыш елларында фидакарь хезмәтләре өчен В.И.Ленинның 100 еллыгы уңаеннан чыгарылган “ За доблестный труд” һәм “ Халыклар дуслыгы” ордены белән бүләкләнә.

**Шиһапов Гыйльметдин Шиһап улы**

**Шиһапов Гыйльметдин Шиһап улы** 1910 нчы елда Кызыл Чапчак авылында туа. Үзенең туган авылында башлангыч белемне ала, пионер сафына баса. 1926 нчы елда гаиләләре Болгар авылына күчеп килә, ә инде 1930 нчы елда колхозга керәләр. Шушы ук

елны, Гыйльметдин комсомолга керә. 1935-37 нче елларда Совет Армиясендә хезмәт итә. Кайткач Гыйльметдин Шиһап улын Каенлы мәктәбенә укытучы итеп җибәрәләр. Бөек Ватан сугышы башлана һәм Гыйльметдин 1941 нче елның 12 августында сугышка китә. Сугышта взвод командиры була. Күрсәткән батырлыклары өчен «Кызыл Йолдыз» ордены белән бүләкләнә. 1946 нчы елны туган якларына кайта. Яраткан эшен дәвам итә һәм аны Кызыл Яр авылына башлангыч мәктәп мөдире итеп билгелиләр.

**4 БҮЛЕК. Сугыштан соң колхоз-совхоз тарихы**

Күмәк хуҗалыклардан совхозларга үзгәртелә һәм 1951 нче елны “Память Ильича“ совхозы төзелә.

**Исламов Исмәгыйль Ислам улы язмаларыннан:**

«Болгар авылы элек-электән үзе бер колхоз вакытында ук, терлекчелек белән шөгыльләнгән. Шулай ук, авыл советы күләмендә үзәк булып дүрт авылдан торган: Болгар авылы, Кызыл Яр (Яуш), Би авылы, Семенеево, Верхний Ключ һәм тагын бераздан аңа Трудовой поселогын да кертkәннәр. Ләкин соңрак, Трудовой поселогы, Прикамский совхозына кертелеп бездән аерылган.

Болгарда электән үк терлекчелек киң күләмдә алып барылган: анда эре терлек фермасы, сарык фермасы һәм тавык фермасы булган. Менә шулай бара торгач колхозлар совхозларга үзгәртелә. 1951 елда колхоз“ Память Ильича” совхозына әйләнә, беренче директоры итеп Хәйретдинов Камил Загриевич була. Совхоз тагын эреләнгән, яки Сухрау, Смыловка, Рековка авыллары белән берләшкәч терлекчелекне тагын да киңәйтү мәсьәләсе таләп ителгән һәм шуннан чыгып совхозга эре ферма бhistoricalалары кирәклеге каралган. Шул планны тормышка ашыру буенча терлекчелек биналарын зурайту, эре терлек комплексы яки 800 башлык эре терлек, сөтчелек комплексы төзәргә алынганнар. 1974 елда шул планга бәйле рәвештә ул комплексны Болгар авылында төзергә хәл ителгән һәм 1975 елда төзелеш башланган. Аны төзүдә җитәкчелек итү һәм барча тиешле корылмаларны булдыру, аларга авыл хужалыгы Министрлыгына заказлар биреп, аларны кайтарту һәм комплекска урнаштыру эшен алып бару өчен инженер - механик һәм куратор кирәк була.

Эшне башкару өчен совхозның үз белгечләреннән бер кешене кую кирәклеге таләп ителә. Бу мәсьәләне җитәкләү өчен колхоз, совхозда күп еллар һәм терлекчелектә җитәкчелек эшләре алып барган, зоотехник, Исламов Исмәгыйль Исламович куела һәм аны вакытлы рәвештә совхоздан авыл хужалыгы Министрлыгы штатына күчереп, шуннан эш хакы түләп, тапшырылган эшне мул тәртиптә оештыра. Комплексның төп зур биналары ике сыер фермасы (коровник), 400 башка мал тудыру бүлеге (родильное отделение) һәм аппаратлар белән (механические доильные аппараты) сыерларны саву бинасы булдырыла. Шуларга ярдәмче өлешләр итеп, сөт суыту, сыерларны ясалма файдаландыру (пункт

искусственного осеменения), ветеринар пункты, тирес чистарту (навоза - уборочный проходной) бинасы һәм хезмәткәрләр өчен юыну, ял итү, газета-журналлар уку бүлмәләре һәм башка вак төяк бүлмәләр төзелә. Аннары комплексны су һәм еллык корм белән тәэмин итү өчен, вентиляцион корылмалары төзелә, соңрак зоопарник (кормаларны эшкәртү урыны), автовеса, корма базы, су башнясы һәм башка эшләр башкарыла. Комплексны җылылык белән тәэмин итү өчен зур котельный төзелә. Бу мәсьәләдә совхоз директоры (атаклы агроном) Хәйрутдинов Камил Заһертдинович җаваплы эш алып бара. Оешкан рәвештә эшне алып барып, төзелешләре тәмамлангач, комплекс 1979 елда файдалануга тапшырыла. 1979 елның 1 февралендә шул ук Исламов Исмәгыйль совхоз штатына кире күчерелеп (начальник комплекса КРС) комплекс җитәкчесе итеп куела. Комплекска 400 баш сыер урнаштырылып үз эшен башлап җибәрә. Эшләрне башкару өчен совхоз директоры Хайрутдинов Камил Загриевич, комплекс җитәкчесе Исламов И.И. белән берлектә тиешле штат туплыйлар: инженер-механик итеп Зарипов Васил Файзрахмановичны,

зоотехник - Абдулханова Гүзәлия,

механизаторлар, котельный җитәкчесе - Сабиров Раиф Илдархановичны, ветврач-Хөснетдинов Равил Габбасовичны,

ветфельдшер - Хабибрахманов Файзрахман Хабибрахмановичны,

осеменатор - Хужиев Фазлыйахмат Хужиевичны

һәм ул фуражир да итеп куела, сыер савучылар, бозау караучылар һәм башка хезмәткәрләр. Комплекста күп кенә кул көче белән эшләнә торган эшләр механизм көче белән эшләнүгә әйләнеп хезмәткәрләрнең эшен бик күпкә җиңеләйтә һәм жайландырыла. Бигрәк тә, сыерларны саву мәсьәләсендә, биналарны чистарту (тирес түгә) һәм сулар җылыту, сөтләрне суыту, кормалар төяу, кертеп кормушкаларга тарату эше да механизацияләнә. Алга таба кормаларны кертеп тарату өчен жайландырылган махсус арбалар кайтарылып, аңа төяү мәсьәләсе, трактор белән төяүгә әверелдерелә, башка эшләрне жиңеләйтү мәсьәләсе дә хәл ителә. Тора бара мал саны артырыла һәм яңа төр (порода-черно-пестрый) сыерлар сатып алына. Эш дәверендә бозауларны салкын метод белән үстерү тәртибе дә кертелә. Бозауларны чыныктырып сәламәт итеп үстерү, шул ук бозаулардан яхшы сөт бирә торган сыерларның тана бозауларын, аерым ысулда (направленное выращивание) үстереп көтүне яңарту мәсьәләсе юлга салына. Эш дәверендә кадрлар үзгәреп яки алышынып тора. Комплекстан тыш, элекке ферма биналарында да терлеклар тотыла, контрольный коровник бүлеге ачыла. Беренче бозаулаган башмакларның сөт бирүен тикшереп, күп сөт бирә торганнарын көтүне янартырга юнәлтелә.

Аның өстенә тагын шул иске ферма биналарының берсендә терлек симертү группасы да һәм тагы яшь маллар, бозаулар үстерү группаларыда оештырыла һәм алар бар да унышлы гына эш алып баралар. Комплекста сөт алу буенча, бозаулар алу буенча һәм терлек симертү буенча иң алдынгылардан булмаса да алдынгылар рәтендә эшне алып баралар. Комплекста эшчеләр әлбәттә үзгәреп тора, комплексны җитәкләүче Исламов И. совхозның баш зоотехнигы итеп билгеләнгәч Идрисов Гарифка тапшырыла, аннан Галимов Расимга. Осеменаторлар алышынып, күп еллар буе Мингалиев Рафис эшли, сыерлар күбәйгәч аның ярдәмчесе булып уңышлы гына Идиятуллина Миннури башкара, алар районда алдынгы осеменаторлар булалар. Хужиев Фазлыйәхмәт комплекста төрле эшләр башкарды, мактауга лаек иде. Эш дәверендә комплекска сөт суыту аппараты корылып, сөтне суытып, чистартып хөкүмәткә озату буенча да алдынгы урындабулуга ирешелде. Шулай ук, терлек азыкларын эшкәртеп бирү, бардалар ясау, патокалар куллану, сыерларга бозаулар алдыннан һәм бозаулагач родильное отделениедэ торган чорда солы ясап бирү оештырылды һәм ул зур файда китерә иде. Сыерлардан сөт алу буенча да, оста куллы тырыш сыер савучылар: Хайдарова Зәйтүнә, Хәйруллина Фәридә, Галиева Фәйрүзә, Буранкова Мария, Ахунова Тәслимә һәм башкалар. Тиресләрне механизм җыештыру һәм чыгару буенча Хәйруллин Әхәт белән Гатан Хәйдәр күп еллар яхшы эшләделәр. Бозаулар үстерү буенча Ахметзянова Асылбикә, Галиуллина Мәүлиһә күп еллар яхшы күрсәткечләр бирде. Терлекләрне симертү буенча да район буенча яхшы яхшы күрсәткечләр белән Ганиев Рәфкать үзенең тормыш иптәше Тәскирә белән хезмәт керттеләр. Скотниклардан күп еллар тырышып, яхшы эшләүчеләр Галиахметов Әхәт, Валиев Расим, Ахунов Миннәхмәт, Валиев Мисхәт, Гатин Жәүдәт һәм башкалар булдылар» - дип тәмамлый Исламов И.

**5 Бүлек.“ Память Ильича” совхозының алдынгылары.**

**Зиннатуллин Габделхак-** ***беренче коммунист.*** 1931 нче елдан партия члены. 1929-1930 нчы елларда авылда колхоз төзелә, Габделхак абый ул елларда колхоз председателенең (Хәбибуллин Фатих абыйның) ярдәмчесе булып эшли, кулак калдыкларына каршы көрәшә. 1941-43 нче елларда Ватан сутышында катнаша. 1943 нче елда инвалид булыш (2 кулын да өздереп) Болгарга кайта. Гомеренең соңгы елларына кадәр яшьләрне патриотик рухта тәрбияләү өлкәсендә эшләде.

**Садыйков Гариф Боран улы**(1915-1945) - колхозыбызның иң ***беренче тракторчысы.*** 1939 нчы елда хәрби хезмәткә китә. Хәрби хезмәтне тутырып кайткач, алты ай авылында бригадир булып эшли. Бөек Ватан сугышы, тыныч тормышны дәвам итәргә комачаулый. 1941 нче елның 7 нче июлендә Гариф Ватанны сакларга китә. Мәскәү янындагы сугышта катнаша, аннан хатлары килә. 1945 нче елда Ватан өчен батырларча һәлак була.

**Хөснетдинов Әкмәл** Бөек Ватан сугышы ветераны. 1925 нче елда туган. 1943-1946 ны елларны сугышта катнаша.1948 не елда гаилә кора. Авылда ***гомер буе бригадир*** булып эшли. Миннур ханым белән гөрләшен яшилэр. 2009 нчы елны бриллиант туйларын билгеләп үттеләр.

**Хәбибрахманов Файзрахман**

1924 нче елның 8 нче ноябрендә Каенлы авылыннан күчеп Болгарга килгән һәм бүгенге көнгә кадәр шунда яши.1943 нче елның гыйнварында сугышка китә һәм 1948 нче елда гына кайта. Күп еллар фермада ***ветеренар врач*** булып эшләде. Хәзерге вакытта лаеклы ялда, җиң сызганып, авылыбызда мәчет төзәтү өчен янып-көеп йөри башлады. Тынгысыз көннәр, тырыш хезмәт юкка чыкмады. 1992 нче елның җәендә авылыбызга ямь биреп мәчет калкып чыкты.

***«Память Ильича» совхозының мактауга лаек сыер савучылары***

**Зиннатуллина Фания**

Зиннатуллина Фәния 1938 нче елны Түбән Кама районы Ташлык авылында туган. Авылында белем алганнан соң Казанга китә һәм төзелештә эшли. 1957 нче елда Болгар авылына килә һәм 1975 нче елга кадәр төрле эшләргә йөри. 1975 нче елдан алып сыер савучы булып урнаша, үзенең йөкләмәләрен уңышлы үткәне өченкыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнә.

**Галиева Фәйрузә**

Галиева Фәйруза Саетгәрей кызы 1949 нчы елда туа. 1964 нче елда сигезьеллыкмәктәпне тәмамлап, Түбән Уратма авылында сыер савучы булып урнаша. 1967 нче елда Болгар авылына килеп, сыер сава башлый. Күп кенә «Мактаулы грамота» лар белән бүләкләнә. 1973 нче елда «Хезмәттәге батырлык өчен» дигән медальи белән, 1976 нчы елда «Ярышта жиңүче» дигән значок белән бүләкләнә.

**Идрисова Халидә**

Идрисова Халидә 1933 нче елның 13 апрелендә туган. Дүрт класс белем ала. Ундүрт яшеннән фермага бәрәннәр карарга керә, анда биш ел эшли. Соңрак төрле эшләрдә йөри. 1969нчы елда сыер савырга керә һәм хәзерге көндә дә мактаулы эшен дәвам иттерә. Эш дәверендә, ягьни 1974 нче елда «Ударник коммунистического труда» дигән мактаулы исемгә лаек була, 1977-1979 нчы елларда яхшы күрсәткечләре өчен «Мактаулы грамота»лар белән бүләкләнә.

**Хәдиуллина Сәбилә**

Хәдиуллина Сәбилә Хуҗи кызы 1933нче елның 1 апрелендә туган. 1950 нче елны бозаулар карый башлый. Ә 1951 нче елда, колхозлар кушылгач, сарык фермасында бәрәннәр карый. 1956 нчы елда Сәбилә ханымны сарык фермасының мөдире итеп билгелиләр. Ул 1958 нче елга кадәр эшли. Совхозда сарык һәм тавык фермалары ябылу сәбәпле ул сыер савучы булып урнаша.

**Мингалиева Саимә**

Мингалиева Саимә 1935 нче елда туа. Дурт класс белем алган. Унбиш яшендә фермага сарыклар карарга керә. Унтугыз яшендә тормышка чыга да, бригадада эшли. Ике ел авыл депутаты булып тора. 1978 нче елда фермага сыер савучы булып урнаша. Яхшы күрсәткечләре өчен берничә тапкыр «Мактаулы грамота»лар белән бүләкләнә.

**III. Йомгаклау**

Туган җир... Туган авыл. Нинди якын, кадерле сүзләр. Һәр кешенең газиз туган йорты, нигезебез урнашкан кадерле туган авылыбыз бар. Һәр авылның үзенең кабатланмас, истәлекләре, тарихы күп. Кая гына барсак та, нинди генә матур урыннарны күреп соклансак та, туган төбәгебезнең гүзәллеген бер ни дә алыштыра алмый. Авыллар, мәктәпләр, колхоз-совхозлар... Аларда безнең үткән тарихыбызның бер өлеше, халыкның моңы, кайгы-шатлыгы, куанычлары һәм сагышлары, халкыбызга җиң сызганып хезмәт иткән данлыклы кешеләре бар.

Бу эзләнү эшендә Болгар авылы тарихын, мәктәбе тарихын, аның җитәкчеләрен өйрәнү максат итеп куелган иде. Максатка ирешү өчен без мәктәп музеенда, авыл китапханәсендә саклanучы мәгълүматлар, альбомнар белән таныштык, Авыл Советы материалларын кулландык. Югала барган тарихи материалларны яңарттык; колхоз-совхозларда эшләгән кайбер җитәкчеләр, авылдашлар белән очраштым. Эшемнең ахырында мин максатыма ирештем дип әйтә алам. Бу эзләнүләр минем авылдашларыма кирәк булыр дип уйлыйм, чөнки авылның100 еллыгы якынлаша. Тагын да күбрәк материаллар туплап, Болгар авылының тарихы турында китап басу хыялы бар авылдашларның. Шуңа ниндидер өлеш кертсәм мин һәм укытучым бик бәхетле булырбыз. Чөнки укытучымның әби-бабалары шул авылга беренчеләрдән килеп утырганнар, минем дә ерак бабаларым анда яшәгән.

Материалларны өйрәнгәннән соң, авыл һәм мәктәп үзләренең үсешендә бик озын юл үткәннәр дигән нәтиҗә ясадык. Минем әтием, туганнарым шундый яхшы мәктәптә укулары белән чиксез горурланалар. Чөнки Болгар мәктәбен тәмамлап югары үрләргә ирешкән, төрле профессия белгечләре бар. Эшемне дәвам итеп киләчәктә аларны барларга телим. Эш барышында мин үзем өчен бик күп кызыклы ачышлар ясадым,укытучылар,мәктәпне тәмамлаган атаклы авылдашларыбыз турында күп нәрсәләр белдем. Алга таба да, районыбыз, Республикабыз турында белемнәремне тирәнәйтермен дип уйлыйм. Бүгенге көндә Болгар авылы яшәү, эшләү өчен барлык шартлары да булган матур, төзек авыл. Кызганычка каршы, мәктәп кенә балалар саны аз булу сәбәпле бүгенге көндә эшләми.

**IV. Кулланылган чыганаклар:**


1. Авыл Советыннан алган материаллар.
2. Авыл китапханәсендәге һәм мәктәп музеендагы альбомнар.

3. “Туган як” исемле газета.
4. Ветеран укытучы 86 яшендәге Булатова Әнисә Ишметовна белән әңгәмә.
5. Тыл ветераны, алдынгы сыер савучы Хәйруллина Фәридә Гаттаровна белән әңгәмә.
6. Авылның остабикәсе Өнҗүдә апа истәлекләре.
7. Авылдашларның шәхси альбомдагы фотолар.
8. Бәйрәмова Ф.Ә. Таралып яткан татар иле – Фәнни-популяр язмалар, Казан: “Аяз” нәшрияты, 2003 ел
9. Гарипова Ф.Г. Авыллар һәм калалар тарихыннан. I, II том, Казан: “Матбугат йорты” нәшрияты, 2001 ел.

*Мансурова Алсу, 10 нчы сыйныф,*
*Башкортстан Республикасы Бүздәк районының*
*«Каран урта гомуми белем бирү мәктәбе»*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Мансурова Зөлфия Җәмил кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Башкортстан Республикасы Бүздәк районы
## Каран җирлеге авылларының антропонимикасы
### Кереш

Минем илем - гөлчәчәкле Башкортостан. Ә туган ягым Бүздәк районы Бәйрәш авылы Башкортстан дәүләтенең кечкенә бер өлешен тәшкил итә. Башкортстан картасында ул бер нокта булып күренсә дә, туган ягым минем өчен иң зур, иң матур, иң кадерле җир булып тоела. Чөнки һәркемгә үз туган ягы, туган туфрагы газиз. Адәм баласына туган ягының һәр җан иясе, үсемлеге, хәтта нәни колыны да кадерле. Зурмы, кечкенәме – һәр кешегә үзенең төбәге, аның табигате, кешеләре якын. Туган ягым – ул минем туып үскән авылым. Тук башаклар белән дулкынланучы иген кырлары, җылы җилләрдә тибрәлүче чәчкәле болын – урманнар, биек таулар, киң яланнар, җәйрәп яткан күлләр матурлыгы сыйган бу сүзләргә. Туган җир туган нигездән, туган авылдан башлана. Аның турында бик күп сөйләргә була. Шулай да мин туган авылыбызның кыскача тарихына тукталып үтәсем килә.

Авылымның исеме – Бәйрәш. Олы буын кешеләренең сөйләүләренә караганда безнең авыл калын – кара урманнар, сазлыклар, елгалар белән әйләндереп алынган булган. Моннан 300 ел элек шушы урынга беренчеләрдән булып Дүртөйле районнан берничә гаилә килеп урнаша. Төзү өчен урманнар киселә, сазлыклар кибә. Шулай итеп авылга нигез салына. Бәйрәш дигән исеме дә шуннан килеп чыга.

Безнең авыл табигатьнең иң гүзәл урыны – тау итәгендә урнашкан. Туган авылыбызның сокландыргыч урыннары чыннан да бик күп. Яшел тугайлы болыннарга, балыклы, кош - кортлы агым суларга, түгәрәк күлләргә, челтерәп аккан чишмәләргә бай ул.

Авылларда үткән тарихыбызның бер өлеше, халыкның моң-зары, кайгысы-шатлыгы, куаныч һәм сагышы. Һәр авыл үзенә генә хас атамаларны саклый. Бу атамалар борынгы тарихыбызны, данлы үткәнебезне чагылдыра. Бер генә атама да юкка гына бирелмәгән. Һәрбер атаманың нигезендә ниндидер сәбәп ята. Аның бер ишеләре этнонимга, икенчеләре тарихи вакыйгаларга, өченчеләре гадәт-йолаларга һәм башка үзенчәлекләргә мөнәсәбәтле рәвештә бирелгән. Һәр төбәкнең үзенең үсеш баскычларын, чорларын чагылдырган тарихи берәмлекләре – атамалар системасы бар. Бу атамаларны өйрәнү белән махсус фән шөгыльләнә. Ул – *ономастика*.

Димәк, ***ономастика*** – тел белеменең барлык төр ялгызлык исемнәрен өйрәнә торган махсус тармагы. Ул үзе берничә тармактан гыйбарәт. Шуларның иң әһәмиятлеләреннән берсе – *топонимика*. ***Топонимика*** (грекча *топос* – “урын”; *-оним* – “исем, атама”) атамаларны җыеп кына калмый, ә аларның лексик-семантик үзенчәлекләрен, ясалыш-төзелешләрен дә өйрәнә. Ул тарих, археология, география, диалектология һәм башка фәннәр белән тыгыз бәйләнештә яши.

**Проблема: Җирле ономастика өлкәсендә эшлисе эшләр шактый күп әле.** Әйтик, Башкортстан Республикасы Бүздәк районы Каран җирлеге авыллары ономастикасы да тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгән. Ул үз тикшеренүчеләрен көтә.

**Максат:** Башкортстан Республикасы Бүздәк районы Каран җирлеге авылларының антропонимикасын системалы рәвештә өйрәнү.

Шушы изге максаттан чыгып, безнең өйрәнүләребезнең ***объекты*** итеп Башкортстан Республикасы Бүздәк районы Каран җирлеге урнашкан авылларның (*Каран, Уран, Бәйрәш, Яңа Актау, Иске Актау, Әмир* авылларының) антропонимикасы алынды.

**Эзләнү предметы:** югарыда санап үткән авыллардагы яшәгән халык исемнәре, ялгызлык исемнәреннән барлыкка килгән атамалар һәм кушаматлар.

Башкортстан Республикасы Бүздәк районы Каран җирлеге авылларының антропонимикасын системалы рәвештә өйрәнү, максатыбызга ирешү өчен түбәндәге **бурычларны** куйдык:

**1**) Туган як тарихының бүгенге көндәге әһәмиятен ассызыклау;

**2**) кеше исемнәренең килеп чыгышын, мәгънәсен ачыклау;

**3**) алар белән бәйле топонимнарны барлау;

**4**) кулланылыш үзенчәлекләренә карап төркемләү, ачу.

**Гипотеза:** Шушы җирлектә яшәгән халык үзенең туган ягының тарихын, исемнәренең аңлатмасын белергә тиеш.

Фәнни эзләнү барышында мин тагын үз алдыма түбәндәге **бурычларны** куям:

1. төбәгебез тарихы буенча тагын да күбрәк материаллар туплау;
2. галимнәребез Г.Ф. Саттаров, Ф.Г. Гарипова һ.б. язма чыганакларын тулырак өйрәнү;
3. антропонимика турында күбрәк мәгълүмат алу;
4. үземнең фәнни хезмәтем белән эти - әниләр, укучылар алдында чыгышлар ясау.

Түбәндәге максатка ирешү өчен **Г.Ф. Саттаров, Ф.Г. Гарипова, М.З. Зәкиев, Р.Г. Әхмәтьянов, М.И. Әхмәтҗанов, Р.И. Хаҗиев, Ә.Ә. Әхмәтгалиев** һәм башка галимнәрнең хезмәтләренә таянып эш ителде. Материалларның икенче өлеше шушы төбәктә яшәүче Тимашева Сәхия, Шәрипова Сания, Хәмитова Мәүдә, Мансурова Зөлфирә һәм башка шундый фидакарь затлардан һәм авыл мәхәлләсе имамы Әхмәтҗәнов Гизәр абыйдан язып алынды.

**Эшнең гамәли әһәмияте:** Кеше исемнәренең үсеш-үзгәрешен, ясалышын, таралыш-кулланылышын, төзелеш үзенчәлекләрен өйрәнүнең тел һәм халык тарихы өчен зур әһәмияте бар.

**Эшнең структурасы:** Хезмәт керештән, ике бүлектән (I бүлек Башкортстан Республикасы Бүздәк районы Каран җирлеге авылларының ономастикасы; II бүлек Ялгызлык исемнәреннән ясалган атамалар) һәм файдаланылган әдәбият исемлегеннән тора.

Туган як антропонимикасын өйрәнү халыкның гореф-гадәтләрен, йолаларын, динен, телен онытмауда һәм саклауда зур роль уйный. Үткәнебезне, хәзергебезне һәм киләчәгебезне ныклы бәйләнешкә кертә. “Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк”, – дигән татар халкы.

## I бүлек Башкортстан Республикасы Бүздәк районы Каран җирлеге авылларының ономастикасы

### 1.1. Төбәк антропонимиясе

Һәрбер телдә кешегә эндәшү, мөрәҗәгать итү өчен хезмәт итә торган билгеле бер антропонимик категорияләр бар. ***Антропоним*** термины (грекча *антропос* – “кеше” һәм *онома* – “исем” сүзләреннән) кешеләрне атау өчен хезмәт итә торган исем, атасының исеме, фамилия, кушамат һәм псевдоним төшенчәләрен аңлата һәм билгеле бер телдә кешеләрне конкрет атау берәмлекләрен белдерү өчен хезмәт итә. Татар телендә кешегә эндәшү, атап мөрәҗәгать итү категорияләренә исем, кушамат, ата исеме, фамилия керә, ягъни боларның һәрберсе кешене атауның аерым номинатив категорияләре булып санала. Бу номинатив категорияләрнең килеп чыгышын, төзелеш һәм кулланылыш үзенчәлекләрен, үсеш-

үзгәреш закончалыкларын ономастиканың ***антропонимика*** дигән бүлеге өйрәнә [6; б.9-10].

Татар халкы элек-электән яңа туган сабыйга исем кушуга зур җаваплылык белән караган. Матур эчтәлекле, аһәңле, җиңел һәм анык әйтелешле исемнәр бирергә тырышкан. Исемнең җисеменә туры килүен теләгән һәм тәэмин иткән. Балага исем кушу – бик җаваплы зур һәм мөһим вакыйга. Менә шуңа кытай халык мәкалендә хаклы рәвештә: «Начар язмыш белән туу куркыныч түгел әле ул, ә менә начар исем алу – коточкыч»**, -** диелә.

Һәрбер халыкта кеше исемнәренең шактый кызыклы һәм бай тарихы, үзенчәлекле традицияләре барлыкка килү, бирелү-кушылу йола-мотивлары бар.

Дөньяга яңа туган сабыйга исем сайлаганда һәм кушканда, баланың матур, чибәр, якты-нурлы йөзле һәм якты күңелле булуын теләүне мотив итеп алып, аны чибәрлек-матурлыкны, пакьлек-сафлыкны, яктылык-матурлыкны белдерүче сүзләргә нигезләнеп ясалган исемнәр аша чагылдырганнар. Кеше исемнәре, күренекле татар - башкорт шагыйре Шәехзадә Бабич әйткәнчә, гаҗәеп бер бакча. Ш. Бабичның, бер шигырен “Исемнәр бачасында” дип атап, байтак кына хатын - кыз исемнәрненә карата күңел түрендә калырдай шигъри юллар язуы билгеле:

... Гөлнур туташ, гөлең бар бит, нурың бар бит,

Күзеңдә “сүр”, күкрәгеңдә “нурың” бар бит,

Сигез оҗмах каршысында синең белән

Җир мактанган: “ Минем дә бер хурым бар!” – дип, [4; б.175] дигән шигъри юлларны укыгач, кем генә бу исемнәрне якын итмәс, аларны аһәңле һәм матур дип санамас икән?! Җимеш бакчасында төрле агачлар үскән кебек, исемнәр бакчасында да төрле җимешләр – исемнәр бар. Һәр кеше үз баласына үзенә ошаган, үзе матур, мәгънәле санаган исемне куша. Һәм әлбәттә, исеме җисеменә туры килсен дип тели. Чөнки һәрбер исемнең, кешеләр шикелле, үзенә генә хас матурлыгы бар. Һәм һәрбер кеше үз исеменең матур яңгырашлы, ачык мәгънәле булуын тели. Борынгы бабаларыбыз ук “Исемең матур – кемнәр куйган” дип юкка гына әйтмәгәннәрдер шул.

Һәр төбәкнең, авылның шушы якта гына кулланылган исемнәре бар. Үз авылыңдагы кеше исемнәрен, фамилия, кушаматларын алып, мәгънәләрен карасаң, үзе бер кызык дөньяга кереп китәсең. Кушаматларның килеп чыгышын тикшерә башласаң, нинди генә тарихка, шул кушаматка бәйле вакыйгага тап булмыйсың! Һәрбер кушаматның үз чыгышы, һәрберсе үз иясенә ябыштырып куйгандай йөри. Исемнәрне карасаң, кайсы исемнең кайсы чорда “модада” булуын, кайсы исем авылда берәү генә (һәм әлбәттә, ул кешегә инде кушамат та кирәк булмый), кайсысы – бик күп таралганлыгын беләсең. Һәрбер исемне кушаматы белән әйтсәң, шул исемнең иясе бөтен характерлы үзенчәлекләре белән күз

алдына килеп баса. Авылыбызның мулласы булып халыкка хезмәт итүче Әхмәтҗанов Гизәр абыйдан мәхәлләбездә туган сабыйларның барысына да, шәригать кануннарына туры китереп, исем куша.

Без гадәттә исемнәрнең мәгънәсе турында уйланып тормыйбыз, күнеккәнчә сөйли бирәбез. Ә уйлап карасаң, аларда кызык нәрсәләр ачыла. Кеше исемнәрен генә алып карыйк: Әхмәт, Гали, Вәли, Сания, Рәбига, Зөһрә, Марат, Вил һ.б, һ.б. лар. Болар ни аңлата? Әйтик, маңгаенда ак таплы колынга Йолдыз Кашка дигән кушамат бирәбез икән, бу әле аңлашыла, моның ап-ачык нигезе, мәгънәсе бар. Ә мин үземнең нигә Алсу булуымны аңлый алмыйм. Минем Алсулыгымның сәбәбе нәрсәдә соң?

Әллә исем, бер кешене икенчесеннән аерып тану өчен, ясалма рәвештә төзелгән авазлар тезмәсеме? Яки тамга кебегрәк бернәрсәме? Әйе, исемнәр – нигездә кешеләрне бер-берсеннән аеру - тану өчен хезмәт итә торган тамга. Ләкин гаҗәеп тамга... Чөнки авазлардан тезеп кенә исем ясап булмый бит. Я, кемнең шундый исем ясаганы бар?

Кайберәүләр, бәлки: “Ничек булса да барыбер түгелмени? Асия белән Нурияне, Марат белән Марсны аера алгач, шул җиткән”, – диярләр. Әйе, мәгълүм нәрсәләр белән канәгатьләнүчегә шуннан артыгы кирәкми... Әмма һәрнәрсәнең төбенә төшәргә, сәбәбен, нигезен эзләргә тырышкан укучы өчен мондый аңлатма гына җитми билгеле.

Без биредә Башкортстан Республикасы Бүздәк районы Каран җирлеге авылларында кулланылган кеше исемнәренә, фамилияләргә һәм кушаматларга хас үзенчәлекләрне карап үтәрбез.

### 1.2. Төбәктә фамилияләр кулланылышы

***Фамилия*** (латин сүзе, “гаилә” дигән төшенчәне белдерә) – аерым бер гаиләнең, гаиләләрнең яки нәселнең рәсми атамасы, нәсел тамгасы. Ул гадәттә, шул гаилә яки нәселнең барлык вәкилләренә карый. Фамилия хәзерге заманча өч компонентлы атау системасында (исем + атасының исеме + фамилия) бер гаилә яки нәсел кешеләренең барысы өчен уртак һәм буыннан буынга күчеп килә торган номинатив категория (атау категориясе) булып санала. Димәк, фамилия шәхесләрне гомумиләштерү-берләштерү һәм аеру-конкретлаштыру хезмәтен үти, бер үк вакытта гомумилекне һәм аерымлыкны белдерә [Саттаров Г.Ф., 1990, 249]. Авылдагы фамилияләргә килгәндә алар бик күп төрле. Фамилияләрне икегә бүлеп булыр иде. Беренчесе - бу фамилияләрне барлыкка китергән исемнәр әле хәзер дә киң кулланышта йөри (хәлбүки, алар да инде әкренләп азая бара).

Мәсәлән: Мансуров, Сабитов, Гаязов, Хөсәенов һ.б.

Икенчесе – бу фамилияләрне барлыкка китергән исемнәр хәзер авылда бөтенләй юк.

Мәсәлән: Гиззәтуллин, Тимашев, Диникиев, Шадманов, Халиков, Гафуров һ.б.

Төбәктә бер үк фамилияләрнең күп кулланылуы игътибарга лаек. Мәсәлән: *Хафизов – Хафиз* (г.-т.) – “саклаучы; күңелдән ятлаучы; Коръәнне яттан белүче; истәлек, хәтер”, Сабитов – Сабит (г.) – “сүзендә нык торучы, чыдам”, Мансуров – Мансур (г.) – “җиңүче, өстен чыгучы”, Исхаков – Исхак (яһүди, көлде, ул көләчәк”, Зиннәтуллин – Зиннәт (г.) – “бизәк, затлы әйбер”, Гиззәтуллин- Гиззәт (г.) – “хөрмәт, көч-куәт”, Гарифуллин – Гариф (г.) – “белүче, укымышлы, акыл иясе” *[5]*.

Төбәктә фамилияне кыскартып, исем урынына шуны куллану очраклары күзәтелә. Кайвакыт аңа “абый” сүзен дә өстиләр. Мәсәлән, өлкән укытучыларга шулай эндәшү хас: Чанышев абый, Гобәев абый, Гафуров абый һ.б.

**Төбәк антропонимиясендә шәхескә эндәшү, мөрәҗәгать итү сүзләре дә игътибарга лаек**: *әнкәй, әткәй, апа, апаем, абый, бажа, малай, бабай, әби, әбием, җиңгәчәй*, балдыз, *бианай*, биятай*, кияү, килен, җизнәй, авылдаш, замандаш* һ.б.

Мәсәлән: “Апаем, бергәләшеп җизнәйләргә барып киләек эле.”  “Апаем” дип бездә ир һәм кыз туганнарга да бер төрле эндәшәләр

Күргәнебезчә, Каран төбәге авыллары үзенчәлекле антропонимикага ия. Бу төр категорияләрнең барлыкка килүе, үсүе һәм формалашуы җәмгыять йогынтысында барган. Димәк, алар – төбәк тарихының көзгесе булып торалар.

## II бүлек. Ялгызлык исемнәреннән ясалган атамалар

Ялгызлык исемнәре белән бәйле атамалар төбәктә шактый күп. Бу төр топонимнарның килеп чыгышы да, халыкның яшәеше һәм тормыш-көнкүреше белән бәйле.

Ялгызлык исемнәреннән ясалган топонимнарны түбәндәге өч төркемгә бүлеп карыйбыз:

1) антропонимнар (грек. *anthropos- кеше, onyma - исем*) — кешеләргә эндәшү, атап мөрәҗәгать итү өчен хезмәт итә торган исем, ата исеме, фамилия, кушамат, псевдоним.

Антропоним телдәге башка сүзләрдән үзләренең индивидуаль характерда булулары, аерым бер кешене генә атаулары белән аерылалар. Җәмгыятьтә кешегә мөрәҗәгать итү өчен кулланыла торган билгеле бер кабул ителгән тәртип саклана.

Бүгенге көндә татар телендә исем-ата исеме-фамилия (мәсәлән, Бикташев Камил Ибраһим улы) тәртибе киң таралган. Аерым очракларда, өстәмә рәвештә, кушамат, псевдоним да кулланылырга мөмкин.

2) гидротопонимнар;

3) этнотопонимнар.

Түбәндә антропонимнардан асалган атамаларны карап үтәбез.

### 2.1. Антропонимнардан ясалган атамалар

Антропотопонимнарда туган телебезнең борынгы тамырлары, сүзләре мул сакланган. Аларда телебезнең тарихи үсеше, төбәк халкының тарихы, көнкүреше, гореф-гадәте, йола-традицияләре, уй-хыяллары, матди һәм рухи мәдәнияте шактый тулы чагыла.

**Мәсәй тавы.** Качандыр безнең авыл Көязе елгасының ике як ярында да урнашкан булган. Тау яклап Мәсәй исемле кеше яшәгән. Аның ике хатыны һәм ике улы булган. Ул бик уңган һәм бай кеше була. Үз көче белән буа буган, су тегермәне төзегән, шул тегермән белән бөтен авыл халкы кулланган.

Кулаклаштыру заманы башлангач, аның бөтен байлыгын алып, үзен төрмәгә утырталар. Үзе белән ике улын һәм өлкән хатынын да утырталар, ә яшь хатыны авылда кала. Берничә ел ул Мәсәйдән калган тегермән белән ашлык тарта. Аңа ирсез һәм улсыз бик авырга туры килә һәм бу эшне ташлый.

Ә аның сөйгәне Мәсәе туган ягына кире әйләнеп кайтмый, аның алдагы тормышы билгесез була. Аның истәлегенә багышлап авылдашлары ул яшәгән урынга “Мәсәй тавы” дип исем биргәннәр.

**Әхмәй акланы.**

Яшәгән ди безнең авылда Әхмәй исемле бер кеше. Ул үзенең авылының табигатен бик яраткан. Безнең авылдан ерак түгел генә бер аклан булган, анда печән үскән, җиләк, гөмбә җыерга да халык шунда йөргән. Арып талҗыгач, сусавың басылганчы салкын чишмә суын эчәргә мөмкин була. Әхмәй дә бу урынны бик ярата, монда агачлар утырта башлый.

Җәен печән чаба, хатын-кызлар, бала-чагалар җиләк-җимешен җыеп кышкылыкка кайнатма ясый, киптерә. Дару үләннәре дә монда бихисап була.

Әхмәй утырткан агачлар еллар үтү белән үскәннәр. Бу агачлар әлеге вакытта акланга килгән кешеләрне кояш кызулыгыннан саклыйлар, җил-яңгырлардан ышыклыйлар.Тирә-якны саф һава белән баеталар. Җәен-көзен Әхмәй акланыннан кеше өзелми.

**Фәйзулла тавы.**

Борын заманда авылда Фәйзулла (г. – “ Аллаһ + юмарт”) исемле кеше яшәгән. Аксакаллар сөйләве буенча бу кеше акылга зәгыйфь һәм диндар булган.

Бер биек тау башында мәгәрә булган. Шул мәгәрәдә Фәйзулла көн саен биш вакыт намазын укыган. Аның тавышы көчле һәм чиста булган. Ул укыган намаз тирә-якка яңгырап ишетелеп торган. Авыл халкы шуннан гына намаз вакыты икәнен белгәннәр. Шул вакыттан бу тауны Фәйзулла тавы дип йөртә башлаганнар.

**Бәрхәм күле.**

Элек-электән авылдан ике чарым ераклыкта урнашкан бу күл. Монда ел саен аккошлар очып килгәннәр, алар оя корып бала чыгарганнар. Күл янында таллар, төрле куаклар, җиләк-җимешләр күп, төрле файдалы үсемлекләр үскән. Кешеләр шушы җиргә

җиләк җыярга килгән вакытта, күләгәдә ял итеп күлдән су эчкәннәр һәм кошлар сайравын тыңлаганнар.

Бер вакыт авылдан шушы җиргә җиде кеше күченеп килергә җыенганнар. Шушы җиде кешенең алтысы билгесез сәбәпләр аркасында кире уйлаганнар, ә Бәрхәм исемле кеше монда берүзе өй, абзар һәм мунча салган. Ул бик уңган, җитез, батыр кеше булган, ул җиң сызганып басу -кырларда тир түгеп җир эшләре башкарган, арыш һәм бодай үстергән.

Менә шушы көннән башлап бу күлне " Бәрхәм күле" дип йөрткәннәр. Бу күл һәм Бәрхәм хакында төрле имеш-мимешләр дә йөри.

Бәрхәм исемле кеше караклар тоткан дип тә сөйлиләр. Көндез караклар ял итеп, йоклап кичкелеккә хәл җыйганнар, ә кичен карангы төшкәч, Бәрхәм аларны күрше авылга урлашырга җибәргән. Шушы тәртипсез зимагур-караклар кемнең малын, кемнең кош - кортын урлаганнар.

Авыл кешеләре шушы каракларны тота алмаганнар, чөнки кире әйләнеп кайтканда алар бик хәйләкәр булганнар, эзләре буенча аркалары белән турыга алга карап кайтканнар. Эзләрне бутап, һәм хайваннарга тояклар урынына икенче әйберләр куеп юлларын бутатканнар; халык белмәсен өчен, алар әллә нәрсәләр кыйланганнар.

Элегерәк  Сабанай авылында аучы яшәгән .Бервакыт шулай аучы ауда йөргәндә "Бәрхәм" күлендә бик матур кошлар күргән, бу "Бәрхәм аккошлары" булып чыккан. Ул озак итеп сокланып аларга карап утырган, алар искиткеч матурлар, күзене дә аласы килмәгән. Ә шулайда аучы, аккошларны жәлләмичә бер ап-ак кошны атып өенә алып кайтып киткән, ә икенче көнне аның өе гөрелдәп янып беткән, күз ачып  йомганчы өйдән бер нәрсә дә калмый.

Шулай итеп бу аучыга һәм аның гаиләсенә бәхетсезлек килә. Бәхетсезлек дигәннән, аучынын үзенең бер кулы кибә һәм ул бик ямьсезләнә, бөкерәеп бетә, һәм шул көннәр дә ул интегеп үлеп китә, яраткан хатыны акылдан яза.

Менә әйтәләр бит аккошка тиергә ярамый, чөнки аккошларга тигән кеше үзенә мең кайгы һәм җәза ала, хәтта аткан, үтергән кешегә генә түгел, аның гаиләсенә дә кайгы килә.

**Зөлфәт чишмәсе.**

Бу чишмәне ни өчен Зөлфәт (г. "таң алды, мәхәббәт иясе") дип әйткәннәрен дә сөйләрмен.1997нче елда Зөлфәт дигән бер бабай су буйлап йөргәндә бик сусап китә һәм аның йөрәге дөп-дөп тибә башлый.Зөлфәт җиргә утырып хәл җыям дигәндә чишмә тавышы ишетә,артына борылып караса,анда чылтыр-чылтыр чишмә ага.Ул бу чишмәнең суын эчә дә терелеп китә.Бу чишмә турында Зөлфәт авылга кайтып сөйли. Авылдашлар чишмәне күргәч,аңа Зөлфәт бабайның исемен бирәләр.

**Йомгак**

Эшебезенең төп максаты Башкортстан Республикасы Бүздәк районы Каран җирлеге авылларының антропонимикасын һәм антропонимикадан ясалган атамаларны системалы рәвештә өйрәнүдән, аны теоретик тасвирлаудан, атамаларның барлыкка килүен, үсүен бәян итүдән гыйбарәт иде. Без куелган максатка ирештек дип уйлыйбыз. Барлык тупланган материалны тарихи-лингвистик яссылыка анализлап чыкканнан соң, түбәндәге нәтиҗәләргә килдек:

1. Без өйрәнгән антропонимнарның күбесе бик борынгы чорларда ук барлыкка килгәннәр. Аларны лексик-семантик яссылыкта төркемләп тикшерү нәтиҗәсендә Каран авылы җирлеге атамаларының искиткеч бай булуы ачыкланды.

2. Төбәк үзенчәлекле антропонимик системага ия.

3. Югарыдагы мисаллардан күренгәнчә, төбәктәге исемнәрнең күбесен гарәп-фарсы чыгышлы исемнәр тәшкил итә.

4. Каран халкына кушаматлар куллану да хас.

5. Топонимнарның килеп чыгышы да халыкның яшәеше һәм тормыш-көнкүреше белән бәйле. Алар арасында зур күпчелекне кеше исемнәренә нигезләнеп ясалган топонимнар алып тора.

Шулай ук тагын әйтәсем килә: татар ир-ат һәм хатын-кыз исемнәренең тулаем саны 25 меңнән артып китә. Димәк, дөньяда татарлар, кеше исемнәренең саны буенча төрекләрне узып, беренче урынны тотучы халык дип, горурланып әйтә алабыз. Шунысы белән аеруча горурланам: безнең якларда заман шаукымына ияреп балаларына Трактор, Октябрина кебек мәгънәсез исемнәр кушучы булмаган. Авылдашларым мәгънәле исем йөртә. Чын мәгънәсендә исемнәре җисеменә туры килә дип әйтергә мөмкин. Ә атамаларда халкыбызның борынгы теле, тарихы, тормыш-көнкүреше, гореф-гадәтләре, материаль һәм рухи культурасы, милли мирасы эзлекле чагыла. Алар туган телгә, Ватанга, туган төбәккә мәхәббәт, ихлас ярату тәрбияләүгә булыша.

**Шартлы кыскартылмалар**

г. – гарәп теле

г.-т. – гарәпчә-татарча

г.-ф. – гарәпчә-фарсыча

т.-ф. – татарча-фарсыча

ф. – фарсы теле

ф.-г. – фарсыча-гарәпчә

**Файдаланылган әдәбият исемлеге**

1. Әхмәтьянов, Р. Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге / Р. Г. Әхмәтьянов. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2001. – 272 б.

2. Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1965.

3. Гарипова, Ф. Г. Исемнәрдә – ил тарихы / Ф. Г. Гарипова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. – 264 б.

4. Заһидуллина, Д. Ф. Сәгыйть Рәмиев – Шәехзада Бабич. – Казан : Мәгариф, 2005. - 287 б.

5. Миргазов, Р. Ф. Татар исемнәренең аңлатмалы яңа сүзлеге. – Березники: Шәхси китап нәшрияте, 2009.

6.Саттаров, Г. Ф. Татар антропонимикасы / Г. Ф. Саттаров. – Казан университеты нәшрияты, 1990. – 278 б.

7.Саттаров, Г. Ф. Татар топонимиясе / Г. Ф. Саттаров. – Казан университеты нәшрияты, 1998. – 438 б.

8.Саттаров, Г. Ф. Татар исемнәре ни сөйли?/ Г. Ф. Саттаров. – Казан: Раннур, 1998. – 487б.

9.Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – 1 т. – Казан, 1977; – 2 т. – Казан, 1979; – 3 т. – Казан, 1981.

10.Хаҗиев, Р. И. Тарихи бизәкләр: Татарстан Республикасы Мөслим районы Торыш төбәге авылларының тарихы һәм ономастикасы / Р. И. Хаҗиев. – Казан: РИЦ “Школа”, 2006. – 100 б.

11. URL : http//matbugat. ru/ news/ ИСЕМНӘР ТУРЫНДА ГОМӘР САТТАРОВ БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ.

12. URL : http//www.watan.su. Татар исемнәренең аңлатмалы яңа сүзлеге.

*Сөнгатуллина Нәргизә, 8 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының*
*Муса Җәлил исемендәге «1 нче гимназия»*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Садыкова Сиринә Илсур кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## ТАТАР ХАЛЫК ӘКИЯТЛӘРЕНДӘ МИФОПОЭТИК ОНИМНАР

### КЕРЕШ

Хәзер төрки тел гыйлеме алдында, шул исәптән татар тел белемендә, борынгы төрки язма ядкәрләрнең телен бөтен тулылыгы белән өйрәнү бурычы тора. Бу – татар теленең үсешен күз алдында китерү өчен генә түгел, бәлки тагын ике зур проблеманы – телнең татар халкы этногенезында тоткан тарихи урынын билгеләү һәм хәзерге шартларда элекке

традицияләр җирлегендә татар телен дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрү мәсьәләен хәл итү белән дә бәйләнгән, дип яза В.Хаков «Татар әдәби теле тарихы фәне һәм аның алдында торган бурычлар» дигән мәкаләсендә[1] Татар теленең үсешен күзәткәндә, төрки язмачылыктан тыш, татар халык авыз иҗатына да аеруча игътибар ителә. Бу соңгы елларда аеруча нык күренә. Әкиятләр, табышмаклар, мәкальләр, бәетләрнең тел үзенчәлекләрен төрле аспектларда өйрәнү, шул исәптән лексикасын анализлау тел белемендә төп мәсьәләләрнең берсенә әйләнеп бара.

Фольклорга игътибар артуның икенче сәбәбе дә бар. Халкыбызның килеп чыгышына, үткәненә, тарихы һәм этнографиясенә игътибар арткан бу чорда, билгеле, аның авыз иҗатына да игътибар көчәя. Халык авыз иҗаты – һәрбер халыкның җанлы тарихы, тәҗрибәсе, сүз осталыгы ул.

Матур әдәбият мифологик образлар белән фикерләүдән башлап мифологиядә нигезендә барлыкка килгән художество чараларыннан, персонажлардан һәм сюжет-мотивлардан поэтик-стилистик алым буларак файдалануга кадәр юл үткән (мәсәлән, антик әдәбияттан Гомерның « Илиада», «Одиссея», поэмалары; татар әдәбиятыннан: Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф», Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан», Г. Тукайның «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш», «Шүрәле», «Су анасы», әсәрләре, Һ. Такташның «Җир уллары трагедиясе» кебек әсәрләрне мисал итеп китерергә мөмкин. XX нче йөз ахырында, аннан соң иҗат ителгән әсәрләрдә дә мифологик алымнар авторлар тарафыннан яратып кулланыла Мәсәлән, Ф.Бәйрәмованың «Күл балыгы» повесте, З.Хәкимнең «Су төбендә сөйгәнем» комедиясе, Н.Гыйматдинованың «Ак торна каргышы» һәм «Болан» повестьләре, А.Хәлимнең «Өч аяклы ат», Г.Гыйльмановның «Албастылар», «Оча торган кешеләр», «Син кем?», «Фәрештә», «Күрәзә» әсәрләрендә мифопоэтик алымнар кулланылыш тапкан.

Хезмәтебезнең ***максаты*** – татар халык әкиятләренең мифопоэтик ономастикасын тикшерү. Максатка ирешү өчен, түбәндәге ***бурычлар*** куелды:

 мифопоэтика һәм поэтик ономастика төшенчәләре турында гомуми мәгълүмат бирү;

 татар халык әкиятләрендә кулланылыш тапкан мифопоэтик онимнардан әкияти персонаж исемнәрен анализлау;

 мифопоэтонимнарның мәгънәләрен ачыклау;

***Теманың теоретик әһәмияте.*** Мәкаль, әйтем, табышмак, әкият, бәетләр, халык авыз иҗаты әсәрләре буларак, бик борынгы заманнардан ук барлыкка килгәннәр. Шуңа күрә татар халык авыз иҗаты әсәрләренең телен өйрәнү татар теле тарихын өйрәнү өчен дә әһәмиятләре зур.

Тикшеренү эшен язу барышында фәнни-методологик нигез буларак В.Хаков, Ф.Урманче, Г.Саттаров, Л.Җамалетдинов һәм башка галимнәрнең хезмәтләренә мөрәҗәгать иттек. ***Чыганак*** буларак «Татар халык иҗаты» җыентыгының «Әкиятләр» томы, төрле әкият җыентыклары файдаланылды.

Эшнең ***төзелеше*** кереш, ике бүлек, йомгак, кулланылган әдәбият, чыганаклар исемлегеннән гыйбарәт. Керештә эшнең максат-бурычлары билгеләнә. Беренче бүлек теоретик характерда, биредә без поэтик ономастика һәм мифопоэтика төшенчәләренә аңлатма бирдек. Икенче бүлектә татар халык әкиятләрендә мифопоэтонимнардан әкият персонажларының исемнәре өйрәнелде. Йомгакта эш барышында ясалган гомуми нәтиҗәләр урнаштырылды.

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК
## ТАТАР ХАЛЫК ӘКИЯТЛӘРЕНДӘ МИФОПОЭТИК ОНОМАТИСКАНЫ ӨЙРӘНҮНЕҢ НӘЗАРИ АЛШАРТЛАРЫ

### 1.1. Ономастика һәм поэтик ономастика турында гомуми мәгълүмат

Җир йөзендәге һәрбер кешенең, шәһәр һәм авылның, тау, елга, күл, урман һ.б. исемнәре бар. Һәрбер атама үз эчендә ниндидер мәгънә саклый. Күп кенә атамаларның мәгънәләре бер караштан аңлашыла, икенче берләренең мәгънәләренә төшенү өчен, күп тикшеренү, эзләнүләр үткәрергә кирәк. Бу эш белән тел белеменең аерым бер тармагын тәшкил итә торган ономастика (грекча “исем кушу сәнгате” мәгънәсендәге сүздән) фәне шөгыльләнә. Ул барлык төр ялгызлык исемнәрен лингвистик яссылыкта тикшерүне таләп итә.

XV-XVIII гасырларда яралгы хәлендә булган татар ономастикасы, XIX йөзнең I чирегендә үсеш тарихының икенче этабына аяк басып, XXI гасырда “күптөрле телләр материалына нигезләнеп, гамәлгә ашырыла торган интенсив гыйльми тикшеренүләр нәтиҗәсендә, елдан-ел киңәя, байый һәм тирәнәя барган” фән тармагына әверелә.[1]

Ономастика тел белеменең башка тармаклары белән тыгыз бәйләнгән: ономасиология, социолингвистика, стилистика, коммуникатив лингвистика һ.б.

Топонимика белән антропонимика ономастиканың ике иң мөһим һәм зур бүлекләрен тәшкил итә. Топонимика барлык төр географик атамаларның (топонимнарның) килеп чыгышлары (кайсы телгә караулары һәм мәгънәләре), формалашу-үсешләре, структур-ясалыш һәм кулланылыш үзенчәлекләрен өйрәнү белән шөгыльләнә. Топонимиканың су чыганаклары атамаларын – гидронимнарны тикшерә торган бүлеге гидронимика дип, ландшафт атамаларын өйрәнә торган бүлеге – оронимика; җирле, зур булмаган географик объектларның атамаларын өйрәнә торган бүлеге микротопонимика дип атала. Аерым бер торак пункт (шәһәр, авыл, станция һ.б.) географик атамаларын өйрәнү шулай ук

топонимикага карый. Аны атау өчен әлегә махсус термин кулланылмый. Мәсәлән, Казан топонимиясе дигәндә, Казан шәһәрендәге физик (табигый) һәм ясалма географик объектларның атамалары тулаем күздә тотыла. Топонимиканың бу бүлеге урбанонимика дип атала.

Ойконим *(гр. oikos- йорт, торак)* – барлык төр торак пункт атамаларын белдерү өчен кулланыла торган топонимның бер төре. Шәһәр атамасы төшенчәсен белдерү өчен *астионим*, авыл атамасын белдерү өчен *комоним* термины кулланыла. Ойконимик терминнар составына торак пунктларның төрләре (шәһәр, авыл, бистә һ.б.), аларның состав өлешләре һәм каралты-кураларны белдерә торган атамалар керә. Ойконим килеп чыгышын, үсеш-кулланылыш закончалыкларын өйрәнә торган топонимика тармагын ***ойконимика*** дип атыйлар, ә ойконимика тулаем җыелмасын ***ойконимия*** дип йөртәләр.

Топонимия – географик атамалар, ягъни сүзләр белән бәян ителгән җир теленнән гыйбарәт кыйммәтле тарих, буыннан буынга күчеп килә торган халык хәтере, милли ядкарь асыл хәзинә. Һәрбер республика, өлкә, район, шәһәр яки авылның җирле географик атамалары күбесенчә борынгы заманнарда ук барлыкка килгән. Әлеге атамалар, буыннан-буынга күчә барып, артык зур үзгәрешләр кичермичә, безгә килеп җиткәннәр һәм яшәеш-кулланышларын дәвам иттерәләр. Алар әйләнә-тирәнең табигате, халыкның теле, тарихы, тормыш-көнкүреше, гореф-гадәтләре, материаль һәм рухи культурасы турында ерак гасырлар аша күп нәрсәләр сөйлиләр, бай фәнни мәгълүматлар бирәләр. Халкыбызның тарихи үткәннәрен һәм хәзергесен тулы итеп күз алдына китереп бастырырга һәм туган ягыбызны, шәһәребезне яки авылыбызны яхшырак танып белергә булышалар.

Ялгызлык исемнәрен язма сөйләм эчендә өйрәнүнең иң уңышлы юлы – матур әдәбият өлкәсендә эзләнү, тикшеренүләр алып бару. Хәзерге вакытта тел һәм әдәбият фәне чигендә формалашкан, матур әдәбият әсәрләрендә куланылган барлык төр ягызлык исемнәрен өйрәнә торган поэтик ономастика киң колач җәеп үсеп килә.

Сүзнең әдәби әсәр тукымасын барлыкка китергәндә, образ-сурәт рәвешен алу очраклары аның күпмәгънәлелек нигезендә булган үзгәрешләре белән генә чикләнми. Битараф сүзнең сурәткә әверелүе, сурәтле сүз тәшкил итүе башка җирлектә дә булырга мөмкин. Шуларның берсе – әдәби контекстта сүзнең этимологиясен ачыклау мәсьәләсе. Мәсәлән, исем этимологиясе, ягъни кеше исем-фамилиялеренең, географик атамаларның беренче, лексик (дооноmастическое значение) мәгънәләренә ишарә итеп сурәт ясау киң таралган күренеш. Бу алым язма әдәбиятның барлык төрләрендә дә кулланыла һәм аның тамыры борынгыдан ук килә.

Болардан тыш әдәби әсәрләрдә еш кына кеше исеменең төп мәгънәсе белән генә түгел, ә аның яңгырашы белән дә персонаж характерының билгеле бер ягын тасвирлап

күрсәтүләр очрый. Бу очракта әдипләр герой исеменең тирәнгә яшеренгән ассоциацияләре белән эш итә. Ягъни образны иҗат иткәндә, аның укучыга тәэсирен билгеләгәндә, исемнең төп мәгънәсе генә түгел, ә аның авазлар табигате дә, әйтелү үзенчәлеге дә исәпкә алына.

Шуңа бәйле рәвештә ономастика фәненең мөһим бер тармагы – поэтик ономасика барлыкка килә. Поэтик ономастика дип, матур әдәбият әсәрләрендә барлык төр ялгызлык исемнәрне, аларның барлыкка килү принципларын, стилистик һәм идеологик функцияләрен өйрәнүче ономастиканың бер тармагына әйтәләр.[1] Татар ономасты Г.Ф.Саттаров поэтик ономастика төшенчәсен матур әдәбият әсәрләренә һәм әдәби каһарманнарга исем бирү сәнгате дип билгели.[1]

Поэтик ономастика берничә мөстәкыйль тармакны үз эченә ала:

1. Поэтик антропонимика – матур әдәбият әсәрләрендә антропонимик категорияләрнең (исем, фамилия, атасы исеме, кушамат) функцияләрен, семантикасын, кулланылыш үзенчәлекләрен өйрәнә.

2. Поэтик топонимика – матур әдәбият әсәрләрендә топонимик категорияләрнең (гидроним, ороним, ойконим, микротопонимнар) вазыйфасын, бирелү мотивларын, кулланылыш үзенчәлекләрен тикшерә.

3. Поэтик псевдономастика – әдәби псевдонимнарны өйрәнү белән шөгыльләнә.

4. Поэтик зоонимика – матур әдәбият әсәрләрендә зоонимнарның (кош-корт, хайван кушаматлары) бирелү сәбәпләрен, поэтик максатларда кулланылыш мөмкинлекләрен тикшерә.

5. Поэтик теонимика – мифологик зат, илаһи көч, Алла исемнәренең әсәр поэтикасын тудырудагы ролен өйрәнә.

6. Поэтик прагматонимика – товар-әйбер исемнәренец сүз-сурәт ясау мөмкинлекләрен тикшерә.

Поэтик онимнар – лингвистик категория булган ялгызлык исемнернең сөйләмдәге халәте, “эш вакыты” ул. Әдәби әсәр эчендә формалашкан ономастик система иң элек язучының шәхси сыйфатлары, индивидуаль иҗат психологиясе кебек факторлар белен тыгыз бейленештә тора. Шул сәбәпле аларны әдәбият һәм тел чигендә тора торган категорияләр буларак кына карарга ярамый. Әдәби герой исемнәре һәмм географик атамалар лингвистик, поэтик, семиотик һәм психологик, фәлсәфи аспектта якын килеп, комплекслы өйрәнүне таләп итә торган өлкә булып тора.

Димәк, әсәргә сүз сайлауның язучының индивидуаль иҗат психологиясе, стиль, метод, жанр кебек категорияләр белән билгеләнә торган үз поэтик законнары, кагыйдәләре бар. Бу кануннар, билгеле, әсәрнең исемнәр системасына да сизелерлек йогынты ясый.

### 1.2. Миф һәм мифология турында төшенчә

Миф әдәби категория булуга карамастан, тикшерү объектына нисбәтле булу сәбәпле, миф һәм мифология мәсьәләләрен яктыртуны да кирәк таптык.

Билгеле булганча, мифология язма әдәбиятының формалашуы һәм борынгы чордан алып үсеше өчен дә нигез хезмәтен үтәгән. Матур әдәбият мифологик образлар белән фикерләүдән башлап (мәсәлән, антик әдәбиятта Гомерның «Иллиада», «Одиссея» поэмалары), мифологиядә эшләнгән художество чараларыннан, персонажлардан һәм сюжет-мотивлардан поэтик – стилистик алым буларак файдалануга кадәр юл үткән. Шуны да әйтеп үтәргә кирәк: җәмгыятьтә Урта гасыр әдәбияты белән бергә андагы мифологик алымнар белән дә кызыксыну мөһим урын били. Мәсәлән, Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф», Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан», Г. Тукайның «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш», «Шүрәле», «Су анасы» әсәрләре, Һ.Такташның «Җир уллары трагедиясе». Аталган әсәрләрдә дә без мифопоэтик онимнар белән очрашабыз.

Мифология (грекча«миф» – сүз, хикәят) – борынгыларның дөнья, тирәлек турындагы фантастик күзаллаулары һәм хыялда туган фантастик образлар, персонажлар турындагы хикәятләре (мифлар) җыелмасы. Мифларны өйрәнү белән шөгыльләнүче фән тармагы мифология дип йөртәләр[1].

Мифларга ышану беткәннән соң, мифология җирлегендә эшләнгән поэтик образ тудыру алымы халык лирикасында, шулай ук язма поэзиядә дәвам иткән һәм, тагын да камилләшеп, аңлы рәвештә кулланыла торган сәнгатьчә фикерләү чарасына әверелгән. Мифларның бу үзлеге язма истәлекләрдәге поэтикасында, аерым алганда, ялгызлык исемнәренең кулланылышында да чагылыш таба.

Мифлар, аларның сәнгати үзенчәлекләре, халык ышанулары, фәлсәфә белән бәйләнешләре рус галиме А.Ф.Лосев хезмәтләрендә яктыртыла[1]. «Миф (сүзнең туры мәгънәсендә) – ул хикәяләү, чынбарлыкны фантастик рәвештә гәүдәләндергән «хикәяләрнең» җыелмасы, әмма бу сүз сәнгате жанры түгел, ә бәлки дөньяны билгеле бер күзаллау. Еш кына ул күзаллау хикәяләү формасын ала; дөньяны мифологик рәвештә күзаллау башка төрле формаларда да булырга мөмкин – хәрәкәт (йолалардагы кебек), җыр, бию һ.б.[2]

Киңрәк мәгънәдә алганда, миф ул – җәмгыятьнең, кәбиләнең, ыруның һәм аерым кешенең яшәү, дөньяны күзаллау рәвеше. Тормышта билгеле бер тәртип урнаштыручы һәм шуны тайпылышсыз саклаучы мифлар – борынгы җәмгыятьнең рухи нигезе.

Миф атамасының килеп чыгышы борынгы грек теле белән бәйләнгән. Анда *mjtos* сүзе риваять, дастан сөйләү дигәнне аңлата. Димәк, мифларга беренчел билгеләмә, исем биргәндә үк аларның нигездә әдәби әсәр булуына басым ясала.

Миф төшенчәсе үз эченә хәрәкәт, йола, гореф-гадәт, ышану, җыр, бию, драматик күренешләрнең барысын да ала. Безнең көннәрдә мифларның төп яшәү рәвеше – прозаик хикәяләү ярдәмендә халык тормышының төрле ягына кагылган күзаллауларның эчтәлеген, мәгънәсен тыңлаучыларга, төгәлрәк алганда – укучыларга җиткерү.

Татар халкында, халык иҗатында, матур әдәбият әсәрләрендә сакланып килгән мифларны, төгәлрәге аларның кайбер үзенчәлекләрен түбәндәге төркемнәргә бүлеп күзәтергә мөмкин:

1) Хайваннар белән кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрен чагылдырган мифлар.
2) Галәм, Җиһан төзелеше, Ай, Кояш, Йолдызлар белән нисбәтле мифологик күзаллаулар.
3) Алла, алиһәләр һәм мифологик персонажлар белән бәйле хикәятләр.
4) Түбән мифология персонажлары.

Мифология сүзе фәндә 2 мәгънәдә йөри. Беренчедән, төрле халыкларның мифларын өйрәнә торган фән. Икенчедән, билгеле бер халыкта таралган мифларның тулы җыелмасын шул ук сүз белән билгелиләр: татар мифологиясе, үзбәк мифологиясе һ. б.

Татарларда мифология фән буларак формалашкан дип әйтү мөмкин түгел. Шуңа күрә икенче мәгънәсен генә күздә тотабыз.

Татар мифларын өйрәнүнең төп чыганаклары:

1) мифологик әсәрләр, нигездә хикәятләр.

2) халык иҗатының кайбер жанрлары: мәкальләр, табышмаклар, дастаннар, әкиятләр.

3) Туган тел һәм тел берәмлекләре.

4) археологик материаллар.

5) башка, бигрәк тә төрки- монгол халыкларының мифологиясенә караган мәгълүматлар.

6) Сәяхәтче-галимнәрнең тарихи һәм тарихи- этнографик хезмәтләрендә теркәлеп калган мифологик материаллар[1].

Мифлар кешелекнең ыруглык дәверендә үк барлыкка килгәннәр. Кеше әле бу чорда үзен табигатьтән һәм кандаш ыруыннан аерып карамаган, менә шуңа күрә дә үзенең сыйфатларын һәм ыруглык мөнәсәбәтләрен табигатькә, андагы бөтен җанлы һәм җансыз нәрсәләргә күчергән. Шул рәвешле, безнең ерак бабабыз бөтен дөньяны «кешеләштергән»: җир, кояш, үсемлек һәм хайваннарны җанлы итеп кенә түгел, ә кеше кебек үк яшәүче, фикерли һәм хисләнә белүче тереклек ияләре итеп, ыруг члennары кебек бер-берсе һәм кеше белән үзара кардәш затлар итеп күз алдына китергән һәм мифларын да нәкъ шундый фикерләүгә нигезләп иҗат иткән.

Борынгылар мифлар аша чынбарлыкны аңлатып кына калмаганнар, ә алар ярдәмендә тирәлеккә, табигатькә тәэсир итәргә дә тырышканнар.

К. Маркс күрсәтүенчә, «һәртөрле мифология табигать көчләрен хыялда һәм хыял ярдәмендә җиңә, бйсындыра һәм формалаштыра». Шул ук вакытта аерым мифларда, фантастик сюжетка һәм образларга төренеп, борынгы кешенең табигатьне беренче җиңүләре гәүдәләнә. Прометей, Геракл, Алып кебек геройларның эшчәнлеге турындагы сюжетлар – моңа ачык мисал.

Иҗади фантазия белән үрелү, художестволы, сәнгатьчә фикерләү белән тыгыз бәйләнештә һәм мөнәсәбәттә булу – мифологиянең аеруча мөһим үзенчәлеге.

Шулай итеп, без бу бүлектә миф төшенчәсенә билгеләмә биреп, аны төрле яктан карап үттек. Иҗат ителү һәм төп яшәү формасы тел белән бәйләнгәнлектән, хикәяләүгә корылган мифлар халык иҗатының иң борынгы катламы булып исәпләнәләр.

## ИКЕНЧЕ БҮЛЕК
## ТАТАР ХАЛЫК ӘКИЯТЛӘРЕНДӘ МИФОПОЭТИК ОНИМ ТӨРЕ БУЛАРАК ПЕРСОНАЖ ИСЕМНӘРЕ

### 2.1. Тылсымлы герой, кош-корт, җәнлекләрне атау өчен кулланылган мифопоэтик онимнар

Соңгы елларда халык авыз иҗаты теле, мәдәни гореф-гадәтләрнең бер чагылышы буларак, тикшеренүчеләрнең игътибарын үзенә җәлеп итә. Халык авыз иҗаты текстларындагы тел мәгълүматлары халыкларның рухи мәдәнияте тарихын өйрәнү һәм торгызу өчен киң кулланыла. Халык авыз иҗаты әсәрләре халыкның тормыш-көнкүреше, тарихы, шул исәптән, тел-сөйләм үзенчәлекләре белән тыгыз бәйләнештә тора. Үзендә этнос турындагы эзлекле тирән һәм төрле пландагы мәгълүматларны туплаган халык авыз иҗаты теле – чыннан да, мәдәният тарихы өчен бик бай чыганак. Халык авыз иҗаты телен өйрәнү лингвистика һәм этнолингвистика теориясен тирәнәйтә, күп гасырлык халык авыз иҗатын тарихи һәм типологик аңлауга этәрә. Фольклор теле, бигрәк тә аның лексикасы, мифология, архаик һәм дини күзаллаулар белән турыдан-туры бәйләнгән. Гомумән алганда, фольклор теле мәдәниятнең мөһим элементларын яңадан торгызырга, халыкларның беренчел яшәү урыннарын һәм мохитләрен, тарихның төрле этапларында үзара мөнәсәбәтләрен ачыкларга мөмкинлек бирә.

Халыкның яшәү рәвешен, аның милли характерын, мәдәниятен халыкның һөнәрләре, гореф-гадәтләре, кием-салымы һәм ризыклары, аны чолгап табигать шартлары, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы формалаштыра. Башка бик күп галимнәрнең фикерләренә кушылып, без дә теләсә кайсы халык тормышының бу яклары әкиятләрдә дә ачык чагылыш таба дип

уйлыйбыз. Чыннан да, нәкъ менә халык әкиятләрендә халыкның тормышны танып белү тәҗрибәсе ныгып калаһәм буыннан-буынга тасвирый формада күчә бара.

Татар халык әкиятләрендә халкыбызның менталитетына караган бик кызыклы мәгълүматлар тупланган. Бу фикерне без әкиятләрдәге мифопоэтик онимнарга карата да әйтә алабыз.

Тикшеренү нәтиҗәләреннән күренгәнчә, татар халык әкиятләрендә мифопоэтик онимнар күп кулланылган.

Татар халык әкиятләрендә еш очрый торган мифопоэтик оним – ул ***Дию***.

***Дию*** *кайтты да хәбәр итте: «Теге тимер мунчаны кыздырып ягыгыз. (“Дию кызы, бай малае һәм мулла”)*

Дию төрки-татар халыкларының мифларында, әкият-дастаннарында төрлечә сурәтләнә. Кыргыз галимнәре Диюнең түбәндәге үзенчәлекләрен билгеләп үтәләр. Дию – тышкы күренеше белән кешегә охшаган демоник зат; коточкыч зур (дәү!) гәүдәсе йон белән капланган; маңгаенда ялгыз мөгезе бар; тешләре дә, кулындагы тырнаклары да бик үткен; оча ала; бик зур көч-кодрәткә ия; чүлләрдә һәм Каф тавында яши; мифларда, эпоста һәм әкиятләрдә кайвакыт мәрхәмәтле, әмма, нигездә, явыз зат, батырның, гомумән кешеләрнең, куркыныч дошманы.[1] Татар мифологиясендәге Дию күрсәтелгән сыйфатларның барысына да ия.

Дию онимының кулланылышы “Кисекбаш китабын”да да теркәлгән:

*Чөн ишетте бу сүзне* ***Дию****дин Гали,*

*Менде ташның өстенә ул дәм вәли (“Кисекбаш китабы”).*

Татар халык әкиятләрендә шулай ук еш очрый торган герой – ул ***Елан***.

***Ак елан*** *әйтә:*

*– Мин аларның патшасы. Минем исемем* ***Шаһмара****, – ди.*

“Еланнар патшасы Шаһмара” – татар халкының тылсымлы әкияте. Л.Җамалетдинов фикеренчә, татарларга иран фольклорыннан кергән.[1] Төп эчтәлеге Борынгы Шәрекъ мифологиясендә һәм ташъязма әдәбиятта чагылыш тапкан мифологик сюжетка нигезләнә: кешенең Икенче дөньяга — Җир асты патшалыгына эләгүе һәм анда күргән газаплары тасвирлана. Биредә әкияттә чагылыш тапкан тагын бер мотивка игътибар итми мөмкин түгел: төрки-татар мифологиясендә һәм халык иҗаты әсәрләрендә елан уңай персонаж буларак сурәтләнә.

*Суны алып килеп, ашларын пешереп, ашап утырган чакта, патша улының чатырына бер* ***Ак бүре*** *килеп сәлам бирде. (“Ак бүре”)*

Татар халкының тылсымлы әкиятләрендә мифопоэтик оним буларак Сандугач исеме дә очрый:

*Хәзер* ***Алпамша Сандугачка*** *әйтә:*

*– Мин, ди, ничек тә алдап-йолдап бу* ***Кылтап патша****ның акбүз атын алырга тиешмен, ди, шул акбүз ат белән мин аны җиңәрмен, – ди. (“Алпамша”)*

## 2.2. Кешеләрне атау өчен кулланылган мифопоэтик онимнар

Тикшеренү нәтиҗәләреннән күренгәнчә, татар халык әкиятләрендә мифологик персонаж буларак тылсымлы яки уйлап чыгарылган затлар гына түгел, кешеләр дә кулланыла. Мисал өчен, “Дутан Батыр” әкиятендә мондый геройлар икәү – Дутан һәм Җалмавыз. Мисал:

*Бу урманда бер* ***Җалмавыз*** *карчык бар икән. Бу* ***Җалмавыз*** *карчык адәм исен сизгәннән соң килеп чыга да, авызын зур ачып, боларны йота.* ***Дутан*** *янына да бара. Йотыйм дип авызын ачканда,* ***Дутанның*** *тае тыпырчына башлый, кешни, пошкыра. Атының тыпырчынганын сизеп,* ***Дутан*** *уянып китә. Торып караса як-ягына: туганнары юк, атлары гына калган.* ***Дутан*** *каршында күрә маңгаенда табак шикелле зур күзле бер карчыкны. (“Дутан батыр”)*

Ф.Урманче билгеләвенчә, бу әкияткә борынгы сынау йолаларында булган, яшүсмерне ниндидер җәнлек-хайванның йотуы белән бәйле саф мифологик мотив килеп керә.[1] Димәк, аңлашылганча, идея-эчтәлеккә бәйле мифопоэтик образның, шуңа бәйле рәвештә мифопоэтик онимның кулланылуы табигый.

***Җалмавыз карчык*** – татар, башкорт, казакъ, кыргыз мифологиясендә һәм фольклор әсәрләрендә киң таралган һәм төрле яктан сурәтләнгән, каршылыклы, уңай сыйфатларга да ия булган, кара урманнарда, тау куышларында, кое төбендә (казакъ халык әкияте «Вәзир»дә) яшәүче җиде башлы явыз зат. Исеменең килеп чыгышына киң тукталып, Р.Г.Әхмәтьянов, барыннан да элек, Җалмавыз сүзенең төрле телләрдә төрлечә язылуын күрсәтеп үтә: татарча Җалмавыз яки Ялмавыз.[2]

Җалмавыз яки Җалмавыз карчык образы башка халыклар мифологиясендә дә бар. Исемнәре дә якын. Чуваш телендә Йелмевес, нугайча Елмауыз, казакъ, каракалпак телләрендә Җалмауыз, кыргызча Җалмоаз, Җелмогуз, карачай-балкар телендә Джелмауз, Себер татарларында Йылмагүз.

Фактик материал күрсәткәнчә, әкиятләрдә *Зөһрә*

*Боларның туган бер балалары үлә барган, ди. Шуннан, бервакыт әби бер кыз китергән. Исемен* ***Зөһрә*** *дип кушканнар. (“Зөһрә”)*

*Зөһрә* – латин теленнән Венера, татар мифологиясендә, фольклорында һәм язма әдәбиятта еш очрый торган йолдызның исеме; билгеле бер символик-мифологик мәгънәгә ия. Борынгы Рим мифологиясендә Венера – мәхәббәт алиһәсе. Төрки-татар дөньясында исә Зөһрә исеме, барыннан да элек, Таһир – Зөһрә буенча билгеле.

Типологик яктан ул шактый соң дәверләргә – урта гасырларга карый. Татар халкында киң мәгълүм булган һәм «Зөһрә йолдыз» дип аталган мифологик легенда да шул ук фикерне раслый. Анда сүз халыкара мифологиядә киң таралган искиткеч матур ятимә кыз Зөһрә һәм аны даими эзәрлекләп торган үги ана хакында бара. Зөһрәнең матурлыгыннан көнләшеп, үги ана аңа бертуктаусыз мәгънәсез эшләр табып тора. Шулай бер кичтә үги ана көне буе эшләп хәлдән тайган Зөһрәгә «төпсез савытка су ташырга кушкан, үзе бик ачуланып: «Әгәр дә таң атканчы тутырмасаң, йортыма аяк басачак булма, кыйнап үтерермен», — дигән». Зөһрә төне буена мәгънәсез эш эшләп, төпсез савытка су ташып интеккән һәм күктәге Айга караган. Шунда бер йолдыз атылып, Зөһрәне «нурларына чолгап күтәрә башлаган» һәм Ай уртасына алып барып куйган. Легенда түбәндәге гаҗәеп матур сүзләр белән тәмамлана: «Сез әгәр дә тулган айга игътибар белән карасагыз, Ай уртасында көянтәсенә чиләкләрен аскан Зөһрә кызның басып торганын әле дә күрерсез. Ә Ай янында ялтырап яна торган йолдыз булыр, бусы инде Зөһрәне Күккә күтәргән йолдыз. Аны Зөһрә йолдызы дип йөриләр.

Әлеге мифның илаһи сакраль мәгънәсе дә бар: әгәр Зөһрә алга таба да Җирдә – бу дөньяда калган булса, аның газаплары дәвам итеп, ахыр чиктә ул, бәлки, һәлак булган булыр иде.[1]

Татар халык әкиятләрендә *Гөлчәчәк, Алпамша, Сылу-көмеш* исемнәре дә кулланылган:

*Борын-борын заманда, зур карурман эчендә бер убырлы карчык торган, ди, аның бер улы белән* ***Гөлчәчәк*** *атлы бер килене булган, ди. (“Гөлчәчәк”)*

*Патша, бу көнгә күренмәс* ***Сылу-көмеш*** *белән бик кызыксынып, вәзирләр чыгып китү белән, теге карчыкның улын чакыртып ала. (“Күзгә күренмәс сылу-көмеш”)*

***Алпамша*** *ташны тотып алып, берсен икенчесенә китереп бәреп яра да, ике ташны кулына киеп, ярылган ике ташны култык астына кыстыра да тауга менеп китә. (“Алпамша”)*

Тылсымлы әкиятләрдә еш кына *Убырлы карчык* мифопоэтик атамасы урын ала:

*Иртәгесен торгач,* ***Убырлы карчык*** *бу кызны мунча ягарга җибәрә. (“Үги кыз”)*

*Убыр* – татар һәм башкорт фольклоры персонажы; явыз зат; һәрвакыт кешеләрнең дошманы буларак сурәтләнә; төрле халыклар мифологиясендә таралган башка явыз затларның куркыныч сыйфатларына да ия: татар-башкорт мифологиясенең *Убыры,* рус фольклорының *Упыре* кебек, алдау-хыянәт юлы белән кешеләрнең, бигрәк тә тәүфыйклы яшь кызларның, канын эчә; җае чыкканда, аларны үлем хәленә җиткерергә мөмкин.

## ЙОМГАК

Тикшеренү эшебездә татар халык әкиятләрендә теркәлгән мифопоэтик онимнарның кулланылыш үзенчәлекләрен тикшердек мәгънәләрен ачыкладык. Эш барышында түбәндәге нәтиҗәләргә килдек.

Мифлар халыкның күзаллавын чагылдыра торган мөһим чыганак булып саналалар, шуңа күрә дә буыннан-буынга тапшырылып килгән әкиятләрнең зур күпчелеге мифларга нигезләнеп язылган. Алар борынгыларның дөнья, тирәлек турындагы фантастик күзаллаулары һәм хыялда туган фантастик образлар, персонажлар турындагы хикәятләре (мифлар) җыелмасы. Татар халык иҗаты әсәрләрендә, матур әдәбиятта еш кына мифологик эчтәлеккә корылган сюжетлар еш очрый. Мондый әсәрләрдә мифопоэтик онимнарның кулланылуы табигый.

Татар халык әкиятләрендә түбәндәге ялгызлык исемнәре теркәлде:
-тылсымлы геройны атау өчен кулланылган мифопоэтик онимнар: ***Дию*, *Дию пәрие, Пәри*** һ.б.
-кош-кортны атау өчен кулланылган мифопоэтик онимнар: ***Сандугач***.
-җәнлекләрне атау өчен кулланылган мифопоэтик онимнар: ***Елан Патша, Ак бүре*** һ.б.

Кешеләрне атау өчен кулланылган мифопоэтик онимнар үзенә бер аерым төркем тәшкил итә. Биредә ***Зөһрә, Алпамша, Алып батыр, Убырлы, Җалмавыз, Сылу-көмеш*** һ.б. исемнәрне атарга мөмкин.

Гомумән, татар халык әкиятләрендә бирелгән мифопоэтик онимнар – аерым тикшеренүне сорый торган мәсьәлә. Чөнки татар халык әкиятләре татар халкының интеллектуаль үсешен, аның күпмәгънәле яңгырашын, үткәнен, күзаллауларын чагылдыра торган үрнәкләр булып торалар.

Йомгаклап әйткәндә, татар халык әкиятләрендә мифопоэтик ономастика шактый зур урын алып тора. Тикшеренү эшебездә тылсымлы персонажларны атый торган исемнәрне анализладык, бу теманы әкиятләрдә мифопоэтик топонимнарның кулланылыш үзенчәлекләрен тикшерү юнәлешендә дә дәвам итәргә мөмкин.

## КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

<u>Рус телендә</u>

Буслаев, Ф. И. Народный эпос и мифология: [сборник] / Ф. И.Буслаев / [Сост., авт. вступ. ст. и коммент. С. Н. Азбелев]. – Москва : Высш. шк., 2003. – 398 с.

Замалетдинов, Л. Ш. Татарская народная сказка и литературные сказки Тукая / Л. Ш. Замалетдинов: Автореф. ... канд. филол. наук. – Казань, 1993. – 24 с.

Замалетдинов, Л. Ш. Общности в сказках народов Среднего Поволжья и Приуралья / Л. Ш. Замалетдинов // Межэтнические общности и взаимосвязи фольклора народов Поволжья и Урала. – Казань: ИЯЛИ им. Г.Ибрагимова КФАН СССР, 1983. – С. 91-99.

Замалетдинов, Л. Ш. Сюжетный состав сказок / Л. Ш. Замалетдинов // Поэтика татарского фольклора. – Казань: ИЯЛИ им. Г.Ибрагимова КФАН СССР, 1991. – С. 60-75.

Кульсарина, Г. Г. Язык и стиль башкирских народных сказок: Автореф. ... канд. филол. наук. / Г. Г. Кульсарина. – Уфа, 2004. – 24 с.

Лосев, А. Ф. Философия. Мифология. Культура / А. Ф. Лосев. – Москва : Политиздат,1991. – 525 с.

Михайлов, В. Н. Некоторые аспекты лингвостилистического анализа ономастики в составе художественный произведений // Лексика русского языка. – Рязань, 1979. – 35 с.

Михайлов, В. Н. Роль ономастической лексики в структурно- семантической организации художественного текста / Русская ономастика. – Рязань,1982. – С. 100- 123.

Мухамедзянов, Р. К. Специфика татарских фольклорных жанров / Р. К. Мухамедзянов. – Уфа: БашГУ, 1989. – 136 с.

Национальный язык и национальная культура. – Москва : Наука, 1978. – 214 с.

Поэтика татарского фольклора. – Казань: ИЯЛИ им. Г.Ибрагимова, 1991. – 132 с.

Яхин, А. Г. Система татарского фольклора / А. Г.Яхин. – Казань: Тат. кн. Изд-во, 1984. – 200 с.

**Татар телендә**

Әхмәдуллин, А. Г. Әдәбият белеме сүзлеге / А. Г. Әхмәдуллин. – Казан : Татар. кит. нәшр.,1990.

Әхмәтьянов, Р. Татар терминологиясенең тарихи чыганаклары / Р. Әхмәтьянов. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2003. – 174 б.

Баязитова, Ф. С. Фольклор әсәрләренең теле һәм диалектлар / Ф. С. Баязитова // Исследования по татарскому языкознанию. – Казань : КФАН СССР, 1984. – 129 с.

Җамалетдинов, Л. Ш. Тылсымлы әкиятләрдә елан белән бәйле мифологик образлар / Л. Ш. Җамалетдинов. // Борынгы татар фольклоры мәсьәләләре. – Казан : КФ АН СССР, 1978. – Б. 15.

Җамалетдинов, Л. Ш. Әкиятләрнең килеп чыгуы / Л. Ш. Җамалетдинов. // Татар фольклоры жанрлары. – Казан : Г.Ибраһимов исемендәге ТӘһСИ, 1978. – Б. 5-25.

Җамалетдинов, Л. Ш. Әкият традициясе һәм заман / Л. Ш. Җамалетдинов // Татар халык поэтик иҗатының хәзерге торышы. – Казан : Г.Ибраһимов исемендәге ТӘһСИ, 1988. – Б. 5-24.

Исәнбәт, Н. Татар халкының поэтик иҗаты / Н. Исәнбәт. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1967. – 405 с.

Курбатов, Х. Р. Хәзерге татар теленең стилистик системасы / Х. Р.Курбатов. – Казан : Тат. кит. нәшр., 1971. – 192 б.

Мәһдиев, М. С. Фольклор жанрларын анализлау / М. С. Мәһдиев. – Казан : КДУ, 1986. – 128 б.

Нуриева, А. Х. Татар теле тарихыннан материаллар / А. Х. Нуриева. – Казан : 1975. – 97 б.

Саттаров, Г. Ф. Г.Ибраһимов әсәрләрендә атамалар // Казан утлары. – 1958. – Б. 180-184.

Саттаров, Г. Ф. Татарстан АССРның антропотопонимнары = Антропотопонимы Татарской АССР: (Татарстан авылларының исемнәре) / Г. Ф. Саттаров; В. И. Ульянов-Ленин исем. Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы КДУ. – Казан : Казан ун-ты нәшрияты, 1973. – 296 б.;

Саттаров, Г. Ф. Татар исемнәре сүзлеге / Г. Ф. Саттаров. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1981.

Татар грамматикасы. Т.2. – Москва : “Инсан”, Казань: “Фикер”, 2002. – 448 б.

Тумашева, Д. Г. Хәзерге татар әдәби теле. Морфология / Д. Г. Тумашева. – Казан : КДУ нәшр., 1978. – 221 б.

Урманче, Ф. И. «Тирән тамырлар». Фәнни эзләнүләр юлында / Ф. И. Урманче. – К.: Фикер, 2000.

Урманче, Ф. И. Татар халык иҗаты / Ф. И. Урманче. – Казан  : Мәгариф, 2005. – 383 б.

Урманче, Ф. Татар мифологиясе: энциклопедик сүзлек: 3 томда / Фатих Урманче; Татарстан Респ. Фәннәр акад., Тел, әд. һәм сәнгать ин-ты. — Казан : Мәгариф, Т. 1: А – Г. – 2008. – 302 б.

Урманче, Ф. Татар мифологиясе: энциклопедик сүзлек: 3 томда / Фатих Урманче; Татарстан Респ. Фәннәр акад., Тел, әд. һәм сәнгать ин-ты. — Казан : Мәгариф, Т. 2: Д – С. – 2009. – 360 б.

Хаков, В. Х. Татар әдәби теле тарихы фәне һәм аның алдында торган бурычлар // Татарское возрождение. Эпоха и личности. – Казань : Фән, 2000. – Б. 67-74.

Хангилдин, В. И. Татар теле грамматикасы. II басма / В. И. Хангилдин. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1959. – 642 б.

Ярми, Х. Татар халкының поэтик иҗаты / Х. Ярми; СССР ФА, Г. Ибраһимов исем. Казан Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1967. – 308 б.

## ЧЫГАНАКЛАР

Балалар фольклоры / Төз. Л. И. Минһаҗева. – Казан : Хәтер, 2009. – 479 б.

Көмеш-сылу. Татар халык әкиятләре./ Төз. Н. Вәлитова. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1993. – 352б.

Татар халык авыз иҗатыннан үрнәкләр. Әкиятләр // Татар балалар әдәбиятыннан хрестоматия: Ике томда. Беренче том: Урта һәм югары педагогик уку йортлары өчен уку ярдәмлеге / Төз. Л. И. Минһаҗева, И. Х. Мияссарова. – Казан : ТаРИХ, 2003. – Б. 5-19.

Татар халык әкиятләре: Әкиятләр. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1989. – 480 б.

Татар халык иҗаты. Әкиятләр (икенче китап). – Казан : Татар. кит. нәшр., 1978. – 447 б.

*Шәймәрдәнова Диләрә, 9 нчы сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының*
*«Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче Җәлил беренче урта гомуми белем бирү мәктәбе»*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләре: Шакирова Эльмира Шарифулл кызы,*
*Шәймәрдәнова Лилия Нур кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

## Нинди кош син, Каз?

### Кереш

Кеше – табигать баласы, ә табигать – яшәү чыганагы. Кешелек җәмгыяте барлыкка килгәннән бирле, кеше табигать белән бәйләнештә торган, үзенә якын йорт хайваннарын һәм кошларны кулга ияләштергән. Шул рәвешле тормыш алар белән үрелеп бара башлаган. Шулай бергә яшәүче һәм татар халкы белән бер-берсеннән аерып карап булмаучы кошларның берсе – ул каз. Татарда каз гомер-гомергә бик дәрәҗәле, затлы кош булып саналган. Ә нинди кош соң ул каз? Халкымның тормышы аерылгысыз бәйләнгән бу кош турында минем тирәнрәк беләсем килде. Шуңа да эзләнү эшемдә әлеге темага тукталырга булдым. Эзләнү эшемнең максаты: нинди кош ул каз? Татар халкында каз белән нәрсәләр бәйле, каз образы безнең тормышыбызда һәм әдәбиятыбызда нинди урын алып тора? сорауларына җавап табу. Минемчә, республикабызда милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы уңаеннан, быел бу тема бик актуаль, чөнки каз белән бәйле кайбер халык традицияләрен бүгенге көн яшьләре әле белеп бетермәскә мөмкин. Максатыма ирешү өчен мәктәп һәм поселок китапханәсенә, интернет челтәренә мөрәҗәгать итеп, халкыбызның бәйрәмнәренә, гореф-гадәтләренә, йолаларына караган материаллар җыйдым, әбием һәм әнием сөйләгән чыганакларга таяндым, каз образы кергән һәм казга белән бәйле булган әдәби әсәрләр белән таныштым.

### Төп өлеш

#### 1 нче бүлек. Башкалабыз атамасы „каз“ сүзеннән килеп чыкканмы?

Фәнни эшем өчен эзләнүләр вакытында интернет челтәрендә мин “Сөембикә” журналының “Хатлар йорты” проекты җитәкчесе Энҗе Садыйкова белән интервью укыдым. Ул «Татарстан» журналы сайтында бик кызыклы бер тикшерү нәтиҗәләренә тап булган.

Казан биологлары Игорь, Олег һәм Артур Аскеевлар Идел буе территориясендә казның ничәмә-ничә дәверләр буена йорт кошы булып саналуының төп сәбәбен, нинди токым казлар

үрчетелгәнне белү теләге белән, фәнни эзләнү үткәргәннәр. Каз безнең якларда үрдәккә кадәр үк, иң беренчеләрдән булып кулга ияләштерелгән кошлардан санала икән.

Ни өчен тикшерүне нәкъ менә каз турында үткәрдегез, мәсәлән, сыер турында түгел дигән сорауга фәнни эш авторларының берсе Олег Аскеев болай дип җавап бирә: «Чөнки каз безнең төбәктәге изге кош. Безнең якларда казга бәйле бик күп ышанулар һәм легендалар бар. Татарлар гына түгел, мари, удмурт, башкорт халкы да бик ярата әлеге кошны. Идел буе һәм Урал аръягы халыклары казга табынган. Минем уйлавымча, Казан, гомумән, „котел“ дигәнне аңлатмый. Безнең шәһәрнең атамасы „каз анасы“ сүзеннән килеп чыккан», — дип яза ул.

Әлеге теориягә ышаныргамы, юкмы, белмим. Ләкин аның булуы ук бик кызык һәм урынлы. Чөнки бик борынгыдан безнең Идел буйларында каз булган һәм ул халык тормышында зур урын алып торган, — дип яза Энҗе ханым.

Әйе, каз ул — кулга ияләштерелгән иң борынгы йорт кошларының берсе һәм авыл халкының аерылгысыз бер өлеше. Халык элек-электән күп итеп каз асрарга яраткан. Кайсы гына авылга барма, каз асраучы гаиләләрне очратасың. Хәзер безнең әбиләр каз бәбкәләрен сатып алалар, ә элек алай булмаган. Каз бәбкәләрен ана каз утырып чыгара торган булган. Бәбкәләр чыгуын бөтен гаилә бер булып, сөенеп көтеп алган. Ана казга изге җанга караган кебек караганнар, аны кадерләгәннәр. Урыны да гомер-гомергә иң җылы урында, гадәттә, өй эчендә, сәке астында булган. Әйбәтләп утырып бетererме, йомыркаларының барысы да бәбкәле булырмы дип өметләнеп көткәннәр. Каз гаиләгә әнә шулай зур шатлык алып килә торган булган.

**2 нче бүлек. Балачакның иң якты хатирәсе дә ул.**

Мин кечкенәдән әнинең каз турында төрле кызык хәлләр сөйләвен ишетеп үстем. Безнең әбиләрнең өйләре бик зур түгел. Шул кечкенә генә өйдә ана каз иң дәрәҗәле урында — караватастында утырып бала чыгара торган булган. Каз утыра торган бүлмә ниндидер бер изге урынга әйләнгән. Анда шауларга, кычкырып сөйләшергә ярамаган, чөнки ана каз куркып, йомыркаларына зыян китерергә мөмкин булган.

“Без үскәндә өйдә мич артында яки өйалдында каз утырганда каты сикереп уйнарга ярамаганын һәр бала белә иде. Тавышланып-сикереп уйнасаң, янәсе туачак бәбкәләр тумаска да мөмкин”, - дип искә ала әни. Ә инде бәбкәләрнең борынлавын ничек сабырсызланып көткәннәр алар! Каз йомыркаларын карау үзе бар могҗиза булган. Әби ул йомыркаларны каз астыннан ала, алар йөзәрлек итеп җылы су салынган табакка сала һәм көтә икән. Бераздан йомыркаларның кайберләре суда әкрен генә селкенә башлый. Йомырка эчендә җан кергән бәбкәләр үзләре хакында әнә шулай белгертәләр. Әби бу йомыркалардан тиздән бәбкәләр чыгачак, Аллаһ боерса, дип яңадан каз астына салган. Йомыркаларны озак

тотарга ярамаган, алар суынырга мөмкин. Селкенмәгәннәрен ул каз оясының уртасынарак куйган. Алар шунда тизрәк җылынып, бәбкә тусын өчен.

Каз оясыннан йомырка алу үзе бер тарих булган. Ана каз ничектер пышылдап кына “сөйләшә” икән, әби дә аңа йомшак кына җавап бирә. Шунысы кызык, әбидән башка кеше оясына якын килә башласа, ана каз кызыл телләрен чыгарып усал итеп ысылдый башлаган. Кая анда ояга якын килү! Ачуын китерсәң, тешләп алуы да бар. Ә әбигә бер сүз “әйтми”! Алар икәү ничектер үзара пышылдашып кына сөйләшкән кебек тә булганнар.” Әби кулын ояга тыгар алдыннан каз менә моннан ал дигән шикелле уң йә сул канатын күтәреп куя торган булган. Ә инде ишегалдына чыксаң, ишек төбендә ата каз утырып торган: ана казның һава суларга чыканын көткән. Бәбкә чыгарганда ана каз оясыннан күп дигәндә 15 минутка гына чыгып керә торган булган. Ә чыгып киткәнче, оядагы йомыркаларын, суынмасын өчен, салам белән шундый оста итеп томалап куйган, адәм баласы да алай эшли алмый торгандыр.

Әнинең сөйләвенчә, ана каз шактый усал да булган. «Әни ашарга бирә, шуңа аны чукымый, мин караватка якынрак килсәм, мине чукый да ала. Аптырадым гына бит. Берсендә башка сукты минем. Әнинең оегын кияргә кирәк, ул бит карават астында безнең аякны гына күрә дип уйладым. Әнинең оегы да булышмады — каз мине барыбер чукып алды. Зиһенле, белә бит кемнең кем икәнен», — дип сөйли минем әнием.

Өйдә бәбкә тавышы ишетелү үзенә күрә кечкенә генә бәйрәм шикелле булган. Йомырканы тишеп чыккан хәлсез томшыкны әби әкрен генә суга тидереп алган... Чыккан берен мич башына алдан әзерләнгән җылы урынга җибәрәгән, йомырка, яшь кычыткан кушып ясалган җим белән сыйлаган. Бераздан утырып, ябыгып беткән ана казга бәбкәләрен кушканнар. «Берәрсен ят итмәсә ярар иде, барысын да кабул итсә ярар иде», — дип догаларын укып башкарган карт әби бу олы эшне. Беренче тапкыр бәбкәләрен күргән ата казның кыланмышлары үзе бер спектакль булган. Шатлыгыннан тыпыр-тыпыр биегән ул, ә әби такмак әйтеп торган.

Авыл баласы өчен каз бәбкәсе саклау, ата каздан курыкмаска өйрәнү, каз боты ашарга лаек булырлык үсеп җитү яки йорт-җир тирәсендә кичке табында каз боты белән бүләкләнерлек ниндидер бер зур эш эшләү гомергә истә калырлык вакыйгалар булган.

**3 нче бүлек. Казның көнкүрештә файдасы.**

Култык астындагы берничә бөртек хәрам йонынннан тыш, казның бер генә әйберсе дә әрәм булмый. Йон-мамыгы – мендәргә, ите – ашарга, мае ризык кыздырганда тотыла. Каз мае туңмай шикелле катмый, гел йомшак булып тора торган эрү май. Аны дару сыйфатында кулланганнар. Мәсәлән, кыш көне бит өшегәндә беренче булып каз мае ярдәмгә килгән. Каз маен бүген дә дәвалау өчен кулланалар. Кышкы суыкларда, колак

очлары өшесә, каз мае сөртсәң, салкын тигәндә каз маен эретеп эчсәң, проблемалар ким була. Каз канаты белән идән себерергә була. Каурый очыннан май канаты – дөгәч ясыйлар...

Ә менә каз каурые каләм буларак 1200 ел кулланылган икән. Бары тик XIX гасыр ахыры XX гасыр башларында гына каурый каләм урынына ручка уйлап табылган. Ручка сүзенең этимологиясен кереп карасаң да, аның бик күп илләрдә каурый сүзен аңлатканын күрербез. Penna латинчадан кош канаты дигәнне аңлата. Инглиз, голланд халыкларында ручка — pen, шведларда — penna, Норвегия халкында һәм исландларда — penn

Татар өен өем-өем мендәр-ястыклардан башка күз алдына да китереп булмый. Халык казның мамыгыннан бик оста итеп файдаланган. Пар мендәрләр, юрганнар белән кызны кияү йортына озатканнар.

Ә каз ите гомер-гомергә бик затлы ризык булып саналган.Ниләр генә пешермәгән халык каз итеннән — каз бәлеше, каз коймагы, каз тәбикмәге, каклаган каз дисеңме. Каз – туйларның да төп күрке. Чөнки кыз яки улның туен үткәргәндә пар каз борынгыдан инде туйның хөрмәтле күчтәнәче булган. Шундый хөрмәтле, зур бәйрәмнәрдә өстәлнең күрке ул каз.

Ә каз өмәләре! Авыл тормышының әлеге матур бизәге күмәк өмә булудан тыш, авыл яшьләренең танышу, аралашу, күңел ачу чарасы булып та хезмәт иткән. Шушы каз өмәсенең үз эчендә генә дә тагын әллә никадәр кызыклы йолалар бар. Каз канатын, киләсе елга казлар күп булсын дип, елга буена сибүме, кичке уен вакытында егетләргә каз канаты сату, каз бәлеше белән сыйлану дисеңме… Әлеге матур гореф-гадәтне яктыртуга күренекле язучыбыз Гомәр Бәширов үзенең «Туган ягым — яшел бишек» әсәрендә тулы бер бүлек багышлаган. Ул анда каз өмәсен бөтен нечкәлекләре белән тасвирлап бирә, әлеге бәйрәмнең авыл халкы өчен никадәр мөһим булуын дәлилли.

Кәрим Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» пьесасында да әлеге йола бик зур урын алган. Әсәрнең төп асылы ул булмаса да, әлеге гореф-гадәтләр, каз өмәсе шулхәтле тирән, матур итеп күрсәтелгән анда.

Татар халкында каз белән бәйле ырымнар да күп. Мәсәлән, казлар бәбкәне күп чыгарсын өчен, киек казлар кайткан вакытта җирдән салам алып, каз оясына салганнар. Казларны чишмәгә юарга төшкәндә юл буйлап сыдырган каурый чәчә барганнар. Бу да киләсе елга казлар ишле булсын, судан тезелешеп кайтсын дигән нияттән башкарылган. Яр тутырып казлар үссен дип, кайбер авылларда каурыйны су буена тезеп чыкканнар. Каз өмәсенә килүчеләр канат урларга тырышкан. Канат урлап алып кайтсаң, үзеңнең дә казың уңа, имеш. Ә хуҗалар канатны бирмәскә тырышкан, тиз генә санап алып куйган. Бик гозерләнеп сорасалар, канатны өй почмагына кыстырып куйганнар, кирәк кеше шуннан алып киткән. Кешегә биргәндә канатның очын кисеп, казан өсләрен сыпырып кына да биргәннәр. Югыйсә кул арты китәргә мөмкин, дигәннәр. Каз канатын еракка, су артында

яшәүчеләргә бирергә ярамый дигән ырым да бар. Кайдадыр сул канатын бирергә яраган, ә уң канатны бирәүгә дә бирмәгәннәр.

Тере казны да ырымлап кына сатканнар. Усал, мәкерле кешеләргә каз сатмаганнар. Алган кеше сатучыга бер телем ипи бирергә тиеш булган.

**4 нче бүлек. Каз — татар халкының бик көчле символы.**

Каз образы — ул татар халкының онытылган, ләкин бик көчле символы.

Халык авыз иҗатында, язучыларыбызның әдәби әсәрләрендә бу образ еш очрый һәм күп очракта ул изге кош буларак сурәтләнә.

Ана каз образы — ул татар хатын-кызы, әни кеше образы. Мәсәлән, бу теманы Әмирхан Еники үзенең «Ялгыз каз» әсәрендә бик тирән итеп ачып бирә. Сугыш гарасатлары вакытында иптәшен югалткан ана каз кешеләргә ияләшә. Ләкин каз үзен бик бәхетсез хис итә. Чөнки ул ялгыз, ә аның нәселен дәвам итәсе, бәбкәләр үстерәсе килә. Хуҗабикәсенең тавык астына салып чыгарткан каз бәбкәләрен күрү белән, каз бөтен тынычлыгын югалта. Әсәр ахырында табигать барыбер үзенекен эшли — каз шул бәбкәләргә әни була. Әдип әсәрдә ана каз өчен дә, нәкъ кеше кебек гаилә, нәсел дәвам итү дигән төшенчәләрнең бик әһәмиятле булуын күрсәтә.

«Бер оя бала үстерәләр», — дип сөйләшә бездә халык. Бу күп балалы, матур, үрнәк гаиләләргә сокланып әйтелә торган сүз.

«Кыз гомере — каз гомере» дигән мәкаль дә бар халыкта. Татар халкы кызларны каз белән чагыштыра. Кадерләп тәрбияләсәң дә, көз җиткәч, ничек кенә моңсу булмасын, казларны башка язмыш көтә. Ничек кенә үз янында тотарга теләсәң дә, кыз бала да гомер буе туган-үскән йортында яши алмый. Ул тормышка чыгып, үзенең насыйбы белән гаилә корырга, әти-әни кочагыннан аерылырга тиеш.

Халык авыз иҗатында да казлар турында байтак укырга була. Мәсәлән, «Каз» сүзе кергән мәкаль-әйтемнәр:

Ялгыз казның тавышы чыкмый.

Аңарда каз зиһене бар.

Каз канаты кавырсын, хатым килсә, алырсың.

Аерылган каз тупланган каргага җим булыр.

Балалы казга җим тимәс.

Каз артыннан тавык Идел аша очмас.

Каз — каз белән, үрдәк үрдәк белән очар.

Каз какылдаудан туймас, үрдәк бакылдавын куймас.

Каз үрдәкне талый, үрдәк тавыкны талый.

Оясын пычраткан каз басып торыр.

Кыр казлары турында җырлар бихисап. Йорт казы турында алай ук күп дип әйтеп булмый. Иң популяр ике татар халык җыры бар:

**«Каз канаты»**

Каз канаты кат-кат була,
Ир канаты ат була;
Чит җирләрдә бик күп йөрсәң,
Сөйгән ярың ят була.
Каз канаты каурый-каурый,
Хатлар язарга ярый.
Уйнамагач та көлмәгәч,
Бу дөнья нигә ярый.
Каз канаты ап-ак була,
Ир канаты ат була;
Чит илләрдә йөргән чакта
Бик сагынган чак була.

**«Дүдәк-дүдәк»**

Йөгерә үрдәк, йөгерә каз
Боты озынга күрә.
Әй, дүдәк, дүдәк, дүдәк,
Басма өстендә каз, үрдәк,
Кыйгак-кыйгак,
Бак, бак, бак, бак,
Басма өстендә каз, үрдәк.
Без кызларны яратабыз
Бите кызылга күрә.
Әй, дүдәк, дүдәк, дүдәк,
Басма өстендә каз, үрдәк,
Кыйгак-кыйгак,
Бак, бак, бак, бак,
Басма өстендә каз, үрдәк.
Йөгерә үрдәк, йөгерә каз,
Кала эзеннән тамга.
Әй, дүдәк, дүдәк, дүдәк,
Басма өстендә каз, үрдәк,
Кыйгак-кыйгак,

Бак, бак, бак, бак,
Басма өстендә каз, үрдәк.
Үтә матурларны сайлап,
Урта матурдан калма.
Әй, дүдәк, дүдәк, дүдәк,
Басма өстендә каз, үрдәк,
Кыйгак-кыйгак,
Бак, бак, бак, бак,
Басма өстендә каз, үрдәк.

**Йомгак**

Эшемне йомгаклап, шуны әйтәсем килә: каз — ул аккошлар, затлы кошлар нәселеннән дип уйлыйм мин. Шуңа күрә ул халкыбызның дәрәҗәле йорт кошы булып санала. Бик нечкә, шул ук вакытта кыю да, горур да кош бит ул.

Фәнни эшне эшләү дәверендә куелган максатка өлешчә ирештем дип саныйм. Гореф-гадәтләр онытылмасын, алар онытылса милләт, халык юкка чыгачак. Минемчә, буыннан буынга күчә торган рухи тәҗрибә һәм йолалар вакытлар узу белән һич тә әһәмиятләрен югалтмаслар, киресенчә, аларның кыйммәте арта гына барыр.

**Кулланылган әдәбият**


1. “Сөембикә” журналы. 2021, февраль №2
2. Еники, Әмирхан. Сайланма әсәрләр. – Казан : Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты (ТаРИХ), 2002. – 416 б.
3. Кәрим Тинчурин. Сайланма әсәрләр. 2 том. – Казан : Татарстан китап нәшрияты, 1971.
4. Татар халык авыз иҗаты.
5. Интернет челтәре материаллары.

## Татар халкының Бөек шагыйре, журналист, хәрби корреспондент Муса Җәлилнең бай мирасы

*Муфтахов Ильяс, 7 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Адымнар – Түбән Кама»*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Валеева Лейсан Мидхат кызы,*
*туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

### Түбән Кама шәһәрендә М. Җәлил һәйкәле тарихы

### Кереш

“Түбән Кама шәһәрендәге М.Җәлил һәйкәле тарихы” темасына багышланган фәнни эшнең актуальлеге бүгенге көндә дә Җәлил батырлыгы ватанпәрвәрлек хисләрен тәрбияләүдә үрнәк, шагыйрь иҗатындагы сугыш темасының әле дә аваздаш булуы белән аңлатыла.

Фәнни эшкә Түбән Кама шәһәрендәге М.Җәлил һәйкәле тарихын өйрәнү максаты куела. Әлеге максатка ирешү юлларына түбәндәге бурычлар билгеләнә:

1. Герой-шагыйрь М.Җәлилнең иҗатын, тормыш юлын өйрәнү.
2. М.Җәлилгә куелган һәйкәлләрне барлау.
3. Түбән Кама шәһәренең элеккеге архитекторы Ф.Ханов белән әңгәмә.
4. Шәһәребез газеталары материалларына күзәтү.
5. Түбән Кама шәһәрендә куелган һәйкәлнең рухи кыйммәтен ачыклау.

Эшнең фәнни кыйммәте әлеге темага әзер материал, фәнни һәм әдәби мәкаләләр булмавы белән аңлатыла.

Фәнни эшкә әзерлек вакытында М.Җәлилнең 5 томлыгы кулланылды[4]. Шулай ук, вакытлы матбугат битләреннән, истәлекләрдән мәгълүмат җыелды.

Эш кереш, ике бүлектән, икешәр бүлекчәдән торган төп өлеш һәм йомгактан тора. Эшкә нәтиҗәләр йомгакта ясалды. Кушымтада күрсәтмә материал тупланды. Эш ахырында кулланылган әдәбият исемлеге китерелде.

### Беренче бүлек.

### М.Җәлил – батырлык һәм иҗат көче символы

#### 1.1. Герой-шагыйрь М.Җәлил язмышы.

Татар халкының бөек улы, герой шагыйрь Муса Җәлил (Муса Мостафа улы Җәлилов) 1906нчы елның 15нче февралендә элекке Оренбург губернасы (хәзерге Оренбург өлкәсе Шарлык районы) Мостафа авылында крестьян гаиләсендә алтынчы бала булып

дөньяга килә. Алты яшеннән авыл мәктәбенә укырга керә, гаилә шәһәргә күчкәч, укуын “Хөсәения” мәдрәсәсендә дәвам иттерә. Мәдрәсә елларында (1914-1917) матур әдәбият әсәрләрен яратып укый, Тукай, Дәрдмәнд, С. Рәмиев иҗатлары белән яыннан таныша, шулар тәэсирендә үзе дә шигырьләр язып, аларны мәдрәсәдәге кулъязма журналга урнаштыра бара. “Кызыл йолдыз” газетасында унөч яшьлек М. Җәлилнең “Бәхет”исемле шигыре басылып чыга. Шуннан соң аның революция, көрәш рухы белән сугарылган романтик шигырьләре матбугат битләрендә еш күренә башлый. 1922нче елның көзендә М. Җәлил Казанга килә. Башта ул “Татарстан”газетасы редакциясендә эшли, ә 1923нче елдан Татрабфакта укый башлый.

1925нче елда исә “Барабыз” исемле беренче шигъри җыентыгы дөнья күрә. М. Җәлил “Кечкенә иптәшләр” һәм “Октябрь баласы” дигән беренче татар балалар журналларын оештыруда актив катнаша һәм җаваплы редакторы булып эшли. Бер үк вакытта ул 1927-1931нче елларда I Мәскәү дәүләт университетының әдәбият-сәнгать факультетында укып югары белем ала.

1935нче елда Мәскәү дәүләт консерваториясе каршында татар опера театрына профессиональ кадрлар әзерләү өчен Татар опера студиясе оештырылгач, М. Җәлилне шунда әдәби бүлек мөдире итеп эшкә чакыралар. Ә1939 елда М. Җәлил Татарстан Язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре итеп билгеләнә[1:512].

Ватан сугышын ул шушы җаваплы постларда эшләгән җәмәгать эшлеклесе һәм күренекле әдип сыйфатында каршылый. 1941нче елның июль аенда М. Җәлил армиягә алына. 1942нче елның июнендә Волхов юнәлешендә барган канлы сугышлар вакытында, аларның часте чолганышта калып, М. Җәлил каты яраланган хәлендә дошман кулына эләгә. Шул көннән патриот шагыйрьнең фашист тоткынлыгындагы газаплы һәм героик тормыш этабы башлана. М. Җәлил һәм җәлилчеләрнең, яшерен оешма төзеп, фашизмга каршы алып барган героик көрәше, каһарманлыклары турында дистәләрчә китаплар - романнар, повестьлар драма әсәрләре һәм поэмалар язылган, кинофильмнар төшерелгән. Иң мөһиме: Җәлил һәм аның иптәшләре ахыргы сулышларына кадәр ватан алдында турылыклы булып калалар һәм фашизмга каршы көрәштә тиңдәшсез рухи ныклык, батырлык үрнәге күрсәтәләр. 1944нче елның февраль аенда Җәлилгә һәм аның көрәштәшләренә Дрезденда суд була. Фашистик хәрби суд аларны, “дәүләткә каршы җимерү эше” алып баруда гаепләп, үлем җәзасына хөкем итә. Шул елның 25нче августында Плетцензее төрмәсендә унбер җәлилченең гомере өзелә. 1956нчы елның 2нче февралендә СССР Верховный Советы Президиумы Указы белән Муса Җәлилгә Ватан сугышы чорында күрсәткән тиңдәшсез ныклыгы һәм батырлыгы өчен Советлар Союзы Герое исеме бирелде, ә әсирлектә тудырган поэтик иҗаты – бөтен дөньяга мәшһүр “Моабит дәфтәрләре” Ленин премиясенә лаек булды.

**2.1.М.Җәлил истәлегенә куелган һәйкәлләр.** М.Җәлил истәлегенә беренче һәйкәл Казанда куела (куш. 1). 1966нчы елның 3 нче ноябрендә Казан Кремле каршында Муса Җәлилгә һәйкәл ачыла. Скульптор Владимир Цигаль ясаган монумент шагыйрьнең тууына 60 ел тулу хөрмәтенә куелды. 1994нче елда монумент комплексы җәзалап үтерелгән татар геройларының барельефлары белән баетыла.

Хәзер бу һәйкәл комплексы РФнең мәдәни мирас объекты булып тора. Шагыйрьнең билгә кадәр ялангач гәүдәсе, аны чолгаган чәнечкеле тимер чыбыкларны өзәргә тырышып, алга омтылган. Һәйкәлдәге Муса образы ныклык һәм үҗәтлекне тасвирлый. Җәлилчеләр истәлегенә куелган барельефлы композиция хәзерге заман кешеләренә сугыш фаҗигасе, һәлак булган әдипләр, 1944нче елның 25 нче августында татар шагыйре җәзалап үтерелгән Берлинның Плетцензее төрмәсе хакында искәртеп тора.

1976нчы елда Оренбург өлкәсе Шарлык районы Мостафа авылында – М.Җәлилнең туган җирендә һәйкәл ачыла. Танылган Оренбург архитеткоры Н.Г.Петин әзерләгән бюст 8 метрлы гранит стелага урнаштырылган. Бюсттагы Муса еракка төбәлгән карашы белән туган җирләрен күзәтүче лирик шагыйрь образында ( куш. 2). Чираттагы һәйкәлләр Оренбургта (куш.3), Санкт-Петербург (куш.4) шәһәрләрендә ачылалар.

Мәскәүдә М.Җәлилгә ике һәйкәл куелган. Аның берсе этно-мәдәни юнәлештә белем бирүче 1186нчы мәктәп янында урнашкан (куш.5). Икенчесе 2015 нче елны, Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышлап, Царицыно паркына урнаштырыла. Бу урын очраклы сайланмаган, чөнки янәшәдә М.Җәлил урамы уза. Һәйкәлнең авторлары – скульптор А.С.Злотя һәм архитектор А.М.Калмыков, биеклеге – 4,6 метр,сын граниттан ясалган. Бу һәйкәлдә шагыйрь образы “Моабит дәфтәрләре”н кулына тотып, горур кыяфәттә тасвирлана (куш.6).

Соңгы елларда М. Җәлилгә Чиләбе (куш.7), Нижневартовск(куш.8), Казакъстанның Усть-Каменогорск (куш.9) шәһәрендә М.Җәлилгә һәйкәлләр куела[2]. Башлыча, рус халкы яшәгән шәһәрләрдә татар милләте вәкиле булган шәхесне зурлау – үзе бер горурлык! 2012нче елда Түбән Кама шәһәре кешеләре дә М.Җәлилгә куелган һәйкәл өчен куандылар. Бу һәйкәлнең үзенчәлекле тарихы турында алдагы бүлекләрдә сөйләнер.

Бүлеккә нәтиҗә. Тарих турында хатирәләрне ныгыта торган һәйкәлләр аша безнең чор кешеләре Җәлил батырлыгын буыннан-буынга тапшыра.

## Икенче бүлек

## М.Җәлил һәйкәленең рухи кыйммәте

### 2.1. Түбән Кама шәһәрендә куелган һәйкәлнең тарихы.

Түбән Кама шәһәрендә куелган М.Җәлил һәйкәленең еллар буена сузылган тарихы бар. Бу һәйкәлне булдыру өчен бик күпләр тырышты. Һәйкәл салу турындагы карар 70нче елларда ук кабул ителә. 1976нчы елда М.Җәлилнең 70 еллык юбилеена матур һәйкәл

булыр дигән изге ният туа. Ул чакта, Түбән Кама шәһәр идарәсе каршындагы бакчага бу проектны нигезләүче истәлек-таш та салалар.  Әмма, еллар үтү белән таш та, карар да онытыла. Шәһәребезнең милли тормышын сүндермәскә тырышып йөрүче  мөхтәрәм кешеләр әлеге мәсьәләне кат-кат күтәрәләр. Әмма эреле-ваклы түрәләр бу мәсьәләгә битараф булып кала баралар.

Һәйкәл төзелү эшенең икенче этабы 90нчы еллар ахырында башлана.  1996-2006 нчы елларда мәсьәлә кабат күтәрелә. Ул чакта безнең шәһәребездә эшләүче галим Азат Зыятдиновның сүзенә колак салып, хакимият вәкилләре әлеге идеяне яңадан күтәреп чыкты. Ике төрле вариант тәкъдим ителә. Беренче проектта җәлилчеләрне күмәк гәүдәләндергән гомуми образ тәкъдим ителә. Икенче вариантта гимнастерка кигән якты йөзле сугышчан-шагыйрь образы сынландырыла. Икенче вариант раслана.  Яңа һәйкәлнең проекты да эшләнә. Аның авторы фикеренчә, ул Түбән Камада яшәүчеләргә Муса Җәлилнең фашистлар төрмәсендә үткәргән еллары һәм шагыйрьнең батырларча  һәлак булуы хакында искәртеп торачак. Һәйкәл  Тынычлык проспектында урнашыр дип көтелә. Тынычлык проспекты  да һәйкәлле булуны озак көтә. Әмма бу эш чынга ашмый кала.

Шәһәрдәге җәмгыять оешмалары башлаган изге эшнең тәмамланмавына бик борчылалар. Инде саргая төшкән газета битләрендәге язмалар Җәлил һәйкәлен булдыру өчен көрәш сәхифәләренең бер мизгелен тасвирлаучы юлларга әйләнгәннәр. “Без – Түбән Кама аксакаллары уку йортларында уздырыла торган төрле чараларда катнашабыз, җәлилчеләрнең батырлыгы хакында да сөйлибез. Узган ел барлык уку йортларында аңа багышлап төрле чаралар уздырылды. Аерым алганда, 3нче, 8нче, 14нче мәктәпләрдә булган очрашулар вакытында укучылар еш кына: “Ни өчен шәһәребездә герой шагыйрьгә һәйкәл юк? – дигән сорау бирделәр. Без, билгеле, Җәлилгә инде бронза һәйкәл дә эшләнгән булуы, тиздән һәйкәлне куярга җыенулары, аның урыны да билгеле икәнлеге, хәтта җитәкчеләребезнең бу һәйкәлне шагыйрьнең 105 еллыгына куярга вәгъдә бирүләрен әйтеп, балаларны тынычландырдык. Тик әле 106 еллыгына да һәйкәл куя алганыбыз юк.” – дип борчыла С.Минһаҗев. – Соңгы вакытта матбугатта кайберәүләр, үзләренә дан казануны күздә тотып, каһарман җәлилчеләрнең данын юкка чыгарарга, кара тап ягып, ялган дәлилләр табып, аларның батырлыгын шик астына куярга тырышалар. Җитәкчеләребез дә, шулар шикелле, Җәлилнең батырлыгына шикләнмиләрдер бит? Ә без –аксакаллар шурасы әгъзалары һич тә алай уйламыйбыз. Шагыйрьнең тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнүнең, аның исемен мәңгеләштерү йөзеннән һәйкәл куюның балаларга патриотик тәрбия бирүдә роле бик зур. Шуңа күрә, җитәкчеләребез бу сүзләрне ишетерләр һәм ниһаять, һәйкәл булыр, дигән өметтә калабыз” – дигән сүзләрне җиткерә ул [3].

2006 нчы елдагы вакыйгалар, алда телгә алынган А.Зыятдинов йогынтысында нык алга китә. Шәһәребезнең “Нефтехим” җәмгыяте белән килешеп, берләшмә акчасына Җәлил сынын койдырталар. Инде сын әзер булгач та, куярга рөхсәт бирелми, еллар үтә. Бу хакта “Идел” журналы битләрендә языла: “Муса Җәлил һәйкәленең биш ел элек үк эшләнүен, әмма әлегәчә төрле сәбәпләр аркасында куела алмавын әйтте. Дәүләттән бер тиен акча сорамыйча булдырылган (бөтен чыгымнарны Түбән Кама “Нефтехим” ачык акционерлар җәмгыяте күтәрә) әзер һәйкәлнең (!) шулкадәр вакыт остаханәдә тузан җыеп ятуы чиксез гаҗәпләндергән иде. Ләкин Азат ага әңгәмәнең ахырына таба мине, шул исәптән, “Идел” укучыларын, гомумән, милли гаме исән һәр адәмне юаткандай итте: “Алла боерса, һәйкәлне ачу тантанасы быел, 25 августта – Җәлилчеләр көнендә булыр дип көтелә”.

Әмма, ни кызганыч, 2011 елның 25 августы башка елдагы бу көннән һичнинди аермасыз узып та китте...

– Юк, быел да куймадылар, – телефоннан сөйләшкәндә Азат аганың тавышы моңсу иде...

Мин исә, шундый зур урыннарда утырган һәм шундый күп исем-атлар иясе дә милли баганаларны ныгыту мәсьәләсендә көчсез икән, без фәкыйрьләргә – гади халыкка ни кала, дип уйга баттым...

Бер ел узды...” [6]. Бу көннәргә  бер ел узгач, 2012нче елның 25 августында Түбән Кама шәһәрендә Муса Җәлилгә һәйкәл куела. Вакыйга зур бәйрәм булып үтә. Милләтпәрвәр шәһәрдәшләребез ярдәме белән халык теләге җиңеп чыга. Һәйкәл Техниклар йорты янәшәсендә, Ял паркының матур бер җирендә урын алган. М.Җәлил һәйкәле шәһәребезнең затлы, эчтәлекле һәм кадерле бизәгенә әйләнде.

**2.2. М.Җәлил образын мәңгеләштерүнең идея-эстетик кыйммәте.**

М. Җәлил үзенең шигырендә  “Утта булган балчык кире купмас, Эштә булган тимер тутыкмас. Эш күрсәткән ирне ил онытмас, Каберенә эзне суытмас” –  дип язган. Үзенең язмышын алдан сизенгәнме, дигән сораулар туа күңелдә. Язмышыннан билгеле булганча, немец әсирлегенә эләккәч, Җәлил фашистларга каршы агитация алып бара. Аны үлем карарын көтү дә сындыра алмый: яшерен оешма фаш ителгәч, Җәлил көрәшен туктатмый, шигырьләре аша дәвам итә. “Исемем дә яңгырар җыр булып”, – бу юл Җәлилнең тоткынлыкта язган “Моабит дәфтәре”ннән. Аның исеме “Моабит дәфтәрләре” аша кайтып ирешкән җыр булып кына түгел, батырлык образы булып та яңгырады.

Һәйкәлләрдә образы мәңгеләштерелгән Муса Җәлил – ул чордагы совет солдатларының һәм барлык татар халкының батырлык үрнәге булып тора. Сугыш чоры, сугыштан соңгы авырлыкларны күрүчеләрнең саны сирәгәя. Батырлык, патриотизм төшенчәсен  безнең заман балаларына, киләчәк буынга аңлатырга таяныч булып та хезмәт

итәчәк М.Җәлил һәйкәле. Һәйкәлне булдырырга теләүчеләр менә шул максатларны күздә тотып тырышканнар. Ә М.Җәлил сынын иҗат итүче Рәис Сафин аны батырлык гәүдәләнеше, лирик-шагыйрь һәм мәшһүр татар егете образларын берләштереп иҗат иткән. Һәйкәлне ачу тантанасында А.Зыятдинов барлык шәһәрдәшләребез исеменнән зур эшне башкарган сынчы Рәис Сафинга, остаханә җитәкчесе, рәссам Марат Әфләтуновка, кою остасы Николай Расковалкинга чиксез рәхмәтләрен белдерде. Без, яшь түбәнкамалылар, М.Җәлил һәйкәлен булдырган өчен шәһәрдәшләребезгә зур рәхмәт әйтәбез. Җәлил исеме, батырлыгы, иҗаты онытылмас, буыннан-буынга тапшырылыр!

Һәйкәл янына җыелган олы буын вәкилләре сугышта һәлак булган әти-әниләрен, туганнарын искә алачаклар. Балалар бу һәйкәлдә кем сыны булуы белән кызыксыныр, алар өчен әлеге һәйкәл М.Җәлилнең иҗатын өйрәнергә зур этәргеч булып хезмәт итәчәк. Җәлил туган көндә, җәлилчеләрне искә алу көннәрендә, Җиңү бәйрәмендә һәйкәл янында кешеләр бик күп булдылар. Төрле чаралар үткәрелде. Димәк, һәйкәлнең идея-эстетик вазыйфасы патриотик тәрбия чарасы буларак та көчәя. Җәлил шигырьләре, аның батырлык чагылдыручы образы буыннан-буынга һәйкәлләр итеп тапшырырлык олы мирас!

Бүлеккә нәтиҗә. Түбән Кама халкы сөекле шагыйренең иҗатын, батырлыгын онытмады, киләчәк көннәрдә дә шәһәрдәшләребезнең онытмавын кайгыртып, шагыйрь истәлеген мәңгеләштерде. Башта ук ирешә алмаса да, түбәнкамалылар дистә еллар узгач, һәйкәлле булды.

## Йомгак

Түбән Кама шәһәрендә М.Җәлил һәйкәле тарихын өйрәнү максаты белән әзерләнгән фәнни эшкә герой-шагыйрь М.Җәлилнең иҗатын, тормыш юлын өйрәнү, куелган һәйкәлләрдә М.Җәлил образын күзәтү, Түбән Кама шәһәрендә куелган һәйкәлнең тарихын өйрәнү һәм рухи кыйммәтен ачыклау бурычлары билгеләнде. “Түбән Кама шәһәрендә М.Җәлил һәйкәле тарихы” темасына багышланган фәнни эшнең актуальлеге Җәлил иҗатындагы сугыш темасының бүгенге көндә дә аваздаш булуы белән аңлатылды. Кереш, ике бүлектән, төп өлеш һәм йомгак һәм кушымтадан торган эшкә тәбәндәге нәтиҗәләр ясалды:

1. М.Җәлил иҗатын сугыш темасы аша күзаллыйбыз. Шигырьләрен укып, сугышның нинди явыз афәт икәненә төшенәбез. Бүген дә, планетабызның әле бер, әле икенче җирләрендә сугыш уты кабына. Тарих турында хатирәләрне ныгыта торган һәйкәлләр аша безнең чор кешеләре Җәлил батырлыгын буыннан-буынга тапшыра. Казан, Оренбург, Санкт-Петербург, Чиләбе, Казакъстанның Усть-Каменогорск, Нижневартовск шәһәрләрендә М.Җәлилгә һәйкәлләр куелган. Мәскәүдә

Җәлил һәйкәле ике җирдә куелган. Муса Җәлил исеме, аның “Моабит дәфтәрләре” җыентыгы бар халык өчен батырлык, иҗатның сугышка каршы көч булуы символына әверелде. Җәлил шигырьләре, аның батырлык чагылдыручы образы – буыннан-буынга һәйкәлләр итеп тапшырырлык олы мирас.

2.Түбән Камада М.Җәлил һәйкәле булдыру тарихы 1976 нчы елдан башлана. Зур каршылыкларны җиңеп, милләтҗанлы шәһәрдәшләребез ярдәме белән халык һәйкәлле булуга ирешә. М.Җәлил һәйкәле Техниклар йорты янәшәсендә, Ял паркының матур бер җирендә урын алган.

3. М.Җәлил образын мәңгеләштерүнең идея-эстетик кыйммәте чиксез. Беренчедән, М.Җәлил – татар егете, милләтебез аның батырлыгына, гаҗәеп киңкырлы иҗатына соклана. Герой татар егете сынын мәңгеләштергән һәйкәлләрнең бөтен Россия буйлап урнашуы – татар кешеләре өчен олы горурлык.

Икенчедән, һәйкәлләрдә образы мәңгеләштерелгән Муса Җәлил – ул чордагы совет солдатларының һәм барлык татар халкының батырлык үрнәге. Сугыш чоры, сугыштан соңгы авырлыкларны күрүчеләрнең саны сирәгәя. Муса Җәлил истәлегенә куелган һәйкәл батырлык, патриотизм төшенчәсен безнең заман балаларына, киләчәк буынга аңлатырга таяныч булып та хезмәт итәчәк.

Өченчедән, шәһәребездәге һәйкәлнең идея-эстетик әчтәлегенә салынган тагын бер мөһим юнәлеш – аның рухи мирас булуы. Җәлил туган көндә, җәлилчеләрне искә алу көннәрендә, Җиңү бәйрәмендә һәйкәл янында төрле милләт вәкилләре җыела. Һәйкәлнең идея-эстетик вазыйфасы патриотик тәрбия чарасы буларак та көчәя. Биредә иҗади фикерләр дә, сугышка каршы булу, тынычлык яклау теләкләре дә яңгырый. Бүгенге көндә актуаль булган толерантлык тәрбиясен, сугышның куркыныч афәт икәнен үтемле итеп аңлату өчен иң кулай урын.

Сүзне йомгаклап әйткәндә, түбәнкамалылар өчен М.Җәлил һәйкәле – шәһәрнең затлы, эчтәлекле һәм кадерле бизәге һәм тирән эчтәлекле рухи мирасы.

**Әдәбият**


1. Әдипләребез: библиографик белешмәлек: 2 томда: 1 том / төз. Р. Н. Даутов, Р. Ф. Рахмани. – Казан : Тат.кит.нәшр.,2009. – 511-515 б.
2. Интернет-чыганак материаллары.
3. Минһаҗев, С. Җәлилгә кайчан һәйкәл булыр? / С. Минһаҗев. – “Туган як”, 14.02.2012.
4. Мостафин, Р. Ә. Тарихларда укып ятларлык. // Әсәрләр: 5т. / М. Җәлил. 1 Т. Шигырьләр; кереш сүз авт. Р. Ә. Мостафин. – Казан : Тат.кит.нәшр., 2006. – 10-42 б.
5. Муса Җәлил турында истәлекләр / Р. Ә. Мостафин. – Казан: Тат.кит.нәшр., 2006. – 319 б.

6. Мөхәммәтшин, Р. Бер Һәйкәл тарихы / Р. Мөхәммәтшин. - “Идел”, №11, 2012. – 29-31 б.

*Харисов Азат, 3 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының*
*«Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 27 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе»*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Гыймранова Илсөяр Гарәфетдин кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Дөньяны бары тик Тынычлык яшәтә, яшәртә!

### КЕРЕШ

Татар милләтенең йөзек кашы булган, бөек шагыйребез, безгә тыныч тормыш бүләк иткән батырыбыз, Муса Җәлил турында бөтен кеше дә белергә тиеш. М. Җәлил үзенең шигырьләре белән күп еллар кечкенә буынны тәрбияләүгә зур өлеш кертте. М. Җәлил кебек батыр язучылар һәм сугышта катнашкан ветераннарыбыз бармак белән генә санарлык калды, шуларны барлау максатыннан чыгып эшләнелде.Украинада барган сугышлар беркемне дә битараф калдырмый. Тынычлык бүгенге көндә иң кадерле әйберләрнең берсе булып тора. Шуңа күрә мин фәнни тикшеренү эшемнең **темасы** итеп : **“Дөньяны бары тик Тынычлык яшәтә, яшәртә!”-** дип алдым. Мин бу теманы **актуаль** дип саныйм. Беренчедән быел Бөек җиңүнең 80 еллыгын билгеләп үтәргә җыенабыз, икенчедән бүгенге тыныч тормышта да кайбер илләрдә канкойгыч сугышлар бара, өченчедән безгә бу матур тормышны бүләк итүче ветераннарыбызның батырлыкларын яшь буыга җиткерү, өлкән буын кешеләренә хөрмәт тәрбияләү. Балаларда Туган илгә мәхәббәт тәрбияләү, сугыш ветераннарыбызны онытмауларын күздә тотып эшләнде. Мин киләчәк буынга тарихыбызны, сугыш ветераннарын онытмаска, бүгенге тыныч тормышның нинди зур югалтулар барәбәренә булуын, киләчәктә мондый афәтләр кабатланмасын дигән максаттан чыгып эшләдем. Кинотеатрның яшьләр күңелендә “ кинотеатр Джалиль” булып, буш сүзләр булып кына калмавын, шәһәребездә һәйкәлләр барлыгын белеп үсүләрен эшемнең зур **проблемасы** итеп алдым.

**Фәнни тикшеренү эшемнең объекты:** Түбән Кама шәһәренең истәлекле урыннары, Ватан Сугышы ветераны, “Нефтехимик” эзтабарларының хезмәте.

**Фәнни тикшеренү эшемнең предметы:** шәһәрнең һәйкәле, кинотеатры, ветераннары.

**Максат:** Туган якка, халыкына сугыш китергән зыянны ачыклау.

**Бурычлар:**

- Һәйкәл, кинотеатрлар турында материал туплау.
- Бүгенге көндә безнең арада булган өлкән буын кешеләре яки сугыш ветераннары белән аралашып, сугыш турында чыганаклар җыю.
- Төрле китап, газетларда басылып чыкка мәкаләләрдән файдалану.
- Фотоматериаллар туплау.
- Туган илгә, туган җиргә мәхәббәт, патриотик хисләр тәрбияләү.

## 2.1. ШӘҺӘРЕБЕЗДӘ М.ҖӘЛИЛ БЕЛӘН БӘЙЛЕ БУЛГАН ИСТӘЛЕКЛЕ УРЫННАР

Мин Татарстанның иң гүзәл төбәгеннән - Түбән Кама шәһәреннән. Минем өчен туган җирем, гүзәл каламнан да кадерле, аннан да матур җир юктыр шикелле дөньяда. Шәһәрем буйлап ясаган экскурсияләрдә иң беренче булып 1нче номерлы гади генә бер мәктәп, ягъни гимназия булды. Килеп керү белән башка мәктәпләрдән әлләни аерылмый да кебек, укытучым сөйли башлагач төшендем, бу гади мәктәп кенә түгел, ул герой-шагыйрь Муса Җәлил исемен йөртә икән (кушымта №1, 1 нче рәсем). Мәктәп җыйнак кына, укучылар тәрбияле, әйтерсең, Җәлил “оныклары”.

Алдагы “танышыбыз” әле күптән түгел генә шәһәребездә калкып чыккан мәһабәт Муса Җәлил һәйкәле (кушымта №1, 2 нче рәсем). Күтәрелеп карау белән бу сында ниндидер моңсулык, йөзендә әйтерсең: “Эшләнеп бетмәгән эшләрем кала...”,- дигән, үкенүне күреп була. Ә менә башкалабыз Казан шәһәрендәге һәйкәл башкачарак (кушымта №1, 3 нче рәсем).

Анда ул, югарыга очар очен канатларын җайлап куйган бөркетне хәтерләтә. Ике кулы артка каерып бәйләнгән... Менә-менә җилкәләрен киереп, чылбырларны өзәр дә һавага күтәрелеп китәр кебек.

Ә алдагы сәяхәтебез шәһәребездә күптән эшләп килүче, Муса Җәлил исемен йөртүче “Җәлил” кинотеатры турында (кушымта №1, 4 нче рәсем). Анда күпләрнең, яше-картының рәхәтләнеп ял итү урыны.

Сугыш дип әйтүгә бөек шагыйребез, “чәчәк телле”, патриот-шагыйрь - Муса Җәлил күз алдына килеп баса. Кем генә булуына карамастан зур кешеме, кечкенә генә баламы бу изге, милләтебезнең йөзек кашы булган Җәлилебез, кыю сугышчыбызны белмәгән кеше юк. Һәр татар баласы аның шигырьләрен, җырларын, экиятләрен тыңлап үсә.

М.Җәлил, шундый вәхшәт эчендә үлемсез җырларын иҗат итеп, бер батырлык күрсәтсә, шул җырларны төрмәнең калын стеналары аша иреккә чыгара алуы белән икенче батырлык эшли. Бу үлемсез җырлар безгә Җәлилнең авазы булып кына түгел, фашистлар

җәзалаган миллионнарча корбаннарның, миллионнарча көрәшчеләрнең васиятләре булып килеп җитте.

Тирәнтен уйландыра, авыр уйларга чумдыра торган фаҗига бу. Күпме кешенең чәчәктәй гомерен өзде ул. Күпме гөнаһсыз кешенең каны дәрья урынына акты. Әле хәзер дә, ул еллардан соң 80 ел вакыт үтсә дә, фашизмга ләгънәт укыйлар. Ватан өчен барган изге көрәштә татар халкының күпме бөек улы башын салды. Күпме әсәрләр, шигырьләр, күңелләрдә туып та ак кәгазь битенә төшмичә, яралгы хәлендә югалды. Муса Җәлилнең дә нибары 94 шигыре генә бик бормалы юллар аша туган илгә кайтып җитә алды.

Үлем карары чыгарылгач та, шагыйрь күңелен төшерми, рухын сындырмый. Төрмәнең кысан, караңгы камерасында да аның өчен иҗат йолдызы балкый. Тоткынлыкта тимер чыбыклар белән уратып алынган төрмә камерасында да ул, җырчы сабан тургаедай, һаман биеккә тартыла.

## 2.2. ВЕТЕРАН БЕЛӘН ОЧРАШУ

Минем кечкенә генә булган шәһәремдә **ЗУР** батырлар яши икән бит. Үзе җыйнак кына, чәчләре инде күптән агарган шәһәрдәшем, безгә шушы матур көннәрне бүләк итүче, Гайфуллин Харис Гали улы белән күрешергә насыйп булды. Бабайны күрүгә “Әлдермештән Әлмәндәр”дәге чиста, саф күңелле, эчкерсез, батыр, нурлы йөзле кеше килеп басты алдыбызга. Ул - Ватан солдаты. Сугыш турында сөйләгәндә бабайның җиңелчә генә калтырануын, күзләрендә яшь бөртекләре җемелдәшүен һәм кечкенә бала башыдай йодрыкларының, нечкә иреннәренең тагын кысылганын күрдем. Күпме балаларның ятим, хатыннарны тол иткән “йөзе кара” сугышка чиксез нәфрәт билгесе итеп кабул иттем мин бу халәтне.

Сугыш башланган көннәрдә табигать ниндидер котылгысыз бәла килүен көткәндәй үлгән кебек тынып калды... Шәһәр, авыл урамнарында тәрбиячесез калган балалар төркемләп тә, ялгызлап та йөриләр. Алар үтеп баручыларга ябык кулларын сузып икмәк сорыйлар. Сугыш белән корылык китергән афәтнең иң куркынычы шушы иде, сезгә шуларны күрергә язмасын, - ди ул. (Кушымта №1, 5нче, 6 нчы рәсемнәр)

Авылдамы, шәһәрдәме, туган республикабыздамы, ватаныбызның башка төбәкләрендәме, чәчләренә чал кунган, маңгайларна тирән җыерчыклар сызылган могтәбәр ветераннар, икенче бөтендөнья сугышында җиңү яулаган каһарманнар белән очрашканда, күңелдә еш кына бер сорау туа. Шул сорау белән мин тагын Харис бабайга мөрәҗәгать иттем:

- Шундый югалтулар һәм батырлыклар бәрабәренә ирешкән җиңү көннәрендә җир йөзендә кайчан да булса тагын сугыш, кан кою булыр дип күз алдына китерә ала идегезме?, –дигән сорау бирдем.

-Юк! Кеше акылына килер, сугышлар турында уйлау түгел, ул сүзне бөтенләй онытыр кебек тоела иде, дип җавап бирде ветеран бабай. Әйе, кызганычка каршы кешелекнең сугыш дигән афәттән әлегәчә арына алганы юк. Гомер-гомергә аның бәгырен эзәрлекләп һәм телгәләп килгән сугыш шәүләсе әле булса Җир шары өстендә эленеп тора. Дөньяның әле бер, әле икенче почмагында шартлау авазлары гөрселди. Алай гына да түгел, кешелек һәм зәңгәр бишегебез алдында яшәргәме, әллә... юкка чыгарыргамы дигән сорау куелган. Американың котырынып кораллануы, яшәү, Бәхет һәм Гүзәллек дигән мәңгелек изге төшенчәләр белән хисаплашмыйча, коточкыч финалга ашкынуы бөтен прогрессив дөньяны сагаерга мәҗбүр итә. Бүгенге көндә дә Украина җире кан һәм күз яшьләре белән сугарылган. Ерткычларча җәзалаланган, меңнәрчә картларны, балаларны һәм ата-аналарны күргәч, Украинаның гүзәл шәһәрләре һәм авыллары урынына таш һәм күмер өемнәре генә калганын күргән саен, минем җаным тетрәп, йөрәкләрем боздай булып китә. Бүгенге көндә дә шушылар өчен кайгырып, кабат җир йөзендә сугышлар булмасын,- дигән сүзләрне һәрдаим безгә кабатлап торды.

Юк шул, сугыш аяусыз, сугыш – рәхимсез, шәфкатьсез! Күпме асыл ир-атларны үзенең комсыз тегермәненә салып тарттырган, күпме тол-ятимнәрне арттырган ул! Күпме карт-карчыкларны улларыннан, егетләрне сөекле кызларыннан аерган ул!

Ир туган илен онытмас,- ди халык.

Безнең татар халкы уллары да кабахәт дошманга каршы шулай ук батырларча һәм оста сугышканнар.

Шундый күренешләр белән очрашкан саен мин кабат дәхшәтле сугыш кырларын, анда ятып калган ябь-яшь ир-егетләрне күз алдына китерәм. Бүген менә шундый бәхетле, имин тормыш өчен, күгебез һәрвакыт аяз булсын өчен корбан булдылар бит алар. Яшь буын белеп торсын: бүгенге якты көннәрнең һәр иртәсе күп миллионлаган гомерләр хакына яулап алынды. Яу кырында һәлак булганнарга. Шул мәһшәрдән исән кайтканнарга, тылдагы “шинельсез солдатлар”га – тол хатыннарга, сугыш чоры балаларына карата битараф булуны, гаделсезлекне күтәрә алмыйм! - ди бабабыз.

Сугыш еллары һаман ераклаша бара. Җиңү бәйрәме көнне мәңгелек ут янына килүче ветераннар сафы да һаман сирәгәя. Алар белән бергә халкыбызның сугышчан батырлыгы да акрынлап тоныкланырмы. Юк, моңа юл куярга ярамый. Музейларга, һәйкәлләргә сукмак өзелмәсен. Һәйкәлләр, мәңгелек утлар янында чәчәкләр бетеп тормасын. Бу бүгенге яшьләргә өлкән буыннардан амәнәт!

СУГЫШ... Әмма... Сугыш сугыш инде ул! Берни белән дә хисаплашып тормый ул орыш, кан-яшь коеш...

Әйе...

Үлгәч кайтулар юк... Үлгәч, кеше, хәтерсезлек баткаклыгына суырылып, акрын гына онытылу томаннары арасында кала бара...

## 2.3 . СУГЫШ КАЙТАВАЗЫ...

Күп корбаннар китергән канкойгыч сугыш инде күптән тәмам. Еллар узган саен аның кайтавазы да ерагая кебек. Хәзер инде сугыштан кайтмый калган “хәбәрсез югалган”нарны көтүдә өмет тә юк. Сугыштан исән–имин әйләнеп кайтканнары да бик өлкән яшьтә һәм алары да язын сызып кына эрегән кар кебек, арабыздан китә баралар. Ә менә исемнәре билгеле булмыйча сөякләре төрле җирләрдә чәчелеп ятучы солдатлар әле һаман да бик күп. Энтузиастлардан төзелгән дистәләрчә эзтабарлар отрядлары аларны ачыклау белән шөгыльләнә. Шәһәребезнең “Нефтехимик” эзтабарлар отряды да (командиры Ольга Ланцова (Кушымта № 1, 7нче рәсем) бу изге эшкә зур өлеш кертә. Бөек Ватан сугышында һәлак булучы солдатларның һәм офицерларның сөякләрен һәм шәхси әйберләрен эзлиләр. Эзтабарлар отряды күп еллар рәттән һәлак булган сугышчыларның калдыкларын табу буенча Бөтенроссия төбәкара эзләү чараларында катнаша. Аларның даими бара торган урыннары — Ленинград һәм Смоленск өлкәләре.(Кушымта №1, 8 нче рәсем). Сугыш чорында, һәлак булган очракта исемнәрен ачыклау мөмкин булсын өчен, солдатлар үзләре турында кыскача мәгълүматлар язылган махсус капсулалар (солдат медальоннары) йөрткәннәр. Казу эшләрендә эзтабарлар әнә шундый медальоннарга тап булсалар, бик яхшы инде. Чөнки һәлак булган сугышчының исеме мәгълүм була. Шулар буенча аның туган-тумачасын да табарга мөмкин икән.

“Нефтехимик” эзтабарлар отряды, политехника колледжы, шәһәр музее һәм үзләренең “НКНХ” акционерлык җәмгыяте музейларын экспонатлар белән даими баетып торалар. Шул ук вакытта яшьләр арасында патриотик тәрбиягә зур әһәмият бирәләр, очрашуларда катнашалар.

«Сугышта үлгән бер генә солдатның булса да гәүдәсе җиргә иңдерелмәгән икән, сугыш беткән булып исәпләми», дип әйткән берәү. Әйе, сөякләре төрле җирләрдә чәчелеп ятучы, исемнәре билгесез солдатлар әлегә бик күп. Аларның каберләрен генә күреп булса да, күңелләрен юатырга теләүче туганнары, балалары, оныклары яши тирә-ягыбызда. Шуларның хәер–догаларын ишетмәгән килеш, илебез азатлыгын яклап гомерләрен биргән каһарманнарның рухлары тынычланырмы икән?...

## ЙОМГАКЛАУ

Эш барышында алдыма куйган **максат** һәм барлык **бурычлар** да чишелде. Мин фәнни-тикшерү эшем буенча әдәбият кулландым, ветераннар белән очраштым, М.Җәлил белән бәйле истәлекле урыннарда булдым, архив материаллар тупладым; массакүләм информация чараларын файдаландым; фотоматериаллар җыйдым һәм үземә шундый

нәтиҗә ясадым. Бүгенге көндә дә ветераннарның сугышчан батырлыклары яшь буынны тәрбияләүдә зур роль уйный, уйнаган һәм уйнаячак.

Эшемнең барышында **гипотеза** тулысы белән расланды. Шәһәребез яңарышлары белән яшь буынны таныштырып, тарихыбызны балаларга җиткерә алуыбызга бик шат.

Эшемне төгәлләп шуны әйтергә кирәк: бүген без яшь буынга ветераннарыбызга, өлкән буын кешеләренә иътибарлырак, итәгатьлерәк булырга тиеш. Шуңа күрә без үзебездән шундый **тәкъдим** кертәбез: Эзләнүләр нәтиҗәсендә тупланган хезмәтемне туган якны өйрәнүдә һәм әдәбият дәресләрендә тәрбия эшендә материал буларак кулланырга мөмкин.

**Библиография**


1. Җәлил, М. Шигырьләр. 1918-1941. – Казан : Тат. кит. нәшр.: 1975ел.
2. Мостафин, Р. “Җәлилчеләр. – Казан : Тат.кит.нәшр.: 1988 ел.
3. Мостафин, Ш. “Хәтер яктысы”. – Казан : Тат. кит. нәшр.: 2004 ел
4. “XX гасырның беренче яртысында дөнья.” 1918-1945. Профессор О. С. Сороко-Цюпа редакциясендә. – Казан : Тат. кит. нәшр.: 1996 ел.
5. “Каһарман каләме”. Бөек Ватан сугышында һәлак булган татар язучыларын иҗатыннан үрнәкләр. – Казан : Тат. кит. нәшр.: 2010 ел.
6. Шаһинур Мостафин. “Вәсият”. – Казан. – 1994ел.
7. Эзләнүләр, уйланулар, табышлар. – Казан : Тат. кит. нәшр.: 1989 ел.
8. Юнысов, Ә. Ә. “Солдат хәтере”. – Казан : Тат. кит.нәшр.: 1990 ел.
9. Зәйнуллин, З. “Ник ямансу бу көзләр?” – Казан : Тат. кит.нәшр.: 1998 ел.
10. Рәкыйпов, Ш. “Кызлар йолдызлар”. – Казан : Тат.кит.нәшр.: 2000 ел.
11. Имамов, Ф. “Югалган эзләр”. – Казан : “Ихлас”: 2012 ел.



*Шәфыйкова Динә, 6 нчы сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «62 нче аерым фәннәрне тирәтен өйрәтүче урта гомуми белем бирү мәктәбе»*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Вафина Альмира Мөхәмәтнәҗип кызы, туган тел һәм әдәбияты укытучысы*


## Хыялланырга да курыккан вакыйга: Муса Җәлил премиясе лауреаты – скрипкачы Динә Закирова

### Кереш

Быел халкыбызның горурлыгы – каһарман шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 119 ел! Ватаныбызның батыр һәм тугры солдатының исеме безнең илдә генә түгел, бар дөньяда

билгеле. Фашист коллыгына эләккәч тә рух ныклыгын саклап кала алган, дошманга каршы көрәшен дәвам иткән Җәлилнең якты исеме халык хәтерендә яши. Муса Җәлил – чын мәгънәсендә, каһарманлык билгесе, Ватанга чиксез тугрылык һәм мәхәббәт символы.

Шагыйрь һәм аның иҗаты, батырлыгы онытылмый. Илнең күп кенә шәһәрләрендә герой хөрмәтенә аталган урамнар бар. Бюстлар һәм мемориаль такталар, хәтта, башка илләрдә дә урнаштырылган.

Ә Татарстаныбызда Муса Җәлил исеме белән бәйле нинди истәлекләр бар соң? Әлбәттә, алар күп. Казаныбызда Муса Җәлил һәйкәле, Муса Җәлил музей-фатиры, Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры. Һәм шуларга өстәп республикабызда Муса Җәлил дәүләт премиясе дә бар. Премия турында тулырак мәгълүматны эшебезнең төп өлешендә бирәчәкбез.

**Эшебезнең актуальлеге**. Каһарман шагыйрь, халкыбыз улы Муса Җәлилнең исеме күңелләребездә мәңге саклана. Муса Җәлил премиясенә ия булучыларның исемнәрен белеп, ул премияне нинди хезмәте өчен алуларын ачыклап, без республикабызда яшәп иҗат итүче күп кенә данлыклы шәхесләребезне белә алачакбыз.

**Эшнең өйрәнелү объекты** булып музыка уен коралы – скрипка торачак. Шулай ук Татарстан Республикасының атказанган артисты, Муса Җәлил дәүләт премиясе лауреаты скрипкачы Закирова Динә Ильяс кызы булачак.

**Өйрәнелү дәрәҗәсе.** Муса Җәлил дәүләт премиясе лауреатлары турында күп мәгълүматлар табарга мөмкин. Тик аларның кайберләренең исемнәре халык арасында танылып өлгерә, ә кайберләре турында мәгълүмат җитәрлек дәрәҗәдә түгел. Без эшебездә скрипкачы Динә Закирова турында сөйләп, аны яшьтәшләрем арасында ныграк танытырмын дип ышанам.

**Эшнең максаты:** Муса Җәлил дәүләт премиясе лауреаты Закирова Динә Ильяс кызының тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнү. Динә апа турында күбрәк мәгълүмат туплау өчен, аның белән очрашып сөйләшү. Максатка ирешү өчен берничә **бурычны** аерып куйдык:

• Муса Җәлил дәүләт премиясе турында мәгълүмат бирү;

• Закирова Динә Ильяс кызы турында мәгълүматны мөмкин кадәр күбрәк туплау;

• Муса Җәлил дәүләт премиясенең скрипкачы тормышында мөһим роль уйнавын ачыклау;

• Динә апаның иҗатына мәхәббәт тәрбияләү.

**Тикшеренү эшенең яңалыгы.** Без радио һәм телевидениедән артистларның чыгышларын еш карыйбыз. Аларның концертларына йөрибез. Театрларда еш булабыз. Тик минем яшьтәшләрем татар артистларының күбесен белми, аларны танымый. Ә аларның

дәрәҗәле исемнәре турында сөйләп тә торасы түгел. Без бүген Динә апаның дәрәҗәле исемнәре турында сөйләрбез, безнең эшебезнең яңалыгы да шул булыр.

**Гипотеза.** Без Муса Җәлил дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган артисты Закирова Динә Ильяс кызының тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнеп, аның турында чыгыш ясап, конференциядә катнашучыларга аның исемен танытырбыз. Бүгенге чарадан алар, татар милләтен, татар телен саклап калуга үзенең зур өлешен керткән тагын бер шәхес турында күбрәк белеп китәрләр. Тикшеренү эше тасвирлау, чагыштыру, әңгәмә кору **методларына** таянып башкарылды.

**Хезмәтнең структурасы.** Эш кереш, төп өлеш, йомгак, кулланылган әдәбият исемлеге, кушымтадан тора.

## Беренче бүлек. Муса Җәлил исемендәге дәүләт премиясе

Муса Җәлил исемендәге республика премиясе – Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе бүләге иясе каһарман шагыйрь Муса Җәлил исемендәге дәүләт бүләге. 1968 нче елда нигезләнгән. 1991 нче елдан соң премияне тапшыру туктатылып торылган. 1997 нче елның 14 нче февраленнән премияне янәдән торгызу турында указга кул куела. Премия кабат 2002 нче елдан тапшырыла башлый.

Муса Җәлил исемендәге республика премиясе интеллектуаль һәм рухи куәтен үстерү максатында, сәләтле яшьләрнең әдәбият, сәнгать, фән, мәгариф, эшмәкәрлек өлкәсендәге уңышларын бәяләү өчен булдырылган.

Муса Җәлил исемендәге республика премиясе Габдулла Тукай премиясеннән кала, икенче дәрәҗәдәге дәүләт бүләге. Татарстан министрлар кабинеты карары белән рәсмиләштерелә.

М. Җәлил исемендәге республика премиясе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары нигезендә 2 елга бер тапкыр 4 премия бирелә. Лауреатларга исем, диплом, күкрәк тамгасы, акчалата бүләк тапшырыла. 1968-2007 нче еллар аралыгында акчалата премиянең күләме 40 мең, 2007 нче елдан соң 100 мең, ә 2015 нче елдан соң 200 мең.

Муса Җәлил исемендәге республика премиясе Муса Җәлилнең туган көнендә 15 нче февральдә тапшырыла. Бу премиягә 30 яшькә кадәр булган талантлы шәхесләр дәгъва итә ала.

## Икенче бүлек. Муса Җәлил премиясе лауреаты скрипкачы Динә Закирова

### 2.1. Динә Закированың тормыш юлы

Закирова (Гарифуллина) Динә Ильяс кызы 1986 нчы елның 19 нчы июлендә Чаллы шәһәрендә туа. Динә апаның әти-әнисе Татарстан Республикасының Мөслим районы Мөслим авылыннан. Гаилә корганнан соң, алар 1985 нче елда Чаллыга күчеп килгәннәр. Әтисе – Ильяс Рәмзи улы, һөнәре буенча сантехник, ә әнисе – Диләрә Закирҗан кызы, 13 нче татар сәнгать мәктәбендә балаларга баян дәресләре укыта. Динә апаның кыз

фамилиясе – Гарифуллина. Ул Чаллы шәһәренең 54 нче гимназиясендә белем ала. Әти-әнисе җырга, моңга гашыйк кешеләр булалар, шуңа күрә кызлары Динәне 5 яшендә музыка мәктәбенә укырга бирәләр. Кызчыкның әнисе баянда уйнаса да, хыялы скрипкада уйнау булган. Шунлыктан кызы Динәне скрипка классына биргән. Шулай итеп, Динә Закирова музыка мәктәбен, Чаллы музыка училищесын, аннан Казан дәүләт консерваториясен тәмамлап, әнисенең хыялын тормышка ашыра.

Кечкенә бала өчен музыка мәктәбендә уку җиңел генә бирелми. Динә апа мәктәпне ташлап, ярты ел чамасы мәктәпкә йөрми. Тик әнисенең үз сүзендә нык торуы белән, үгет-нәсихәте белән яңа уку елында кабат музыка мәктәбенә әйләнеп кайта. “Әти-әниемә гомерем буе рәхмәтлемен, - ди ул. Бала музыка мәктәбендә укыймы, өстәмә белем бирү учреждениесендә шөгыльләнәме, ата-ана баласына карата таләпчән булырга тиеш. Мин әти-әниемнең ярдәме, вакытында ныклы карар кабул итүе нәтиҗәсендә бүгенге һөнәремне сайладым. Хәзер мин тормышымны скрипкасыз күз алдына да китерә алмыйм. Өйдән кулыма скрипка тотып чыгып китмәсәм, мин үземдә ниндидер бушлык хис итәм”.

Динә апалар гаиләдә ике бала. Аның Илшат исемле энесе бар. Бала вакытта җәйге каникулларны авылда әби-бабай янында үткәрергә ятратканнар. Авыл балалары белән төрле кызык уеннар уйнаганнар. Күңелендә авыр хатирә булып калган бер вакыйганы Динә апа сөйләмичә булдыра алмады. “Миңа 10-11 яшьләр тирәсе булгандыр, биш-алты бала карьерга комлыкта уйнарга киттек. Безнең белән биш яшьлек кызчык та бар иде. Арабызда иң кечкенәсе. Комлыкта рәхәтләнеп уйныйбыз, көлешәбез. Бервакыт нәрсәдер җимерелгән кебек тавыш килде. Ком ишелгән, ә аның өсте каты кызыл балчыклы. Ә яныбызда теге биш яшьлек кечкенә кыз юк. Иптәшләребез белән ком арасыннан кызны казып чыгардык, тик ул яшәрлек түгел иде инде, - дип искә алды Динә апа, бу күңелсез вакыйга турында. Шул көннән комлы җирләрне яратмыйм, ә бу урыннан узганда күңелдә хатирә кабат яңара”.

Тормыш иптәше Илнур Закиров, Галиәсгар Камал театры артисты. Алар ярты ел очрашып йөргәннән соң өйләнешәләр. Илнур абый турында Динә апа болай диде: “Илнур – тыйнак, җитди, җаваплы, ышанычлы кеше. Биш вакыт намаз укый. Гаиләдә 4 баланы әниләре бер ялгызы тәрбияләп үстергән, барысына да югары белем биргән”. Динә апа белән Илнур абыйның уртак җимешләре – кызлары Зәлия 2014 нче елда дөньяга килә. Хәзер ул 5нче сыйныфта укый.

Тормышында зур югалтулары да күп була Динә Закированың. 2018 нче елда 54 яшендә каты авырудан соң иң якын кешесе – әнисе бакыйлыкка күчә. Әнисен югалтуны бик авыр кичерә Динә апа. Әле безнең белән аралашып сөйләшеп утырганда да, аның күзләреннән мөлдерәп яшь тама. “Бүгенгедәй истә: әнине җирләп кайтканнан соң, бүлмәгә кереп утырдым да бер ноктага карап каттым. Әни юк, дип уйлап кына куйдым, каршымдагы гөлнең яфрагы

каты итеп селкенеп куйды. Әйтерсең лә, әни “мин монда бит” диде. Әни һәрвакыт янымда кебек. Сөенечләремне дә, көенечләремне дә гел әнием белән уртаклашам”.

Закировлар гаиләсе Казан шәһәрендә яши. Узган ел алар яңа фатирга күчтеләр.

## 2.2. Динә Закированың иҗаты

Динә Закирова консерваториядә укыганда ук, 2008 нче елдан Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында эшли. “Кечкенәдән театрга гашыйк кешенең мәшһүр театрга эшкә урнашуы үзе бер могҗиза”, - ди Динә Ильяс кызы. Театрда аны Татарстанның халык артисты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Фоат Әбүбәкеров үз канаты астына ала, оркестрда уйнау тәҗрибәсен өйрәтә. Һәрдаим киңәшләрен биреп тора. Бүгенге көндә Динә Закирова шушы театрда эшләвен дәвам итә. Театрга килгән тамашачыны Динә апа фойеда скрипка уйнап каршы ала. Аның скрипкасыннан моңлы татар көйләре агыла.

2009-2011 нче еллар аралыгында Динә Закирова җырчы Айдар Фәйзерахманов җитәкчелегендәге татар дәүләт фольклор ансамблендә эшли. “Айдар абый бик таләпчән, акыллы җитәкче. Аның кушканнарын гел үтисе генә килеп тора”, - ди Динә Закирова. Укып эшләү Динә апага вакытны дөрес һәм нәтиҗәле бүләргә өйрәтә. Иртән репетициягә бара, көндез укый, кичен театрда спектакльдә...

Динә Закирова – “Алканат” рок төркеменең солисты да була. Шулай ук “Җырлыйк әле” телевизион тапшыруында эшли: скрипкада уйный. Бу тапшыруга эләгүем, Аллаһы Тәгалә бүләге, - ди Динә апа. Тапшыруда үз эшләренең осталары тупланган. Тапшыруны халык яратып карый. Минем әби белән бабам да тапшыруны көтеп ала иделәр. Мин дә әнием белән тапшыруны карарга яратам. Бүгенгесе көндә Закировлар “Җырлыйк әле” тапшыруының алып баручылары.

Динә Закирова берничә җирдә эшләве өстенә бик тәмле итеп ашарга да пешерә, буш вакытында түбәтәй, калфакларны үзе тегә һәм сәйлән белән чигә, ташлар белән бизи. Бу эшләр аңа сәхнә образын тулыландыру өчен кирәк. Үзенә сәхнәдә ни кирәк, барысын да үзенчә эшли.

Динә Закирова 2007 нче елда “Минута славы” тапшыруында, 2011 нче елда Культура каналында “Шабловка 37” тапшыруында, 2023 нче елның март аенда Останкино беренче каналында була торган “Могҗизалар кырында” катнаша. “Кечкенәдән минем хыялым әтием белән шушы тапшыруга барып, барабан кырында шигырь сөйләү иде, - ди Динә апа. Хыялым чынга ашты, тик урыннар гын башкача. Мин барабан артында уенчы, ә кызым Зәлия шигырь сөйләүче”. Тапшыруга ул әтисе һәм кызы белән барган. Һәр сөйләгән сүзе йөрәккә май кебек. Мин дә бу тапшыруны зәңгәр экран аша карадым.

**2.3. Динә Закирова – Муса Җәлил дәүләт премиясе лауреаты**

2021 нче елның 15 нче февралендә Галиәсгар Камал театры музыканты Динә Закировага һәм Галиәсгар Камал театры артисты Илнур Закировка татар телен һәм мәдәниятен саклау, үстерү һәм популярлаштырганнары өчен Муса Җәлил исемендәге дәүләт премиясе тапшырыла.

«Аудиофлешка форматында балалар өчен татар халык әкиятләрен иҗат иттек. Халкыбызга хезмәт итә алуыбыз белән без бик бәхетле. Әлеге бәяләү безнең өчен зур дәрәҗә. Мин үзем скрипкасыз беренче тапкыр сәхнәгә чыгам. Бу минем өчен аеруча дулкынландыргыч мизгел. Оештыручыларга, безне тәкъдим иткән җитәкчеләребезгә зур рәхмәт әйтәсем килә», — диде Динә Закирова.

Проектта Илнур Закиров диктор буларак хезмәт күрсәткән булса, Динә Закирова музыкаль бизәлешен тулысынча эшләгән, уен коралларында да үзе уйнаган.

«Дәүләт премиясен алу дулкынландыргыч мизгел. Үзебезнең эшебезне күрсәтә алганбыз икән, мин бик шат. Динә белән бергәләп татар халык әкиятләрен аудиоформатта эшлибез. Бу проект бүгенге көндә дә дәвам итә», - диде Илнур Закиров.

Скрипкачы Динә Закирова әйтүенчә, эшнең матди ягын уйламаганда гына уңышка ирешеп була: – Бу – хыялланырга да курыккан вакыйга минем тормышымда. Горурлык ташып тора, болай сөенгәнем юк иде әле минем. Әкиятләргә килгәндә, үзем – әкият тыңлап, әкият укып тәрбияләнгән бала. Әкиятнең көче, фантазияне арттыруда роле әйтеп бетергесез аның. Әкиятләр җыр-моң белән үрелеп барды, без аны татар халык музыкасы, үзебезгә хас уен кораллары белән баеттык. Бу эшләр ниндидер материаль максатларны күздә тотып эшләнмәде, безнең максат телне саклауга өлешебезне кертү иде. Әкиятләрне мирас буларак балаларга тапшырырга кирәк. Шуңа әкиятләрне аудиовариантта эшләдек һәм шушы юнәлештә эшне дәвам иттерәбез. Бу зур проект буларак планлаштырыла, аңа шигырьләр дә кирәчәк. Хәзерге вазгыятьтә бу – бик кирәк эш дип саныйм.

Безнең Динә апа белән сөйләшүгә тормыш иптәше Камал театры артисты Илнур абый Закиров та кушылды. Ул премия турында гына түгел, Җәлил шәхесе, аның батырлыгын турында болай диде: – Бәлки ул премияне алу хыялда булгандыр да, ләкин эшебезне андый максат куеп эшләмәдек. Ә премиягә тәкъдим ителгән эш ике ел элек Мәскәүдә башланып киткән иде. Без гастрольдә идек, Камал театры директоры Илфир Якупов шунда таушалып беткән русча әкиятләр җыентыгын күрсәтте. Баксаң, әлеге җыентыктагы әкиятләр бер җирдә дә татарча басылмаган булган. Мин аларны татарчага тәрҗемә итә башладым. Әлеге басма мине бик тә әсәрендерде, чөнки кайберләрендә 1800 елны, фәлән авылда яшәгән кешедән язып алынган, дигән мәгълүматлар бар иде. Димәк, бу – хәтерне саклау да бит әле. Премия – зур дәрәҗә дә, бәлки Аллаһы Тәгаләнең зур

сынавыдыр да. Бүләкләр кайчак кешене үсендерә, ә кайвакыт кирәкмәгән сыйфатларның калкып чыгуына китерергә дә мөмкин. Премиянең Җәлил исемен йөртүе турында да уйланам. Яшерен-батырын түгел, без шәхесләрне туган һәм вафат булган көннәрендә искә алабыз, һәйкәлләренә чәчәк салабыз да аннары көндәлек мәшәкатьләр белән яши башлыйбыз. Җәлилне дә 15 февральдә генә искә алабыз кебек. Шулай да быел искә алу чараларында мәктәп балаларының күплеге сөендерде һәм өмет уятты. Җәлил батырлыгын аңлыйлар, кызыксыналар, кабул итәләр дигән фикер ныгыганнан-ныгый миндә. Татар үз батырларын онытмас дип уйлыйм. Дөньябыз тыныч булсын дип телисе кала.

2024 нче елның 25 нче гыйнварында Закирова Динә Ильяс кызына “Татарстанның атказанган артисты” исемен тапшырдылар. - Татарстан Республикасы Мәдәният министырлыгының беренче коллегиясендә миңа зур дәүләт бүләгенең медале белән таныклыгын тапшырдылар! Татар тотып карамыйча ышанмый диләр бит әле. Бүгенге көннән мин үземнең чын "Атказанган артист" булуыма ышана башладым! Әти-әниемә, укытучыларыма, сөекле ирем белән алтын кызыма, коллегаларыма, җитәкчеләремә, минем өчен сөенүче тамашачыма чиксез зур рәхмәтлемен, - диде Динә Закирова.

**Өченче бүлек. Закирова Динә Ильяс кызы һәм Шәфыйкова Динә Альберт кызы**

“Тарих битләрен барлаганда” юнәлешендәге эшебездә Динә апа Закирова турында язуыбыз һәм бу теманы сайлавыбыз очраклы гына түгел. Чөнки мин дә нәкъ Динә апа кебек, 5 яшемдә музыка мәктәбенә йөри башладым. Ике ел әзерлек классларына йөрдем, ә беренче класска ике мәктәпкә берьюлы бардым. Үземнең теләгем буенча мине скрипка классына алдылар. Шулай итеп, минем скрипкада шөгыльләнүемә алты ел була. Скрипкада шөгыльләнү, чыннан да, җиңел түгел. Мәктәпкә барасы килмәгән, скрипканы кулга аласы килмәгән вакытлар да була. Тик әти-әнием әйтте: “Башлаган эшеңне ахырга кадәр җиткер. Скрипкага үз теләгең белән килдең. Димәк, укып бетерергә кирәк”.

Әнием кечкенәдән мине татар концертларына, татарча спектакльләргә йөртте. Галиәсгар Камал театрында бик еш фойеда Динә Закированың скрипкада уйнаганын күрә идем. Бәлки, скрипка музыка уен коралын сайлауга нәкъ менә Динә апа этәргеч булгандыр да.

Закирова Динә Ильяс кызы белән якыннан танышып аралашуыбызга дүрт ел була. Узган уку елында Динә апа безнең мәктәпкә очрашуга килде. Үзенең яраткан көйләрен уйнады. Бигрәк тә әниләргә багышланган көйләрне уйнарга яратуын әйтте. Динә ападан һәрвакыт җылы нур бөркелеп торды. Ягымлы итеп сөйләшә, олыны олы, кечене кече итә белә. Аңа карап, аны гел тыңлыйсы гына килеп тора. Җылы очрашу бик тиз тәмамланган кебек булды.

Ә хәзер Муса Җәлил иҗатына багышланган Форумда катнашабыз, Сезнең турыда язасыбыз килә дигәч, Динә апа безнең белән очрашуга бик теләп ризалашты. Үзе турында күп сөйләде. Дусты скрипкада матур көйләрен яңгыратты.

Закирова Динә Ильяс кызы – танылган скрипкачы, Татарстанның атказанган артисты, Муса Җәлил исемендәге дәүләт премиясе иясе. Ә Шәфыйкова Динә Альберт кызы – 6 нчы сыйныф укучысы, киләчәктә скрипкачы булу өчен тырышып укучы кыз. Әйе, бу лаеклы исемнәргә ия булу өчен бик күп тырышлык куярга кирәк әле.

## Йомгак

Скрипка иң катлаулы музыка уен коралларының берсе. Скрипка – музыка патшабикәсе. Скрипка музыка уен коралында уйнау өчен күп сабырлык, тырышлык, түземлек кирәк. Закирова Динә Ильяс кызы бу сыйфатларның барысын да үзенә туплаган иҗат кешесе. Лаеклы исемнәргә ия булу өчен нәкъ менә шушы сыйфатлар кирәктер дә инде, минемчә.

Ә инде миңа килгәндә, музыка мәктәбенә йөрү миңа көн тәртибемне нәтиҗәле бүләргә ярдәм итә. Мин үз алдыма максат куям: мәктәптә дә тырышып укырга һәм музыка мәктәбенә дә өлгерергә. Әлегә куйган максатыма ирешәм. “5” ле билгеләренә генә укыйм, төрле мәктәп чараларында катнашам, конкурс-конференцияләргә йөрим. Музыка мәктәбендә дә уңышларым шатланырлык. Халыкара күпжанрлы сәнгать бәйгесендә 1 нче дәрәҗәдәге диплом белән бүләкләндем. Шулай ук Халыкара фестивальдә 2 нче дәрәҗә дипломга лаек булдым.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә кирәк, күп тырышлык куйганда гына югары үрләр яуларга, иҗади уңышларга ирешергә була. Ә татар халкының Динә Закирова кебек халык өчен җан атып, халык көйләрен күңелгә үтеп керерлек итеп скрипкада уйнаучысы бар икән, димәк, татар җырлары, татар көйләре яшәячәк.

Гипотезабыз тулысы белән акланды. Без Муса Җәлил дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган артисты Закирова Динә Ильяс кызын конференциядә катнашучыларга таныттык. Бүгенге чарадан алар, татар милләтен, татар телен саклап калуга үзенең зур өлешен керткән тагын бер шәхес турында белделәр.

## Кулланылган әдәбият


1. Бүген герой-шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 118 ел // Сабантуй. – 2024. – февраль (№2)
2. Бүген каһарман язучы Муса Җәлилнең тууына 118 ел /Салават күпере. – 2024. – март(№3)
3. Гыймадова, Г. Җәлил премиясе ни дәрәҗәдә популяр? // Ватаным Татарстан. – 2021. – февраль саны
4. Закирова Динә Ильяс кызы белән әңгәмә. – 2024
5. URL : https://tnv.ru/tat/news/mednet/369459-din-zakirovaga-tatarstanny-atkazangan-artisty-medalen-tapshyrdylar/
6. URL : https://kamalteatr.ru/about-the-theatre/media/din-zakirova-m-r-st-m-siraev-atkazangan-artistlar/

7. URL : https://kamalteatr.ru/tat/about-the-theatre/media/kamallylar-musa-lil-premiyase-laureatlary/

**Тарих битләрен барлаганда. Халкымның гореф-гадәтләре.**

*Байгузина Айзилә һәм Инзилә, 6 нчы сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «37 нче күп профильле лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләре: Усманова Рузилә Рәшит кызы,*
*Хәнәфиева Ләйсән Фәйзехан кызы,*
*туган тел һәм әдәбияты укытучылары*

## Курай моңы – халкым бизәге

### Кереш

Татар-башкорт халкының милли музыка кораллары арасында иң данлыклысы – курай. Бу музыка коралы тугандаш халыкларның рухи мәдәнияте, мең еллар дәвамында килгән бай тарихы белән тыгыз бәйләнгән. Нәкъ курай моңына туган якның бик кадерле тавышлары сеңгән: бу иртәнге чык чыңы, агач яфракларының серләшүе, үзенә юл ярып агучы чишмә челтерәве …

Без инде берничә ел лицеебызда оештырылган “Курайда уйнарга өйрәнәбез” түгәрәгенә йөрибез. Курай, аның тарихы, файдасы турында күбрәк беләсебез килде һәм без укытучыларыбыз ярдәме белән бу эзләнү-тикшеренү эшен башлап җибәрдек.

**Эшнең максаты:** курайның барлыкка килү тарихын һәм аның кешенең тормышындагы ролен өйрәнү.

**Бурыч:**

- әдәби чыганаклар белән танышу;
- курайның килеп чыгышы һәм мәгънәсе турында олылар белән сөйләшү;
- үз халкының тарихын һәм мәдәниятен белү яхшырак.

**Гипотеза:** курайның барлыкка килү тарихын һәм әһәмиятен өйрәнгәч, мин үз халкымның мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен яхшырак беләчәкмен.

**Объект:** курай музыка коралы.

Һәр кеше үзенең бөек Ватаны, туган ягы белән горурланырга, үз халкының үткәнен һәм бүгенгесен белергә тиеш дип уйлыйбыз. Шуңа да бу эшебезне өйрәнү безгә бик ошады.

### Нәрсә ул курай?

Курайның килеп чыгышы турында риваять яши. Аның буенча, бер явыз ханының башында мөгез үскән булган. Ул яшь егетләрне чәчен кисәргә чакыра торган була һәм алар ханның бу серен белгәч, үлем җәзасына хөкем ителгәннәр. Бер егет качып китә. Таулар аша

качып барганда, ул үләннәр тавышы ишетеп ала. Бер камышны кисеп ала да, анда тишемнәр ясап, көй уйнап җибәрә. Курай моңы аша явыз ханның серен тарата.

«КУРАЙ» атамасының килеп чыгышы төгәл ачыкланмаган. Бу сүз борынгы төрки сүз. Элек эре зонтик сыман үсемлекләрнең сабагын "кура" дип йөрткәннәр, "най" - тростник, флейта дигәнне аңлаткан. Бәлки, курай сүзе шул сүзләренең кушылуы нәтиҗәсендә барлыкка килгәндер. "Кура" дигән көпшә үсемлекне элекеге заманнардан ук белгәннәр. Аны август аеның ахырларында үткен пәке белән кисеп алып, яфраклы ботакларыннан арындырганнар һәм йортның коры җирендә, түшәм астында киштәдә язга кадәр киптергәннәр. Шул көпшәдән курай ясап җыеннарда, сабантуйларда, мәҗлесләрдә, аулак өйләрдә уйнаганнар. Ә көтүчеләр җәен табигать кочагында, болыннарда көтү көткәндә курай уйнаганнар.

Курайны куллар белән үлчәп ясаганнар. Кулны 8-10 тапкыр куеп, көпшәне үлчәгәннәр, аннары кисеп алганнар. Курайның алгы ягында 4 тишеме һәм арткы ягында бер тишеме булган. Тишекләр түбәннән башлап ясалган: беренчесе 4 бармак ераклыкта, алдагы өчесе 2 бармак ераклыкта, соңгы бишенчесе аскы якта, дүртенче тишектән 3 бармак ераклыкта. Татар кураенда җиде уйнау тишеме бар: алтысы – өстә, берсе аскы якта урнашкан, шуңа күрә курайда җиде ноталы теләгән һәр көйне уйнарга мөмкин.

Болыннарда үскән курадан ясалган курай тиз ярылып яки сынып китә торган булган. Шуңа күрә, кешеләр тора-бара, аны иске җиз ләгән яки чиләк калаеннан ясау ысулын тапканнар. Вакыт узу белән курайны металл һәм пластмасс трубкалардан да ясый башлаганнар.

Хәзерге практикада әлеге музыка коралының шактый күп төрләрен очратырга мөмкин, аларның һәрберсе конструкция һәм функциональ характеристикалары белән аерылып тора. Курайның озынлыгы төренә карап 120-180 мм-дан 450-1000 мм га кадәр. Музыкаль диапозоны якынча өч октава.

*Көпшә.* Ачык типтагы озынча флейта, аның аерым бер үзенчәлеге булып 2 тишем булуы тора, аларның һәрберсе музыкаль эшләнмәнең алгы өлешендә урнашкан.

*Агач.* Чикләвек, балан яки өрәнге кебек югары сыйфатлы һәм нык агач токымнардан ясала. Үзенчәлеге булып тишемнәренең вариативлыгы тора: 4-6 тирәсе. Озынлыгы өстәмә конструкция элементларына бәйле рәвештә 25тән 30 см кадәр үзгәрә.

*Бакыр.* Сыбызгы музыка коралы. Бу конструкцияне ясау өчен гадәттә алюминий, бакыр яки көмеш эретмәләре кулланыла. Типның уртача диаметры 23-25 мм тәшкил итә, шул ук вакытта эшләнмәнең озынлыгы 26-27 см була, җиде тишектән тора.

*Казан.* Озын музыка коралы, аның аерым үзенчәлеге булып конус формасында булуы тора. Курайның гомуми озынлыгы 56-80 см, Шул ук вакытта тишекләр саны 2, 5, 6 яки 7 булырга мөмкин.

*Нугай курае*. Бу музыка коралының шактый популяр төре. Ул кул озынлыгында була, бармак киңлеге белән үлчәп ике тишек ясыйлар. Нугай кураенда тавыш формалашуда тел катнаша, Гадәттә, мондый курайда хатын-кызлар уйный.

Соңгы елларда курай халкыбызда яңадан зур кызыксыну уятты. Ул хәзер кара мунчаларда түгел, зур сәхнәләрдә яңгырый, музыкантларыбыз милли оркестрга кушылып моңлы көйләрен суза.

Хәзерге курайның прообразы нәрсә булганлыгы төгәл генә билгеле түгел. Озын буйлы, ачык флейта кебек уен кораллары дөньяның күп кенә культураларына хас. Археологик казу материаллары һәм язма чыганаклар мондый төрдәге музыка коралларының борынгылыгын раслый. Мәсәлән, безнең эрага кадәр 11 гасырга караган тишексез ачык флейта Такталачук археология комплексын (Татарстан) казу вакытында табылган. Бишунгар каберлегендә (Башкортостан) безнең эрага кадәр 4-11 гасырларга караган унбер тишекле сөяк флейта табылган. Филадельфия университеты музеенда курайдагы кебек үк тишекләр саны булган көмеш флейта саклана.

**Курайга “туган” уен кораллары**

***Свирель*** тынлы уен коралы, флейтаның бер төре. Агачның өске очында сызгырту җайланмасы. Йомшак эчле агачтан, талдан, шомырттан ясала. Россиягә свирель борынгы Грециядән килгән. Антик заманнарда свирель бер-берсе белән бәйләнгән төрле озынлыктагы җиде камыш торбадан торган музыка коралы булган. Борынгы грек мифологиясе буенча аны Гермес сыерлар көткәндә вакыт уздыру һәм күңел ачу өчен уйлап тапкан. Бу музыка коралын хәзер дә Греция көтүчеләре ярата.

***Сыбызгы*** (каз. Сыбызғы) - казах тынлы уен коралы, традицион рәвештә камыштан яки агачтан, соңрак һәм сирәгрәк көмештән ясалган. Ул XVIII гасырга кадәр Казахстан территориясендә иң киң таралган музыка коралларының берсе булган. Бу уен коралы казахларда күп кенә риваятьләрдә очрый. Казахстан территориясендә ике төрле сыбызгы бар. Көнчыгыш сыбызгысы конус формасында, озынлыгы буенча кыскарак һәм диаметры буенча кечкенә формада, көнбатыш төре зуррак һәм озынрак. Евразия халыкларында сыбызгы төрле исемнәр астында кулланыла: венгрларда, молдаваннарда һәм болгарларда ***кавал,*** башкортларда ***хыбызгы***, төркмәннәрдә ***гаргы тюйдук***, монголларда ***цоор,*** алтайларда ***шоор***, кыргызларда чоор һәм башка күп кенә халыкларда бар.

***Саламури*** грузин флейтасы. Грузиянең иң киң таралган, көтүчеләр кулланган, музыкаль уен коралларының берсе. Камыштан ясала, озынлыгы 240-390 мм.

## Психологик яктан курайның файдасы

Бүгенге көндә тикшерүчеләр төрле музыкаль тавышларның кеше организмының эмоциональ һәм физик халәтенә тәэсирен актив өйрәнәләр. Музыканың сихри үзлекләре инде күптән кинода, рекламада һәм терапия сеансларында киң кулланыла. Кешеләргә музыкага турыдан-туры тәэсир итә.

Хәзерге вакытта беркем дә музыканың кешенең үз-үзен тотышына һәм эмоцияләренә иң актив йогынты ясау сәләтен шик астына алмый. Музыка дулкынландыра һәм тынычландыра, агрессияне киметә һәм авыруны юата, билгеле бер истәлекләр тудыра һәм кайбер кирәкмәгән информацияне онытырга ярдәм итә.

Курайда уйнау уңай халәт тудыра, кәефне яхшырта. Курайда уйнарга өйрәнүче балалар тыныч холыклы булалар. Кеше музыка коралында уйнаудан эстетик рәхәтлек ала. Курай кешенең рухи халәте өчен дәвалау үзлекләренә ия.

Музыканың кешеләрнең кәефенә һәм иминлегенә ничек тәэсир иткәнен аңлар өчен, без тикшерүләр үткәрдек. Моның өчен без сыйныфташларыбыз белән тест ясадык. Без үзебезнең эмоциональ халәтебезне курайны тыңлаганчы һәм аннан соң 5 баллы шкала буенча бәяләдек. Нәтиҗәләрне карап һәм бәяләп, без сыйныфташларыбызның гомуми хәле яхшырды, кәефләре күтәрелде дигән нәтиҗәгә килдек.

## Курайда уйнауның сулыш органнары параметрларына йогынтысы

Курайда уйнау эстетик тәрбия биреп кенә калмый, ә сулыш мускулатурасының көче һәм чыдамлыгы да үстерә. Өстәвенә, курайда уйнаучылар тәмәке тартмый, актив тормыш рәвеше алып бара. Курайчылар арасында озак гомерлеләр күп.

Курайда уйнау процессында нинди органнар катнаша, бала уйнаганда нәрсәләр кичерә соң? Галимнәр билгеләгәнчә, курай кулларның вак моторикасын үстерүгә, сулыш системасы үсешенә йогынты ясый, кәефне күтәрә. Кул моторикасын үстерү, бармак үсеше бала өчен бик мөһим. Катлаулы музыкаль әсәрләрне, бигрәк тә халык әсәрләрен башкару курайчыдан сыгылмалылык, кул бармакларының тизлеген таләп итә. Бу вакыт узу белән, даими күнегүләрдән соң килә.

Курайда уйнау - кешенең сулыш системасы өчен бик файдалы. Бу яктан курай дәресләре зур кызыксыну уята. Курайда уйнарга өйрәнү барышында сулыш органнары ныгый. Курайда уйнаганда сулыш алуның төрле төрләре кулланыла: кыска сулыш, ашказаны сулышы, кабырга аша сулау. Курайда уйнау дөрес сулыш алуны үстерүгә һәм үпкәләрнең сулыш алу күләмен арттыруга ярдәм итә, бу очракта үпкәләрнең түбән өлешләре эшкә җәлеп ителә.

Гомумән алганда, курайда уйнау - үпкәләрдә генә түгел, ә бөтен организмда, бигрәк тә баш миендә кан әйләнешен яхшырта, организмны сәламәтләндерә, хәтерне үстерә.

Курайда уйнаганда шәхси гигиена кагыйдәләрен да саклау бик мөһим. Атнага бер тапкыр курайны медицина спирты белән сөртеп алырга кирәк, тешләрне һәм авыз куышлыгын җентекләп чистартып тору да мөһим. Бу эшебезнене язганда, без Австралиядә үпкә астмасын тынлы уен кораллары ярдәмендә дәвалауларын белдек.

**Йомгаклау**

Курай – иң борынгы уен коралларның берсе. Ул башка уен коралларыннан аермалы буларак, тиз ясала, гади, җиңел, уңайлы. Курайда уйнау күп кенә көйләрнең легендалары, туган як тарихы белән танышырга ярдәм итте. Төрле дәрәҗәдәге конкурсларда катнашып, без күп кенә танылган курайчылар белән таныштык, дуслар таптык.

Дөньяның күп халыкларында курай кебек музыка кораллары бар икән. Борынгы татар-башкорт уен коралы курай классик һәм заманча музыкада киң кулланыла. Музыка белән шөгыльләнү, аерым алганда, курайда уйнау безнең көйне ишетүебезне, аңлавыбызны үстерә, төрле тавышларга сизгерлекне арттыра. Киләчәктә без бу тема буенча эшне дәвам итәргә телибез.

**Әдәбият исемлеге**


1. Давлетбаева Р. Г. Диалог языков и культур (лингво - культурологический словарь). «Китап», 2003 г.
2. Халитов Р.Ф. Татарские народные музыкальные духовые инструменты: Описание и методика изготовления. К., 1992;
3. https://tatarica.org/tat/razdely/narody/tatary/tatarskaya-narodnaya-muzyka/kuraj Онлайн - энциклопедия Tatarica



*Галеева Зарина, 8 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының*
*«10 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе»*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Хакимова Рамзия Риф кызы,*
*туган тел һәм әдәбияты укытучысы*


**Минем гаиләм шәҗәрәсе**

**Кереш**

Фәнни-тикшеренү эшенең **темасы:** Минем гаиләм шәҗәрәсе.

Безнең гаиләнең традициясе-шәҗәрәләр ясау, исемнәребезне барлау, гаиләбез белән горурлану. Гаиләне яклау, саклау кирәк. Гаилә белән горурлану хисләре тәрбияләү төп **максатыбыз.** Безнең гаиләнең традициясе дә-минем гаиләм шәҗәрәсен җыю,исемәрне барлау.

Дөньяда һәр нәрсәнең, һәр кешенең исеме бар. Бала туу белән, аңа исем бирелә. Балага нинди исем кушарга дигән **проблема** һәр заманда актуаль булган. Гаиләнең ныклылыгы, дуслыгы,тулылыгы проблемасы да күтәрелә. Димәк, эшемнең темасы бүгенге көндә бик актуаль.

Проблемага ачыклык кертеп, кешенең исеме тормышына һәм язмышына йогынты ясавы турында аңлатуны **максат** итеп куйдым.Минем гаиләдәге исемнәрне күрсәтеп китәсем килде. Гаиләмнен шәҗәрәсен курсәтәсем,гаиләм белән горурлану хисләре кичерәсем килә.

**Төп өлеш**

**I бүлек. Исемнәрдә-кеше язмышы**

Бала туганчы ук,  ата-ана аңа исем эзлиләр.Чөнки ул- иң кадерле, газиз, беркемне дә кабатламас бала. "Исем ул синең үзең генә дә түгел бит: ул синең йөзең, ата-анаңның, ыругыңның, нәселеңнең йөзе һәм байрагы. Исем ул синең тормыш юлыннан күтәреп барган үз байрагың"- дип юкка гына язмагандыр.

Ата-ана, баласына исем кушканда, теләсә нинди очраган исемне битараф рәвештә алмый. Үзенең зәвыгы, уй һәм фикерләреннән чыгып, гаилә әгъзалары белән белән сөйләшеп, уртаклашып исем сайлый.

Татар халкы элек-электән яңа туган сабыйга исем кушуга зур җаваплылык белән караган. Исеме җисеменә туры килә торган матур эчтәлекле, җиңел әйтелешле исемнәр бирергә тырышкан. Менә шуңа кытай халык мәкалендә хаклы рәвештә: "Начар язмыш белән туу куркыныч түгел әле ул, ә менә начар исем алу- коточкыч" диелә.

**II бүлек. Исемнәрнең мәгънәсе.**

Без, гадәттә, исемнәрнең мәгънәсе турында уйланып тормыйбыз, күнеккәнчә сөйли бирәбез. Уйлап карасаң, аларда кызык нәрсәләр ачыла. Кеше мәсәлән, үзенең нигә Рәмзил булуын аңлый алмый.

Әллә исем, бер кешене икенчесеннән аерып тану өчен, ясалма рәвештә төзелгән авазлар тезмәсеме? Яки тамга кебегрәк бернәрсәме? Әйе, исемнәр- нигездә кешеләрне бер-берсеннән аеру- тану өчен хезмәт итә торган тамга. Ләкин гаҗәеп тамга... Чөнки авазлардан тезеп кенә исем ясап булмый бит.

Һәр кешегә матур исем кирәк,
Аның булсын тирән мәгънәсе.
Шушы исем аңа гомерлеккә!
Истә тотсын әткә-әнкәсе.
Шушы исем белән яшәп кеше,
Үрләр яулый, таный, таныла,
Исем мөһим кеше язмышында,
Һәркем салсын моны аңына.

**Исем кешегә гомерлеккә бирелә.**

Балага бирелгән исем матур булып, аның мәгънәсе тирән булырга тиеш. Ата-ана баласының исеме белән горурланырлык булсын. Матур эчтәлекле, тыйнак, җыйнак исемнәр һәрвакыт кешеләр күңеленә хуш килә. Исеме матур кеше үзе дә матур була. Үсеп җиткәч, иләмсез, ят исемнәре аркасында балалары уңайсыз хәлгә калмасын өчен, ата-ана исем кушканда сак эш итсеннәр иде диясе килә. (Исем кушу йоласы!)

Әти-әнием миңа да бик матур исем биргәннәр. Минем исемем – Зарина.

Әниемнең исеме-Алсу Мөнир кызы, әтиемнең исеме- Ренат Рафик улы.

Алсу - татар исеме, ал төс-якты,матур,нурлы төс.Төсне генә белдерми, ә су өстендә балкыган кояш нурын да курсәтә. Кояш чыккандагы беренче ал төснең судагы чагылышын күрсәтә! Алсу йөзле, алмадай чибәр,балкыган кеше. **musulmauk.ru**

Ренат-Ринат-татар-башкорт-рус исеме. Яңа туган дигәнне аңлата. Революция,фән,эш. **http://millattashlar.ru**

Безнең Татарстанда икетеллелек булганлыктан,мин рус телендә дә мәгълүматлар таптым. Бу минем өчен бик тә кызыклы мәгълүмат!

1)Зарина – с золотыми украшениями, узорами.(https://nameology.ru/nacionalnye-imena/zhenskie-tatarskie-imena)

2) Имя Зарина имеет несколько версий своего происхождения, перевода:

славянская – означает «заря», «красота рассвета»

тюркская – обозначает «украшенная золотом» **(https://my-calend.ru/names/zarina)**

**Йомгаклау**

Башта укытучым белән бергәләп “ Актаныш таңнары” газетасындагы иске, кызыклы исемнәрне карап үттек. Элек катлаулы исемнәр кушканнар. (Газетада өлкән яшьтәге кешеләр күберәк). Ә хәзер гадирәк исемнәр кушалар. Минем сыйныфымда гади,татар исемнәре генә кушылган диярлек. Соңыннан гаиләбезнең шәҗәрәсен өйрәндем. Моның өчен әти-әни,әби-бабай, күршеләр белән сөйләштем. Тик кайбер туганнарның туган еллары онытылган. Авыл советындагы архивта да сакланмаган. Бу бер көнлек кенә эш түгел. Без-гаиләбез белән туганнарны барлау, җыю традициясен мин тагын да дәвам итәчәкмен.Гаиләмнең килеп чыгышы белән, тату-дус,бердәмлеге белән горурланасым килә. Без җиде буынны белергә тиеш!

**Кулланылган әдәбият:**


1.Татарча-русча кеше исемнәре һәм фамилияләре сүзлеге, Татарстан китап нәшрияты, 2006 ел.

2.Гомәр Саттар-Мулилле”Татар исемнәре ни сөйли”? “Раннур” нәшрияты 1998 ел.

3.Авыл советтының халыкларны раслау-теркәү китабы.

4. Гаиләнең шәҗәрәсе
5. Интернет ресурслар:
6. **musulmauk.ru**
7. **http://millattashlar.ru**
8. https://magarif-uku.ru/tatar-isemnere/ir-at/r/
9. https://nameology.ru/nacionalnye-imena/zhenskie-tatarskie-imena
10. https://www.yandex.ru/search/?text

*Гарипов Раяз, Ибраһимов Әмир, 5 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль*
*районының «37 нче күп профильле лицей»*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләре: Усманова Рузилә Рәшит кызы,*
*Хәнәфиева Ләйсән Фәйзехан кызы,*
*туган тел һәм әдәбияты укытучылары*

## Чәй – шифалы эчемлек

### Кереш

Чәй –халкыбызның яраткан эчемлеге. «Чәйдән соң – күңелдә җәй», ди безнең халык. Чыннан да, бер йотым булса да чәй эчеп куйсаң, күңелләр җылына, кәефләр күтәрелә. Чәйне татарлар кайнар килеш, каты итеп, сөт, сөт өсте салып, бал белән эчәргә ярата. Кунакларны чәй белән сыйлау татар халкында кунакчыллыкның бер билгесе булып тора. Өйгә кем генә кермәсен, барысын да чәй белән сыйлап чыгаралар.

Безнең гаиләдә бик еш чәй эчәләр. Бу бездә үзенчәлекле ритуал кебек. Чәй эчү традициясе кайдан килгән? Аның файдасы нинди? Бу сорауларга җавап бирү өчен без да эшебезне башлап җибәрдек.

**Эшебезнең максаты:** татар халкының чәй эчү традицияләренең үзенчәлекләрен өйрәнү.

**Бурычлар:** чәйнең барлыкка килү тарихы белән танышу, аның файдасын, чәй эчү традицияләрен өйрәнү.

Эшебезне башкарганда чәй эчү традицияләрен белү өчен без төрле мәгълүмат чыганакларына мөрәҗәгать иттек, шәһәр һәм мәктәп китапханәсендә булдык. Энциклопедияләрдә, китапларда, интернет-ресурсларда мәгълүмат таптык.

**Чәйнең тарихы**

Чәйнең ватаны – Кытай иле. «Чәй» сүзе нәрсәне аңлата соң? Бу сүзне төрлечә әйтәләр, ләкин барлык вариантларда да аларны гомумиләштерүче бер иҗек — «ча» иҗеге бар. Борынгы кытай теленнән «ча» яшь яфрак дип тәрҗемә ителгән.

Чәйнең килеп чыгышы турында риваятьләр яши. Менә шуларның берсе. 5 мең еллар элек кытай императоры урманда ял иткәндә, эчәр өчен хезмәтчеләренә су җылытырга кушкан. Көтмәгәндә җил күтәрелгән, һәм чынаякка берничә чәй яфрагы эләккән. Император эчемлекне эчкән һәм кәефе күтәрелүенә игътибар иткән.

Шулай итеп чәй эчү гадәте барлыкка килә. Ә менә тагын бер риваять. Электән көтүчеләр тауларда үскән мәңге яшел үсемлекнең яфракларын чеметеп кенә суга салып, шул суны эчсәләр, күңелләре күтәрелүен, көчләре артуын һәм текә тауларга да бик җиңел менә алуларын сизгәннәр. Көтүчеләр яфракларның могҗизалы көчен үзләрендә сынап карарга булганнар. Алар башка дару үләннәрен кебек аларны киптереп, кайнар суда пешергәннәр һәм хуш исле төнәтмә эчә башлаганнар.

Чәйне үсемлек буларак VII гасыр башыннан гына үстерәләр. Европага бераз соңрак, Португалия диңгезчеләре аша 1517 елда килеп керә. Россиядә беренче тапкыр чәйнең барлыкка килүе 1683 елда Мәскәү илчесе Василий Старковның Монголиягә баруы белән бәйле. Ул аннан дүрт потка якын диңгез арты эчемлеген алып кайта. Чәй башта тиз арада боярлар, ә аннары башка катламнар арасында тарала. Халык моңа кадәр чәй эчмәгән дип уйлый күрмәгез. Чәйне туган якларда үсүче файдалы үләннәрдән кайнатмалар ясап эчкәннәр. Чәй кайнату өчен Тулада самавырлар уйлап табылган. Чәй эчкәндә әһәмиятле гаилә мәсьәләләре хәл ителгән, мөһим танышулар оештырылган, сәүдә килешүләре төзелгән һәм сәяси эшләр турында фикер алышканнар. Һәр мәҗелестә дә чәй өстәле зур тырышлык, зәвык белән әзерләнгән.

Элек чәйне зур самавырлардан касәләргә салып, каты итеп һәм бик кайнар килеш эчкәннәр. Хәзер дә чәйне каты итеп ясап чынаяктан эчәләр, ә самавыр күп кенә гаиләләрдә табынының түрендә тора. Самавырларның нинди генә юк. Татарстанның Милли музеенда аларның 100дән артык төре саклана.

Чәй барлыкка килгәнче татарлар сөт, катык, әйрән эчкән. XIX гасырда чәй эчү гадәте татар халкы тормышына ныклап кереп урнаша. Хәзер бу тылсымлы эчемлектән башка бер генә милли бәйрәмне дә күз алдына китереп булмый. Татарлар чын чәйнең «йокыны куа» икәнен дә белгәннәр. Әгәр дә аңа лимон өстәсәң, абруе тагын да арткан. Татар халкы чәйне сөт яки сөт өсте белән эчәргә ярата. Гадәттә яңа сауган яки кайнаган сөт салына. Сөтле чәй өчен ул катырак итеп пешерелә. Татарның 90 проценты чәйдән тора дигән сүз юктан гына чыкмаган. Безнең халык, гомумән, чәйсез яши алмый ул. Өйгә кем генә кермәсен, табын әзерлиләр. Кунакны тәмле ризыклар, чәй белән сыйлап чыгаралар. Татар халкы гомер—гомергә бик кунакчыл булган, килгән кунакны «якты чырай, такта чәй» дип каршы алган. Элек татарлар такта чәй яратканнар, ул пресслаган турыпочмаклы плитка формасында

булган. Шуны сындырып хуш исле эчемлек пешергәннәр. Иртән торуга һәр йортта самавыр кайнап торган, тәмле чәй исе чыккан.

Татар чәе турында билгеле кешеләр дә искә алып киткән. Тарихчы Николай Воробьев: «Татарларда иң киң таралган эчемлек – чәй. Алар аны бик еш һәм бик озак итеп эчәләр», — дип язган. Ә алман табибы Николай Фукс үзенең хезмәтендә: «Татарлар чәй эчәргә ярата. Аны бал белән кимендә 4 чынаяк эчәләр», — дип искә алган. Инглиз язучысы, рәссам Эдвард Турнерелли: «Мондый тәмле чәйне Европаның бер илендә дә очратканым булмады», — дигән.

**Чәйнең файдасы**

Чәйне куллану кешенең органнарына уңай йогынты ясый. Бу аның турында көндәлек эчемлек буларак кына түгел, профилактика һәм хәтта дәвалау чарасы буларак та сөйләргә мөмкинлек бирә.

Киптерелгән чәй үсемлеге сабаклары һәм яфраклары кофеин, эфир мае, С, В витаминнарына һәм башка матдәләргә бай.

Яңа гына җыелган чәй яфрагында С витамины лимонга караганда дүрт мәртәбә күбрәк, ә яшел чәйдә, кара чәйгә караганда бу витамин 10 тапкыр күбрәк. Менә шушы витаминнарга бай булганга күрә чәй кеше организмына уңай тәэсир ясый, акыл активлыгын үстерә, арыганлыкны бетерә, нерв һәм ашкайнату системасының эшчәнлеген яхшыртырга, кәеф күтәренкелеге хисе уята, ару-талчыгу белән көрәшергә ярдәм итә. Дәвалау үзлегенә ия үсемлекләр арасында чәй иң алдынгы урыннарның берсен алып тора.

Әби-бабаларыбыздан файдалы киңәшләр:

- әгәр арысагыз, башыгыз авыртса, дару йотарга ашыкмагыз, бер чынаяк куе чәй эчеп куегыз;
- әгәр туңсагыз, бер чынаяк чәй сезне җылытып кына калмас, салкын тиюдән дә, зарарлы микроблардан да саклар;
- хәтта күз авыртканда аны яңа пешерелгән җылы чәй белән юсаң, файдасы тия;
- бөтнекле чәй йөрәк эшчәнлеген яхшырта, баш авыртуын да бетерә;
- салкын тигәндә, төрле үләннәрдән кушып ясалган чәйләр дә бик файдалы;
- автобуста күңел болганганда да яшел чәйне коры килеш чәйнәргә кушалар;
- тире ялкынсынганда, ашказаны язвасында да яшел чәй булыша;
- чәйне җиләк-җимешләрдән, үләннәрдән дә хәзерлиләр;
- бөтнекле, мәтрүшкәле чәйләрне бик күпләр яратып эчәбәләр;
- нарат җиләгеннән ясалган чәйне - ревматизм белән авырганда, кара җиләк чәен -эч киткәндә, ә каен җиләге чәен эчеп бавырда, бөердә таш барлыкка килүдән дәвалаunion;
- чәй көч бирә, йөрәкне тынычландыра, кан басымын түбәнәйтә, салкын тиюдән саклый.

**Чәй турында кызыклы фактлар**

Пакетлы чәйнең тарихы 1904 елга барып тоташа. Нью-Йорк кешесе Томас Салливан чәйләрне кәгазь пакетта сата башлый. Бер клиенты чәйле пакетны суга ялгыш төшереп җибәрә, чәй кыяфәтенә кергәч, эчеп карый.

-җир шарында бер секундка ике миллион чынаяк чәй эчәләр.

Чәйнең ватаны булып Кытай саналса да, аны Төркия, Ирландия һәм Бөекбританиядә күбрәк эчәләр.

Һәр хуҗабикәгә 2, 5, 6 саннарын истә калдырырга киңәш ителә. 2 минут төнәтелгән чәйдәге кофеин кәефне күтәрә. 5 минут төнәтелгән чәйнең эфир майлары организмны тынычлындыра. 6 минут пешкән чәй эчү өчен иң тәмле, хуш исле чәй санала.

Россия Федерациясе президенты Путин да яшел чәй генә эчә.

Яшел чәй ракка каршы эчемлек булып санала.

**Төрле халыкның чәй пешерү ысуллары**

Һәр халыкның дип әйтерлек чәй пешерү буенча үз ысуллары бар һәм һәрберсе үзенекен мактый.

Чәй эчүнең үз традицияләре бар. Чәй өстәлендә һәрвакыт ашъяулык булырга тиеш, бәйрәм ашъяулыгы – аерым очраклар өчен, гадиерәге – көндәлек чәй өстәлен бизи.

Кытайлар аны чәйнектә түгел, ә капкачлы махсус чынаякта пешерәләр.

Инглизләр чәйне бары тик сөт белән генә эчә. Башта сөт салына, аннан чәй ясала. Бу – кагыйдә.

Төньяк Африкада яшел чәйне бөтнек белән төнәтеп, шикәр кушып, кайнар килеш эчәләр.

Көнчыгышның кайбер илләрендә чәйне боз белән һәм цитрус җимешләре согы белән эчәләр.

Тибетта чәйне бик каты пешерәләр һәм аңа сары май, тоз кушып эчәләр. Катнашманы махсус савытта куе масса булганчы болгаталар.

Кыргызстанда, Монголиядә чәйгә он, тоз һәм сарык мае кушалар.

**Мәкальләр**

Татар халкының чәй яратуын мәкаль-әйтемнәрдә дә күрәбез.

**Чәй** эчсәң күңелдә җәй.

**Чәй** чынаягы 3 булыр, 3 булмаса хуҗаларга көч булыр.

Китәр вакыт җиткәч самовар куймыйлар.

**Чәй**нең 70 төрле файдасы бар.

Тәмле **чәй** — якты чырай.

Ачык чырай – такта **чәй.**

Бер чынаяк **чәй**нең кырык ел хәтере бар.

Кайнаган **чәй** эчелгәнгә исәп, бирелгән кыз киткәнгә исәп.

**Чәйсез** торып була, икмәксез торып булмый.

Әйрән эчкән ярлы бар, **чәй** эчкәннән ким түгел.

Ач карынга каты **чәй**.

Бар янында бар яхшы, **чәй** янында бал яхшы.

Бер чынаяк **чәй**нең кырык ел хәтере бар.

Кырда кайнаган **чәй** тәмле була.

Татар колагы катканчы **чәй** эчә, ди.

**Чәе** булса, шикәре табылыр.

**Чәй** яны – гаилә җаны.

Гыйлем **чәй** түгел, авызыңа тиз генә чөмерә алмассың.

**Чәй** эчеп беткәч, шикәр китермиләр.

**«Чәй» сүзе кергән фразеологизмнар**

*Аш артыннан – чәй* фразеологик әйтелмәсе ашагап алганнан соң, чәй эчерү йоласы; *ашың-чәең тәмле булсын* – кунакка кереп, табын янында ашап утыручылар булса, аларга теләк итеп әйтү; *тезне тезгә куеп чәй эчү* – бик якын, дус булып, сөешеп, чөкердәшеп, дус гаилә булып яшәү; *чәйне куян каны кебек ясау* – чәйне бик куе ясап эчү; *чәеннән Мәскәү юлы күренә* – чәй бик сыек ясалган булуы һ.б

**Йомгаклау**

Эчәсе килсә дә, ашыйсы килсә дә, арыса-талса да, кәефе кырылса да, сөенеч-шатлыклары ташып торса да халкыбыз тәмләп, хуш исле чәй эчкән. Бүгенге көнгә кадәр чәй эчү йолалары татарлар тарафыннан бәяләнә һәм сакланып килә. Әлек әби-бабаларыбыз чәйне самоварларда кайнатып эчкән, хәзерге көндә дә татар гаиләләрендә бергә җыелып, бер өстәл артында чәй эчүләр саклана. Безнең гаиләләребездә дә шулай.

Кунакчыл татарның иң беренче сүзе – «Чәй эчәбезме?», чәй эчү тәкъдименнән баш тартып, сез хуҗаларны рәнҗетергә дә мөмкинсез.

«Бер чынаяк чәйнең кырык ел хәтере бар», ди халык. Сезгә кунакка килгән дустыгызны бер чынаяк чәй белән сыйласагыз, ул сезнең яхшылыгыгызны һәрчак хәтерендә саклар һәм яхшылык белән җавап бирер.

**Кулланылган әдәбият исемлеге**

Баюканский, В. Зачем мусульманину чай? - Издательство: ООО Типография «Липецк-Плюс», 2013. – 390 с.

Бушков, Р. А. Букет напитков Татарстана / Р. А. Бушков, Ф. Г. Мазитова. – Казань : Татарское кн. изд.-во, 1993.− 192 с.

Фукс, К. Ф. Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях. – Казань : Университетская типография, 1844. – 134 с.
URL : http : // www.poznanie21.ru/current/48120/php
URL : http : //www.festival.1september.ru/articles/502467

*Кадыйров Ихсан, 6 нчы сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәренең*
*«1 нче лицей-интернат»*
*муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Мөбәрәкшина Гөлсинә Нәгыйм кызы,*
*тьютор*

## Әлмәт муралларында татар халкының тарихы һәм гореф-гадәтләре

### Кереш

Мәдәният милләтнең матди һәм рухи кыйммәтләре җыелмасыннан гыйбарәт. Халык мәдәниятенең кайбер элементлары: милли гореф-гадәтләр, тарих, фикерләү стиле, тел һәм яшәү рәвеше үзенчәлекләре. Милләт саклансын һәм дәвам итсен өчен аның тарихын һәм гореф-гадәтләрен белү һәм киләчәк буыннарга тапшыру мөһим.

Эшнең **актуальлеге:** информация күплеге һәм төрлелеге чорында милли үзенчәлекләр турында кызык, мавыктыргыч һәм заманча итеп сөйләү өчен яңа ысуллар табарга кирәк. Мәдәни кодларны һәм кыйммәтләрне төрле буын һәм милләт вәкилләренә җиткерү өчен урам сәнгате, безнең фикеребезчә, иң отышлы һәм нәтиҗәле чара.

Әлеге проект эшендә без халык мәдәниятен урам сәнгате аша өйрәнү, күрсәтү һәм башкаларга җиткерү үзенчәлекләрен өйрәнүне **максат** итеп куйдык.

Билгеләнгән максатка ирешү өчен түбәндәге **бурычлар** куелды:

1) Төрле чыганаклардан Әлмәт мураллары турында информация табарга;
2) Информацияне системалаштырырга;
3) Проект һәм презентация әзерләргә;
4) Проектны тәкьдим итәргә.

**Тикшеренү объекты:** Әлмәт шәһәре мураллары.

**Тикшеренү предметы:** татар халкының тарихы, гореф-гадәтләре һәм көнкүрешенең муралларда чагылышы.

**Тикшеренү ысуллары:** анализ, синтез, гомумиләштерү.

Проектның **нәтиҗәсе** буларак мәктәп укучылары өчен экскурсия үткәрү планлаштырыла.

## 1. Әлмәт мураллларында татар халкының тарихы һәм гореф-гадәтләре

### *1.1. “Алтын алмалар турында әкиятләр” паблик-арт программасы, үзенчәлеге һәм максатлары*

Мәдәният турында белем - халык традицияләрен аңлауның бер ачкычы. Хәзерге көндә барлык халыкларның да күп гореф-гадәте онытылган, буыннар бәйләнеше югала, ә бу, үз чиратында, гомуми мәдәнилек дәрәҗәсенә йогынты ясый. Безнең шәһәрдә татар халкының мәдәни мирасын саклауга зур игътибар бирелә. Мураллар ясау моның ачык мисалы булып тора.

“Мурал” дип архитектура корылмалары диварларында ясалган сәнгати сурәтләр атала. Бу сүз испан теленнән килә, “muro” - "дивар" дигәнне аңлата. [1, б. 3]

Мурал, сәнгатьнең аерым төре буларак, бер гасыр чамасы элек Мексикада, кешеләргә яңа сәнгать алып килү өчен революция вакытында барлыкка килә.

2017 елда Әлмәттә «Алтын алмалар турында әкиятләр» паблик-арт программасы башланды. Әлеге программа «Татнефть» компаниясе инициативасы буенча Санкт-Петербургтагы «Новь» паблик-арт проектлары бюросы һәм Стрит-артны өйрәнү институты экспертлары тарафыннан тормышка ашырылды. Шулай ук проектта төрле илләрдән чакырылган белгечләр һәм рәссамнар катнашты. “Алтын алмалар турында әкиятләр”нең нигезендә Әлмәт районында антропологлар, тарихчылар һәм фольклорчылар үткәргән зур культурология тикшеренүе ята. Ул татар халкының гореф-гадәтләренә, кыйммәтләренә һәм эстетикасына багышланган. Күмәк эш нәтиҗәсендә әкиятләр, әлифба китабы, борынгы тәңкә сюжетлары һәм сурәтләре, музей күргәзмәләре һәм сирәк китаплар кысаларыннан чыгып, яңа формада йорт диварларына һәм җәмәгать пространстволарына күчә. Шулай итеп меңъеллык тарих уяна һәм яңа мәгънәләр белән тулылана. Проект Әлмәт шәһәренең тарихи хәтерен һәм мәдәни кодын тикшерүне, паблик-арт (җәмәгать пространствосындагы сәнгать) барлыкка китерүне, шәһәр мохитен үзгәртүне һәм шәһәр халкы, кунаклары өчен махсус белем бирү программасын берләштерә.

### *1.2. Мураллларда татар халкы һәм Әлмәт шәһәренең тарихы*

Италия рәссамы Hitnes`ның <u>«Алмалар тарихы» диптихы</u> «Зөһрә» татар әкиятенә һәм Әлмәт аксакалларының истәлекләренә нигезләнгән. Бу - Әлмәт символының берсе булган алмагач интерпретациясе.

1950 нче елларда Әлмәт авылы территориясендә нефть ятмалары ачылганнан соң бу җирлекнең тиз үсеше башлана. 1952 елда авылга эшчеләр посёлогы, ә бер елдан шәһәр статусы бирелә. Яңа кварталлар, кибет, хастаханә, кунакханә, белем бирү һәм мәдәният оешмалары төзелә башлый. Халык авыз иҗатын җыю экспедициясе вакытында тупланган җирле халыкның хатирәләре буенча, тиз үсүче шәһәрне яшелләндерү өчен бик күп

үсентеләр, шул исәптән алмагачлар утыртылган. Тиздән кешеләр урамдагы үсенте ботакларын үз кишәрлекләрендә утырту өчен ала башлаган. Яңа Әлмәт алмагач чәчәкләренә күмелгән, күктә карлыгачлар очкан, аларның тавышын кешеләр «Аллаһ-Аллаһ» диюгә охшатканнар. [2, б. 39] Шәһәр исеме дә агачлар белән семантик бәйләнешне саклаган: «алма» сүзе шәһәрнең исеме белән аваздаш.

<u>“Асар. Ризаэддин Фәхреддин портреты” диптихы</u>, авторы – Дима Fatum.

Фәлсәфә фәннәре докторы Әлфрид Бостанов сузләренчә, Россия ислам мәдәниятендә берничә төп исем бар. Һәм Әлмәт, һәм Татарстан, һәм күрше Башкортостан өчен Риза Фәхретдин – шәхесе турында бәхәс тумаучы кеше. Ул – мирасы бөтенесе тарафыннан танылган зыялы. [3]

Ризаэддин Фәхреддин – энциклопедист галим, язучы, дин әһеле һәм фәлсәфәче. Әлмәт үзәк мәчете һәм шәһәрнең бер урамы аның исемен йөртә.

Риза Фәхреддин – мәдәният өчен бик мөһим булган көчле фигура. Рәссам Дима Fatum эшләрендә төрле элементларны бергә куша, бу – Фәхреддин өчен идеаль алым. Аның шәхесе күп катлы, зур, һәм аның турында визуаль тел белән сөйләү җиңел түгел. Диптихның эскизы өстендә ел ярым эшләгәннәр. [3]

Коллаж техникасын кулланып Fatum мәгърифәтченең тормышы һәм эшчәнлегендә мөһим роль уйнаган элементларны тасвирлый. Муралга якыннан караганда алар бербөтен, бары тик туры мәгънә ташыган кебек тоела. Ә ераккарак китә башласаң муралдагы һәр деталь аксакал портретына әверелә башлый: болытлар – чалмага, наратлар һәм өй элементлары – акыл иясенең күзләренә әйләнә. Арба - Фәхреддиннең авылдан Мәккәгә юлын, эзләр - дүрт томлы “Асар” хезмәтен (хәзерге вакытта да шәҗәрәләр төзегәндә кулланыла) символлаштыра. Кайбер символларны бары тик галимнең тормыш юлын һәм эшчәнлеген җентекләп өйрәнгәннән соң гына аңлап була.

<u>«Әлифба» сериясе</u> татар язуы тарихына багышланган. Ул татар әлифбасындагы Ә, Ө, Ү, Җ, Һ хәрефләрен һәм аларга башланган сүзләрне сурәтли. Бу серия Төзүчеләр проспектындагы өч бинаның биш стенасында урнашкан, тагы бер рәсем — әлифбаның үзенә, уку-язу нигезләренә өйрәтә торган китапка багышланган эш.

Серия идеясе кураторлар төркеменең Елховой авылы музеена тикшеренү экспедициясе вакытында, элеккеге совет әлифбасы хәрефләрен күргәч барлыкка килгән. Сериянең визуаль нигезе итеп китап графикасының иң яхшы үрнәкләрен алганнар. Аерым алганда, 1904 елгы Александр Бенуаның “Рәсемле Әлифба”сын. Соңгы йөз ел эчендә татар әлифбасы берничә тапкыр үзгәргән, гарәп язуыннан латин графикасына, аннары хәзер кулланыла торган кирилл алфавитына күчкән.

Сериянең төп эшендә Дима Fatum туган телнең буыннар хәтерен саклап калу образын булдырган. Гадәти татар пейзажы фонында укытучы һәм укучылар әлифба тирәли урнашкан. Китаптан белем чәчәге үсеп чыга.

### *1.3. Мураллларда татар халкының гореф-гадәтләре*

Иллюстратор Гүзәл Гариповага "Һ" хәрефе һәм "Һөнәр" сүзе белән эшли. Үз эшендә ул татар халкының традицион милли бәйрәме Сабантуй белән заманча скейтпаркны берләштергән. Аның рәсемендә бер көтү бала-чага сурәтләнгән, һәрберсе Сабантуй ярышларында катнаша: балалар авыш бүрәнә өстеннән йөриләр, әтәч артыннан колгага менәләр, капчык белән сугышалар, кашыкка йомырка куеп йөгерәләр, көрәшәләр, бәйләнгән күз белән җеп кисәләр һәм бииләр.

"Җ" хәрефе һәм "җир" сүзен ачыклау өчен Роман Мураткин бәйрәм күренешен сайлаган. Гармунчы җитәкчелегендәге бәйрәм процессы кыр эшләренең тәмамлануын билгеләп үтә. Игенчелек календаренең мөһим этаплары, мәсәлән, чәчү яки уңыш җыю, еш кына бәйрәмнәр белән тәмамланган. Бәйрәмнәрне бөтен җирдә үткәрмәсәләр дә, алар әле дә крестьян тормышының мөһим өлеше булып кала бирә. Элегрәк мондый бәйрәмнәр ритуаллаштырылган характерда Татарстанның һәм Россиянең бөтен территориясендә билгеләнеп үткән. Шул рәвешле кешеләр җиргә рәхмәт белдереп, юмарт булуын сораганнар. Үз эшендә Роман Әлмәт пейзажына хас мөһим детальне — калкулыклардагы нефть каланчалары силуэтын да күрсәтә алган.

Берлинлы рәссам Агостино Якурчи ясаган "Биш чәйнек, яки Исәнмесез" шәһәрнең иң истәлекле мураларыннан берсе. Аның стиленең аермалы сыйфатлары - якты төсләр, гадиләштерелгән формалар, төгәллек. Мурал шәһәргә керү юлындагы өйнең диварына төшерелгән.

Кунакчыллык, бүгенге һәм үткәннең традицияләрен бәйләп, табын артында чәй эчү аша уңышлы гәүдәләндерелгән. Рәссам "исәнмесез" сүзен нигез итеп алган. Аның чәйнекләрдән төзегән пирамидасы татар мәдәнияте өчен мөһим булган җылы, матур аралашып утыруны символлаштыра. Визуаль мотивлар өчен XIX гасыр чигеш үрнәкләре кулланылган, шулай итеп муралда лалә чәчәкләре барлыкка килгән.

Әлмәт авылы җитди тарихи давыллардан һәрвакыт ерак булган, шуңа күрә күпләр бирегә авыр хәлләрдән качып килгәннәр - халыкның катнаш составы әнә шулай формалашкан. «Алтын алмалар турында әкиятләр» проектын башлаганда үткәрелгән язучылар бәйгесенә Казаннан Алсу Нургаязова «Ризык» хикәясен җибәрә, ул хикәя нигезендә грек неомуралисты Димитрис Таксис "Төшке аш" муралын ясады. Сюжет буенча рус гаиләсе татар күршеләрен көчләп чукындырудан яшергән. Бу трагикомик мизансцена Татарстан өчен хас булган күрше хакы, милләтара дуслык традицияләрен күрсәтә.

Дивардагы чигешләр исә кул эше традициясенә ишарә итә, рәссамга татар рәсем сәнгате тарихы белгече Гүзәл Фуад кызы Вәлиева-Сөләйманова киңәшләре ярдәм иткән.

“Төшке аш” муралы белән Испаниядән килгән рәссам Ракель Родригоның “Ал да гөл” эше яхшы яраша. Гадәттә өйләрне бизәүдә кулланылган чигүгә Ракель яңа мәгънә өсти. Аның эшләренең максаты – чигү традициясен ябык пространстводан (өйдән) урамга чыгарып шәһәр мохитенең бер өлеше итү. Нечкә һәм сизелер-сизелмәс Рабиц челтәре, калын мамык җеп һәм әсәрнең күләме аркасында бизәкләр табигый рәвештә урбанистик пейзажга үрелеп кергән дигән тәэсир туа.

«Ал да гөл»нең эскизын ясый башлаганда рәссам Әлмәт флорасына хас чәчәкләрне табарга була. Программа кураторлары шәһәр калкулыкларының берсендә чәчәкләр җыеп фотосын рәссамга җибәрәләр. Родриго күпьеллык җитенне – татар кул эше осталары тарафыннан тукыма бизәгәндә формасы еш кулланылган чәчәкне сайлый. Элекке һәм яңаны, кәсеп һәм хәзерге җитештерүне чиратлаштырып Родриго, эшнең ахыргы хәлен күрер өчен компьютерда аның эскизын ясап чигешнең күп өлешен Валенсиядә башкарган, ә калганын җирле халык белән Әлмәттә ясап бетерде. Йорт ишегалдында Рабиц челтәрен элделәр, мастер-класс оештырдылар – анда ике көн эчендә 100 кеше катнашты. Ракель шәһәр халкын чигеш техникасына өйрәтте һәм иң яхшы өйрәнчекләре аңа төп чәчәкне ясауда ярдәм итте.

“Татарлар чәчәк, үсемлек орнаментын юкка гына сайламаган: ул бөтен шәрыкъ һәм мөселман халыкларының сәнгать теле булып декоратив-гамәли иҗатның төрле категорияләрендә үсеш алган. Тукучылык, күн, агач эшкәртү кебек технологик мөмкинекләр булмаган очракта еш кына үсемлек формаларына охшатып эшләнгән геометрик орнамент үсеш алган. Аның мотивлары теге яки бу дәрәҗәдә уңдырышлылык, сөю, бәхет һәм "җәннәт бакчасы" символлары булган”, - ди Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова. [3]

«Котлы булсын!» муралы, автор – Роман Kreemos.

Изге теләк теләү («алкыш») — үзенчәлекле фольклор жанры, ул татар мәдәниятенә хас мөһим сыйфатны, яхшы теләк теләү традициясен күрсәтә.

“Котлы булсын” дигән язу Алтын Урда тәңкәләрендә еш очрый. Алар XIII-XIV гасырларда киң территориядә — төньякта Болгар шәһәреннән алып Кырымга кадәр һәм көньякта Румыниягә кадәр җирләрдә таралган. Тәңкәләр арзан торганнар һәм гади кешеләр арасында киң кулланылышта булганнар: бакыр акчалар көндәлек әйләнештә йөргәннәр. Шулай итеп, бу язу халыкның киң катламына юлланган, күпчелек өлеше сакланып калмаган архитектура һәм әдәбият белән берлектә империя хакимияте символын формалаштыруда катнашкан.[3]

“Кот” — төрки сүз, ул «бәхет» дигәнне аңлата. Мондый язулы тәңкәнең әйләнештә йөрүе, метафора буларак, халык арасында хәер-фатиха алышуны аңлаткан. Алтын Урда дәүләте белән бергә әлеге тәңкәләр дә юкка чыккан, моңа карамастан, бу сүзтезмә тотрыклы сакланып, хәзерге татар телендә еш кулланыла. Бүгенге көндә аның мәгънәсе киңәйгән: аны хәерле теләк теләгәндә, төрле котлауларда, шулай ук яңа әйбер сатып алгач (беренчел мәгънәсен искә төшерә), әйтәләр.

Бу мурал - «Котлы булсын!» теләгенең һәм аның рус теленә «Будь счастлив!» тәрҗемәсенең интерпретациясе. Рәссам үз стилистикасына хас шрифт композицияләренә татар милли бизәкләре элементларын өстәгән. Хәрефләр бер-берсенә бәйләнгән кебек язылган. Сүзләрне укуы җиңел түгел, ләкин аны аңлаган кеше күп гасырлардан килгән зирәклекнең сихри тәэсиренә эләгә. Бу эш акчаның бүгенге көндә онытылган, беренчел әһәмияте турында да хәтерләтә. Тәңкәләрне бер кулдан икенче кулга күчереп, кешеләр бер-берсенә изге теләк теләгәннәр.

**Йомгаклау**

Бу проектны әзерләгәндә мин татар халкының тарихы һәм гореф-гадәтләре, аерым алганда, туган шәһәрем татарларының тормышы турында бик күп яңа информация белдем. Тикшеренү вакытында темага кагылышлы әдәбият өйрәндем, музейларда булдым, кызыклы кешеләр белән аралаштым.

Татар йолалары, гореф-гадәтләре һәм халык иҗаты бик кызыклы. Иң мөһиме - аларны кадерләп саклау, буыннан-буынга тапшыру, тарихка мәхәббәт тәрбияләү. Кешенең милли традицияләрне тормышында куллануы аны шәфкатьлерәк итә. Безнең белән янәшә яшәүче халыкларның мәдәниятен һәм традицияләрен белү һәм хөрмәт итү бик мөһим.

Әлмәттә татар халкының гореф-гадәтләрен һәм традицияләрен саклыйлар һәм хөрмәт итәләр, алар турында китаплардан яки гаиләдә генә түгел, урам сәнгате аша да белеп була. Милли үзенчәлекләр турында сөйләүнең яңа ысулы буларак мураллар төрле буын һәм милләт кешеләрен үзенә тарта, аеруча балалар һәм яшүсмерләр урам сәнгате белән актив кызыксына.

Халык мәдәниятен урам сәнгате аша өйрәнү, күрсәтү һәм башкаларга җиткерү үзенчәлекләрен өйрәнү вакытында без, интернет һәм кесә телефоннарыннан аерылып урамга чыгу, андагы сәнгать аша милли тарих һәм традицияләр турында белү мөмкинлеге гореф-гадәтләрне аңлату һәм саклауның иң отышлы ысулы дигән нәтиҗәгә килдек.

Үземнең тикшеренү материалларын класстан тыш чаралар үткәрү, туган якны өйрәнү эшендә кулланырга мөмкин. Шулай ук материал әлмәтлеләргә генә түгел, башка кешеләргә дә кызыклы булырга мөмкин, чөнки алар безнең район, илебез тарихының һәм мәдәниятенең бер өлеше булып торалар.

Әлеге проектның **гамәли нәтиҗәсе** буларак лицеебыз укучылары өчен экскурсия үткәрергә ниятлим.

**Әдәбият һәм чыганаклар**

1. Урамнарга чыккан сәнгать. Әлмәт гизү. Искусство во дворах. Прогулки по Альметьевску. – Казань : Изд-во «Юлбасма», 2021. – 64 с.
2. Локальные тексты города. Нарративы и практики жителей / Аналитический отчет. – Самиздат, 2018. – 107 с.
3. URL : https://almetpublic.art/tat

*Кәримова Аделина, 7 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «37 нче күп профильле лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләре: Усманова Рузилә Рәшит кызы,*
*Гыйльмуллина Гөлия Рашат кызы,*
*туган тел һәм әдәбияты укытучылары*

## Серле “40” саны

### Кереш өлеш

Минем фәнни-эзләнү эшемнең темасы: “Серле 40 саны”.

Мин 40 санының серләренә төшенү өчен әдәби әсәрләр, интернет сайтларын өйрәндем. Бу теманы сайлавымның сәбәпләре: өй эше итеп безгә “кырык” сүзе кергән мәкальләр, санамышлар, табышмаклар табып килергә куштылар һәм әлеге тема мине кызыксындырды. Шунлыктан мин 40 санының серләренә ныклабрак төшенергә уйладым.

Төрле әдәби чыганакларны өйрәнү нәтиҗәсендә, мин күп кенә саннарның да нindидер үзлекләре, әһәмиятләре барлыгын белдем, мин 40 санының серләренә төшенергә тырыштым. Әлеге сан кергән әдәби әсәрләр, табышмаклар, мәкаль-әйтемнәр, әкиятләр белән таныштым.

Максатым:

- барлык чыганакларны анализлап, 40 санының барлык серләрен ачу, кайсы өлкәләрдә куллануын белү;
- бу тема буенча анализ һәм нәтиҗәләр ясау.

Бурычлар:

- фәнни эзләнү эшен язу өчен информацияләрне сайлап алу һәм өйрәнү;
- 40 санының кызыклы серләрен ачу.

Эзләнү объекты: саннар, халык авыз иҗаты, китапханә.

Максатка ирешү юллары:

- энциклопедия, дәреслек, белешмәләр, интернет-чыганаклар белән эшләү;
- табылган информацияләрне анализлау.

Эзләнү алымнары:

- әлеге проблема буенча, теоретик белешмәләрне өйрәнү;
- әдәби чыганакларга анализ ясау.

Минем эшем укучыларга, укытучыларга, дәрес вакытында өстәмә материал буларак кулланырга файдалы булыр дип уйлыйм. Мин эзләнүләр вакытында бик күп яңалыклар белдем. Татар телендә кырык саны бик киң таралган.

1.1. **Саннар… Алар безнең тирә-ягыбызда...**

Саннар… Алар безнең тирә-ягыбызда. Әмма күпләр саннарны исәп-хисап мәгънәсендә генә күрә, аларның, бәлки, тагы ниндидер өстәмә мөһим мәгънәсе дә бардыр. Борынгы заманнарда кешеләрнең таш балталары һәм җәнлек тиресеннән тегелгән киемнәре генә була, шуңа күрә саннарга ул хәтле ихтыяҗ булмый. Соңрак хайваннарны кулга ияләштерәләр, уңыш үстереп, аларны җыялар һәм әкренләп сатып-алу белән шөгыльләнә башлыйлар. Монда инде саннар кирәк була. Алдан кул бармаклары белән саныйлар, аннары аякныкына күчәләр. Алар да җитмәгәч, саннарны уйлап табалар.

Тарих битләрен күз салсак, кешеләрнең саннарны язу өчен төрле символлар уйлап тапканнарын күрәбез. Борынгы Русьта саннарны хәрефләр белән язганнар. Беренче 9 хәреф берәмлекне, икенче 9 хәреф дистәне, соңгы 9 хәреф йөзләрне күрсәткән. Мәсәлән 10000 не «тьма» дип атаганнар. Унлы санау системасы индуслардан гарәпләргә, ә гарәпләрдән европалыларга кергән. Саннар турындагы фән үскән, алар турындагы ырымнар, мәкаль-әйтемнәр дә арта барган. Кайберләрен карап китик.

1 саны борынгы кульязмаларда азрак очрый. Бу сан Алла, Космос, Галәм кебек бербөтенне аңлаткан. Борыңгы бабаларыбыз “Бер”ле санында магик көч бар дип уйлаганнар. Ул бердәм һәм бөтен дигән мәгънәне аңлаткан.

3 – магик саннар рәтендә беренче сан. Бу сан белән чын магик исәпләү башлана, аның белән ниндидер яңалык ачыла. Өч көн үтте – чия чәчәге шиңде. Дөньяда өч нәрсә бик кирәк: акыл, белем һәм хезмәт. Өч, өчтән соң көч. һ.б

100 саны - тулы камиллекне күрсәтүче сан. Бөтен, гадәттә, 100 өлешкә бүленә (100%). Эра йөзьеллыкларга бүленә. Халык 100 санын “бик күп” төшенчәсенең билгесе итеп кулланган. Йөз явызлыкны бер дөреслек җиңә. Йөз надан бер галимнең тырнагына тормас.

Борынгы көнчыгышта бигрәк тә 7, 40 саннары танылган булган.

Без мәктәбебез укучылары һәм укытучылары арасында саннар турында сорашу үткәрдек, түбәндәге сорауларны бирдек:

1) Тормышта нинди саннарны ешрак кулланасыз?
2) Саннар кергән мәкальләрне беләсезме?
3) Саннар кергән нинди мәкальләр беләсез?

Сорауларга 34 кеше җавап бирде.Тикшерү барышында шуны ачыкладык:

1) Тормышта нинди саннарны ешрак кулланасыз?

“5” – 32%

“1” – 26%

“4” –24

“2” – 11%

Башка саннар – 7%

2) Саннар кергән мәкальләрне беләсезме?

Әйе – 93%

Юк – 7%

3) Саннар кергән нинди мәкальләр беләсез?

Один в поле не воин – 5 кеше

Одна нога тут, другая там – 3 кеше

Не имей сто рублей, а имей сто друзей – 7 кеше

Лучше один раз увидеть, чем сто раз услышать – 2 кеше

Кыңгыр эш 40 елдан соң да беленер - 3 кеше

Җиде кат үлчә, бер кат кис - 5 кеше

100 сум акчаң булганчы, 100 дустың булсын – 4 кеше һ.б.

Рус халкының “яраткан” саннары булып 1, 2, 100 исәпләнә, ә татар халкында “яраткан” саннар булып 1, 2, 7, 40 тора икән. Без үзебезнең эшебездә 40 санына тукталырбыз.

### 1.2. 40 саны әдәбиятта

Татар халык әкиятләрендә, табышмакларда, мәкаль һәм әйтемнәрдә 40 саны саны еш кулланылган.

*40 саны белән мәкальләр.*

**Мәкаль** - сөйләшкәндә сүзгә ямь һәм куәт бирү өчен, көнкүрештә күп сыналган дәлил яки шигъри бер мисал урынында әйтеп йөртелә торган, кыска, ләкин гомуми бер, тирән мәгънәне эченә алган төгәл җөмләле халык хикмәте әсәре. Мәкальләр системасында зур бер урынны сан сүз төркеме кергән мәкальләр алып тора. Мәкальләр эчендә саннарны өйрәнү зур кызыксыну уята.

1. **Кырык** ел яңгыр яуса да, мәрмәр ташка су үтмәс
2. **Кырык** мирнең көен көйләгәннән бер арбаның чөен чөйләгәнең артык.
3. **Кырык** эт арасында бер этнең койрыгы бот арасында.
4. Кыңгыр эш **кырык** елдан соң да беленер.
5. Кызның яры **кырыктыр**, ише чыкса юлыктыр.
6. **Кырык** кеше бер якка, кырын кеше бер якка.
7. Кырын кеше **кырыгында** таз була, ди.
8. Улга утыз өйдән тыю,
   Кызга **кырык** өйдән тыю.
9. Кызлы кеше капкасына **кырык** ат бәйләнер.
10. Мамык бик җиңел бит ул, мин аның **кырык** потын берьюлы күтәрәм, — дип әйтте ди бер мактанчык.
11. Бәрәңге әйткән: «**Кырык** биш көндә карыныңа керермен»,- дигән.
12. Мокытны **кырык** ел укыт — барыбер мокыт.
13. **Кырык** кеше бер якка, кырын кеше бер якка.
14. **Кырык** каргага бер таш җитә.
15. Коралда **кырык** кешенең көче бар.
16. Бер көн сыйлаганга **кырык** көн сәлам.
17. Кыңгыр эш **кырык** елдан соң да беленер.
18. Бер чынаяк чәйнең **кырык** ел хәтере бар.
19. **Кырык** корама, йөз ялгау.
20. **Кырык** ел чабата ясап, чабатага олтан сала белмәгән.
21. Бер чыраның яктысына **кырык** кеше утыра.
22. Бай бөлгәнче - **кырык** ел, ярлы баеганчы - кырык ел.
23. Ватыласы арба **кырык** көн алдан шыгырдый.
24. Бер дус **кырык** ел сыналыр.
25. Каты агач шарт сынар, черегән агач **кырык** ел чыдар.
26. Авыздан чыккан бер **сүз кырык** кешегә җитәр.
27. Бер кеше тәхеткә менсә, **кырык** кеше атка менә, ди.
28. Коралда **кырык** кешенең көче бар.

40 татар халкының “яраткан” саннарының берсе булса, рус халкында бу сан киң таралмаган. Без берничә мәкаль генә очраттык.

**Сорок** лет - бабий век.

**Сорок** лет не сорок реп.

**Табышмаклар** - фольклор әсәрләренең вак төрләреннән берсе. Табышмак исеменнән күренгәнчә, табу, ягъни ул бүленеп табыла торган әйбер. Ул татар халкында бик нык таралган. Табышмак ике кисәктән тора: берсе-табышмагы әйтелү, икенчесе-чишелеше, җавабы. Табышмагын берәү әйтсә, җавабын икенче берәү табып бирә. 40 сүзе кергән татар халык табышмакларын да очраттык.

Җаны юк, үзе **кырык** төрле тел белә. (Каләм)

**Кырык** бармак, **кырык** тырнак, бер агачта ике яфрак. Ике җанга бер сулыш. (гаилә)

Безнең киленнең **кырык** итәге,

Урамга чыкса җил кайтара. (тавык)

Ак казым **кырык** канатлы булса да очалмый.(Кәбестә).

Кырда **кырык** багана, баганалар саен **кырыгар** бożра, бożра саен **кырыгар** ат, барысы ничә ат? (Алтмыш дүрт мең ат)

*Санамышлар*

Бер, ике, өч, дүрт, биш, Алты, җиде, сигез, тугыз, ун. Байлар кия кызыл тун. Кызыл тунның бәясе - Йөз дә кырык сигез сум.

*Әкиятләр*

Әкиятләрдә дә 40 санын еш очратырга була. Мәсәлән, “Өч күгәрчен” әкиятеннән өзек. “Патша, кызын бу егеткә биреп, кырык көн туен итте, илле көн уен итте, ди. Туй үтү белән, егет кызны үз өенә алып кайтып, әти-әниләре белән бик күңелле итеп көн итә, шуның белән әкият тә бетә”.

“Али-баба һәм 40 юлбасар” әкиятендә дә бу сан белән очраштык.

*Халык ышанулары*

Яңа туган балаларга бик тиз күз тиючән була. Шуңа күрә әби-бабайларыбыз кырык көн булмыйча, күкрәк баласын чит-ят кешеләргә бик күрсәтмәскә кушканнар. Моны безнең әби-бабаларыбыз тикмәгә генә эшләмәгән. Болай итү баланы күз тиюдән саклаган. Гомумән, кырыгы тулганчы баланы ялгыз калдырырга кушмаганнар (төрки халыкларда кырык саны тылсымлы сан булган). “Кырыгы тулганчы баланы ялгыз калдырма, янына пычакмы, кайчымы куй, җен алыштырмасын, усаллар, шайтаннар тимәсен”, —диләр. Кырык көн узгач, бәби туе уздырганнар.

Кешеләр үзләренең 40 яшь тулган көнен бәйрәм итмәскә тырышалар. Халык ышанулары буенча, бу туган көнне билгеләп үтсәң, күңелсезлекләр, кайгылар килергә мөмкин икән.

Аучыларга 40 аю гына ауларга ярый. Кырык беренче аю, шулай ук кайгы-хәсрәт китерергә мөмкин, дип ышанган халык.

Үрмәкүчне үтерсәң, 40 гөнаһың бетәр, имеш.

Шулай итеп, халык бу санның ниндидер сере барына ышанып яшәгән.

### 1.3. 40 саны математикада

40 саны унарлы системада гадәти булмаган сан булып исәпләнә. Элек рус халкында “сорок” дип капчык аталган, чөнки капчыкка 40 тиен яки кеш тиресе сыйган. Бу нәкъ бер тун тегәргә җиткән. Бу акча берәмлеге булып йөргән, чөнки оброк, ясакны тире белән түләгәннәр.

### 1.4. 40 саны медицинада

Кеше баласы 40 атнада ана карынында формалаша.

Бала тапкач, яшь анага 40 көн аеруча сакланырга кирәк. Коточкыч стресс кичергән хатын-кыз организмына элеккеге халәтенә кайту өчен нәкъ кырык көн кирәк икән. Табиблар да ай ярым ял гына итәргә куша, димәк бүгенге медицина да халыкның зирәклегенә таяна.

Халык медицинасында да саннарга шактый урын бирелә. Теш сызласа, табаныңны мунчада кырык тапкыр чабарга кирәк икән.

Элек-электән кайбер куркыныч чирләрнең карантины да нәкъ 40 көнгә сузылган.

### 1.5. 40 саны биологиядә

Кыргаяк (кырык аяк) - буынтыгаяклылар классыннан юеш урыннарда үрчи торган күп аяклы тереклек иясе. Галимнәр ачыклавынча, кыргаякларның төрләренә карап, аяклары 30-400 кадәр булырга мөмкин икән. Әле борынгы заманнардан 40 саны күп дигәнне аңлаткан, шуңа да күп аяклы булганга кыргяк исеме белән атап йөртә башлаганнар.

### 40 саны диндә

Төрле дини китапларда да бу серле сан белән очрашабыз. Ислам дине буенча, Мөхәммәт пәйгамбәргә 40 яшендә пәйгамбәрлек иңә. 40 көнгә бер мөселманнар изге китап - Корьәнне укыйлар. Кеше үлгәч, аның кырыгын үткәрәләр, җанының тынычлыгына дога кылалар.

Христиан динендә Иисус пәйгамбәр 40 көн ашамыйча чүлдә яшәгән. Шул вакытлардан христианнар Пасха бәйрәме алдыннан 40 көннән торган Бөек пост тоталар. Дин буенча, кеше үлгәч, аның җаны 40 көн җир белән күк арасында тора дип санала, шуңа күрә 40 көн үткәч, туганнар җыелып, аны искә алалар.

### Йомгаклау

Саннар… Алар безнең тирә-ягыбызда. Саннар дөньясы бик кызыклы. Әлеге эш белән шөгыльләнгән вакытта мин үзем өчен бик күп кызыклы һәм яңа мәгълүматлар таптым. 40 саны белән якыннанрак таныштым, аның кешелек дөньясындагы урынын ачыграк күрдем. Кешеләр бу санга аерым игътибар биргәннәр. Ләкин әле аның турында барысын да белеп бетерү өчен бик күп укырга, эзләнергә кирәк дип уйлыйм. Тикшеренүләр азагында шундый нәтиҗәгә килдем: саннарның яхшысы яисә яманы юк.

Без саннар белән адым саен бәрелешәбез, алар белән янәшә атлыйбыз, алардан башка яшәүне күз алдына да китермибез. Ләкин язмышыбызны саннарга гына таянып төзергә ярамый, һәркемнең үз бәхете, уңышы, киләчәге үз кулында. Тик бик күп тырышырга, җиң сызганып эшләргә, куелган максатларга ирешергә кирәк. Шул вакытта бар саннар да уңыш, бәхет китерер, киләчәгебез дә якты булыр.

**Кулланылган әдәбият**


1. Аникин, В. П. Русские народные пословицы, поговорки, загадки и детский фольклор. – Москва : Просвещение, 2004.
2. Даль, В. И. Пословицы русского народа. – Москва : Художественная литература, 2003.
3. Пословицы, поговорки. - URL : http://www.poskart.ru/tsifry.html
4. Татар халык мәкальләре. 3 том. Н. Исәнбәт.
5. «Татарча-русча тезмә сүзләр сүзлеге", под редакцией Сафиуллиной Ф. С. – Казань : Татарстан китап нәшрияты, 2002 ел.



*Мингараев Рияз, 8 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының*
*«Каенлы урта гомуми белем бирү мәктәбе»*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләре: Гарипова Лилия Рауф кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
*Гарипов Расим Фаиз улы,*
*тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы*


## Туган ягы кирәк кешегә

### КЕРЕШ

Туган ил кайдан башлана? Бәлки, ул бала аңлый башлагач, әнисенең сөйкемле күзләреннәндер? Бәлки, сабый беренче күргән авыл өстендәге зәңгәр күктәндер? Бәлки, Туган ил турындагы беренче хисләр, уйланулар туган йортта, үзең белем алган мәктәптәндер....

Шулай да, Туган ил ул, минемчә, туган авылыңнан башлана. Кая китсәң дә, авылга тизрәк кайтасы килә, аны юксынасың. Кыскасы, туган авыл һәркем өчен дә бик кадерле ул.

Безгә мәктәптә илебез тарихын, башка илләр тарихын өйрәтәләр, ләкин уку программаларында туган авылның тарихын өйрәнү каралмаган. Минемчә, үзен мәдәниятле, зыялы санаган хәзерге заман кешесе үз авылы тарихын белергә, аның белән кызыксынырга

тиеш. “Үткәнен белмәгән кешенең киләчәге юк” диләр бит. Авыллар тарихы, аның күренекле кешеләре турында материалларны әзме-күпме табарга була. Ил тарихында зур роль уйнаган колхоз- совхозлар турында бик аз өйрәнелгән. Менә мин дә Каенлы авылы тарихында бай урын алып торган колхозлашу чоры, колхоз- совхоз булып торган вакытларын; колхоз җитәкчеләре, иген- кырларында, терлекчелектә хезмәт иткән авыл батырлары турында мәгълүматлар туплый башладым. Табылдыклар белән уртаклашырга булдым.

**Эшемнең темасы**: «Туган ягы кирәк кешегә»

**Проектның актуальлеге**: үз тарихын белмәгән халыкның киләчәге юк. Бала туган җиренең тарихын белергә, шуның аша халыкка якынаерга тиеш. Халыкка якынаю -Туган җиребездә, аның үткән тарихында- колхозлар-совхозлары турында эз калдырган - якташларыбыз, авылдашларыбыз турында сөйләү.

**Проект эшенең максаты**: авылым тарихын, бигрәк тә колхозлашу чорларын өйрәнү.

**Максатыма ирешү өчен түбәндәге бурычлар куелды**:

*авылым тарихындагы колхозлашу вакытына кагылышлы кайбер тарихи документларга, халыктан язып алынган мәгълүматларга таянып, 20нче гасыр башы тарихын яктырту;

*колхозлашу чоры турындагы истәлек - материалларны күбрәк туплау, эзләнүләр алып бару;

*югала барган тарихи материалларны яңарту;

*авылдашлар, якташлар,әби-бабаларымның үткәнен барлау.

Авыллар тарихы, колхозлашу чорлары архивы материалларын анализлау, сораштыру, әңгәмә **алымнар**ыннан файдаландым. Әлеге хезмәтне эшләгәндә миңа Каенлы авылы турындагы китаплар, авылдашларымның истәлекләре терәк булды.

**Теманың өйрәнелү дәрәҗәсе:** проект эшенә тәкъдим ителгән теманы укыгач та, минем күңелемдә бихисап фикерләр туды. Эчтәлекне төрлечә ачарга мөмкин. Тарихи китапларда, энциклопедияләрдә, интернет чараларында бу тема төрлечә яктыртылган. Кемдер колхоз- совхозлар турында уңай фикердә, икенчеләр тискәре уйларын да җиткергән. Нәрсә язсалар да, бу еллар тарих бит инде. Мин дә бу кызык та, шомлы да еллар , илгә яңалыклар алып килгән бу еллар турында үз фикеремне әйтергә булдым.

Проект эше традицион рәвештә кереш, төп өлеш, йомгаклау, әдәбият исемлеге һәм кушымтадан гыйбарәт.

Кереш үз эченә проект эшемнең актуальлеген, өйрәнелү дәрәҗәсен, максатын һәм бурычларын ала.

Төп өлешнең беренче бүлеге Каенлы авыл тарихында колхозлашу чоры,төрле исемдәге колхоз-совхоз булуы, анда хезмәт куйган җитәкчеләре турында мәгълүматларны үз эченә ала.

Икенче, өченче бүлекләрдә мин Бөек Ватан сугышы вакытында авылларның төп эшче көчләре - тыл ветераннары; сугыштан соңгы еллардагы колхоз- совхоз хуҗалары турындагы эзләнүләрем белән уртаклаштым.

Йомгакта нәтиҗәләр ясала, ачыш-табышлар бәяләнә.

Әдәбият исемлегендә хезмәтне язу барышында файдаланылган әдәби, вакытлы матбугатка мөрәҗәгать итүне дәлилләдем.

## ТӨП ӨЛЕШ

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК. КАЕНЛЫДА КОЛХОЗ ОЕШТЫРУ КИРӘК!

Татарстан- серле,тарихи, шанлы , бер гасырлык ил бит ул!

20нче гасырның егерменче елларында авыл хуҗалыгы промышленностьтан һәм ил ихтыяҗларыннан нык артта кала. Сәбәпләре түбәндәгечә: беренчедән, авыл хуҗалыгы таркау була. Беренче бишьеллык башына илдә 25 миллион крестьян аерым хуҗалык булып яши. Тракторлар, авыл хуҗалыгы машиналары, агротехника кулланырга мөмкинлек юк. Нишләргә? В.И. Ленинның кооперация планында күрсәтелгәнчә, эре авыл хуҗалыгына күчү башлана. 1927 нче елның декабрендә үткән XVсъезд авыл хуҗалыгын коллективлаштыруны барлык чаралар белән җәелдерү турында карар чыгара.

Каенлыда да колхоз төзү бик шау-шулы була. Беренче тапкыр 1930 нчы елның 4 апрелендә 25 хуҗалыктан торган колхоз төзелә. Гарәп хәрефләре белән “Колхозның ядрәләре” дип язылган исемлектә партия членнары, ярлылар, урта хәллеләр, хәлле крестьяннар була. **Исемлекне сайтта күрәсез**

Бу вакытта колхозда- 111 җан, 16 ат була. Барлык җир мәйданы- 183 гектар. Беренче язда чәчелгән культуралар: борай(пулба)- 16 га, солы-28га, бәрәңге- 10 га, тары- 2 га, киндер- 2 га, борчак, ясмык, карабодай бергә- 4 га. Бу елны 13 сабан сукасы, 8 тырма, 2 ургыч, 3 чәчкеч, 1 салам кагу машинасы, 1 яргыч, 4 сортировка, 2 окучник, 1 культиватор, 2 сугу машинасы, 1 печән чапкыч, 1 сепарат була.

Колхоз оешкач, идарә әгъзалары итеп Садыйков Гариф, Исламов Риза, Хәйруллин Гомәр сайланып куела. Бу вакытта һәркем эш коралларын: ат, арба(тарантас), чана( кашовка), җигү сбройлары, сабан, тырма берләштерә. Үзенең язгы чәчүгә билгеләнгән җир мәйданын капларлык орлыгын колхоз амбарына илтеп куя.

Колхозчыларның хезмәт вакыты көннәр белән түгел, сәгатьләр белән языла, кимчелекләр дә сәгатьләр белән штрафлана. Яхшы эшләүчеләр шул рәвешле үк бүләкләнә. Ел ахырында 10 сәгать эшне бер көн хисабыннан хезмәт көненә әйләндерәләр.

Миңлегәлиев Исмәгыйльнең хезмәт көне: “ 1931нче елның 10 февраленнән идарә члены булып эшли башлый, хезмәтенә эш сәгатьләре язу эшенә карап билгеләнәчәк. Октябрьдә 240 сәгать языла, ноябрьдә бер ай колхоз рәисе булып эшли һәм шулай ук” 240 сәгать языла.” [4-75 ]

1931 нче елның июнь башында колхозда 48 хуҗалык була. Җәйдән башлап, колхозга керү күмәк төстә оеша, ел ахырында 108 хуҗалык колхоз члены була. Колхоз “Каенлы” исеме белән йөртелә. Район буенча алдынгылар сафында була. Дәүләт алдындагы бурычлар арттырып үтәлә. Колхозның рәисе итеп Садыйков Гариф билгеләнгән була. Дөрес, ул бер үк вакытта бригадир да, хисапчы да, ә язу- сызу эшен башта Федотова Маня, аннары Фәхри Шәрәфиев исемле укытучылар башкара.

1933 елда язгы чәчү тәмлангач колхоз рәисенең колхозчылар алдында ясаган докладын,Фәхри Шәрәфиев язып бара. Менә шул чыгыштан бер өзек.

*“Колхоз язгы чәчүдә 295 гектар җиргә арыш уҗымы чәчте. Гектарыннан 10центнер алырга планлаштыра. Керем эшләре, 1932 елда бер эш көненә икмәкләтә 16, 5 кадак, акчалата 30 тиен түләнә.*

*Төзелешләр турында.62 баш ат сыешлы атлар абзары, Зәй буенда ике ташлы тегермән җиткерелде.*

*Эшкә яраклы ирләр- 64, хатын – кызлар-129, шуларның 26 сы ударник. Икмәк әзерләү планы 1932 елда 7162 пот булып, ул фактта 7169 пот, ягъни 101% тәшкил итә.*

*Колхозыбыз районда алдынгылардан саналган “Ленин” исемендәге колхоз белән ярыша. Язгы чәчүне тәмамлагач уздырылган тикшерү вакытында безнең колхоз алда булып чыкты.*

*Колхозда товарлыклы фермалардан 24 баштан торган сыер фермасы, 109 баштан торган каз фермасы бар. 1932 елда хөкүмәткә 80 баш каз, 5 үгез бирелде. 1май бәйрәме уңаеннан промышленность эшчеләренә колхоз тарафыннан өч яшьлек бер үгез, колхозчылар тарафыннан 2000 данә йомырка һәм бер сыеры булган һәр хуҗалык берәр кадак май бирде.”[4-78-79]*

Колхозның ***беренче рәисе Садыйков Гариф*** 1933 елга кадәр эшли. Аннан соң 6 ел буена ***Миңлегалиев Исмәгыйль*** рәис булып тора. Бу елларда колхозга нәселле маллар алына. Атлар өчен саман( суккан) кирпечтән бик зур сарай төзелгән, түбәсе янмый торган әчетелгән балчыклы салам белән ябылган булган. Колхозга полуторка дип аталган берьярым тонна йөк төяшле “ГАЗ” машинасы кайта. Анда Гайфетдинов Мөхәммәтдин дигән кеше шофер булып эшли. Сугыш башлангач, машина фронтка озатыла.

1939 елда колхоз рәисе итеп ***Ибраһимов Миңлевәлине*** сайлыйлар.

Сугыш башлангач, шулай ук сугыштан соңгы иң авыр вакытта колхоз белән ***Фазлый Нуриев*** идарә итә. Бөек Ватан сугышы елларында колхозда төп эшче көч булып хатын-кызлар, яшүсмерләр, балалар, картлар кала. Еллар бик авыр булса да, колхозда эш туктамый. Сугышка атларны да алганга, сөрү җирләрен үгезләр белән эшкәртәләр.

“Каенлы” колхозыннан сугышка алынган атларның берсе турында бик кызыклы истәлек күпләргә таныш. “...1942 елның җәендә Ширәмәт военкоматыннан атларны да фронтка озатырга боерык килә. Берничә колхозчы, билгеләнгән атларны туплап, Бөгелмәдә вагоннарга төйиләр,аннары Горький өлкәсендәге бер станциягә кадәр озатып, тиешле кешеләргә тапшырып кайталар. Атлар арасында бик елгыр “Молот” исемле алаша да була.

Көз җитә. Дәүләткә ашлык тапшыру башлана. “Каенлы”дан берничә яшүсмер ашлык төягән олаулар белән Кама буендагы Смыловка пристанендә урнашкан икмәк кабул итү пунктына китәләр. Кайтканда болында туктап ял иткәндә, әрәмәләр арасыннан ат кешнәгән тавыш ишетелә. Күп тә үтми атның үзе дә күренүгә егетләрнең берсе: “Бу бит безнең “Молот”!- дип кычкырып җибәрә. Бар да бу хәлгә гаҗәпләнәләр. Ат “авылдашлары” на ияреп авылга кайта. Әлбәттә, бу хәл район военкоматына хәбәр ителә. Берничә көннән “Молот” яңадан сугышка мобилизацияләнә. Авылдан алып чыгып киткәндә, атның күзләрендә елтыраган яшь тамчыларын күреп, озатучылар тыела алмыйча еладылар,”- дип искә ала Каенлы авылы тарихын язучы Фәхри абый Шәрәфиев.[4-82]

## ИКЕНЧЕ БҮЛЕК. КОЛХОЗЧЫ ТОЛ ХАТЫННАР, ЯШҮСМЕРЛӘР

Бөек Ватан сугышы елларында тылда калганнар өчен дә тормыш бик авыр була. Колхозның төп эшче көчләреннән булган авыл апалары, кызлары турында мәгариф ветераны, шул ук вакытта сугыш ятиме Саимә апа Сөләйманова үзенең күңелендә йөрткән авыр сагышларын, әтисен югалту ачысын, бәхетсез яшьлеге турында “Зәй сулары ага тора..” китабында искә ала."...Өйдә калган хатын-кызлар көне буе авыр эш башкара. Өенә кайткач та эш көтә. Ярый әле иреннән хат килгән булса. Хат урынына кара печать сугылган кәгазь дә ишекне шакуы бар бит. Хатыннарның бар курыкканы шул: балалар ятим калмасын." Саимә апа Каенлы авылының тыл ветераннарына багышлап “Авылдашларыма мәдхия” исемле шигырен дә иҗат итә.

Сугыш елы авырлыгы
Барыгызга да тиде:
Хәерниса ат караса,
Маһруй бригадир иде.
Кирәк булса, сез булдыгыз
Яшь килен дә, егет тә.

Урманнарда йөрдегез сез
“Пуховойны” җигеп тә.
Алма кебек Зөһрәләр
Яшь көе тол калдылар.
Колхоздагы авыр эшне
Алар тартып бардылар...[2-80]

Саимә апаның балачагы, яшьлеге дә сугыш, сугыштан соңгы авыр елларга туры килә. “Сугыштан соңгы елларда колхозны алга өстерәүчеләр, әлбәттә, 13-14 яшьлек малай-шалайлар иде. Көн дә яшьтәшләремә наряд бирелә: кайсына үгез җигеп сукага, тырмага чыгарга, кайсыларына икмәк төяп, Смыловкага илтеп тапшырырга. Ярый ла, ат сбруең рәтле булса. Алары да я юкәдән, я сүстән ишеп ясалган була. Дилбегәсе дә өзелеп аптырата. Ничә җирдән төенләргә туры килә.”[2-81]

Өлкән яшьтәге мәгариф ветераны үзенең истәлекләрендә бик җылы хисләр белән ул вакытта колхозның авыр йөген иңнәрендә тартучы колхоз рәисе Фазлый Нуриевны искә ала. “Бик авыр еллар. Яшьтәш малайлар белән, без дә, кызлар да, Ташлык әрәмәсен дә урлап кистек, Смыловкадан тоз да ташыдык, юа эзләп Аргы болынга да барып чыга идек. Безгә тәгәрмәчләре кыек-мыек йөри торган ат арбасына утырган Фазлый абый очраштыргалый. Ул безне орышмый, арбасына утыртып кайта иде, ә урланган әйберне күрмәмешкә сабыша иде. Мин ул рәисебезгә әле дә рәхмәтемне укыйм, догадан калдырмыйм. Кызлар, тырышып-тырышып, я колхоз басуларында, я яшелчә бакчасында, я ындыр табагында булыштылар.” [2-83]

Бу елларда иген басулары белән беррәттән күксагыз (каучук бирә торган күпьеллык үсемлек), кукуруз, бәрәңге, киндер, җитен дә үстерәләр, ә һәр басулардагы чүп- үләнне кул белән утаганнар. Колхозның шулай ук яшелчә һәм җиләк-җимеш бакчасы да булган. Анда кәбестә, кыяр, кишер кебек яшелчәләр үстерелгән, ә алма бакчасына мал-туар кермәскә дип, койма- киртә урынына, һәр кешегә бүлеп, канау казырга кушканнар.Тагын Саимә апаның истәлекләренә тукталабыз. “ Кешеләр төшке ашка кайтып китәләр. Без иптәш кызым белән су гына эчәбез дә, үзебезгә тигән өлешне казыйбыз да казыйбыз. Ник казымаска! Яшелчә бригадиры безне гел мактый: “Болай эшләсәгез, сезгә колхоз берәр сарык бирер әле”, -ди. Казыдык. Тик безгә дигән сарык бәрәнләмәгән булган икән шул. Их, юләр балачак!”[2-90 ]

## ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК.СУГЫШТАН СОҢ КОЛХОЗ-СОВХОЗЛАР ТАРИХЫ

Ике дистәгә якын Каенлыда “Каенлы” колхозы булса, күрше авыл Кече Җирекледә “Ерыклы” колхозы эшләп килә. 1951 елда ике колхоз берләшеп “Каенлы” колхозы дип йөртелә башлый.

1956 елда Казан заводларының бер эшчесе ***Камалиев Мирзаһит*** утыз меңенче сыйфатында Каенлыга җибәрелә һәм колхоз рәисе вазыйфасына керешә. Камалиев М. рәислек иткән чорда колхозда күп кенә төзелеш эшләре башкарыла. Кырда, ындыр табагы янында агач бүрәнәләрдән уртак стеналы күп санда амбарлар кордыра.

Авыл чатындагы таш кибет өстенә өскорма рәвешендә алты почмаклы колхоз идарәсе итеп корыла. Уңыш үстерү дә зур үсешкә ия була. Иген уңышы ун центнердан артыграк була.

1959 ел башында Кече Аты( Үчкә), Тоба авылларын берләштергән “Якты юл”, Байданкино һәм Байгыл авылларын эченә алган “Кызыл Зәй”, “Каенлы” колхозлары берләшеп, март аенда “Кызыл Зәй” колхозы оештырыла. Колхоз үзәге Каенлы авылында, ә колхоз председателе итеп ***Иманаев Рәхим Фәрди улы*** сайлана. Бу елга хәтле яшәп килгән өч авыл Советы да берләштерелә, “Каенлы авыл Советы”на туплана.

Иманаев Рәхим абый рәислек иткән чорда колхозда бик күп үзгәрешләр, төзелешләр башкарыла. Каенлыда: 1960 елда колхоз конторына яңа бина салына. Сельпо конторы, амбулатория(ФАП), агач мәчет сүтелеп, клуб җиткерелә. 1959 елның җәендә Байгыл авылында эчке янулы двигатель белән эшли торган станция төзелә. Станция колхоз составына кергән авылларны электр энергиясе белән тәэмин итә. 1960 елның мартында биш авылны берләштергән Борок авыл хуҗалыгы артеле “Кызыл Зәй” колхозына кушыла. Шулай итеп “Кызыл Зәй” колхозы 11 торак пунктны үз эченә ала.

1962 елда Иманаев урынына Түбән Уратмадан китерелгән ***Ризванов Назыйм Ризванович*** сайлана. Ул рәислек иткән чорда МТП( машина-трактор паркы) төзелә. Колхозга тракторлар гына түгел, йөк һәм җиңел машиналар кайтарыла башлый.

1961 елда акчага реформа булганлыктан, 1963 елда колхозчыларга хезмәт көненә акча да бирә башлыйлар. Тик бу уйланып бетерелмәгән сәясәт булып чыга, колхозчыларга натуралата түләү киредән әйләнеп кайта.

“Кызыл Зәй” колхозы, 1963 елда Ширәмәт районы бетерелгәнлектән, Яр Чаллы районына карый башлый.

Бу вакытта колхозчыларның берничәсе кер юу машиналары сатып алган була. Өйләрдә чикләнмәгән күләмдә лампочкалар яндыра алганнар. Колхоз тегермәне дә электр энергиясе белән эшли башлый. 1964 елның декабрендә Каенлы авылында Ибраһимов Нурислам беренче телевизор да сатып ала.

1967 елның гыйнварында Н.Ризванов башка эшкә күчү сәбәпле, ***Нурислам Ибраһимов*** колхоз рәисе вазыйфасына куела. Ул 1970 елның мартына кадәр “Кызыл Зәй” колхозы белән идарә итә. Ул төзелеш эшләренә игътибар биргән. Шуларның берничәсен әйтеп үтәм: кирпечтән ашханә салдыра. Авыл уртасында ике катлы бина калкып чыга. Анда

колхоз идарәсе, авыл Советы, партия комитеты, радио челтәре, почта, саклык банкы, телефон станциясе урнаша. 1968 елда авыл урамнарында траншеялар казыла. Су колонкалары куела.1971 елның 1сентябрендә 320 урынга исәпләнгән мәктәп төзелеше тәмамлана.

1970 елның мартында колхоз совхоз итеп үзгәртелә. Н. Ибраһимовны ***Хәйруллин Нурулла Хәйруллович*** алыштыра. "Совхоз зур үзгәрешләр кичерә." "Гыйнвар башында совхоз үзәге булган Каенлыда 360 урынлы яңа клубка нигез салынды. Шул ук авылда барлык уңайлыклары булган 16 фатирлы ике катлы торак йорт төзү эше башланды. Төзүчеләр аларны 1974 елда файдалануга тапшырачаклар." Бу турыда "Ленин нурлары" район газетасында1нче ПМКның баш инженеры Н.Кутилинның мәкаләсе басыла.[1-"Ленин нурлары"]

Бу төзелешләргә кушылып авыл кырында котельная бинасы корыла. Авылдан Чистай юлына кадәр 4 километр озынлыкта дамба күтәрелә. 1973 елның мартында авылга Түбән Камадан беренче автобус килә. Нәкъ менә шушы айдан "Кызыл Зәй" совхозы директоры итеп ***Әхмәтшин Габделбәр Салихович*** куела. Ул "Кызыл Зәй" совхозы белән 22 ел җитәкчелек итә. Совхоз белән идарә итү шактый катлаулы, хуҗалык 11 авылны берләштерә, аларның бер-берсеннән шактый читтә урнашканнары да, арада кечкенә авыллар да бар, ә ул елларда кечкенә авылларны бетерү, эреләндерү политикасы бара. Габделбәр Салихович барлык авылларны саклап калу бурычын куя. Моның өчен:

-Һәр авылда мал тотарга, мал булса халык яши.

-Халыкны шәһәргә китүдән туктатырга куша.

Яңа төзелеп килүче Түбән Кама шәһәре кешеләрне магнит кебек үзенә тартып тора. Моның өчен мәдәният учаклары төзергә, юлларны төзекләндерергә, су мәсьәләсен хәл итәргә, торак йортлар җиткерергә була. Каенлыда өчәр катлы тагын ике йорт, Үчкә авылында икешәр фатирлы бер катлы биш йорт калкып чыга. Соңрак мондый йортлар Тоба, Кече Җирекле авылларында да салына. Яшәү,эшләү өчен шартлар тудыру өчен дә күп эшләр башкарыла. Орлык киптерү, Тоба, Каенлыда силос траншеялары, 1000 баш сыярлык комплекслар сафка баса. Шулай ук Красный Бор, Борок авылларында терлек абзарлары, җәйге лагерьлары төзелә. Борокта һәм Каенлыда бәрәңге, ашлама, орлык саклау складлары салына. Каенлы сигезьеллык мәктәбе, җиткерелгән дүрт йорт газ белән җылытуга күчерелә. Үчкәдә башлангыч мәктәп ремонтлана , Тобада башлангыч мәктәп яңадан төзелә. Каенлы мәктәбендә янкорма булып тир ачыла. Инеш елгасы аша язгы ташуда агызылмый торган капиталь күпер сафка баса. Габделбәр Салихович 1995 елда башка эшкә күчерелә.

"Кызыл Зәй" совхозы белән 1995-1999 еллар аралыгында совхозның баш экономисты булып эшләгән ***Галиев Марат Әхәтович*** һәм ***Алмаз Фаррашович*** идарә

итәләр. Районда күрсәткечләре буенча алдынгылар рәтендә йөргән совхоз бу чорда артка тәгәри. Шул сәбәпле, “Кызыл Зәй”нең дәрәҗәсен күтәрергә Түбән Кама УМСы җитәкчесе ***Риан Һадиевич Мотыйгуллинны*** чакыралар. Риан Мотыйгуллин совхоз белән идарә итә башлагандагы хәлләр турында искә ала: “Совхоз бетү, таралу алдында тора. Маллар бик нык кимегән, ашатырга салам да юк, фураж турында әйтмим дә. Чәчү вакыты җитте, техника төзек түгел, симәнә җитәме- юкмы, белгән юк. Беренче көннән Аксардан фураж кайтартып, сыерларның тамагын туйдырып, сөт күләмен арттырдык. Җәйге лагерьларны ремонтлап, савым сыерларны болынга озаттык. Кырларга күп итеп бодай. Арыш утырттык. Көзен гектарыннан уртача 35 центнер бодай җыеп алдык. Алдагы елларда совхоз кырларына шикәр чөгендере дә чәчтек. Чөгендерне немец технологиясе белән утырттык. Германиядән үк инженер- агрономнар килде. Чит ил белгечләре белән мин - татарча, алар немецча сөйләшә идек. Һәрвакытта да мин алар белән килешми идем. Бервакыт мин бер белгеч белән ачуланышып торганда , хәтта Илсур Метшин да килеп чыкты. Чөгендер утыртуның технологиясен үземчә аңлап эшләгәнгә, башлык хуплады да”, - дип исенә төшерде Риан абый.

Риан Мотыйгуллин “Кызыл Зәй” совхозы, соңрак “Каенлы” күмәк хуҗалыгы белән 2008 елга хәтле идарә итә. Аннан бу хуҗалык “Бәхетле-Агро” күмәк хуҗалыгының “Каенлы” бүлекчәсенә әверелә. Шулай итеп, 70 еллык “Каенлы” колхозы, совхозы тарихы шушының белән тәмамлана.

## ДҮРТЕНЧЕ БҮЛЕК. “КЫЗЫЛ ЗӘЙ” ХУҖАЛЫГЫН АЛАР ҖИТӘКЛӘГӘН.

Ике дистә елдан артык “Кызыл Зәй” колхозы- совхозы белән идарә иткән ***Габделбәр Салихович Әхмәтшин*** турында күп сөйләргә була. Ул 1939 елның 29 мартында Кызыл Чапчак авылында эшче-крестьян гаиләсендә икенче бала булып дөньяга килә. Әтисе 1943 елда Ватан сугышында һәлак була. Габделбәрнең балачагында колхозда ат та көтә, урман кисүдә, йөк ташуда да катнаша. Авылда урта мәктәптә укый. 3 ел флотта хезмәт итә. армиядән кайткач РТСта техник- электрик, нормировщик, агроном булып эшли. Читтән торып Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлый. 1967 елдан Сухрауда “Память Ильича» совхозында агроном булса, ә 1973 елда “Кызыл Зәй” совхозына директор итеп куела һәм 22 ел җитәкче булып эшләгән.

Габделбәр Салихович 1995 елда район авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең җир һәм үсемлекчелек өлкәсендә баш белгече – үсемлекчелек бүлеге начальнигы итеп билгеләнә

70 яше тулып үткәнче яраткан эшен башкара. Авыл хуҗалыгына керткән зур хезмәте өчен Әхмәтшин Г.С. югары оешмалар тарафыннан күп тапкырлар бүләкләнгән, авыл

хуҗалыгы казанышлары күргәзмәләрендә катнашкан. “Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре” исеменә лаек булган.

***Мотыйгуллин Риян Һади улы***

Мотыйгуллин Риян Һади улы 1940 нчы елда Тобада туа. Каенлыда җидееллык мәктәп бетергәч, урта мәктәпне Кызыл Чапчакта тәмамлый. 1959-1962 елларда армиядә була. Аннары бригадир, электрик булып эшли. 1965-1969 елларда Чистай авыл хуҗалыгы техникумын бетереп 18 ел дәвамында “Кызыл Зәй” совхозында баш инженер; 1988-90 елларда Түбән Кама сельхозтехникасында баш инженер, 1991-95 елларда “Тоба” хуҗалыгында директор; 1995-99 елларда Түбән Камада УМС та начальник; 1999-2008елларда “Каенлы” күмәк хуҗалыгы директоры булып эшли.

Риян Һадиевич, яхшы җитәкче буларак, күп грамоталар белән бүләкләнгән. 2000нче елда “Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре”, 2005 елда “Россия Федерациясенең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре” исеме бирелә. Шул ук елда әлеге җитәкченең исеме “Россиянең иң күренекле кешеләре” “Лучшие люди России ”энцеклопедиясенә кертелә. Бу энцеклопедиягә Түбән Кама районнан бары ике кешенең исеме теркәлгән. Риан абый турында җылы фикерләрне “Туган як”газетасында язып үтәләр: “Гомеренең 50 елын авыл хуҗалыгына багышлаган Риян Мотыйгуллин. Заманында «Кызыл Зәй» совхозында баш инженер булып эшләгән, ул совхоздан бер техникасыз аерылып чыккан «Тоба» хуҗалыгын аякка бастыра алган Риян ага бу тантанада ясаган чыгышында элекке колхозлар чорында техниканың күп булуын, һәр эшне җиренә җиткерүләрен сөйләп үтте.” [3- “Туган як”]

Әхмәтшин Г.С. “Кызыл Зәй” совхозы белән идарә иткәндә, оста җитәкче белән бергә кулга- кул тотынышып уңган җитәкче- агрономнар да үз көчләрен куялар. Күп еллар совхоз район күләмендә бар яктан да алдынгылыкны бирми. “Ленин нурлары” газетасының 1990 елның 59нчы санындагы 27 мартында бастырылган Р.Хәйруллинның “ Кырга чыгар алдыннан” мәкаләсеннән өзек : “ Кызыл Зәй” совзозы басуларының уңдырышлылыгы күп хуҗалыклары җирләреннән ярлырак, әмма былтыргы нәтиҗәләргә карасак, “Кызыл Зәй”дә 18, центнер уңыш җыелып алынган. ...“Кызыл Зәй” дә күп еллар игенчелек ветераны, элекке баш агроном Татарстанның атказанган агрономы Фаяз Галиуллин туфракның уңдырышлылыгын яхшырту өстендә эшләде. Хәзер ул пенсиядә. Аның эшен баш агроном М. И. Гыйниятуллин уңышлы дәвам итә.” [1- “Ленин нурлары”]

### ***Алдынгы агрономнар***

***Галиуллин Фаяз Заһидулла улы***

Галиуллин Фаяз Заһидулла улы 1924 нче елда Каенлыда дини гаиләдә туа. Әтисе колхозга керми, күп еллар авылның мулласы булып тора. Фаяз абый Бөек Ватан сугышында

катнаша, батырлыклар эшли, орден- медальләр белән бүләкләнә.1948 елда авылдашы Әлфия апага өйләнә, 7 бала тәрбияләп үстерәләр.1952нче елдан агроном булып эшли.

Хөкүмәтебез фидакарь хезмәтләрен искә алып, Галиуллин Фаяз абыйга “Татарстанның атказанган агрономы” дигән мактаулы исем бирә, Почет билгесе ордены һәм күп санлы Мактау кәгазьләре белән бүләкли.
2013 нче елда 88 яшендә вафат була.

***Гыйниятуллин Мәхмүт Исмәгыйль*** улы

Гыйниятуллин Мәхмүт Исмәгыйль улы 1951 елның 2 нче декабрендә Чирмешән районы, Яңа Кади авылында тугыз балалы колхозчы гаиләсенең бишенче баласы булып дөньяга килә. 1959 елда башта сигезьеллык мәктәбен тәмамлый, аннан урта белем ала. 1970 елда Лениногорскийда шофёрлар әзерләү курсын тәмамлап, колхозда шофёр булып эшли. Шул ук елның көзендә Совет Армиясе сафларына алына. Армиядән соң бер ел туган авылында кабат шофёр булып эшли. 1974 елда Казанга күптәнге хыялын тормышка ашырырга, югары белем алырга китә. Туган туфрагын, табигатьне ратканга, сайлаган киләчәк һөнәрен дә Мәхмүт җир белән бәйли. 1979 елда агроном белгечлеге дипломын кулына алып Каенлыга юллама белән эшкә җибәрелә һәм “Кызыл Зәй” совхозына бүлекчә агрономы булып эшкә урнаша. Совхозның баш агрономы Галиуллин Фаяз Заһидулла улы лаеклы ялга киткәч, Мәхмүт Исмәгыйль улы аның урынына кала. 2004 нче елга хәтле баш агроном булып эшли.

Мәхмүт Исмәгыйль улы үзен яхшы оештыручы, сәләтле белгеч, җаваплы җитәкче итеп күрсәтә. Аның фидакарь хезмәте хөкүмәт тарафыннан югары бәяләнә, бик күп Мактау граматалары бирелә, ә 2002 елда “ Татарстанның атказанган агрономы” дигән мактаулы исемгә лаек була.

## ЙОМГАК

Туган җир... Туган авыл. Йөрәккә нинди якын, кадерле сүзләр. Безнең һәрберебезнең газиз туган йорты, нигезебез урнашкан кадерле туган авылы бар. Һәр авылның үзенә хас кабатланмас, истә кала торган урыннары күп. Кая гына барсак та, нинди генә матур урыннарны күреп соклансак та, туган төбәгебезнең гүзәллеген бер ни дә алыштыра алмый.

Авыллар, колхоз-совхозлар... Аларда безнең үткән тарихыбызның бер өлеше, халыкның моңы, кайгы- шатлыгы, куанычлары һәм сагышлары, халкыбызга җиң сызганып хезмәт итүче данлыклы кешеләре бар.

Мин үземнең хезмәтемдә авылым тарихындагы колхозлашу вакытына кагылышлы кайбер тарихи документларга, халыктан язып алынган мәгълүматларга таянып, 20нче гасыр башы тарихын яктырттым; колхозлашу чоры турындагы истәлек- материалларны күбрәк тупларга тырышып ,эзләнүләр алып бардым; югала барган тарихи материалларны

яңартым; колхоз-совхозларда эшләгән кайбер җитәкчеләр, авылдашлар белән очраштым. Күбрәк белергә омтылдым.  Эшемнең ахырында мин максатыма ирештем дип әйтә алам. Бу эзләнүләр минем яшьтәшләремә дә кызык булыр дип уйлыйм.

“Еллар үткәч, ташны казып алып әйткән халкым:минем җирем бу!

Бабаларым шунда гомер иткән, минем авылым, минем нигез бу!”- дип  сүземне йомгаклыйм.

## ӘДӘБИЯТ


1.“Ленин нурлары”газетасы Н. Кутилин “Совхоз зур үзгәрешләр кичерә.” 28.01.1973; Р.Хәйруллин  “Кырга чыгар алдыннан” №59, 27.03.1990

2.Сөләйманова, С. “Зәй сулары ага тора”Түбән Кама, 2013,80-81, 90б.

3.“Туган як” газетасы  “Районның 50 еллык тантанасында” мәкаләсе, 25.03.2015

4.Шәрәфиев, Ф. “Каенлы авылы тарихы”Казан, 2009, 75, 78-79, 82



*Шакирова Язиля, 9 нчы сыйныф,*

*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «22 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*

*Җитәкчесе: Аменова Эльмира Зуфар кызы,*

*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*


## Гаилә – буыннарның өзелмәс чылбыры

## КЕРЕШ

Халкыбызда элек-электән якыннарга, кардәш-ыруга хөрмәт, кайгыртучан мөнәсәбәт, туган илгә мәхәббәт яшәгән. Бу сыйфатлар борынгылар тарафыннан югары бәяләнгән: Илен белмәгән – игелексез,

Халкын белмәгән – холыксыз,

Ә нәселен белмәгән - нәселсез,- дигән тәкъбир безне әхлаклы булырга өнди. Шулай ук «Җиде буыныңны бел!» дигән гади, ләкин искиткеч нәсыйхәткә халкыбызның тирән тарихы сыйган. Юкка гына балалар шагыйре Ш.Галиев:«Исәннәрнең кадерен бел, үлгәннәрнең каберен бел,»- дип язмаган. Гаилә тарихын өйрәнүне һәм белүне мин бик мөһим дип саныйм.Мине һәрвакытта да туган ил, гаиләм, туган нәселдәшләрем тарихы кызыксындыра.Туган як тарихыннан читкә китеп тә, үз нәселеңне белмичә яшәп, туган ил тарихын өйрәнү мөмкин түгел. Нәселебез турында күбрәк мәгълүмат туплау өчен төп максат итеп үз нәселеңнең  тарихын,  гореф - гадәтләрен өйрәнүне, нәсел агачын төзүне һәм аны киләчәк буынга  тапшыруны куйдым. Максатны ачыклау өчен түбәндәге **бурычларны** билгеләдем**.**

1.Нәсел агачына кергән нәселдәшләрем, туганнарым турында мәгълүмат җыю.

2 Тарихи материаллар, биографияләр,фоторәсемнәр туплау.

3. Исән булган иң олы туганнар белән очрашу.

4. Шәҗәрәләр төзергә өйрәнү.

5. Туганнарыма карата мәхәббәт хисләре тәрбияләү.

**Актуальлеге.** Без, хәзерге заман балалар, үткән буын әби - бабаларыбыз турында аз беләбез, ә борынгы бабаларыбыз моны тугыз буынга кадәр белергә тиеш дип санаганнар, һәм мин шуның өчен дә үз нәсел агачымны төзү белән шөгыльләнә башладым. Практик үзенчәлеге. Факультатив шөгыльләрдә укучыларны нәсел агачы төзергә өйрәтү.

**Эзләнү методы.**

1. Әти- әнидән, әби- бабайдан сорашу.

2. Гаилә документларын , фотоларын карау,өйрәнү.

3.Туганнар турында матбугатта басылган мәкалә - язмаларны өйрәнү.

## Төп өлеш

### Шәҗәрә төзү эшен нидән башларга?

Өлкән буын белән яшьләр арасындагы мөнәсәбәт, рухи элемтә – мәңгелек мәсьәлә ул. Яшьләрне тәрбияләүдә өлкәннәр тәэсире бик кирәк. Шул очракта гына яшь кешегә үз нәсел шәҗәрәсен үзләштерү өчен уңай шартлары туа. Өлкәннәргә хөрмәт алар белән бергә яшәгәндә күбрәк чагылыш таба. Хәзер шәһәрдә генә түгел, авылларда да ата- анасы, улы, оныгы белән бергә яшәү сирәк күренешкә әйләнеп калды. Гаилә әгъзалары арасында аралашу да тансык бер шөгыль була бара. Бу хәл буыннар чылбырының йомшаруына, кардәшлектә аралашу өзелүгә китерә, гаилә традицияләренең, гореф – гадәт һәм йолаларның буыннан – буынга күчемлелеген тоткарлый.Шуңа күрә монда иң мөһиме шул: һәр әби- бабай һәм ата- ана үз баласына ике якның да нәсел шәҗәрәсендәге бабаларның тормышы, эш- гамәлләре турында сөйләп, өлкәннәргә хөрмәт тәрбияләргә, гадәт- йолаларны балаларга тапшырырга тиеш.Мин үземнең бабамнар белән бик горурланам. Алар үз һөнәрләрен тапканнар, бәхетле гаилә корганнар. Балаларын үстереп тормышка аяк бастырганнар. Җиде буынга кадәр үз нәсел – нәсәбәңне белү – һәркем өчен гадәти хәл булган.Без, бүгенге көн яшьләре, җиде буыныбызны беләбезме? Минем бабаларым кемнәр булганнар? Шушы сорауларга җавап эзләү мине әлеге хезмәтне эшләргә этәрде. «Һәр кеше үзенең җиде бабасын белергә тиеш, -диләр борынгылар.Шулвакытта гына кеше туган иленең, туган төбәгенең үз халкының үткәнен яхшы белә» Халкыбызда борын- борыннан җиде буын әби-бабаңа кадәр үз нәселеңнең буыннарын күңелдән белү һәм нәсел шәҗәрәләрен кәгазьгә теркәү гадәте булган. Шәҗәрәләр белү, язып бару- матур һәм борынгы гадәт. Алар аркылы кешеләр ата- бабаларының дәвамчысы булуларына

төшенгәннәр. Нәрсә соң ул шәҗәрә? Гарәп теленнән кергән «шәҗәрә» сүзе агач дигән мәгънәне белдерә. Буыннарның өзлексез алмашынып торуын ботаклы агачка охшатып төзелгән шәҗәрәләр язу,нәсел шәҗәрәсен төзү гадәте борынгы заманнар да ук халыкларда билгеле булган.

1. Эшне иң элек әби-бабайлардан, нәселнең иң өлкән кешеләреннән үз нәселең турында сораштырудан башларга кирәк. Иң кирәкле мәгълүмат: әби-бабайларның исеме, фамилиясе, әтисенең исеме, туган елы, үлгән елы һәм туган урыны.

2. Бигрәк тә кешенең туган урынын белү мөһим. Исемнәрен, туган елларын гадәттә беләләр, ә менә туган урыннарын күпчелек белми икән. Монда буталчык чыгуы мөмкин: чөнки Мөхәммәд, Гали яисә Кәрим һ.б. исемле кешеләр районның бу авылында да, теге авылында да бар - ә нәсел җепләре бер үк чыганакка барып тоташмый.

3. 100 елга кадәр мәгълүматны район ЗАГС бүлегендә табарга була. Аннан әлеге материаллар Дәүләт архивына күчә.

Шәҗәрә - нәсел агачы, бабаларыңның әллә ничә буынга кадәр исемнәрен, дөньядан үтү тәртипләрен белү дигән сүз. Димәк, шәҗәрәнең төп чыганагы – гаилә, әти – әниләр, әби-бабайлар.

Шәҗәрә төрләре:

*Күтәрелә баручы шәҗәрә* – бу шәҗәрәдә аерым бер кешедән башлыйлар, аннан соң буыннар буенча атасына, бабасына, бабасының атасына һ.б., билгеледән билгесезлеккә баралар.

*Төшә баручы шәҗәрә* - бу шәҗәрәне иң ерак ата-бабадан башлыйлар һәм аннан соңгы яшерәк буыннарга күчәләр.

*Ирләр шәҗәрәсе* – анда ирләрдән килеп чыккан буыннарны гына күрсәтәләр, хатыннары янәшә язып куела.

*Катнаш шәҗәрә* – анда ир-ат һәм хатын кыз рәте буенча барлык ата-бабаны күрсәтәләр.

*Туганлык шәҗәрәсе* – булган якын туганнар языла. Шәҗәрәнең язылу формасы төрле булырга мөмкин.

**Минем нәсел шәҗәрәм**

Мин – Шакирова Язилә Рөстәм кызы, 9 нчы сыйныфта белем алам. Гаиләбездә яхшы күңеллелек, өлкәннәргә хөрмәт, үткәннәр белән кызыксыну кебек сыйфатлар беренче урында тора. Шуңа күрә без әтием ягыннан да, әниемнең дә нәсел агачын үзебездә саклыйбыз, аны өйрәнәбез, эзләнү эшләре алып барабыз. Һәр ике яктан да туганнарыбыз якты эз калдырган. Бу эшемдә мин әнием ягыннан нәсел агачына мөрәҗәгать итәм. Бу эшемне язганда ярдәм итүче Миннәхмәт бабам белән Дания әбием булды. Алар әниемнең

этисе белән әнисе. Хәзерге вакытта Балык Бистәсе районы Тәберде Чаллысы авылында яшиләр. Нәсел турындагы төшенчәне бозмас өчен, шәҗәрә ирләр ягыннан төзелде.

Әниемнең этисе Әхмәдиев Миннәхмәт Мөнир улы. Ул 1958 елда Балык Бистәсе районы Тәберде Чаллысы авылында туа. Туган авылында урнашкан сигезьеллык мәктәпне яхшы билгеләргә генә, үрнәк тәртип белән тәмамлый. Тугызынчы, унынчы сыйныфларда укуны Миннәхмәт бабай күрше авылда урнашкан Котлы Бүкәш урта мәктәбендә дәвам итә.

Алар гаиләдә 6 бала үсеп, төрлесе төрле уку йортларында белем алалар. Олы абыйлары Мансур Бөгелмә шәһәрендә электриклар училищесын тәмамлый, Мәхмүт абыйсы авиация институтын тәмамлый, Нурзия апасы педагогия институтны сайлый, Нурия апасы медицина институтында укый. Миннәхмәт бабай Мәхмүт абыйсы киңәше белән авыл хуҗалыгы институтына укырга керә. Чөнки кече энеләре тумыштан авыру булу сәбәпле, әнисен һәм энесен тәрбияләү өчен авылда төпләнеп калырга кирәклеген яхшы аңлый ул....1976 -1981 елларда Казан авыл хуҗалыгы институтында укый һәм уңышлы тәмамлый. 1981- 1983 елларда Армия сафларында хезмәт итә. Аның армиядәге хезмәтендә узган юлын бик югары бәялиләр. Шунда бөтенләй калырга тәкъдим итәләр. Югары хезмәт хакы, уңай шартлары тудырылган фатир вәгъдә итәләр. Әмма бабай бу кызыктырып торучы тәкъдимгә риза булмый. Чөнки аны туган нигезендә олыгайган, тәрбиягә мохтаҗ булган әнисе(этисе 1 нче курста укыган вакытта вафат була), тумыштан авыру энесе, һәм «сөйгән яры» көтә. Армиядән кайткан елны, 1983 елның 2 декабрендә тормыш корып җибәрә. Шул көннән башлап Дания әби белән алар гел бергә. Ул туган авылда, туган нигездә төпләнеп кала. Әнисен һәм авыру энесен тәрбияләп соңгы юлга озата. Туган авылда өлкән инженер, өлкән хисапчы, колхоз рәисе, авыл җирлеге үзидарәсе рәисе булып эшли. Хәзерге көндә лаеклы ялда.

Миннәхмәт бабайның этисе Әхмәдиев Мөнир Мөхәммәтша улы. Ул 1919 елны Казан губернасы Лаеш өязе Тәберде Чаллысы авыланда туган.14 яшеннән хезмәт юлын колхозда тимерче булып башлап җибәргән. Армия сафларына алынганчы ул тимерче, калайчы, комбайнчы, слесарь булып эшләгән. ТАССРның Биектау районы Усады мехонизаторлар мәктәбен бетергән.1940 нчы елның октябреннән 1941 елның январь аена кадәр Литваның Вильнюс шәһәрендә 501 гаубич артиллерия полкында наводчик ярдәмчесе булып хезмәт итә. Аннан соң 1941 нче елның июненә кадәр Литваның Таурага шәһәрендә слесарь булып эшләгән.1941-1946 елларда Ленинград һәм Волхов фронтларында Кутузов исемендәге 1 нче мина - инженер бригадасында рядовой, автослесарь булган. Алар сугыш кырында ватылган техниканы ремонтлап кире фронтка җибәргәннәр. Бабабыз калай-тимер эшләренә оста булгач, пилоткаларга беркетелә торган йолдызларны да ясаган. «Ленинградны саклау өчен», «Германияны җиңү өчен» медальләре бар. 1945 елның 30 май приказы белән Мөнир

бабай «Кызыл йолдыз ордены» белән бүләкләнгән. Сугыштан соң тормыш юлын комбайнчы булып дәвам иткән. 1977 елны 58 яшендә йөрәк авыруы белән үлгән. Мөнир бабайның тормыш иптәше Әхмәдиева(Низамова) Нурсабах Низаметдин кызы турында да мәгълүмат тупладык. Ул 1919 елны Казан губернасы Лаеш өязе Тәберде Чаллысы авыланда туган. 1933 нче елны Балык Бистәсе районы Тәберде Чаллы авылында 5 классны тәмамлый. 1935 елда шул ук җирлектәге Калинин исемендәге колхозга гади колхозчы буларак эшкә керә. Бөек Ватан сугышы елларында аларны урман кисү, окоплар казу эшләренә җибәргәннәр.1995 елның 8 октябрендә вафат була. Мөнир бабайның этисе Мөхәммәтша турында мәълүмат юк.

**3.Гаиләмнең традицияләре, гореф-гадәтләре.**

Минем гаиләм бик дус һәм тату. Без һәрвакыт үзара аралашып, ярдәмләшеп яшибез. Миннәхмәт бабай белән Дания әбинең йорты төп йорт булу сәбәпле элек-электән ул барлык туганнарны үзенә сыйдырган, туганнарны очраштыру, аралаштыру урыны булып тора. Әбием дә, бабам да бик юмарт, ачык йөзле кешеләр. Сабантуй, Ураза гаете, Корбан гаете бәйрәмнәргә туган нигезгә бабайның туганнары агыла. Әбинең туганнары да монда еш очраша. Нурсабах әбине һәм этинең тумыштан авыру энесен карап,тәрбияләп соңгы юлга озатканга барча туганнар да әби белән бабайга бик рәхмәтле. Кулларыннан килгәнчә һәрвакыт ярдәмгә килергә торалар, безнең гаиләне бик якын итәләр. Бабай да, әби дә намазда. Бабай җомга намазына мәчеткә йөри. Безнең гаиләдә Ислам диненә карата хөрмәт бик зур. Әни дә, сеңелләре Гүзәлия белән Лилия студент елларыннан бирле намаз укыйлар, мәктәп елларыннан бирле Рамазан аенда Ураза тоталар. Хәзер инде әби-бабай йортында бергә җыелып (3 кодагый, 3 кыз гаиләсе) авыз ачу, сәхәр ашау, я мәчеттә туганнар белән җыелышып ифтар ашы үткәрү традициягә әйләнеп китте. Авылда булганда бабайны бергәләп җомга намазына озатып калабыз. Әби бабайны һәр җомгадан мәчеттән кайтканын чәйләрен куеп, кайнар коймаклар пешереп каршы ала. Бабай мәчеттә булганда, әби янына 3 кызы тезелеп басып(хәзер инде мин дә намазга бастым) намаз укыйбыз, намаздан соң әбинең Коръән укыганын утырып тыңлыйбыз. Соңыннан әрвахларга догалар кылабыз, теләкләр телибез.

Әби белән бабай бер-берсенә карата ихлас мәхәббәт хисләре кичереп, бер-берсенә ихтирам һәм хөрмәт белән бик матур яшәгәннәр. Бабай һәр елны әбинең туган көненә(27 апрель) аның яраткан чәчәкләре-кызыл розалар бүләк итә иде. Хәзер, соңгы елларда, бу гадәт тагын да матурайды. Бабай бик иртә торып урманга менә һәм әбинең уянган вакытына күп итеп умырзаялар җыеп төшә. Шундый романтик, нечкә күңелле кеше дә безнең бабай.

Гаиләбездә бәйрәмнәр, туган көннәр дә искиткеч күңелле уза. Бәрәңге утырту, казу,печән әзерләү кебек авыр эшләрне дә бергәләшеп бик җиңел һәм күңелле итеп

башкарабыз. Безнең нәселнең иң яраткан бәйрәме-Сабантуй. Без бу көнне барыбыз да төп нигезгә җыелабыз, бер-беребезнең хәлен беләбез, табын артында сөйләшеп утырабыз. Аннан соң барыбыз бергә җыелып Сабантуйга чыгабыз. Төрле уеннарда катнашып, җырлап-биеп күңел ачабыз, ял итәбез.

Безнең авылыбызның үзенчәлекле аерым гореф-гадәте бар. 1 нче Май Хезмәт бәйрәме көнне балалар йомырка җыярга чыгалар. Элек бабайлар җыйган, аннан әниләр, хәзер инде оныклар йомырка, конфет, шоколадлар җыярга кайталар. Балалар йомырка җыйганда, олылар бакчаларны чүптән тырмалый, җир казый, бергәләшеп өй юа. Ә кич белән түгәрәк өстәл әзерләп, хәләл итләрдән шашлык кыздырабыз. Элек бабай-әбиләр яшьрәк чакта урманга менеп табигать кочагында ял итә торган булганнар. Хәзер балалар, кияүләр, оныклар белән өйдә яисә беседкада табын корып ял итәбез. Бәйрәмнәрдә бүләкләр ясап бирешәбез. Ислам динендә бәйрәм булып саналмаса да, Яңа елга әби-бабай да безгә - 6 оныгына матур Яңа ел күчтәнәчләре әзерли. Һәр чирек азагында мәктәптә укучы оныкларын яхшы укыганнары өчен акчалата бүләкли. Бу безгә киләсе чиректә дә тырышып укырга стимул булып тора.

Шәхсән безнең үзебезнең гаиләдә ел саен әти белән әнинең 1 нче сентябрь- белем бәйрәменә, мәктәпкә безнең белән барулары, гаилә белән фотога төшү матур традициягә әверелеп китте.

**III. Йомгаклау.**

1.Мин үземнең гаилә шәҗәрәсен төзегәндә шуны аңладым: әби-бабаларны өйрәнгәндә кеше туган иленең, туган төбәгенең, туган йортының, үз халкының тормышын өйрәнә, татар милләте тарихы белән якыннан таныша.

2.Гаилә шәҗәрәсен төзегәндә бик күп истәлекләр белдем. Әби-бабайлар сөйләгәннәргә нигезләнеп нәсел шәҗәрәмне төзедем. Мондый фәнни эзләнү эшләрен тормышка ашыру өчен хыял, теләк һәм синең алдыңда максат булырга тиеш, ә инде шул максатны тормышка ашыру өчен тырыш хезмәт кирәк.

Тарихка сәяхәт кызыклы да, катлаулы да эш. Мин бу сәяхәт вакытында үз нәселемнең зур, эшкә кыю, куркусыз икәнлеген аңладым. Үткәннәрне барлап, киләчәк өчен зур байлык калдыруым белән чиксез горурланам.Буыннар чылбырын өзмичә, һәр буын, гаилә тарихына үзеннән өлеш кертеп, үткәннәр белән киләчәк буыннар арасында арадашчы ролен оста башкарса, нәселнең киләчәге өметле булачак. Шәҗәрәңне, ягъни нәсел агачыңны белү, эзләү - синең дә, минем дә, безнең дә игелекле бер эшебез булсын иде.

Фәнни эшемне тәмамлап шуны әйтергә кирәк, милләтебезнең киләчәге өметле, әгәр дә һәр нәсел гаилә төзеп, сау —сәламәт балалар тәрбияләсә. Нәсел агачлары корымасын алар гел тармакланып торсын.

## Кулланылган әдәбият.

1. http://www.matbugat.ru

2. http://www.myheritage.com

3.Кулъязмалар, архив материаллар,гаилә фотолары.

4.Әхмәтҗанов, М. И. Татар шәҗәрәләре. – Казан : Татар. кит. нәшр.,1995. - 128 б.

4.Биктимерова, Ә. Т. Минем шәҗәрәм. – Казан : Мәгариф, 2000 ел.

5. Гарифуллин, Д. И.Шәҗәрәләр. – Яр Чаллы, 2002.

6. Протащук, И. Ю. Генеалогиягә кереш (нәселне өйрәнү). – Хәтер, 2009. – 182б.

*Шәяхмәтов Камил, 8 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының*
*Муса Җәлил исемендәге «1 нче гимназия»*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Хәйруллина Гөлназ Рәшит кызы,*
*туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

## Изге Коръән – могҗиза

### Коръән нәрсәдән гыйбарәт?

Коръән—дөнья әдәбиятының борынгы үрнәге, шул ук вакытта ул фәлсәфә китабы да. Монда кешелек дөньясының язмышы, Җир йөзендә кешенең тоткан урыны турында фикер йөртүләр, Кешегә, аның яшәү рәвешенә, фигыль-гамәленә карап бәя бирүләр зур урын алып тора. Шуңа күрә Коръәнгә дин күзлегеннән генә карау җитми, аңа фән күзлегеннән дә карарга кирәк.

Русиядә иң беренче Коръән Санкт-Петербург шәһәрендә 1787 нче елда Әби патша (Екатерина II) фәрманы белән нәшер ителгән. Коръәнне басмага Казанның имам-муллалары әзерләгән, шунлыктан аны “Казан басмасы” дип тә атап йөрткәннәр. Бу тиңдәшсез зур гамәлнең башкарылуына 225 ел тулу уңаеннан, 2012 нче ел Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан җөмһүриятебездә Коръән елы дип игълан ителде. Изге Коръәннең сүрә-аятьләре безгә Аллаһның Үз Сүзләрен ирештерә. Шунлыктан, Коръән Кәрим – хакыйкый дин гыйлеме, туры юл күрсәтә, дөрес итеп гамәл-гыйбадәт кылырга өйрәтә торган китап кына түгел, ә иң югары әдәп-әхлак үрнәге, кешелекнең һәм җәмгыятьнең барча авыру-проблемаларыннан дәва, акыллы-зирәк үгет-нәсыйхәт, дөнья-ахирәт, тормышыбызның игелеге-бәрәкәте-тынычлыгы ачкычы да. Кыскасы, адәм баласының, яисә җәмгыятьнең бүгенге көндә нинди мохтаҗлыгы бар – һәрбарчасының чишелеше Коръән Шәрифтә бик тәфсилләп аңлатылган. Бу уңайдан,

дөньякүләм танылган берничә галимнең Коръән турындагы фикерен карап узыйк әле. “Коръән сүрәләрендә күпкырлы белем һәм кеше башына килердәй һәрбарча сорауга җаваплар тупланган” (Ю.Абрамов, В.Демин. “100 Великих Книг”, Москва, Вече, 2000). “Коръән – шигырь төзелеше буенча да, тантаналы олылау, тормыш-көнкүреш зирәклеге буенча да – бердәнбер булган әдәп-әхлак, дин, гражданлык, сәяси һәм юридик Хөкем-Кануннар Җыентыгы” (В.Порохова. “Коран, перевод смыслов и комментарии”, VI басма, Москва, Әл Фуркан, 2002). Нинди дөрес сүзләр-фикерләр. Олуг Коръән бербөтен китап итеп иңдерелмәгән, ә аерым аятьләр рәвешендә, тормыш барышында килеп туган сорауларга-вакыйгаларга аңлатма-җаваплар буларак, Пәйгамбәребезгә 40 яшь тулгач, 23 ел дәвамында яңа эраның 610-632 елларында иңдерелгән. Мөхәммәд (с.г.в.) исән вакытта, Коръәнне китап итеп җыю кирәк тә, мөмкин дә булмаган: беренчедән, мөселманнар килеп туган һәр сорау-проблемага җавап-чишелешне Пәйгамбәрнең үзеннән ала алган; икенчедән, Коръәннең иң соңгы аяте Пәйгамбәребезнең вафатыннан 10 гына көн алдан иңгән. Шулай итеп, бу кыска гына вакытта Коръән сүрәләрен китап итеп җыю, билгеле инде, мөмкин булмаган. Беренче хәлиф (Пәйгамбәрнең эшен дәвам итүче) Әбү Бәкр р.г. заманында (632-634 еллар), Коръән аятьләрен язып, китап рәвешендә җыйганнар; икенче хәлиф Гомәр р.г. заманында (634-644 еллар) Коръән берничә данәгә ишәйтелгән; ә өченче хәлиф Госман р.г. заманында (644-656 еллар), Коръәннәрне дөрес итеп укый-аңлата белүчеләргә тапшырып, дөньяның төрле ягына таратканнар. Коръәннең дөрес укылуы-аңлатылуы җәһәтеннән, бу бик кирәкле гамәл булган, чөнки Ислам дөньясы киңәйгән, Коръәннең бердәнбер нөсхәсе (оригиналы) белән генә Аллаһ Юлына өндәү инде мөмкин булмаган. Риваятьләр буенча, иңдерелгән сүрә-аятьләрнең Җирдә дөрес әйтелеше-укылышы һәр елның Рамазан аенда Җәбраил фәрештә тарафыннан тикшерелеп торган. Раббыбызның Изге Китабы: “Укы!” – дигән Алла боерыгы белән иңдерелә башлаган. Бу әмер бик ачык, төгәл, катгый. Шунлыктан, Хира (“сөекле”) дигән тау куышы караңгылыгында Пәйгамбәребезгә иңдерелгән әлеге беренче изге аять-күрсәтмә, өммәтнең белем дөньясына таба юл алуына иң зур сәбәп-этәргеч булган. Ә нәрсә укырга боера соң безгә Бер Раббыбыз? Бу турыда Коръәндә катгый күрсәтмә юк; әмма шул ук аять безне, нәрсә генә укысаң да: “Юктан бар итеп яралтучы Раббың исеме белән башлап укы!”– дип өйрәтә. Димәк, бу гади күз йөртеп чыгу гына түгел, ә башка яссылыкта-биеклектә, үз алдыңа аерым-үзенчәлекле максат куеп уку; бик зур игътибар белән, тирәнтен уйлап, тормышка-көнкүрешкә үз карашыңның нинди булуын тикшереп карау гамәле. Шулай итеп, бу әмерне “Укы!” гына дип түгел, ә “Аңларга тырыш!” дип тә кабул итәргә; үзеңә, әйләнә-тирәңә, дөньяга күңел күзе белән карарга тырышырга бурычлыбыздыр, мөгаен. Һәрбер кеше – телиме ул моны, теләмиме – барыбер үзен-үзе өйрәнү (“уку”) белән мәшгуль.

## Изге Коръән – Аллаһы могҗизасы

Галәмнәрнең Бөек Серләре ачкычы Коръән Хәкимдә саклана. Олуг Коръән – Аллаһ тарафыннан кешелеккә (!) бүләк ителгән искиткеч Могҗиза; матур, тыныч, бәхетле яшәр өчен иң дөрес һәм гадел җитәкчелек. Бөек Коръәнне укый белү (аңлау!) – адәм баласы өчен бик зур ярдәм, Бер Раббыбыз тарафыннан бүләк ителгән бик зур өстенлек.Тирә-юнь мохит “китабын” һәм Изге Коръәнне уку-өйрәнү ярдәмендә, кеше үз тормышының “китабын” яза һәм бу “китап”ның эчтәлеге безнең Җирдәге тормышыбызда да, бакый дөньяда да ни рәвешле яшәячәгебезне бик төгәл билгели.

Коръән Кәрим инде 14 гасыр дәвамында кешелекне хәйран калдыра торган могҗиза булып тора. Шөбһәләрне бетерү юнәлешендә гелән яңа ачышлар ясала. XX гасырның 70-80 елларда компьютер технологияләре хасил булгач Коръән Кәримдәге сүзләр һәм хәрефләр җәһәтеннән өйрәнелде.

Мәсәлән, Коръәндә «дөнья» (әд-дунья) вә «ахирәт» (әл-ахирә) сүзләре бер дәрәҗәдә 115 мәртәбә кабатлана.

«Шайтан» һәм «фәрештә» сүзләре вә алардан ясалган сүзләр дә Коръәндә бер күләмдә — 88 мәртәбә очрый. «Үлем» сүзе вә аннан ясалган сүзләр 145 мәртәбә кабатлана һәм шул ук вакытта «хәят» вә аннан хасил булган сүзләр дә 145 мәртәбә кабатлана. Димәк нихәтле терек булса, шул хәтле үлем дә Коръәндә «дин» вә аннан чыккан сүзләр 92 мәртәбә, «мәчет» сүзе дә 92 мәртәбә кабатлана «Иман» сүзе вә аның төрләре 811 мәртәбә телгә алына. Ә «гыйлем» сүзе — 782 мәртәбә вә аның синонимы булган «мәгърифәт» сүзе 29 мәртәбә кулланыла, «гыйлем» вә «мәгърифәт» сүзләренең санын кушсак (782 вә 29) 811 була, ягъни гыйлем вә мәгърифәт ничә булса, иман шулчаклыдыр. Коръәндә күкнең җиде өлештән торуы әйтелә. Аллаһ бу хакыйкатьне Коръәндә җиде тапкыр әйтә, ягъни күкнең җиде икәнлеге җиде кат әйтелә. Күкне һәм җирне алты көн эчендә яратылганы да 7 тапкыр әйтелә. Фатиха сүрәсе дә 7 аятьтән гыйбарәт. Тәмугның 7 өлеше булуы да әйтелә. Шаһәдәт сүзтезмәсе дә 7 сүздән тора: «Лә иләһә иллә аллаһу, Мөхәммәдәр рәсүлүллаһ». Кадер сүрәсендә 30 сүз бар. Кадер кичәсен үз эченә алган рамазан ае да утыз көннән килә. «Бәхетсезлек» сүзе һәм аннан чыккан сүзләр Коръәндә 102 мәртәбә телгә алына һәм «сабыр» сүзе төрләнешләре белән дә 102 мәртәбә очрый, димәк, нихәтле кыенлык килсә, шул хәтле сабыр итү кирәк. «Җәза» вә аннан килеп чыккан сүзләр 117, кыямәт көненә чын йөрәктән ышанганнарны гафу итүче «әл-мәгъфирәт» сүзе һәм аның төрләре нәкъ менә ике тапкыр күбрәк — 234 мәртәбә кабатлана. «Коръән» сүзе 80 мәртәбә телгә алына, ә аның иңү ысулын күрсәтүче «вәхи» сүзе дә 80 тапкыр кулланыла. Коръәндә рәсүл сүзе төрләре белән 368 тапкыр, нәби сүзе 75 мәртәбә, «яхшы хәбәр китерүче» сүзе — 18 мәртәбә, «коткаручы» сүзе — 57 мәртәбә. Һәммәсе — 518. Инде иманлыларга яхшы хәбәр китерүче вә хәвефтән

əгəһ кылучы пəйгамбəрлəрнең исемнəре ничə тапкыр зикер ителгəнен санап чыгыйк: Муса — 136, Ибраһим — 69, Нух — 43, Йосыф — 27, Лут — 27, Гыйсə — 25, Адəм — 25, Һарун — 20, Исхак — 17, Сөлəйман — 17, Ягъкуб — 16, Давыт — 16, Исмəгыйль — 12, Шөгаеб — 11, Салих — 9, Һуд — 7, Зəкəрия — 7, Яхъя — 5, Мөхəммəд (Əхмəд) — 5, Əюб — 4, Юныс — 4, Əл-Йəсагъ — 2, Ильяс — 2, Идрис — 2, Зүл-Кифел — 2, Ильясин — 1. Һəммəсе 518 тəшкил итə. Гыйсə һəм Адəм г-млəрнең исемнəре бер күлəмдə телгə алынган. Чөнки Аллаһ əйтə: «Хакыйкатьтə Гыйсə Аллаһның каршында Адəм кебидер…» Шунысы гаҗəп, «ай» сүзе 12 мəртəбə кабатлана, «көн» сүзе — 365 тапкыр, «көннəр» сүзе 30 мəртəбə, ягъни бер айның көннəре санынча телгə алына. Мондый күпсанлы төгəллеклəр очраклы була алмый, əлбəттə! Коръəн — ул чын могҗиза китабы, аның буенча яшəүчелəр димəк хакыйкый бəхет ияларедер. Күптəн түгел генə Коръəнгə кагылышлы таган бер истəлекле вакыйга булды: Казанга республикабызның “Яңарыш” фонды заказы буенча эшлəнгəн дөньядагы иң зур Коръəн китабы кайтарылды һəм 2012 елның маенда Болгар җиренə урнаштырылды. Италиянең “Реверра ЛТД” компониясе тарафынан эшлəнгəн 623 битле, 1,5 х 2м үлчəмдəге əлеге изге китапның авырлыгы 800 кг.

**Коръəн фəнгə юл күрсəтə**

Гомернең иң читен, җайсыз, уңгайсыз бер минутында,
Əгəр янсам каты хəсрəт вə кайгының мин утында,
Укыйм тиз-тиз күңелдəн гаҗаиб сүрə Коръəннəн,-
Газаплар мəгънəви бер кул илəн алынадыр җаннан.

Г.Тукай

Коръəн – мөселманнарның изге китабы һəм гарəп əдəбиятының классик ядкаре. Лексик яктан бу сүз гарəп телендə “уку”, “яттан сөйлəү”, “кычкырып уку”, “китап” мəгънəлəрендə белдерелə. Коръəннең тууы Мөхəммəд пəйгамбəрнең эшчəнлеге белəн бəйлəнгəн. Бу тарихи зат якынча 570 нче елда Гарəбстандагы Мəккə шəһəрендə туа. Кырык яшендə аңа Аллаһы тарафыннан Җəбраил фəрештə аша Коръəн китабы иңдерелə башлый һəм 23 ел дəвамында 114 сүрə иңə. Ул Ислам динен тотучылар өчен төп кулланма. Анда динебезнең кануннары, тəгълиматлары яктыртыла. Шул ук вакытта, аны куллана алган кеше тарихтан, фəлсəфəдəн, тел гыйлеменнəн күп кенə мəгълүматлар белəн таныша. Хəзрəти Ибене Мəсгуд (р.г) əйткəн: “Əгəр гыйлем эстəсəң, Коръəн мəгънəлəренə төшенер өчен фикер йөрт, чөнки ул əүвəлге заманнарның тарихын да, хəзерге заман вакыйгаларын да бəян итə.” Һəр фəн иясе телəсə өстəмə материалны Коръəннəн таба ала. Чөнки дөньяви гыйлемнəр дə Аллаһы Тəгалə куйган кануннарны өйрəтə. Физика, химия, биология, математика яки бүтəн фəннəр – алар барысы да Аллаһының җир йөзенə урнаштырган кагыйдəлəрен өйрəтəлəр. Бу китапка карасак, анда дини йолалар, гыйбадəтлəр белəн

беррәттән күп төрле фәннәргә кагылышлы мәгълүматлар бар. Ул безгә космос, медицина, тарих, икъдисад һәм сәясәт кебек фәннәр турында хәбәрләрне күпләп бирә. Шуларны карап китик әле. Бу китапта бернәрсә дә төшеп калмаган, дөньядагы бөтен әйберләргә дә, күренешләргә дә аңлатма бар. Аллаһы Тәгалә: “Без бу китапта зекер итмичә һичбер нәрсәне төшереп калдырмадык,”- дип әйтә. Тагы бер аятькә туктарбыз. “Без дөньядагы бөтен тере җан ияләрен судан хасил иттек,”- ди Аллаһы Тәгалә. Адәм балаларының, хайваннарның тәннәрендә һәм, гомумән, табигатьтә су булмаса, дөньяда тереклек тә булмас иде. Коръән-Кәрим моның турында сөйли, каяндыр эзләп тә йөрисе түгел. Чөнки хәзерге заман ачышлары Коръәндә инде ничә гасыр элек сурәтләнгән булган. Бу Коръәннең дөрестән дә бер могҗиза булуын күрсәтә. Метеорологлар исәпләгәнчә, Җирдән секунд саен 16 млн тонна су парга әйләнә. Елга аның күләме 505 трлн. тоннага җитә. Иң гаҗәпләндергәне шул: ел саен Җир өстенә явучы яңгырның да күләме шул кадәр икән. Ягъни, ел саен 505 трлн. тонна су парга әйләнә һәм 505 трлн. тонна ява. Димәк, табигатьтә бертуктаусыз тигез күләмдә, төгәл билгеләнгән пропорцияләрдә су әйләнеше бара. Яуган һәм парга әйләнгән суның гаҗәеп тигезлеге турында галимнәр әле соңгы елларда гына белделәр. Ә “Коръән”дә бу турыда 14 гасыр элек кешелеккә хәбәр ителгән булган. 1962 нче елда Аден култыгы һәм Кызыл диңгез сулары очрашучы Баб-эль- Мандеб бугазында Һинд океаны һәм Кызыл диңгез суларының үзара катнашмавы билгеле була. Атлантик океан һәм Урта диңгез сулары кушылган җирдә дә шундый тикшеренүләр үткәрәләр. Гибралтар бугазында, инде меңнәрчә еллар буе очрашучы ике су массалары үзара катнашырга, аларның тозлылык һәм тыгызлыклары бертөрле булырга тиеш кебек, Ләкин алар, кушылган урыннарының иң якын җирләрендә дә үз сыйфатларын саклыйлар, әйтерсең лә, нindидер пәрдә аларның катнашуына комачаулый. Ике диңгез суларының кушылуына комачаулаучы физик көч “өслек тартылышы көче” дип атала, һәм ул диңгез суларының төрле тыгызлыгы нәтиҗәсендә барлыкка килә. Океанологларның XX гасырның соңгы чирегендә уздырган тикшеренүләре нәтиҗәсендә билгеле булган фәнни фактлар “Коръән”дә VII гасырда ук чагылыш тапкан. “Аллаһ берсе – татлы, берсе тозлы ике диңгезне янәшә агызды. Аларның арасында Аллаһның кодрәт пәрдәсе бардыр, сулары кушылмас” (“Коръән” 55:19 – 20).

Фән галимнәре 19 нчы гасыр азагында Коръән белән кызыксынып китәләр. Үзләренең фәнни эшләрен эшләгән вакытларында теге яки бу күренешкә гаҗәпләнеп, иманга килеп, ислам динен кабул итүчеләр дә бар. Алар бу аятьләрне дөрес дип табалар. Шуларның берсе – Франция галиме Жак Ив Кусто. Ул – дөньяда танылган галимнәрнең берсе. Океаннарда, диңгезләрдә тикшерү эшләре белән шөгыльләнүче. Нобель премиясе Лауреаты, үзенең ачышы турында газета битләрендә язып чыга. Ачыш шуннан гайбарәт: кайбер океаннарның, диңгезләрнең сулары икегә бүленгән, бер ягы тозлы, икенче ягы

тозсыз су; алар арасында күзгә күренми торган пәрдә бар, бер-берсенә кушылмыйлар икән. Бу ачыш турында мөселман галимнәре укып карагач, бер дә гаҗәпләнмиләр, бары тик аңарга хәбәр генә бирәләр: “Бу күренешне сез ачмадыгыз, моның хакында “ Аллаһы Тәгалә Коръән – Кәримдә 1400 ел әүвәл әйтеп куйган. (Әррахман сүрәсе,18-19 аять) Жак Ив Кусто, бу хәбәрне ишеткәч, исе китеп: Әгәр Мөхәммәд пәйгамбәрнең тикшерә торган кораллары – микроскоп, лупалары булмаса, ничек белсен ул бу күренешне?! Мөхәммәд (с.г.в.) укый-яза белмәгән, диңгез, океан күрмәгән. Юк, пәйгамбәр сүзе генә түгел, бу – бөек Аллаһының сүзләре. Бу хәл аңа Ислам динен кабул итәргә сәбәп була. Жак Ив Кусто зур галим генә түгел бик зур хөрмәт иясе булып санала. Аның артыннан бик күп кешеләр иманга киләләр. Бүген исә Париж шәһәренең үзендә генә дә 105 мәчет бар. Франциядә 1200 мәчет эшли, ә европаның иң зур мәчете Лондон шәһәрендә төзелгән. Тагын бер гаҗәп нәрсә белән танышып китик. Лондонда мәшһүр “Британия”музее бар. Анда килгән һәр кеше иң башта мумияләр бүлеге белән кызыксына. Бүлектә пыяла савыттагы сәҗдәгә киткән кеше мәете аеруча игътибарыны җәлеп итә. Бу мәетнең эчендәге бөтен әгъзалары үз урынында, хәтта чәче белән сакалы да сакланган. Кыскасы, аңа кеше кулы тимәгән, ул мумияләштерелмәгән. Үлгән кешенең берничә атна эчендә таркалуы һәркемгә билгеле. Ә менә бу мәетнең 3000 ел дәвамында черемичә, таркалмыйча саклануының сере нәрсәдә? Бу сорауга җавап изге Коръән аятьләрендә бирелгән. Анда тасвирланган вакыйгалар безнең көннәрдә исбатланды. “Юныс”сүрәс 92 нче аятен тәфсирләгәндә мондый аңлатма бирелә: “Сине диңгез ярының бер читенә ыргытырбыз – мәетең таркалмаган булыр, бозылмас, анадан тума ялангач гәүдәңне синнән соң килгәннәргә гыйбрәт булсын өчен сакларбыз”. Аять һәм тәфсир Фиргәвен мәетенең мумияләнмәвен, төгәл булачагын да белдерә. Чөнки мумияләнгән мәетнең эчке органнары алына. Бу җәһәттән дә тиңе булмаган мәет аять һәм тәфсирләренең дөреслеген тагын бер кат раслый. Әйе, бер мәетне 3000 ел буе бозмыйча саклау изге китап хуҗасы булган Раббыбызга кыен түгел. Коръән 14 гасыр буена үзенең барлык хакыйкатьләрен кешелек алдында таныта бара. Һәркем, һәр милләт, һәр ил аннан файдалана. Шуңа да карамастан, кыйммәте кимеми, тәгълиматы картаймый, нуры сүнми. Бу – үзе бер олы могҗиза. Ислам диненең фәнне үстерүне яклавын, Коръәндә кыю һәм тәвәккәл фәнни фикерләр булуын дәлилләгән тагын бер бик үзенчәлекле аять бар: “ Әгәр көчегез җитсә, җир вә күкләр читеннән үтеп китегез! Юк, үтә алмассыз, мәгәр күп көч вә күп белем, күп мал белән үтәрсез.” (55 нче сүрә, 33 нче аять). Шулай итеп бөтендөнья тарту көче, аны җиңү, галәмгә чыгуны тәэмин итә торган, төп фикерләр турында күпме гасырлар элек үк бик кыю итеп әйтелгән булган. Әлеге сүзләрнең дөреслеген бүгенге чынбарлык ышаначлы дәлилләде. Космосны үзләштерү, чыннан да, чиксез тырышлык һәм тәвәккәллек, тирән һәм күпкырлы белем, бик зур матди чыгымнар таләп итә икән шул.

Коръәндә соңгы гасырларда гына ачылган табигать законнары һәм күренешләре турында әйтелгән сүзләр дә бар. Бу уңайдан 79 нчы сүрәсенең 29, 30 нчы аятьләрендә: “Ул төнен караңгы ясады, көнен якты итте, моның соңында Аллаһ, торырга яраклы итеп җирне түшәде,” – дип әйтелә. Ягъни: ул җирне җәеп салды, диелә 30 нчы аятьтә.“Дәхә” сүзе гарәп телендә “җәеп салу” һәм “түгәрәкләү” мәгънәсенә ия. Бу аятьтә әлеге тирән мәгънәле сүз кулланылган. Җир өстән “җәелеп китсә” түгәрәк формага ия була. Коръән фәнгә каршы түгел, ул фәнне үстерүне яклый, анда шул чор үсем дәрәҗәсендә фәнни фаразлар, гыйлем эстәүгә омтылыш хуплана. Нинди генә шартларда да белемле булу, белем алу кирәклеге ассызыклана. Коръәндә гыйлем сүзе 782 тапкыр кабатлана. Коръән сүзе гарәп телендә үзе дә “уку” мәгънәсендә бирелә. Хәтта Мөхәммәд (с.г.в.) гә дә таулар арасында йөргәндә тавыш килә: “укы, укы, укы”. Шуннан соң беренче “Икъра бисми раббикәлләзи халәкъ,” дигән аять иңә. Мәгънәсе – “укы”. Бу кешенең дөньяда яшәвенең максатын һәм бурычын бирә, кешедә мәгърифәткә, белем алуга, һәр төрле һөнәр өйрәнүгә кызыксыну, омтылыш уята. Шулай ук уку турында хәдисләр дә бик күп: “Һәр кеше өчен гыйлем эстәмәк фарыз”, “Гыйлемнән зур хәзинә юк”, “Бишектән алып ләхеткәчә гыйлем алыгыз”… Бу китапта кешеләрнең, хайваннарның, җир, күк, тау, үсемлекләрнең һәм башкаларның ничек яратылуын күзәтергә, өйрәнергә өндәү күзәтелә. Коръәндә һәм хәдистә баланың яралуы һәм ана карынында ничек үсүе бик ачык бәян ителә. Яралгының 41 нче көнендә малаймы, кызмы булуы билгеләнә, 4 ай да 10 нчы көнендә Аллаһының әмере белән яралгыга җан иңдерелә. Бу хәдистә яралгының үсешен төгәл, көнләп һәм сәгатьләп сүрәтләүгә игътибар итегез. Могҗиза булмаса, нәрсә соң бу алайса? Билгеле булганча, гинекология өлкәсендә беренче тикшеренүләр безнең эрага кадәр 4 нче гасырда үткәрелә. Борынгы галимнәр экспериментлар ярдәмендә нинди дә булса нәтиҗәләр ясарга омтылалар. Шуннан соң 2 мең ел дәвамында гинекология өлкәсендә күзгә ташланырлык прогресс күзәтелми. Микроскоп уйлап табылгач, бары тик 17 нче гасырда гына ана карынындагы эмбрионның үсеш этапларын өйрәнү мөмкинлеге туа. Галимнәр үзләренең ачышларын Коръәндә табып гаҗәпкә калалар. Коръән сүрәләре күп кенә күренекле шагыйрьләрне дә уйландырган. Бөек рус шагыйре А.С.Пушкин Коръәннең роле турында:

С небесной книги список дан
Тебе, пророк, не для строптивых;
Спокойно возвещай Коран,
Не понуждая нечестивых! – дип яза.

Дөнья тарихында Гете, Гейне, Пушкин, Жуковский, Лермонтовлар Коръән аятьләрен шигъри юлга салганнар. Пушкин үзенең 9 шигырендә Коръәннең 75 аятен тәфсир кыла. Без яратып укый торган Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” поэмасы да Коръәнгә нигезләнеп

язылган. Ул үз әсәренә нигез итеп Коръәндәге Йосыф сүрәсен ала. Төп күренешләр һәм вакыйгалар әсәрдә Коръәндәге тәртиптә бара. Гомумән, изге китаптагы эчтәлек тулысы белән диярлек “Кыйссаи Йосыф” та гәүдәләнеш тапкан. Тукаебыз да үз иҗатында бик күп мәртәбәләр Коръәнгә мөрәҗәгать итә. Г. Тукайның иҗаты Коръән-Кәрим белән сугарылган дисәк тә дөрес булыр. “Дусларга бер сүз,” “Китап,” “Васыятем,” “Таян Аллага”, “Туган тел”, “Кыйтга” һәм башка бик күп шигырьләре барлык кешеләрне иксез-чиксез нур белән сугарылган Коръән аятьләрендә нинди олуг илһам барлыгын аңларга чакыра. Без белемебезне камилләштерү юлында, фәнни прогресска караган Коръән аятьләренә бирелгән комментарийларны һәм хәдисләрне тагын да тирәнрәк, тулырак өйрәнергә тиешбез. Гасырлар дәвамында дин һәм фән арасына куелган киртәләр барысы да Коръән һәм хәдисләр нурыннан “җимерелер” дип ышанасы килә.

**Тылсымлы 19 саны**

- Коръән 114 сүрәдән тора, бу 19 x 6 дигән сүз.
- Беренче биш аять 19ар сүздән тора.
- Иңдерелгән беренче сүрәдә 19 аять, 285 (19 x 15) хәреф.
- Иңдерелгән соңгы “Ярдәм” сүрәсе 19 сүздән гыйбарәт.
- Коръәндә “Бисмиллаһ” тезмәсе 114, ягъни 19 x 6.
- Коръәндә “Бердәнбер” сүзенең 19 мәгънәсе бирелә. “Аллаһы Бердәнбер” тезмәсе дә 19 тапкыр кабатлана.
- Аллаһының 99 исеменнән берсе булган “Рахман” сүзе 57 мәртәбә очрый (19 x 3)
- Изге китапта вакланмалы саннар да бар. (Мәсәлән, 1/10, 1/3, 1/2 и 2/3) Гомуми саннарның микъдары 38 ( 19 x 2)
- 19 саны 10 һәм 9 саннарының суммасын белдерә. Әлеге саннарның беренче дәрәҗә суммасы 19; икенче дәрәҗә аермасы шулай ук 19.
- Кояш, Ай һәм Җир 19 ел саен бер рәткә тезеләләр.
- Галлей кометасы Кояш системасы аша 76 елга бер үтә (19 x 4)
- Коръәндә диңгез сүзе 32, җир сүзе 13 тапкыр очрый. Ике сүзне кушсаң, 45 саны чыга. Процент бүленешенә китерсәк, 29/71. Галимнәр тикшеренүе күрсәткәнчә, су Җир шарының 71%, ә җир 29%ын тәшкил итә.

| | | |
|---|---|---|
| җир | 13 тапкыр | 13/45 = 28.88888889% |
| диңгез | 32 тапкыр | 32/45 = 71.11111111% |
| барлыгы | 45 тапкыр | 100 % |

**Медицина өлкәсе**

Коръәндә язылганнарның кешеләргә дәва булуын раслаган бик күп мисалларны китерергә мөмкин. Әйтик, Стэнфорд университеты докторы Фредерик Лускин үзенең тикшерүләре белән гафу итә алу пациентларның гомуми сәламәтлеген ныгытканны раслады. Даими стресс аркасында барлыкка килгән гипертония, ашказаны авыруларын вакытында гафу итә, кичерә белү дәваларга булыша. Коръән безгә: «берәү хаксыз золымга сабыр итсә, һәм залимне гафу да итсә, бу эш, ягъни үч алмыйча сабыр итү һәм Аллаһ ризасы өчен гафу итү, бик зур саваблы вә бик зур файдалы эштер», — дип докторлар ачыш ясаганчы ук киңәш итте. Коръән, Аллаһы Тәгалә сүзе буларак, рухи гына түгел, ә тән авыруларыннан да иң яхшы «дару». Бүгенге көндә бик күп тикшеренүләр Коръән уку һәм аны тыңлау шифа икәнне раслады. Американың Флорида штаты клиникасы табиблары һәм доктор Әхмәт әл-Кадый үзләренең тикшеренүләре турында Истанбулда уздырылган Халыкара ислам медицинасы форумында сөйләгәннәр иде. Эксперимент вакытында сүрәләрне тыңлау йөрәк-кан тамырлары һәм нерв системасы эшчәнлегенә уңай тәэсир иткәне күренгән. Сүрәләрне аңлап тыңлаганда бу уңай тәэсир тагын да нәтиҗәлерәк булган. Шуны да әйтергә кирәк, экспериментта мөселман булмаган кешеләр дә катнашкан.

**Йомгаклау**

Чынлыкта Коръән тормышыбыз өчен бетмәс дәва-шифа табу чыганагы һәм Аллаһның зур бүләге – рухи, физик сәламәтлекне саклау өчен изге кулланма икәнен истән чыгармыйк.

**Кулланылган әдәбият**

1. https://islam.ru/content/kultura/63188

2. https://e-minbar.com/quranic-studies/koran-hudozhestvennoj-literature/koran-tvorchestve-russkih-poetov-myslitelej

3. Татар әдәбияты: Теория. Тарих / Д.Ф.Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов, Т.Ш. Гыйләҗев. – Казан: Мәгариф, 2004. – 247 б.

**Фән дөньясында**

*Абдуллина Алия, 9 нчы сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының*
*«28 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе»*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләре: Мингәрәева Гөлсара Минрәхим кызы,*
*Гыйлфанова Гөлназ Рәшит кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

## Сәмигулла Хәйретдинов – фән күгендәге йолдыз

### I. Кереш

**1. Теманың актуальлеге**: Минем фәнни-тикшеренү эшем арабыздан бик иртә киткән республиканың танылган журналисты, тарих фәннәре кандидаты , авылның данын күтәрүдә , аның тарихын өйрәнүдә зур өлеш керткән Сәмигулла Хәйретдиновның тормыш һәм иҗат юлына багышлана. Мин С.Хәйретдиновның “ Күңелем синдә, авылым!..” җыентыгы белән таныштым. Искиткеч олы талантка ия булган авылдашым турында минем күбрәк беләсем килде. Шуңа күрә дә мин фәнни-эзләнү эшчәнлегемдә С.Хәйретдиновның тормыш юлын, иҗади эшчәнлеген өйрәнүне максат итеп куйдым. Әлеге тикшеренү эше дә Сәмигулла Хәйретдиновның шәхес, журналист, тарих фәннәре кандидаты, язучы буларак аның күпкырлы эшчәнлеген билгеләүдән тора. Эзләнү барышында шунысы мәгълүм булды: Иске Рәҗәп авылы кешеләре Сәмигулла Хәйретдинов турында беләләр. Аның тормышын өйрәнү безгә ни өчен кирәк соң дигән сорауга - туган җиргә милли горурлык тойгысын тәрбияләү өчен дип җавап бирер идем мин.

Һәр төбәкнең үзенең күренекле шәхесләре була. Алар турында горурланып сөйләргә, кылган гамәлләрен хөрмәтләргә, яшь буынны алар үрнәгендә тәрбияләргә.

**Фәнни – тикшеренү эшенең өйрәнү объекты**: авторның “Күңелем синдә, авылым!..” исемле җыентыгы, Сәмигулла Хәйретдиновны якыннан белгән авылдашларының истәлекләре, С.Хәйретдиновка багышлап язылган мәкаләләр, шигырьләре, мәктәп музее материаллары, язучы һәм якташыбызның тормышына караган документлар, шәхси фотографияләр.

**Эшнең максаты**: төрле чыганаклар аша Сәмигулла Хәйретдиновның тормыш юлына һәм иҗатына күзәтү ясау, тикшерү, материаллар җыю, өйрәнү.

**Тикшеренү эшенең төп бурычлары**: С. Хәйретдиновның тормыш юлын, шәҗәрәсен өйрәнү;

“Күңелем синдә, авылым!..” китабына гомуми күзәтү ясау, авторның иҗат үзенчәлекләрен ачу;

С. Хәйретдиновның күпкырлы эшчәнлеген өйрәнү; мөгаллимлек һәм әдәби эшчәнлегенең юнәлешләрен билгеләү.

**Тикшерү методлары:** эзләнү, тикшерү һәм нәтиҗә чыгару.

**II. Төп өлеш**

**1.Эзләнү тарихы.**

Авылыбыз Шәһри Болгар территориясендә урнашкангадырмы, тарихи мәгълүматлар бик күп һәм кызыклы. Борынгы заманнардан ук безнең Иске Рәҗәп авылы бик зур һәм танылган авылларның берсе булган. Монда төрле чорда, төрле сәбәп белән әледән-әле зыялы кешеләр килеп йөргән һәм авылыбыз тарихында якты эз калдырганнар. Мәсәлән, Шиһабетдин Мәрҗәнинең 1872 елда безнең авылга сәяхәт кылуы турында язган язмалары шуны дәлилли.

Авылыбызга кайчан нигез салынуы турында төгәл мәгълүматлар юк. Легендалар, авылыбызга Рәҗәп атлы Шәһри Болгарның зур кешесе килеп, 1680 елда нигез салган дип сөйли. Әлеге бабай килгән вакытта, бу урында кап-кара урманнан башка берни булмый. Шуннан соң әлеге территориядә Иске Рәҗәп авылы әкренләп торгызыла башлый. Авылыбызның хәзерге исеме Иске Рәҗәп дип йөртелсә дә, 1958 елга кадәр Старый Баран атамалы була. Нишләп Старый Баранмы? Риваятьләргә караганда, Патша Россиясе вакытында халык санын исәпкә алу үткәрелә. Екатерина 2 нче патшалык иткән вакытта, халык санын алучы рус чиновнигы көзге пычрак көннәрнең берсендә авылыбызга халык санын алырга дип килә. Аяк киемен пычратып, каретадан төшеп тормас өчен, авыл халкыннан кычкырып кына бу нинди авыл икәне белән кызыксына. Русча белмәгән авылдашларыбыз, юл сорый дип, “бара-бара”- дип җавап бирәләр. Бу хәл күрше авылда да кабатлана. Чиновник узенең ведомостена безнең авылны “Старый Баран” дип, күрше Чәчәкле авылын “Новый Баран” дип язып куя. Чынлап та шулай булганмы, юкмы икәнен беркем дә әйтә алмый. Ләкин 1695 елның 3 нче декабрендә Петр 1нче патшаның Иске Рәҗәп авылы халкына җир бүлеп бирү турындагы приказында авылыбызның исеме Старый Баран дип атала. Ничәмә еллар буе авыл исемен алыштырыр өчен көч куела. Ләкин туган җиребезнең чын исемен законлаштыруга омтылышлар Сталин үлгәннән соң гына тормышка аша. Иске Рәҗәп авылы – үзенең матур табигате, күренекле шәхесләре белән данлыклы.Туган якның табигате, аңа бәйле кызыклы фактларны, аның тарихын, күренекле шәхесләрен белми торып, тулы булмас иде мөгаен. Иске Рәҗәп авылында танылган шәхесләр күп, шуларның берсе - республиканың танылган журналисты, тарих фәннәре кандидаты Сәмигулла Хәйретдинов.

Мин әлеге кеше турында материаллар туплый башладым. Авыл китапханәсендә Сәмигулла Хәйретдинов китапларыннан күргәзмә ясап куйганнар. Аның турында язылган

мәкаләләрне бик кадерләп Хәйретдинова Флера апа (Сәмигулла Хәйретдиновның абыйсының хатыны) җыеп барган. Флера апа элек авыл китапханәсенең мөдире булып эшләде һәм аның истәлекләрен мин фәнни-тикшеренү эшемне язганда кулландым.

**2. Тормыш юлы.**

С.Хәйретдинов 1946 елның элекке Кузнечиха районы Старый Баран авылында (хәзергечә Татарстан Республикасының Спас районы Иске Рәҗәп) күп балалы гаиләдә туып үсә. Әтисе Кәрим (тулы исеме Кәлимулла) авылның тәҗрибәле умартачысы, Бөек Ватан сугышы инвалиды һәм хезмәт ветераны. Әнисе Минҗамалны да авыл халкы киң күңелле, сабыр холыклы, зирәк акыллы кеше буларак искә ала.

Сәмигулла Хәйретдинов Иске Рәҗәп урта мәктәбендә укыганда иң актив, тәртипле укучы була, яхшы укый. Мәктәп күләмендә чыга торган “Яшь көч”стена газетасының редакторы, яшь хәбәрчеләр түгәрәге оештырып, аның җитәкчесе була. Районыбыз газетасының эшчеләр һәм авыл хәбәрчеләре катнашында уздырыла торган слетларда катнаша, газетада байтак мәкаләләре бастырыла. Җылы эчтәлек белән сугарылган язмалары республиканың балалар өчен нәшер ителә торган газета һәм журналларында дөнья күрә. Әнә шулай балачак мавыгулары аның гомерлек яраткан хезмәтенә әйләнә. Мәктәптә укыганда ук оештыру сәләте, миһербанлы һәм ярдәмчел булуы белән аерылып тора. Ул мәктәпнең комсомол оешмасы секретаре булган чорда биредә ниләр генә эшләнми. Ярдәмчесез калган өлкәннәргә көндәлек булышу, фермадагы терлекләрне шефлыкка алу, башлангыч оешмалар арасында төрле ярышлар, сугыш һәм хезмәт ветераннары белән очрашуларда башлап йөрүчеләрнең берсе була. Бу кызыклы эшләр һәм шул чорда канат ярган шәхесләр турында Сәмигулла Хәйретдинов 1986 елда Татарстан китап нәшриятында “Классташларым” дигән документаль повесть бастырып чыгара. Менә шулай,аның алдагы һөнәре үсмер чактан ук ачыкланып, әкрен-әкрен чәчәк ата башлый. Тынгысыз, эзләнүчән булуы егетне Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә алып килә.

Читтән торып университетта укыган елларда авылыбыз мәктәбендә эшли, шул ук вакытта авылыбызның комсомол оешмасын җитәкли. Укучылар белән курчак театры, драма һәм фотоаппарат белән эш итү түгәрәкләре оештыра. Эшләү дәверендә авылның барлык кешеләрен барлаган, авылыбызның тарихын язган, авыл музеена нигезне дә ул салган.

С. Хәйретдиновның кыска гына гомерен текә таудан тырышып-тырмашып һаман югарыга үрмәләү белән чагыштырасы килә. Университетта укуын бетереп, журналист белгечлеге алгач, ул башта партиянең Мамадыш район комитетында һәм газетасында эшли.

1970 елда талантлы журналистны Казанга эшкә чакыралар. Ун елга якын вакыт эчендә “Татарстан яшьләре” газетасы редакциясендә әдәби хезмәткәрдән җаваплы секретарь дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә .

Сәмигулла абыйның авылдашларына яхшылыгы тими калганы бик сирәктер. Нык ярата иде ул үз якташларын, Иске Рәҗәп авылы кешеләрен бигрәк тә. Журналист буларак аның хөрмәте Болгар авыллары һәм бу тәбәктә яшәүче кешеләр турында язылган эреле-ваклы унбер китабында тупланган! Әлеге китаплар арасында Татарстан китап нәшриятында чыккан “Кырга тартыла күңел” (1975), “Йөрәккә якын юл” (1980), “Еллар шаһит”(1982), “Классташларым”(1986), язылып та дөнья күрә алмый калган “Бәрәнҗәрләр” романы аеруча күренекле урын алып тора.  Яраталар, хөрмәт итәләр иде шул Сәмигулла Хәйретдиновны. Татарстанда гына түгел, татар яшәгән һәр төбәктә аны беләләр, иҗатын, шәхес буларак үзен якын итәләр иде.  Житез һәм өлгер каләм иясе республикабыз авыллары буенча гына тугел, Россиянең татарлар тупланып яши торган төбәкләрендәге хәлләр турында газета битләрендә “Милләттәшләребез авазы” сәхифәсен чыгарып барган.  Әлеге регионнарда милли матбугат, радио, телевидение тапшырулары яралгы хәлендә генә булган бер чорда бу сәхифә милләттәшләребезне туплауда, аларны берләштерүдә бәя биреп бетермәслек уңай роль уйнады.

Сәмигулла Кәрим улы -  авылның горурлыгы, якты маягы, зур талант иясе. Туган авылының дәрәҗәсен күтәрү, таныту, тарихын барлау һәм аны китапка туплау, халыкка җиткерү өстендә бәяләп бетермәслек хезмәт куйган, Иске Рәҗәпне изге Рәҗәп итәргә тырышкан кешеләрнең берсе булды ул.

2001 нче елның июнь аенда Сәмигулла  Хәйретдиновка узе яшәгән йортка мемориаль такта куелды. Ул сагындырып, үзенең юклыгын искә төшереп, гел хәтердә саклана.

**Йомгаклау**

Хатыны - элекке шәфкать туташы (хәзер пенсиядә) Җәүһәрия, кызлары һәм иҗатташ дуслары белән берлектә һәр сентябрь саен (Сәмигулла абый сентярьдә туган, сентярьдә үлде дә) Казаннан аның каберенә кайтып зират кылалар. Олы кызы Ләйсән дә әтисе һөнәрен сайлап, Казан дәүләт университетының журналистика бүлеген тәмамлады. Кече кызы Алинә исә Казан дәүләт мәдният-сәнгать университетында укып, туристлык агетлыгында эшләүче һөнәрен алды. Алинә дә телгә осталыгы, һәр яңалыкны тотып ала белүе һәм аралашучанлыгы белән әтисен хәтерләтә.

Хәтерләтә... Иҗаты әле чәчәк атып килүче талантлы каләм иясе, китаплар һәм фәнни-тарихи язмалар авторы, илле дә тулмый арабыздан китеп барган бу олы җанлы шәхес турында “хәтер” сүзе кушып язасы килми. Әмма кырыс чынбарлык үзенекен итә. Инде күп еллар үтсә дә, авылдашлары һәм бик күпләр өчен ул безнең арада. Күңелдә Сәмигулла абый мәңгелек урын били. Бай тарихлы авылның үткәнен өйрәнеп, үлгәннәрнең каберен, исәннәрнең кадерен белергә кирәклегенә төшендерә.

**Кулланылган әдәбият:**

1. Самаркин, А. След на земле /“Новая жизнь.” – 2006 – 20 сент. – с. 4
2. Хайретдинов, С. “Күңелем синдә, авылым!..” – Казан : Татар. китап нәшр., 2017.
3. Энциклопедия города Болгар и Спасского района. – 2014. – с. 419.
4. Хайрутдинов, С. К. Класстышларым – К.,1986.
5. Хайрутдинов ,С. К. Деревня далеко, деревня рядом: очерки и публиц. заметки. К.,1990.
6. Хайрутдинов, С. К., Ногманов М. Ф. Как одна семья. – К.,1987.
7. Хайрутдинов, С. К. Баранжары / " Ажаган ", 1992, №1 , с.48-61.
8. Хайрутдинов, С. К. Корыган яфрак . Рәхмәт, улым/ "Ажаган ",1991. - №1. - с.51-52 (Рассказы);
9. Галяутдинов, З. Ш. Близкий путь к сердцу (Сост. С. Хайрутдинов). – К., 1982

*Садыкова Рамиля, 11 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге «1 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Апсагитова Аделя Ильяс кызы, математика укытучысы*

## Дизайнда математиканы куллану

### Кереш

Математика һәм дизайн! Бу төшенчәләр арасында нинди уртаклык бар? Математика бүгенге көндә сәнгать дөньясыннан тыш, ә нәкъ менә дизайнда иҗат синонимы булган өлкәләрдә ничек кулланыла? Дизайнда геометриянең нинди роль уйнавына һәм дәвам итүенә бернинди шик тә юк. XX гасыр башыннан геометрик фигуралар төрле товарлар дизайнында кулланыла, бигрәк тә җиһаз һәм төргәкләр дизайнында. Эстетик зәвыкка ия, абстракциягә һәм формаларны экономияләргә омтылучы дизайнерлар геометрик фигуралар ярдәмендә үз эшләрен элегантрак итә.

Математика дизайнда ике сәбәп буенча мөһим роль уйный. Бер яктан, дизайнерларның математик идеяләрне дөрес файдалануы, әлеге идеяләрне куллану өлкәсен киңәйтүе факты. Икенче яктан, математик төшенчәләр фән һәм технологияләр дөньясы белән бәйле булмаган контекстларда барлыкка килгәндә, алар безгә таныш идеяләрне яңача аңларга ярдәм итә, аларны тагын да аңлаешлырак итә. Математика – барлык фәннәрнең патшабикәсе, зирәклек символы. Фәннәр арасында математиканың матурлыгы әйтеп бетергесез, ә матурлык фән һәм сәнгатьнең бәйләүче буыннарның берсе булып тора.

*Гипотеза:* мәктәптә алган математик белемнәр дизайнда кулланыла.

*Эшнең максаты:* математика белән дизайнның үзара бәйләнешен күрсәтү.

*Бурычлар:*

- Дизайн турында тарихи мәгълүматларны өйрәнергә.
- Математика законнарына туры килү күзлегеннән сурәтләрнең, архитектура һәм скульптура әсәрләренең, интерьерның репродукцияләрен анализларга.
- Фән һәм дизайнның үзара бәйләнеше юнәлешләрен өйрәнергә.

**Дизайн тарихы**

Италиядән тәрҗемә иткәндә «дизайн» сүзе «уйдырма», «композиция», «модель» дигәнне аңлата. Рус телендә ул күптән түгел генә барлыкка килде, ләкин сәнгать үзе күп гасырлар элек формалаша башлады. Карала торган эшчәнлек төре белән шөгыльләнүче заманча белгеч предметлы өлкәләрдән күп кенә үзенчәлекләрне белергә һәм проектларны төзеп, аларны гамәлдә дөрес куллана белергә тиеш. Үз эшенең осталары архитекторлар, заказчылар, төзүчеләр, тәэмин итүчеләр һәм подрядчылар белән берлектә эшлиләр һәм эчке киңлекне оештыру белән шөгыльләнәләр. Матурлык һәм файда нисбәте турындагы беренче идеяләр борынгы грек галимнәре Платон, Аристотель, Сократ, Аристипп, Протагорда барлыкка килгән. Ул вакытта инде кешене машиналар белән тоташтыру турында эшләр булган. XIX гасыр уртасында индустриаль производствоны үстерү яңа төр эшчәнлеккә ихтыяҗ тудырган, ул эстетиканы рәсмиләштерүгә һәм бирүгә юнәлдерелгән. Дизайн нәкъ менә шулай барлыкка килгән. XIX гасыр ахырында теориянең һәм принципларның төп кагыйдәләре формалашкан, алар алга таба осталар мәктәпләренә йогынты ясаган.

Дизайн үзендә сәнгать һәм һөнәр берләштерә башлады. XX гасыр башында рәссамнар сәнәгатьтә югары позициядә тора. Алар оешмаларның фирма стилен эшләделәр һәм төрле электр приборлары, автомобильләр чыгаруга йогынты ясый алдылар. Дизайн сәнгать-сәнәгать эшчәнлегенә әверелде. Дипломланган белгечнең барлыкка килүе XX гасырда дизайн мәктәпләре барлыкка килү белән бәйле. Дизайн - иҗади эшчәнлек юнәлеше, ул беркайчан да ирешелгән дәрәҗәдә тукталып калмый. Кешеләрнең яңа ихтыяҗлары һәм уйлары барлыкка килә, ә үз эшенең осталары идеяләрне тормышка ашыра яки үзләренең оригиналь стилен тудыра. Шуңа күрә карала торган сәнгать даими үсештә.

**Дизайнда математиканы куллану**

Дизайнда математика ролен бәяләп бетермәү - димәк, чын дизайнер булу түгел. Барлык кешеләр ике категориягә бүленә - төгәл фәннәрдә көчле иҗади шәхесләр һәм кешеләр. Һәм бу кешеләрнең бернинди уртаклыгы да юк кебек. Ләкин бу алай түгел. Бу ике категорияне берләштерүче (һәм буйсындыра) бер бик төгәл дисциплина бар. Бу математика. Аннан башка, "патшабикәләр", бер генә фән дә, бер генә иҗат тә узмый. Ә инде дизайн -

бигрәк тә. Дизайнда математика ни өчен кирәк? 21 гасырда, дизайн сәнгате берничә аерым дисциплинага бүленгән һәм көллиятләрдә, институтларда, академияләрдә профессиональ өйрәнелә торган 21 гасырда, бу сорау үзеннән-үзе төшеп кала. Чөнки бу һөнәрдә информатика, планлаштыру, эргономика, композиция, проект графигы кебек мәҗбүри фәннәр математика элементларын үз эченә ала. Әйдәгез, математика ничек дизайнда "эшли" икәнен карыйк.

Гади урыннан башлыйк. Математика куллануның иң гади мисалы, мөгаен, *мәйданнарның исәп-хисабы* булыр. Ни өчен? Әйтик, сез үзегезнең кунак бүлмәсенә, йокы бүлмәсенә яки коридорга яңа келәм япмасы сатып алырга җыенгансыз. Һәр бүлмәнең мәйданын иң гади формула буенча исәпләп чыгарачак: S=a x b. Сезнең бүлмәләрегез турыпочмаклы яки квадратлы булса, барысы да гади. Әгәр сезнең ярым түгәрәк куышыгыз булса? Ярдәмгә яңадан геометрия килә. S (түгәрәк)=π x r2, ләкин куыш ярым түгәрәк булганлыктан, мәйданны 2 гә бүләбез һәм бүлмәнең турыпочмаклы өлешенә өстибез. Ә обойлар? Сез, мөгаен, тормышта бер генә тапкыр булса да, бүлмәләргә обойларның метрын исәпләп чыгаргансыздыр. Геометрия - математиканың иң мөһим өлеше, хәтта "чәйнекләр" өчен дә. Профессионаллар турында нәрсә әйтергә инде?

*Интерьер дизайнындагы геометрия*. Геометрия фән буларак бик күптәннән барлыкка килгән һәм асылында ул бер нәрсәне - мантыйкка буйсынган пространстволы күзаллауны аңлата. Перспектива - ике юнәлештә үскән шундый геометрик юнәлешләрнең берсе. Беренчесе - архитектура, төзелеш, дизайн, техника һәм икенчесе - рәсем сәнгате. Мисыр пирамидалары, Парфенон, күп кенә борынгы храмнар, Колизей сурәтләр (сызымнар прототиплары) нигезендә төзелгән, алар җентекләп исәпләнгән һәм планлаштырылган..

Фибоначчи эзлеклелеге. Сезнең күбегез Фибоначчиның эзлеклелеге турында ишеттеме? Бу саннар рәте: 1, 2, 3, 5, 8, 13, 21, 34, 55... Бу рәттәге һәр сан алдагы ике санның суммасы булып тора һәм дизайнда сизелерлек роль уйный. Бу саннарны 1 x 1 квадрат рәвешендә күз алдына китерсәк... 55 x 55..., бу квадратларның кушылмаларын алтын турыпочмаклык дип йөртелә торган формалашу өчен кулланырга мөмкин. Ике күрше сан арасындагы бәйләнеш, мәгънәсе буенча, алтын киселешкә якынлашкан.

*Алтын чәчү*. Сүз уңаеннан, алтын чәчү (алтын пропорция, алтын чагыштырма) турында. Алтын кисешү кагыйдәсе (кисемтәнең тигез булмаган өлешләргә пропорциональ бүленүе бу, мондый очракта кисемтәнең кече кисемтәсе зуррак булган a: b = b : c яки : b = b : a) c яки : a) b = b : c) кебек үк, бөтен борынгы грек һәм борынгы архитектура архитектурасында кулланылган һәм үлчәү эталоны дип саналган..

Алтын чагыштырма киңлек белән биеклек арасындагы гармонияле бәйлелекне тасвирлый. *Дөньяда очраклы бернәрсә дә юк, һәм бу математик принцип* (хәер, башка

барлык нәрсәләр кебек) кешеләр тарафыннан табигатьтән алынган. Фибоначчиның алтын нисбәтен һәм эзлеклелеген архитектурада гына түгел, рәсем сәнгатендә дә кулланганнар. Мисал буларак - Мона Лиза Леонардо да Винчи. Гармония борынгы корылмаларның һәм картиналарның матурлыгының дәвамы булды. Архитектура гына түгел Архитектурада һәм сәнгатьтә генә түгел, интерьерда да без математиканың "эшен" күрә алабыз. Исегезгә төшерегез, без баланс турында беләбез инде. Интерьер пространствосын модельләштерү һәм планлаштыру балансsucc башка (симметрия, асимметрия, радиальлек) узмый...

*Математика һәм интерьер дизайны.* Дизайнны планлаштырганда төгәл кайсы җиһазны сайларга (җиһазның төре һәм күләме). Монда математикадан башка булмый. Интерьер дизайнерлары алар тутырырга җыенган киңлекне үлчәргә тиеш. Җиһазның күләме дә әһәмияткә ия. Кечкенә ретро-урындыклар бик шәп күренергә мөмкин, ләкин зур бинада "югалсалар", аларның матурлыгы инде әһәмиятле булмаячак.

Түшәмне, идәннәрне тиешенчә үлчәмичә, тиешенчә бизәп була алмый. Һәм визуаль кабул итү һәрвакытта да бүлмәдә барысы да "ура" га рәсмиләштерелгән булсын өчен эшли алмый. Шуңа күрә дизайнерлар (декораторлар түгел) интерьерларны укый һәм сызымнарны һәм үз проектларын 3D проекциядә ясый белергә тиеш.

**Йомгаклау**

Математик законнар чагылышлары белән без техникада, сәнгатьтә, фәндә очрашабыз. Математик күзәтүләр кеше иҗатының күпгасырлык тарихы аша уза. Пропорция, симметрия принциплары сәнгатьтә, архитектурада, рәсем һәм скульптура, поэзия һәм музыкада мөһим роль уйный. Табигать законнары, үз чиратында, шулай ук математика законнарына буйсына. Һәм бу факт тагын бер тапкыр безнең дөньяның гармонияле булуын ассызыклый. Дизайн - матурлык һәм гламур кына түгел, компьютер графикасы, математик модельләштерү, геометрия, механика, сызым, тригонометрия һәм арифметика, шулай ук математиканың башка нигезләре буенча кирәкле белемнәр дә. Моннан нәтиҗә күренә - дизайнга математикадан башка булмый.

Математиканың дизайнның төрле өлкәләренә үтеп керүенә мисаллар чиксез... Һәм моның белән никадәр алга таба шөгыльләнсәң, мондый эш шулкадәр мавыктыргычрак була бара. Әмма китерелгән мисаллар да, минемчә, Бертран Рассел сүзләре белән килешер өчен җитәрлек: «Математика хакыйкатькә генә түгел, югары матурлыкка да ия - ул сәнгатьнең иң бөек үрнәкләренә генә хас булган чиста һәм чын камиллеккә омтылучы гүзәллеккә ия».

*Хабибуллин Бәхтияр, 5 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «24 нче лицей-интернат» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләре: Егорова Расима Хамит кызы,*
*Ахмадеева Динара Хамиз кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

## Тәрбияче Шәвәли

### Кереш

Шигъриятгәге таланты белән яраткан шагыйребез Шәүкәт Галиев кечкенәләрнең дә, зурларның да күңелен яулаган шәхес. Татар әдәбиятын аның исеменнән башка күз алдына да китереп булмый.

Укытучым миңа фәнни-гамәли конференциядә катнашырга тәкъдим иткәч, мин шатланып риза булдым. Эзләнү эшенә тема сайлау авырлык тудырмады. Чәчмә әсәрләр миңа якын түгел, ә тезмә(шигъри) әсәрләрне ярата төшәм. Сайлаган темам да бүгенге көндә бик актуаль. Без, мәктәп укучылары, балалар шагыйрьләренең иҗатын тирәнтен өйрәнергә тиешбез, дип саныйм. Шәүкәт Галиев шигырьләрен гаиләмдә кечкенәдән яратып укыганга күрәдәдер, бу тема миндә аеруча кызыксыну уятты. Темамның исеме-“Тәрбияче Шәвәли”.

Минем белән бергә, сыйныфташларым да бу образ белән кызыксындылар. Шәүкәт Галиевнең шигырләрен укыдылар. Барыбызның да күңеленә хуш килгән Шәвәли образын төрлечә күзалладылар. Аларның иҗатын сезгә дә тапшырам. Кайсы Шәвәли сезгә күбрәк ошар икән?

Сайланган теманы ачар өчен фәнни эзләнү эшемә түбәндәге **максатны** куйдым:

- Шәвәли образының укучы балалар өчен тәрбия бирүче образ икәнлеген ачыклау.

Максатка ирешү өчен түбәндәге **бурычлар** билгеләнде:

- Шәүкәт Галиевнең тормышы һәм аның иҗаты турында мәгълүмат туплау, аларны өйрәнү;
- шагыйрьнең шигырьләре белән танышу;
- Шәвәли образынынын туу тарихын барлау.

Максатка ирешү өчен без түбәндәгеләрне башкардым:

- Ш.Галиевнең китапханәдә булган китапларын барлап чыктык.
- балалар өчен язган шигырьләрен укыдым.
- газет, журнал, өстәмә әдәбият һәм интернет чыганаклар аша табылган материалны тикшердем.

Темабызның өйрәнү объекты: Шәүкәт Галиев-шагыйрь һәм татар балалар язучысы.

Өйрәнү предметы: Ш.Галиевнең 5 томлык “Сайланма әсәрләр” сериясеннән 3 нче томы, “Шәвәли” бүлеге. Бу бүлек 84 биттән гыйбарәт.

Фәнни эш кереш өлештән, төп өлеш-тематик өч бүлектән, йомгак һәм файдаланылган әдәбият исемлегеннән тора.

**Төп өлеш**

Шагыйрьнең чын исеме - Шәүкәт Галиулла улы Һидиатуллин. Шәүкәт Галиев-язучының псевдонимы. Олуг балалар шагыйре 1928 нче елның 20 нче ноябрендә Апас районы Олы Бакырчы авылында туган.

Ш. Галиев-балаларга адресланган дистәләрчә китап авторы: “Тамаша”, “Шәвәли”, “Гаҗәп хәлләр, мәзәк хәлләр”, “Кызык”, “Тәмле йорт”, “Котбетдин мәргән”, “Мыеклы бозау”, “Канатлы малай”, “Исәнме, дус!”, “Кем нәрсә ярата?”, “Сайланма әсәрләр” (5 томда) һ.б. Ә безнең мәктәп китапханәсендә мин “ Канатлы малай”(1982), “Исәнме, дус!”(1985), “Камырша”(19897), “Шәвәли хәйләсе”(1998), “Сайланма әсәрләр: биш томда”(2002), “Шәвәли китабы”(2006) китаплары барлыгын белдем. Шәүкат Галиев-иҗаты белән теләсә нинди холыклы баланы үзенә җәлеп итә алучы балалар шагыйре. Иҗаты белән шундый сихри көчкә ия була алган балалар язучысы, балалар шагыйре нинди булырга тиеш соң?

Шагыйрь Роберт Миңнуллин болай дип яза: “Балалар язучысы ул-малайларның-кызларның сыйныфташы да, авылдашы да, сердәше дә, яшьтәше да, замандашы да. Балалар язучысы ул – укытучы да, тәрбияче дә, психолог та, табиб та. Әйе, әйе, табиб та шул. Ул баланың күңелен дәвалый, рухын ныгыта, әле ныгып та җитмәгән хыялларына канат куя ...”

Шагыйребезнең үзе дә, иҗаты да нәкъ менә шул сыйфатларга ия.

Барыбызга да якын булган Шәвәли образының “туу” тарихы да бик кызыклы.

Шәүкәт Галиевнең гаиләсендә дүрт баласы булган икән. Алар: Җәмил, Җәмилә, Җәүдәт, Алсу. Балалар өчен шигырьләр яза башлагач, Ш. Галиев тагын бер тапкыр “әти” була. Чөнки аның “Шәвәли” исемле малае “туа”. Бу малайны ләкләк тә алып килмәгән, кәбестә эчендә дә тапмаганнар, ә менә шигырь эченнән килеп чыккан ул. Малайның яшәү урыны – “Балачак дөньясы”. Ә яшенә килгәндә Шәүкәт абый болай дигән: “Төп йорты-“Сабантуй”, пропискасы монда 1961 нче елдан теркәлгән, инде утыз елдан соң да: “Сабантуй”га хезмәт итәм!”-дип тора. Әле, иманым камил, илле елдан соң да хезмәт итәчәк! Ә яшенә килсәк “Әйдә, кемгә күпме кирәк, шулхәтле санасыннар. Шәвәли яши берьюлы биш-унбиш арасында! Әйе, әйе “гомерлеккә балалыкта калсын, дип” сихерләдем-шигырьләдем мин аны: балалардан аерылмасын, картаймасын иде.” [1, с. 3]

Менә шундый ул, Шәвәли дус!

Шәвәлинең прототибы шагыйрьнең туган авылында яшәгән икән. Тырыш, эшчән авыл малае Шәвәли белән Шәүкәт абый балачактан бергә булганнар. Авыр сугыш елларын, дөньяның ачысын-төчесен бергә татыганнар. Ләкин мин инде 21 нче гасыр баласы булсам да, Шәвәли минем дә яшьтәш, күңеле яшь-һәркемгә иптәш. Шук малайда дөньядагы барлык малайларга хас-зирәклек, шуклык, үзсүзлелек, үҗәтлек, кирелек, масаю кебек сыйфатлар бар. Яхшы сыйфатлары, минемчә, күбрәк, чөнки ул безнең өчен үрнәк.

Мин дә бүген сезне Шәвәли белән якыннанырак таныштырам.

Нинди образ соң ул Шәвәли? Ни өчен ул герой Шәүкәт Галиев иҗатында еш очрый? Язучы бу образны тудырганда нинди реаль шәхесне күзалдында тоткан? Ни өчен олылар да, кечеләр дә Шәвәли образын ярата? Бу сорауларга җавап табу өчен Шәүкәт Галиевнең шактый китаплары тикшерелде, Шәвәли турындагы шигырьләре анализланды. Тикшеренү барышында Шәвәли турында шактый кызыклы мәгълүмат тупланды.

Шәүкәт Галиев тудырган геройлар бик күп булса да, Шәвәли образы укучылар күңеленә якынрак тоела. Тормышчан, кызык булгангамы, Шәвәлине олылар да, балалар да ярата, исеңдә калдыра.

Шәүкәт абыйны Шәвәлидән башка күз алдына китереп булмый. Алар, бер-берсеннән аерылмас җаннар кебек, икесе дә күңелдә милли геройлар булып гәүдәләнәләр. 1963 нче елда Шәвәли “Яшь Ленинчы” (хәзерге “Сабантуй”) газетасында күренә башлый. “Мин” шигырендә үзен шук, үткен, ут малай итеп күрсәтә. 1965 нче елда Ш. Галиев “Шәвәли” китабын 32 мең данәдә тараттыра. 1998 нче елда “Шәвәли хәйләсе” дип китабын исемләп чыгара һәм үзара дуслыкларының ныклыгын тагын раслый. Кереш өлештә бу уңайдан: “Шәвәли образы, Карлсон, Чиполлино кебек үк, республикабызда бик таныш”, - диелә.

Иҗат дәверендә язучы белән Шәвәли башта ике дус, соңрак ата белән ул шикелле бик озак еллар җитәкләшеп баралар, әллә нинди маҗараларга тап булалар, мавыктыргыч ачышлар ясыйлар.

**Шәвәли образы кергән шигырьләр укучыны шуклыкка, җор, үткен телле булырга өйрәтә.** Татар әйтемнәре өйрәткәнчә “агып, тамып” торсаң, сине беркем дә яратмас, дус итмәс. “Ул кем?”, “Иләвәш сере”, “Мин!” шигырьләре моның ачык мисалы:

Мин-Шәвәли,

Шук малай,

Үткен малай,

Ут малай!

**Шәвәли әле үзе бик юмарт та**. Хайваннарга, кечкенәләргә һәрвакыт ярдәмгә килергә әзер тора. Укучыны да шуңа өнди:

Шәвәли күлгә бара,

Шикәрен суга сала:

-Ширбәтле су эчсеннәр,

Балыклар тиз үссеннәр! (“Юмартлык)

Шәвәли - дөнья серләрен аңларга тырышучы хыялый малай. Ул – бик кызыксынучан, эзләнүчән. Тәҗрибәсезлеге, балаларча беркатлы булуы белән шигырьләрдә көлке тудыра да инде. 5-6 яшьлек бала кайда эш, кайда уен икәнлекне аера белми. Останың сәгать сүтеп җыюын карап тора да, үз сәгатьләрен сүтеп уйный, шуның белән хезмәт күнекмәсен ала. Бер-ике шөребе артык калса ни! Ләкин монда **Шәвәлинең әйтер сүзе: рөхсәтсез әйберләргә кагылмаска, ватмаска**! “Һай, тешем!”, “Дару ашаган идем” шигырендә дә “рөхсәтсез кагылу” темасы күтәрелә:

Ни булса да шул булды,

Шелтәләүләр күп булды.

Даруны яшерделәр,

Үземне пешерделәр...

Шулай ул! Рөхсәтсез әйбер алсаң, үзеңә дә “эләгергә” мөмкин!

Олыларны хөрмәт итәргә, аларга урын бирергә, булышырга өйрәткән шигырьләр дә байтак. Мәсәлән, “Автобуста”:

Менә урын-

Утыр, бабам.

Ә мин җәяү

Басып барам.

“Бабасы белән Шәвәли” шигырендә дә Шәвәли кулыннан килгәнчә бабасына булыша:

-Эшләдек җиң сызганып,-

Бардык печән җыярга.

-Ә без балак сызгандык,-

Без су сиптек кыярга!

Кайбер шигырьләрдә сабыйның **тормышка ашмас фантазиясе** елмаю тудыра. Ул ат башы кадәр кәбестә үстерү турында хыяллана (“Мин кәбестә үстерәм”), космоска очу хыялы белән яна (“Космонавт булабыз, дип...”), (Кем белә?”), (“Көзге янында”). Бу шигырьләрдәге юллар баланы хыялланырга этәрә:

Космонавт булыйм, дисәң,

Кирәк чынлап ныгырга;

Курыкмаска өйрәнергә,

Төрлечә чыныгырга.

“Шәвәли йөгерә” шигырендә тиз йөгерүен, максатка ирешүчән малай икәнлеген күрсәтә:

Күнегә торгач, Шәвәли
Тәмам  остарып җиткән –
Йөз метрлы араны да
Илле метрда үткән!

**Эшкә мәхәббәт** тә Шәвәли шигырьләрендә төп тема булып тора. “Чишмә ачтым”, “Энем елый бишектә”, “Туңдырма” шигырьләрен укыганнан сон эшләгән кешенең генә үз дигәненә ирешкәнен аңлыйсың:

Нидер сизеп, тау астына
Төшеп бастым.
Балчык арчып, таш кубарып,
Читкә аттым.
Бәбкә сыман тибеп чыкты
Чишмә ачтым!

Шәвәли әле кыраудан саклап калу өчен кыярларга түбәтәй кидерү хыялы белән мавыгып йөри (“Түбәтәйле кыярлар”). Ә **бу шигырь юлларын укыган бала эти-әнисенә ярдәмче булып үсә**:

- Күрче безнең кыярларны,
Түбәтәйле икәннәр.
Помидорлар-эшләпәле,
Димәк, бар да исәннәр!

**Шәвәли әле тапкыр, зирәк тә икән:**

Усал эт күргәч
Ул болай диде:
- Мин тәмле түгел,
Ашама мине!.. (“Шәвәли хәйләсе”)
Куркуыннан Шәвәли:
- Ә-әнкәй!.. – диеп кычкырган.
- Елак балам юк! – диеп,
Аю тизрәк ычкынган. (“Шәвәли һәм аю”).

Елау бер кешене дә бизәми шул. Хәтта аю да куркып кала.

Һәр вакыйгадан **чыгар юл табарга, бер сү белән әйткәндә “судан коры чыга” белергә Шәвәли образы ярдәм итә.**

Шулай итеп, Шәвәли бик күп сабыйлар, үсмерләр өчен хас сыйфатларны үзенә туплаган да куйган. Ул тапкыр, кызыксынучан, үткен, тыйнак, шук малай.

Ләкин бер кисмәк балны бер калак дегет бозган кебек, аның тискәре сыйфатларын күрсәткән шигырьләре дә бар. ("Пәрәмәч")-түземсезлекне, "Шауламагыз, әти йоклый!"-тиктормаслыкны, "Ут белән шаярмыйлар"-чиктән тыш кызыксынучанлыкны, "Безгә шул да ярап тора"-телевизорны озак карауны, "Сызгырып йөрим"-алдагы көн өчен борчылмауны:

Җәй буена сызгырттым,

Бишмәтне мин оныттым.

Көз килде җәй артыннан,

Башландылар салкыннар...

...Йөрим сыбызгы тотып,

Борынымны сызгыртып...

Һәр бала бу шигырьләрдән үзенә сабак ала.

Алга таба Шәвәлинең төп сыйфаты- бераз гына мактанчыклык икәнен сиземләрбез. Боларын укып, инде, бала бу сыйфатның бик үк әйбәт сыйфат түгеллегенә төшенә. Мәсәлән, "Сабан туе батыры" шигырендә яңа йөрергә өйрәнгән бала балалар бакчасында уздырылган сабантуйда җиңә.

Быел батыр кем дисәң,

Батыр калды Шәвәли.

Зур мәйданда берүзе

Басып калды Шәвәли!

Басып калды Шәвәли-

Екты ул барчасын да.

Батыр калды Шәвәли

Балалар бакчасында!

Шәвәлинең батыр калуы балалар бакчасында гына икән бит!

Әнисенә булыша:

Әбисе күкәйләр әрчеп,

Тозга ук манып тора,

Тагын да тизрәк булсын, дип,

Шәвәли кабып тора! ("Шәвәли ярдәме")

Монда инде Шәвәлинең бераз гына иркәлеге, ялкаулыгы сизелә. Мондый булырга да ярамый!

Аңлашылганча, сабыйлар өчен шигырьләрдә Шәвәли алар яшендә яшәсә, үсмерләргә аталганнарында олыгаеп китә.

Шәвәли турында укыганда, укучылар үзләре белән булган хәлләрне искә төшерәләр. Аның кебек беркатлылык күрсәтәләр, зур диңгезләрдә йөзү турында хыяллана башлыйлар. Шулай итеп, үзләре дә Шәвәлигә әйләнәләр.

Шәүкәт Галиев бөтенебезнең сыйфатларын берүзенә туплаган җыелма образ тудырып ялгышмаган, шуның белән ул безнең һәрберезнең игътибарын үз иҗатына юнәлткән.

Шәүкәт Галиевнең Биктимере, Камыршасы, тагын әллә кемнәре дә яши безнең арабызда, әмма әлеге геройларга хас аерым бер сыйфатны безнең һәммәбездә дә бар дип әйтеп булмый.

**Йомгаклау**

Сибгат Хәким 1967 нче елда Ш.Галиевнең "Гаҗәп хәлләр , мәзәк хәлләр" исемле китабына язган кереш сүзендә: "Шәвәли авторның озак еллар буена үзе белән яши торган, ләкин картаймый торган образы булыр",- дигән.

Шәүкәт абый Галиевнең шигырьләре безне рәхәтләнеп көлдерә, яхшыны начардан аерып күрсәтә. Шагыйрь язган вакыйгалар онытылмый, укучыны үзенә тарта. Чыннан да бүгенге көндә язучының әсәрләре яратылып укыла, Шәвәли кебек геройлары күңелебездә якты нур кебек балкып, киләчәгебезнең бусагаларыннан атлап, мәңге безнең белән яши.

Хәзерге вакытта Шәүкәт Галиевнең шигырьләре бик зур кыйммәткә ия. Хәсән Туфан бәяләвенчә, "Шәүкәт мәктәбеннән безнең киләчәгебез булган балалар тапкырлыкка, табигатьне, дөньяны танырга өйрәнеп чыгалар". Шәүкәт Галиевнең шигырьләре шаярырга, кимчелекләребезне төзәтергә ярдәм итә; елар чакларны көлеп үткәрергә , авырлыкларга бирешмәскә өйрәтә.

Ш.Галиев үзенең Шәвәлиен балачак дустын истә тотып иҗат иткән, ләкин бу образга башка балаларга хас сыйфатларны да туплаган, замана баласы иткән. Мин үзем дә Шәвәлигә бик охшаган. Анарда булган барлык сыйфатлар (уңае да, тискәреләре дә бераз) миндә бар. Әгәр дә язучы шул чорга хас булган сыйфатларны Шәвәлинең сыйфатлары итеп язган булса, Шәвәли герое бүгенге көндә популяр булмас иде.

**Кулланылган әдәбият исемлеге**


1. Бәдретдинов, Х. Чын Шәвәли Олы Бакырчыда яши // "Шәһри Казан", 9 ай, 2000.
2. Галиев, Ш. "Минем беренче гомерем ". - Казан, 1997.
3. Зөлкарнәй, Л. "Күбәләктәй җанга - көч" // "Салават күпере", 1995, № 4.
4. Миңнуллин, Р. Балалар әдәбиятына хезмәт итәм! // "Сабантуй", ноябрь, 2003, №45.
5. Сункишев, А. "Шаян-Шәвәлинең өлкән адашы"// "Йолдыз" газетасы, 1 гыйнвар, 1999 ел.

*Хайруллин Булат, 7 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының*
*«16 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе»*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Бадреева Зөлфия Мирза кызы,*
*инглиз теле укытучысы*

**ШӘКЛИ ФӘҺЕМ, ягъни *Ясалма интеллект* татар телен саклау һәм үстерү өчен нишләргә кирәк дип саный?**

Соңга вакытта нейрочелтәрләр таныла башлады. Ә безнең мәктәптә бу өлкә нинди халәттә микән? Бу юнәлеш мәктәбебездә үсә генә башлады. Директорыбыз Сорокина Екатерина Анатольевна «ясалма интеллект өлкәсендәге проектларны эшләтеп җибәрүгә күчәргә һәм киләчәкчә Түбәнкамалыларның яшәү рәвешен яхшыга хезмәт итүгә юнәлдерергә» кирәклеген җыелышларда гел әйтеп тора.

Эшебез бер минутка да туктап тормый! Шулай итеп укучылар биология, экология, филология, химия, рәсем тармаклары буенча чат-бот белән телеграм-канал булдырганнар. Мәсәлән, 6 нчы В сыйныф укучылары хәзер ясалма зиһен белән бәйле бер технологик мәсьәләне эшли, ул Түбән Камада сукбай этләрне күзәтергә ярдәм итәчәк.

Ә күптән түгел 7 нче В сыйныф укучылары ChatGPT ярдәмендә, "Татар телен саклау һәм үстерү өчен нишләргә кирәк?" дигән сорауга җавап таптылар. Мисал өчен ясалма интеллект түбәндәге тәкъдимнәрне биргән:

-мәктәпләрдә татар телен укытуны торгызу, яңа программалар һәм методикалар булдыру;

-төгәл фәннәрне татар телендә укыту;

-чыгарылыш сыйныф укучыларына Бердәм Дәүләт Имтиханын (БДИ) татар телендә бирдертү;

-дәүләт хезмәткәрләренә мәҗбүри рәвештә телне өйрәнү;

-татар телен дәүләт оешмаларында, шул исәптән мәхкәмәләр (суд), полиция, идарәләрдә мәҗбүри куллану;

-татар телен киңкүләм чараларда, эш урыннарында, җәмәгать урыннарында куллану өчен шартлар булдыру.

Чат-бот – кулланучылар белән аралашу өчен автомат система. Башкача әйткәндә, ул клиентларга төрле мәсьәләләр чишәргә булышучы алгоритм, робот. Мәсәлән, ул интернет-магазинда заказ бирергә булышырга мөмкин.

Искусственный интеллект/ Ясалма интеллект (ИИ) — бу цифрлы технологияләрнең иң актуаль төшенчәләренең берсе. Соңгы елларда ИИ технологияләре үзенең ресурслары, инструментлары һәм хезмәтләре белән безнең тормышыбызны һәр яклап үзгәртеп бора. Тикшеренүләр, бизнес, иҗтимагый хезмәтләр — ИИ бөтен җирдә һәм безгә яңа мөмкинлекләр ача.

Suno.com — ИИ технологияләрен кулланып, тавыш һәм музыка ясау һәм редакцияләүгә ярдәм итүче платформа. Бу сайт кулланучыларга музыкаль композицияләр булдырырга һәм аларны профессиональ сыйфат белән үзгәртергә мөмкинлек бирә. Suno.com, тавыш биеклеген үзгәртү, ритм һәм башка музыкаль параметрлар белән эш итү функцияләрен тәкъдим итә, бу исә иҗат процессын җиңеләйтә.

Gamma.com — бу платформа, контент формалаштыруның яңа формасын тәкъдим итә. ИИ модульләре ярдәмендә, Gamma.com кулланучыларга текст, рәсем, графиклар һәм видеолар ясарга мөмкинлек бирә. Бу сайт күп кенә функциональ мөмкинлекләр белән баетылган, шул исәптән рекламалар, презентацияләр, һәм социаль медиа постлары.

ChanOn AI — оригиналь контентны булдыру өчен ИИ кулланучы булусы. Бу мобиль кушымта, текстлар, рәсемнәр һәм видео ясарга ярдәм итә. ChanOn AI платформасы иҗат итү процессын автоматлаштыра, бу исә кулланучыларның вакытын саклый. Интуитив интерфейсы һәм яхшы алгоритмнар ярдәмендә, кулланучылар тиз арада үз идеяләрен формалаштыра алалар.

**GPT-чатлар** GPT (Generative Pre-trained Transformer) — текст генерацияләү өчен популяр ИИ моделе. Күп кенә платформада кулланыла, GPT-чатлары кулланучыларга сорауларга җавап бирергә, текстларны иҗат итәргә, һәм идеяләр тәкъдим итәргә ярдәм итә. GPT-чатларның функциональлыгы һәркемнең иҗади потенциалын күтәрергә һәм яңа проектлар өчен фикерләр формалаштырырга мөмкинлек бирә.

Нейросеть хәрәкәтләнгән видеолар ясарга мөмкинлек бирә. Бу технологияләр кулланучыларга тексттан һәм рәсемнән видео формалаштырырга ярдәм итә. Мәсәлән, видео редакцияләү өчен нейросети контекстны аңлый, һәм искиткеч видеолар тудыра.

Соңгы елларда, аеруча мәдәниятыбызга һәм сәнгатькә кагылышлы технологик яңалыклар белән кызыксыну арта бара. OpenAI шулай ук иҗат процессын җиңеләйтү өчен уникаль платформа тәкъдим итә: Sora. Бу сайт, кулланучыларга мультфильмнар һәм кыска видеолар тудыру мөмкинлеге бирә.

Sora платформасы, бигрәк тә, мультфильм һәм кыска видеолар ясау өчен уңайлы интерфейс белән җиһазланган. Аның төп үзенчәлекләре:

1. Интуитив интерфейс: Sora тутырылган интерфейс, кулланучыларга катлаулы процессларсыз һәм тиз генә мультфильм ясау мөмкинлеге бирә. Экраның югары өлешендә кирәкле инструментлар тиз таба ала.

2. Генератив ИИ: Sora сайтында GPT алгоритмнарын кулланып, кулланучылар төрле сценарийлар, персонажлар һәм диалоглар тудыра алалар. ИИ ук رازымаларын análитик рәвештә башкару нәтиҗәсендә, кулланучылар гади текстлардан уникаль мультфильмнар тудырырга мөмкин.

3. Эшләүче модельләр: Sora платформасында әзер модельләр һәм шаблоннар бар, алар хайваннар, кешеләр, предметлар һәм башка элементлар белән мультфильмнарны эшләгәч, вакытны экономияләргә ярдәм итә.

Sora шулай ук тиз кыска видеолар тудыруга ярдәм итә. Видеоларда анимированная графика, эффектлар һәм тавышлар куллану ярдәмендә, кыска вакыт аралыгында күп кызыклы контент булдырырга мөмкин. Бу платформаны, тик таныштыру видеолары, реклама роликлары яки социаль медиа өчен контент эшләү өчен кулланырга була.

**Иҗади процессның уңайлылыгы** Sora платформасында эшләү, иҗат итү процессын катлаулыктан коткара. Кулланучылар үз идеяларын тиз арада формалаштыра, вакытларын экономияли һәм шуннан соң, нәтиҗәләрне социаль медиа яки башка платформаларда бүлешә алалар. Sora — бу, иҗатның яңа форматын уята торган әйбер, һәм аның мөмкинлекләре чиксез.

Sora Open AI — мультфильмнар һәм кыска видеолар тудыруда инновацион инструмент булып тора. Аның уникаль функционаллыгы кулланучыларга иҗади процессны җиңеләйтә һәм иҗади идеяләрне тормышка ашыруда зур ярдәм итә. Сезнең өчен иҗат итүнең яңа дөньясын ачу өчен, Sora платформасын куллануны тәкъдим итәбез!

Нәтиҗәдә, ИИ безгә иҗади процессны җиңеләйтә, яңа көчләү һәм идеяләр бирә. ИИ технологияләренең көчле прогресслары, безгә киләчәктә икътисад, иҗтимагый тормыш һәм шәхси иҗат өлкәләрендә яңа вәгъдә итә.

*Харисов Әмир, 6 нчы сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының*
*«Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 27 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе»*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Александрова Алсу Исмәгыйль кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Кеше тормышында ырым, юраулар. Аларга ышаныргамы, юкмы?**

**Кереш**

Халкыбызның тормышы никадәр алга китсә дә, югары технологияләр заманында яшәсәк тә, ырым, ышану һәм юрауларның роле әлегәчә ачыкланыыып бетмәгән. Кешенең иртәгә нәрсә булачагын беләсе, теге яки бу эшне башлаганда, бабаларыбызның акылына, тәҗрибәсенә таянасы килә. Һәр ишеткән ырым, юрауларга ышану дөресме соң? Эзләнү эшенең темасын сайлауга да И.Газиның “Мәүлия нигә көлде?” хикәясеннән соң туган хис-фикерләр этәрде.

**Эзләнү эшенең проблемасы**: ышану-юраулар чынбарлыкны чагылдырамы?

**Максат:** Кеше тормышында ышану-юрауларның ролен ачыклау

**Бурычлар**:

1) теманы ачар өчен, И. Газиның “Мәүлия нигә көлде?” хикәясен укып чыгу, ырым, юрауларны табу;

2) халык афоризмнары арасыннан ырым, юрауларны табу, өйрәнү;

3) аларның безнең тормышка ничек йогынты ясавын ачыклау;

4) ырым, ышану. юрауларны гамәли тикшерү.

**Эзләнү объекты**: И. Газиның “Мәүлия нигә көлде?” хикәясе, матбугат.ру сайты.

**Эзләнү предметы**: ырым, ышану,юраулар.

**Методлар,ысуллар:**

1) әдәби текстны анализлау;
2) белешмә, тәнкыйди һәм фәнни әдәбият белән эшләү;
3) әңгәмәләр үткәрү.

**Төп өлеш**

**1. Ырым, ышану, юраулар әдәбият белемендә**

Ырым, ышану, юраулар әдәбият белеменең фольклорга кагылышлы бүлегендә өйрәнелгән. Үземнең эзләнү эшемдә мин “Мәгариф” нәшриятының Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты белән берлектә нәшер ителгән “Энҗе

чәчтем – энҗе җыям” сериясенең “Халык афоризмнары” дигән беренче китабын файдаландым (баш редакторы К.М. Миңнуллин, төзүче Х.Ш. Мәхмүтов). Бу җыентыкта юрау-ышануларга билгеләмә бирелгән, һәм алар тематикалап бүленгән:

1. Мифик затларга, табигать көчләренә, аерым ел, ай, көннәргә кагылышлы;
2. Төрле агачлар, үләннәр белән бәйле;
3. Хайваннар, кошлар, бөҗәкләр белән бәйле;
4. Кешенең тән төзелеше һәм физик халәтенә кагылышлы;
5. Тормыш-көнкүреш фактларына нигезләнгән;
6. Халык медицинасына кагылышлы;
7. Төш юрау үрнәкләре.

**2. Ырым, ышану, юраулар И.Газиның “Мәүлия нигә көлде?” хикәясендә**

Алынган тема өстендә эшләү өчен, мин И.Газиның “Мәүлия нигә көлде?” хикәясен укып чыктым һәм түбәндәге ышану-юрауларны таптым:

“Самовар сызгырса, кунак килә”;

“Мәче битен юса, тагын кунак”;

“Козгын кычкырса – берәр төрле бәхетсезлек көт”;

“Бусаганы уң аяктан атлап чыксаң – юлың уңа”.

Әсәрнең герое Мәүлия, шушы юрауларга ышанып, имтиханын бирә алмый. Эшенең уңышсызлыгы сәбәбен ул әле объектив рәвештә аңлата белми, чөнки әнисе дә тормышында юрау-ышануларга зур урын бирә.

Әсәрдә автор позициясе:

Автор бу хикәясе белән Мәүлия кебек “җыен чурт-гүргә” ышанучыларга әйтергә тели: юрауларга түгел, үз-үзеңә ышанырга кирәк. Ышанычыңны югалттыңмы – эшең барып чыкмаячак. Ихлас ышану – психологик халәт. Юрау-ышанулар, әлбәттә, кеше тормышында билгеле роль уйныйлар, ләкин хикәядәге кебек хәлиткеч моментларда алар беренче урында торырга тиеш түгел. Автор менә шуны әйтергә тели. Автор үзе юрауларга ышанамы? Ул бу турыда ачыктан-ачык әйтми, ләкин мөнәсәбәтен Мәүлия вакыйгасы аша сиздерә.

**3. Ырым, ышану, юраулар турында интернет киңлекләрендә**

Ышану-юрауларга матбугатта нинди урын бирелә икән? Шуны ачыклар өчен, мин “Матбугат.ру” сайтына мөрәҗәгать иттем. “Татарстан яшьләре” газетасында (2011 ел, 19.07.) Нәзилә Сафиуллинаның “Ырым-шырым” дигән мәкаләсен бик кызыклы дип таптым һәм, үземнең теманы тагын да тирәнрәк ачар өчен, аны җентекләп тикшереп чыктым. Журналист ырым-шырымнарны ике төргә бүлеп карый: яхшыга юраулар һәм начарга юраулар. Начарга юрый торган ырымнарга Н.Сафиуллина мондый мисаллар

китерә: кара мәче юлны киссә- уңышсызлыкка, күзге ватылса – бәхетсезлеккә, кечкенә баланы көзгегә күрсәтмә – тотлыга торган я булмаса сөйләшә алмый торган булыр... Күңелле, яхшы ырым-шырымнар бик аз, ә “начар фал” дигәннәре буа буырлык:

“Тоз түгелсә, авылда тавыклар дәррәү кыткылдый башласа – пыр килеп әрләшү көтелә дигән сүз. Тозны ялгыш түксәң, өйдә тавыш чыкмасын өчен көлеп җибәрергә һәм маңгаеңа шапылдатып сугып куярга кирәк, ди сынамыш. Өйгә кош очып керү яман хәбәргә, имеш. Ишекләрне бикләп, өйдән чыгып киткәч, нәрсәңнедер онытып, кире керү – бетте, юлың уңмаячак дигәнне аңлата. Болай кереп-чыгып йөрүләр озын юлларга чыгу алдыннан бигрәк тә начар фал, имеш. Кире кермичә мөмкин түгел икән инде, өйдә көзгегә карап, үзеңә телеңне чыгарып күрсәтергә кирәк, диләр: шул кирәк сиңа, оешмаган, җыйнаксыз нәрсә дигән сүз буладыр инде бу, яки өйгә кергәч бераз утырып алырга кушалар. Юлга чыгар алдыннан утырып алу шуннан килеп чыккан диләр – берәр нәрсә онытылып калганы искә төшмәсме, янәсе. Туган көнне иртә уздыру, бүләкләрне иртә алу, бала тудыру йортыннан кайтып кермәс борын бәбинең “тәпиен юа” башлау – яман фалдан санала. Өстәлдә буш шешә тору – акчасызлыкка, өстәлдән ипи валчыгын кулың белән сыптырып төшерсәң – муллык күрәсең юк дигән сүз. Телегез кычытып тормаса, кешегә очлы әйбер, әйтик, пычак бүләк итмәгез – әрләшәсез. Киемегезне эчке ягы белән кия күрмәгез – кыйнап ташлаячаклар.»

Журналист дөрес әйтә: әгәр без юрауларга чын күңелебездән ышансак- көнебез шуларны гына уйлап узар иде.

Мәкаләнең ахыры И. Гази әсәре белән аваздаш: гамәлләреңөчен өстеңә җаваплылык аласың килмәсә – юрауларга гаепне аудар, янәсе, борын-борыннан шулай дигәннәр – мин нишли алам?

Алдан әйтеп үтелгәнчә,  бу күренешнең кешегә уңай йогынтысы бар икән. Үз-үзеңне тынычландыру өчен кайвакытта җаваплылыкның бер өлешен икенче нәрсәләргә күчерү кирәк. Ышану кешене тынычландыра, алга таба барырга көч тупларга ярдәм итә. Шулай да, мондый төр ышануга бик бирелергә кирәкми. Кулыңнан килгәнне эшләргә, җавап таба алмаган әйберләрне калдырып торырга ярый.

**4. Ырым, ышану, юрауларның кеше тормышындагы роле**

Күп кенү ырым-ышануларның нигезенә кисәтү, халык күзәтүләре салынган.

Мәсәлән:

“Каен – кайгы агачы, аны йортка якын утыртырга ярамый”.

Ул чыннан да авыр энергетикалы агач, тикмәгә генә, каен – кайгыга, дигән гыйбарә халык теленә кереп китмәгән инде. Аның белән йорт тышларга ярамаган, төзелештә

кулланылмаган. Чөнки ул тиз дөртләп китә, каты яна торган агач. Авыл кешесе үзен янгыннан әнә шундый ырымнар белән сакларга тырышкан.

“Тоз түгү – бәлагә”.

Элек-электән иң кадерле продукт саналган. Тоздан башка бер генә ризыкны да пешереп булмый. Дәвалауда да файдаланыла. Бу ышану тозның кадерен арттыру өчен уйлап чыгарылган дип фаразлыйк.

“Сулы чиләкнең өстен ачык калдырсаң, шайтан койрыгын тыга”.

Моның нигезендә пакьлеккә омтылу, суны чиста килеш саклау теләге ята. Һавадагы тузан кисәкчекләреннән, башка элементлардан саклар өчен, аны ябулы килеш тотарга кирәк. Су янында бәхәсләшергә дә ярамый, ул начар энергияне үзенә йоктыра.

Яшь буында үз-үзеңне матур итеп тота белү, чисталык, пакълек, ашау-эчү әдәбе һәм башка күркәм күнекмәләр тәрбияләүдә ырым, ышанулар киң файдаланылган.

1. “Алъяпкычыңның тискәре ягын бәйләсәң, кешегә тискәре күренерсең”. Балаларны матур киенү әдәбенә өйрәтү өчен кулланылган чара бу .

2. “Ачык урынга олы йомышыңны үтәмә, кояшны рәнҗетерсең”. Кояш кадәр кояшны рәнҗетеп кара әле син, олы йомышыңны теләсә кая үтәп. Моннан да куркыныч нәрсә бармы соң?

3. “Ашаганда өстәлгә таянма, бөкре калырсың”. Бөкрелек тә бик куркыныч нәрсә. Шушы курку хисе төз, матур гәүдәле булып үсәргә ярдәм итә.

4. “Аягыңны селкеп утырма, шайтан килер”. Өстәл янында дөрес утыру кагыйдәләрен өйрәтү өчен кулланыла бу сүз.

5. “Аягыңны озак киенсәң, ярлы булырсың”. Тиз бул, аягыңны озак киенмә дип туглап торганчы, шушы бер сүз җитә балага.

8. “Бәрәңге тукмагын ялама, киявеңнең башы таз булыр”. Әбием сөйли, сугыштан соңгы юклык заманнарда, әниләр боламык дигән ризык пешерәләр иде. Әрчеп пешерелгән бәрәңгенең суын саркыткач, өстенә бераз он сибәсең һәм тукмак белән төясең. Шул тукмакны яларга чират тора идек, ди.

11. “Зиратка бармагың белән төртергә ярамый, бармагың шешә”. Бу сүзнең дә нигезендә әдәп кагыйдәсе ята. Бер нәрсәгә дә, беркемгә дә бармак төртеп күрсәтергә ярамый.

12. “Җиргә төкермә, авыз кырың чабырыр”. Җир ул безнең анабыз, аны пычратырга ярамый, дип туглап тору, бала күңеленә барып та җитмәскә мөмкин әле ул. Ә болай, авыз кырың чабыра, шул сүз җитә.

13. “Җир суалчанын икегә өзсәң, тормышың урталай бүленер”. Җир йөзендәге һәр нәрсәнең җаны бар, аларны рәнҗетергә ярамый дигән фикерне балаларга шулай җиткергәннәр борынгылар.

14. “Җомга турында эш эшләргә ярамый, эшең ут булып янар”. Ислам дөньясында җомга көн – иң зур бәйрәм санала. Бу ял көне.

15. “Иләк аша карасаң, киявең кылый булыр”. Иләк- он или торган эш коралы бит ул, уенчык түгел, дип әйтеп торганчы, бу сүз үтемлерәк.

17. “Ипи валчыгын койма, хәерче булырсың”. Ризык кадерен белергә әниләр безне шулай өйрәтә.

18. “Иягеңә таянма, әниең үләр”. Монда инде сүз медицина мәсьәләсенә барып кагыла. Нәтиҗәсе шул: баланың бите, тешләре дөрес формалаша.

22. “Каршыңа буш чиләкле кеше очраса, юлың уңмас”. Кешеләргә хөрмәт белән карау хисе чагыла бу әйтемдә

23. “Кеше эзенә бассаң, әниең үләр”. Бу канатлы сүзнең нигезендә дә урамда үз-үзеңне әдәпле тоту кагыйдәләре ята.

24. “Көйгән ипи ашасаң, бүредән курыкмассың”. Һәр баланың батыр буласы килә. Кемнең инде үзен куркак дип әйттерәсе килсен.

27. “Кырмысканы үтермә, әниеңнең күкрәге шешәр”. Бу әйтемнең икенче варианты: “ Баканы үтерсәң дә , әниеңнең күкрәге шешә” .

28. "Кич белән тырнак кисәргә ярамый, гомереӊ кыска була". Бу әйтем белән безнеӊ әби-бабайлар әдәплелеккә, чисталыкка өйрәткәннәр.

29. “Көянтәне атлап чыкма, кыярак чыгар”. Хәзе инде көянтә дә юк, кыярак сүзен дә кулланмыйбыз. Ләкин тырма, көрәкише әйберләрне дә атлап чыкмаска, алып куярга кирәклегенә ишәрә ясый торгандыр бу әйтем.

**Гамәли өлеш**

Фәнни эшемнең гамәли өлешен мәчеләргә багышладым. Чөнки мәчеләр белән бәйле бик күп ырым, ышанулар яши. Аларның дөреслеген тикшереп карарга булдым.

“Мәче битен юса, кунак көт”.

Мәчене күзәткәннән соң, шундый нәтиҗәгә килдем: 8 тапкырдан юынганга, кунаклар нибары 1 тапкыр килде. Чынлыкта, мәчеләр чит исне юкка чыгару өчен юыналар икән. Ялау шулай ук песиләрнең ашкайнату һәм бүлеп чыгару системалары эшенә ярдәм итә, шулай ук йонны дымнан саклап кала.

“Кара мәче юлыңны киссә, көнең уңмый”.

Кара мәче юлны кисүенә карамастан, көнем бик уңышлы булды: мин ул көнне ике “бишле” билгесе алдым.

“Әгәр мәче кешегә тартыла икән – яңа кием-салымга, яисә берәр төрле файдага”.

Мәче берничә тапкыр миңа тартылды, ләкин кызганычка каршы, бу ырым да акланмады.

## Йомгаклау

Ырым, ышану, юрауларның эчтәлеге еш кына халыкның борынгы үткәненә, аның иске гореф-гадәтләренә, йола-ритуалларына барып бәйләнә. Алар халык күңеленең көзгесе, халыкның уй-теләкләрен, хыял-өметләрен, шатлык-куанычларын гәүдәләндергән әсәрләр. Гомумән, ырым, юраулар халык педагогикасында әһәмиятле урын алып торалар. Яшь буында үз-үзеңне матур итеп тота белү, чисталык, пакълек, ашау-эчү әдәбе һәм башка күркәм күнекмәләр тәрбияләүдә халык ышанулардан киң файдаланган. Шулай ук аларда халыкның күзәтүләре, белеме дә салынган булырга мөмкин. Ихлас ышану – психологик халәт. Юрау-ышанулар, әлбәттә, кеше тормышында билгеле роль уйныйлар, кешене тынычландыра, аңа көч өстәргә ярдәм итә, ләкин “Мәүлия нигә көлде?” хикәясендәге кебек хәлиткеч моментларда алар беренче урында торырга тиеш түгел. Йомгаклап шуный әйтәсем килә: юл аша чыккан  кара мәче турындагы ырымның дөреслеге синең кем  кешеме яки тычкан булуыңа бәйле.  Куян тәпие уңыш китерә дип ышанырга була, ләкин ул куянга уңыш китермәгән!

## Кулланылган әдәбият


1. Мәхмүтов, Х. Ш.  “Халык афоризмнары”. Беренче китап. - “Мәгариф” нәшрияты, 2002.

2. Әхмәтҗанов, М. “Төш юрау китабы”. - Казан, 1991.

3. Татар электрон китапханә (kitap.net.ru сайты). И.Гази “Мәүлия нигә көлде?”

4. Матбугат.ру сайты

**Авторлык эше: проза. Авторлык эше: поэзия.**

*Әлмөхәммәтов Әмирхан, 4 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәренең*
*«20 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе»*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Шарафеева Рамия Анас кызы,*
*туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

**Бабам сугышта катнашкан**

Бабам сугышта катнашкан
Илебезне саклаган.
Без бәхетле булсын өчен
Бөек Җиңү яулаган.
Бабам белән горурланам,
Батырлыгына сокланам.
Рәхмәтем чиксез минем
Аны мәңге онытмам!

*Багаува Азалия, 7 нче сыйныф,*
*«Ютазы урта гомуми белем бирү мәктәбе»*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Валиуллина Лилия Галимзян кызы*

**Тиен кызы Назлыкай турында әкият**

Борын-борын заманда түгел, ә безнең көннәрдә, яшел тугайлы матур аланда яшәгән ди тиен кызы. Әнисенең бердәнбер һәм иркә кызы булганга, әнисе аңа Назлыкай дип исем кушкан икән. Әнисенең бишек җырларын тыңлап, җылы кочагында иркәләнеп, яшел аланның йомшак үләнендә тәгәрәп үскән ул.

Бер иртәдә Назлыкай шыбырдап яуган яңгыр тавышына уянып киткән. Бераздан яңгыр туктаган, кояш чыккан. Урман кошларының матур җырлары ишетелгән. Назлыкай да аланга чыккан. Кояш нурларында җемелдәшкән яңгыр тамчылары белән уйный-уйный, өеннән читкә киткәнен сизми дә калган тиен кызы. Адашканын аңлап, бик курыккан ул. Кычкыра-кычкыра әнисен чакырган. Тик әнисе аны ишетмәгән. Бераз тынычлангач, Назлыкай әнисен үзе эзләргә уйлаган. Йомшак койрыгын кабартып алган да, ботактан-ботакка сикергән. Юлында очраган беренче куышка башын тыгып, “Әнием!” дип кычкырып җибәргән. Җавапка: ”Син монда нишләп йөрисең, Җирәнкойрык?” – дигән

ачулы тавыш ишетелгән. “Мин сине...”-дип ысылдаган явыз сусар. Бик курыккан тиен кызы, куркуыннан күпме йөгергәнен дә сизмәгән.

Менә каеннар артында таныш нарат агачын күреп алган ул. “Кайтып җиттем!” – дип уйлаган һәм куышка башын тыгып, “Әнием!” – дип кычкырган. Тик куыштан әнисе түгел, ә икенче Әни - тиен килеп чыккан.  “Син адаштыңмыни? Әйдә, безгә кер, мин сине ашатырмын-эчертермен, бездә калырсың,”- дигән.

-Юк, рәхмәт. Сез яхшы һәм мәрхәмәтле әни, ә минем әнием - дөньядагы иң әйбәт әни. Мин аны эзлим, - дигән Назлыкай һәм юлын дәвам иткән.

Әнисен эзли –эзли тәмам хәлдән тайган ул. Аяклары тыңламас булган, бик нык ашыйсы һәм эчәсе килгән. Җитмәсә, кояш та йокларга җыенган. Урман өстенә караңгылык төшкән. Назлыкай яшьле күзләре белән агач башларыннан әнисен эзләгән. Менә ерактагы бер агач башында җирән шар күренгән. Ул якынайган. Менә шатлык! Тиен кызы әнисен танып алган, аның ягымлы тавышын ишеткән.  Назлыкай әнисен кочклап алган да: “Әнием, әнием, беркайчан да аерылышмыйк, мин бит сине бик яратам! Син бит минем иң матур, иң кадерле, иң назлы Әнием!” – дигән.

Әйе, чыннан да, әниләр безнең өчен иң якты кояш алар!

*Бадрутдинова Азалия, 8 нче сыйныф,*
*«Биектау урта гомуми белем мәктәбе»*
*муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе*
*Җитәкчесе: Фәйзуллина Рәзинә Вәлимөхәммәт кызы,*
*тарих укытучысы*

**Һәр районның, һәр шәһәрнең була үз батырлары**

Һәр районның, һәр шәһәрнең
Була үз батырлары.
Аларның да төрлесе бар,
Рус, удмурт, татарлары.
Туган авылым Биектауда
Бик күп андый егетләр.
Тик бер җирдә табылмастыр
Зәки абый кебекләр.
Зәки абый Шәймарданов,
Шушы авылда туган.
Кечкенәдән бик тә тырыш,
Ватан сөюче булган.

Сугыш башланып китүгә,
Дошманга каршы барган.
Япь-яшь килеш, яу кырында
Бик күп җәрәхәт алган.
Герой исеме биргәннәр,
Кырык дүртнең көзендә.
Орден-медаль тулы булган
Зәки абый өстендә.
Бүген аның батырлыгын
Китаплардан беләбез.
Истәлекләр барларга дип,
Гел музейга керәбез.
Шәхси әйбер, фотолары
Хәзер шунда саклана.
Аңа карап, барыбыз да
Горурлана, соклана.
Безнең авыл Герое ул,
Шуңа якын, кадерле.
Һәр май саен чәчкәләргә
Тула аның кабере.
Авыл башыннан керүгә,
Һәйкәле каршы ала.
Зәки абый кем икәнен,
Белеп үсә һәр бала.
Районыбыз горурлыгы,
Безнең өчен зур үрнәк.
Батырларны онытмыйча
Хәтердә саклау кирәк!

*Гараева Азалина, 8 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәренең*
*«20 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе»*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Гараева Айгуль Миншакир кызы,*
*туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

**Җирдә сугыш булмасын...**

Сугыш.... Нинди авыр һәм куркыныч сүз! Бу сүзне ишетү белән күңел тула, елыйсы килә...Чөнки сугыш күпме кайгы-хәсрәт, күпме югалтулар китергән, күпме кешене ятим иткән...

Меңләгән шәһәрләр, гөрләп торган авыллар җимерелгән. Бөек Ватан сугышы чоры халык өчен зур сынау еллары булган. Сугышның беренче көннәреннән үк барлык ир-ат туган илен – Ватанын сакларга киткән. Калган хатын- кызлар, картлар, балалар бөтен эшне җигелеп тартканнар. Көне-төне эшләсәләр дә, ашарларына җитмәгән, чөнки икмәкне фронтка озатырга кирәк булган. Җәй көннәрендә балтырган, кузгалак, ачы какы, төче какы, кычыткан, чөгендер яфрагы – барысы да ризыкка әйләнгән. Бөтен халыкка бик авыр булган, ләкин алар бирешмәгән, бердәм булган.

Минем бабамның әтисе Ямалтдинов Закирҗан баштан фин сугышында катнашкан. Фин сугышы тәмамланып бер ел үткәч, бабамның әтисе, әбиемне калдырып Бөек Ватан сугышына киткән. Әбием ул вакытта бер яшьлек улы белән калган. Баласы бик кечкенә булса да, ул колхоз эшендә катнашкан. Ничек тә сугыштагы кешеләргә ярдәм итәргә теләгән. Сугышчыларыбыз шушы ярдәмне тоеп, аларга булган ышанычны акларга тырышканнар, үзләренең көчләрен жәлләмәгәннәр, алга таба барганнар һәм ниһаят үзләренең максатларына ирешкәннәр. Бабамның әтисе сугыштан бик каты яраланып кайткан. Сугыштан кайткач бик озак хастаханәдә ятып чыккан. Бабам миңа әтисенең сугыш вакытындагы салкыннарда аяк-кулларының өшеп бер ни сизмәгән вакытларын, берничә көн бер ни ашамыйча окопта ач ятулары турында елый-елый сөйли иде. Бабамның әтисе сугыштан соң озак яшәмәгән, шушы авыр яраларыннан терелә алмыйча вафат булган. Әбиемнең бабамны сагынып елый-елый күзләре сукырайды. Гомеренең соңгы көненә кадәр якты дөньяны, безне күрә алмыйча, сукыр булып яшәде.

Гомер кешегә бер генә бирелә. Шул гомерне нәтиҗәле, мәгънәле итеп яшәргә язсын иде. Киләчәктә сугышларны булдырмаска, булганнарын ничек тә туктатасы иде! Моның өчен сабырлык, дуслык, бердәмлек, күркәм холыклы кешеләр кирәк. Андый холыклы кешеләр бар. Алар безнең күңелләргә мәрхәмәт, шәфкать, сабырлык орлыклары чәчәләр. Җирдә сугыш булмасын, бары тик тынычлык кына хөкем сөрсен иде.

Язмамны үзем язган шигырь белән тәмамлыйсым килә.

Сугыш дигән шул яман афәтне
Ходай бүтән күрергә язмасын.
Сабыйларның, әти-әниләрнең
Күңелләренә яра салмасын.

Бабам минем башта финнар белән,
Аннан немец белән сугышкан.
Болар бар да эзсез калмаган шул,
Дөнья белән яшьләй хушлашкан.

Сугышта бабайларыбыз
Җиңәргә тырышканнар.
Һәрвакыт алга барганнар
Уңышка ирешкәннәр.

Тылда калган әбекәйләр,
Аларга булышканнар.
Бөтен кеше көчен куеп
Җиңүгә ирешкәннәр.

*Гыйззәтуллинә Алисә, 7 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының*
*«Инглиз телен тирәнтен өйрәтүче 33 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе»*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Нургатина Раилә Раиф кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Балачагым**

Күңелемнең хыялларда
Очынган матур мәле.
Балачагым дөньясына
Кунакка барыйм әле.
Кыш бабайга ышанып,
Бүләкләр көтә идем.
Берәр могҗиза булыр дип,
Бәйрәм күлмәген кидем...

Озын толымлы кар кызын
Күрергә бик тә теләп,
Матур җырлар өйрәндем,
Эчемнән генә көйләп.
Кыш бабакайны күргәч,
Матур итеп биедем.
Рәхмәт әйттем әниемә,
Балачакка сөендем.

**Биюче булам**

Үскәч бөтен хыялым
Биюче булу минем.
Зур сәхнәләрдә, мәйданда
Тыпырдап биер идем.
Аллы- гөлле күлмәкләр
Өстемнән төшмәс инде.
Аякта читек-кәвешләр,
Укалы яулык иңдә.
Егетләрнең йөрәкләрен
Җилкендерермен әле.
Күңелемнең хыяллардан
Түземсез, кызган мәле...

**Әбием догалары**

Ак яулыклы әбием,
Кадерле дәү әнием,
Яратып, мине сөя:
«Син газизем, нәнием.»
И, әбекәй аңламый шул:
Сабый түгел мин күптән.
Җидедә укыйм хәзер,
Балачак инде үткән.
Шулай булса да, әбинең
Иркәләгән көннәрен
Сагынам, юксынам бик тә
Авылымның төннәрен.
Айлы кичтә әби миңа

Изге дога өйрәтә.
Аятелне ятлагач,
Мөнәҗәтләр көйләтә.

**Туган көн**

Бүген минем туган көн,
Бүләк ала торган көн.
Нинди могҗиза булыр дип,
Йокламый чыктым бу төн.
Иртән-иртүк уяндым,
Чәч ясадым, буяндым.
Тирә-як гүзәллегенә,
Матурлыкка куандым.
Иң матур бәйрәм бүген,
Иң күңелле мизгелем.
Күктә кояш нурын сибә,
Шат елмая һәр гөлем.
Бүләкләр дә төрле-төрле
Йөрәкне шатландыра.
Өстәлдәге сый-хөрмәт
Күзләрне шаккатыра.
Рәхмәт сиңа, әнием,
Бу көнне биргән өчен.
Рәхмәт сезгә, кунакларым,
Хөрмәтләп килгән өчен.

*Нуриева Ләйлә, 10 нчы сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Актаныш районының*
*«Пучы урта гомуми белем бирү мәктәбе»*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Муллагалиева Гульназ Кашаф кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Килмәде...**

Бу мәктәпкә күптән түгел генә эшкә керсәм дә, монда шактый күп хәлләр булды. Әмма иң аянычы, шушы бала белән булгандыр, мөгаен...

Дамир быел безнең авылдагы мөмкинлекләре чикләнгән интернат-мәктәпкә беренче класска килде. Ул үзенең яше өчен рәтләп сөйләшә белмәсә дә, шундый чибәр, шундый мөлаем, сөйкемле бер бала, ә аның күзләре... Аларга карасаң, бөтен дөнья чагыла, ләкин аларда ниндидер бер сагыш бар иде. Ел башында мин аның классташлары кебек яхшы сөйләшә алмаганына бик исем китми иде.

«Андый балалар күрдек, мәктәпкә кергән генә, өйрәнер әле», — дидем мин үземә. Ә соңыннан мин Дамирның алай бик җайлы гына кеше аңларлык итеп сөйләшә алмаячагын аңладым. Аңа «акыл ягыннан бик артта калучы» дигән диагноз куелган икән. Бу минем күңелемә тагын да тиде.

Бер гади эш көнендә төшке аштан соң йокларга ятырга тиеш булган балалар арасында берәү җитми иде. Дамир. Дамир юк...

Мин калган кечкенәләрне дежур тәрбиячегә калдырдым да, ул шук малайны эзләргә чыгып киттем. Коридор борынны кисә торган ис белән тулган, бәдрәф ишекләре пычранып беткән, ә бер почмакта Дамир утыра. Ул миңа үзенең телендә нәрсәдер сөйли, ә мин аны тизрәк юыну бүлмәсенә алып керергә тырышам.

Баланы юындырып, тынычландырып, йокларга яткырырга ашыктым. Калган балалар күптән йоклап китү сәбәпле, аларны уятмас өчен, мин аны үземнең бүлмәдәге диванга яткырдым. Миндә ана инстинкты уянды микән, белмим, мин Дамирны башыннан сыйпап, аңа әкият укып йоклатып җибәрдем.

Бик якын иде бу бала минем күңелемә. Шул көннән соң Дамир гел минем янга килеп, сырпалана, иркәләнә башлады, буш вакытта уйнаганда да, минем янымнан китми иде. Мин үзем дә, ул кояш нурын күрмәсәм, көнем бушка үткән дип чутлыйм, кайбер көннәрне, эшкә гел аның өчен генә бара идем.

Безнең мәктәптә ике атнага бер, бөтен балалар да өйләренә кайтып бетәләр. Бу көнне дә шулай булды. Мәктәп бушап калды, тып-тын. Бер бүлмәдә генә үкереп елаган тавыш ишетелә, ул — Дамир елый. Әйе, минем җан кисәгем, үкреп елап утыра, чөнки аны алырга килмәделәр.

Килмәде бит әнисе, килмәде! Мәктәп администрациясе, шәхсән үзем дә, әнисенә шалтыратып, хәлдән тайдык. Чулпан ханым үзе дә бу интернатта яшәп укыган икән, һәм чыгып киткәч, үз әнисе өйгә кертмәгәч, әтисенең апасына яшәргә кайткан. Шуннан соң ирекле һава сулаган яшь Чулпан, көннәрдән бер көнне, апасына көтелмәгән һәм хәтта кирәк булмаган бала алып кайткан.

Ниһаять әнисе трубкасын алды, минем янга йөгереп килгән Дамир, әнисенең шалтыратуын тоеп алган күрәсең.

— Алло, исәнмесез, бу интернат-мәктәптән, Гүзәл Роберт кызы борчый. Бүген бездә бөтен балалар да кайтып беттеләр, Дамир гына калды, килеп аласыздыр бит? Ул сезне бик юксынды, сагынды.

— Алё. Кем? Минем бернинди Дамир исемле кешем дә юк, син ялгыштың ахры.

Мин ачуымнан тавышымны калынайтып:

— Дамир. Сезнең улыгыз, оныттыгызмыни? Бала күпме күз яшьләре түкте сезнең өчен, ә сез андый кешем юк дисез. Киләсезме юкмы?!

— Юк, килмим...

Шуның белән безнең әңгәмә тәмамланды, мин трубканы ташладым, ярсып елыйсым килсә дә, түздем, чөнки янымда Дамир бар иде. Ул әнисенең килмәвен аңлаган бугай инде, миңа зур зәңгәр күзләре белән карап тора, менә хәзер елап җибәрер сыман. Чыннан да, ул шул ук минутта елап җибәрде, мин эчемнән генә аңа кушылып еладым. Тәрәзәгә күзем төште, анда давыллы яңгыр...

Инде көн ахырына якынлаша, ә ул һаман елый. Мин баланы ничек кенә юатып карамадым, хәлемнән тайгач, аны шәфкать туташ янына алып кердем.

- Нинди дә булса витамин булса да бирегез инде, туктамый бит, —дидем.

Гөлфинә Назиф кызы, аңа үзенең сумкасыннан бер кәнфит алып бирде. Ләкин, бала аны миңа сузды. Гөлфинә апа: «Юк, тәрбиячеңә тагын берне бирәм, ансы үзеңә калсын», — диде.

Ул нечкә тавышы белән, бөтенебез дә аңларлык итеп:

- Моны әнигә калдырам, — диде.

Шулчак минем дә, Гөлфинә апаның да күзләреннән мөлдерәп яшь ага башлады.

**Төнге урам**

Ай, йолдызлар, төнге урам һәм мин...

Мондый вакытта үзем генә булу ниндидер могҗиза кебек: күңелдә бушлык, әйтер сүзләр инде әйтелгән, эшлисе эшләр эшләнгән, тик йөрәккә генә нидер җитми...

Йөрәк суга сусаган гөл кебек, һаман нәрсәдер сорый, кибенә, тибенә. Көне буе көлеп-елмаеп йөрсәм дә, төнгә ул хис-кичерешләрем, кояш белән ай алышынган сыман алышыналар иде. Монын болай икәнен тик үзем генә беләм. Янымдагы якыннарыма һәм тирә-юньдәге кешеләргә сөйләмим. Кемгә кирәк ул, аның урынына кулыма каләм алам да язам. Язам, язам, язам...

...Шушы урамда бергә уздырган вакытлар, монда булган хатирәләр санап бетергесез. Бу урам -"безнең урам". Аннан узганда гел син искә төшәсең һәм тамакта ниндер төер, күңел тула, күзләрдән яшьләр әкрен генә тама башлыйлар.

Исеңдәме, безнең тәүге очрашу? Синең янга курка-курка килүемне мәңге онытасым юк. Моңа кадәр интернет аша гына аралашкан булгач, башка нинди генә уйлар кермәде. "Ул чынбарлыкта нинди икән, мин аны ничек танырмын?","Ә мин аңа ошамасам?", "Ул үзе чибәр микән соң, миңа тиң микән?", "Ә аның янында көлкегә калсам?", "Уртак тел табалмасак?"... Бу меңләгән сорауларга җавап үзеңне күрү белән диярлек табылды.

Син баһадирдай минем каршыма килеп бастың. Мине әллә ничә кеше каты итеп тотып торган сыман, селкенәлмичә тордым. Шулчак син миңа эндәштең, ләкин мин һаман бер сүзсез сиңа текәлеп карап тора идем. Мин үземне аңлыйм да, белештермим дә кебек. Сиңа сокланмыйча да булмый, синең мәһабәт гәүдәң, кара бөдрә чәчләрең, зәңгәр күзләрең һәм искиткеч тавышың...

Мин үз хәлемә килгәч, без күрештек, кочаклаштык. Ярар инде, алай ук булмады, юк, юк. Чынлыкта, синең белән уртак тел табу бер дә кыен булмады, без шундук сөйләшеп киттек, мин үземнең сиңа телсез озак карап торуым өчен синнән ул көнне мең тапкыр гафу үтенгәнмендер. Ул кичне бик зур һәм ямьле бәйрәм булып, анда биһисап күп кеше булса да, җиһанда без икәү генә идек. Үзеннән үзе сиздермичә генә без андагы халык арасыннан чыгып киттек һәм менә, без "үзебезнең урамда". Монда үткән вакыт аеруча истә калды, анда вакыт башкача үтә, анда һава да башка.

Исеңдәме, шул ук кичне мине тәүге тапкыр озатуың? Чын дөресе, мин ул мизгелдә тын да алмый кайттым. Никадәр алҗасам да, йокым качып, нәрсәләр булганын уйлап яттым, һәр искә төшкәненә сөендем дә, көендем дә. Ул вакытта мин сиңа бөтен килеш гашыйк идем һәм безгә бернәрсә дә комачауларга тиеш түгел кебек иде.

Исеңдәме, нәкъ шушы урамда миңа шомырт чәчәкләре бүләк иткәнең? Ямьле май киче, без тагын шушы урамда... Минем нигәдер, кәефем яхшылардан түгел иде, күңелем нидер сизенде, синең янда бигрәк тә бу сәер күренеш. Кәефемне күтәрергә тырышып, син күп сүз сөйләп тормадың, бары тик "көтеп тор, беркая да китмә, хәзер киләм" дидең. Биш минуттан инде син минем алдымда басып тора идең, ә кулыңда, исеннән баш әйләнә торган, мин яраткан шомырт чәчәкләре бәйләме. Иреннәрем елмайды, күзләремә яшь тулды, ул шатлык яшьләре иде, шундук синең муеныңа асылынып, нык итеп кочакладым.

Исеңдәдер инде: безнең соңгы очрашу...

Ул көнне күрешкәч, синең моңсу булуың әллә каян ук сизелеп тора иде. Моңсулыктан да бигрәк, синең күзләрең... Күзләрең барысын да сөйлиләр иде. Аларның карашы буш иде, алар миңа шундый салкынлык белән карыйлар, хәтта иң салкын бозлы котыпта да синең карашыңнан өшегән кебек өшерлек булмагандыр. Без сүзсез генә күрештек, синнән нәрсә булганын сорарга ашыккач та миңа, син берничек тә җавап бирми идең. Без утыргыч янына килдек. Анда барып җиткәнче минем тәнем буенча салкын

йөгерде, мин үземне бөтенләй чит кеше белән барган кебек хис итә идем. Мин утырдым, ә син минем каршыма чүгәләдең һәм күзләремә карадың. Кулымны тоттың да: "без синең белән бүтән күрешә алмаячакбыз, миңа китәргә кирәк, гафу итәлсәң гафу ит мине", - дидең.

Минем башта уйлар төрле-төрле, сораулары аннан да күбрәк, кайсысын бирергә?

Син киттең, еракка киттең, озакка киттең, ә минем йөрәккә һаман нәрсәдер җитми.

Ай, йолдызлар, төнге урам һәм мин...

**Тәүге хисләр**

Җәй. Көне кызу. Җиләкнең эре һәм пешкән чагы, андый вакытта әбием өйдә торамыни инде, хыт шунда боз яусын!

Иртүк торып без җиләккә киттек. Мин, Гүзәл сеңлем, әбекәйне дә калдырмадык. Безнең белән дәү әнисе һәм Самат та барды. Әйе, ул да бар иде, ул булмаса бу сөйләвемнең бер хикмәте дә булмас иде инде. Без җиләклеккә килеп җиттек. Машиналардан төшеп, үзебез белгән бик яхшы урынга юл тоттык. Барганда алар тагын бер-берсенә дәшмәделәр, югыйсә Гүзәл юл буе шуның турында гына сөйләп барды. Төзәнде-бизәнде, өйдән чыкканда иң матур яулыкларын бәйләп, күлмәкләрен киеп чыкты.

Бу безнең Саматлар белән беренче тапкыр җиләккә бару иде. Аңа кадәр гел үзебез йөргәләдек, чиләкләребез дә бик тиз тула иде. Бүген исә, әллә Гүзәлнең сөйгәне булганга чиләкләребез тишелгән кебек булды. Һич тутыра алмыйбыз бит шуларны, нишләтәсең, җиләге хәйран эре күренә. Ләкин, ничек тырышсак та, юк инде, тулмый. Без бит алай гына бирешә торган кызлар түгел, соңгысына кадәр җыябыз.

Ни күзем белән күрим. Самат, утырган тау битенә, ә үзенең чиләге тулы.

- Самат, -дим, - безгә дә җыеп бир әле.

Гүзәл кызарып чыкты, миңа шундук:"Син нәрсә, нигә минем йөземне кызартасың?!"

Самат көлеп куйды.

Көн кыздыра башлады, тамаклар да кипте. Әбекәйдән "Машинада су бармы?"- дип сораган иде сеңлем. Әбием аңа: "Нигә анда кадәр йөрисез, әнә Саматтан сорагыз", - диде. Мин әбекәйгә каршы килергә җыенмаган идем, әмма безнең Гүзәлебез горур бит. Саматта булган суны эчмәс өчен, әллә кайда торган машинага барырга да әзер иде. Нишләтәсең инде, без анда барып су эчкәнче, Самат инде икенче чиләген дә тутыра язган.

Шулай йөри торгач, Гүзәлнең әллә алҗавы җитте, әллә кояшта озак йөргәнгә, "баш авырта" ди башлады. Гомергә булмаганны Гүзәл көйсезләнеп: "Кайтасым килә. Кайчан кайтабыз? Әйдәгез киттек!" - дип җәфалады.

Ул вакытта дәү әнисенең дә чиләге тулып өлгерде, Саматлар кайтырга җыеналар. Әбием түзмичә, аңа безнең белән килгән иптәшләргә утырып кайтып китәргә тәкъдим итте. Шул сүзне генә көткән кебек, Гүзәл тынды һәм бүтән дәшмәде.

...Гүзәл белән Самат мәктәп яны җәйге лагеренда таныштылар. Әбекәебез шул мәктәптә эшләгәч, безне дә ияртеп барды. Көн аяз иде, күктә якты кояш нурларын чәчеп тора. Гүзәлнең кәефе бик яхшы, шуңарга ул лагерьга сикергәли-сикергәли барды. Ул кечкенәрәк булса да, бик тиз ияләшеп китте. Андагы бөтен кеше белән дә дуслашып, танышып чыкты диярлек була, тик бер малай белән генә берничек тә уртак тел табалмады. Әйе, ул егет Самат иде.

Икенче, өченче көннәрне дә алар сөйләшмәделәр һәм хәтта бер-берсен ничектер дошман итеп күрделәр...

Шулай, лагерь сменасы ахырына якынлаша иде. Әйдаманнар балаларга "Сабантуй"га төрле концерт номерлары эзерләргә куштылар. Гүзәл үзе дә, Самат та биюче булуын иптәшләре беләләр иде инде, шуңардан һәм аларны дуслаштыру сәбәпле аларны парлы биюгә бастырырга тырыштылар. Бик озак кына бу икесе каршы килсәләр дә, төркемнәрен кыен хәлгә калдырасылары килмәде.

Матур итеп бию куеп, кабатлап йөри-йөри, лагерьның соңгы көне килеп җиткәнен сизми дә калдык.

Менә Гүзәл искиткеч матур күлмәктән, озын чәчләре ике толымга үрелеп куелган, күзләрендә кояш нурлары ялтырый. Баһадирдай Самат Гүзәл янында басып тора иде, алар бер - берсен тулылындырып торалар, гүя аерым-аерым була алмыйлар. Аларның биюләре белән ачылып китте чара. Бөтен кеше шаккатты, алар кышкы, салкын көндә яуган кар бөртекләре төсле бөтерелә-бөтерелә үзләренең биюләрендә әйләнәләр иде. Чыгышлары шул дәрәҗәдә күз явын алырлык, әйтерсең, алар гел бергә биегәннәр. Берсеннән-берсе чибәр, ә хәрәкәтләре нинди?!

Бу пар биегән чакта күктә хәтта кояш та ничектер яктырак һәм җылырак яктырта башлаган сыман булды. Гүзәлнең сөйләвенчә, биегәндә аның эчендә нindидер тел белән аңлатып та булмый торган хис-кичерешме нәрсәдер, нindидер халәт, “хәрәкәт” барлыкка килде, ул Саматка карагач булды, ди.

Бию бетте. Ниһаять, битләрендә дуслык елмаюлары чагылды. Калган вакытны да алар бергә үткәрделәр, хәтта оештырылган бәйгеләрдә дә бергә катнаштылар. Инде менә саубулашу сәгате дә килеп җитте, ничек кенә авыр булмасын, ләкин һәр кешегә ияләшеп бетелгән, берсен дә җибәрәсе килми бит...

Гүзәл Самат белән соңгы булып саубулашты һәм мине дә көтмичә, өйгә йөгерде. Мин кайтуга, әбием:"Апаеңа нәрсә булды?"- дип сорады. Мин аңа нәрсә дип җавап бирергә белмичә тордым. Озакламый Гүзәл яшьле күзләре белән безнең янга чыкты. "Мин инде аны хәзер беркайчан да күрмәячәкменме?"-диде ул безгә. Без башта аңламыйча тордык. Соңыннан:

-Самат...- диде ул.

Әбием бераз аптырап:

-Кызым, борчылма, күршедә Сәкинә апаң тора, беләсеңме? Самат шуның оныгы, бер дә күргәнең булмадымыни?

-Чынмы?

-Чын, кызым, күрешерсез әле тагын. Үзе дә безнең авылда яши бит ул.

-Кайда яши, әбекәй?

-Анысын соңыннан әйтермен. Биюегез бигрәк матур иде, кызым, Самат белән бер-берегезгә килешеп тә торасыз.

-Рәхмәт, әбекәй. Мин дә бит инде, юкка гына болай кыланмыйм, ошатам бугай мин аны...

Озакламый бу хисләрнең үзара булуы билгеләнде. Бераз вакыт, Гүзәл белән Самат бер кешегә дә әйтмичә очрашып алдылар, кич урамга чыгып урап кайталар иде. Уйлары гел бер-берсендә генә... Мәхәббәт! Нинди матур хис! Әле бит ул тәүге мәхәббәт! Мәңгегә күңелдә кала торган, гел онытылмый торган бер тылсымлы мизгел. Аларның бу сөюләре саф, чиста сөю, күзләрендә ут, йөрәкләрендә ялкын! Читтән карап торганда шулай матур күренәләр.

...Ләкин бу бәхет озакка бармады. Самат һәм Гүзәл турында бик тиз белделәр. Юк, әрләмделәр, аңлыйлар бит инде. Киресенчә, сокланып һәм горурланып карыйлар иде якыннары.

Аларны ничек тә бергә калдырырга, гел сөйгән ярлары турында нәрсәдер әйтеп куярга, аларны күрештерергә тырышалар иде.

Мондый хәлләрдән соң, оялып, кызарып пешкән, башларын игән чияләр кебек, Самат белән Гүзәл оялып йөри башладылар. Тирә-яктагы кешеләрдән генә түгел, ә үз-узләреннән дә.

Шулай алар бер-берсенең исемен ишеткәч яисә гәүдәсенең күләгәсен генә күрсәләр дә, ничек тә булса качарга тырышалар иде. Бик озак, айлар түгел, еллар шундый "качышлы" уенын уйнап йөрделәр. Ләкин, барыбер күңелләре бер-берсен тарта иде, йөрәк онытмый бит...

Җәйге ялларга кайткач, Гүзәл гел миннән аның турында сорый, әбекәйне дә сораулар белән күмә. Әмма Саматның исеме булса да ишетелә икән, кача башлый. Үзе кызык, үзе кызганыч...

Дөрес әйтәләр: "бәхет тынычлыкны ярата" дип, бу матур мәхәббәт турында белми торсалар яки белеп тә алай сөйләп йөрмәсәләр, бәлки, бу пар әле бүгенге көндә бик матур гына гомер итәр иде.

**Татар икәнеңне онытма!**

Берничә ел элек, җәй көне булды бу хәл.

Мин әбием, аның сеңлесе һәм оныгы белән чит илгә сәяхәткә очтык. Бик күңелле итеп вакыт уздырдык, төрле-төрле җирләрдә булдык, яңа дуслар таптык. Кыскасы: күңел ачтык, безгә бик ошады.

Без яшәгән кунакханәдә көн саен ниндидер конкурслар, кызыклы уеннар уздырыла иде. Кичләребез дискотекасыз да калмады.

Шулай берсендә һөнәрләр бәйгесе игълан иттеләр. Матур-матур чыгышлар күрсәттеләр. Илнең төрле нокталарыннан балалар һәм дә ки зурлар җыелган булган бу җирдә. Нинди генә һөнәрләргә ия түгел иде андагы халык! Минем дә бу бәйгедә катнашып, үземнең көчемне сынап карыйсым килде, чөнки анда катнашкан балаларга медаль бирәләр иде! Бик кызыктым шуңа, нинди дә булса истәлек бит. Миңа да кирәк иде ул. Ләкин мин, бүген туган кешедәй, нишләргә белмичә тордым. Әйтерсең, бер һөнәрем дә юк. Башымда нинди генә уйлар үтмәде, әмма берсе дә туры килми иде.

Шул чакта, гел янәшәмдә булган әбекәем миңа киңәш бирде. "Бар, кызым, чык та "Туган тел"не җырла", - диде. Мин бераз каушадым, шулай да бик озак уйламадым, чиратка бастым да үземнең чыгышымны көттем.

Берничә минуттан мин дә сәхнәдә идем. Әкрен генә, талгын гына, мин "Туган тел"не суза башладым. Белмим, матур җырлаганмын микән, юк микән, ләкин бөтен кеше шым калды.

Мин җырлаганда, бөтен нәрсәне онытып, күзләремне йомдым... Күз алдымда минем туып - үскән авылым, аның бихисап киң кырлары, ул кырлардагы сандугачлар, елгалары, күлләре, көмештәй чиста, салкын сулы чишмәләре, куе урманнары, андагы искиткеч тәмле җиләкләре, бөрлегәнле әрәмәләре иде. Җырлап бетергәч, мин күземне ачтым һәм үземнең каршымда күзләрендә яшь булган якыннарымны күрдем. Алар миңа сокланып һәм горурланып карап торалар иде. Шуннан бөтен мәйданда җыелган халык хуплап кул чапты. Шундагы алып баручы: "Это какой язык?"- дип сорады. Мин горур күтәрелгән баш белән: "Татарский", - дип җавап бирдем.

Бу кылган гамәлем белән мин һаман да бик горурланам. Нинди генә хәл булмасын, туган телне белергә, анда ирекле сөйләшергә кирәк. Аны без сакламасак, кем саклый соң? Без татар булуыбыз белән горурланып яшәргә тиеш.

*Хәтта бозлы салкын котыпта.*

*Татар икәнеңне онытма! (Г.Афзал)*

*Фәтхетдинова Нәзилә, 5 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Актаныш районының*
*«Пучы урта гомуми белем бирү мәктәбе»*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Муллагалиева Гульназ Кашаф кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Муса Җәлил – безгә маяк**

Муса Җәлил маяк булып яна
Йөрәкләрнең иң-иң түрендә.
Тап төшермәс бөек, изге исеме,
Кояш булып балкый күгемдә.
Килгән чакта аңа авыр тормыш,
Түзгән шагыйрь башын имәгән.
Үткен кылыч кисеп үткәндә дә,
Курку дигән уйны белмәгән.
Ятса да ул салкын төрмәләрдә,
Хыялында булган болында.
Чәнечкеле тимер чыбык түгел,
Ал чәчәкләр үскән юлында.
Кара үлем килгән аңа бер көн,
Чәчәкләрдәй шиңгән гомере.
Тик яшәгән иҗатында аның
Киләчәккә булган өмете.
Муса абый үрнәгендә без дә,
Киләчәккә юллар салабыз.
Шигырьләрен укып күңелләргә
Ялкынлы көч һәм дәрт алабыз.

**Авылкаем**

Чал гасырлы тарихларда булган
Авылкаем минем, әй Пучым!
Балачагым синдә гөрләп үтә,
Колач җәеп атлап барышым.
Таңнар да синдә яктырак,
Кояш сибә иркә нурларын.
Яшел чирәмендә йөгереп үскән,

Мин бит синең нәни кызчыгың.
Әй авылым, авылкаем минем
Шифа алам синдә күңелгә.
Кырларыңда очкан күбәләкләр,
Җырлар суза йөрәк түрендә.
Нигез ташы ныклы булсын өчен
Туган авыл кирәк һәркемгә.
Яшәү өчен көч алырга
Туган җире кирәк кешегә.
Мәңге яшә туган авылкаем,
Балкы син маяк булып.
Горурланам синдә туганыма,
Синдә якты тормыш юлларым!

**Гаиләм – җылы учагым**

Иң кадерле йомгагым,
Минем бәхет нигезем.
Исеме аның бик гади,
Гаиләм - җылы учагым.
Гади генә түгел ул,
Мәдәниятле гаилә.
Сәнгатьне, әдәбиятне,
Үз иткән матур гаилә.
Татар милли йолаларын
Ядкаръ итеп саклыйбыз.
Тарихларны актарабыз,
Мирасларны барлыйбыз.
Җырлыйбыз да, уйныйбыз да,
Тыпырдап биибез дә.
Сәхнәне бик яратабыз,
Чын милли җанлы гаилә.
Матур яшик, гөрләп яшик,
Гаиләбезгә иңсен нур.
Иман кунган күңелебезгә,
Хәзинәбез булсын ул.

**Шаян песи**

Тәгәри китте йомгагым,
Безнең киң урам буйлап.
Шаян песи күреп алды,
Күзләре булды шакмак.
Әй куана, әй сикерә,
Койрыгын болгый үзе
Читтән генә карап торам,
Үземә дә бик кызык.
Ниләр генә кыланмады
Йомгак белән песием.
Бераз уртәп алыйм диеп,
Мин дә килдем йөгереп.
Мине күргәч, әй качыра
Йомгакны шаян песи.
Әйтерсең лә, тычкан тоткан,
Баһадир булганмыни?!
Шундый кызык хәлләр була
Бу тормышта, дусларым.
Песиегез белән бергә,
Бер йомгакны тотсагыз.

*Шайдуллина Ильвина, 7 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының*
*«Яңа Әлмәт төп гомуми белем мәктәбе» муниципаль гомуми белем учреждениесе*
*Җитәкчесе: Ибрагимова Гульназ Назиф кызы, туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

**Мәңге үлмәс, Муса, синең җыр!**

Илең өчен диеп янып-көйдең,
Халкың өчен диеп көрәштең.
Үз-үзеңне бер дә аямадың,
Бөек көрәшләргә син дәштең.
Синең гомер җырга әйләнде дә,

Гасырларга күчте дәвамы.
Моңлы йөрәкләргә дәрт өстәдең,
Җырдан таптың бугай дәваны.
Үлмәс шигырьләреңдә яшисең,
Җырларыңнан сине таныйбыз.
Бөек Муса! Сине кабатланмас
Дәртле җырчыга без саныйбыз.
Төрмәгә яптылар...Тик анда да
Бирешмәдең, Муса, сынмадың,
Җырларыңдай янып яшәдең син,
Бер минут та тынып тормадың.
Күңелләрдә мәңге яшәр шагыйрь,
Калыр шагыйрь үлмәс җырында.
Горурланып искә алабыз без
Бөек Муса Җәлил турында.
Синең гомерең, Муса, якты маяк
Күтәрүчеләргә ил данын.
Бөек рухлы, кабатланмас шагыйрь,
Сине искә алдык без тагын.
Бөек шагыйрь булып танылдың да,
Безнең күңелләргә кердең син.
Шигырьләрең җырга әйләнделәр,
Шулай буласын да белдең син.
Халкым белән горурланам бүген:
Тудырган ул бөек Мусаны!
Нәкъ Җәлилчә тормышны яратып,
Илгә тугры булып булсамы...
Үлемең дә матур бер җыр булып
Сызылып калды ерак үткәндә.
Батырлыгыңа без сокланабыз
Гомер йомгагыңны сүткәндә.
Үткәннәр бит кире кайта алмый,
Тирән яра кинәт төзәлми.
Шигырьләрең безне өнди, Муса,
Чит кешегә илең бирмә! - ди.

Без дә, синнән үрнәк алырбыз да,

Туган илебез өчен яшәрбез.

Берәүгә дә, ишетәмсең, мәңге

Сөекле Ватанны бирмәбез!

Гомерең синең, Муса, моңлы бер җыр,

Ә үлемең-тагын моңлырак...

Бармы икән тагын шундый гомер

Синең гомердән дә нурлырак?..

Синең гомердән дә моңлырак...

*Шайдуллина Чулпан, 9 нчы сыйныф,*

*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының*

*«8 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе»*

*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*

*Җитәкчесе: Галина Венера Минсултан кызы,*

*туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

**Тыныч яшәргә язсын!**

Яратам мин көз айларын,

Яңгырлар күп яуса да.

Күңелемдә кояш көлә,

Көн болытлы булса да.

Чөнки мин сау-сәламәт,

Әти-әни янымда.

Өйдә рәхәт, табын иркен,

Җыр агыла җанымда.

Көзге яңгырлы кичләрдә

Җыелабыз табынга.

Гаиләбез тату безнең,

Горурланам шуңа да.

Исән булыйк, гел дус яшик,

Әти – әни пар булсын.

Туганнарым хөр яшәсен,

Тыныч яшәргә язсын!

**Туган телем**

Татар теле минем өчен
Иң кадерле, изге тел.
Наз булып ята җаныма
Җырлы, моңлы туган тел.
Шушы телдә әнием минем
Әкиятләр сөйләгән.
Аннан башымнан сыйпап,
Матур көйләр көйләгән.
Телем ачылган беренче
Татарча сүзләр белән.
Горурлык хисе кичерәм
Татар булуым белән.
Барлык телләр арасында
Йөрәккә якыны син.
Хисләрем ташый күңелдә –
Телләрнең асылы син.
Әлбәттә, башка телләрне дә
Белү кирәк кешегә.
Ләкин туган тел бер генә,
Син аны бик кадерлә!

*Шакирянова Амира, 6 нчы сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «7 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Камалова Гульназ Радик кызы,*
*туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

**Әнием минем**

Дәресләрем бетү белән,
Шалтыратам әнигә.
Өйдәме син, әнием, - дим,
Кызың кайтып керүгә.
Әйе, кызым, өйдә, - дисә,
Янына кайтам очып.
Анда җылы, якты, рәхәт,
Аламын аны кочып.
Нигә менә шулай икән –
Әни белән өй ямьле.
Өстәл тулы ризыгы да
Тик аның белән тәмле.
Телим аңа озын гомер,
Күңеле тыныч булсын.
Һәрвакытта янәшәмдә
Маяк булып ул торсын!

## «Без онытмаска тиеш!» Сугыш һәм тыл геройлары турында эзләнү-тикшерү эшләре

*Ахметвалиева Зәринә, 8 нче сыйныф,*
*«Биектау урта гомуми белем мәктәбе»*
*муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе*
*Җитәкчесе: Фәйзуллина Рәзинә Вәлимөхәммәт кызы,*
*тарих укытучысы*

### Бер солдатның тарихы

### Кереш

Сугыш... Күпме сагыш, кайгы, күз яшьләре алып килгән! Никадәр югалту, бәхетсезлек китергән тыныч хезмәт халкына. Кешеләрнең бәхетен урлап, рухын сындырырга, юк итәргә, колга әйләндерергә, тезләндерергә, алар өстеннән явызларча хакимлек итәргә теләгән. Безнең илнең көчсез, әле ныгып җитмәгән булуыннан файдаланырга теләгән. Ләкин бу канлы сугышны башлап җибәрүчеләр бер хакыйкатьне аңламаган. Безнең илебез яшь, көчсез булса да, аның горурланып сөйләрлек , курку белмәс, җиңелмәс батыр уллары, кызлары, шундый батыр йөрәкле балалар үстергән аналары барлыгын белмәгән алар. Безнең илебез зур сынаулар, авыр юллар, чиксез күп югалтулар белән җиңү таңын каршылады.

“Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!” исемле Бөтенрәсәй форумында катнашып, мин сезгә Бөек Ватан сугышында батырлык күрсәткән бабам – Марданов Әхмәтвафа турында сөйләп китүне максат итеп куйдым.

Бурычлар:

1. Сугыш чоры балаларының язмышы белән танышу; әби-бабайлар белән элемтәгә кереп, алар турында күбрәк материал туплау.

2. Патриотик тәрбия бирү, туган ил тарихына кызыксыну уяту.

**Теманың өйрәнелү дәрәҗәсе:** Биектау мәктәбе музеенда эшләп килүче “Батырлык - мәңгелек” түгәрәгенең бер әгъзасы буларак, мин Бөек Ватан сугышында катнашкан һәм тыл ветераннары турында мәгълүматларны күптәннән өйрәнеп киләм. Музеебызда сугыш ветераннары турында аерым бер бүлекне үзем тупладым.

Балык Бистәсендә урнашкан балалар иҗаты үзәгендә дә безнең авыл, аның кешеләре, сугыш чорындагы тормышлары турында бер альбом саклана.

Мәктәп музеенда һәр елны материаллар җыю максатыннан, укытучылар тарафыннан укучылар белән эзләнү эшләре оештырыла.

Эш кереш өлештән, ике бүлектән, йомгак һәм кулланылган әдәбият исемлегеннән тора.

**Төп өлеш.**

**1 нче бүлек.**

**Бер солдатның тарихы**

Кешелек дөньясына кайгы - хәсрәт китергән Бөек Ватан сугышы тәмамлануга сиксән ел вакыт узса да, аның ачы кайтавазы әле бүген дә үзен сиздереп тора. Гомерендә бер мәртәбә дә авыз тутырып “әти” дип әйтә алмаган балалар, хәзер инде үзләре әби-бабай яшендә, канлы ут эчендә йөргән чал ветераннарыбызның да саны елдан - ел сирәгәя бара. Бөек Җиңү көнендә аларның моңсу йөзләрендә һәрчак яшь тамчылары ялтырый.

Утлар, сулар кичкән шундый ветераннарның берсе минем олы бабаем – Марданов Әхмәтвафа Мәрдән улы. Ул 1924 елның 18 маенда Балык - Бистәсе районы Чаллыбаш авылында дөньяга килә. Әтисенең исеме Мәрдән, ә әнисе Шәмсебәдәр исемле була. Аларның биш балалары туа: Нуретдин, Әхмәтвафа, Асия, Шәрәфетдин һәм Зәйтүнә.

Бу гаиләнең тормышы тыныч кына барганда, ил эчендә «колхозлашу» чоры башланып китә. Кызганычка каршы, 1933 елда бу гаиләгә “кулак”исемен тагып, ерак Себер якларына куып җибәрәләр. Бабаемның әтисе Мәрдән Себердә авыр хезмәттән ике елдан соң үлеп китә. Ә әнисе Шәмсебәдәр, бабаема 14 яшь тулганда вафат була. Биш бала ятим кала, бер белмәгән чит җирдә, ят кешеләр арасында яши башлыйлар. Олы абыйлары Нуретдин һәм бабаем җилкәләренә шундый авыр тормыш килеп төшә. Беркөн алар киңәшләшеп, бер карарга киләләр «Үз якларына кайтып китәргә…». Нуретдин абыйның уе эш табып, бераз акча туплау була. Алар юлга чыгып китәләр һәм Пермь өлкәсендәге Половинка авылында тукталып калалар. Нуретдин абый шахтага эшкә урнаша, ә бабаем ат караучы булып эшли. Көннәрнең берсендә аларның өйләренә «кара» кайгы басып керә – абыйлары Нуретдин шахтада ишелгән җир катламы астында калып вафат була. Бабам кечкенә балалар белән берүзе кала. Нишләргә? дигән сорау аны борчый башлый. Ул туган якка, туган авылы Чаллыбашка кайтырга чыга.

Озын юллар узалар алар, ачлы-туклы да булалар,шуңа да карамастан көннәрдән-беркөнне Чаллыбашка кайтып керәләр. Авыл кешеләренең күбесе инде аларны оныткан була, арасында танымаучылар да очрый.

Бабай туган нигезен рәткә китерә, шунда яши башлыйлар. Аңа бу вакытта бары 17 яшь кенә була.

1941ел- Бөек Ватан сугышы башлана. Бер ел бабай колхозда эшли, наныйларын ташламый. 1942 елның җәендә ул сугышка китә. Өйдә хуҗа булып Асия исемле сеңелкәшен калдыра. Аларның аерылышулары бик авыр була, сабыйлар аны елап, авылны чыкканчы озатып баралар. Ул аларга: “Мине көтегез, үзегезне саклагыз – мин исән

кайтырга сүз бирәм" ди. Бу мизгелләрдә аның йөрәгендә нинди утлар янганын, ул үзе генә белгәндер.

1942 елның көзендә, ул 40 көнлек хәрби әзерләнүләрдән соң, Воронеж шәһәренә хезмәт итәргә җибәрелә. Ул 159 нчы ату полкында укчы булып хезмәт итә башлый. Фашистларга каршы көрәштә катнаша, күп кенә дошман белән кара –каршы бәрелешләрдә булырга туры килә аңа.

Минем бабам 1943 елның 5 июленнән – 23 августына кадәр дәвам иткән, иң канлы бәрелешләрнең берсендә – Курск дугасында катнаша. Бу бәрелеш Бөек Ватан сыгышында зур урын алып торган, совет солдатлары бу атышта зур батырлык күрсәткәннәр. Алар җиңүгә ышанып, алга барганнар, Ватан алдында изге бурычларын үтәгәннәр. Бу бәрелештә бабаемның уң аягы каты яралана, аны госпитальгә озаталар. Ул өч ай дәвалanганнан соң, кире фронтка кайта, хезмәтен дәвам итә.

Бабаем 1946 елда гына туган авылына кайта. Аны туганнары шатланып каршы алалар. Сугышта катнашканы өчен бабаем 15 тән артык орден һәм медальләр белән бүләкләнә. Алар арасында "За боевые заслуги", "За оборону Курска", "За победу над Германией в Великой Отечественной войне 1941-1945 года" һәм башкалар.

Минем бабаем 1947 елда авылның иң унган кызы Сания белән гаилә корып җибәрә. Аларның сигез балалары була: 5 малай һәм 3 кыз бала. Карт әби белән бергә 55 елдан артык тату гаилә корып яшиләр. Кызганычка каршы, 2003 елның 23 маенда бабаем кинәт авырып, безнең арадан китеп барды. Әбиебез, исә аның үлеменнән соң сулыкты, сүрәнәя төште. Әбине 2010 елның 16 маенда җирләдек.

Аларның зираттагы каберләре янәшә урнашкан. Без, балалары, оныклары, ел саен 9 май – Җину бәйрәме җитүгә, бергә җыелышабыз, зиратка юл тотабыз. Бабай белән әбинең каберләренә чәчәкләр утыртабыз, кабер урынын чистартабыз.

Мин бабаем белән әбиемне бик яратам, алар турындагы истәлекләремне барсына да сөйлисе килә.

**2 нче бүлек.**

**Гармун тарихы сәхифәләреннән. Җилкәсенә гармун асып, татар сугыш кичкән, кайгысын баскан, шатлыгын уртаклашкан, кайгысын уртаклашкан.**

Татарларда элек-электән гармунсыз авыл булмаган. Яшьләрнең аулак өйләре, кичке уеннары берсе дә уен-җырсыз, гармунсыз үтмәгән. Сугыш вакытында да гармун тарта белүче гармун кадәр генә бәләкәй малай авылда иң кадерле зат булган. Аны әнисеннән ялынып сорап, кышкы кичләрдә, кадерләп, чанага утыртып алып китәләр, китереп куялар. Иң авыр да, иң караңгы көннәрдә халыкны гармуннан аера алмады

Гармун татар халкының тарихында лаеклы урын алган җәүһәр. Хәзерге тормышыбызга кадәр аерылгысыз уен коралы булып тора. Кайберәүләр гармун юкка чыга ди, юк, ул киресенчә камилләшә генә бара.

Үземнең эшемдә гармун тарихы  Бөек Ватан сугышында батырлык күрсәткән бабам – Марданов Әхмәтвафа тормышында гармунның роле зур була.

Борынгы заманнардан ук татар халкы моңлылыгы, уен коралларында оста уйнавы белән аерылып торган. Татар халкында киң таралган уен коралларының берсе – гармун..

Йөрәкләргә рәхәт була
Гармунда бер уйнасаң.
Телгәли ул йөрәкләрне
Уйный белеп уйнасаң.
Нигә гармун чиртә икән
Күңелнең кылларына.
Кемнәр генә гашыйк түгел
Туган як моңнарына.

Гармунда тавыш чыгару өчен юка металл пластинкалар кулланыла, күренке тарткан вакытта шулар аркылы һава йөри һәм аларны тибрәтә, шулай итеп тавыш барлыкка килә. “Шена” дип аталган борынгы кытай уен коралында да шул принцип кулланылган. XVIII гасырда, шушы принципка таянып кечкенә органнар ясый башлаганнар. XIX гасыр башында беренче ирен гармуны ясала. 1829 елда хәзерге гармунга охшаган беренче гармун уйлап табыла. Шул еллардан башлап бик күп кенә осталар гармунны үзгәртү, яхшырту юнәлешендә эшли. Гармунны Вена шәһәрендә һәм Италиядә, XIX гасырның 30нчы елларында Россиянең Тула шәһәрендә ясый башлыйлар. Елдан-ел бу уен коралы камилләшә бара. Аны ясаучы осталар гармунның Тула, Бологой, Саратов, Себер, Касимовка һ.б. төрләрен булдыралар. Аннан соң ике рәтле Вена гармуны, бигрәк тә хромка дип аталган төре популярлык казана.

Татар гармунының тарихы Михаил Вараксин дигән оста исеме белән бәйле. XX гасыр башында Вятка губернасыннан килгән бу кеше Казанда гармуннар ясый башлый. Вараксин гармуннарының даны тиз арада еракларга тарала. 1934 елда гармуннар фабрикасы төзелә. Ә Татарстанда гармун ясау эше 1950-1960 нчы елларда киң колач җәя. Талантлы яшь осталар барлыкка килә. Татарлар арасында тальян гармун киң таралган. 1860 елларда ук этнографлар гармунны татар авылына хас музыка коралы дип язганнар. Аның көйләнеше татар көйләрен уйнарга бик җайлы.

Тальян моңнары ... Әби-бабайларыбызның яшьлек елларында иң кадерле әйберләре тальян  гармуны булган. Тормышның бар матурлыгы һәм гүзәллеге нәкъ менә шул тальян моңнарында кебек. Тальян моңнары элеккедән килгән гореф-гадәтләр турында сөйләүче дә.

Сөйлә әле, гармун, сөйлә, әле,
Сөйләсәң, син сөйли аласың
Көмеш телләреңә милләттемнең
Тарихын син язып барасың.
Син шаһит бит, сөйлә әле бүген,
Салып сөйлә озын көйләргә
Бик шат яшәгәнсең, диләр сине,
Элеккеге аулак өйләрдә.
Әйтче, гармун, ярдәмгә кил миңа
Сөйләсәң син сөйли аласың,
Үткәннәрне бүгенгегә ялгап,
Киләчәккә алып барасың.
Уйна, гармун, моңлы тальян гармун,
Бер сызласын әле күңелләр
Бәлки шуңа күңелләр уяныр –
Без бит әле үле түгелләр.
Уйна гармун, моңлы, тальян гармун,
Бер шатлансын әле күңелләр,
Рәнҗемәсен рухы беркемнең дә,
Җырлап үтсен әле, гомерләр!

Бабамның истәлеге итеп, аның моңлы гармунын саклыйбыз.

“Җан дустын” бабам сугышка да алып киткән. Анда буш вакытларында кулында гармун булган. Атышлар тукталып торган чакта, бабаем дусларынын күңелләрен күтәрү өчен гармунында милли көйләребезне уйнаган. Солдат дуслары аны түгәрәккә алып игътибар белән тыңлаганнар.

Тальян гармун моңнары аларның уйларын туган якка, туганнары, танышлары янына алып киткән. Җиңү көннәрен якынайткан сыман булган.

Солдат биштәрендә дә ул
Уйнап яткандыр, бәлки
Ялга туктаган чакларда.
Сөйләп баккандыр, бәлки.
Безнең гармун моңлы да ул,
Чапты да ул, урды да.
Безнең гармун җырлы да,
Сугышта да катнашкан ул.

## Йомгак

Дәһшәтле еллар афәтен һәр гаилә кичерде. Күп аналар тол калды, улларын һәм кызларын югалтты. Сугыш тирән яра калдырды, йөрәкләргә әрнү салды. Күңелләр һаман сызлана, сыкрый әле. Еллар буена газизләрен көтеп, югалту кайгыларын үзләре белән алып киткән − дөнья куйган аналар да  аз түгел. Хәзерге вакытта илебездә махсус хәрби операция булу сәбәпле  куп югалтулар бара.  Бөек Ватан сугышында  катнашкан ветераннарыбызны һәм хәзерге буын батыр егетләребезне, безнең онытырга хакыбыз юк.

Толларның күзендә,
Ятимнәр йөзендә
Сугышның шәүләсе бар һаман.
Күңелдә шом яши,
Җаен дә җан өши –
Сугышлар дөньяда булмасын!

Кулланылган әдәбият


1. Дәһшәтле чор балалары. – 15 томда. Т. 7. – Казан: Тат. кит. нәшр.,2010.
2. Ә.Н. Хуҗиәхмәтов. Тәрбия дәресләре, - Казан: Матбугат йорты нәшр., 1998.
3. Биектау мәктәп музее материаллары.



*Белодурова София, 9 нчы сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының*
*Бакый Урманче исемендәге «2 нче гимназия»*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениясе*
*Җитәкчеләре: Симкова Гульнара Алмаз кызы,*
*рус теле һәм әдәбияты укытучысы*
*Зарипова Әнисә Газизулла кызы,*
*туган тел һәм әдәбияты укытучысы*


## Туганнарымның хәрби юлы

### Кереш

Бөек Ватан сугышының дәһшәтле һәм фаҗигале көннәре елдан – ел ераклаша бара. Әмма халкыбыз 1418 көн буена дәвам иткән ул коточкыч вакыйгаларны һич тә оныта алмый. Сугышта 27 миллионнан артык совет кешесе һәлак булды, дистәләрчә миллион хатын – кызлар – тол, бик күп балалар ятим калды, инвалидлар биниһая булды. Илебез ярым җимерек хәлгә килде, халкыбыз күпме кайгы – хәсрәт кичерде?!

Президент Владимир Путин 2025 елны Россия Федерациясендә Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгы һәм нацизмга каршы көрәштә тынычлык һәм бердәмлек елы дип игълан итте.

Фәнни- тикшеренү эшемнең темасы – «Туганнарымның хәрби юлы». Минемчә, гаиләм тарихында Бөек Ватан сугышы эзләрен, яраларын яктырту **актуаль мәсьәләләрнең берсе дип саныйм**.

Беренчедән, быел без Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгын билгеләп үтәбез. Бу минем гаиләм өчен генә түгел, Бөек Ватан сугышында катнашкан ветеран бабам өчен дә истәлекле дата, ул көнне Ватаныбыз халкы фашистларны җиңүләре өчен бердәм ватанпәрвәлек һәм рәхмәт хисләрен яу кырында башларын салган һәм илебезгә Җиңү алып кайтан якыннарына, туганнарына җиткерә.

Икенчедән, кызганычка каршы, ветераннар саны кими бара, шуңа күрә безнең төп бурычыбыз: Ватаныбызны саклаган кешеләр турында материал туплау, өйрәнү һәм саклау.

Өченчедән, минемчә, һәр кеше үзенең бабаларын һәм Ватанны саклаучыларның язмышын белергә, алар белән горурланырга, аларны хөрмәт итәргә, истәлекләрен сакларга, ә белгәннәрен киләчәк буыннарга тапшырырга тиеш. Фәнни- тикшеренү эшемнең башкаруда төп чыганак: әти – әниемнең туганнары документлар. Тыныч вакытта Ватан чикләрен саклаган офицер, Кораллы Көчләр ветераны һәм Бөек Ватан сугышында катнашкан бабам турындагы истәлекләр нигезендә җыелган чыганаклар. .

Әлеге теманы сайлауның актуальлеге шунда ки: безнең сыйныф проектта яклауда катнаша, без гимназия музеен Бөек Ватан сугышында катнашкан кешеләр язмышы турындагы истәлекләр белән тулыландырабыз.

**Хезмәтемнең максаты -** сугыш елларында халкыбызның батырлыкларын өйрәнү, Хәтер Китабы битен тулыландыру.

Башкарылган анализ тикшеренү гипотезасын формалаштырырга мөмкинлек бирә: минем бабам-Шәрифуллин Алмаз Гарифулла улы Ватанны саклаучы иде, минем бабам-Шәрифуллин Гарифулла Шәрифулла улы Бөек Ватан сугышында катнашкан һәм Бөек Җиңүгә үзеннән зур өлеш керткән.

**Тикшерүнең проблематика тарафыннан ачыкланган куелган максаты түбәндәге конкрет бурычларны формалаштырырга мөмкинлек бирде**:

1. Бабамның сугыш юллары, бабамның Бөек Ватан сугышы ветераны Шәрифуллин Гарифулланың данлыклы батырлыгы турында мәгълүматлар туплау.

2. Бабамның һәм бабамның биографиясен, бабамның сугышчан юлын өйрәнергә.

3. Минем бабам Шәрифуллин Гарифулланың шәхесенә кагылышлы документларны табарга.

Куелган бурычларны хәл итү һәм тәкъдим ителгән гипотезаны тикшерү өчен түбәндәге тикшеренү методлары кулланылды:

- ✓ 1.гаилә архивын өйрәнү;
- ✓ 2.туганнар белән әңгәмәләр;
- ✓ 3.ветеран биографиясенең алынган фактларын ил тарихы белән чагыштыру;
- ✓ 4.җыелган мәгълүматны анализлау һәм гомумиләштерү

## II. Төп өлеше.

2.1 Хәрби бурыч.

Бөек Ватан сугышы вакытында халкыбыз ничек нык торды, ничек рухы сынмады, чөнки алар өлешенә бик авыр сынаулар туры килде. Алар кем – бу җиңүче солдатлар - мин бу хакта күптән түгел генә уйлана башладым, Хәрби бурыч ул- теләсә нинди вәзгыятьтә үз илемә тугры калу. Россия Федерациясенең Федераль законында болай диелгән: "Хәрби бурыч - хәрби хезмәткәрнең үз-үзен тотышының әхлакый-хокукый нормасы. Хәрби бурыч җәмгыять, дәүләт таләпләре һәм Кораллы Көчләрне билгеләү белән билгеләнә", ә «хәрби хезмәткәрләр статусы турында" бүлегендә хәрби хезмәткәр бурычлы диелә сугышчы Хәрби антка тугры булырга, үз халкыңа ихлас хезмәт итәргә, үз Ватаныңны батырларча һәм оста сакларга; Россия Федерациясе Конституциясен һәм Россия Федерациясе законнарын, гомумхәрби устав таләпләрен төгәл үтәргә, командирларның боерыкларын берсүзсез үтәргә;

Үз халкыңны саклаучыларның намусын һәм сугышчан данын, хәрби дәрәҗә намусын кадерләргә; во хәрби осталыкны камилләштерергә, корал һәм хәрби техниканы куллануга даими әзерлектә тотарга, хәрби милекне сакларга; тәртипле, уяу булырга, дәүләт һәм хәрби серне сакларга; Российской халыкара хокукның гомумтанылган принципларын һәм нормаларын һәм Россия Федерациясенең халыкара килешүләрен үтәргә. (2.1.3. Хәрби хезмәткәрләрнең бурычлары: гомуми, вазыйфаи һәм махсус)

Бу хәзерге вакыттагы законы, тик минем уйлавымча, безнең бабаларыбыз да, бабаларыбыз да бу статуска тулысынча туры килгән, шул исәптән минеке дә.

2.2. Икенче Белоруссия Көнбатыш фронты

Минем бабамның хәрби юлы 1944нче елның 24нче февралендә Белоруссия фронтының сул канат гаскәрләреннән Вгк ставкасының 1944 елның 17 февралендәге директивасы нигезендә формалашкан 2 нче Белоруссия фронты белән бәйле. Фронт составына 47 нче, 61 нче, 70 нче гомумхәрби армияләр, 6 нчы һава армиясе, Днепр хәрби флотилиясе. Соңыннан фронт составына 69 нчы гомумхәрби армия керде. Фронт берләшмәләре Төньяк-Көнбатыш Украина территориясендә һөҗүм сугышлары уздырдылар, дошманның Ковель группировкасын тар-мар иттеләр.

1944 нче елның 5 нчеапрелендә вгк ставкасының 1944нче елның 2 нче апрелендәге директивасы нигезендә гаскәрләрне 1 нче Белоруссия фронты составына тапшыру һәм кыр идарәсен вгк ставкасы резервына чыгару белән таратыла.

Яңадан 2 нче Белоруссия фронты 1944 нче елның 24 нче апрелендә Вгк ставкасының 1944 нче елның 19 нче апрелендәге директивасы нигезендә Көнбатыш фронтның сул канат гаскәрләреннән төзелә. Кыр идарәсе 10 нчы армия идарәсе базасында төзелә. Фронт составына 33 нче, 49 нчы, 50 нче гомумхәрби армияләр керде. Алга таба аңа 2 нче удар армия, 3 нче, 19 нчы, 43 нче, 48 нче, 65 нче, 70 нче гомумхәрби армияләр, 1 нче, 5 нче гвардия танк армияләре, 4 нче һава армиясе, Днепр хәрби флотилиясе керә. 1944 елның язында һәм җәендә фронт гаскәрләре Белоруссиядә һөҗүм иттеләр, һөҗүмнең бөтен полосасы буйлап Днепрны кичтеләр, Могилевны, Белостокны азат иттеләр, Минскины азат итүдә катнаштылар. 1944 елның август - ноябрь айларында фронт берләшмәләре Көнбатыш Белоруссиядә сугыш алып баралар, Көнчыгыш Пруссия һәм Польша чикләренә чыгалар, Нарев елгасының сул ярындагы ружан плацдармын алалар. 1945нче елның кышкы һөҗүме вакытында фронт гаскәрләре Вислага чыгалар, аның сул ярында Бромберг районында плацдарм алалар. Алга таба һөҗүм барышында Балтыйк диңгезе ярларына чыктылар һәм көнбатыштан һәм көньяк-көнбатыштан дошманның Көнчыгыш Пруссия группировкасын камап алдылар. 1945нче елның февраль-апрелендә 1 нче Белоруссия фронты гаскәрләре һәм Кызыл Байраклы Балтыйк флоты белән берлектә Польшаның төньяк районнарын азат иттеләр. 1945нче елның апрель - май айларындагы һөҗүм барышында фронт берләшмәләре Одерны аның түбән агымында кичтеләр, дошманның Штеттин группировкасын тар-мар иттеләр, Берлинны штурмлаган удар группировканың уң флангын тәэмин иттеләр. 1945нче елның 4 нче маенда фронт гаскәрләре Балтыйк диңгезенә һәм Эльбага чыгалар, анда 2 нче инглиз армиясе белән очрашалар. 9 нчы майга кадәр фронт частьлары һәм берләшмәләре Балтыйк диңгезе яры буендагы утрауларны азат итүдә катнаштылар.

1945нче елның 10нчы июнендә вгк ставкасының 1945 нче елның 29 нчы маендагы директивасы нигезендә таратыла. Фронт идарәсе Төньяк группа гаскәрләре идарәсе дип үзгәртелә.

## 3. Практик өлеш. Туганнарымның сугыш юлы

### 3.1 Әниемнең бабасы - Шәрифуллин Гарифулланың- сугышчан юлы

Минем бабам, әниемнең бабасы, Шәрифуллин Гарифулла, 1899 нче елның 13нче маенда туган. Ул батрак гаиләсендә дөньяга килсә дә, мәдрәсәдә белем ала, авылдан ерак түгел Кызыл Армия оеша башлый һәм минем бабам аның сафларына керә. Аңа Балтыйк флотында гражданнар сугышында матрос сыйфатында катнашырга туры килә. Гражданнар сугышыннан соң туган авылы Мөслим районының Түбән табынга кайткач, бабасының бабасы колхозның

беренче рәисе итеп сайлана, аннары Мөслим районы май заводына идарәче итеп билгеләнә. 1938 нче елда бабайны кулга алалар һәм Минзәләгә төрмәгә озаталар. Аннан 1942 нче елда бабам фронтка китә. Минем бабамның кызылармеецлар турында язылган китабы сакланган. Мин бабамның сугыш юлы һәм Ватан картасында нинди эз калдыруы турында шуннан белдем. 1942 нче елның 16 нчы ноябрендә Минзәлә хәрби комиссариаты хәрби бурычны үтәргә рөхсәт бирә. Кызганычка каршы, Шәрифуллин Гарифулла гаскәри хезмәте турында башка мәгълүматлар юк. Ләкин әти-әниләр белән документларны өйрәнгәннән соң, без бабайның ргкның 257 нче гвардия укчы дивизиясендә Днепрга кадәр барып җитүе һәм Икенче Белоруссия Көнбатыш фронтында тарихтагы иң зур сугышларның берсендә катнашуы турында белдек. Бу сугышта ике яктан да 4 миллионга якын кеше катнашты, ә фронт 750 километрга сузылды. Фашист гаскәрләрен өзеп, Днепрның икенче ярына чыгарга кирәк иде. Бурыч авыр иде, чөнки өстән немец авиациясе бомбага тота иде. Днепр өчен сугышта җиңү безгә бик кыйммәткә төште. Бу сугыш иң канкойгыч сугышларның берсе иде. Интернеттагы чыганаклардан без 400000 дән алып 1 200000 гә кадәр кешенең һәлак булуын белдек. Днепрны кичкәндә бик яхшы сугышчан батырлыклары өчен минем бабам «Батырлык өчен» медале (приказ no 49200) белән бүләкләнзнде, ләкин башта җиңелчә яралана (яралану турында белешмә, ә аннары каты контузия ала һәм госпитальгә озатыла.

Госпитальдә дәваланганнан соң, бабам яңадан фронтка кайта. Ул Икенче Белоруссия фронтында сугышкан һәм Берлинга кадәр диярлек барып җиткән. Сугыштан исән- сау туган якларына әйләнеп кайтырга насып була аңа. Бабам озак гомерле булган, ул 1993 елда 94 яшендә үлгән.

**3.2**

1947 нче елның 25 нче гыйнварында минем бабам – Шәрифуллин Алмаз Гарифулла улы туа. Әнисенең истәлекләре буенча, ә ул үз чиратында моны әтисеннән белә, Алмаз бабай, үскәч, Ватанга хезмәт итү эшен сайларга карар кыла һәм офицер була. Башкача булуы мөмкин түгел иде, чөнки ул Бөек Ватан сугышында катнашучының улы иде. Әтисе Алмазга еш кына үзенең Ватанны саклавы турында сөйли иде. Сугыш вакытында тылдагы авырлыклары, бигрәк тә фронтта кичергән, күргәннәре сөйләде. Минем бабамга хәрби эш иң яхшы һәм иң дөрес эш булып тоелды. Шуңа күрә ул сугышчан юлын сайлаган.

Ерак авылдан Ленинград хәрби академиясенә укырга керергә җөрьәт итсә, бабай бик көчле холыклы булгандыр, күрәсең. Әмма, рус телен начар белү укырга керү өчен кирәкле баллар җыярга мөмкинлек бирмәде. Бабай өметсезлеккә бирелми, ул Азербайджанга китә һәм Баку югары хәрби училищесына укырга керә. Үзен яхшы курсант итеп күрсәткәнгә күрә, аны тәмамлагач, кече лейтенант дәрәҗәсендә Германиягә хезмәт итәргә җибәрәләр. Ул вакытта Алманиянең бер өлеше социалистик ил булган һәм совет гаскәр частьләре

тынычлыкны саклап калу өчен тырышканнар. Ватан картасы буенча юл 1971 елдан башлана, ул вакытта бабайны Усть-Каменогорск шәһәре янындагы мотоукчылар частена күчерәләр. Минем әни шунда туды. Безнең гаиләдә бер вакыйга бар, аны миңа бием сөйләде, минем бабамның хәрби-кыр өйрәнүләреннән туп-туры БТРда бала тудыру йортына килүе турында, кызы тууы турындагы хәбәргә шатланып. Бабай гаиләсе белән Советлар Союзы гарнизоннарында хезмәт иткән, солдатларны хәрби сәнгатькә өйрәткән. Усть-Каменогорскидан соң аны чик буе хәрби шәһәре Арыська күчерәләр. Шуннан соң Экибазтуз шәһәренең хәрби частена,аннары Семипалатинскига. 25 ел хезмәт үз туган җирләреннән – яраткан Татарстаннан еракта узды. Хезмәтенең соңгы елларында бабайга хәрби комиссариатта чакырылыш буенча эш башкарырга, кыр өйрәнүләрен оештырырга туры килде. Бабай гаиләсе белән Советлар Союзының төрле почмакларында яшәгән, ә туган Татарстанга кайткач, туган шәһәребез Түбән Камада училищеда хәрби кул булып эшләгән. Бабай 2011 елның 29 ноябрендә 64 яшендә вафат булды.

**III. Йомгаклау һәм нәтиҗәләр**

Гаилә архивын өйрәнеп, туганнарыбыз белән сөйләшеп, туганнарыбызның сугыш юлын гомумиләштердек һәм мондый нәтиҗәгә килдек: ныклык, кыюлык һәм батырлык ул сугышта нык калырга һәм дошманны җиңәргә ярдәм итте, ә 1 тормышка ашырылган анализ тикшеренү гипотезасын расларга мөмкинлек бирде: минем бабам – Шәрифуллин Алмаз Гарифулла улы – Ватанны саклаучы, минем бабам-Шәрифуллин Гарифулла Шәрифулла улы Бөек Ватан сугышында катнаша һәм Бөек Җиңүгә кулыннан килгәнчә өлеш кертә.

Бабамның сугыш юллары, бабамның Бөек Ватан сугышы ветераны Шәрифуллин Гарифулланың данлы батырлыгы хакында белешә алдык, бабамның шәхесенә кагылышлы документлар таба алдык.

Әлеге эш мәктәп музейларын, шулай ук шәһәр музеен тулыландырырга мөмкин.

Без үзебездән киткәннәрне хәтерлибез. Буыннар элемтәсе тере. Димәк, безнең ил исән!

**IV. Мәгълүмат чыганаклары һәм әдәбият исемлеге**


1. https://ru.wikipedia.org/wiki/2-Белорусский_фронт
2. Устав внутренней службы Вооруженных Сил Российской Федерации (утв. указом Президента РФ от 10 ноября 2007 г. N 1495)
3. Мостафин, Ш. Хетер яктысы: Документаль-публицистик язмалар / Ш. Мостафин. – Казан : Татар.кит.нәшр., 2004.-191 б.
4. Иванов, А. А. Память. 27 том. 2 книга / гл. редактор А. А. Иванов; отв. редактор Н. Г. Габдрахманов. – Казань : ГУ Редакция «Книга Памяти» при КМ РТ, 2010. – 351 с.

*Галиев Искандер, 10 нчы сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Казан шәһәре*
*Совет районының «Аерым фәннәрне тирәнтен*
*өйрәнүле 144 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе»*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләре: Заляливева Лейсан Равил кызы,*
*Минзянова Гульсум Абдулгазиз кызы,*
*туган тел һәм әдәбияты укытучылары*

## Г.Әпсәләмов хикәяләрендә батыр сугышчы образын тудыру алымнары, табигать образлары һәм тасвирлары

КЕРЕШ

Бөек Ватан сугышы башлануга барлык язучылар, бөтен халык белән бердәм булып, илне басып алучыларга каршы күтәрелделәр. Күп язучылар, кулларына корал алып, сугышка киттеләр, фронт газеталарында эшләделәр, турыдан-туры сугышта катнаштылар: Г.Әпсәләмов, И.Гази, А.Шамов, Ф.Кәрим, Г.Кутуй, Ә.Еники, Ш.Маннур, Ш.Мөдәррис, М.Җәлил, А.Алиш һ.б. Кызганычка каршы, 30 дан артыгы сугыш кырларында яисә әсирлектә һәлак булдылар.

Кеше кайчан халык күңеленә мәңгегә кереп урнаша соң? Зур батырлыклар эшләсә, аның өчен яшәсә, аның мәнфәгатьләрен һәм хәсрәтләрен чагылдырып иҗат итсә... Әйе, язучыларыбыз һәм шагыйрьләребез явыз дошманны җиңү өчен изге сугышта катнашып кына калмадылар, искиткеч батырлыклар күрсәтеп, үлмәс әсәрләр дә иҗат иттеләр. Фронт вакыйгаларын, фашистларның җинаятьләрен һәм сугышның җанлы эпизодларын күрсәткән шигырьләр, хикәяләр яздылар.

Фәнни эшемне сугыш чоры әдәбиятында кеше образын ачу өчен сугышның үзәгендә булган, фронтовик язучы Г.Әпсәләмов әсәрләренә нигезләнеп тәкъдим итәм.

Г.Әпсәләмовның Бөек Ватан сугышы чорында язылган хикәяләрендә геройларның сурәтләнеше, характерларның ачылышы - шактый үзенчәлекләргә бай өлкәләрнең берсе. Образларның әдәби эшләнеше, аларга йөкләнгән әдәби-эстетик мәгънә ягыннан Г.Әпсәләмовның стиле бу чор язучыларыннан аерылып тора.

Фәнни эшнең объекты итеп Габдрахман Әпсәләмовның хикәяләре алынды һәм анализланды.

Эшемнең максаты - Габдрахман Әпсәләмов хикәяләрендә батыр сугышчы образын тудыру алымнарын, табигать образлары һәм тасвирларын тикшерү.

Бурычларым:

-хикәяләрдә сугышчы образын тудыру алымнарын анализлау;

- әдипнең хикәяләрендә табигать образларын һәм тасвирларын өйрәнү

## Г.ӘПСӘЛӘМОВ ХИКӘЯЛӘРЕНДӘ БАТЫР СУГЫШЧЫ ОБРАЗЫН ТУДЫРУ АЛЫМНАРЫ

Сугыш чоры хикәяләрендә Г.Әпсәләмов, гадәттә, фронт тормышыннан алынган бер эпизодта героеның мөһим бер характер сыйфатын аерып чыгара һәм шуны сөйләмендә дә, үз-үзен тотышында да, тышкы кыяфәтендә дә билгеләргә омтыла. Әдип үзенең героен төрле сынаулар аша уздыра һәм аларда образның характер сыйфатларын аеруча ачык чагылдырырга, бөтен тулылыгы белән гәүдәләндерергә омтыла.

“Егетнең асылы” (1944) хикәясендә дә автор үзенең стиленә хилафлык китерми. Бу хикәянең үзәгендә - гади бер сугышчы. Ләкин автор аның тышкы һәм эчке сыйфатларын ачып бирү, батырлыкларын сурәтләү аша укучыга якынайта, җылылык, дуслык кебек сыйфатлар өрә. Хикәянең беренче юлларында диярлек автор “егетнең асылын” башкалардан аерып куя: “Аннары уң флангтан алып һәрбер сугышчыга аерым туктала-туктала сораштыра башладым. Барысының да йөзләре кырыс,беркадәр ябык иде. Тик сул флангта баскан тәбәнәк буйлы, йомры гәүдәле бер сугышчының йөзендә генә хәйләле елмаю чагыла, кысык күзләре ялтырый, яңаклары, яшүсмерләрнеке шикелле, ут янып тора”. Г.Әпсәләмов үзенең героен сурәтләүне һәр эпизодта дәвам итә. Укучыны алдарак кыяфәтен сурәтләгән образ белән таныштыруны диалог алымын кулланып башкара. Ул - гвардия ефрейторы Әсрар Хәмидуллин икән. Диалог аша прозаик сугышчының сөйләшүенә дә бәя бирә, геройның үзенә генә хас сыйфатларын - һәрвакыт елмаеп торуын билгели. Бу юл белән автор аны тагын бер тапкыр башка сугышчылардан аерып куя.

Биредә беренче карашка Әсрарның, башкалардан аермалы буларак, һәрвакыт елмаеп торуы аның сугыш кырына беренче аяк басуы кебек аңлашылырга мөмкин. Чөнки сугыш һәм елмаю бер-берсенә капма-каршы мәгънәдәге сүзләр. Беренчесе кайгы, хәсрәт, үлем, кан, күз яше кебек сүзләр белән аваздаш булса, икенчесе шатлану, сөенү билгесе буларак кабул ителә. Һәм алгарак китеп шуны да әйтергә кирәк: Әсрар Хәмидуллин образын ачу аның елмаюына бәя бирү аша башкарыла.

Диалог дәвам итә. Г.Әпсәләмов алда искәртеп кителгән аңлашылмаучылыкка ачыклык кертә - Әсрар образының үзеннән аның сугышта кылган батырлыклары хакында әйттерә, ягъни командирның “Сугышка кергәнегез бармы?”, “Бүләкләрегез?” кебек сорауларына җавап ала һәм аның зур батырлыклар кылганда гына бирелә торган бик күп бүләк иясе булуы күренә.

Г.Әпсәләмов сугышчыны сынау, аны эштә күрсәтү, бу образны тулырак ачу өчен вакыйгалар өермәсенә алып кереп китә. Әдәби автор ротасының бурычы - дошман тылына үтеп керү. Юл мәкерле упкыннары булган “Җәһәннәм тавы” аша үтә.

“Хәмидуллин беренче взводта бара иде. Бервакытны мин аның яныннан үттем. Безнең күзләр очрашты. Икебез дә елмайдык. Ышанырсызмы, бу эчкерсез елмаюдан күңелемдә сүз белән әйтеп бирә алмаслык җылы тойгы уянды,” - дип сурәтли автор Әсрарның хәрби бурыч үтәүгә бару күренешен. Бу юлларда командирның баштарак шикләнебрәк караган сугышчыга мөнәсәбәте үзгәрә башлау да сизелә. Тасвирда “эчкерсез елмаю” эпитетын файдалану шуның ачык мисалы булып тора. Әлеге юллар геройның характерын ачуга да хезмәт итәләр.

Тора-бара “елмаю”ның күләме арта - геройның шактый шаян, үткен телле булуы аңлашыла. Бәя кече старшина тарафыннан бирелә:

- Безнең ротаның хәзер үз артисты бар, иптәш гвардия капитаны, - диде. - Элек сугышчылар землянкада тып-тын утыралар иде, ә бүген авызларын җыеп ала алмыйлар.

- Кем ул артист? - дип сорадым мин.

- Кем булсын, ефрейтор Хәмидуллин. Ну тел үзендә, иптәш гвардия капитаны, тотлыкмый да, күзен дә йоммый...

Мин дә көлмичә чыдый алмадым. Чыннан да, егетнең фантазиясе бай икән. Старшина кадәр старшинаны гаҗәпләндергәч, сугышчыларга ничек итеп тәэсир итүе үзеннән-үзе билгеле инде”.

Сугышчылар алдында текә тау. Кайчандыр бирედә авторның булганы бар. Командир хәтерендә ул куркудан, дошманыннан качып котылырга теләгән боланның шул текә ярдан сикереп аягын сындыру күренешенә бәйле рәвештә яңара. Ә хәзер бирედән гади кешеләр-сугышчылар төшәргә тиеш. Кем беренче?.. Шулкадәр кыюлык, көч соралган бу эшкә кем беренче алыныр?..

Әлбәттә, беренчеләрдән булып “Егетнең асылы” хикәясенең төп герое Әсрар теләк белдерә һәм “тау битен кыйгачлатып”, түбән таба төшеп тә китә, “күз иярмәс тизлек белән югары күтәрелә, гаҗәеп кош сыман һавага оча, югала, тагын күренә,тагын югала”. Барысын да сокландырган бу вакыйгадан соң Әсрар тагын да көчлерәк батырлык сораган геройлык кыла - үлем алдында тезләнмәгән, баш имәгән, куркып калмаган бу егет командирын саклап калу өчен дошманга үз күкрәген куя, немец пуляларын үзенә ала. Ләкин дошман пулялары, үлем куркынычы гына егетнең шаян күңелен, батыр йөрәген сүндерә һәм сүрелдерә алмый.

Дүрт бүлектән торган бу хикәянең соңгы ике өлешендә командир белән батыр Әсрарның кабат очрашуы сурәтләнә. Сугышның ачы җилләре, аяусыз утлары егетне кабат читләтеп үтмәгән. Ул госпитальдә дәваланып ята. Әсрарның бөтен йөзе-башы марля белән

уралган, бары авызы гына ачык калган һәм иң аянычлысы - аның күзләре күрми. Әмма сугышчы, эчендә кайгы-хәсрәт булса да, башка авыруларның күңелен күтәрергә омтыла, авыр сынаулар алдында калса да, киләчәккә якты өмет белән яши, терeләчәгенә, дошманны җиңү шатлыгын күрәчәгенә ышана, "аның тавышы ышаныч һәм якты өмет белән тулы".

Бөек Ватан сугышы еллары әдәбиятында, гомумән, әйдәп баручы темаларның берсе - халыкның җиңүгә ышанычы, батырлыгы. Г.Әпсәләмовның "Егетнең асылы" хикәясендә соңгы юлларда көчле яңгыраш алган бу мотив Ф.Кәримнең "Язгы төндә", И.Газинең "Алар өчәү иде" хикәяләрендә дә үзәккә куела.

Шул рәвешле, Г.Әпсәләмов "Егетнең асылы" хикәясендә үзәк герой-Әсрарны төрле яссылыкта сурәтли (тышкы кыяфәте, характер үзенчәлекләре, хәлиткеч вакыйгаларда үз-үзен тотышы, Ватанга, кешеләргә мөнәсәбәте һ.б.). Бу максаттан автор вакыйгалар үстерелешен, чагыштыруларны, геройга төрле персонажларның бәясен куллана.

Г.Әпсәләмов әсәрләрендә күңел процессы конкрет предметларга тиңләштерелеп бирелә, аның әсәрләрендә табигатьнең матурлыгы берничә чагыштыру аша геройның эчке халәте белән үрелеп китә. Г.Әпсәләмов геройларның эчке халәтен тирәнрәк тасвирлаганда да чагыштырулардан оста файдалана.

Әдипнең геройларны психологик планда сурәтләү, эчке дөньяларын укучыга җиткерү һәм бу алымны хикәянең төп сәнгати чарасы итеп куллануы аны татар әдәбиятында психологизм остасы буларак танылган Әмирхан Еники әсәрләренә якынайта. Ә.Еникиның сугыш темасына багышланган "Бала", "Ана һәм кыз", "Бер генә сәгатькә" әсәрләрендә дә психологик халәт алгы планга чыга, сугыш чоры кешеләренең эчке дөньяларын ачу аша яшәү һәм үлем, бурыч һәм намус, кайгы һәм өмет мотивы гәүдәләнә. Бу төшенчәләр Г.Әпсәләмов хикәяләрендә дә кабат-кабат ассызыклана. Әмма биредә бу ике әдипнең әсәрләре арасындагы аерманы да искәртеп китәргә кирәк: Г.Әпсәләмов хикәяләрендә вакыйга бары тик сугыш кырында, җаваплы хәрби бурыч үтәү вакытында табигать күренешләре белән янәшә бирелсә, Ә.Еники әсәрләренә әдәби урын киңлеге хас.

Г.Әпсәләмов хикәяләрендә гомерләрен куркыныч астына куеп зур батырлыклар эшләгән геройлар – гади кешеләр. Алар арасында тыныч тормышта умартачы булып эшләгән Рәшит тә ("Бөркет токымы"), Мәскәүдә "Урак-чүкеч" заводында кара эшче вазыйфаларын башкарган Абушахман да ("Абушахман") һ.б. бар. Иң гади совет кешеләре батырлык эшләргә сәләтле дигән фикер сугыш чоры әдәбиятында башка авторларның хикәяләренә дә хас күренеш булып санала.

Г.Әпсәләмовның сугыш чоры хикәяләрендә дошманнарның сурәтләнеше гаять үзенчәлекле характерда. Авторның барлык хикәяләрендә дә диярлек, дошман гомуми планда гына бирелә. Укучыга аның исеме дә, конкрет шәхесе дә, конкрет кыяфәте дә

аңлатылмый. Ул әсәрләрдә “дошман”, “немец”, “гитлерчы”, “ак фин”, “фин”, “ерткыч” кебек атамаларга гына ия. Прозаик каләмендә дошман солдатларының эш-гамәлләре дә аларның ерткычлыгын, кансызлыгын, вәхшилеген тасвирлау, күп вакытта бу эшләрнең нәтиҗәсен күрсәтү, яки берничә сүз белән генә әйтеп китү белән генә чикләнелә.

Шул рәвешле, Г.Әпсәләмов хикәяләрендә төп геройлар-батыр, кыю солдатлар, Ватан сакчылары. Әдип үзенең әсәрләрендә геройларны тулырак ачу, аларның батырлыкларын, күркәм сыйфатларын табигыйрак чагылдыру өчен хикәяләрнең төзелешеннән, композицион мөмкинлекләреннән, табигать күренешләреннән, рухи кичерешләрен сурәтләүдән оста файдалана. Дошман гомуми характерда гәүдәләнә, автор басып алучыларга нәфрәт белән карый һәм бу сыйфатны геройларның да эш-гамәлләре нигезенә сала, рухи кичерешләренең сәбәпчесе итә.

ТАБИГАТЬ ОБРАЗЛАРЫ ҺӘМ ТАСВИРЛАРЫ

Г.Әпсәләмов бөтен иҗаты белән - романтик рухлы язучы. Аның хикәяләре гаҗәеп бер яктылык, күңел күтәренкелеге белән аерылып торалар. Һәр әсәрнең вакыйгалары гүзәл, мәһабәт табигать кочагында бара, әйтерсең туган җирнең табигате үз улларына көч-куәт биреп, аларны саклап тора. Үлгән очракта да ул аларны кадерләп үз куенына ала. Табигать мәңгелек булуы белән үк вакытлы күренеш булган сугышка каршы куела, табигать каршында сугыш никадәр зыян китерсә дә, барыбер көчсез булып кала.

Г. Әпсәләмовның “Зәңгәр иртә” хикәясе 1945 елда язылган. Бу әсәрдә автор сугыш кырындагы вакыйгаларны табигать күренешләре белән янәшә сурәтли, аяусыз көрәш, хис-кичерешләр җил, буран, урман, күк белән тәңгәллектә бирелә. “Зәңгәр иртә”гә хас әлеге үзенчәлек хикәянең беренче юлларыннан ук үзен сиздерә: “Нурулла туктады да артына борылып карады. Куып килүчеләр күренми иде. Куе урман һичбер җан әсәре булмаган шикелле тып-тын, хәтта артык тын иде”.

Хикәядәге табигать һәм вакыйгалар янәшәлеген түбәндәге таблицадан күрергә мөмкин:

| | |
|---|---|
| Нурулланы куып килүчеләр юк. | Урман тып-тын. (18 б.) |
| Ләкин аның йөрәге тибүдән туктамаган әле, аның йөрәге яшәүгә сусап тибә. | Шулай ук җир йөзендә дә кич түгел, иртә, иртәнең дә фирүзә төслесе! (24 б.) |
| Солдатлар чаңгы белән баралар. | Ай нурында коенып утырган ап-ак урман әкрен генә гөжли иде. (20 б.) |
| Ардашев автоматыннан атты. | Урман эче, чәлпәрәмә килгән пыяла сыман, яңгырап китте. (21 б.) |
| Берничә минут чамасы һичнәрсә аңламыйча, һичнәрсә тоймыйча, үлек шикелле хәрәкәтсез ятты. Аннары ... аның | Ул бәсләнгән керфекләрен күтәрде һәм гаҗәеп бер күренеш алдында хәйран калды: кар баскан агачлар котырынып-котырынып |

| | |
|---|---|
| томаланган зиһене әз-әз генә ачыла башлады. | бииләр, күк йөзе әллә нинди кызыллы-сарылы куркыныч төскә кергән.(21 б.) |
| Нурулла күзләрен ачты | Бу юлы агачлар үзләренең котырынып биюләреннән туктаганнар, күк тә үзенең табигый зәңгәр төсенә кергән иде. (22 б.) |
| Нурулла бу секундта үлемнең чиксез якын булуын гына сизде һәм бөтен көчен аңа каршы көрәшкә туплады. | Урмандагы һәрбер агач, дөньяга тереклек бирә торган кояшның һәр тамчы нуры, ниһаять, йөрәгенең һәр тибеше: “Яшәргә! Яшәргә!” - дип кабатлыйлар иде. (23 б.) |

Күргәнебезчә, Г.Әпсәләмов Нурулланың кичерешләрен тулырак чагылдыру максатыннан урман, күк, кояш образларын файдалана, аларны җанландыра, хикәянең геройлары дәрәҗәсенә күтәрә. Якында дошманнарның, куркынычлыкның булу-булмавы урман шавы аша аңлатылса, яшәү - кояш нурлары, табигый зәңгәр күк, фирүзә төсле иртә, үлем кызыллы-сарылы куркыныч күк йөзе  образлары белән бирелә.

Хикәядә табигать вакыйгаларга каршылыкта да сурәтләнә. “Якында кемнеңдер сулыш алуы ишетелгән төсле тоела. Нурулла иреннәрен нык кысып, сулышын туктату белән гыжлау да тынды. Аның каравы урман тынлыгы тагын да тирәнәйгән, серлеләнгән кебек булды,” - дип яза автор хикәянең башлангыч юлларында. Антитеза  алымы Нурулла өчен куркыныч күренешләрнең алда булачагына ишарәли. Гомумән, Г.Әпсәләмов укучының игътибарын урман тынлыгына юнәлтә, алдарак “куе урман һичбер җан әсәре булмаган шикелле тып-тын, хәтта артык тын иде” дисә,  бу очракта, сулыш алу күренешенә бәйле рәвештә, “ урман тынлыгы тагын да тирәнәйгән, серлеләнгән кебек булды”, - дип яза. Татар әдәбиятында да, халык авыз иҗатында да тирән тынлык хәвеф-хәтәр билгесе буларак чагылыш таба.

“Зәңгәр иртә” хикәясендә вакыйга кыш көнендә урман, тау, күл буенда бара. Шунлыктан табигать тасвирлары әдәби урын чагылышы буларак та китерелә. Автор кырлар, урманнар, күлләр, елгалар  аша укучыны да хәрби бурыч белән юлга чыккан ике герое - Нурулла белән Ардашев артыннан алып китә. Текстка мөрәҗәгать итик: “Ардашев алдан барды. Ай яктысында чалгы эзләре ап-ачык күренәләр! Аланнарда, киң сазлыкларда ул эзләр зәңгәрсу тасмалар шикелле ялтырап еракка-еракка сузылалар. Бара-бара чаңгычылар бер тауга килеп җиттеләр. Түбәндә очлы чыршылар белән уралган  түгәрәк күл җәелеп ята. Болыт кисәкләре тулган айны әледән-әле каплап торганлыктан, күл өсте бер яктыра,  бер карасуланып китә”.  Икенче бер мисал: “Матур зәңгәр иртә туып килә. Ап-ак каен урманы шул нәфис зәңгәрлек эчендә искиткеч  матур бакчага охшый; кояш әлегә күренми, тиздән аның тәүге алтын нурлары бәллүр урман эченә сибелерләр дә каенның

бәскә төренгән бөдрә ботакларыннан тамып торган ак мәрҗәннәрдә, серле топазларда чагылып уйный башларлар”. Шул рәвешле, Г.Әпсәләмовның “Зәңгәр иртә” хикәясендә вакыйгалар табигать күренешләре янәшәсендә сурәтләнә.

Вакыйгалар белән табигать бердәмлеге, геройларның психологик халәте табигать белән бәйләнештә ачылу Г.Әпсәләмовның башка әсәрләрендә дә күзәтелә. Әлеге алымны үзәккә алган әсәрләрнең берсе - “Икенче гомер”(1943). Бу хикәядә дә, алдарак тикшерелгән “Зәңгәр иртә”дәге төсле үк, совет солдатларының батырлыгы, көче, җиңүгә ышанычы һәм яшәү, үлем, гомер төшенчәләренең фәлсәфи чагылышы нигез итеп алына.

“Икенче гомер” хикәясе табигать тасвирлары белән башланып китә. Автор өч тәүлек буена туктамыйча искән салкын, үзәккә үтә торган җилне сурәтләве белән укучыны әсәрнең беренче юлларыннан ук булачак вакыйгалар, сугыш кыры, солдатларның рухи халәтләре һәм тормышлары эченә алып кереп китә.

“Әле күптән түгел генә ап-ак халат кигән төсле, ак бәсләргә төренеп, тирән хыялга, очсыз-кырыйсыз уйларга чумып торган биек наратларның ылыслары, яшь килендәй нәфис ак шәл бөркәнгән ак каеннарның ботаклары шәрәләнде, каралды. Урман, кара урман, кемгәдер ачуланган сыман, меңнәрчә тавышлар чыгарып шаулады, үкерде. Кургашын төсендәге авыр, соры болытлар белән капланган күк йөзендә көндез-кояш, төннәрендә ай һәм йолдызлар күренмәде. Бары вакыт-вакыт, төнге караңгылык чаршавын ертып, ак ракеталар гына күккә күтәрелде һәм ерак тупларның ялкыннарыннан кабынып-кабынып киткән кызгылт шәүләләр генә, аҗаган утлары кебек, бик азга ялтырадылар”, - дип яза Г.Әпсәләмов. Шул рәвешле, табигать күренешләрен, салкын җилнең һәм аның нәтиҗәсенең тасвирын салмак кына ак ракеталар очуы, ягъни якында барган сугыш хәбәре алыштыра.

Соңрак автор фронт сызыгының артта, еракта калуын әйтеп үтә һәм әсәрнең геройлары белән таныштыра башлый. Прозаик хикәянең салмак тонына тугры калып һәм серлелекне саклап, таныштыруны түбәндәге җөмләдән башлый: “Биредә, дошман тылында, бары тик урман гына шаулый һәм берүзләренә генә билгеле булган сукмаклардан үткен разведчиклар гына йөри...” Укучы “Икенче гомер” хикәясенең геройлары үткен, батыр разведчиклар булачагын аңлый. Әлеге җөмләдә Г.Әпсәләмов стиленең тагын бер үзенчәлеге күренә: ул - урман образы. Алдарак анализланган “Зәңгәр иртә” хикәясендә дә вакыйгалар үстерелешенә бәйле рәвештә шаулаган, тавышланган яисә бөтенләй тынып калган урман образы “Икенче гомер”дә дә дәвам иттерелә. Ләкин өч өлештән торган икенче әсәрдә ул бары тик беренче өлештә генә кулланыла.

Шул рәвешле, табигать күренешләре, урман, кыя, тау образлары Г.Әпсәләмов хикәяләренең аерылгысыз бер өлеше. Гүзәл табигать күренешләре геройларның хисләрен чагылдыручы, эш-гамәлләренә бәя бирүче, булачак вакыйгаларга ишарәләүче һәм батырлыкның көчен күрсәтүче алым булып торалар.

# ЙОМГАК

Илебез тарихының гаять авыр, катлаулы, төрле каршылыкларга һәм җиңүләргә бай булган Бөек Ватан сугышы еллары татар әдәбияты - татар әдәбияты тарихының иң кечкенә һәм иң үзенчәлекле чорларының берсе.

Бу дәвернең иң үзенчәлекле сыйфаты шунда - сугыш башлануга барлык язучылар, бөтен халык белән бердәм булып, илне басып алучыларга каршы күтәрелделәр, зур көрәшкә килеп кушылдылар. Илебезнең чикләрен басып кергән, бик күп авылларны яндырган, шәһәрләрне таш өеменә әйләндергән, сабыйларны да кызганмыйча утка тоткан ерткыч дошманга каршы күтәрелгән, “Барысы да җиңү өчен!” дигән чакыруга кушылып кулына корал алган язучы Габдрахман Әпсәләмов бу исемлектә иң күренеклеләрдән санала.

Дәһшәтле сугыш кырлары, ут өермәләре, дошман пулялары сугышчы-язучының тормышында гына түгел, аның әсәрләрендә дә чагылыш таба, әдипнең аерылгысыз иҗат темасына әверелә. Бөек Ватан сугышы еллары яшь язучы өчен зур сынау, тормыш мәктәбе була һәм аның иҗатының, нык тамырланып, киң колач белән үсеп китүенә нигез хәзерли.

Г.Әпсәләмовның сугыш чорында язылган хикәяләренә күзәтү ясап түбәндәгеләрне әйтергә мөмкин:

1. Г.Әпсәләмовның бу чор хикәяләренең төп темасы - геройлык; кеше көчле теләк белән янганда туган җир, Ватан өчен төрле дәрәҗәдәге батырлыклар эшләүгә сәләтле.

2. Язучы үзенең геройларын төрле ситуацияләргә куя, төрле шартларда сыный.

3. Әдипнең хикәяләре нигездә романтик рухта язылган.

4. Үзенең хикәяләрендә Г.Әпсәләмов дошманның вәхшилеген, кансызлыгын сурәтләүгә дә, яшәү, яшәү мәгънәсе,үлем турында уйлануларга да урын бирә.

5. Геройларны хәрби бурыч, дошманга нәфрәт, Ватанны ярату яшәтә.

Г.Әпсәләмов хикәяләрендә төп геройлар - батыр, кыю солдатлар, Ватан сакчылары. Әдип үзенең әсәрләрендә геройларны тулырак ачу, аларның батырлыкларын, күркәм сыйфатларын табигыйрак чагылдыру өчен хикәяләрнең төзелешеннән, композицион мөмкинлекләреннән, табигать күренешләреннән, рухи кичерешләреннән оста файдалана. Дошман гомуми характерда гәүдәләнә.

Г.Әпсәләмовның сугыш чоры хикәяләрендә канлы, кайгы-хәсрәтле сугыш вакыйгалары табигать кочагында бирелә. Урман, кыя, тау, елга тасвирлары үлемгә каршы торучы, Ватаны, туган халкының азатлыгы өчен көрәшүче, дошманга нәфрәт уты белән янучы геройларның батырлыклары, эш-гамәлләре, хис-кичерешләре белән үрелеп китә. Гүзәл табигать күренешләрен сурәтләү геройларның хисләрен чагылдыручы, эш-гамәлләренә бәя бирүче, булачак вакыйгаларга ишарәләүче һәм батырлыкның көчен күрсәтүче алым булып тора.

Сугышчыларның героизмын тагын да югарылыкта бирү, идеаллаштырып сурәтләү максатыннан автор төрле вакыт аралыкларын куллана, сугыш кырында булган вакыйгалардан соң күп вакытлар узгач, геройларны кабат очраштыра һәм аларның яңадан-яңа батырлыклар кылырга әзер булуларын ассызыклый. Бу алым аеруча “Егетнең асылы” һәм “Икенче гомер” хикәяләрендә чагылыш таба.

Шул рәвешле, Габдрахман Әпсәләмов хикәяләренең сәнгатьчә үзенчәлеге, беренче чиратта, Ватаны, иле, халкы өчен батырлыклар эшләүче, дошманга нәфрәт уты белән янучы геройларның чагылышында, бу максаттан психологизмның, табигать күренешләренең оста файдаланылуында, сюжетның үстерелешендә күренә.

КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ


1. Әдәбият белеме сүзлеге / Төз. А. Г. Әхмәдуллин. – Казан : Татар.кит.нәшр., 1990.- 239 б.
2. Еники, Ә. Бала // Ә. Еники. Сайланма әсәрләр: 5 томда. - Т.1. – Казан : Татар.кит.нәшр., 2000. - 447 б.
3. Еники, Ә. Бер генә сәгатькә // Мәктәп китапханәсе. Сайланма әсәрләр. – Казан : Татарстан Республикасы (Тарих), 2002. - 416 б.
4. Әпсәләмов, Г. Зәңгәр иртә // Бөек Ватан сугышы чоры прозасы. – Казан : Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты (ТаРИХ), 2002. - Б. 18-25.
5. Әпсәләмов, Г. Икенче гомер // Бөек Ватан сугышы чоры прозасы. – Казан : Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты (ТаРИХ), 2002 .- Б. 25-33.
6. Әпсәләмов, Г. Абушахман // Бөек Ватан сугышы чоры прозасы. – Казан : Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты (ТаРИХ), 2002. - Б. 46-57.
7. Әпсәләмов, Г. Бөркет токымы // Бөек Ватан сугышы чоры прозасы. – Казан : Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты (ТаРИХ), 2002. - Б. 57-63.
8. Ганиева, Ф. Үлемнән көчлерәк булу // Бөек Ватан сугышы чоры прозасы. – Казан : Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты (ТаРИХ), 2002. - Б.5-17.



*Гатиятуллин Саид, 7 нче сыйныф,*
*Казан шәһәре Вахитов районының «96 нчы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Закирова Альмира Хәнәфи кызы,*
*туган тел һәм әдәбияты укытучысы*


**Һәр заманның үз геройлары**

Үз гаиләңнең тарихын өйрәнү-мавыктыргыч шөгыль генә түгел, ә шәхес формалашуның мөһим процессы. Ул нәселдән булу хисен тәрбияли, ата-бабаларың һәм

аларның казанышлары өчен горурлык хисен ныгыта. Якыннарыбызның үткәнен белү нindiдер зур һәм әһәмиятле нәрсә белән бәйләнеш хисе тудыра, саклану һәм ышаныч хисе формалаштыра. Безнең ата-бабаларыбызның тормышы хикәягә генә түгел, ә илһам чыганагына, үсеп килүче буын өчен кыйммәтләрне, хезмәт сөючәнлекне һәм тормыш принципларын күрсәтүче күрсәтмә үрнәккә дә әверелә.

Кеше шәхесен формалаштыруда гаилә алыштыргысыз роль уйный. Ул база кыйммәтләре, әхлакый ориентирлар һәм социаль күнекмәләр төзелә торган фундамент булып тора. Гаиләдә бала беренче әхлак дәресләрен үзләштерә, тирә-юньдәгеләр белән аралашырга өйрәнә, яхшылык һәм яманлыкны танып белә, намуслылык, хезмәт сөючәнлек һәм хөрмәт турында күзаллаулар формалаштыра. Өлкән буыннар тапшыра торган тәҗрибә һәм белем шәхес үсешенең аерылгысыз өлешенә әверелә. Ата-аналарның үз-үзләрен тотышын һәм аларның үзара мөнәсәбәтләрен күзәтеп, балалар ситуацияләрне анализларга, карарлар кабул итәргә һәм җәмгыятьтә үз-үзләрен тотышының үз стратегиясен формалаштырырга өйрәнәләр. Гаилә - дөньяга карашны билгеләүче һәм озак елларга шәхес формалаштыручы тормышның беренче һәм иң мөһим мәктәбе.

Бөек Ватан сугышы-илебез тарихында миллионлаган гаилә язмышында онытылмас эз калдырган фаҗига бит ул. Эш фронтта да, тылда да фашизмны җиңүгә өлеш керткән туганнарым истәлегенә багышлана. Аларның тарихын өйрәнү-ул ата-бабалар истәлегенә хөрмәт күрсәтү генә түгел, ә алар яклаган кыйммәтләрне аңларга һәм аларны киләсе буыннарга тапшырырга омтылу да. Күп санлы язмышларны һәм һөнәрләрне берләштергән ыруым гаиләдә салынган һәм буыннан-буынга тапшырыла торган бердәм кыйммәтләр белән бәйләнгән. Мин үземнең ата-бабаларым белән горурланам һәм аларның батырлыгы турындагы истәлекне саклауны бурычым дип саныйм.

**Эшнең максаты:** илебезнең тарихи вакыйгаларына гаиләмнең төрле әгъзаларының ролен һәм керткән өлешен тикшерү.

**Бурыч:**

1. Нәсел тарихындагы төп фактларны һәм вакыйгаларны ачыклап, генеалогик тикшеренү үткәрергә.
2. Гаиләгә һәм ил тарихына кагылышлы тарихи мәгълүматларны һәм документларны җыярга һәм системалаштырырга.
3. Уникаль мәгълүмат алып һәм гаилә хикәяләрен анализлап, туганнарга интервью бирергә.

**Өйрәнү объекты:** Минем гаиләм, минем нәселем.

**Өйрәнү предметы:** тарихи вакыйгаларда, бигрәк тә Бөек Ватан сугышында катнашуга басым ясап, минем гаиләмнең, минем нәселемнең тарихы.

Бу эш очраклы гына сайланмаган. Шәҗәрә агачын тикшерү белән әнием ягыннан минем Зөфәр бабай шөгыльләнә, ә эти ягыннан аның Венера әби шөгыльләнә. Әнием Лилия алар җыйган архив язмаларын өйрәнүне дәвам итеп гаиләбезнең шәҗәрә агачын булдырды.

«Илдә барган вакыйгалар, әлбәттә, безнең республика тормышында да чагылыш тапты. Зөфәр бабай үз тикшеренүләрен шундый сүзләр белән башлый. Үз шәҗәрәмнең тарихын һәм фамилиямнең килеп чыгышын белү һәм язу теләге миндә XX гасырның 90 нчы еллары башында барлыкка килде. Бу чорда булган вакыйгалар да моңа зур өлеш кертә.

Буыннан-буынга тапшырыла торган сугыш турындагы хикәяләр-ул истәлекләр генә түгел, ә үткәннәр һәм гаилә кыйммәтләре турындагы күзаллауларыбызны формалаштыручы тере тарих. Минем гаиләмдә бу вакыйгалар фронтларда сугышкан, армиядә хезмәт иткән яки тылда фидакарь хезмәт иткән кешеләрнең язмышлары белән үрелеп бара.

Минем бабам **Гараев Гарай Мингарай улы** (бабам Зөфәр бабай) 3 сугышта катнашкан: Беренче бөтендөнья (1914-1918), Гражданнар (1918-1922), Бөек Ватан сугышында (1941-1945). Беренче бөтендөнья сугышы елларында австриялеләр тарафыннан әсирлектә була, анда 1916 елда атаклы Брусиловский үсеше вакытында эләгә, 1917 елда Россиягә Бөек Октябрь революциясеннән соң кайта. 1983 елда 87 яшендә вафат була. Аның тормыш тәҗрибәсе алдагы буыннар өчен ныклык һәм сабырлык мирасына әверелде.

Аның кызы **Гәрәева Нурлебанат** (1924-2019) һәм кияве **Гиниатуллин Абдрахман Хәлирахман улы** (1919-2001) сугыш буе фронт өчен Казан авиация җитештерү берләшмәсендә эшлиләр. Горбунова, пикировкалаучы бомбардировщик Пе-2 яки «Пешка» өчен югары төгәллекле детальләр ясаганда, аны шулай атаганнар. Хәтта тылда булганда да, минем бабам һәм әбием фашистларны Бөтен фронтларда үтергәннәр, завод сугыш елларында чыгарган 10 мең самолетка шәхси өлеш керткәннәр.

Аларның өч улының берсе, минем бабай - **Гиниатуллин Зөфәр Габдрахман улы** (1951), сугышмаса да, 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы елларында хәбәрсез югалган, Армиягә алынганчы Татарстан территориясендә яшәгән хәрби хезмәткәрләрне эзләүгә күп еллар багышлаган. «Кар десанты» отряды командиры сыйфатында 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы елларында Казан шәһәрендә оештырылган 146нчы Кызыл Байраклы, Суворов орденлы утрау дивизиясенең Казан – Мәскәү – Рига - Тарту (Эстония) - Бөек Новгород – Псков - Остров (Псков өлкәсе) – Мәскәү - Казан маршруты буенча барган.

Аның гамәлләре-ул сугыштан соңгы хәтер батырлыгы, тарихны саклауга һәм һәлак булганнар истәлегенә хөрмәт күрсәтүгә мөһим өлеш кертү. Бу сугыш турындагы хәтернең ничек яшәвен һәм яңа буыннарны илһамландыруын дәвам итә алуы үрнәге.

Минем бабам, Гөлнур әбиемнең әтисе, **Ибәтуллов Кияметдин (Киям) Шәрәфетдин улы** (1923-1976) Татар АССРның Буа кантоны Татар Убеи авылында туган. 1942 елда Кызыл Армиягә чакырыла һәм фронтка җибәрелә, фрейтор хәрби дәрәҗәсендә, анда разведка ротасында сапер булып хезмәт итә, 1943 елның июлендә Курск дугасындагы сугышларда катнаша, моның өчен Сталин тарафыннан имзалаган Мактау грамотасы белән бүләкләнә

Минем бабама бәхет елмайды - исән-сау әйләнеп кайтты. 1947 елда ул **Салахова Миннинур Ярулла кызы** (1921-1999) өйләнә. Сугыш елларында башка авылдашлары белән бергә Тәтеш районында окоплар казый. 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы елларындагы батыр хезмәте өчен, I, II һәм III дәрәҗә» әнилек даны «медальләре белән бүләкләнә.

Оныкларының берсе, минем абыем **Ганеев Дамир Гәләй улы** (1983-2023), 2022 елның декабрендә үз теләге белән СВОГА китә һәм 2023 елның 16 маенда Артемовск шәһәрен азат иткәндә һәлак була. Аңа 40 яшь була, аның өч улы кала. Бу тарих-буыннар аша кабатлана торган фаҗига. Сугыш дәһшәтен кичергән бабай үзенең киләчәк буыннары өчен тыныч тормышка өметләнә. Тыныч вакытта үскән оныгы, кайчандыр бабасы кебек, Ватанын сакларга кирәклегенә юлыккан һәм без тыныч яши алсын өчен үз гомерен биргән.

Бөек Ватан сугышы тәмамлануга сиксән ел узган инде, әмма аның авыр мирасы әле дә бик күп гаиләләрнең йөрәкләрендә борчу хисе уята. Миллионлаган кешеләр, ир-атлар һәм хатын-кызлар, егетләр һәм кызлар, тыныч киләчәк өчен гомерләрен биреп, Ватанны саклауга бастылар. Бу сугыш халык хәтерендә, һәр гаиләдә, һәр йөрәктә онытылмас эз калдырды.

Бүген безнең ил кабат катлаулы вакытлар кичерә. Россия, элеккечә үк, үз мәнфәгатьләрен һәм куркынычсызлыгын яклап, нацизмны торгызуны булдырмый калып, үз чикләре сагында тора. Безнең ил кешелексез көчләүгә һәм геноцидка дучар булган Донбасс кешеләрен яклап чыкты. Мондый мизгелләрдә сүзләр түгел, ә гамәлләр тикшерелә - үз уңайлылыгыңны һәм хәтта Ватан өчен гомереңне корбан итәргә реаль әзерлек.

Минем гипотезам гамәлдә расланды. Гаилә тарихын өйрәнү мавыктыргыч шөгыль генә түгел, хәтерне саклау, гаилә элемтәләрен ныгыту һәм ил тарихын тирәнрәк аңлауның мөһим коралы булуын исбатлады. Мин үз эшемдә төрле тикшеренү ысулларын кулландым: документаль һәм методик әдәбиятны җыю, анализлау һәм гомумиләштерү, архив язмаларын һәм фотоларын өйрәнү, өлкән буын белән интервьюлар уздыру.

Бу эш минем гаиләм тарихын гына түгел, ә гомумән илебез тарихын өйрәнүгә уникаль тикшеренү язарга нигез була ала.

Минем эшем инде үз гаиләләренең тарихын өйрәнергә, ата-бабалардан мирас итеп алынган чыгышларын, тамырларын, гореф-гадәтләрен һәм кыйммәтләрен яхшырак аңларга теләгән башка кешеләр өчен илһам һәм мотивация чыганагы булды.

Минем гаилә мисалында мин гаилә-җәмгыятьнең нигезе, ә гаилә традицияләре һәм кыйммәтләре аның тотрыклылыгында һәм үсешендә төп роль уйный икәнен күрсәттем. Бу кыйммәтләр шәхеснең әхлакый-этик нигезен формалаштыра һәм тотрыклы һәм имин җәмгыять формалаштыруга ярдәм итә. Нык гаилә балалар тәрбияләү өчен уңайлы мохит тудыра, социаль элемтәләрне ныгыта һәм иҗтимагый теләктәшлеккә ярдәм итә.

Шулай итеп, гаилә җәмгыятьнең структурасына, үсешенә һәм иминлегенә сизелерлек йогынты ясый. Гаиләм тарихы - моңа ачык дәлил.

*Гыйлемханова Инзилә, 9 нчы сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының*
*«А.А. Шаповалов исемендәге 31 нче лицей»*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Садыкова Лидия Хамдегали кызы,*
*туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

## Советлар Союзы герое Зәки Шәймәрданов – нәселем горурлыгы

Онытма син!
Хәтерләүдән курыкма син!
Үткәнеңне онытма син!
Исеңдә тот, аларның син
Сугышларда кан түккәнен.
Һәр нигезнең, һәр авылның,
Һәр каланың үткәне бар...
Гыйбрәт алырлык мирасның
Калганы бар,
Киткәне бар... (Р. Фәйзуллин)

### I. КЕРЕШ ӨЛЕШ

Туган җир, туган туфрак, туган нигез... Бу тирән мәгънәле төшенчәләр һәркем өчен изге һәм кадерле төшенчәләрне аңлата. Кеше кайда гына булмасын, нинди генә урыннарны күреп сокланмасын, аның күңелен һәрвакыт газиз җире, туган нигезе үзенә тарта. Без шулай үзебезнең нәсел тарихыбызны белергә тиеш. Аны сакларга, үзеңнән соң киләчәк буыннарга кадерләп тапшырырга кирәк.

Шуңа күрә дә минем эзләнү-тикшерү эшемнең **максаты**:

Бөек Ватан сугышы хәтирәләре, авылым тарихы аша Советлар Союзы Герое исеме алган кыю егет – безнең туганыбыз - Зәки Шәймәрдановның тормыш юлын, батырлыгын өйрәнү, киләчәк буынга җиткерү өчен мәгълүмат туплап системага салу.

**Бурычлар**:

1. Бөек Ватан сугышы, авылым тарихы турында күбрәк мәгълүмат туплау;

2. Дәү әниемнән. туганнардан ерак бабам – Советлар Союзы герое Зәки Шәймәрданов турында сөйләтү;

3. Гаилә архивындагы документлардан ерак бабам турында өстәмә мәгълүмат туплау.

**Гипотеза:** Гаилә архивындагы документлардан ерак бабам турында өстәмә мәгълүмат туплап, аның исемен нәселебез тарихында алтын хәрефләр белән язылып калуын тәэмин итү.

**Тикшерү объекты**: ерак туганым, бабам – Советлар Союзы герое Зәки Шәймәрдановның тормыш юлы һәм батырлыгы турындагы мәгълүматлар.

Тикшерү- эзләү эше барышында мин әлеге **метод**ларны кулландым:

1. Бабам турында якын туганнар белән сөйләштем, сораштырулар алып бардым;

2. Гаилә архивын һәм мәктәп музеендагы материалларны, аның турында язылган газета-журналлардагы материалларны өйрәндем;

3. Җыелган мәгълүматны туплап, тәртипкә салдым.

Минем бу эзләнү эшенең **практик үзенчәлеге, актуальлеге дә бәхәссез**, чөнки анда тупланган материалны тарих, әдәбият, әйләнә-тирә дөнья дәресләрендә кулланырга була. Шулай ук әлеге эшем ерак туганым Советлар Союзы герое Зәки Шәймәрданов турындагы барлык мәгълүматны киләчәк буынга – туганнарыма җиткерүдә дә бик актуаль булыр дип ышанам.

**Эшнең структурасы**: максат һәм бурычлардан чыгып, кереш, төп һәм йомгаклау өлешләреннән тора.

## II. ТӨП ӨЛЕШ

Минем сезгә үземә туган тиешле булган Шәһимәрдән бабай белән Кәримә әбинең тырыш улы, Ватаныбызны саклауда үзеннән зур өлеш керткән кыю авыл егете, курку белмәс, батыр йөрәкле, 1941-1945 елгы Бөек Ватан сугышында Советлар Союзы Герое исеме алган – Зәки Шәймәрдановның тормыш юлы, батырлыгы турында сөйлисем килә.

Ул безнең, барлык нәсел-нәсәпнең, авылдашларның, районыбыз Балык Бистәсендә яшәүчеләрнең генә түгел, Татарстан халыкның да горурлыгы булып тора. Чөнки ул – Татарстанда яшәүче 185 Советлар Союзы Героеның берсе бит. Аның тиңдәшсез батырлыгы тарих битләренә алтын хәрефләр белән язылган. Яшь буынга патриотик тәрбия бирүдә туганымның тарих дәреслекләрендә язылган истәлекләре бик зур әһәмияткә ия. Сугыш

темасын үткәндә Курск дугасында барган сугышта катнашкан Зәки Шәймәрданов дип әйтүгә, безнең авылдашыбыз батырлыгы турында язганнар бит дип горурланабыз. Аның алдында баш иябез, каберенә эзне суытмыйбыз. Туганнар белән аралашып, кунакларга йөрешеп, мәктәптә кичәләр үткәреп аны искә алабыз, туганлык җепләрен өзмәскә тырышабыз.

### 1.1. Туганым - кыю егет - Зәки Шәймәрданов турында

1923 елның кояшлы, матур 23нче июль иртәсендә хәтфә палас кебек җәелеп киткән иген басулары өстендә канатларын кагып сабан тургайлары сайраган бер чорда, чәчәккә күмелгән болыннар, кечкенә калкулыклар аша агып килүче Биектау авылын урталай ярып үткән Шомбыт елгасы буенда, авылының гади крестьян гаиләсендә, өченче бала булып, озын керфекле, коңгырт күзле кечкенә бер кара малай дөньяга аваз сала. Әтисе Шәһимәрдән, әнисе Кәримә малайга мулладан Зәкиҗан дигән исем куштыралар. Документларда Зәки булып йөри.

Зәки башлангыч белемне Биектау мәктәбендә ала. 5, 6, 7 сыйныфларда Тәберде Чаллысы авылының ШКМында укый. Сәләтле бала була. Бигрәк тә математика, физика фәннәрен ярата. 7нче сыйныфны тәмамлаганнан соң 8нче сыйныфка Котлы Бөкәш мәктәбенә укырга килә. Аны тәмамлаганнан соң Урта Азиянең Катта-Курган шәһәреннән әтисе белән бертуган абыйсының ике кызы кайтып төшә һәм Зәкине үзләре белән ияртеп алып китәләр. Ни дисәң дә, өйдә 8 бала, тормыш авыр була. Ул анда педучилище тәмамлап, туган якларына кайта, ләкин аңа укытучы булып эшләргә насыйп булмый. Район башкарма комитетының физкультура һәм спорт бүлегенә эшкә чакыралар. Анда да озак эшли алмый ул...

### 1.2. Сугыш чоры

Фашистлар илебезгә басып кергәндә Зәки абыйга бары тик 18 яшь кенә була. 1942 елның 12 мартында 19 яшьлек комсомолец егетне Татарстанның элеккеге Кызыл Йолдыз районы хәрби комиссариаты аша армиягә алып, артиллерия училищесына офицерлыкка укырга җибәрәләр. Ләкин бу вакытта котырынган дошман Иделгә якынлышкан чак була, укырга туры килми.

Немецлар котырынып, Сталининград янына ук килеп җитәләр. 1942 елның башында Сталинград өчен канкойгыч сугышлар башланып китә. Мамай курганы өчен сугыш 105 көн, 105 төн бара. Курганны 38нче гвардия дивизиясе сугышчылары үз кулларында тота. Ләкин, аралар сирәгәйгәч, көчләр кимегәч, артиллерия училищесы курсантларын аларга ярдәмгә ыргыталар. Алар ярдәмендә, Мамай курганы азат ителә. Шулай итеп, 13 нче гвардияче дивизиянең артиллерия полкының наводчигы Зәки Шәймарданов, тәүге кат Сталинградта дары исен исни, дошман белән күзгә-күз очраша.

Тәбәнәк буйлы, көләч йөзле татар егетен карт фронтовиклар араларына теләп алалар. Аңа хәрби һөнәрне оста үзләштерергә, гитлерчыларның мәкерле планнарын тиз аңларга ярдәм итәләр.

Октябрь аенда З. Шәймәрданов расчеты беренче мәртәбә авыр хәлдә кала. Дошман безнең артиллериячеләр өстенә орудияләрдән, минометлардан һәм һавадан утлы кургаш яудыра. Сафлар сирәгәйнәннән-сирәгәя бара. Ләкин совет сугышчылары югалып калмыйлар, артка чигенмиләр, ярсыган фашист салдатларының 6 атакасын кире кагалар.

Дошман тагын безнең позицияләргә якынлаша. Шул төнне Шәймәрдановлар орудиясе янында гына бомба ярылып, тупчыларны көчле шартлау дулкыны читкә чөя. Зәки абый бу шартлаудан көчле контузия ала, ләкин орудиесе яныннан китми. Дошман өстенә бер-бер артлы снарядлар җибәрә. Кичкә кадәр ул илбасарларның өч авыр танкын һәм фашистлар төялгән биш автомашинасын юк итә. Елганың сул ягына немецлар чыга алмыйлар, чигенергә мәҗбүр булалар. Сталинград астында дошманның фельдмаршал Паульс җитәкчелегендәге тулы бер армиясе әсирлеккә төшә.

Алга китеп шуны әйтәсе килә: Сталинградта һәр йорт, йортның һәр бүлмәсе өчен сугыш бара. Иделнең уңъяк ярындагы йортлар, төзелешләр җимерелеп бетә. Зәки бабай Павлов йорты өчен барган сугышта да катнаша. Шәһәр җимерелеп бетә. Хәрәбәләр арасында яраланган 3 агач кына исән кала. Сугыш беткәч, ул урында геройлар аллеясы ясала. Хәзерге вакытта Волгоград шәһәренең бер урамы 13нче гвардиячеләр дивизиясе исемен йөртә.

1961 нче елдан Сталинград - Герой-шәһәр Волгоград дип йөртелә башлый.

1943 елның июлендә Зәки абыйлар полкы Курск дугасы позицяләренә урнаша. Красная Дубрава авылы янында совет тупчылары өстенә 27 танк ташлана. Сержант Шәймәрданов орудиясенә таба ата-ата 12 танк үрмәли. Алар артыннан ук пехота төялгән 7 бронетранспортёр килә. Орудие терәп атарга көйләп куелган. Ут ачарга команда бирелә. Зәки расчётына туп-туры килүче авыр “тигр” шунда ук прицелга эләгә. Шартлау гөрелтесе яңгырауга, “тигр”га ут каба.

Аның артыннан ук икенчесен туктап кала, яна башлый. Шуннан дошман отряды югалып кала, колоннада тәртип бозыла. Немецларның моңа ачулары чыгып, расчёт өстенә берничә орудие залпы бирәләр, пулемётлардан ут ачалар. Рассчеттагыларның берничәсе һәлак була, кайсылары яралана. Орудия янында Шәймәрданов бер үзе басып кала. Шартлау дулкыны аны да орудиясе яныннан алып-алып ташласа да, яңадан күтәрелеп, каршылыгын дәвам итә. Бу бәрелештә дошман 3 “тигр”ын һәм 1 урта танкын калдырып кире чегенә.

Курск дугасында Зәки Шәймәрданов гитлерчыларга каршы менә шулай батырларча сугыша. Анда яулаган данын Украина фронтында тагын да ныгыта.

Украинаның Червонный Прапор авылын азат иткәндә фашистларның 3 машинасын, 40 лап солдат һәм офицерын юк итә.

Кировоград шәһәре өчен барган сугышларда да татар егете Шәймәрданов үзен снайпер-наводчик итеп таныта. Фашистлар безнең укчылар өстенә 9 танк һәм 18 бронетранспортёрларын җибәрә. Монда да артиллеристлар ярдәмгә киләләр. Ләкин якында гына төшеп ярылган снорd бөтен расчётны кырып сала, Зәки Шәймәрданов җиңелчә яралана. Ул бу бәрелештә үзе корып, үзе төзәп, үзе атып, дошманның ике танкын яндыра, 4 бронетранспортёрын сафтан чыгара.

Көнбатышка бару юлы җиңел булмый. Сандомир плацдармында аеруча кыен була. Ләкин сержант Шәймәрданов орудиесе позицияләрендә нык тора. Азат ителгән һәр авылны һәм шәһәрне яңадан дошман кулына бирмәс өчен күпме көч куела, күпме җан кыела...

Күрсәткән батырлыклары өчен авылдашым, туганым тупчы - 21 яшьлек Зәки Шәймәрдановка 1944 елның 13 сентябрьдә Курск дугасында күрсәткән батырлыклары өчен Советлар Союзы Герое дигән мактаулы исем бирелә. Аннан соң да әле Зәки абый 8 ай буена дошманны куып үз өнендә тар-мар итү операциясндә катнаша. Җиңү көнен Берлинга каршылый. Сугыш кырында партия сафларына керә. Украина, Белоруссия шәһәрләрен, Венгрия, Польша, Чехославакия җирләрен азат итүдә катнаша. Күкрәген Ленин ордены, Алтын Йолдыз һәм бик күп башка орден-медальләр бизи. Бу чорга аның исәбендә дошманның юк ителгән 24 танкы, 21 орудиесе, 18 бронетраспортеры, бик күп тере көчләре була.

### 1.3. Сугыштан соңгы чор

Сугыштан соң Зәки Севастополь шәһәренең зенит-артиллерия училищесына укырга җибәрелә. Аннан соң Уфа шәһәренең хәрби училищесында укый, ләкин хәрби кеше буласы килми, районга кайтып, райбашкарма комитетының статистика идарәсендә эшли. Соңыннан ике тапкыр партия мәктәбендә укый. Укып кайтканнан соң, гомеренең соңгы коннәренә чаклы, партия райкомының төрле бүлекләрендә эшли.

Хезмәт юллары:

1945 ел. Зәки Шәймәрданов Алтын йолдызын тагып туып үскән авылына, Биектауга кайта. Авылдашлар аны, түгәрәккә алып, күккә чөйгәннәр. Ул кайту белән партиянең Кызыл Йолдыз район комитетында инструктор булып эшли башлый.

1950-52 елларда Казан шәһәрнедә партия мәктәбендә укый.

1952-53 елларда яңадан райкомда эшли.

1953-54 елларда Котлы Бөкәш, 1954-58 елларда Мамадыш районында партия оешмасы секретаре вазифасын үти.

1958 нче елдан гомеренең актыккы көннәреннә кадәр КПССының Балык бистәсе райкомы инструкторы була.

## 1.4. Батырның исеме онытылмый

Аңа багышланган музей, Батырлар аллеясында бюст безнең авылда гына түгел, хәтта Венгриядә дә бар, диләр. Илебезнең байтак музейларында аңа махсус экспозицияләр эшләнгән. Геройлар үлми, аларның исемнәре тарих битләренә язылып, буыннан-буынга барып җитәр, чөнки буыннар чылбыры өзелми әле... өзелми... Шуңа мисал итеп, Бөек Җиңүнең 30 еллыгы хөрмәтенә чыгарылган газета мәкаләсеннән өзек китерәм: "Хәзер Биектау сигезьеллык мәктәбе Пионер дружинасы герой авылдашыбыз Зәки Шәймәрданов исемен йөртә. Укучылар кыш буена аның каберен кардан чистартып, венокларын яңартып торалар, ә язга чыгу белән рәшәткәләрен буйыйлар, хуш исле тере чәчәкләр китерәләр. Бөек Җиңүнең 30 еллыгы якынлашкан бу көннәрдә дружинада эшне тагын да җанландыра төшкәннәр. Мәктәптә Зәки абыйның балачагын, сугышчан һәм хезмәт юлын чагылдырган почмак булдырганнар. Анда геройның бюсты, сирәк сакланган фоторәсемнәре, документлары, фронт газетларында басылган язмалар һәм башка материаллар бар. 9 майда - Җиңү көнендә - мәктәп укучылары, укытучылар, гомумән, бөтен авыл халкы герой каберенә килеп баш иячәк...". Биектау унберьеллык мәктәбендә герой авылдашыбыз белән очрашлар бик еш була иде, дип искә ала Рамзил Гилемханов. Без - батыр солдат булырга хыялланып йоргән малайлар - аны авыз ачып тыңлый идек. Сүзләре әле дә колакта уелып калган:

1944 елның көз айлары иде, дошман һәр карыш җир өчен тише-тырнагы белән тырнаша, ә без һаман Көнбатышка барабыз. Бер көнне оборона позицияләренә урнаштык. Чөнки анда гитлерчыларның күп санлы гаскәре тупланган булган. Бик авыр, кан түккеч бәрелеш булды ул. Немецлар көн буена ярты сәгать саен атакага күтәрелеп тордылар. Сугышта нинди төр кораллар бар, барысы да катнашкандыр анда. Тирә-юньдә бомбалар, снарядлар, миналар шартлый, пулялар сызгыра. Шартлау дулкыны мине дә орудие яныннан читкә алып ташлаган. Ике як та хәлсезләнде. Ату тавышлары да сирәгәйде, ә бераздан бөтенләй тынды. Җирдән торып, орудие янына килсәм, күрше расчётларда да, бездә дә бер генә исән җан иясе дә күренми. Иң авыр минутлар иде бу, янда дуслар булмауның нинди кыен икәнлеген шунда гына сиздем. Тылдан килеп чыккан резерв гаскәрләрен, танкларны һәм алар артыннан "ура" кычкырып йөгерүче пехотачыларны күргәч, шатлануымны күрсәгез иде!

Бу сугышны безнең чор кешеләре үзләре татып карадылар. Ләкин сезнең тормыш, балалар, тыныч, күгегез һәрвакыт аяз, зәңгәр булса иде, - диде ул...

Бүген инде өченче буын туганнарның балалары Зәки ага белән горурланып, үз Ватаныбызны саклауга үзләреннән өлеш кертәләр.

## 1.5. Герой каберендә ут яна

Котлы Бөкәштән Биектауга килгәндә зират почмагындагы бер кабердә ут яна. Көзге пычрак, караңгы төннәрдә дә, кышкы күз ачкысыз бураннарда да бу ут юлчыларга маяк

булып тора. Юлчылар кабер янына килеп, баш киемнәрен салып, бер минут тын гына басып торалар да, үз юлларына китәләр. Буыннар бәхете хакына фашистларга каршы яусыз көрәшкән Советлар Союзы Герое Зәки Шәймәрданов кабере ул. 1967 елның төкерек җиргә төшкәнче бозга әйләнерләк салкын январь аенда җирлиләр аны.

Зәки абый сабыр холыклы, тыйнак, сизгер һәм бик кешелекле була. Хезмәттәш иптәшләре, дуслары аны хәзер дә үз араларында кебек хис итәләр, КПСС райкомы инструкторы Л. В. Апредев Зәки Шәймәрданов белән күп еллар бергә эшләгән. Бер хатирә аның да хәтеренә тирән сеңеп калган:

- Яңгырлы, салкын көз иде. Мин “Шомбыт” совхозында, ә Зәки спиртзаводта партия җыелышын үткәрергә трактор арбасында бардык. Шомбытка килеп җиткәндә “суга төшкән тавык” кебек манма суга баттык, туңдык. Ләкин Зәки һаман шат, кешеләр белән сөйләшә, көлешә башлады, - ди Леонид Васильевич, - менә бит, сугыш ныгыткан кешегә бу гына бернәрсә дә тормагандыр инде, күрәсен.

## III. ЙОМГАКЛАУ

Әйе, курку белмәс,батыр йөрәкле Зәки Шәймәрдановның исеме тарихка язылды. Аны авыл халкы гына түгел, районыбыз, республикабызда да бик яхшы беләләр. Бөек Җиңүнең инде 79 еллыгы якынлашканда да һәрберебез геройларга баш иябез. Батыр якташыбыз, туганыбыз безнең күңелләрдә һаман исән калыр, истәлеге мәңге сакланыр. Мина әти-әнием, әби-бабам горурланып сөйләгән кебек, мин дә киләчәк буынга Советлар Союзы герое Зәки бабам турында горурланып сөйләрмен әле.

*Гильфанова Равиля, 10 нчы сыйныф, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче Җәлил беренче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениясе*
*Җитәкчеләре: Асадуллина Альфия Мансур кызы, Ватанны саклау һәм иминлек нигезләре укытучысы, Шаймарданова Лилия Нур кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Кеше бәхете

Кеше бәхете ... Бәхетле кеше ... Бу сүзләрдә никадәр мәгънә һәм фәлсәфә бар ... Нәрсә соң ул кеше бәхете? Бәхетле кеше нинди була? Бу сорауларга һәркем үзе генә җавап бирә ала. Әлеге сорауларны кешеләр бик борынгы заманнарда ук үз-үзләренә биргәннәр. Бүген дә бирәләр. Тик мин хәтта киләчәктә дә бу сорауга бер сүз белән генә җавап биреп булмас дип уйлыйм. Шуңа күрәдер инде, борынгылар әйтмешли, һәр кеше үзенчә бәхетле, һәр кешенең үз бәхетсезлеге

дигән сүзләрдә без белергә теләгән фәлсәфи мәгънә ята. Ләкин, шулай булса да, мин үзем бәхетле дип санаган кешеләрнең нилектән бәхетле булуларының уртак сәбәпләренә үземчә төшенеп карарга телим. Мондый кешеләр үз халкының мохитында туып-үсеп, аның игелекле тәрбиясен алган, аны Аллаһы тәгаләнең зур насыйбы дип санаган, бу изге бурычны халыкка кайтару юлында, милләт мәнфәгате өчен армый – талмый хезмәт итә торган мөхтәрәм затлар була. Халык шундый уллары белән горурлана. Халык шундый ул – кызлары белән көчле була. Вакыты җиткәч, халык андый улларын зурлый, аларны зур дәрәҗәләргә, дан шөһрәтләргә лаек дип саный. Замандашларыбыз арасында андый шәхесләр аз түгел [1].

Минем сүзем шундый затларның берсе – талантлы һәм тәҗрибәле укытучы, бистәбезнең сугыш ветераны, хәзерге көндә Су – Джок терапия буенча кешеләрне дәвалаучы – Хамидуллин Габит Шарифуллович турында.

Габит Шарифуллович минем белән очрашуга килеп керүгә, бүлмәм, ничектер, яктырып киткәндәй тоела. Бик ашыгыч эшләремне дә читкә куеп, аның белән озаклап сөйләшеп утырасы килә. Бу кешедән ничектер җылылык, зыялылык бөркелеп тора. Безнең бистәнең Ветераннар советы рәисе болай дип сөйләгән иде: “Ул хәрәкәтчән, актив, сүзне турыдан яручы, ихлас, гади, беркатлы. Шул ук вакытта гаять эмоциональ, кызу канлы, романтик рухлы. Аңарда эчке хәрәкәт бар, ут бар, яну бар“.

Габит Шарифуллович – татар халкының фаҗигале язмышын үз җил-кәсендә татыган шәхес, тормышның төбеннән үз көче белән күтәрелгән. Авырлыкларны тормыш аның гомер юлына берсе артыннан икенчесен куя тора.

“Мин, Хамидуллин Габит Шарифулла улы, 1924 елны Әлмәт районы Кама – Исмәгыйль авыл советына караган һәм 1922 елны аннан күчеп, 5 чакрым ераклыкта утырган Гөлбакча исемендәге 30 – 35 йортлы авылда туганмын“, – дип сөйләп китте ул үзе турында.

**2нче бүлек. Үзем турында үзем.**

Гөлбакча авылы – исеме җисеменә бик тә туры килә иде. Аны мактавым минем туган авылым булу өчен генә түгел. Ул бәрәңге бакчаларына терәлеп тора торган катнаш урман эчендә, сөзәк ярлы, чирәмле уйсу җирдә урнашкан.

Уртада зур кешеләр дә коена алырлык буасы, коесы һәм салкын,чиста, тәмле сулы чишмәсе бар иде. Яз – җәй көннәрендә кошлар сайравын тыңлыйсың, көтүен куасың, сөенеп – куанып чиста, тәмле суына барасың. Кош – корт, мал-туар асрау өчен, утын, печән хәзерләү өчен менә дигән аланлыклы урыннары күп иде. Хәзерге вакытта авылның якты истәлеге генә калды. Ләкин авылның эзе калмаса да ул “яши” бирә. Һәр елны май аеның соңгы шимбәсендә кечкенә авылның элек яшәгән уллары бу җирлекне сагынып киләләр. Тирә - як авыллардан, шәһәрләрдән кайткан кешеләр, авыл кешеләре, кунаклар авыл истәлеген, хәтерне яңартырга

зират янына киләләр, кайгы уртаклашалар һәм хәлләрен сорашалар, аңлашалар һәм искә төшерәләр [2].

Очрашу шатлыгы ... күз яшле истәлекләр ...

Сугыш башланган көнне Әлмәттә татар халкының милли бәйрәме Сабан туе иде. Һәр авылдан кыңгырау тавышлары, гармун уйнап, яшь-ләрнең төрле көйләргә җырлашып җыелуы үзе бер хозурлык. Табигать тә бу бәйрәмгә ямь өстәде. Ул көнне озын көн (22 июнь көне), кыска төн, күк йөзе кояшлы , аяз иде . Бәйрәм ... кәефләр күтәренке ... шатлыклы йөзләр ... Уеннар башланды. Кинәт, бәйрәмнең кызган чагында , райком секретаре Таһиров биек итеп ясалган күперчек өстенә менеп , уеннарны туктатырга кушты. Шунда ул фашистлар Германиясенең илебезгә һөҗүм итүе, чикне бәреп керүе, самолетлары безнең тыныч шәһәрләребезне бом-бага тотуы турында белдерү ясады. Шунда ук: дөреслек безнең якта, гадел сугыш , азатлык өчен сугыш, дошман тар – мар ителер дип белдерде. Сабан туе туктады ... Тыныч, шатлыклы бәйрәм көне, фашистларның илебезгә ерткычларча һөҗүм итүе белән, кайгылы караңгылык көненә әй-ләнде. Мәйданда беркем дә калмады. Барысы да авылларына, өйләренә таралдылар.

Ил - ананың чакыруы буенча этиләр, ирләр, кияүләр фронтка китә башладылар. Эшкә яраклы төзек автомашиналар, тракторлар, атлар һәм корал тота алырдай миллионлаган кешеләр илне дошманнан сакларга киттеләр. Моңарчы таза - сау ир – атлар башкарган бөтен эшләр аларның хатыннары, балалары җилкәсенә калды. Хатын – кызларны, колхоз эшеннән тыш, торф әзерләүгә, урман кисәргә, төзелеш эшләре алып барырга, окоп казырга, танкларга каршы киң, тирән чокырлар казырга йөрттеләр.

Мин 10нчы классны бетерергә тиеш булсам да укуны ташладым. Укуның барыбер кирәге калмас, исән кайту да булмас, дип уйладым. Хөкүмәткә икмәк тапшыручы булып эшләдем. Ике атка өч яки өч ярым центнер икмәк төяп, Бөгелмә элеваторына илтеп тапшыра идек. Аннары Молотов (хәзерге Пермь) шәһәрендә көнбатыштан кайтарылган станокларны платформалардан бушату , ташкүмер бушату эшендә йөреп, өзлегеп, авырып авылга кайттым.

Миңа һәм минем яшьтәгеләргә “сугыш” сүзенең мәгънәсе соңрак аңлашылды. Без үскәндә “Сиваш”, “Тимер ташкын” китапларын укып, “Чапаев”, “Котовский” киноларын карап, сугышның, Испаниядә, Хасан күле, фин сугышы чорында безнең гаскәрләрнең җиңүе белән бетүен белә идек. Хәзер дә шулай булыр, җиңү безнең якта булыр һәм тиз булыр, дип уйлый идек. Ләкин фашистларның Мәскәүгә якынлашуы бу сугышның чынлап та дәһшәтле булуын һәм озакка барачагын күрсәтте. 1942нче елның апрелендә, әле миңа 18 яшь тулмаса да, повестка килүе бу фикерне тагын да тирәнәйтте [3].

Безне, повестка алучы егетләрне, пароходта Идел буенча югарыга алып киттеләр. Пароход, бомбага тотылудан куркып, утсыз – нисез төннә-рен генә бара иде. Ахырда безне Ярославль шәһәренә, лейтенантлар әзерли торган пехота училищесына алып килделәр. Бер атнадан Марий – Эль өлкәсенә, “Суслонгер” лагерына күчерделәр. Биредә 1943нче елның январь уртасына кадәр бик кыен, ачлык шартларында, салкын землянкалар-да хезмәт иттек. Тактик занятиелар, маршировка, сугыш алымнары өйрәт-теләр. Тактик занятиеларга бару һәм кайту, ә ул биш чакрым ераклыкта, гел йөгереп кенә үтә иде. Кичләрен, занятиелардан соң, җиде – ун чакрым ераклыктагы урманга утынга бара идек. Ял көннәре дип аталган көннәрдә өстән явып торса да, пычрак булса да, маршировкалар үткәрә иделәр. Юешләнгән киемнәрне өскә ябынып кына җилләтә идек. Солдатларның телендә тизрәк фронтка китү, бу тәмуггтан котылу, тегендә ике якның берсе булыр, бу интегүләр артта калыр, дигән фикерләр булды. 1943нче елның январь уртасында безнең батальонны киендерделәр, концентратлар, ипи, шикәр кисәкләре бирделәр һәм фронтка озаттылар. Сталинградка барып җиттек. Фронтның артында, шәһәрнең ике ягында, коралсыз, окоп-сыз оборонада тордык. Немецларның өч йөз утыз меңле гаскәре чолгап алынганлыктан, әсирлеккә бирелгәнлектән, безне оборонадан алып, очрашу урыны билгеләп, тараттылар. Сез ант иттегез, сезне продукция һәм транспорт белән тәэмин итә алмыйбыз диделәр. Очрашу урыны төньяк Кавказ, Новочеркасск шәһәре иде. Кем ничек булдыра, шулай барды. Юлда җимерек шәһәрләр, авыллар, һәр ике якның да җимерелгән, ватылган машиналары, танклары, пушкалары ята иде. Ач көе, җәяүләп, пычрак ярып, калмык далалары аша Дон елгасына якынлаштым. Донны аркылы чыгу өчен егерме чакрым ераклыкта понтонный (ясалма) күпер барлыгын ишеткәч, узып баручы полуторка машинасына ябышып карадым. Ләкин кузовта миналар, снарядлар һ.б кораллар булганлыктан, шоферлар утыртмыйлар иде. Пычракка гына батып беттем. Икенче көнне елганы җәяүләп кичәргә булдым. Ерактa елганың икенче ярына якынлашып баручы солдатны күрдем. Ул тәҗрибәле булган күрәсең, таяк белән бозлы суны төрткәләп бара. Су култык асты тирәнлегендә, әкрен генә боз өстеннән ага, ә аста снаряд һәм мина тишкән урыннар булуы мөмкин . Мин таяк тотмадым, шул юнәлештә кереп киттем. Февраль ае суык, су салкын иде. Мин ярга аяк басканда, теге солдат чыгып җитеп, учак ягып, киптереп тә бетергән иде юеш өстен. Мин дә аңа кушылдым. Алда Новочеркасск шәһәре.

Новочеркасскига барыбыз да вакытында килеп җиткәнбез. Хәрби ант безне тискәре уйлардан, хәрәкәтләрдән тоткарлау ролен уйнады. Биредә дә ашау начар. Ике йөз кешелек батальонга ике зур гына балык, ул да тозсыз пешерелгән. Ипи бөртек килеш янган, көек исе килә. Ягулык булып иске әрем куралары хезмәт итте. Аңлашыла, барысы да сугыш хикмәтләре. Продукция артта, тылда, алып килергә дә җитешә алмадылар.

Шулай итеп, Дон аръягында, фронт линиясеннән ерак түгел, һөҗүмгә әзерләнә башладык. Туклану тәртипкә китерелде. Безне егерме дүртенче гвардия дивизиясенә, җитмеш икенче полкка билгеләделәр. Буем кечкенә булса да, миңа кул пулеметы бирделәр. Ату күнегүләрендә дивизия командиры исеменнән мактауга лаек булдым. Әле һөҗүмнәр башланганчы ук, шушы чорда, мине, унике көнлек ял йортына җибәрделәр. Биредә ашау да икенче төрле, туклыклы, тәмле. Йокысы да койкада, ак простыняларда. Тыныч, ату тавышлары да еракта гына ишетелә . Һава сугышларын гына күзәтергә мөмкин. Биредә, гомер эченә беренче мәртәбә укроп тәмен татыдым [6].

Менә 1943нче елның август ае. Безнең батальонга зур гына Дмитриевка авылын немецлардан азат итү бурычы йөкләнде. Алдынгы позицияләргә җиткәнче үк миномет уты белән дүрт пулеметчы яраланды. Авылга барып җиткәнче үк егермеләп немец самолеты бомбага тоттылар. Бомба ташлаган һәр самолет үзенең пулеметларыннан әйләнә-әйләнә атып йөрде, башны күтәртмәделәр. Ярый әле якында гына әзер окоп кебек чокырлар булды. Өзлексез гүләү, бомба шартлау, тузан, улау. Һавага куллар, аяклар өзелеп оча, һава дулкыны окоптан чыгара, күтәрә, ә ярчыклар шинельләрне көйдереп, тәнне пешерәләр. Бомбага тоту туктагач, кораллары чистарттык. Эчке күлмәк чүпрәк ролен уйнады. Кем исән, кем юк аны тикшереп торырлык түгел иде. Авыл кырыена килеп җитеп, елгага якынлашканда, икенче катка бомбага тоттылар. Яр буе чокырлары саклану урыны булды. Тагын корал чистарту. Кинәт каяндыр болытлар килеп чыкты һәм коеп яңгыр яуды. Яңгыр шулкадәр көчле иде, елгада кеше гәүдәләренә хәтле акты. Яңгыр ничек тиз башланса, шулай кинәт туктады да. Кипшенеп тә бетермәдек, елга аркылы чыгып, авыл кырында позиция билгеләп, үзеңә окоп казырга приказ булды. Ярты тәүлек эчендә авыл өч мәртәбә кулдан – кулга күчте. Тигезсез һәм нәтиҗәсез сугыш. Ахырда дошман авылны тулысы белән яулады, безне чолгап алды. Әле камалу тулысынча төгәлләнмәгән булган, батальон командиры бөҗрадан, камалудан котылу өчен, оешкан тәртиптә егерме чакрымга чигенергә кирәклеген аңлатты. Кем беренче булып йөгерә, аны атачагын аңлатты, кисәтте. Безнең яктан үлүчеләр саны, яралылар саны күп иде, алар шунда калдылар. Яктырганчы егерме чакрым араны чигенеп, тагын яңа позициягә урнаштык. Өч мәртәбә атакага күтәрелдек, тик бар да файдасыз булды. Бу сугышта минем аякны яраладылар.

3267 номерлы госпитальдә ятып чыктым. Аякка басып та булмый иде әле. Алгы сызыкта басарсың да, аксавың да бетәр, диделәр. Бу юлы 96 нчы гвардия дивизиясе, 291 нче полкка эләктем. Кешеләр белән танышып та өлгермәдем, кулым яраланып, тагын госпитальгә эләктем.

1944 нче елның апрелендә хәрәкәттәге 51нче армия составында Сиваш оборонасын өзеп, Симферопольне азат итүдә катнаштым. Аннары мине 51 нче армиянең, 194 нче Армейскии запасной стрелковый полкның штабына писарь итеп куйдылар. Кырым тулысынча немецлардан азат ителгәч, безне Белоруссия аркылы Икенче Балтыйк буе гаскәрләре составына җибәрделәр.

Латвияне азат итү, Ленинград блокадасын юкка чыгару, Ленинград фронтына ярдәм итү 51 нче армиянең бурычы булды. Икенче май көнне елга порты Иелгаваны азат иттек. Шул ук көнне, Берлин да алынганны белгәч, барлык кораллардан атып салют бирдек. Җиңү игълан ителсә дә, сугышны бер–ике ай дәвам итәргә туры килде. Милләтчеләр, власовчылар, бендеровчыларны юк итү процессы барды.

Безнең 51 нче армия штабын саклаучы рота Свердловский шәһәренә, Урал хәрби округы штабы карамагына җибәрелде. Биредә ике тапкыр госпитальдә ятып чыктым, һәм, ниһаять, дүртенче апрель көнне, демобилизацияләнеп өйгә кайтып киттем.

Мине тормыш өч мәртәбә зур бүләк белән бүләкләгән булып чыкты. Чөнки өйдә өч тапкыр “геройларча һәлак булды“ дигән кара кәгазь укы-ганнар. Мин һәрвакыт карандаш белән булса да хат яза идем. Хатның бу хәбәрләрдән соң язылуын белгәч, кара кәгазьне ерта барганнар.

**3нче бүлек. Үзем турында үзем.**

“Еллар үтәр, тарихчылар безнең газетабызның саргайган битләрен дулкынланып актарырлар , хәрби язучыларыбызның һәм журналистларыбыз-ның иң кечкенә генә хәбәрләрен укып та: - Нинди изге , нинди бөек эш эшләгәннәр ! – дип , аларның исемнәрен бик зур хөрмәт белән телгә алырлар “, - дигән Афзал Шамов. Чыннан да, еллар үтә. Әмма сугыш истәлекләре хәтердә дә, тарих һәм матбугат битләрендә дә саклана, яңара тора, һәр елны Җиңү көне җиткән саен, бу истәлек – хатирәләр тагы да ачыграк булып күз алдына килеп баса. “Беркем дә, бернәрсә дә онытылмады!“ - дигән сүзләрне кабатлап, батырларның исемнәрен искә алабыз, үзебезнең татар егетенең батырлыгы белән горурланабыз. Аның ут астында үткәргән көннәре истәлекләрен тыңлыйбыз. Әйе, хатирәләр күп, дулкынландыргыч, тетрәндергеч. Габит ага Хамидуллин җиңү көнен җиткергәнче көрәшкән. Сугыш дәһшәтен бик күп кичергән: өч мәртәбә өйдәгеләр аның турында үлем хәбәрен алган, ләкин ул дошманга бирешмәгән; башкалар белән бергә атакага барган, төрле операцияләрдә катнашкан, күп кенә медальләр белән бүләкләнгән. Әйе, беркем дә, бернәрсә дә онытылырга тиеш түгел! Әлеге сүзләр сугыш китергән дәһшәтне, явызлык – рәхимсезлекләрне үз җилкәләрендә нык татыган һәм фашизм дигән кара көчне җиңеп чыккан Солдатның Ватан – ана сакчыларына алмашка килүче яшь буынга үтенече дә, теләге дә, изге васыяте дә. Тынычлык өчен көрәшкән беркем дә читтә калырга тиеш

түгел! Шуңа күрә бүгенге язмада да мин туган ил иминлеге өчен утка кереп, гомерләрен кызганмаган каһарманнарның берсе турында сөйлисем килде һәм күңелемдә туган кайбер уй-фикерләр белән уртаклашырга телəдем.

Сугыш гарасатларын үткәч, Габит ага Хамидуллин, тыныч тормышка кайта. 1947 нче елның апрель аенда үзенең тормыш иптәше белән Свердловск шәһәрендә өйләнешеп, туган ягына кайта. Өч мәртәбә “үлгән“ Габитны һәм аның “марҗасын“ күрергә бөтен авыл халкы җыела. 1948 нче елның январендә улы Сәгыйть, ә 1950 нче елны уллары Рәис дөньяга килә. Үзе 1948 нче елның сентябреннән алып 1952 нче елның августына кадәр Бөгелмәдә Педагогия институтында, тарих – филология факультетында укый. Райком аны колхоз активына, политукулар алып бару өчен пропагандист итеп куя.

Ул үзенең тел байлыгы, яхшы дикциясе белән танылган. Аннары Габит ага Җәлил беренче санлы мәктәбендә эшли башлый. Ул бишенчедән алып унберенче сыйныфларга хезмәт дәресләре (хәзер технология дип атала) алып бара. Укытучы буларак, ул педагогикада яңалыклар белән кызыксына, Казан шәһәрендә фәнни-практик конференциядә катнашып, министрлык грамотасын алып кайта. Ул бервакытта да бер урында таптанып тормаган, район укытучыларына ачык дәресләр күрсәткән, аңа бик зур бәя биргәннәр. Алай гына да түгел, Габит ага Шәрифуллович метод берләшмә җитәкчесе дә булган, яшь укытучыларга даими рәвештә методик яктан ярдәм күрсәткән. Аның мастерскоенда программага туры китереп ясалган, һәр сыйныфка яраклы стендлар, инструкцияләр элеп куелган булган. Остаханәдә күргәзмәләрне даими тулыландырган, укучылары белән мәктәпкә кирәк-ярак җиһазлар җитештергәннәр. Балаларны төрле профессияләргә өйрәткән, шул исәптән нефтьчеләр цехларына экскурсияләр оештырган. Профориентация эшен бик оста алып барган. Габит ага инициативасы белән мәктәптә өстәмә белем бирү максатыннан, төрле профессиягә укыту башланган: КиП слесаре, тегүче – моторист, повар, медсестра. Шулай ук мәктәптә, Сарманнан СПТУ – 91 нең филиалы ачыла һәм ул бүгенге көнгә кадәр эшләп килә, укучылар шофер, тракторист һөнәрләрен үзләштерәләр.

Габит ага соңгы вакытларда партком секретаре булып, үзенең эшен җиренә җиткереп башкара торган булган. Җыелышларда һәрвакыт нинди дә булса инициатива белән чыгыш ясап аны тормышка ашыра торган булган. Аның фотосүрәте район мактау тактасында торды. Шулай эшләп ул мәктәптә беренчеләрдән булып “РСФСР ның өлкән укытучысы“ исемен ала, “Ветеран труда“ медаленә лаек була. Габит ага пенсиягә киткәч тә мәктәп тормышы белән актив кызыксынып тора, технология укытучыларына булдыра алганча ярдәм итә.

## 4 нче бүлек. Пенсиядә - яңа тормыш.

Пенсиягә чыкканчы һәм чыккачта, Габит ага сигез ел халык контролендә, ун ел ветераннар советында эшләгән. Бер очтан, күптәннән җыеп килгән, сәламәтлеккә кагылышлы материалларын да тәртипкә китергән. Нокталы массаж турында материаллар өйрәнгән. Ике йөз егерме төрле, үзебезнең җирлектә үсә торган дару үләннәре, җимешләр, яшелчәләрнең файдасы һәм нинди авыруга каршы икәнлеген күрсәткән таблица төзегән. "Су – Джок" дип исемләнгән нокталы массаж (рефлексология) турында китаплар өйрәнә һәм шул белемен практикада кулланып үзенә, гайләсенә һәм башкаларга файда китерә. Моны ул, үзенең яшьлегеннән килгән, врач булу хыялының тормышка ашуы дип атый [4].

Табиблыкка укыйсы килү теләге Габит ага күңелендә 8-9 нчы сыйныфларда укыганда "бөреләнә" башлый. "Валентлык" темасын үткән вакытта дәрестә була алмадым, ә үзлегемнән өйрәнеп аңлап бетермәдем һәм шуңа, медицина институтына укырга керү теләгем булса да, конкурстан үтә алмам дип куркып, анда бармаска уйладым," – дип сөйләде ул еллар турында Габит ага.

Югары белем алмаса да, авылда фронттан сәламәтлеген югалтып кайтучыларны борынгыдан халык арасында кулланыла торган дәвалау ысуллары белән дәвалап карыйсы килү теләге уяна аңарда. Өстәвенә, үзе дә фронттан радикулит дигән авыру белән "бүләкләнеп" кайткан була. Әле яшь булгач, киләчәктә тормыш итәсен истә тотып, үзен-үзе халык ысулы белән дәвалап карамакчы була ул [5].

Соңыннан, укытучы булып эшләгән елларында да Габит ага халык дәвалау ысуллары белән кызыксынуыннан туктамый. Еллык календарь битләрендә басылып чыккан төрле үлән шифалары , дәвалау ысуллары ту-рындагы язмаларны җыярга тотына. Нокталы массаж буенча уннан артык автор тарафыннан язылган китаплар булдырып, шул өлкәне ныклап өйрәнә башлый. Ә дәвалау ысулларын куллануны, үзен сынап карар өчен, мәктәп балалары белән башлый ул. Өченче сыйныфта укучы, сәламәтлекләре чамалы булган унбиш баланы тәкъдим итәләр үзенә. Аяк табаны массажы буенча ун сеанс күнегүләр алганнан соң, унөч бала шифа таба, авыртулары юкка чыга. Әнә шулай, балалар белән дәвалау сеанслары уздырганнан соң, йөрәксенеп, олы яшьтәге кешеләрне дә дәваларга тотына ул: югары кан басымы, нерв авырулары, балага уза алмый интегүчеләргә ярдәм итә. Барлык дәва мәгълүматлары кечкенә генә куен дәфтәренә тупланган аның. Шул мәгълүматларга таянып, кая гына барса да, ярдәм сораучыларга киңәшләре белән булыша ул. Дәвалау белән Габит ага инде җиде-сигез ел шөгыльләнә.

"Габит ага, сез үзегезне бәхетле дип әйтә аласызмы? " – дигән сорауга ул: "Мин үземне бәхетле дип саныйм", - дип җавап бирде.

“Беренчедән – сугышта булган хыял тормышка ашты. Аннан исән-сау кайту хыялы. Пулялар сызгырган, мина һәм снарядлар ярылган, шартлаган тавышларны ишетмичә, өйдә, якыннарың янында йомшак урында йоклау турында кем генә хыялланмый икән.

Икенчедән – физик сәламәтлек булмаса да, тормышта үземә урын таптым һәм үземнең вазыйфаларымны яхшы башкардым.

Өченчедән – яшьлек хыялымда врач булу теләге бар иде. Дипломлы врач булып булмаса да, үземә, гайләмә, һәм башка интегүчеләргә ярдәм итә алырлык булдым.

Дүртенчедән – пенсиягә чыгып, бер-ике мәртәбә пенсия аласы иде, дигән уйлар тормышка ашты. Аллага шөкер, пенсиягә чыгып инде егерме елдан артык яши бирәм.

Бишенчедән – балаларым начарлык эшләп, кайгы – хәсрәт китермәделәр. Өч улым да нефтянник һөнәрен сайладылар.

Алтынчыдан – үзем медицина буенча укый алмасам да, кызыма шул һөнәрне үзләштерергә ярдәм иттем“.

Дөрестән дә, бүлмәсендә бикләнеп ятарга күңеле түзми бу кешенең. Мәшәкатләре күп, халкына хезмәт итәсе бар аның, шуның өчен бик бәхетле кеше ул.

Габит абый белән Асия апа, инде алтмыш өч ел бергә тигез, тату гомер иткәннәр.

## Йомгаклау

Киләчәгең булсын дисәң, үткәнеңне онытма.

Еллар үтә. Әмма сугыш истәлекләре хәтердә дә, тарих һәм матбугат битләрендә дә саклана, яңара тора. Һәр елны Җиңү көне җиткән саен, бу истәлек – хатирәләр тагы да ачыграк булып күз алдына килеп баса. “Беркем дә, бернәрсә дә онытылмады!” - дигән сүзләрне кабатлап, батырларның исемнәрен искә алабыз, үзебезнең якташларыбызның батырлыгы белән горурланабыз.

Менә мин үземнең эшемдә халык бәхете өчен гомерен кызганмаган шәхес турында сүземне йомгаклыйм. Безнең татар милләтенең менә нинди уллары бар. Кешенең олы җанлылыгына, рухи ныклыгына ышанып, яхшылыкка, изгелеккә, ярдәмчеллеккә өнди ул безнең укучыларны. Бик күпләр бар дөньяга чырай сытып караган елларда бусы да бик актуаль.

## Кулланган әдәбият

1. Әмирханов, Р. М. Ризаэддин Фәхреддин: мирасы һәм хәзерге заман / Мәкаләләр җыентыгы. – Казан, 2003.

2. Әхмәтҗәнов, Р. М. Риза Фәхреддинов шәҗәрәсе. - Казан утлары. -1984. - №1.

3. Ибраһимов, И. Балаларга үгет-нәсыйхәт. – Казан : “Дом печати” нәшрияты, 2001.-192 б.

4. Мәшһүр мәгърифәтче-галим, педагог Ризаэддин Фәхреддин мирасын укыту-тәрбия процессында файдалану. – Казан, 2008. - 212 б.

5. Сәхипова, Р. Ә. Халык педагогикасы нигезендә укыту һәм тәрбия бирү. – Казан, 2005. - 256 б.

6. “Тәрбия” газетасы, - 2003. - № 9.

*Фазлиева Ралина, 9 нчы сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «22 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Аменова Эльмира Зуфар кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Сугыш чоры баласы - гади укытучы

### Кереш

Укытучы! Нинди горур исем! «Яшь буынның киләчәге, аларның язмышы укытучы кулында, аның алтын йөрәгендә», - дигән бөек рус язучысы Александр Фадеев.

Кеше тормышының истәлекләргә бай, һәрвакыт сагынып сөйли торган бер мизгеле ул - мәктәп еллары. Күпме язмышларны олы тормыш юлына аяк бастырган мәктәп үзе, гүя, баласын олы юлга озаткан ана кебек, шуларны сабыр гына күзәтеп тора. Кайгысыз сабый чакны артта калдырып, тәүге тапкыр мәктәп бусагасын атлап кергәндә, еллар буе шатлык-борчуларны бүлешеп яшәп, олы тормыш юлына аяк басканда балаларга төпле һәм акыллы киңәшләрен бирүче - Укытучы. Никадәр сабырлык, түземлелек сорый укытучы хезмәте!

Укытучы - дөньяны танырга, акны карадан, яхшыны яманнан аерырга өйрәтүче ул.

Кешенең иң матур истәлекләре, иң изге хыяллары, иң беренче шатлык-куанычлары аның балачагы һәм үсмер чоры белән бәйләнгән. Менә шушы матур истәлекләр арасында шактый зур урынны мәктәп бусагасын атлап кергән көннән алып, зур тормышка озатып, соңгы кыңгырау чыңлаган көнгә кадәр бала белән һәрвакыт бергә Укытучы атлый. Ул аны белем дөньясына алып керә, хезмәт һәм иҗат шатлыгын тоярга өйрәтә, фикерләү сәләтен үстерә, дөньяга карашын формалаштыра, аңардан шәхес тәрбияләүгә бөтен көчен куя. Укытучы хезмәте авыр да, җаваплы да, кызыклы да. Укытучы һөнәрен сайлау - тынгысызлык, эзләнү юлын сайлау, үз-үзенә һәм башкаларга искиткеч таләпчән булу, көндәлек тырыш, эзлекле хезмәт юлын сайлау дигән сүз ул.

Бу язмамның герое да тормышның төрле этапларын үтеп, яшь буынны тәрбияләүдә фидакарь хезмәт куйган -Рифгат Әбрар улы Хәсәншин турында.

2024 нче елның октябрь ае. Гимназиядә укытучылар көненә багышланган музыкаль чара үткәрелә. Без бу чарага һәрвакыт ветеран укытучыларыбызны да чакырабыз. Алар арасында тыйнак, бик аз сүзле Ривгат абый да бар. Очрашудан соң ул безгә үзенең үтенечен җиткерде. Аның кулында куен дәфтәре иде. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә «куен дәфтәре»нең мәгънәсе һәртөрле кирәкле мәгълүмат, эшләнәчәк эш, фикерләрне теркәү максаты белән янда

йөртелә торган кечерәк дәфтәр, блокнот дип бирелә. Димәк, Рифгат абыйныңниндидер язмалары, истәлекләре бар. Чынлыкта исә, ул туган авылының тарихы турында китап чыгарырга тели икән. Бу дәфтәрдә Ривгат абый авыл тарихына бәйле барлык вакыйгаларны туплаган. Мин дәфтәрдә булган язмаларны электрон вариантка күчерә башладым. Дәфтәрдәге язмаларны укый башлагач, миндә бик күп сораулар туды. Шушы сорауларга җавап табу максатыннан мин эзләнү эше башладым. Минем эзләнү эшемнең нигезендә мәктәбебезнең ветеран укытучысы Хәсәншин Ривгат Әбрар улы, аның тормыш юлы, туган авылы тарихы тора.

Хезмәтемнең актуальлеге:

Без, укучылар, мәктәбебезнең тарихын белергә тиеш, чөнки мәктәп һәр кешенең тормышында мөһим роль уйный. Без укытучылар турында истәлекләрне сакларга тиешбез. Гимназиябездә хезмәт куйган ветеран укытучы  Ривгат абый Хәсәншиның тормыш юлы һәм эшчәнлеге турында без аз беләбез.  Шуннан чыгып, аның тормыш юлын, сугыш чоры балаларының язмышы белән танышуны, укытучының мәктәп тарихында тоткан урынын өйрәнүне фәнни –тикшеренү эшебезнең  төп максаты итеп алдык.

Максаттан чыгып, түбәндәге бурычлар билгеләнде:

-Сугыш чоры баласы - Ривгат абый Хәсәншинның язмышы белән бәйле материал туплау;

- Архив материалларын өйрәнеп системага салу;

-Иске Кармәт авылы тарихыннан кирәкле мәгълүматларны алу;

Төп эшебездә өйрәнү объекты – Ривгат Хәсәншинның тормыш юлы, аның эшчәнлеге, Аксубай районы Иске Кармәт авылы тарихына бәйле вакыйгалар.

Фәнни эшебездә: өлешчә эзләнү, тикшеренү, чагыштыру, анализ кебек метод-алымнарын файдаландык.

Фәнни эшебез кереш, төп өлеш һәм йомгаклаудан тора. Ахырдан кулланылган әдәбият исемлеге бирелде.

Эзләнү барышында мин төрле тикшеренү методларын кулландым:

-гамәли эзләнү – мәгълүматлар туплау;

-мәктәп тарихының үзгәрү динамикасын күзәтү;

-анализлау, чагыштыру, нәтиҗә чыгару;

-тупланган материалны компьютер ярдәмендә системага салу;

- мәктәп музеенда сакланган экспонатларны өйрәнеп, олы укытучыларның истәлекләрен тыңлап материал туплау;

-Ривгат абыйдан интервью алу;

**Төп өлеш**

**Сугыш чоры баласы-гади укытучы Ривгат Әбрар улы**

Хасаншин Ривгат Әбрар улы 1934 елның 7 нче декабрендә Аксубай районының Иске Кармәт авылында, колхозчы гаиләсендә 8 нче бала булып дөньяга килә. Бүгенге көндә Ривгат абый Түбән Кама шәһәрендә яши.

2024 нче елның 7 нче декабрендә педагогик хезмәт ветераны Хәсәншин Ривгат Әбрар улы үзенең 90 яшьлек юбилеен билгеләп үтте. Аның балачагы һәм яшьлеге Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы елларга туры килә. Аның характерын фронтларда батырларча сугышкан һәм тылда фидакарь хезмәт иткән өлкәннәрнең үрнәге формалаштырган һәм хезмәт юлын билгеләгән.

Әй ул көннәр!
Йөрәк - бәгырьләрне
Өзде инде, өзде гомергә.
Бу йөрәкләр ничек түзде икән
Калмаенча кара күмергә.

Сугыш... Нинди шомлы һәм авыр сүз бу! Ул ничә миллион кешенең гомерен өзгән, күпме баланы ятим иткән, аналарны тол калдырган.

Сугыш... Меңәрләгән шәһәрләрне җимергән, җир йөзендә гөрләп торган авылларны юкка чыгарган, шау чәчәккә күмелгән бакчалар янып, көлгә әйләнгән.

Бөек Ватан сугышы... Бөек Җиңү... Бу вакыйгалар, андагы батырлыклар 80 еллык тарих катламы астында калды. Ләкин әнә шул катламнар астында югалмыйча, кешелек дөньясын юкка чыгудан саклап калган, бүгенге көннәргә кадәр халык күңелендә, ил йөрәгендә онытылмаган каһарманнарыбызның батырлыклары әле дә исән, дөнья тарихында алтын хәрефләр белән язылган. Шуңа күрә безгә аларны онытмаска, сафлары сирәгәя барган сугыш ветераннарын, тыл батырларын хөрмәт итәргә, зурларга, батырлыкларын киләчәк буыннарга тапшырырга тиешбез. Әйе, без сугышны әле онытмадык...

Бөек Җиңүнең 80 еллыгы... Бик күп сулар аккан, бик күп кышлар - җәйләр узган, чор белән чор алышынган, тик ничек кенә булмасын, без халкыбызның тарихын, үткәнен онытырга хаклы түгелбез.

**1.1 Безнең язмыш сугыш уты белән үрелгән.**

«Әй, язмыш, язмыш... Узган юллар, узган еллар, мизгелләр кинодагы кебек күз алдыннан үтә. Миңа да гомер юлымда ниләр генә күрергә туры килмәде. Сугыштан соңгы еллардагы хәлләрне үз күзем белән күреп белгәнгә, алар кабат-кабат хәтерне яңарта, йөрәкне әрнетә. Мин 1934 нче елның 7 нче декабренда Аксубай районы Иске Кармәт авылында колхозчы гаиләсендә 8 нче бала булып дөньяга килгәнмен. Гаиләдә мин төпчек бала идем.  Сугыш башланганда миңа нибары җиде генә яшь иде» - дип, сөйләп китте ветеран укытучы Ривгат абый, сугыш турында хәтирәләрен барлавын үтенгәч.

Барлык сугыш чоры балалары язмышы белән аваздаш Ривгат абыйның да язмышы. Сугыш елларында күргән авырлыклар өстенә сугыштан соңгы еллар авырлыгы өстәлә. Әле кечкенә булуына карамастан, әнисенә хуҗалыкта булышкан. Авылда ашарга азык, кияргә кием булмаган. Сугыш башланыр алдыннан ачылган яңа кибет киштәләре дә буш булган. Авылга сугыштан солдатлар кайтса, аны күрергә күршеләр, малай-шалайлар керә торган булганнар. Ул вакытта газета – журналлар алучы юк, чөнки аларга язылырга акча булмаган. Исәнләшергә, күрешергә кергәч, кайбер солдатлар кечкенә кызларга, малайларга бер кисәк шикәр биргәннәр. Ривгат абый истәлекләреннән: «Менә бер көнне сугыштан Гилязев Фоат абый кайтты. Без дә аны күрергә кердек. Безнең исебез китте, Фоат абый татарчаны оныткан, гел русча гына сөйләшә. Безгә авыл малайларына бик сәер һәм кызык булып тоелган иде. Ничек инде гомер буе татарча сөйләшкән Фоат абый татар телен онытсын?!

1945 нче елның 8 май көнендә безнең гаиләгә дә похоронка килде. Минем иң яраткан Камил абыем Германиядә яраланып һәлак булган. Абыем 1943 нче елның гыйнварында сугышка китә һәм фашистларга каршы аяусыз көрәшә. Камил абый 1015 нче укчы полкның 285 дивизиясе составында була. Күрсәтелгән батырлыклары өчен ул II дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнгән. 9 май көнне, Камил абыем турында барысын да күңелем, йөрәгем аша үткәреп, яшел чирәмдә уйланып, бәбкәләр саклап утырам. Авыл уртасыннан Әнәс исемле малай кайтып килә. Сугыш беткәнен шул Әнәс хәбәр итте. Бу хәбәр тиз арада бөтен авылга таралды.

Бөек җиңү көне, җанда чаткысы,
Бөек бәйрәм, чал чәчләрдә -яктысы,
Бөек шатлык, күзләрдә яшь тамчысы

Җиңү көне! Җиңү көне! Җиңү көне! Минем хисләрем нәкъ шушы җырдагыча иде. Бөек шатлык, күзләрдә яшь тамчысы, беренчедән Камил абый һәлак булды, икенчедән Җиңү!»

Сугыш бетсә дә, тормыш көннән көн катлауланган. Барлык кеше дә авыр хезмәт башкарган, рәхәт тормыш турында берәү дә сорамаган. Һәр кеше кулыннан килгән кадәр тырышкан: басу да сукалаган, үгез һәм ат белән йөкләмә үтәү өчен ашлык төягән. Көчләреннән килгәнчә Җиңү көнен якынайтканнар. Сугыш чорында балачагы туры килгән Ривгат абый да тырыш, булдыклы, кешелекле, авырлыклар алдында каушап калмый торган олы йөрәкле, киң күңелле, сабыр һәм шул ук вакытта гади һәм тыйнак кеше. Шундый авыр сугыштан соңгы чорлардан соң да ул үзенең тормышта юлын тапкан. Урта мәктәпне тәмамлагач, ул колхозда эшләгән. Берникадәр вакыттан соң аны Кызыл Армия сафларына чакыралар. Ул Киевта хезмәт итә. 1953 нче елның ноябрендә Парадта катнашкан. Ул 2 ел хезмәт итеп, офицер дәрәҗәсе алып туган авылына кайта. Авылда 4 ай башлангыч сыйныфта укытучы булып эшли. 1957 нче елда берникадәр вакыт клуб мөдире булып эшләп

ала. Шул елны Ривгат абый Казан дәүләт педагогия институтына укырга керә. Әти-әнисенең улларын бик тә укытасы килә, ләкин уку өчен акчалары булмый. Ривгат абый 3 нче курсны тәмамлагач, читтән торып укуга күчә һәм туган авылында физкультура укытучысы булып эшли башлый. Мәктәптә параллель класслар булмау сәбәпле, Ривгат абыйга ОБЖ, физкультура, физика, хезмәт һәм башка фәннәр укытырга туры килә. Халык саны буенча 1958 нче елда Аксубай районы Иске Кармәт авылында 841 кеше, 1979 нчы елда 895 кеше исәпләнгән. 2015 елда 450 кеше( татарлар 55%, чуашлар 40%) исәпләнә. Бүгенге көндә Иске Кармәт авылында башлангы мәктәп кенә бар. Анда 2 укытучы укыта, 6 укучы укый. Ривгат абыйның әтисе, әнисе ягыннан апалары барысы да укытучылар.

1986 нче елны Ривгат абый гаиләсе белән Түбән Кама шәһәренә күчеп килә. «Балаларга авылда эш булмагач, аларны барыбер шәһәргә җибәрергә туры киләчәген аңладык та, бөтен гаиләбез белән шәһәргә күченеп килдек һәм дөрес эшләдек» -дип сөйли Ривгат абый. Шәһәргә килүгә 3 ай дигәндә, өр яңа йорттан ике бүлмәле фатир бирәләр.

1987 елда беренче директор Вышинский Александр Павлович белән бергә Ривгат абый беренче укучылар өчен 22 нче мәктәпне ачканнар. 22 нче мәктәптә 16 ел директор урынбасары булып эшли. ОБЖ фәнен укыта.

Ривгат абый эшләгән елларда гимназия «Балалар бакчасы-мәктәп - көллият – вуз» системасында эксперименталь эш программасын тормышка ашыру процессында катнаша. Системаның структурасы - күп баскычлы, эзлекле, адаптацион. Ул биш баскычтан тора, аның звеносы - инглиз телен тирәнтен өйрәнүле 22-нче номерлы мәктәп колледж-класслары. 1999-2000 уку елында беренче тапкыр гуманитар юнәлешнең «Халыкара мөнәсәбәтләр» белгечлеге буенча 10 нчы колледж-класс ачыла.

1999 елның 2 июленнән лицей «Инглиз телен тирәнтен өйрәнүле 22 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» исемен йөртә башлый. Билгеле булганча, мәктәп - ул икенче йорт. Биредә балалар укып кына калмыйлар, ә үзара аралашалар да. 1998 елдан мәктәптә «Содружество» балалар оешмасы эшли башлый, ул үзенең төп юнәлеше итеп балаларның иҗади активлыгын үстерүне күз алдында тота. 2003 нче елны тавышы карлыгу сәбәпле Ривгат абый, 68 яшендә, лаеклы ялга китә. Күпчелек халык шәһәргә киткәч, колхоз беткәч, халык укырга чыгып йөрми башлагач, кыр, сыза, чишмә исемнәре онытылып бетмәсен дип, ул туган авылының атамаларын үзе белгән кадәр язып калдырырга уйлый. Шул елларда языла башлаган куен дәфтәре битләрен ачабыз....

## 2. Аксубай районы Иске Кармәт авылы

Аксубай районы – бик үзенчәлекле район. Археологлар тарафыннан Яна Кармәт авылы янында имәнкискә кабилә- кавемнәре чорына мөнәсәбәтле авыл хәрабәләре кабер ташлары булган зират билгеләнгән. Авыл урынында элек кара урман үскән Аю аланы. Аю аланы елгасы.

Аю аланы чишмәсе кебек топонимнар бу урманнарда ерткыч җанварлар да яшәгәнлеген дәлилли. Авылны нигезләүчеләр урман кисеп йорт урыннары, чәчүлек җирләре ясаганнар. Аксакаллар сөйләвенә караганда. Иске Татар Кармәте авылына иң беренче Кариәхмәт исемле мөселман килеп утырган. Башта авыл берничә йорттан гына тора. Тора-бара ул зурая. Авылдагы нәселләр арасында Сембер якларыннан килүчеләр дә бар.

Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, авылга чуашлар һәм руслар килеп утыра. Христианлаштыру сәясәте башлангач, авыл халкының бер өлеше керәшен татарларына әверелә. Чукындыру көч, ирексезләү юлы белән алып барыла. Чукындырылган халык поп килгәндә тәреләрен чыгарып куя, ул киткәч яшерә. Кайберәүләр чукындыру максаты белән килгән попны кыйнап та ташлаган. Авыл халкының мөселман өлеше-Олы ара. Алар яшәгән урам Татар очы дип йөртелә. Керәшен татарлары-Кече ара. Алар торган урамны Керәшен очы диләр. Зиратлары аерым була. Революциягә кадәр Олы аралар керәшен татарларына кыз бирмиләр, аралашмыйлар. Соңыннан керәшен татарлары исламга кире чыга. Олы һәм Кече аралар революциядән соң гына гына дуслашалар. Авыл тирәсендәге куаклар арасына бер ачыклыкка чуашлар килеп утырган Мәетләрен алар (һәм русларда) Рус Кармәтенә илтеп күмә торган булганнар. Елга буендагы каенлык чуашларнын кирәмәтләре булган Алар шунда чыгып, нәзер әйтеп сарык һәм бәрән суя торган булганнар. Авылда Чуаш ягы дип атала торган топоним (урам исеме) бар. Революциядән сон татар, рус. чуаш халыкларыннан оешкан өч колхоз барлыкка килә

Рус Кармәтен халык Иске авыл дип йөртә. Анда элек татарлар яшәгән. Бу авыл халкы арасында кайчандыр хәзерге Буа районыннан күчеп килгән Кушай бабай да булган Казан ханлыгы алынганнан соң, авылга ике рус бояры килеп утыргач, андагы татарлар Яна Кармәткә күченәләр. Кушай нәселе хәзер Яна Кармәттә яши. Авылның яртысын шушы нәсел тәшкил итә Бу авылга Иске Кармәттән күченүчеләр дә булган Яна Кармәт авылы кешеләре аксыл йөзле, аксыл кашлы һәм керфекле, күзләре зәнгәрсу; К. Р. Х авазларын нечкә итеп әйтәләр. Авылга 1964 елның 23 апрелендә Иске Татар Кармәте (XVII йөзнең икенче яртысында нигезләнә) һәм Югары Чуаш Кармәте (XVIII йөздә нигезләнә) авыллары кушылу нәтиҗәсендә нигез салына.

**Ривгат абый язмаларыннан.**

«Елга буйлап аска төшсәк авыл ягына Үгез елгасы, Кармәт елгасына килеп кушыла. Үгез елгасыннан соң, Кармәт елгасының уң ягында әпәй (ипи) тавы, ул ярым түгәрәк ипигә охшаган, шуннан арырак кыр эчендәрак сыер күле. Язын бу күлдә сары төстәге төнбоеклар чәчәк ата, җәен ямь-яшел камыш үсә. Тагында түбәнрәк Бикләү күле. Бу күлне (кайчандыр сыер күле кебек булгандыр) 1913 елларда тирәсендә булса кирәк, хөкүмәт акча биреп авыл халкыннан казыткан, эшсезлекне бетерү өчен. Шул күл яныннан Бикләү күле елгасы

башлана, аның уң ягына акбалчык һәм атау елгалары (сызала) килеп кушыла, һәм арьяк урамы бакчалары артыннан үтеп Кармәт елгасына кушыла. Атау елгасы белән Кармәт елгасы кушылган җирдә колхозның алма бакчасы, түбән өлешендә карлыган иде. Үсентеләрен Кармәт елгасы арасындагы, элекке кече колхоз бакчасыннан күчереп утырткканнар. Ул карлыганнарны, әтинең сеңлесе Рәшидә апа, бригадир булып эшләгәндә, утырткан булган икән. Кармәт елгасының алма бакчасына җиткән өлеше Алмантай дип атала. Алмантай исемле чуваш монда су тегермәне тоткан. Аерым хуҗалык вакытында Срур бабай халыкка акча түләп буа будырган. Яхшылабрак карасаң ул буа урыны хәзердә билгеле. Шул буада су тегермәне булган. Мондагы болынлык Тау Асты дип атала. Болынлык су белән капланган кошлар да җәйлүгә кала торган булганнар. Аккошларны Сидор дигән кеше атып алган һәм бүтән аккошлар җәйлүгә калганнар. Сугышка кадәр (1941г) колхоз атлар, посилкалар, тачкалар белән колхозчылардан буа будыра иде. Аскы якка чыбыклар, туфракка салам салып буа буалар иде.Усал малайлар урыс малайларын буа суында коендырмый иде.

Колхоз бакчасы беткән җирдә минзәли кизләүе иде. Хәзер ул кизләу кипте, чөнки Шарлавык елганы тирәнәйтте һәм су аска китте»

**Аксубай районы Иске Кармәт авылының күренекле кешеләре.**

Ф.М.Белов (тәхәллүсе Белов Михаил) (1911−1982) – прозаик, драматург, тәрҗемәче, СССР Язучылар берлеге эгъзасы, Бөек Ватан сугышында катнаша, Кызыл Йолдыз ордены кавалеры;

Л.Г.Мөхетдинов (1956 елда туган) – ТРның атказанган транспорт хезмәткәре;

Р.Х.Низаев (1951 елда туган) – нефтьче, техник фәннәр докторы;

Г.И.Акташ (1935−2014) – шагыйрь;

Р.Х.Хисмәтуллин (1934 елда туган) – хокук белгече, язучы.

Иске Кармәт авылының иң күренекле, абруйлы кешесе – Хәсән Туфан(1900−1981). Ул Совет чорының классик шагыйре, ТАССРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, ике Кызыл Байрак ордены кавлеры.

Туган авылында аңа багышланган бик бай һәм гаҗәп үзенчәлекле музей-йорт эшләп килә.

**Йомгаклау**

Һәр авылның үзенең генә хас, кабатланмас, истә кала торган урыннары күп. Сокланып туймаслык тугайлар, челтерәп ага торган йөгерек чишмә буйлары, балыклы күлләр, куе әрәмәләр белән уратылган елга үзәннәре, туган ягыбызның кырлары, басулары, шаулап торган урманнары күңелләргә рәхәтлек биреп, туган илгә мәхәббәт тәрбияли. Кая гына барсак та, нинди генә матур урыннарны күреп соклансак та, туган төбәгебезнең матурлыгын берни дә алыштыра алмый. Минем хезмәтем дә үз авылының тарихына

битараф булмаган, табигатен һәм авылдашларын яратучы, хөрмәт итүче сугыш чоры баласы, гимназиябезнең ветеран укытучысы – Хәсәншин Ривгат Әбрар улы.

Эшебездә куйган максатыбызга ирештек дип уйлыйбыз. Максатка ирешер өчен, музей документлары белән таныштык, китаплардан, интернеттан мәгълүмат алдык, фотолар тупладык. Хезмәтебезнең – төп герое Ривгат абый Хәсәншин белән берничә тапкыр очрашуда булдык, аннан интервью алдык. Сугыш чоры балалары бик күп михнәтләр күргән. Хәзерге тормышның кадерен белегез, тырыш һәм әдәпле, сәламәт булыгыз - дип, безгә изге теләкләрен теләде соңгы очрашуда Ривгат абый. Әйе, бу сугыш илебезгә күпме кайгы-хәсрәт, күпме күз яше китереп, күпме сабыйларны ятим калдырды. Шулай булуга да карамастан, Ватанга булган мәхәббәт, тыныч, бәхетле киләчәккә ышаныч барысыннан да көчле булып, Бөек Җиңүгә китерде. Ривгат абыйның туган авылы Аксубай районы Иске Кармәт авылы турында күп белешмә алдык. Лаеклы ялга чыккач, Ривгат абый туган авылы тарихына кагылышлы бик күп мәгълүмат җыя. Ул үзенең язмаларында, истәлекләрендә авылның башкалар сокланырлык матур якларын: географик атамаларын, Аксубай районы турында фикерләрне, күренекле, эшчән кешеләрен, гүзәл эшләрен күрсәтә. Без аның куен дәфтәрендә язылган истәлекләрне яхшылап өйрәндек. Еллар үткән саен, шактый сандагы авылларның юкка чыгуларын беләбез.Ләкин Ривгат абыйның туган авылы яшәячәк, чөнки буыннар чылбыры өзелмәгән. Киләчәгенең матур буласына ышанып, үткәннәрне онытмыйча, шөкер итеп яши белә халкыбыз. Шулардан чыгып, без түбәндәге нәтиҗәләргә килдек:

Милләтне яшәтүче көч ул – татар авыллары һәм аның халкы.

Авылның киләчәген аның күренекле шәхесләре, талантлы кешеләре, уңган-булган халкы тәэмин итә.

2025 елда Бөек Җиңүнең 80 еллыгын зурлап билгелибез. Ул — безнең өчен иң олы бәйрәм. Тарихи даталарның берсе дә шундый дәрәҗәгә күтәрелә алмый. Чөнки Җиңү көне — чын халык бәйрәме, күңелләребездән ихлас шатлык һәм сагыш яше аккан, үз гомерләре белән исәпләшмичә Җиңүне якынайткан әти-бабаларны искә алу, аларның батырлыгына соклану һәм горурлану, хәтер көне. Ил азатлыгы өчен көрәшкән геройларның, тыл каһарманнарының фидакарьлеге беркайчан да, беркем тарафыннан да онытылмаска тиеш. Аларга мәңгелек һәйкәл — ул безнең хәтеребез һәм горурлыгыбыз!

**Кулланылган әдәбият**

1.Арсланов, Л. Ш. Финны, угры и самодийцы в восточном Закамье / Л. Ш. Арсланов, Е. Г. Казаков. - Елабуга, 1993.

2. «Безнең мәктәп дөньясы»- альманах, 2000 ел

3. Ветеран укытучыларның һәм мәктәпне тәмамлаган чыгарылыш класс укучыларының истәлекләре.

4.Гыймадиева, Н. С. Имтиханнар өчен сочинениеләр. - Казан, 2003.

5.Казыйханов, В. С. Әхлак дәресләре. - Яр Чаллы, 1998.

6.Рифә Рахман. Татар телендә 100 сочинение. - Казан, 2001.

7. 1987 нче елдан алып 2019 нче елга кадәр булган приказлар кенәгәсе.

Сылтамалар:

https://tatarica.org/tat/razdely/municipalnye-obrazovaniya/municipalnye-rajony/aksubaj-rajony/iske-karmt Онлайн - энциклопедия Tatarica

https://tat.nur.tatar/hesen-tufan-biografiya-tormysh-yuly

https://ifmk.kpfu.ru/news/aksubaj-rajony-iske-karmət-avylynda-dialektologik-ekspediczіya/

https://ok.ru/group/57076981956685/topic/153419223094605

*Һадиев Инзил, 7 нче сыйныф,*

*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «А.А. Шаповалов исемендәге 31 нче лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*

*Җитәкчеләре: Һадиева Сиринә Әсхәт кызы,*

*Ильина Зоя Евдоким кызы*

*туган тел һәм әдәбияты укытучылары*

## Мәңгелек хәтер

### Кереш

Үлем турында уйлама,
Илең турында уйла.
Илең турында уйласаң,
Гомерең озын була.
(Фатих Кәрим)

Бөек Ватан сугышында катнашкан ерак бабам Хәлиулла турында эзләнү-тикшерү эше язу теләге минем күңелемдә күптән яши. Ерак бабам турындагы истәлекләрне безгә аның кызы – Зөлфирә әбием еш сөйли. Балалары һәм оныклары, булган мәгълүматларны җыеп, стена газетасы да чыгардылар. Ул гәзитнең бер нөсхәсе әбиемдә саклана. 9 нчы май – Җиңү көне якынлашканда, әбием ул гәзитне кадерләп, өйнең түренә элеп куя. Истәлекләр кабат яңартыла. Бу тема безнең гаилә өчен һәрвакыт **актуаль.** Ел саен без аны шулай искә алабыз, шул рәвешле, разведчик булып күп батырлыклар күрсәткән ерак бабам белән горурлану хисләре елдан ел арта.

**Гипотеза:** Әгәр без моннан 80 ел элек тәмамланган, илебезгә күз яше, ачлык, үлемнәр һәм кайгы китергән, салкын тын өргән сугыш турында онытмасак, аның батырлары белән горурланып үссәк, тыныч тормышның кадерен ныграк белербез.

**Проектның максаты:** Бөек Ватан сугышында разведчик булган ерак бабам турындагы истәлекләрне алдагы буыннарга тапшыру максатыннан өйрәнү.

**Проектның объекты:** гаилә истәлекләре**.**

**Проектнын предметы**: Бөек Ватан сугышында катнашучы - минем ерак бабам.

**Проектның бурычы:**

1. Батыр бабамның сугыш юллары белән танышу.

2. Бөек Ватан сугышы елларында туганнарыбыз язмышы турында мәгълүмат җыю.

**Тикшеренү ысуллары:**

-туганнар белән сөйләшү-сораштыру (интервью);

-гаилә архивын (фотоальбом, газетадагы мәкалә) өйрәнү;

-китаплардан һәм интернеттан мәгълүмат эзләү;

-җыелган мәгълүматны туплап, тәртипкә салу.

## Төп өлеш. Разведчик бабам

### 1.1. Армиядән – фронтка!

Минем ерак бабам Хәбибрахманов Хәлиулла 1913 елның 28 октябрендә Калинин районы (хәзерге Актаныш районы) Иске Сәфәр авылында туган. Әти-әниләре, әбисе белән бабасы дини белемле һәм авылда хөрмәткә ия кешеләр булганнар. Ерак бабам 4 кенә класс белем алса да, алдынгы фикерле булган. 15 яшендә, бәхет эзләп, чит җирләргә чыгып китә һәм Ижау шәһәренә барып урнаша. 1935 нче елны, 22 яшендә Совет Армиясенә чакырылып, 1937 нче елга кадәр хезмәт итә. Армиядән кайткач, Ленинград шәһәренә китеп, “Монетный двор”да эшли башлый. Тынгысыз еллар була, 1939-1940 нчы елларда Фин сугышында катнаша, ә 1941нче елда фашист гаскәрләре илебезгә һөҗүм иткәч, батыр солдат ике дә уйлап тормыйча, сугышның башыннан ук илебезне сакларга китә. Украина фронты [3] 502 нче укчылар полкында (стрелковый полк) разведчик булып хезмәт итә, берничә тапкыр яралана, госпитальдә дәвалана, аннары 70 нче укчылар дивизиясенә разведчик итеп күчерелә. 1943 нче елны аны 17 нче ротага күчерәләр, чөнки ул узен каһарман, кыю солдат итеп күрсәтә.

### 1.2. Хәрби бүләкләре

Сугышның башыннан ахырына кадәр ут эчендә йөргән ерак бабам! Батыр һәм оста разведчикның күкрәгендә бик дәрәҗәле хәрби бүләкләр балкыган: 3 нче һәм 2 нче дәрәҗә Дан орденнары, Кызыл Йолдыз ордены, ике данә “Батырлык өчен” медале. Бу орден-медальләр аңа катлаулы сугышчан бурычны үтәгәндә әсирләр алып кайткан өчен бирелгән.

Бик әһәмиятле бер вакыйганы әйтеп узасы килә: 1944 нче елның көзендә Висла елгасы аръягында Сандомир плацдармында [3] торган разведкада күрсәткән батырлыгы өчен генерал Петр Михайлович Чирков ерак бабамны туган авылына кыска вакытлы ялга

җибәрә. Бу бит сугыш вакыты, гаҗәп хәл! Кайтып әти-әнисен, туганнарын, бөтен авыл кешеләрен шатландырып ял итеп китә. Бу бит үзе югары дәрәҗәдәге бүләк!

### 1.3. Туган якка кайту

Җиңү көнен ерак бабам Чехословакиядә каршы алган. Туган ягына 1945 нче елның 15 нче октябрендә генә кайткан ул. 1946 нчы елда Миннәхмәтова Мәрьям белән тормыш коралар. Мәрьям әби безнең авылдан сугышта башыннан ахырына кадәр катнашып исән кайткан бердәнбер хатын-кыз! Ул Ерак Көнчыгышта – илебез чикләрен японнардан саклаучы зенит батареясында хезмәт иткән, орденнар, медальләр белән бүләкләнгән. Кызганычка каршы, алар сакланмаган.

Тормышлары җайланып кына барганда, бик авыр кайгы кичерәләр: 6 баланың төпчеге - 10 яшьлек балалары суга батып үлә. 5 балага  белем биреп, илебезгә лаеклы уллар-кызлар тәрбиялиләр. Олыгайган көннәрендә балаларының хөрмәтендә гомер кичерәләр, оста умартачы, бакчачы, вак тешле тарак ясаучы буларак авылдашлары арасында да хөрмәткә лаек булалар.

Еллар үтә, ләкин ерак бабам кебек кешеләрнең Бөек Ватан сугышында күрсәткән тиңдәшсез батырлыгы беркайчан да онтылмасын, киләчәк буыннар өчен бу сүнмәс маяк булып торсын иде. Бу Җиңүнең нинди авырлыклар бәраберенә яуланганын беркайчан да онытырга тиеш түгелбез. Еллар тыныч булсын, илебенең куәте ныгысын! Шуны безгә васыять итеп калдырган бабаларыбыз.

## 2. Бабам истәлекләре

### 2.1. 22 “тел”

“Отпуск турында мин уйламаган да идем. Дошманны җиңгәч кенә өйгә кайтырмын дип хыялландым, ә хәзергә дошман тулысынча җиңелмәгән, ял турында ничек уйламак кирәк? Сугышырга кирәк, ләкин беркөнне, разедкадан соң, дусларыбыз Стрельковский, Чебыкин һәм Колчерин белән бергә “тел” алып кайткач, мине рота командиры чакырып алды. “Иптәш Хәбибрахманов, - диде ул, - генерал сезгә туган ягыгызга айтып килү өчен ял бирде.”

Кич белән, өйдә утлар эленгәч, туган авылым урамыннан атлыйм. 6 ел була икән инде моннан киткәнемә. Финляндиянең карлы якларында сугышырга туры килде. Фин сугышыннан соң Ленинградта эшләдем. Аннары фронтка киттем.

Өебезнең ишеге ачык иде. Шакымыйча гына эчкә үттем. Әтием- Хәбибрахман карт өстәл артында утыра.

-Керергә буламы? –мин әйтәм.

-Керегез, кер,-дип җавап кайтарды атай. Ишектән керүче фронтовикның мин икәнен күреп, көтелмәгән шатлыклы очрашудан күзләренә яшь килде.  Барысы да өйдә иделәр: әнкәй, сеңлем Мөхлиса, энем Хәбибулла. Шатланыша-шатланыша, өстәл әзерләделәр”.

“Офицер Бабич төркеме белән төнге разведкага кузгалдык. Дошманны юк итәргә дип, әткәйгә сүз биреп киткән идем. Дошманга иң беренче ташландым, берсен җиргә егып салдым. Иптәшләрем Муратов, Пономаренко белән аны кулга алдык”. Шулай итеп, алар 22 “тел” алып кайталар һәм шуның өчен бүләкләнәләр.

**2.2.“Генерал батырны эзли”**

Сугыш бетеп, 20 ел узгач, колхоз идарәсенә Генерал П.М.Чирковтан хат килеп төшә [1: б.2]. Күп юллар узган, төрле печатьләр белән чуарланып беткән бу хатның татар теленә тәрҗемә ителгән кыскартылган вариантын тәкъдим итәбез:

“Кадерле иптәшләр!

Сезнең колхоз члены булган Хәлиулла Хәйбрахманов сугыш елларында минем командалыктагы (гвардияче) 15 нче укчы дивизиядә хезмәт итте. Батыр һәм оста разведчик иде. <...> Куелган бурычларны бик яхшы үтәде. <...> Кызганычка каршы, безнең арада элемтә юк, ә аның турында – батыр разведчик турында бик беләсем килә.

Хөрмәт белән Чирков Петр Михайлович, генерал-лейтенант, гвардияче 15 нче укчы дивизиянең элекке командиры.”

**2.3.Батырлар очраша**

Шул рәвешле генерал, ерак бабамны эзләп табып, Одессага чакыра. Ике арада хатлар йөри башлый. 1965 нче елда Одессада Җиңү көненә багышланган очрашуда, ниһаять, үзенең генералы И.М.Бабич белән очраша (Рәс.11). Моннан соң алар арасында элемтә өзелми: 1975 нче елда Ленинградта, 1979 нчы елда Брест крепостендә, 1989 нчы елда (бу вакытта ерак бабама 76 яшь) немецлардан үзләре азат иткән Владимир-Волынск шәһәрендә сугышчы-разведчикларның гвардия берләшмәләре төзелүнең 50 еллыгына багышланган чарада катнаша. 1992 нче елда 79 яшендә бакыйлыкка күчә.

**2.4. Нәсел җепләрен өйрәнү**

«Илен белмәгән – игелексез, халкын белмәгән – холыксыз, нәселен белмәгән - нәсәпсез» дип, юкка гына әйтмәгән халкыбыз. Борынгы заманда һәр кеше үзенең җиде буын бабасын белергә тиеш булган, үз нәселен белгән кеше абруйлылардан саналган. Минемчә, буыннар тарихын өйрәнү кызыклы һәм файдалы. Ерак әби-бабайлар кем булган, ничек яшәгән һәм ни белән шөгыльләнгән, без кемгә охшаган? Билгеле булганча, аларның холык-фигыльләре бездә чагыла, яшәү рәвешләре безнең тормышта да уз урынын ала.

Һәр кеше үз гаиләсендә буыннан буынга килгән истәлекләрне белеп, аларны саклап, киләчәк буынга тапшырырга тиеш, чөнки без - нәсел дәвамчылары.

Ерак бабам белән бәйләнешне миңа әбием шәҗәрә ясап аңлатты. Хәлиулла бабай минем дүртенче буын бабам була. Ул минем әниемнең әнисенең әтисе. Гадирәк итеп

әйткәндә, Зөлфирә әбиемнең әтисе. Аның  биш баласы, 12 оныгы булган. Хәзерге көндә 29 оныкчыгы, һәм тагын яңа буын - 4 нәсел дәвамчысы бар.

### 2.5. Фронтовик туганнар

**(Бөек Ватан сугышында катнашкан кайбер туганнарыбыз язмышы турында эш барышында табылган мәгълүмат)**

Безнең авылдан Бөек Ватан сугышына 567 кеше киткән (9ы безнең туганнар). Шуларның 312се  һәлак булган, калган 255е әйләнеп кайкан [4: б.152]. Фарсыев Муллаян абый (Әсхәт бабамның абзасы) Мәскәү оборонасын саклауда батырлык күрсәткән, туган авылына исән кайткан; Мөхәммәтһади (Муллаян абыйның бертуган энесе) взвод командиры булган, хәбәрсез югалган; Хәйрулла белән Хәтмулла (Хәлиулла бабамның абыйсы хәбәрсез югалган һәм энесе Белоруссия фронтында ятып калган [2: б.480]; Әсхәт бабамның әтисе Ахунҗанов  Әхмәтшәрип Ахунҗанович (1905-1942) рядовой 27.07.1941 – ... .03.1942 Мәскәү янында хәбәрсез югалган.

## Йомгаклау

Быел зур дата - Бөек Җиңүнең 80 еллыгы. Бу уңайдан язылган әлеге эзләнү-тикшерү эшем ерак бабамның рухына дога булып барып ирешсен иде. Бу эшне төгәлләгәннән соң күңелемдә җиңел бер рәхәтлек барлыкка килде, чөнки мин куйган максатыма ирештем: разведчик бабам турындагы мәгълүматны  горур рәвештә башкаларга һәм алдагы буыннарга сөйләрлек итеп тупладым.

“Исәннәрнең кадерен бел, үлгәннәрнең каберен бел” ди халык мәкале. Ерак бабам туган авылында – Иске Сәфәр авылы зиратында җирләнгән. Ел саен яз көне без аның каберен чистартып, җыештырып кайтабыз. 9 нчы май – Җиңү көнендә сугыш кырларында ятып калган барлык туганнарны, авылдашларны искә алабыз: альбомдагы фотоларны бергәләп карыйбыз, әбием сөйләгәннәрне тыңлыйбыз, “Сәфәрем” китабы буенча да истәлекләр яңартабыз, “Үлемсез полк”, “Җиңү тәрәзәләре” кебек акцияләрдә катнашабыз. Самат Шакирның “Бабамның медальләре” шигырен дә мин ерак бабамның якты истәлегенә багышлап ятладым.

Кызганычка каршы, бүгенге көндә дә җир йөзендә сугышлар тынмый. Тарихчылар исәпләвенчә, сугышның һәр көнендә 14 мең кешенең гомере өзелгән. Бу исә, минут саен 10 кеше дигән сүз. Тетрәндергеч саннар! Әйе, һәр туган яңа көн, бүгенге бәхетле тормышыбыз өчен без, иң элек гүзәл тормышларын биргән каһарманнарга, сугыштан исән-сау кайтып хезмәт иткән тыл батырларына мәңгелек бурычлы. Кадерлик, онытмыйк аларны, баш иик аларга. Дөньяда яшәүче барлык кешенең бер теләге бар – туган илдә тынычлык булсын! Сугыш уты бер җирдә дә кабынмасын, дөньялар имин булсын.

Изге җиребезне илбасарлардан саклап, аның иминлеге өчен гомерен дә кызганмаган батырлар алдында баш иябез! Безнең бурычыбыз – сугыш елларындагы халыкның батырлыгын онытмыйча, үзебездән соң килгән буыннарга тапшыру. Аларның исеме, якты маяк булып, буыннардан-буыннарга күчсен!

**Әдәбият исемлеге**


1.“Актаныш таңнары” район газетасы. - 1975. - 4 май. – 4 б.

2. Книга памяти. Хәтер китабы: в 2 т. Т.2 / под ред. Р .Р. Идиятуллина. – Казань : Татарское газетно-журнальное издательство,1994. – 557 б.

3.Сандомирский плацдарм [Электронный ресурс] – URL : https://ru.wikipedia.org/sandomir- Мөрәҗәгать вакыты: 16.01.2025

4. “Сәфәрем” тарихи-нәфис басма / Р. С. Сәетов, И. Г. Хаҗиева. - ТР, Яр Чаллы: ҖЧЖ “Ислам нуры” нәшрияты, 2020. - 618 б.



*Хузиахметова Ильвина, 9 нчы сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «16 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләре: Фәрхетдинова Фәнирә Гарәф кызы,*
*рус теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*Сәлимова Гүзәлия Рәшит кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*


## Батырлар исеме мәңгелек

Кереш

1945 нче елдагы Җиңү-кешелек дөньясын юкка чыгудан, безнең ил һәм Европа халыкларын фашизм коллыгына төшүдән коткарып калды. Бөек Җиңү совет кешеләренең, сугышчыларының батырлыгы, ныклыгы, куркусызлыгы, Ватаныбыздагы халыкларның дуслыгы, бердәмлеге, нәтиҗәсендә яуланды.

Миллионнарча корбаннар, җимерелгән шәһәрләр, яндырылган авыллар...

Сугыш шаукымы бер генә гаиләне дә читләтеп узмаган, һәр йортның, һәр гаиләнең ишеген шакыган. Кара кайгы күпме аналарның, толларның, ятимнәрнең күңелендә төзәлмәс җәрәхәт калдырган. Ул җәрәхәтләр һаман да сызлый, һаман да әрни.

Солдат сугышны сайламый. Ул сугышны игълан да итми. Ул бары тик, биргән антына һәм хәрби бурычына тугрылыклы булып, халык һәм Ватан исеменнән бирелгән боерыкны гына үти.

Аның каһарманлыгы, батырлыгы, Ватанга ихтирамы һәм мәхәббәте нәкъ менә шунда күренә.

80 ел үтсә дә, сугыш китергән тирән хәсрәт, күңел ярасы онытылмый. Күпме сабый этисез, күпме ана баласыз, күпме кызлар, күпме хатыннар тол калды ул елларда. Әле хәзер дә алар югалткан кешеләрен көтеп яшиләр.

Еллар үтү белән күп вакыйгалар хәтердән җуела. Әмма без тарихтагы кайгылы көннәрне онытырга тиеш түгелбез.

Сугыш күптән бетте. Окоплар казылган җирләр тигезләнеп гөл бакчага әверелде, алар матур яшел чирәмнәр белән капланды, белиндаж урыннары чәчәкләргә күмелде. Әмма Җир - ана сугыш эзләрен мәңге онытмас.

Безнең арада сугышны беркайчан онытмыйча, хәтерләрендә саклаучы батырлар яши.

Без яши торган җирне саклап калу өчен, батырлар ут-су кичкәннәр, окопларда туңганнар, бозлы елгаларны ерып чыкканнар.

9 нчы май-Җинү бәйрәме генә түгел. Сугыштан туган якларына әйләнеп кайта алмаган батырларны искә алу көне дә.

Җиңүнең 80 еллыгы уңаеннан мин фәнни -тикшеренү эшемнең темасы итеп “Батырлар исеме мәңгелек”.

Мин бу теманы бик **актуаль** дип саныйм, чөнки сугыш тәмамланган еллар бездән ерагая, сугыш ветераннары әзәя бара.

**Эшемнең төп максаты:**

- сугыш кырларында һәлак булган Сабирҗан бабай истәлекләрен өйрәнү;

- бүгенге көндә безнең арада булган сугыш ветераннарының исемлеген барлау;

- Каенлы авылыннын китеп һәлак булган авылдашлар исемлеген барлау;

- сугыш афәтенең һәр кеше, һәр гаилә өчен фаҗига булуын раслау;

- Җиңүнең 80 еллык юбилее уңаеннан Бөек Ватан сугыш материаллары белән күбрәк кызыксыну.

Каенлы авылы халкының сугыш чоры тарихын һәм сугыш ветераннары турында белү минем **бурычым.**

**Эзләнү – тикшеренү эшемнең объекты** – Каенлы авылының Ахуновлар гаиләсе.

**Гипотеза:** яшь авыл егетләренең күрсәткән батырлыклары, ул көннәр өчен чынбарлыкмы?

**Эш алымнары:**

- солдат хатларын анализлау;

- эзләнүләр;

- ветераннар белән очрашу.

**Практик әһәмияте**: укытучылар һәм укучылар сыйныф сәгатьләрендә, төрле кичәләрдә куллана алалар.

# 1 нче бүлек. КАҺӘРЛӘНГӘН ЕЛЛАР

## 1.1 Сугыш ачысы

Ул каһәр суккан сугыш елларын онытырга мөмкинме соң? Әле генә дөньяга аваз салганнарның да, инде тәпи атлап киткәннәрнең дә, урамнарда уйнап йөрүче бала-чагаларның да, сөякләре дә ныгып җитмәгән килеш колхозның авыр эшләренә җигелгән яшүсмерләрнең дә, буй җиткән кызларның да, килен булып килгән, әмма ана булу бәхетенә ирешә алмаганнарның да, ир белән яшәү бәхетен татып та бетермәгән хатыннарның да, балаларын кочаклап тол калганнарның да иң ачы күз яшьләре аккан еллар бу! 1941-1945 нче еллар! Күпме балалар әтиләрен соңгы тапкыр күреп калгандыр. Әтиләрен бөтенләй күрми калган сабыйлар... Боларны тарихтан сызып ташлау мөмкинме соң?

Гадәттәгечә җәйге аяз, бик матур бер көн. Кояшның гаме юк, кыздыра да кыздыра, ара-тирә болытлар арасына да кереп яшеренә. Авыл халкы җәйге эш- мәшәкатьләре белән яши. Тик бу матурлык, тынычлыкка бер мизгелдә нокта куела. Сугыш! Илне дә, авылларны да кара сөрем томалый. Халык көндә нинди хәбәр булыр икән дип, Левитан тавышын тыңлый... Үлем, кырылыш, авыллар, шәһәрләр юк ителә. Елап калды авыллар да, балалар да, игеннәр дә... Бишектәге сабыйлар бу сүзне аңламады, әтиләренең аларны ни өчен болай каты кысып сөюләрен дә абайламыйлар. Сугышның ни икәнен аңлап бетермәсәләр дә, бала-чагалар әниләре күзләреннән агып төшкән яшьләрне күреп, сагая калалар. Икенче көнне үк сугышка чакырып повесткалар килә башлый. Башта фронтка яшьрәкләрне алалар. Аларның күбесе 1941-1942 нче елларда билгесез югала да. һәр көнне диярлек сугышка чыгып киттә Каенлы авылының ир-егетләре. Авыл халкы әрнеп, елашып, яулыкларын болгап, басу капкасына кадәр озата баралар. Күпме Каенлы авылының баһадир ирләрен сугышка озатып калды икән авыл капкасы? Ул капка хәзер юк инде. Аның аша автобус тукталышына илтә торган юл үтә. Солдатлардан өч почмаклы хатлар килә башлый. Беркем берни яшерми, күбесе бергәләп укыла. Хатларның эчтәлеге дә бертөрлерәк: башта озын-озын сагынычлы сәламнәр, өй, балалар хәлен сораштыру, аннары «Көтегез, исән булсак, бер кайтырбыз, кайта алмасак, бәхил булыгыз» кебегрәк җөмләләр. Күбесендә бер-ике җыр да язылган була. Сыгылып елый хатыннар. «Госпитальдә ятам», - дип язылган хатлар килсә, шатланалар, чөнки монысы инде исән калган дигән сүз. Авыл советы каршындагы баганага табак формасындагы радио эленгән. Левитан соңгы хәбәрне җиткереп тора. Тик сөенечле хәбәрләр генә бер дә ишетелми. Дошманнар әле бер, әле икенче шәһәрне алып торалар. Авылда хәлләр мөшкелләнгәннән мөшкелләнә бара: маллар ачыга, балалар ач, ягарга утыны юк. Ярый әле ул елларны Ташлык әрәмәсе була. Чаналар тартып, Зәй бозы өстеннән чыгалар да, юанрак әрәмә эзләп, балта белән чабып эшкәртәләр. Ботак, чыбык-чабыгын кисеп ташлыйлар югыйсә кул чанасына төяү читенләшә! Әрәмә урларга халык күбрәк төнлә

йөри - ул чакта каравылчылар кайтып киткән була. Әгәр алар эләктерсәләр, балтаңны алып калалар, бауларыңны чабып ташлыйлар.

Мәктәптә дә укулар хөртиләнә: укырга китап, язарга дәфтәр, язу каралары юк. Дәфтәр урынына иске китапларның буш битләренә язалар. Китапларны инде я берничә партага берне генә бирәләр, я бөтенләй юк. Кара ясау ысулын да табалар: казан астына утырган корымны кырып алалар да сөт белән кайнаталар. Ясаган караларны бәләкәйрәк шешәләрдә йөртәләр. Укытучылар һәр көнне сугыш хәлләрен аңлатып торалар. Кайчакта класс тәрәзә пәрдәләрен, кич белән өй тәрәзәләрен капларга кушалар, немец самолетлары күрмәсен, янәсе. Шундый куркыныч булып китә: менә-менә фашист самолеты очып килер дә бомбасын ташлар кебек тоела.

Шундый авыр чакларда авыр шартларда укысалар да, укытучылар бик таләпчән була. Яз көне унар фәннән имтихан алалар.

Күп гаиләләргә инде кара кәгазьләр килә. Каты яраланып кайтучыларда була. Болары инде «бәхетле кешеләр», алар исән калуларына сөенәләр. Бакчаларны эшкәртү тагын да кыенлаша. Көрәк белән казып чыгу озак та, авыр да. Анын да җаен таба халык. Чиратка куелган бер япьле сөрәнгә үзләре җигелеп сукалыйлар. Аларга балалар да булыша. Орлыгы җитсә, бәрәңге утырту бер ни түгел икән ул. Кайчакта заемын вакытында түли алмаган кешеләрнең утыртырга дигән бәрәңгесен дә алып чыгып китәләр. Бер сүз әйтмиләр, чөнки барысы да «Ил өчен!», «Җиңү өчен!». Җәйләрне көтеп алалар, чөнки туйганчы юа, кычыткан ашы ашыйлар. Сугыш еллары авырлыгы барысына да тия. Авыр булса да балалар үсә тора. Яшүсмерләр дип атый башлыйлар үзләрен. Олылардан калышмаска тырышып эшлиләр. Кинолар карарга да, аулак өйләр уздырырга да вакыт тапкан булалар. Аякларындагы чабатага да гарьләнмиләр, әниләрен борчымаска тырышалар. Ләкин бу матур яшьлек түгел инде.

Яшьлегемне сагынмыйм
Кояшка карап торамда,
Нурларына табынмыйм.
Сугыш елларында үткән,
Яшьлегемне сагынмыйм.
Яшьлек, яшьлек диеп сөйләп
Өзәләр үзәгемне.
Ә мин уйлыйм, ул елларда
Ничекләр түзгәнемне?!
Бер туйганчы ипи ашау
Керә иде төшләргә,
Булмады шул, ул чагында.

Ипиләре тешләргә!

Юа, чирәм... Төрле үлән

Кырыктык ничә тапкыр...

Кемдер яшьлеген сагына

Ә мин куркам, ул – кайтыр.

Кайтыр да, ул урап алыр,

Кара сөреме белән...

Үткән яшьлегемне, дуслар,

Куркып төлләрдә күрәм....

Яшьлекне сагыну шулай,

Була икән төрлечә.

Бәхетле яшьлек булсын ул, - дип яза Саимә апа.

### 1.2. Сабирҗан бабай

Йортларның төзеклеге, урамнарының тигезлеге, һавасының сафлыгы, еракларга сузылып киткән басу- кырлары белән Зәй елгасының куенына сыенып торган Каенлы авылында 1895 елның язында яшь гаилә - Ахунҗан белән Таифәнең олы шатлыгы булып дөньяга беренче балалары туа. Сабирҗан дип исем кушалар. Гаиләдә ир бала туу бик зур сөенеч китерә. Патша фәрманы кушуы буенча ир балаларга җир кишәрлеге бирелә.

Бәләкәйдән үк җор, бөтерчек кебек җитез була ул. Бере артыннан икенчесе, өченчесе, җиденчеседә туа. Сабирҗан, Хуҗаҗан, Гарифҗан, Ибраһим, Габделәхәт, Җәмил, Сания һәм Зәйнәпләр...

5 малай! Тансыкка арада ике кыз да бар.

Тату гаилә барысына да куанып, сөенешеп яшиләр. Җир дә күп тия Ахунҗаннарга: эшлә дә, эшлә генә. Балалар да кул арасына керәләр.

Ахунҗан җирдән нык файдаланып, мал – туар да асрый. Аның сабаннар да катнаша торган атлары да була. Бер генә минутын да бушка уздырмый Ахунҗан. Күрше авыллардан йомырка җыеп, каядыр алып барып товарга алыштырып кайта да, халыкны керосин, галош, читекләр белән тәэмин итә башлый.

Үзенә күрә бер генә тәрәзәле кладовой җиткерә. Өзелми авыл халкы, әйбер сорап төнлә дә килүчеләр була. Бер үк кибеттә кызыл мал да, тоз да, керосин һәм башкалар сатыла. Юеш ихата салкын бит. Ахун исә үз эше белән һаман күрше - тирә авылларга йөри. Каенлы авылының як- ягында рус, керәшен авыллары. Барысы белән дә уртак тел табарга кирәк. Руслар аны яратып “ Наш Ахунка” дип кенә йөриләр. Бигрәк тә Сухрау, Ширәмәт яклары. Гаилә арткач, Ахун алты почмаклы өй дә салып куя. Кырда да эш туктамый, вак булса да

сәүдә дә үтә. Әмма кулак итеп куылгач, ярлылар комитеты бу өйне сүттереп, кемгәдер өй төзеп, Ахун караңгы мунчасында кала.

Үз кул көче белән үз хезмәтеннән тәм табып, алты бала үстерүче сәүдәгәр Ахун гаиләсе өчен бик авыр булган ул революция дигән җәфа. Чын мәгънәсендә җәфаланган байтак гаиләләр. «Ярлылар оешмасы» колхоз төзү чорлары, тагын әллә нинди комитетлар хәллерәк гаиләләрне бөтенләй юкка чыгарганнар. Аларның йорт-җирләрен, мал-туарларын талап алганнар, туган авылларыннан сөргәннәр. Ахун гаиләсе дә бүген- иртәгә сөрелүне көтеп, таланганнан калган кара мунчада яши башлаган. Аллага шөкер, бу гаилә сөрелмәгән. Каенлы авылында читкә сөрелүчеләр булмаса да, таланучылар байтак була. Шул ачуданмы, әллә инде алда ни буласын чамалаганнармы, берничә гаилә колхозга барыбер кермәгән.

Ахуннар керә керүен. Олы уллары Сабир да. Акбәкәлен (данлыклы атын) колхозга биргән. Сабирҗан абый - актив, әллә кайларда укымаса да, гарәпчәсен дә, русчасын да шартлатып белә. Озак еллар авыл советында эшләгәнлектән, аңа киңәш сорап күрше-тирә авыллардан да киләләр. Хәтере дә яхшы була. Бертөсле сугыш ачысын кичергән фикердәшләре Ульданов Сәубән, Ризатдин абый, Фәхертдин карт белән сөйләшер сүзләре күп, тарих язалар, нәсел җепләрен барлыйлар алар.

Истәлекләр, уйлар, фикерләр! Һәр кешенең дә йөрәгендә генә сакланып яшәгән мәңгелек истәлекләре була торгандыр, мөгаен. Ничәмә-ничә тапкыр ул истәлекләрне башыңда яңартып, күңелең белән яңадан кичереп, гомереңнең үткәнен дә сизми каласың. Әйе шул, ага торган Зәй сулары кебек бит ул гомер дә: әйтергә теләгәнеңне әле әйтермен, әле сөйләрмен, әле язармын дия-дия соңарып та каласың.

1914 нче ел. Империалистик сугыш башлангач, унтугыз яше генә тулган Сабирҗан абый кулына корал алырга мәҗбүр була. Сугышта аны немецлар әсирлеккә төшерәләр, Германиядә күргән әсирлек газапларын ул әрни-әрни гел сөйли торган. Әсирлек көннәрендә нинди газаплар күрүен үзе генә белеп түгел, авылдашларына да, еш сөйләгән ул. Аңа бер немец бай хатын ихатасында хезмәт итәргә туры килгән. Шунда күргән кимсетелүләр аның йөрәгенә тирән сеңеп калган булса кирәк. 5-6 ел әсир булуының Сабирҗан абыйга файдасы да тия. Ул чип- чиста немецча сөйләшергә өйрәнеп кайта. Әмма туган туфрагына кайткач, авызыннан бер генә дә немецча сүз дә кыстырмый ул. Бар нәрсәдән дә куркып яши. Дөрес аны кимсетмиләр, шулай да кулак малае дип курка ул.

1921 нче ел. Каһәр суккан ачлык еллары. Сабирҗан бабай шушы елны өйләнә. Озак еллар авыл советында сәркәтип булып эшли. Хыялы вак сәүдәгәр булуһәм игенчелек белән шөгылләнү. Кая инде ул! Хәзер эләктереп алырлар.

Башка эшләр дә җитәрлек, барысына да өлгерергә, барысына да ярарга кирәк. Гаилә дә зурая, ике кыз, ике малай үстерәләр: Икълимә, Гамир, Саимә, Хазим. Җәмәгате дә колхоз эшеннән калмый. Матур яшиләр алар.

Буш вакытларында тарих (авылның үткәне), нәсел җепләре белән кызыксына. Үз тирәсенә фикердәшләр туплый. Исламов Ризатдин, Ульданов Сәүбән (ул империалистик сугышта бер аягын өздереп кайткан, шуңа күрә кушаматы аксак Сәүбән) Керешәләр болар авыл тарихын барларга. Сабир бабай сугышка кадәр дә, сугыш башланганда да авыл советында секретарь булып эшләгән. Аерым мәктәпләр дә укыган булмаса да, аны белүче картлар бик "башлы" иде Сабир дип сөйлиләр. Әле аңа тарих укытырга да кушканнар, өч тапкыр үтенеп килсәләр дә, грамотам әз дип, укытучы булып китмәгән. Чыннан да ул оста тарихчы да булгандыр, чөнки авыл шаҗәрәсен язуны да ул башлап җибәргән, әмма сугыш барысына да киртә куйган.

Менә 1941 нче ел. Монысы инде аның өчен һич гафу ителмәслек сугыш. Сугышның, бигрәк тә немецлар белән сугышның нәрсә икәнен татыган Сабирҗан абыйга моны аңлавы читен түгел. Сугыш авыл ирләрен чүпли башлый. Башкалар белән бергә ахуннныкылар да фронтка китә. Сабирҗан абыйның дүрт туганының инде икесе һәлак була.

Әле генә үткән сугыш газаплары аны төшләренә кереп бимазаласа, бусы инде-тагын куркыныч иде....

Күпләп, күпләп ир-атларны сугышка озаталар: китәләр, китәләр, китәләр.

Сабир бабайның элекке тәҗрибәсе булганга кичкә кергәч, ул авыл яшьләрен корал тотарга "атарга" өйрәтә.

Инеш буе "на плечо!" "Айт- два, по-плостомски" – дигән тавышлар белән яңгырап тора...

Иртән торсаң, кич ятсаң гел бер сүз! Тагын кемнәрне алдылар икән?..

Ул да булмый кара язулар да килә башлый. Үлүче- кырылучы яшьләр күбәя...

Менә Сабир бабайның туганнарының да кара язулары килә башлый:

Ахунов Габделәхәт, Ахунов Хуҗа, Ахунов Салих

Ахунов Ибраһим (әле дүртенче баласына бер генә яшь була). Түзмәгән Ахунов Сабир абый бу хәсрәткә. Яше олы булса да, хәрби комиссариятка үзе теләп сугышка китәргә теләген белдерә. Сугыштагы энесе Ахунов Җәмилгә язган хатында мондый юллар бар: "... һәр көн, һәр сәгать сугышка алуларын көтеп, телефон янында торам". Яше шактый булгангамы, әллә инде эше җаваплы дипме, аңа бер ай тирәсе җавап килми. Энесе сугыштан яраланып кайткач, ул хатны әбиемә тапшырган булган (ул хат әле дә исән).

Менә 1942 нче елның 14 нче апреле. Сабирҗан бабайга повестка килгән көн. Апрель... Авыл халкы җыйнаулашып Сабир бабайны армиягә озата. Юл өзелер-өзелмәс кенә ни чана, ни арба юлы. Өч баласын җитәкләгән хатыны (дүртенчесе әле биш кенә яшьтә

өйдә кала) авыл капкасына кадәр озата бара. Бабай саубулашканда күз яшьләрен күрсәтмәскә тырышып, үзен озата баручы Хәсәнша бабай чанасына арты белән менеп утыра. Бер генә җөмлә әйтә дә Сабир чаныга йөз түбән капланды, - дип сөйләгән Хәсәнша бабай – “Их, каласың Каенлым ике мәчетең белән...”

Хатыны өч баласын кочаклап юл өстендә таш кебек катып калган...

Юк, таш кебек катып торырга вакыт булмаган ул толларга “Сталин өчен, ил өчен!” лозунгасы астында яши башлаган алар. Бу җөмләләрне язганда Саимә апаның түбәндәге шигырь юллары искә төшә:

Сугыш елы авырлыгы

Барыбызга да тиде,

Хәерниса ат караса,

Маһруй бригадир иде.

Алма кебек Зөһрәләр

Яшь көе тол калдылар

Колхоздагы авыр эшне

Алар тартып бардылар

Әйе, армиягә озата тордылар-кара язу килә торды.

Сабирҗан бабай– өлкән сержант, булган һәрвакыт, алгы сызыкта. 4 ел буе хатлары килеп торган (аларның күбесе хәзер дә исән әле) “Тиздән наступлениягә керәбез”. Русчалатып “Наше дело правое, мы победили” дигән сүзләре кабатланган. Сабирҗан бабайны башта берничә ай курсларда укыталар. Менә шул вакытта күп язган инде ул хатларын. Бер хатында шундый юллар бар: «... үзем, бәлки, старший сержант булып куярмын, курсларны яхшы билгеләргә генә бетердем.

Үземә... ай өчен 100 сум хезмәт хакы бирделәр. Менә бүген танк һәм лоторий билетына язылдык, аңа 65 сум түләдем дә инде...

...Без монда чишенеп ятмыйбыз, һәрвакыт, һәр минут гитлерчы этләрне тар-мар итәргә әзер торабыз. Без ил өчен үләргә сүз бирдек. Исән калсак, кайтырбыз, кайта алмасак, бәхил булыгыз. Җиңү безнең якта булачак. Исәнлектә күрешик. Хушыгыз, атагыз Сабирҗан. 30.07.1942» Аның хатлары еш килеп торды. Кайсы көнне икешәр, өчәр хаты килер иде. Хатынына гарәпчә язса, балаларына татарча яза. Хатларында туган авылны, гаиләсен, балаларын өзелеп сагынуы тасвирлап язылган. Күп вакыт шигъри юллар, я булмаса җырлар өстәп куя: «Мылтык атам туры итеп, Туры итеп, төз итеп. Балаларым, хатны укыгыз, Шат итеп, күңелле итеп. «Ахунов» дип язып куйдым Билемдәге каешка. Тәмле йокымнан уянам «Әткәй» дигән тавышка. Икълимә кер юган ташлар Бардыр Зәй буйларында. Әткәйне күрми үләм дип, йөргәндер уйларында». Аның Икълимә исемле кызы кер чайкаган вакытта фаҗигале төстә һәлак була.

1942 нче елның 23 нче мартында сугышка алынган энесе Ахунов Җәмилгә язган хатында мондый юллар бар: “Здравствуй, мой дорогоценный брат Замиль! Ставлю Вас на известность и заявляю, что немцы убили нашего брата Ибрая. Никогда не забуду и не пощаду врагов... Шлю тебе ... приветь и желаю победу над врагом. Бей гитлеровских собак не щадя своей жизни, как они Ибрая убили, дорогого нашего брата. Наша дело правая, победа будет за нами. Бей их несмотря ни на что... этих гитлеровских собак... защищай нашу Советской родины. Мы крепляем наш тыл, а ты бей немецких собак...

Теперь из братьев осталсы я один, на днях и я поеду сам. Буду драться, как я дрался раньше с немца. Замиль, я сегодня получил от тебя письмо и не отходя от сельсовета жду ответ от военкомата. Замиль, ставлю в известность о том, что папа и сестра Зайнаб живы и Аклима, Гамир, Саима, Хадим живы, Хузи взяли в стройбат. Меня поставили обучать молодых и старших для обучения на пункт на военное обучение... Мы победим, враг будет уничтожен.”

Бу хатны яраланып кайткан Җәмил абый хатынына биргән. Моннан җитмеш еллар элек язылган бу хат әле дә исән, тик хәзер аның кайбер урыннарын укып та булмый инде. Сабирҗан абый ни өчендер бу хатны рус телендә язган. Рус мәктәпләрендә укымаса да, тормыш өйрәткәндер инде. Ул елларда солдат хатларына цензура да көчле булган. Шиклерәк сүзләр булса, ул хат юкка чыгарылган. Нигә шулай булмасын, ачып карарга җайлы өч почмак хатлар бит алар. Кем хаты кемгә кадерле!? Бердәнбер язылган хаты килеп җитмәүчеләр дә күп булгандыр. Бу хатлар төргәккә төрелгән булсалар да, хәзер инде алар бик тузган, бик саргайганнар, күп сүзләрне танырлык та түгел.

Аны исән кайтыр дип көтәләр. Ерак Польша җирләрендә ятып калган мәңгегә. Чолганышта калган пулеметны алып чыккан өчен аңа “За отвагу” медале бирелгән. Бу батырлыгы турында “Ватаным” газетасында материал да чыккан. Аны укыган бер авылдашы сөйләгән икән.

Мәскәүдәге Истәлек – Память дигән китапта да Сабирҗан бабай турында язылган. 1945 нче ел. Ул рота командиры. Урман буенда хәл җыялар. “Туганнар тиздән сугыш бетә, озакламый өйгә кайтырбыз”,-ди. Шул арада урман эченнән фашистлар килеп чыга...һәм каты һөҗүм башлана. Бу 23 нче март көне була. Сабирҗан бабай немец пулясыннан, урманнан ерак та булмаган бер елга кырында чалкан авып төшә.

Мәңгелек истәлек булып хатыны учында йомарланган кара язу гына кала. Кабере- Кенигсберг, Польша, Пруссия, Гданск 7нче каберлек.

Үзең теләп киткәнсең син
Туган илне сакларга
Җинеп кайтырбыз дигәнсең
Өйгә язган хатларда
Еракта ятып калсаң да,
Бергә безнең теләкләр

Озатасың әле безне

Теләп изге теләкләр.

Балаларның газиз әтисе

Тол калганның иң-иң якына…

Барысы таныш, барысы кадерле-

Күргәннәргә бирсен сабырлык һәм

Кабынмасын сугыш ялкыны! – дип яза кызы Саимә апа үзенең “Әй Каенлым, Каенлым” дигән китабында. “Бик күп була иде эткәйнең җыр – шигырьләре хатлары эчендә, хатларны кайчакта һәр баласына аерым – аерым да язар иде, дигән юллары да бар.

**1.3. Каенлы авылының сугыш кырларында һәлак булган батырлар исемлеге.**

Әйе, армиягә озата торалар-кара язулар килә тора. Каенлы авылыннан гына да 150 гә якын кеше озатылган. Яртысы диярлек әйләнеп кайтмаган. Күбесенең әле дә кайда җирләнгәне билгеле түгел. Бер гаиләдән бишәр кеше үлгән.

Таш һәйкәлгә тезелеп киткән:

Ахунов та, Ахунов...

Алты улын озатканда

Ничек түзгән Ахуны.

Әхтәмов Сабирҗан Әхтәм улы

Әхтәмов Мәгъсүмҗан Әхтәм улы

Ахунов Сабирҗан Ахун улы

Ахунов Хуҗаҗан Ахун улы

Ахунов Салихҗан Хуҗаҗан улы

Ахунов Ибраһим Ахун улы

Абдуллин Йосыф Абдулла улы

Баязитов Лотфулла Гайнетдин улы

Борһанов Илһам Борһан улы

Вәлиуллин Камил Вәлиулла улы

Вәлиуллин Салих Вәлиулла улы

Вәлиев Госам Миңлевәли улы

Гайфетдинов Мөхәм Гайфетдин улы

Гайфетдинов Салих Гайфетдин улы

Гыйльфанов Харис Гыйльфан улы

Гыйльфанов Фәхрулла Гыйльфан улы

Гомәров Госман Гомәр улы

Галиуллин Нури Галиулла улы

Гәрәев Равил Миңлевәли улы

Динмөхәмматов Вәгыйз Хәмидулла улы

Ибраһимов Юныс Ибраһим улы

Ибраһимов Вәли Ибраһим улы

Ибраһимов Харис Ибраһим улы

Исламов Хуҗа Шәйхетдин улы

Ибраһимов Исхак Ибраһим улы

Камалов Әхмәдулла Фәррах улы

Кәбиров Салих Фәсхи улы

Мөбәрәкшин Фәһемша Мөбарәк улы

Мөфтиев Гариф Сәләх улы

Нәбиуллин Әхмәдулла Нәби улы

Нигъмәтҗанов Гомәр Нигъмәтҗан улы

Нуриев Гаяз Нури улы

Ризатдинов Наил Ризатдин улы

Рәхимов Салих Рәхимҗан улы

Рәхимов Харис Рәхимҗан улы

Салаватов Габдулла Салават улы

Сибгатуллин Исмәгыйль Сибгат улы

Сибгатуллин Ибрай Сибгат улы

Сафин Хәйрулла Хәмидулла улы

Сибгатуллин Сибгатулла Сибгат улы

Сәләхов Хафиз Сәләх улы

Ульданов Ибраһим Әхмәтгәрәй улы

Фәсхиев Мөслих Фәсхи улы

Фәйзуллин Ибрай Миңгали улы

Хәйруллин Гомәр Хәйрулла улы

Хәйруллин Харис Хәбибулла улы

Хөсәенов Шәйхетдин Хөсәен улы

Хәмидуллин Нурулла Хәлиулла улы

Хәмидуллин Хәкимулла Хәлиулла улы

Хәмидуллин Нәбиулла Хәлиулла улы

Хәсәнов Салихҗан Хәсәнҗан улы

Хәсәнов Галимҗан Хәсәнҗан улы

Хәмидуллин Борһан Хәмидулла улы

Ханов Миңлебай Миңлехан улы

Ханов Ибрай Миңлехан улы

Ханнанов Харис Ханнан улы

Хөснетдинов Фәррәхетдин Хөснетдин улы

Шәмиев Нурмөхәммәт Габдулла улы

Шиһапов Мөсләх Шиһап улы

Шәкүров Гаттар Газзалый улы

Шәйдуллин Һадиулла Габдулла улы

Юнысов Зариф Юныс улы

Юнысов Әгъләм Юныс улы

Яруллин Миңлебай Хәйрулла улы

Яруллин Исмәгыйль Хәйрулла улы

Шәкүров Сәүбән Сөләйман улы

1.4 Каенлы авылына исән-имин әйләнеп кайттылар:

Ахунов Җәмил Ахун улы

Әхмәтов Вафа Әхмәтсафа улы

Әхтәмов Гарифҗан Әхтәм улы

Бикчәнтәев Фәйзелхак Солтан улы

Гайфетдинов Салих

Гайфиев Шәйхелислам Мөхәмәтдин улы

Галиуллин Фаяз Заһидулла улы

Гарифуллин Шәйдулла

Гомәров Габдрахман Гомәр улы

Гыйльманов Гата Гыйльман улы

Гыйльфанов Гариф

Гәрәев Миргасыйм Вәли улы

Зыятдинов Фәррах

Ибраһимов Госман

Ибраһимов Исмәгыйль

Ибраһимов Харис

Исламов Салих

Камалов Фәррах Камали улы

Касыймханов Әхтәмхан Касыймхан улы

Кәлимуллин Нурмөхәммәт Әлмөхәммәт улы

Маликов Ибраһим Малик улы

Мәрдеханов Сәгыйдулла

Миңлебаев Закир

Миңлебаев Хуҗа

Миңлевәлиев Харис

Миңлегалиев Исмәгыйль

Миңлегалиев Харис

Мөбәрәкшин Дәүләтша

Нәбиуллин Гыйльмулла

Нигьмәтҗанов Юныс Нигъмәтҗан улы

Нигьмәтҗанов Галимҗан Нигъмәтҗан улы

Хәмидуллин Нурулла Хәлиулла улы

Хәмидуллин Хәкимулла Хәлиулла улы

Хәмидуллин Нәбиулла Хәлиулла улы

Хәсәнов Салихҗан Хәсәнҗан улы

Хәсәнов Галимҗан Хәсәнҗан улы

Хәмидуллин Борһан Хәмидулла улы

Ханов Миңлебай Миңлехан улы

Ханов Ибрай Миңлехан улы

Ханнанов Харис Ханнан улы

Хөснетдинов Фәррәхетдин Хөснетдин улы

Шәмиев Нурмөхәммәт Габдулла улы

Шиһапов Мөсләх Шиһап улы

Шәкүров Гаттар Газзалый улы

Шәйдуллин Һадиулла Габдулла улы

Юнысов Зариф Юныс улы

Юнысов Әгъләм Юныс улы

**Йомгаклау**

Эш барышында куйган максат һәм барлык бурычлар чишелде. Өлкән буын кешеләреннән, бигрәк тә, ветеран укытучы Саимә ападан сорашып күп мәгълүмат тупладым; авыл советына, авыл китапханәсенә, авыл мәктәбенә мөрәҗәгать иттем; сугышчы Сабирҗан бабай истәлекләрен, хатларын җыйдым; шәһәр музееның “Сугыш” экспозиция материаллары белән таныштым һәм нәтиҗә ясадым.

Бервакытта да җирдә сугышлар, кан коюлар булмасын иде. Дөньялар имин, тыныч булсын!

Эшемне төгәлләп, шуны әйтергә телим, Каенлы авылының сугыш батыры Сабирҗан бабай исеме дә сугышның зур сынаулар икәнен дәлилли.

Кулланылган әдәбият:

1. “Әй, Каенлым, Каенлым” Саимә Сөләйманова. – Казан : “Милли китап” нәшрияты, 2009.

2. Каенлы авылы тарихы Фәхри Шәрәфиев. – Казан : “Сүз”, 2009.

3. “Зәй сулары ага тора ...”. Саимә Сөләйманова. Татарстан Республикасы, Түбән Кама. ”Гүзәл” НПҮ ААҖ. 2013 ел.

**«Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын»**

**Бөтенрәсәй форумы материаллары**